Камил Кәримов

# Уен

Роман, хикәяләр һәм
Юморескалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
К95

**Кәримов, К.Ә.**

Уен : роман, хикәяләр һәм юморескалар / Камил Кәримов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 367 б.

ISBN 978-5-298-01852-4

Танылган язучы Камил Кәримовның яңа китабына соңгы елларда язылган «Уен» романы, хикәя һәм юморескалары тупланган. Автор үзенең утыз еллык иҗат кыйбласына тугры кала – сурәтләнгән вакыйгалар лирик юморга һәм коллизияләргә искиткеч бай.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01852-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Кәримов К.Ә., 2010

# Уен

*Роман*

## Үҗәт көзгеләр каршында

Кемдер аңа ике сәгать буе залдан комсызланып текәлеп утырды. Мең кеше арасыннан аерылып торган явыз, хөсетле, хәлне алырдай караш иде бу. Концертның икенче бүлеген көчкә ерып чыкты Сөмбелә. Саубуллашып, сәхнә алдына баш иярgә килгәндә, алып баручы яшь егетне култыклап өлгерде, мактаныр өченгә түгел, алай-болай сөрлегеп китмәгәем диде...

Менә хәзер ул кеше бизәнү бүлмәсенең ишеген шакыр. Керә-керешкә үк концертка мәдхия укыр, иң яраткан җырчым – Сез дип, кулын үбәр. Өченче звонокка чак өлгердем, соңга калмас өчен сәгатенә йөз егерме миль белән кудым, чәчәк кибетенә сугылырга вакыт калмады, дияр. Күкрәк кесәсенә ашык-пошык тыгылып, симез бумажнигын чыгарыр, кабаланып чылбырын аерыр һәм җыр китабы калынлыгы яшел акчалар арасыннан алтынлы-гөлле визиткасын алып бирер. Төннең теләсә кайсы вакытында мобильнигыма шылтырат, концертларыңны оештырырга ярдәм итәрмен. Главалар арасында дусларым бик күп, аларга минем бер сызгыруым җитә, дияр... Тагын нindидер мактанулар, алдагы планнар турында сорашулар, очрашуга өметләр... Сөмбелә, әлеге визиткага күз йөгертеп чыккач, күнегелгән миһербанлык белән: «Оhо! Сез бик зур кеше икәнсез!» – дип соклангандай итәр.

Соңгы вакытларда җырчыбыз грим бүлмәсенең ишекләрен бикләп утыра башлады. Концерт алдыннан бизәнсә дә, соңыннан юынса да – янына иптәшләрен кертми торганга әверелде... Кермәсеннәр, күрмәсеннәр, көлмәсеннәр, кызганмасыннар...

Бизәнер өчен аңа ким дигәндә ике сәгать вакыт кирәк. Ак вертолет белән сабантуй аланына алып китәләрме, теплоходка төялеп чит илгә чыгамы, әллә автобус белән Сургут каласына барып җитәме – барыбер, Сөмбелә әнә шул ике сәгать вакытны алдан ук исәпләп куярга тиеш. Аппаратураларны бушатып, микрофоннарны көйләр өчен ярты сәгать җитә. Ә калганы җырчыга бизәнер өчен китә.

Сөмбелә бизәнгән арада төркем эшсезлектән интегеп тик йөри. Баянчы пыяла кружкага чыбык батырып чәй кайната, биючеләр туктаусыз тәмәке тарта, музыкантлар кыланчык шешәләрдән сыра имә, антураж дип алынган икенче җырчы арзанлы күлмәген тигезләргә үтүк эзли. Артык иртә алып килгәне өчен төркем Сөмбеләнең үзенә ишеттермичә генә зарлана, әрли, әрәм үткән шушы ике сәгать эчендә Казанда эшләнергә мөмкин булган, ләкин бүленеп калган файдалы эшләрне саный. Гадәттәгечә...

Күңел ачу учаклары базарга авышканнан бирле концерт заллары, сәхнәләр эреләнде. Хәзер инде авыл клубларында чыгыш ясау артистлар өчен чынга ашмастай хыялга әверелеп бара. Зур залларның сәхнә арты да иркен – бер яктан икенче якка күчкәндә сөртенмисең, бәрелешмисең, тырпаеп торган кадакларга эләгеп ертылмыйсың... Грим бүлмәләре дә күбәү. Сөмбелә үз янына һичкемне кертми, бикләнеп бизәнә.

Сөмбеләнең тамашачысы концерттан соң бик тиз тарала. Шушы Чаллы, шушы ук зал бит инде югыйсә... Әле ун ел элек кенә... тәнәфес игълан итәр хәлең юк – сәхнә артына тамашачы тула. Фотога төшик дип, крутойлар ыгы-зыгы килә, әби-апалар кассета сатып алырга тели, мәктәп балалары автограф сорый. Кайбер кылтым егетләр, иренегезддәге иннекнең эзе битемә төшсен әле, дигән булып, туганнарча гына үбешүгә өметләнә... Концерт ахырында пәрдәне ябып өлгермисең – ярты зал сәхнәгә менеп баса, кием алыштырырга ашыккан җырчыны җибәрми тора, микрофон чыбыкларын җыярга ирек бирми, «Газель» йөртүченең кайтырга дип юлга ашыктыруын колакка да элми. Тамашачы һаман тантана итә... Әйе, һәрхәлдә элек шулайрак иде.

Җыр сәнгате бик авыр эшкә әверелеп бара.

Данлыклы Чаллы залы Сөмбеләгә дә суынды. Залның җан җылысын кайтарыр өчен сыналган йә сыналмаган яңа ысуллар уйлап табарга кирәк. Әлбәттә, элек тә концерт залының кеше күзе төшәрдәй һәр почмагында бер-ике буш урын була торган иде, тик бүгенгечә күпләп түгел...

Сөмбеләнең бүген никтер ишекне бикләргә кулы бармады. Биек көзгеле өстәлләрнең уртадагысына терәлеп утырды. Лавсан букчасыннан чәчәкле салфетка табып алды. Ләкин аны бизәнгән килеш нурланып торган битенә тидерергә ашыкмады. Бүлмәнең өч як стенасына тигезләп эленгән көзгеләрдән кимчелек эзләде. Күпне күргән алдавыч көзгеләр Сөмбеләнең барлыгын төрле яклап күзәтеп тора. Бу бүлмәдә күпне күтәргән урындыкның шөрепле буыннарын шыгырдатып һәр көзгегә борыла-борыла карый торгач, аның үзеннән гайрәте чигеп куйды... Айның җиргә күренми торган салкын ягы булган кебек, артистның да тамашачыга күренми торган ягы бар. Дөрес, сәхнә кануннары кушканча, залга арт белән басу тыела. Эстрада җырчысы сәхнәдә бөтерелеп тормаса, халык аны ветераннарга тиңли башлый. «Тиз арада җиде-сигез килога ябыгырга кирәк, – дип уйлап куйды Сөмбелә, – элек мин җәй көне коелып бетә торган идем...»

Грим бүлмәсендәге һәр көзге, аның чамадан чак кына артып киткән килбәтен аеруча күрсәтеп, бәхәскә керергә тели иде сыман. Сул стенадагы көзгеләр: «Син бу күлмәгеңне Зилә Сөңгатуллина үрнәгеннән күчердең, нечкә билле, чатыр итәкле күлмәк сиңа килешми. Безгә ышанмасаң, әнә ишеккә кагылган арткы көзгедән сора. Синең кулбаш сөякләрең өрелде, торыгың кыскарды, табаның җәелде», – диләр. Алдагы көзгеләрдә: «Өске өлеше иңенә сыланып тормаса, күлмәгеңне хет өрфиядән тектер – барыбер килешмәс», – дигән чагылыш бар. Грим бүлмәсе белән бүленеп калган озын идәннең теге ягында егетләр аппаратура җыялардыр, дөп-дөп атлаулардан уң стенадагы көзгеләр тыпырдый. Тыпырдап, дерелдәп үчеклиләр кебек: «Бенефисыңа утыз җиделе башмагыңны капларлык озын күлмәк тектер. Итәгеңнең бер ягыннан ерык ач. Ерыгы зуррак булган саен, артист яшьрәк күренә. Сиңа инде миңле ботыңны төбенә чаклы күрсәтсәң дә таман булыр...»

Ишекне шакучы юк... Сөмбелә, ниһаять, каршысында күзенә терәлеп торган көзге тоткынлыгында калды. Муенына көмеш чылбыр белән эленгән тугыз ташлы кулонын сөяк пеналга салды. Алкалары юк аның, гомергә алка такмады, хәтта колагын да тиштермәде. Ясалма керфекләрен куптарып алды. Чылбыры вак-вак бөҗралардан торган көмеш сәгатен ычкындырды. Пеналда һәммәсенең аерым бүлеме бар иде. Һәм үз чыраена үзе каты бәгырьле карар чыгаргандай, кулындагы юеш мамык кисәге белән әле маңгаена, әле битенә аркылы-торкылы эзләр төшерде. Майлы кершән белән алсуланган мамык чеметемнәре, өстәлгә өелгәч, көзгедәгесе белән ике күч булып күренде. Күз читендәге ерганаклар тирәнәйде, маңгай чәче астында яшеренеп яткан сызыклар, башны югары чөйгәч, бераз әзәйгән кебек булды. Иреннең чия кызылын кәгазь киптергечкә күчереп бетергәч, ул яңадан кызгылт көрән иннек ягып куйды. Йөзендәге җиңеллектән хәтта кәефе күтәрелгәндәй булды. Көзгедән калын соры кашлы, киң маңгайлы, коңгырт күзле, җыры бүленеп калган бөрмә иренле, Казанга качып килмәсә, Акъярда менә дигән авыл укытучысы була алырдай Сөмбелә апа карап тора иде... Бик озак киелеп, озак салына торган купшы яшел күлмәк эченнән чыгып спорт костюмын да киеп өлгерсә, артист үзен яртылаш кайтып җиттем дип исәпли ала.

Сөмбелә, ике кулы белән үрелеп, күлмәк артындагы «молния» каптырмасын аермакчы иде, ишекне бикләргә онытканын исенә төшереп сискәнеп куйды. Кырыкмаса-кырык тапкыр алышынган чыбык элгечкә килеп кагылган гына иде, кемдер ишек шакыды. Әгәр шушы мизгелдә ул «Керегез, ишек ачык!» дип дәшсә, оятка каласы иде. Ник дигәндә, янына керәсе кешене әллә кайчаннан бирле ишек төбендә көтеп торган кебегрәк килеп чыга бит бу.

Сөмбелә, аяк очларында гына йөгереп дигәндәй, көзге янына килеп басты:

– Керегез, кер, мин киенгән! – диде ул, өстәлдәге мамык өемен учына йомарлап.

Ишек ачылмады, әмма кабат шакыдылар.

– Керегез! Әйтәм ич, ишек бикле түгел! – Бу юлысы Сөмбелә, каршы алырга килүен сиздерергә теләп, үкчәсенә катырак басып атлады.

Теге якта сап-сары розалар тулы кәрҗин басып тора иде. Чәчәкләрне югары күтәргәнгә үзе күренмәгән алты яшьләр чамасындагы бер кыз, бүләкне җырчы апасына тапшыргач, йөгереп китеп барды. Әгәр концерт күлмәген алыштырып өлгергән булса, Сөмбелә ул баланы куып тотар, шап-шап итеп сөяр, ягымлы сүзләрен кызганмас, исемен сорар, кем кызы икәнен әйттермичә калмас, һичьюгы, бүлмәгә алып кереп, сумка төбендәге хәзинәдән берәр конфет тоттырып тоткарлар, сары розаларны үз куллары белән тапшырырга оялган абзагызны... әйе, әйе, һичшиксез абзагызны, бүлмәгә керергә мәҗбүр итәр иде.

Ут сүнеп алды – монысы инде зал хуҗалары телендә «Ашыгыгыз, вакыт бетте!» дигәнне аңлата. Хәзер исә эчтән бикләнгән грим бүлмәләрен каерып ачардай булып әүхәт белән вахтер килеп җитәр. «Ачкычларны тапшырыгыз!» дигән әмере ишетелә дә инде. Вахтерның кырыс тавышыннан шунысы аңлашыла ки: димәк, аренда түләве тиешенчә җыелмаган, зал ишеге төбендә торган контролерга, рубильникны күтәреп торган электрикка, мунчаласын залдагы җылы торбага киптерергә элгән идән юучыга, пыяла канатлы урам ишегеннән «Хуш киләсез!» дип каршы алып, «Барыгыз инде, бар, озак маташасыз!» дип озатып калучы вахтерга, оешмаларга билет таратучы әбиләргә, урам ягына белдерү ябыштыручы исерек рәссамга, ак пәрдәнең соры ягын әйләндереп, сәхнә түренә кәрҗин белән ясалма чәчәк чыгарып куйган ике эшчегә, авторлык хокукын сакларга теләгән оешманың вәкиленә – кыскасы, Казаннан артистлар килгәнне кул сузып көтеп торган Мәдәният сараеның барлык тамагына мәһәр азрак эләкте дигән сүз... Вахтерның тел төбендә әнә шул тамаклар исеменнән җыйналган өметсезлек. Ниһаять, ул кырыс тавышлы марҗаның түгәрәк гәүдәсе Сөмбелә каршындагы көзгедә пәйда булды.

– Господи! Битлеген салган, кабыгын һаман салмаган! Утны сүндергәч кармаланып чишенерсең, бел шуны!

– Чабата! Син бу түткәйне бәхилләттеңме әле?! – Сөмбеләнең ялварулы тавышы грим бүлмәсе ишегенә капланган вахтер аша сәхнә ягына таралды. Ләкин җавап әйләнеп кайтмады.

Чабата бу минутта әле һаман касса бүлмәсендә, саннары ышкылып беткән кесә калькуляторына баскалап, бүгенге концертның финанс хәлен исәпләп азаплана иде. Утның сүнеп алуыннан каушап, ул кат-кат санады.

Вахтер түткәй, Сөмбеләнең киткәнен көтеп алырга теләгәндәй, сөялгән урыныннан кыймшанмады.
– Узган атнада Уразаева концерты булды. Вәт халык ташкын булып килде ичмасам. Рәт арасында идәнгә чүгәләгән кешеләрне пожарниклар да куып чыгара алмады.
– Берәр круг биреп карасын әле. Икенче килүендә халык ничегрәк җыелыр икән, әйтерсез. – Сөмбелә үз тавышына мөмкин кадәр ясалма ягымлылык кертергә тырышты, ике арадагы сүз ыргытыш берүк әрләшүгә күчмәсен, концерт белән керердәй заллар санаулы гына, бу түткәй каршына әллә ничә килерсең әле.
Чишенә башласам, бәлки, ишек төбеннән китеп торыр бу дип, Сөмбелә күлмәгенең замогына үрелергә иткән иде, тик көзгедә сыланып калган чырайга тагын бер кат карагач кире уйлады...
Профессияң артист булсын да, аптырап утыр, имеш... Сөмбелә көзге каршындагы кәрҗиннән сап-сары розаларны пөхтәләп алды да вахтерга таба борылды. Көзге өстәле белән ишек арасында биш-алты гына адым булса да, ул бер тирән сулыш белән һәр чәчкәне иснәп өлгерде. Яшьлек хатирәләрен яңартып, югалтуларны барлап, сөелү минутларын күзаллап, туган якның көзге болыннарына әйләнеп кайткандай, канатланып сөенерлек халәт иде бу...
– Сез минем әниемә охшагансыз, бик матур кеше, мәгез әле, шушы чәчәкләрне өегезгә алып кайтыгыз. – Сөмбеләнең чәчәк бәйләме сузган кулы кинәт тартышкандай сискәнеп куйды... Ә бит урамдагы алтын көзнең үрнәгедәй сап-сары чәчәкләр арасында яшел сөенечләр булырга мөмкин. Бәлки, ул үзенең визиткасын йә булмаса куен дәфтәреннән кача-поса гына ертылган кәгазь кисәгенә телефон номерын язып җибәргәндер. Таныш бизнесменнар кулыннан алганда, чәчәкләр сабагында хәтта «уе»лар да ияреп килә иде.
– Кая әле, сынык башлы розалар эләкмәде микән, – дигән булып, ул вахтерга дип бүлеп алган бәйләмне аска таба каратып селкегән булды.
Юк, бәйләм арасыннан бер хәбәр дә коелмады, чәчәкләре дә исән-сау, әле тәнәфес вакытында гына Голландиядән кайтып төшкән кебек...
– Тик төнлә белән ваннага чылатырга салыгыз, яме, көндез шиңмәс алар. Сары розалар төнлә шиңә.
– Беләм, беләм, мин инде концерт саен чәчәк ташыйм. Бүген чәчәксез калам икән дип торам. Розаларны төнлә йөздерергә кирәген дә, көндез вазага ике сәдәф аспирин саласын да беләм. И, рәхмәт, миңа да букет бирәсезме?! Тавышыгыз матур сезнең. Җырларыгыз йөрәктән чыга. Татар булмасам да, кемнең тавышы кайдан чыкканны чамалыйм. Дворецта унбиш ел эшлим инде мин... – Аның тавышы әкренләп кырыслыгын югалтты һәм, ниһаять, якын киңәшчегә әверелде. – Еш киләсез шул. Афиша өстенә афиша ябыштырабыз. Артистлар үзара киңәшеп, чират саклап килсәгез, безгә дә күңелле булыр иде... Элек рәхәт иде, бөтен концертларны филармония билгели, айга бер генә бригада килә. Тамашачы да гел шул ук кешеләр, концертка дигән акчалары җыелып өлгерми хәзер.
– Апа, сез миңа булышыгыз әле.
Вахтер түткәй, утлы күмергә орынгандай кагылып, Сөмбеләнең күлмәк замогын ычкындырды да ашыгып китеп барды.
– Тынычлап, иркенләп чишенегез, мин ашыкмыйм, иртәнгә чаклы утырасы әле, – дигән сүзләре мышный-мышный чәчәк иснәве белән өзек-өзек бүленде.
Килеп җиттек, дисәләр киенә, бетте, дигәнгә чишенә, киттек, дисәң, күзен йомамы – җырчы инде ул! Мотор тавышын җиңеп, башкаларны уздырырга теләп сөйләшә һәм юл буе акырып җырлап кайта торганы музыканттыр йә тел бистәсе, рәсми телдә әйтсәк, алып баручыдыр ул кеше. Үз тавышын үзе хөрмәт иткән җырчы юлда һич җырламас һәм дә сөйләшмәскә тырышыр, кабинадагы катнаш һаваны турыдан-туры суламас өчен муенын борынына тиклем яка эченә батырыр. Йокымсырап барганда, тамак төбендәге тавыш җепселләре ял итә, көч җыя.
Сөмбелә арткы утыргычта колачын җәеп берүзе барды. «Алтылы» дип халык теленә кергән бу машина гадилегенә күрә бик йомшак, олы юлның шадраларын җиңелчә капшап кына үтә, арткы утыргычы офислардагы күн диван кебек сыгылып тора, баш астына берәр әйбер салсаң, йоклар өчен җайлы. Ләкин йокы дигәнең ике көнсез әйләнеп кайтмаслык итеп качты. Ян тәрәзәләрдән баксаң – язны көтеп кара шәүлә булып калган өнсез урман ишарәсе, арткы тәрәзәгә борылсаң – «Газель» уты күзгә төшә, алга карап барсаң – соры юлда фара нурларының туктаусыз эзләнүе машинаны агымга каршы ашкынган моторлы көймә кебек итә, башка каба. Көпчәкләрнең шыбырдавында су тавышы бар. Төннең тирән чагы. Әгәр шушы минутта таң ата алса, яз башланыр иде кебек. Кышның монысы да ялыктырды. Язның шулкадәр тансык чагы. Бу кадәр зарыгып, өметләнеп, хыялланып көткән мәлдә яз дигәнең кинәт килсәме – йөрәгең сөенечтән шартлар иде.
Чаллы юлы гүя алкын елга кебек, аның инде һәр борылышы, һәр күпере, якын-тирәдәге һәр уты таныш... Гомер дигәнең агымсуларга караганда тизрәк ага. Соңгы егерме ел эчендә Сөмбеләнең күргәннәрен елгалар куып тотарлык түгел...
Казанга кайтып җиткәнче, үз башыннан кичкәннәрне тәфсилләп искә алырга, ялыктыргыч вакытны онытылып үткәрергә була иде әле. Дүрт сәгатьлек хатирәләргә язмышның ничә вакыйгасы сыяр иде икән?.. Тик «алтылы»ның хуҗасы – Чабата – тынлыкны харап итте. Аңа берәүнең дә исеме белән

эндәшкәне юк. Җиңел сөякле, чандыр гәүдәле, какча чырайлы бу кеше абый да түгел, энекәш тә түгел, яшь аермасының ничек булуына карамастан бөтенесе дә аны Чабата дип кенә атап йөртә. Ул, егерме ел буе җыр һәм бию ансамблендә биеп, кырык яшеннән пенсиягә чыккан. Чигүле түбәтәй, яшел атлас камзул, эленке генә бәйләнгән, туры төпле, озын балаклы буй-буй ыштан киеп биегәнен телевизордан еш күрсәтәләр. Бию уртасында шома табанлы читек-кәвешен салып чабата киеп куя да шуның сөенеченнән егылганчы бии. «Чабата» биюенең исеме үзенә кушамат булып тагылыр дип кем уйлаган?! Чабата – Сөмбелә төркеменең администраторы, дөрес, визиткасына ул үзен эре-калын хәрефләр белән продюсер дип яздырган. Концертларны оештыру, билет тарату, җыелган акчаны кассадан алу аның өстендә.

«Газель» микроавтобусын Сөмбеләгә сайлау уенында катнашканга бүләк иттеләр, ә радиоаппаратураны үзенеке итәр өчен бәйрәм көннәрендә химия заводында өч ел буе бушлай җырлыйсы бар әле.

– Бая кассирша безне үртәп маташа, Уразаева афишасын күргәч, Сөмбелә концертына дип алынган билетларның күбесен кире китереп тапшырдылар, ди.

– Җавабыңны бирә белдеңме соң?!

– Әйе менә, әрләшеп утырдым ди кассирша белән!

– Ничәнче тапкыр бит инде!.. Концертыбызга бер атна кала дигәндә генә афишасын китерә дә элә. Мин җырлап киткәнне көтеп торса ярамаганмы?! Юри, үчегеп эшли бит ул аны.

– Усаллык белән түгелдер, бик самими кыз әле ул.

– Юри эшли, юри! Ни өчен икәнен дә беләм. «Ягымлы яз» конкурсында мин аңа каршы сүз әйткән идем, сәхнәдә үзенә-үзе артык ышанып, чамасыз эре кыланганы өчен. Бу жюриларда йөреп күпме дошман җыйдым.

– Һәр нәрсәнең үз вакыты: берәүләр сәхнәгә менеп килә, икенчеләр жюрига төшеп утыра... Уразаеваның тавышына сүз әйтерлек түгел! Ул тембр дисеңме, ул дикциясе; үзе нәфис, үзе сөйкемле, моңлы, һичбер музыкасыз-нисез җырлый ала, яшьлегенә күрә горурлыгы да килешә.

– Яклама шуларны! Сәхнәдә яшьлек кенә җитми, тәҗрибә дә кирәк.

– Тәҗрибәнең поты бер тиен хәзер. Тамашачы дигәнең концертка җыр тыңларга дип түгел, артистның үзен күрергә килә. Тыңлыйм дигән кеше өчен җыр белән кибетләр тулы. Аудио дисеңме, видеосы кирәкме – җылы өеңнән чыкмыйча, төнге транспортларда интекмичә, сөтле чәеңне йоткалап, диваныңа җилкә терәп – рәхәтләнеп тыңла... Юк шул, әгәр берәр җырчыны яратса, меломан дигәнең барыбер өеннән чыгып китә. Яшьләрне яраталар шул.

– Яшьлек үтә, тәҗрибә кала.

– Ие, бер яшьлек үтә, аның урынына икенче Уразаевалар килә. Тәҗрибәле җырчылар юбилейларда, бенефисларда мактаныр өчен генә кирәк. Тамашачы карт җырчыны эзләми.

– Илһам абый белән Әлфия апаларны кая куясың? Заллары гел тулы, чәчәккә күмәләр, сәхнәдән төшермиләр...

– Оештыра белмәсәң, аларга да кеше килми.

– Менә күрдеңме, үз гаебеңне үзең таныдың?! – дип канатланды Сөмбелә, әлеге бәхәснең шулайрак төгәлләнүен көтә иде инде ул. – Оештыруың шуның хәтлек кенә! Афишаны элеп кайтасың да вәссәлам!

– Җ-җ-жук, телефон аркылы кассадагы хәлне гел сорашып торам...

Чабатаның мин-минлегенә тисәң, тартык авазларда терәлеп кала торган гадәте бар, Сөмбелә моны бик яхшы белә. «Жигули» эчендәге кысанлыкта кабынып киткән котылгысыз бәхәснең гел яшьләрне мактауга корылуы аны рәнҗеткән иде, шуңа күрәдер ул администраторның каушавыннан канәгатьлек хисе кичерде. Абзагыз дорфаланып кырыс хөкем карарын укып бара. Үзенең артык борчылганы сизелми, җырчы әйтергә мөмкин булган соңгы сүздән курыкмый, димәк, аны чакырып торган башка җырчы бар, димәк, аны тагын да ныграк үртәп, ул исемне әйттерергә кирәк.

– Ялкауландың син, Чабата, акчаны җиңел эшләргә өйрәндең. Башкаларны кара: «Күңел» радиосына реклама биргәннәр, Чаллы телевидениесе көн саен клипларын күрсәтеп тора, баерак оешмаларга барып билетлар таратып йөрү дисеңме?..

– Рекламага түләсәк, ярты заллы концертларыңнан нәрсә калыр? Синең белән аншлаг күргән юкка инде...

– Оныттыңмы? Күп булды инде минем дә аншлаглар.

– Ну, Сөмбелә, «элек» дип күпме шапырынсаң да, аннан тамак туймый.

– Аның каравы җыелган акчаның унбиш процентын биреп барам мин сиңа.

– Әйе, Зәлияләр унны гына түли. Ну тулы залдан шактый чыга ул.

Алай... Зәлияләр төркеменә күчәргә икән моның исәбе дип кызулык белән нәтиҗә ясап өлгерде Сөмбелә, исәп-хисапларын өйрәнгән, нәтиҗә ясалган. Инде китәсе көнен генә сорыйсы калды.

– Әйт, Чабата, ничәсенә чакырдылар, ераккамы?

– Октябрь бәйрәме тирәсендә Нижгар–Мәскәү–Питерга бер атналык маршрутлары бар. Татар диаспоралары гарантияли.

– Әйтәм җирле, баядан бирле алар җырын җырлап барасың!.. «Эльруш» дуэтына ияреп китеп миңа кире кайтканыңны онытма!

– «Эльруш» дуэты таркалды бит. Юкса мин аларны Җир шары буйлап йөртеп чыга идем.

– Син таркаттың аларны, Чабата!

– Җ-җ-җ-жук! Нишләп мин булыйм?! Раушания кияүгә чыгып кына х-х-х-харап булды алар.

– Син, син! – Чабатаның каушавыннан Сөмбелә тагын да ныграк комарланды. – Зәлия белән Зөфәрне дә таркатачаксың! Әйткән иде диярсең!

– Җ-җ-җ-жук! З-зәлия җ-җырлаганда з-залдагылар җ-җ... җылап утыра! Мин аларны рәхәтләнеп тыңлый алам. Ә синең җ-җырлаганны тыңламас өчен фойега ч-чыгып китәм.

– Туктат, туктат машинаны! Мин «Газель»гә күчеп утырам. Бар, яраткан җырчыларыңны бүген үк куып тота аласың!

«Алтылы»ның багажнигыннан сәхнә күлмәкләре кидерелгән кофр белән озын каешлы сәяхәт сумкасын алган арада «Газель» куып җитте. Чабата кузгалып китәргә ашыкмады, ул әле Сөмбеләнең дулап саубуллашуына һаман да ышанып җитми иде, күрәсең. Уңышсыз концертлардан соң җырчы кызыйның холыксызлануы гадәти хәл, көзге төн аны тиз суытыр, авыз эченнән мыгырдап гафу үтенер дә яңадан килеп утырыр дип көтте... Килүен кире килде Сөмбелә. Ләкин гафу үтенер өчен түгел, бүгенге сүз көрәшендә җиңүче булып калыр өчен генә.

Ул сәхнә артыннан кабат баш ияргә чыккандай мактаулы халәттә ияген чөйде, гәүдәсен турайтты, вак, әмма ышанычлы адымнар белән фара нурларын кисеп, Чабата ягындагы ян тәрәзәгә иелде:

– Мин сиңа әйтеп өлгермәгән идем, бүген миңа бер кочак роза керттеләр, зур гына компаниянең генераль директоры иде. Ул шәп проект тәкъдим итә... Синең китеп баруың әйбәт булды әле. – Һәм Сөмбелә, үз ялганына үзе куанып, әзер елмаюын яшерә алмады. Фара яктысы зал түреннән сузылган прожектор нурлары сыман иде, ә олы юлда тыз-быз үткән йөк машиналарының көпчәк чыжлавы көчле алкышларны хәтерләтте...

Унике урынлы «Газель» сигез кеше белән шыгрым тулган. Арткы рәтләрне сүтеп алып, аппаратураларны төярлек мәйданчык ясагач, бәләкәй автобус эче күченергә әзерләнгән бүлмә эчен хәтерләтә иде. Кеше саен берәр сумка, биючеләрнең түбәгә иңсә белән эленгән озын күлмәкләре, Наилнең тез өстендә йоклап кайткан ак тышлы баяны, Тимурның ау мылтыгы кебек саклап барган гитарасы, бернинди геометрик фигурага да охшамаган кул сандыгы эчендәге саксофон белән Алып батырның кыска тунынннан коелган төймә кебек аяк астында комачаулап яткан запас көпчәкне дә исәпкә алсаң, суларлык һава күләме бик чамалы монда. Шулай да, ут сүнгәч, салонда иркенәйгән кебек булып китте.

– Чабата бабай безнең көйгә кайта алмый, мин аны җибәрдем, – дип акланып өлгерде Сөмбелә, ник дисәң, йомшак кәнәфидән каты сәкегә күчеп утыруның сәбәбен сорамый калмаслар иде. Алдан ук җавап биреп, эшне җиңеләйтте.

Араларына солистка кереп утыргач тынып калсалар – моңарчы бу җиде кешенең кем турында сөйләшеп барганын күз алдына китерүе кыен түгел. Шуңа күрә Сөмбелә тынлыкны үз кулына алырга булды.

– «Карамай»га җиткәч туктарсың, Илфирәт, сыйлыйм үзегезне!

– Банкет! – дип төзәтте Фаил, исән микән дигәндәй, тез өстендәге баянын капшап.

Чаллыга барган саен ач кайтабыз дип көрсенеп арыган тавышлар, яңадан уянып, «банкет» сүзенә әллә ничә төрле бизәк өстәделәр:

– На шару!.. Халявый... Үзе сыйлый... Бер атнадан бирле банкет күргән юк... «Карамай»га чаклы тагын туксан чакрым кайтасы, әллә «Кыстыбый»га туктыйкмы?.. Юк, «Карамай» – супер! Андагы кебек итеп беркайда да пешерә белмиләр... Сиңа инде йөз илле грамм салып бирсәләр, урамдагы көйгән шашлыкны да мактыйсың...

Банкет дигәч, Илфирәт тәмәке кабызды. Сөмбелә, башын кыегайтып кына, шырпы очында биеп алган мескен ялкынга күз салды, тик каршы дәшмәде. Йокы ачылсын дип тырышуларыдыр инде, күрәсең, төнге юлда шоферлар аеруча еш тарта. Тартасы килгән саен урамга чыгам дип машина туктата башласаң, Чаллы белән Казан арасын тәүлек буе кайтырсың. Шоферга беркем каршы сүз әйтә алмый. Юлга чыккач иң кадерле кеше ул. Исән-сау йөртү өчен генәме? Казанга кайтып җиткәндә, сәгать инде төнге икеләр тирәсе булыр. Шушы сигез кешенең һәркайсысын фатир ишегенә тиклем кайтарып, таратып чыгасы бар. Кемне алдан, кемне иң соңыннан илтәсен шофер үзе хәл итә. Йокының иң тәмле чагында, ашамаган-эчмәгән, юынмаган килеш тагын бер сәгать буе шәһәр эчендә каңгырап йөрисең килмәсә, рульдәге кешегә каршы дәшмә.

Банкет тукталышын йокы аралаш үтеп китмәс өчен, егетләр бер-бер артлы мәзәк сөйли башлады.

Сөмбелә көзге пәлтәсенең йомшак якасына ышыкланып сулышка ияргән төтен исен сөзде. Ул мәзәкләрнең беренче рәтеннән үк теманы аңлап ала да ишетмәмешкә сабыша. Сөйләүчегә кысылмый, кычкырып көлми... Караңгыга ышыкланып тик елмаеп бара. Әгәр онытылып китеп сүзгә кушылсаң,

шунда ук мәзәк персонажына әвереләсең, кеше ышанмаслык көлкеле маҗараларга синең дә катышың бар кебек һәм аларның һәммәсе дә синең баштан узгандыр кебек килеп чыга.

«...Яңа татар үзенең хатынын диңгез буена ял итәргә җибәрә...» дип башланып киткән мәзәкләр Сөмбеләнең игътибарын җәлеп итмәде. Аның баш миендә кайнаган уйлары егетләрнең тел очында уйнаган көрлектән көчлерәк иде...

Кемнән килде соң бу розалар? Бүләкме, шаяртумы, онытылган мөһим бер вакыйганы искә төшерү дип аңларгамы моны? Кеше кулы белән бүләк тапшыруның сәбәпләре бардыр ич: авыруы күзгә күренеп торган гарипме ул, әти-әнисенең рөхсәтеннән башка гына акча туздырырга җөрьәт иткән меломан малай-шалаймы, әллә үз яшеннән үзе оялырлык чамасыз өлкән агаймы?!

Яз – ирләрнең актив чагы... Кыш буе карлы саф һавада сихәт җыйган, мут телевизор каршында диван колачлап гайрәт туплаган ирләрдә, язга чыккач, куәт ташый, «малайлар чуагы» башлана...

Чабата да – чын ир кеше. Алмагачлар чәчәк атканга сөенеп, шомырт чәчәкләре коелганга көенеп язны еламсырап үткәрә торган ир уртасы, быелгы кышның кире кайтмаслыгына ышанып, әнә ничек батырайган! Моң белән акча эшләп аның гаиләсен күтәрергә булышкан Сөмбеләгә каршы дәшә, үрти, чагыштыра, күрәләтә хыянәт итә. Бер Чабата гына түгел, туксан чакрым буе анекдот сөйләп барырдай җиде кешенең һәркайсы да шулай. Алар ике-өч сәгать буе концертында туганнарча, дустанә елмаеп-көлеп синең өчен сөенгән булып торыр да, пәрдә ябылгач, янә дошманыңа әверелер.

Пәрдә ябылганнан соң башланган ыгы-зыгысы, җыеп төяү, вак-төякне югалту, башкарылган җырларны бәяләү, бүгенге хаталарны эзләү, банкетларда юанулар һәм, ниһаять, кайтып җитүләр, кыскасы, үз өеңнең бусагасын атлап кергәнче кылынганнарның барысы-барысы бергә сәхнә арты дип атала. Сәхнә арты хыянәт белән тулы. Алып килгән чәчәк бәйләмен концерт беткәнче саклап, соңыннан, пәрдә ябылгач кына сәхнә артына кереп, җырчыны эзләп йөрүчеләр бармы – алар әнә шул хыянәт дигән нәрсәне үз күзләре белән күрергә, башкаларга бәйнә-бәйнә сөйләргә теләүчеләр. Әле өеңә кергәч, рәхәтләнеп башымны куям дип өметләнгән иске мендәрең өстендә дә сине хыянәт көтеп ятарга мөмкин, чөнки уңышсыз юлга чыксаң, сәфәреңне кыскартып, төннең теләсә кайсы михнәтендә көтмәгәндә кайтып керәсең. Әгәр өметләнмәгән уңышка очрасаң, гастрольләреңне озайтып, өйдәгеләр борчылып көтсә дә кайта алмыйсың. Һаман саен кабатлана торгач, билгесезлекнең нәтиҗәсе булып, сине пәрдәнең ике ягында да хыянәт сагалап тора башлый. Бер хыянәт, ике хыянәт... өч... биш... Ахыр чиктә син ул хыянәтләргә күнегәсең...

Хыянәтләр артистны чыныктыра, яшәргә, җиңәргә өйрәтә.

Җыр уен кебек ул – яңа чагында гына кызык. Яраткан «шлягерларыңны» ун-унбиш тапкыр рәттән тыңласаң – туясың. Аннан соң тагын яңалары кирәк. Күпме патефон тәлинкәсе, аудиокассета, компакт-дисклар ярылып, сүтелеп, кырылып өелеп ята, чүплеккә чыга. Күпме җырчы тамашачыны күрүдән мәхрүм булып өендә – ябылуда яши... Чабатага һәйкәл куярлык – ул Сөмбеләне биш ел буе рәттән тыңлады. Әйбәтрәк түләсәң, тагын да тыңлый ала иде әле. Үзгәртергә, үзгәрергә, нәрсәдер эшләргә, яңарырга кирәк! Төркемне бер «Жигули»га сыярлык итеп биш кенә кешегә калдырыргамы? Ул чагында ваграк район үзәкләренә, эрерәк авылларга рәттән кереп йөрергә була. Соңгы ун елда бөтенләй концерт күрмәгән авыллар бик күп. Ләкин билет бәяләрен шәһәрдәгедән сигез-ун тапкырга киметергә туры килә. Кулыңа калган акчаң сыңар туфли алырга җитәрме? Икенче сыңарын алыр өчен тагын бер авылга керәсе була. Бичарага ничара... Сөмбелә авыл буйлап хәер сорашып китте, дип, и сөйләнер иде артистлар.

Нишләргә?! Үзең кебек тагын берәр җырчы алып, төркемнең шавын арттырыргамы? Ул чагында: «Син дә мулла, мин дә мулла, садаканы кем бүлә?» Концерт Сөмбеләнеке дигән тамга төшеп калырга тиеш буламы? Антураж булып килгән яшь җырчылар да тиз үсә. Бер-ике ел ияреп йөриләр дә телевидениенең йолдызлар фабрикасына шомарырга дип ашыга-ашыга китеп тә баралар.

Популярлык казану бик авыр, ләкин әнә шул танылган җырчы дигән исемне елдан-елга саклап калуы тагын да авыррак... Иртәгә үк... Юк, бүген үк, кайтып бераз ял итү белән, яңа күлмәк тектерергә, яңа плакат ясатырга, синнән отып алып табын артында җырланырлык яңа җыр эзләргә кирәк. Яңа җырга лаек булыр өчен үзең дә яңарырга кирәк...

Чын сәхнә – түгәрәк мәйдан ул, аның кыйбласы бихисап, пәрдәләре ялтыр-йолтыр, утлары көлтә-көлтә, яшел, кызыл, зәңгәр төсләре катлы-катлы. Ак белән сорыны, кара белән коңгыртны бутамасаң гына, кызыллыктан – алсулыкны, зәңгәрлектән шәмәхәләнүне аера алсаң гына синеке ул сәхнә...

Банкет булмаса, артистлар арка терәвенә кыек-мыек сөялгән килеш кайтып җитәселәр иде. Сөмбелә «Газель»не кафе янында туктаткач, төнге сәгать икедә көн яңадан башланды. Күңел ачу йокыдан көчлерәк иде бүген.

Чәчүләр бетеп, җыеп алынасы байлыкны алдан ук санап, югарыдагыларга рапорт биргәч, шәһәрнең базарлы мәйданнарына ярминкәләр килә, авылларда язгы бәйрәмнәр башлана. Хисләргә туенган яшьләр никах хәстәрен күрә, юбилейлар, туйлар, өмәләр китә... Кыскасы, елның җырлы-уенлы чоры бу. Җим сибәр сәгатьне көткән күл балыгы кебек, артистлар арасында да ыгы-зыгы арта. Сөмбелә хәзер җитәкчеләрнең кунакка чакырганнарын кул кушырып көтеп ятмый, бәйрәмнәрне үзе эзли, исләренә

төшереп шылтыраткалап тора. Кайсы гына җырчының өенә кермә – районнардан, шәһәрләрдән ялынып алып кайткан телефон кенәгәләре журнал өстәлендә өелеп торыр. Эш югында көннәр буе хәбәрләшеп тә сыңар концерт оештыра алмаган чаклар була. «Зәйтүнәгә ныклап әйтергә кирәк, «уңыш»лы вакытны кулдан ычкындырмасын, әнисе югында телефоннан китмәсен, җырлап акча эшләүнең җиңел түгеллеген белеп үссен. Юкса, өйдә үзе генә калгач, әнисенең көлмәкләрен киеп артист булып уйнарга ярата ул. Ходаем, кызымны җырчы язмышыннан ераграк тот...» – дип, юлдагы уйлары белән пыран-заран килеп, подъездга кергәч, Сөмбелә почта әрҗәсенә ачкыч эзләп джинсы кесәсенә тыгылды. Чәчәкле кәрҗинне идәнгә куймаска тырышты. Сөмбеләләрнең «егерме дүртенче»ләре лифт каршысында ук.

Сөмбелә әрҗәдән төшкән яңалыкларны актара башлады. Һәр реклама кәгазен, бушлай таратыла торган гәҗитләрне җентекләп караштырды. Көнелендәге кысыр өметне юатырга теләп, ниндидер билгесезлектән хат эзләде бугай ул. Роза чәчәкләре арасында ияреп килергә тиешле язу почта аша әйләнеп кайтыр кебек иде аңа. Кызына күренгәнче көтелмәгән яңалыкларны сөзеп алуың хәерлерәк. Зәйтүнә хәзер урта мәктәптә соңгы елларын укый, аттестат алганчы ук өлгереп җиткән зур кыз инде ул, әнисенә кагылышлы һәр яңалыктан зур сер эзләргә ярата, сораулары күбәя.

Почта әрҗәсеннән алай искитмәле яңалык чыкмады, бәлки, телефоннан берәр хәбәр бардыр әле дигән уй Сөмбеләне өйгә ашыктырды.

– Абау, розалар!!! – Зәйтүнә әнисенең хәлен сорарга да онытты. – Әллә спонсорлар бар идеме, бүген минем туган көнем дип шаяртмансыңдыр әле?!

– Чәчәксез кайткан көннәрем сирәк инде, кызым.

– Анысы шулай, әни. Мондый чәчәкләрне, телевизордан күренер өчен, чиновниклар гына бүләк итмәли иде бугай. Розалар... бер кәрҗин!

– Сары розалармы?

– Бүләк ителгән чәчәкләрнең сарысы-кызылы юк, әни!..

– Минем төсләр аера торган чагым шул, кызым. Синең яшьтә булсам, бәлкем, үрле-кырлы сикерер идем дә...

– Әни, кем бүләк итте? Главамы, КамАЗ директорымы?! Әллә... джентльменмы?.. – Зәйтүнә, бик мөһим кешенең исемен ишетергә теләп, сурәттәй катып калды.

– Белмим, кызым. Кәрҗин үз аягы белән керде, җентельменын күрмәдем.

– Әни! Әйтәм ич, сиңа әле шундый шәп кеше гашыйк булачак! Менә күрерсең... Бөтен гәҗит, радио-телевидениеләрне шаулатып туй итәрбез. Бөтен кеше сине – бәхетле Сөмбеләне – яңадан күрер өчен концертларыңа ябырылып килер... Ә мин аңа эти дип дәшәрмен...

– Моңарчы бер дә кияүгә бирәсең килмәде...

– Җүләр, бала-чага булганмын.

– Бүген үстеңме?

– Үстем. Мин синең кебек ялгыз яшәмәм.

– Бирсен Ходай!

– Кияүгә китсәм, үзең генә каласың.

– Бүген үк китмисеңдер ич?

– Юк. Таныштык кына әле.

– Кем белән? Кайчан? Иртән мин юлга чыкканда, өйдә бала-чага булып, «Марс» шоколады алып кайт» дип еламсырап озатып калган идең.

– Мәктәптән соң өйгә кайтмыйча, туп-туры университетка барып килдем, укырга керүчеләр өчен программа кирәк иде. Менә шунда таныштым.

– Мин сиңа бүген шоколад алып кайтмадым. Кәрҗин күтәреп йөреп, бөтенләй онытып җибәргәнмен.

– Ярар. Бүгенгә түзәрмен. Яңа егетем Мөхәммәт тә шоколадлы. Алжирдан.

– Негрмы? Йә Хода... Африкадан кода белән кодагый килеп төшсә... Балантау халкының коты алыныр.

– Озаграк карап торсаң, күз иярләшә аңа. Әле беренче курста гына укый ул. Син дә ияләшерсең.

– Йә, булды, кызым. Бүген болай да башым чатный. Шаяртуларыңны иртәгесе көнгә калдыр.

– Әни...

Зәйтүнәсенең тавышында ниндидер гозер бар кебек тоелды Сөмбеләгә.

– Нәрсә, кызым, әллә бүген үк Африкадан илчеләр киләме?

– Юк, әни. Минем бүген университеттан кайтканда мобильнигымны чәлдерделәр. Маршруткада бик тыгын иде.

– Әрләрлек тә хәлем юк. Акча эшлисең килсә, әнә районнарга, колхозларга шылтыратып чык. Белешеп кара, концертлар кирәкми микән. Белмәгән эшең түгел, телеңнән килә.

– Белештем, әни. Байлангарга багышлап җыр язганнар, авылда кичәсен үткәрәселәр, ди. Сиңа композитор белән элемтәгә керергә куштылар... Кармыш авылына Чишмә бәйрәменә чакырдылар.

Теләчедә районның унбиш еллыгына багышлап Культура сарае ачыла, диделәр, килергә куштылар. Аланда уңыш бәйрәме, көнен-сәгатен билгеләп үзеңә элемтәгә керәсе булыр. Шулай итеп, дүрт концерт сиңа! Минем гонорар бер телефонлык.

– Әйе. Эшләп кайтыйм әле башта ул авылларда. Аннан булыр сиңа кесә телефоны.

– Әни, иртәгә үк кирәк шул. Юкса Африка белән элемтәм өзелә.

– Әйтәм аны бик тыпырчынасың... Ярар, таң атканчы гына түз инде алайса. Акча кулга кереп өлгермәде... инде чыгып та бара...

Чиләктәге суга аспирин салып, розаларны шунда күчергәч, өй эченә шоколад конфеты исе таралгандай булды. Йокы бүлмәсендә караватлары янәшә торса да, аларның юрган-мендәрләре аерым. Бүген Зәйтүнә әнисенең юрган астына шуышып керде, куенына сыярга тырышып бөгәрләнде.

– И әнием, әле дә ярый син бар бу дөньяда!

Конфет исе куенга да кереп тулган иде инде. Алар тәмләп йокыга киттеләр.

## Яңа ел күбәләкләре

– Мин!..

Тимер-калкан ишек артындагы кешенең кемлеген белер өчен шушы бер сүз җитте. Сөмбелә аның тавышын «ә?» дигәннән дә таный ала.

Дүрт бармаклы йозак ачылгач, тимер тупса өстендә Чабата пәйда булды. Чаңгычыларныкы кебек чуклы калфагын каш астына тиклем батырып кигән, мамыклы курткасыннан чыгып торган калын свитер муенчагын борынына кадәр күтәргән. Салкын күзе белән агарып ялтыраган борыны гына калган. Кулларын күн бияләй кигән килеш кесәсенә тыккан.

– Син нәрсә, Чабата, җәяү килдең мәллә? Шушындый суыкта!

– Машинам кабынмады. Телефоннан аңлата торган сүз түгел. Ашыктым.

Сөйләшә торгач, Чабатаның күкшегән иреннәре җылына башлады.

– Иртәгә кабынып иде әле. Тамагыңа җил бәрсә... Хәер, синең җырлыйсың юк ла.

– Заказчик барында тизрәк хәл итик. Башкалар сизеп алганчы.

– Алар чынлап та минеме – Сөмбелә килсен дип сорыйлармы? Әллә кем булса да ярыймы? Дөресен әйт, сырлап-мырлап торма, мин инде көйсез кәләш түгел.

– Точно, сине чакыралар.

Сорау өстенә сорау яудырып тинтерәтүе Чабатага ышанмаудан түгел, ул инде сыналган администратор, әйткәнен хәленнән килгәнчә төгәл үти, чакырган җырчысына тамашачы җыя белә, акча бүлгәндә хәрәмләшми. Сөмбеләне эшсез калдырып еш кына башка җырчыларны алып чыгып киткәләгән икән, монда берни эшләр хәлең юк, халык кемне сагына, шуны чакыра. Соңгы елларда Чабата җиңелрәк эшкә күчте, ул хәзер Зәлия белән Зөфәргә иярде. Бу җырчыларның иң йолдызлы чагы, концертларын тәмамлап яңадан башласалар да, җыелган зал таралышмас, таң атканчы тыңларга әзерләр. Әлмәттә бер көндә рәттән ике аншлаг җыелган, диделәр. Шуңа күрә дә Чабатаның һич уйламаган җирдән Сөмбеләне Әлмәткә чакырып килүе бераз икеләнергә мәҗбүр итте. Тамашачыны кулга иялэштергән Драма театры бинасында булса бер хәл... йөз илле меңле шәһәрдә Сөмбеләне сагынырдай биш йөз тамашачыны өй саен чакырып та җыяр иде әле Чабата. Ә ул мең урынлы Техниклар йортына афиша илтергә җыена.

– Нәрсәдән куркасың? Синең инде Әлмәттә җырламаганыңа бишбылтыр.

– Өч кенә ел әле... – Башка артистлар арасында гайбәт булып таралмасын өчен юри төгәллек кертте Сөмбелә, Әлмәткә юлы ябык дип уйламасыннар.

– Өч ел күрмәгән җырчыны мин дә сагынам, – дип, үзенчә сөендерергә тырышты Чабата. – Сөмбеләне алып килсәң, аншлаг гарантируем, диделәр.

– Ник, алайса, турыдан-туры үземә чыкмаганнар, синең аркылы эзлиләр?

Монысына Чабатаның бераз чырае сытылды. Суыктан агарып кергән бит алмасында кызыллык тибеп алды.

– Безне гел бергә эшлиләр дип белгәннәрдер. Моңарчы администраторлар аша эш иттеләр ич. Ну, теләсәң әйтермен аларга, сиңа шылтыратырлар. Бәлки, миннән башка гына барасың киләдер?

– Кырык градуслы салкында бригада сөйрәп зыянга эшләп кайтсаң... Буш залга җырласам, кәефемә салкын тия минем.

– Бүген – кырык, иртәгә – ноль... Яздан курыкма, килеп терәлгән. Гарантия диделәр. Барырга тек барырга!

Татар эстрадасында җиләкле аланнар тарая Сөмбелә өчен. Югары Ослан, Тәтеш, Бөгелмә, Лениногорск кебек татарча ишетми торган төбәкләрне генә түгел, Минзәлә, Актаныш, Әтнә, Баулы кебек әлифбалы кала-салаларның юлларын да онытып бара инде ул. Әлмәткә дә өмете өзелгән иде.

* * *

Реклама ярдәмен тоя башлагач, синоптикларның да алдан юраганы юш килә башлады, ялганлаудан туктадылар: «йә ява, йә юк», «юнәлешсез җил», «мөмкин», «ихтимал», «көтелә», «үзгәрүчән» дигән икеле-микеле сүзләрне сирәк ишетәбез хәзер. Сынап карарсыз. Һава торышының спонсоры энергетиклар дисәләр, коры һәм кызу көннәр килергә мөмкин, нефтьчеләр вәгъдә иткән көнне аяк астын дегеткә батырып яңгыр явар иде, ә инде «Газпром» ярдәме тисә, җөмһүриятне томан капларга мөмкин...

Инде атна буе бүгенге һава торышының спонсоры ОАО «Холод», ягъни тәмле-туклыклы туңдырмалар җитештерә торган комбинат бугай... Сөмбелә иягенә тиклем җылы суга чумып ваннада ята, ә урамда яз башына хас булмаган утыз биш градус суык.

Су өсте күбекләнмәгән иде, юыну бүлмәсенең стенасына ябыштырылган көзге өлгеләрендә төрле ракурсларда чагылган гәүдә сурәтен күреп сөенде әле ул. Шөкер, буй-сыны әнисеннән... Гөлчәчәк, пенсия яшенә җитсә дә, гел җиңел сөякле, әгәр кызының концерт күлмәкләрен кидерсәң, таман гына булыр... Шунысы үкенечле, Сөмбеләнең җырчы булып эшләвенә тиздән егерме ел була, ә Гөлчәчәк белән Харисның кызлары җырлаганны Казанга килеп тыңлый алганнары юк... Әллә бенефисны туган авылда гына үткәрәсе микән дип тә уйлаган иде ул. Тик бу уеннан кире кайтты, иҗат кичәләрен зурдан кубып оештырыйм дисәң, зур җитәкчеләрне, олы шәхесләрне, хәбәрчеләрне күпләп чакырырга кирәк. Ә алар бәйрәм-мәҗлесләрдә буш сүзләр сөйләп алҗыган халык, Казаннан чыгарга бик яратмыйлар. Авылдан туган-тумачаны төяп килүең күпкә җайлы.

Сөмбелә торып басты, ванна суы тубыктан гына калды. Кайнар тәненә бәлзәмле крем сылады, кулы сыйпап торган һәр урынны җентекләп, гаебен эзләп күзәтеп барды. Юк, юк... Тәнендә сөялләр, тамыр төеннәре дә, төкле шадралар да күренми. Кызыгалар әле аңа, барыбер кызыгалар. Сыныйлар, күзәтәләр, качышлы уйнап сары розалар китерәләр. Болар берсе дә тикмәгә генә түгел... Байлары күбәйгән саен тамашачылары кимегән Әлмәтнең мең кешелек залында Сөмбелә концертына билетлар сатылып беткән! Бу бит триумфаль аншлаг! Әллә икенче сулышы ачылды микән? Әлмәттән кайткач, кочагы белән афишаларын тоттырып, Чабатаны башка шәһәрләргә дә җибәреп карыйсы булыр.

Иртәгә Әлмәттә зур концерт. Һәм бу мөмкинлекне шоуга әверелдереп исемне яңартырга кирәк. Сөмбелә программаны ныгытыр өчен Уразаеваны да чакырды. Кыз, вак-төяк студияләргә баш имичә, эстраданың олы юлыннан бара. Ул киләчәктә зур җырчы булып үсәр, шул вакытта Сөмбеләне дә үз төркеменә ияртер... Эстрада дөньясында кылынган бик күп гамәлләр әҗәткә эшләнә: яхшысы да, яманы да... Күптән инде конферансье дип атала торган һөнәри мәзәкчеләрне дә чакырганы юк иде. Алар бездә унбишләп кеше, Сөмбелә инде барысының да репертуарын яттан белә. Шуңа күрә үз концертларын үзе алып барырга күнегеп килә иде. Ләкин Әлмәтнең укалы тамашачысы Шәрәфине ярата – сәхнәгә чыгып бер сүз әйтмичә басып торса да, халык аңа ярты сәгать буе кул чабачак.

Шулай итеп, Сөмбелә концертының алып баручысы Шәрәфи булса, алып кайтучысы – «Газель»ле Илфирәт.

– Чаллы аша барабызмы, әллә яңа күпердәнме? – дип сорады ул, артистларны төяп бетергәч.

Сөмбелә чак кына җавап биралмыйчарак торды. Чаллы юлы киң, төзәтелгән, туктап-туктап чәй эчәрдәй, хаҗәт кылырдай җылы корылмалар бик күп, әмма ераграк чыга, салкында болай да бензин күп бетә. Җитмәсә, тукталыш ышыкларында, урман почмакларында, үзәнлек чокырлары саен «дзот»ларда гаишниклар сагалап тора... Ә Саескан күпереннән китсәң, юл йөз чакрымга кими. Чамасыз тар, сикәлтәле, кыек-мыек ул, әлегә кайнар чәйле куышлары, заправка тукталышлары да ике-өч урында гына, аның каравы юлчылар белән качышлы уйнарга ярата торган инспекторлары азрак...

– Мин ишетми калдыммы, әллә син әйтми торасыңмы? – дип кабатлап сорады Илфирәт.

– Әйдә КамАЗ юлыннан.

– Ә штрафларны кем түли?

– Алайса, Саескан күпереннән.

– Мондый суыкта сүнеп калсак, машиналар әз йөри.

– Ярар, трассага чык.

– Барырга-кайтырга утыз литр бензин әрәм китә.

– Ну, соң, Саесканнан, дим ич!..

– Артык куып булмый. Вакыт ягыннан санасаң, шул ук.

– Син нәрсә, Илфирәт, суыктан курыксаң, рульгә үзем утырам. Кирәксә, Ульян каласы аркылы өченче юл бар.

Илфирәт тавыш-тын чыгармыйча рәхәтләнеп көлә белә, андый чакта аның грузиннарга охшаган чырае күп җыерчыклы татарга охшап кала.

– Артистлар ягына өрдерә торган мич җылынсын өчен генә сөйләндереп торам. Алтышар сәгать паром көткән чакларга үч итеп яңа күперләрдән йөрик әле! Бабайлар: «Өйләнгечтән юл туры...» – дип яшәгәннәр. Ә җитәкчеләребез нәрсә ди: «Юлның кыскасы...»

– Сүзнең остасы!.. – дип түгәрәкләде Шәрәфи.

Соңгы елларда Шәрәфинең тагын бер сәләте ачылды. Ул җиңел машина сәхнәсендә генә сөйләргә ярый торган такмакларның русчасын татарчага, татарныкыларын русчага тәрҗемә итәргә ярата. Кыска-кыска такмакларын кабатлатып, ютәл купканчы көлә торгач, ялыктыргыч сәфәр тиз үтә, ерак юллар да кыскара.

Март суыгы, мәрхәмәтлек күрсәтергә теләгәндәй, олы юл читендәге тал-тирәкнең һәр ялангач ботагын мамыклы бәскә төргән. «Газель»нең тизлеге арткач, ян тәрәзәләрдә дә шул ботакларның сурәте беленә башлады. Кайры тунның мехлы ягы күлмәкләргә чытырдап ябыша, кемгәдер орынсаң йә кулдан-кулга нидер күчерсәң, ток суккандай итә. Коры суыкларда моңын өшетмәс өчен, Сөмбелә сулышны җылыдан алырга тырыша, авыз-борынын тун эченә яшерә. Шәрәфи мәзәкләреннән дә тун эчендә көлеп барды.

Артистның үз концертына соңга калып килүе гадәттән тыш хәл түгел, бәлки гадәти хәл. Аны «йолдыз авыруы»ның бер төре дип атасаң да ярый. Популяр шәхесләргә хас вакыт җитмәү синдромы да ул. Соңга калу вак-вак тоткарлыклардан, әрәм-шәрәм иткән минутлардан, техник сәбәпләрдән җыела. Еракта яшәгән кеше эшенә гел башкаларга караганда алданрак килә, ә балкон тәрәзәсеннән эш урыны күренеп торган кеше һәрвакыт соңга кала.

Кыска юлга артык ышанып куаламадылар, тукталышларда эленке-салынкы маташтылар, кичтән эчкән сыраларны бушату, тәмәке тартулар күбәйде... Һәм баскыч төбендәге реклама коймасына сыланган Сөмбелә портретына фара яктысы килеп төшкәндә, концерт башланырга нибарысы бер сәгать вакыт калган иде. Соңга калу инде бу! Әле аппаратураларны бушатып урнаштырасы, микрофоннарны көйлисе, сәхнәне бизисе, күлмәкләрне үтүклисе, чәй эчәсе һәм иң четереклесе – Сөмбеләнең бизәнәсе бар. Ул арада әле егетләрнең берәрсе кибеткә китеп өлгерә.

Машинадан төшүгә, Сөмбеләне тамашачылар сырып алды. Эчтә каршыласалар, соңга калып килгән өчен борчылалар дияр идең, ә болар Мәдәният сараеның ишеге төбендә үк. «Ник ике көн рәттән куймыйсыз? Без барыбыз да билетсыз калдык!» – дип өзгәләнүләре җанга рәхәт. Күптән, бик күптән ишеткәне юк инде Сөмбеләнең шушы ягымлы сүзләрне. Ул: «Белмим шул... Исәнмесез! Тагын килербез, бик чакырсагыз... Керерсез, басып торып булса да тыңларсыз, пожарниклар рөхсәт итсә...» – дип сөйләнүдән гайре аклану сүзләре таба алмады.

Тагын биш минуттан башларга дигәндә, бөтенесе дә әзер иде, хәтта чыбыклы стаканнарда кайнатып чәй дә эчеп өлгерделәр. Шунда гына Сөмбелә, нидер сизенеп, сагаеп калды: юлдан килгән шәпкә репетиция ясыйсызмы, әллә халыкны залга кертә башлыйбызмы, дип теңкәгә тиюче юк. Сәер, бик сәер хәл бу. Фойеда өченче звонок яңгырады. Чабата да каядыр олакты. Сәхнә белән зал арасында авыр дивар булып шәмәхәдән коелган калын пәрдәне каерып теге якка карагач, Сөмбеләнең йөрәге куырылды – өч тамашачы утыра, ә керү ишеге ябык – чаршавына чаклы корылган.

Ул, бәрелеп-сугылып дигәндәй, грим бүлмәсенә керде. Кесә телефоныннан Чабатаны эзләп тапты.

– Син кайда?

– Кассада.

– Ник халыкны кертмиләр?

– Башлый торыгыз.

– Ничек инде башлый торыйк?! Ике минут калды, ә залда өч кеше утыра. Тугыз йөз туксан җидесе кая? Ишеккә берьюлы ябырылсалар, җимерәләр ич.

– Башлагыз, Сөмбелә, башла!

– Минем белән киңәшмичә нинди этлек эшлисең анда? Ну-ка, Чабата, хәзер үк монда кил!

Чабата каушады, тартык авазларны сайлап:

– С-с-с, – дип нидер аңлатмакчы иде ул, тик Сөмбелә, «монда кил!» дигән әмерен соңгы сүз итеп, телефонын шапылдатып япты.

Алар грим бүлмәсеннән башкаларны куып чыгардылар да бикләнеп сөйләшмәк булдылар. Концертант белән администраторның кычкырып сөйләшүен йозакка бикләп буламы – артистлар ишек артына сөялеп тыңлап тордылар.

Чабата. Менә аренда кәгазе. Менә ДК персоналына түләгән ведомость. Ә менә чиста выручка!

Сөмбелә. Ә билетлар?

Чабата. Мең билет залдагы өч егет кулында.

Сөмбелә. Тышта йөзләгән кеше калды. Кертик алайса.

Чабата. Әйттем. Егетләр риза түгел.

Сөмбелә. Нәрсә, әллә мине картага оттырганнармы?

Чабата. Ва-банкта унсигез яшьлек җырчылар хәзер. Бәлки, гашыйклардыр. Крутойлар арасында фанатлар беткәнме?

Сөмбелә. Миңа табынырга, үзең әйтмешли, әллә унсигез яшьлек чагыммы?

Чабата. Алай димә. Әлфия апа синнән ике тапкыр... Ну аның да фанатлары бар. Башла концертны.

Сөмбелә. Бригада белән киңәшәм, алар ни дияр.

Киңәшеп торасы булмады. Ишек аркылы тыңлап торган иптәшләр исеменнән Шәрәфи җавап бирде:

– Спектакльләр әзерләгәндә, репетицияләрне без гел буш залда үткәрәбез... Главное – бушлай түгел. Калганына исең китмәсен. Син алгарак чыгып җырла, прожекторлар утыннан күзең әлҗе-мөлҗе килер дә өч кеше тулы зал булып күренер.

– Программаны кыскартмыйбыз, – диде Сөмбелә. – Сындырдык дип сөенмәсеннәр.

– Ә тәнәфес ясыйбызмы соң?

Шәрәфи шушы сүзе белән шартларга җиткән киеренкелекне җимереп ташлады, Сөмбелә пырхылдап көлеп җибәрде хәтта.

– Тәнәфес юк. Интегеп утырсыннар!

Сөмбелә өч тапкыр күлмәк алыштырып чыкты. Соңгысында бенефис өчен язылган яңа җырларны сынап карады. Җырдан җырга күчкәндә әйтелә торган сүзләрне дә үзгәртмәде. «Рәхмәт, халкым, сез барында мин үсәм әле. Җылы өйләрегезне, матур сериалларыгызны ташлап килгәнегез өчен, көчле алкышларыгыз өчен рәхмәт!» – дигәндә залдагы өч пар кул озакка сузылган алкышлар белән җавап бирде.

Соңгы җырны гына алыштырды Сөмбелә. Дәртле музыкага күмелеп саубуллашырга тиешле төркем «Кыр казы» җырына тезелешеп чыгып басты.

Кыр казы
Иделләр читендә,
Ялгыз башым миңа читен лә...

«Кыр казы»ның соңгы кушымтасында Сөмбеләнең яшьле күзләрен шәмәхә пәрдә каплады. Ул грим бүлмәсенә ашыкмады (анда артык якты, җитмәсә, хәзер кеше кереп тулачак), сәхнә артындагы иске декорацияләр арасына посып, сабыйларча үкереп елады. Күз яшенең һәр бөртеге, һәр сулкылдау-ыңгырашуы җырдан җырга җыела килеп тулган иде инде. Әгәр бушанмасаң, бүгенге хурлыктан йөрәгең шартлап ярылырга мөмкин иде.

Яшьләр ашык-пошык кием алыштырды, тавыш операторы сәхнә идәннәрен дөбердәтеп аппаратураларны җыйды. Һәркайсы үз эше белән мәшгуль. Аның нинди хәлдә икәнен күпне күргән Шәрәфи генә сизеп алды, бушансын бераз дип, якын килми торды. Аннан соң, чәйнекнең кайнарлыгын белергә теләгәндәй итеп кенә, имән бармак сырты белән Сөмбеләнең иңбашына орынды.

– Сеңлем, мин синең сөлгеңне алып килдем, җебегән кершәннәреңне шушында гына сөрт. Күзләреңне яхшылап корыт, яшьләр күрмәсен. Күз яшеңне сүз яше диярләр.

– Рәхмәт...

Сөмбелә, сөлге канатларын җәеп, чишмә улагыннан юынгандай сөртенде.

– Тирләп-пешеп җылап алдың, ә?! Сихәте булыр. Күз яшьләреңне кемгә багышладың?

– Рәнҗедем.

– Рәнҗедем?! Вәт җүләр, мин бит тиңсез мәхәббәтең укшыта, әй лә, үксетә дип торам.

– Өч кешенең күңелен күрер өчен өч сәгать буе шамакайландык.

– Начальство банкетларга чакырса, йөгерә-йөгерә киләбез лә.

– Андый чакыруларга шартын алдан ук белеп, әзер булып барасың. Ә монда... мең урындыкка өч капиталист утыра. Рәнҗедем.

– Рәнҗедем дигәннән, минем Комаргуҗада шәп председателем бар. Дояркалар янына чәйгә чакырды бу мине. Бер сәгать чамасы кәефләрен күтәрдем мин боларның. Саубуллашканда, бухгалтер кыз: «Рәнҗемәсәгез, менә шушыларны гына алыгыз инде, зинһар», – дип, миңа акча сузды.

– Рәнҗетүегез өчен рәхмәт! Башка вакытта тагын да күбрәк рәнҗетегез, яме, мин әйтәм... Ә син мең билет сатылган өчен рәнҗеп торасың.

– Ул күзле бүкәннәр сәхнәгә менеп рәхмәт тә әйтә белмәделәр.

– Ник әйтмәсеннәр, бүлмәңә чәчәк керттеләр.

– Розалармы?

– Әйе, күргән идеңме?

– Юк. Болай да беләм.

– Димәк, кемнән икәнен дә беләсең, шуңа җылыйсың.

– Белмим шул... Бер кәрҗинме?.. Сап-сары розалармы?

– Раштуадай суыкта кәрҗинләп чәчәк китерергә син әкияттәге үги кыз түгел лә... Сарысын сары – анысы факт, ну зур бәйләмне чытырдавык бәйләүгә төреп биленнән кызыл пута белән буганнар. Кагыйдәне исеңә төшерәсе юктыр инде – аншлаг булган көнне солист хисабына банкет. Әйдә, киен тизрәк. Әлмәтне чыккан чакта бер шәп кафе бар, ул төнге уникедә ябыла.

– Юк, юк. Әлмәттә түгел. Үзебезнең Чаллы аша кайтабыз. Анда да шәп урыннар бар. Алар тәүлек буе эшли.

– Баш өсте, Сөмбелә ханбикә!.. Роза, роза – от Дедушки Мороза! – диде дә Шәрәфи үзенең нинди изге эш эшләгәнен дә абайламыйча китеп барды.

Шушы кеше сәхнәдәге тәҗрибәсен өләшеп йөри: әрсезләрне туктата, китек күңелләрне юата, мохтаҗларга җор сүзен садака итеп өләшә. Булган хәлләрне мәзәкчәгә тәрҗемә итеп, чынбарлыкның уң ягын әйләндерә. Авыр сүзләрне рифмалаштырып, ул ике-өч минут эчендә кызның күз яшен киптерде, болытлы дөньясына кояш чыгарып куйды. Һәм бая гына нурлары сүнгән Сөмбелә яңадан эстрада йолдызына әверелде: «Нишләп торам әле мин бу чытырманда?!» – дип, кемнәрдер ташлаган иске декорацияләр арасыннан елмаеп килеп чыкты.

Өч кешегә җырлап, Әлмәттән бер кочак сары чәчәкләр күтәреп кайткач, Зәйтүнә дә уйга калды. Бер кат тынычланып, инде көндәлек мәшәкатьләр белән юана-юана искечә яшәп торабыз дигәндә генә өй эченә сагышлы кояш булып тагын сары розалар бәйләме килеп керде. Хәзер әниле-кызлы чәй эчәргә теләсәләр дә, вакыт табып икәүләшеп телевизор карасалар да, үзара сөйләшеп утырулары элеккечә серләшү-чөкердәшү түгел, ә ниндидер тикшеренү эшләренә охшап кала. Һәр сорау ачыктан-ачык әйтелмәс: кинаяле, ишарәле, икеле-микеле булыр, һәр җавап аклануны таләп итә сыман, ә җавапсыз калган сораулар астыртын нияткә бәрабәр.

– Әни, син яшь чагыңда берәр егетне елатып калдырмадыңмы?

– Безнең Балантауда чәчәкләр телендә сөйләшердәй малайлар юк иде.

– Бәлки, курсташларың арасыннан текә бизнесменнар чыккандыр. Араларында сагынучылары бардыр...

– Яңа байларның сагыну стилен беләм мин. Аларның мәхәббәте саунага, ресторанга, табигать кочагына чакырудан башлана. Текә байлар кызыгырлык яшьтән уздым инде.

– Бәлки, синең җырларыңа гашыйк булып яшәгән берәр министрның хатыны үлгәндер?

– Матбугатта некролог чыгар иде. «Бәлки-бәлки» дип миннән сорау алырга бик оста син. Ә бәлки, негр кияүнең шаяртуыдыр? Аларның бай малайлары гына укый ала бит бездә.

– Әни, син кәрҗин күтәреп кайтып кергәндә Мөхәммәт белән танышмаган идек әле без.

– Әйе шул. Аптырагач кына әйтүем.

– Әни, әйдә залда ремонт ясыйбыз. Стенага алтын сарылы обой ябыштырабыз. Өйгә кояш кергән кебек булыр. Сары розаларны биек аяклы подставкаларга куябыз.

– Әгәр бүтән бүләк итмәсәләр?..

– Ясалма чәчәкләр алырбыз, алар матуррак та, озын гомерле дә... Ә бу «Мистер Икс» таныш кешеңдер, оныткансыңдыр гына, исеңә төшерерсең әле, менә күрерсең, кызым әйткән иде аны, диярсең.

Әйе, искә төшсен өчен белсәң иде әүвәл: яхшылык телиме ул Сөмбеләгә, әллә үч аласы киләме? Күзгә күренмичә, тавышын ишеттермичә, хат-фәлән җибәрмичә генә сагалап йөрүенең сәбәбе рәнҗүме, әллә сокланумы?! Бу күзгә күренмәс кеше гел янәшәдә кебек, Сөмбеләнең кая барып җырлыйсын алдан ук көтеп тора, кемнәр аркылы чакырасын да белә. Тагын нинди сынаулар оештырыр икән әле ул? Моңарчы кыланганнарын кабатламасмы? Ахыры ничек бетәр? Үзен сиздермәве белән җырчыны чыгырыннан чыгарып, соңгы чиктә сәхнәдән этеп төшерергә телиме? Конкуренция дигәннәре сәнгатьтә генә түгел, сәнгатьтә дә бар лабаса! Ләкин Сөмбелә берәүнең дә ярын тартып алмады – ул бөтенләй кияүгә чыкмады, «җырдан туган кызы»на да унҗиде тулды, минем кызым ул, дип эзләп килердәй кеше күптән инде гүр иясе... Сәхнәгә ашкынып килеп кергән ачык кендекле, ялангач ботлы, биеп торган күкрәкле, әмма тавышсыз җырчыларның спонсорларын үзенә каратмады, хөсетлеләрне яуга күтәрерлек мактаулы исеме дә, абруйлылар хисабыннан алынган фатиры да юк. Маньяклар, фанатлар әзәрлекләп борчымады, автограф сораучылар да имза куелган җирдә калды, ияреп йөрмәделәр.

Чәнечкеле гөлләр белән бимазаларга алынган әлеге күзгә күренмәс кешене бик ерактан, яшьлекнең үзеннән эзли башларга кирәктер. Әгәр анда табылмаса, язмыш йомгагын бөтенләй сүтеп, өр-яңадан урап куярга туры килер.

## Аю табаны

Октябрь бәйрәмнәре җиткәч, Балантау авылы кар күбегенә күмелде. Көз дип әйтер өчен артык кырыс, кыш өчен шактый йомшак көннәр иде бу.

Армиягә повестка килгән өйләрдә озату мәҗлесләренә әзерлек башланды.

Җир шарының үз күчәре тирәсендә зыр-зыр әйләнүенә инану өчен кырлы стаканны тутырып, артыннан конфет кәгазе иснәп кую җитә икән. Тик, хикмәти Хода, Идрис солдат хезмәтенә китә дигән елны май аенда ук коммунистлар партиясе эчкечелеккә каршы сәясәт башлап җибәрде: спиртлы эчемлекләрне сату чикләнде, исерткечсез мәҗлесләр үткәрү макталды, киң таралган шәрабларны бетерү йөзеннән җылы якларда җәйрәп яткан сортлы виноград плантацияләрен туракладылар. Ул законга бик тиз арада «сухой» дигән кушамат тагылды.

Кабинетыңа бикләнеп эчсәң, өстәлгә җәелгән гәҗиттә «сухой закон»ның татарчага тәрҗемәсе туры килә. Өеңә кайтып пәрдәңне корсаң, идән астындагы хәзинәңә үрелгәнеңне телевизор экранынннан Генераль секретарь күзәтеп тора. Инде яманатлы эчемлекне лимонад шешәсенә күчереп салсаң, өч борынның берсе барыбер өстеңнән жалу язып җибәрә. Качып эчә алу мәртәбәгә әверелде, «аек туй» кунаклары чоланнан чыкмады, киңәшмәләргә керәсе кызыл чырайлар кершән белән акшарланды, тыйнак сөйләшүләрдә лавр яфрагы, әнис, тмин, канәфер кебек тәмләткечләр авыздан төшмәде.

Зәкиулла Шакирович, армиягә китәсе егетләрнең ата-аналарын парткомга җыеп, Горбачев портреты астында әңгәмә үткәреп алды.

– Сөйләшү шушы булсын, малайларны озатканда, өстәлгә аракы куймыйсыз! Юлга кыстырып җибәрүләр дә ни-ни!.. Татвоенкоматка салмыш килгән призывникларны туп-туры айныткычка озатачаклар, штрафын үзегезгә түлисе. Ишетсен колагыгыз!

– Закун игълан ителгән көнне генә усал була. Яз көне чыккан указ өчен ул хәтлек борчылмасак та ярыйдыр, – дип, җыелган халык парторг белән сүз көрәштерә башлады.

Зәкиулла Шакирович җыелган халыкның кәефен-фикерен ныграк белер өченме ачыктан-ачык сөйләшергә мөмкинлек бирде. Соңгы фикерен кадаклап куйганчы, башкалар ни уйлаганны белү бик кирәк иде. Дөрес, әниләр авызларына су кабып утырдылар, җитәкчеләр әйткәнчә, эшләгәндә озату мәҗлесләренең мәшәкате, җәнҗалы азрак булачак. Шуңа күрә, берсен-берсе бүлдереп, гел ирләр генә гәпләште.

– Җитмеш ел буе әйләнгән башны кисәк туктатсаң, халык ычкына бит соң! Делянкадан утын кайтартсаң да, печәнгә төшсәң, өмә белән өй күтәрсәң дә, гел эш башында әүвәлгечә ярты йөри. Бакча сукалатсаң да, акча биреп кенә котылып булмый.

– Чаллыдагы малай янына иркенләп кунакка барганыем. Яшьләр эштә чакта көндез вакытым иркен дип йөз дә бишенче номерлы кибетләренә чиратка басканыем. Түбәгә, тимерче кадагы белән кадаклап, калай радио беркеткәннәр: «Гражданнар! Минздрав кисәтә! Спиртлы эчемлекләр сәламәтлек өчен зыянлы!» – дип һәр минут саен такылдап тора. Ике сәгать тордым чиратта. Йөз егерме минут дигән сүз бит ул! Әгәр йөз егерме тапкыр «ярамый!» дип тукып газиз башкаеңны миңгерәтсәләр, шуңа ачу итеп гел киресен эшли башлыйсың. Ике шешәне эчке кесәмә яшердем дә яңадан чират койрыгына барып бастым.

– Әйтәм аны җиңги эзләп бармыйча кайта белмәдең Чаллыдан. Күңелле яшәгәнсез икән.

– Сиңа көлке. Тыелган әйберне гел комарланып җыясы килә бит ул. Кирәкме-юкмы, запаста кытаклап торсын. Гозерлеләр арасында бөереңә таянып йөрүе рәхәт.

– Тыелмаганы да җитәрлек. Стакан төбенә унбиш грамм корвалол, егерме тамчы вәлериән, егермене сукыр кычыткан, аю камыры төнәтмәсе саласың да су кушып йөз граммга чаклы җиткерәсең. Аш алдыннан түнтәреп куйсаң, шәп кенә. Әгәренки шул минутта ишек шакысалар, сәкегә җәелгән намазлыкка сикереп менәсең дә «әссәламегаләйкем рәхмәтулла»ны әйтеп башыңны читкә борасың... Эчүчелек авыру бит ул, авыруны указ белән дә, әрләп тә дәвалап булмый. Аны дару белән дәваларга кирәк.

– Тәк, агайлар, җитте! Сез монда, – дип, имән бармагы белән Горбачев портретына таба төртеп кисәтте парторг, – антисоветская пропаганда белән шөгыльләнмәгез. Балантау Һинд океанындагы утрау түгел, сез үзегезнең СССРда яшәгәнегезне онытмагыз. «Сухой закон» көннән-көн корылана бара. Хәзер райком кешеләре дә ГАИ инспекторы кебек өрдереп карыйлар. Җитәкчеләргә эш җиңеләйде, кемнедер урынынннан куарга теләсәләр, берәр рюмка җибәргәнен сагалап кына торалар. Кемнең кем булуына карамастан җәза көтә.

– Ну, алайга китсә, партком секретарьларын исни алмаслар инде, – дип шаяртмакчы булды Идриснең әтисе.

– Парткомны райком иснәр, райкомны – обком! Обкомны иснәүчеләр Мәскәүдә утыра! Так што, тыныч булыгыз, аекка сабышып исереп йөрергә ирек бирмәсләр. Ишетсен колагың – армиягә озатканда, өстәлгә хәмер куймыйсыз!

– Повестка килмәгән ич әле, Зәкиулла! – дип, сөйләшүнең азагын йомшартырга иде агайларның исәбе.

– Кемнәр китәсе однозначно билгеле. Малайларыгыз район хәрби комиссариатының карарын телдән ишетте. Повестка юл билеты бит инде ул. Ә мин сезне беләм, хәзер әче бал куя торган чагыгыз. Сөйләшкәнчә ни-ни!.. Ишетсен колагыгыз!

Булачак солдатларның газиз туганнары парткомнан таралышканда, Гөлчәчәк капка төбендәге сукмакның кырпак карын себереп маташа иде. Идриснең әнисе Халидә Сөмбеләнең әнисе белән күршеләр генә түгел, бер тәрәз төбендә үскән гөлләр кеби генә дә түгел, яшьтәшләр дә, бер чорда укып, клубка бергәләшеп йөреп, бер-бер артлы килен булып төшкән ахирәтләр. Шуңа күрә ул туп-туры Гөлчәчәк янына килеп басты.

– Сөмбеләң кая? Капка төбен өйалды идәне кебек итеп сөртеп тора иде бит. – Халидә елмаерга тырыша, тик кырылган кәефен яшерә алмый.

– Кыз клубта әле. Тәрәзә ярыкларын ябыштыралар. Кыш бик тузынып килергә уйлый, ди, быел. Галанка мич белән ат абзары чаклы клубны ничек җылытмак кирәк?! Капка төбенә аптыраганнан гына чыгуым, әллә берәр кизү йөри инде, Ходаем, бу араларда гел башым авыртып тора...

«Синең башың ындыр табагына Казан кунаклары килгән көннән бирле авырта түгелме соң?!» – дип чак әйтеп куймады Халидә. «Ул төнне безнең өйнең дә уты сүнмәде, игътибар иткәнсездер, шуннан бирле Идриснең сөмсере коелды», – дип тә өстәсә, капка төбендәге хәл белешү ике гаилә арасындагы сәясәткә әвереләсе иде.

Халидә – якты чырайлы хатын. Авылда аны башка Халидәләр белән бутамас өчен «сары чәчле» дип йөртәләр. Хәтта «Халидә чәче сыман сап-сары» дигән чагыштырулар да ишетелгәли. Тик аны сары төс белән генә тасвирлап әйтеп булмый. Кукуруз чәкәненең яңа гына бөркелеп чыккан пумаласы төсле, кыргый болынлыкта елкылдап яткан көзге сусән уты сыман ул чәч Халидәнең йөзенә нур бөркеп тора. Егетләр сөяр яшькә җиткәч, ул, «марҗа кызы» дип гел үртәмәсеннәр өчен, ефәк толымнарын, төенләп, яшел косынка белән каплап йөртә иде. Килен булып төшкәннән бирле кеше сүзенә ияләнде, үртәүләргә исе китми, хәтта яшел яулыгын күзләре төсендәге зәңгәргә алыштырды.

Җиденче класста укыганда микән, Сөмбелә балан тәлгәшләре күтәреп кергән иде. Әнисе ел саен балан җыя, бер өлешеннән как коя, калганын тәлгәшле килеш чормага чыгарып элә. Язга чаклы исән-имин тора, бозылмый. Балан бәлеше пешерәм дисәң, чормадан кирәгенчә алып төшәсең дә бөрчисең... Халидәнең яшенә күрә кан басымы уйнаклап тора иде. Чи баланны сытып, кайнар чәйдә пешекләп эчәргә кирәк иде... Сөмбелә Халидәнең җыелган урын өстендә ял итеп яткан чагына туры килде: шәмәхә фланель халат кигән, яулык бәйләмәгән, толымнары ап-ак мендәр өстендә, зәңгәр күзләре җемелди... уенчык караватка салган Казан курчагы диярсең... Идрис тач әнисенә охшаган. Күләгәсез чәченең һәр бөртеге нурланып тора. Зәңгәр күзле. Атналап кырынмый йөрсә дә ияк очында кабарган төкләре бик сизелми. Икесе тиң какча буйлы, җиңел сөякле. Әнисенә ияреп чыкса, Идрис кыз балага охшап кала. Сөмбелә аны егет итеп күрергә теләми, күбрәк иптәш кыз урынына йөртә. Хикмәте менә шунда...

Гөлчәчәк, себерке сабына таянып, Халидәнең моң-зарларын тыңлады, бүлдермәде, каршы төшмәде, «әйе, әйе» дигәндәй ым кагып торды.

– Нужаланып үстерәсең, үстерәсең малайны, хөкүмәткә илтеп тапшырасың. Инде кешечә бәйрәм ясап озатырга да ярамый икән. Киткән чакта ачык машина кузовында ничекләр итеп урам әйләнмәк кирәк?! Шушындый җилдә җырлыйлар бит әле алар. Районда җыелып, Татвоенкоматка илтеп япканчы күпме туңасылары булыр. Әтиләре әйтмешли, сөяк-санакларын җылытырга җае чыкмаса, салкын тиеп лазаретка егылышып бетәрләр...

– Тегe ике чиләкле имән мичкәң исәнме?

– Исәнен исән. Тик партком Зәкиулла әче бал куймаска кушып бик каты сөйләште бит.

– Ә без чүлмәк утыртабыз, коры сырага чүпрә катышмый. Сосласын үзем әзерлим, балан җыйганда очраштырган колмагым исән...

– Авыз иткәнем бар барын, ну эвәрәсе кулымнан килмәс.

– Өйрәтермен, Халидә. Безнең әни, мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, гел чүлмәк утырта торганые. Әткәй, мәрхүм, коры сыра яратты, хәмер белән мавыкмады...

Кич җитеп, урамга таралган майлы таба, елкы шулпасы, сызыкта кыздырылган бәрәңге, кәбестә бөккәне исләрен күшеккән җилләр исни башлагач, авылга җан керде. Гөлчәчәк мичтәге кисәү башларын, утлы күмерләрне казан астындагы учакка тартты, каз шулпасы куәтлерәк кайный башлады. Яңа кышның салкыны көндезләрен кояш җылысына каршы тора алмыйча килеп-китеп йөри. Зуррак мал суйсаң сүле агып бетәр дип, сугымлыкларга тотынырга тәвәккәллек җитми. Ишлерәк оялы өйләр дә каз өмәсенә ашыкмый. Ит кирәксә, инде күптән симереп туктаган казларны берәм-берәм чалып юана халык. Елкы-каз ите озаграк кайнарга тиешле...

Якты көннәр кыскарып бетеп бара. Эш кешесе бер караңгыда чыгып китә, дөм караңгыда кайтып керә, керә дә аш пешкәнне көтеп утыра. Харис диван-караватка авышып телевизор карый, Сөмбелә, көзге каршында үзенә-үзе иптәш булып, әле бүген генә хат ташучы кулыннан алган «Агитатор блокноты»н актара.

Гөлчәчәк, аш кайнаган арада тик утырмас өчен, чоланга чыгып, ярты чиләк арыш алып керде. Мич каршындагы сәкегә суккан палас җәеп, салкын арышны шунда таратты, уч төбе белән сыйпап тигезләде. Чүмечтәге салкын суны самавыр астында таманлап, вак-вак йотымлап бөркеде дә арышны калын җәймә белән каплап куйды. Баштарак хатыны ватылган электр үтүгенә үч итеп күмер үтүге белән нәрсәдер үтүкли дип уйлады, ахрысы, өйгә көек исе таралмагач, Харис соңыннан сорап куясы итте:

– Нишлисең син анда?

– Салат онына арыш үрдерәм, – диде хатын, тавышын горур гөрелдәтеп.

– Кызым, әниең язгы чәчүгә әзерләнә бугай.

– Әни, чынлап та, нәрсәгә ул?

– Чүлмәк утыртабыз, кызым. Коры сыра булыр.

– Сөмбеләне армиягә алалармы әллә? – дип, яңадан телевизорына ябырылды әти кеше.

– Идрисне кешечә озатырга кирәк, – диде Халидә. Коры сырага статья юк икән. Мин сосла ясап бирәм, калганын күршеләргә тапшырам.

– Салат оны, сосла, коры сыра дигән булып... Гомердә чүлмәк утыртканың юк ич синең!

– Әйе шул. Сезнең өйгә килен булып төшкәннән бирле тотынган кәсебем түгел. Синең коры сыра сораганың юк ич, яратмыйсың бугай.

– Кемне? Синеме?

– Коры сыраны.

– Ә син чынлап та чүлмәк утырта беләсеңме?

– Беләм.

– Вәт, хикмәти Хода! Кайчан өйрәндең?

– Әнидән күрдем... Әни әбидән өйрәнгән... Әбием, бабакай тиешле кешебездән яшь килеш тол калгач, Габдулла муллага бала караучы булып ялланган, шунда кул арасына кергән.

– Да, кызым. Әниеңнең чыбык очы муллалар нәселенә барып тоташа икән... Син дә өйрәнеп кал. Кооператив ачарбыз. Җырлый-җырлый сыра сатарсың...

Ачның ачуы яман дигәндәй, шаяртып Сөмбеләнең кәефен күтәрергә теләгән иде Харис, киресенчә килеп чыкты, кыз әтисенә шундый итеп карап куйды, телевизор экранында калын-калын ак сызыклар йөгерешеп алды хәтта.

Яшерен-батырын түгел, өйдәгеләр Сөмбеләгә хәзер никтер кияүдән кайткан кыз кебегрәк итеп карыйлар. Була бит шулай, клубтан кайтышлый ат җигеп сагалап торалар да толып каплап билгесез тарафтагы аулак өйгә алып кайтып ябалар... Үзен мәҗбүр итә алганы язмышка баш иеп яшәп кала, ә теләмәгәне бер атнадан булса да барыбер качып кайта. Тешләнгән йә корт төшкән алма ише кипшеп, сулыгып ятасың. Андыйларга авыр сүз әйтергә ярамый, серкәләре су күтәрми; шук егетләр, җилдән бала тапкан яшь бичәләр хакында мәзәкләр сөйләсәң, мыскыл итү кебек килеп чыга. Ә инде үгет-нәсихәт биреп, яучылар чакырту, кодалау, әти-әниләр аркылы таныштыру кебек йолалар белән колагына чалынсаң, кем булуыңа карамастан, өй эчендә генә түгел, авылда бер кан дошманга әвереләсең. Димәк, баланың китек күңелен сыйпап, холкына ятып, кыланышларына түзеп яшәргә туры килә. Әгәр көннәрдән бер көнне: «Мин Казанга китәм!» – дип кырт кистереп әйтә калса, Сөмбеләгә һичкем каршы төшмәс, киресенчә, сөенерләр генә иде. Казан каласы – зур кала, мул дөнья, киң дәрья... Миллионлаган кеше арасында китек күңелле, сынык сөякле, яраланган йөрәклеләре дә аз түгелдер. Сөмбелә китеп урнашса, анда һичшиксез насыйбын-тиңен табар, бер бәхетсезне бәхетле итеп булса да, үзе бәхетле була алыр иде. Мәгәр кызый авылдан китү турында сүз кузгатмый, артистлык хыялы турында кат-кат искәртеп өйдәгеләрнең теңкәсенә тими. Сөмбелә берәүне көтә. Ул көткән кеше авылның чокыр-чакырлы урамнарыннан олы юлга чаклы ат белән алып чыгачак, ә Казан юлында алар һичшиксез сап-сары «Москвич» машинасына күчеп утырачак. Көткән кешесе киткәннән бирле җәй белән кыш алышынды, хыялы алышынмады, бары тик теге ат кына, кыңгыраулы тарантастан тугарылып, түрле чанага җигелде. Кыз өч ай эчендә үзенә йомылды. Эчтән сызды, тик ашаудан калмады, тумышыннан килгән елмаюын югалтса да, клуб ачкычын авыл советына илтеп ыргытмады, сөйләшеп утырасы урында авыз эченнән көйләде. Ошамаган сүз ишетсә, «ярамыйга карамый»ны җырларга тотынды... Август төнендә гармунчы янында калып ике араданиләр булганын Сөмбелә бары тик үзе генә белә. Һәм өйдәгеләрнең аның турында начар уйлап хафалануы белән ирексездән килеште ул. Иң мөһиме, шушы борчулы көннәр бәрабәренә төпчек кыз әти-әнисеннән ирек яулады...

Сәке өстенә җәелгән арыш көяз кәләшкә әверелде. Гөлчәчәк күрмәгәндә Харис үзе дә килеп җәймәне ачып карый, кулы белән сыйпап тигезли, су бөрки, орлыклар тылсымын бик сакланып кына кире каплап куя.

Бишенче көнне арышның шытымы бөртек буена җитте. Гөлчәчәк үрентеләрне табаларга җәеп сүрән мичкә тыкты. Иртәнгә алар үргән килеш әүвәл пешә, аннан шытырдап кипкән була.

Келәттәге лар артында кырык еллык тузан эченнән кул тегермәнен эзләп алып керделәр. Аның ике ташы да исән-сау иде, мунчала белән юып корыткач, чатнаган, кителгән урыннары күренмәде.

Кул тегермәне белән салат оны тарттыру курчак уенына әверелде, Сөмбелә әйләндерде, әнисе ташка арыш коеп торды. Харис кызлар уйнаганны карап көлеп утырмакчы иде, йомыш куштылар үзенә, заманында мич казнасы янында хезмәт иткән, ә хәзер исә көрпә салудан арыга тотылмаган кумер чүлмәген, чоланнан алып кереп, чәй содасы белән эчен-тышын ышкып юасы бар иде. Ир кешенең кул көченнән корым катламы кырылып, чүлмәк кызыл кирпеч төсенә керде.

– Гөлчәчәк, тишек ләбаса бу, кадак эшләпәсе сыярлык.

– Төбеннән мәллә?

– Юк, төптән чиртеш буе өстәрәк.

– Шулай тиеш. Әйтәм ич, әбиләрдән калган хәзинә ул. Син аны агач бөке белән томала.

– Ну, хатын! Ул-бу була калса, өр-яңадан борынгы заманча яши башларга әзер икән без...

– Тәүбә, диген, ниткән «ул-бу» ди сиңа! Шөкер, әнә Горбачевыгыз Әфгандагы сугышны туктатырга уйлый, ди, солдат улкайларыбызны кире кайтарачак, ди.

– Ә Идрисләр ник китә алайса?

– Идрисләр алар Кызыл мәйданда Җиңү парадларында мактаныр өчен генә барып кайтасылар! – диде Харис, кызының күрше егете турындагы сүзгә кушылуына сөенеп.

Кичкә тагын мич ягылды. Усак утыннары шарт-шорт янган арада, Гөлчәчәк, бик эшем кешесе чыраен чыгарып: «Тегене бир, моны китер!..» – дип, өйдәгеләрне тыпырдатты. Харис, бер култык арыш саламы алып кереп, аны салкын суда юып бирде. Сөмбелә ипи камыры изә торган күәсне алып керде. Калганын Гөлчәчәк үз кулына алды.

Ярты чиләк иләнгән арыш оны өстенә теге салат онын салгач, ипи күәсе тула язды. Башта Гөлчәчәк бу ике онны коры килеш болгатты, аннан кайнатылган суны җылымсалатып әз-әзләп салып торырга кушты. Күәс эчендәге боламык сыек камырга әверелде. Гөлчәчәкнең кулына күз иярми. Атна саен чүлмәк утыртып шомарып беткән диярсең! Ул арыш саламын чүлмәк эченә тыгызлап тутырды да сыек камырны шунда бушатты.

– Салам белән камырны бергә кушкач, сыерларга башак болгату була түгелме соң инде бу, Чәчәк? – дип аптырап калды Харис. Тик Гөлчәчәк җавап кайтармады. Эшендә булды.

Ипи салганда, сулы пумала белән үрелеп, мич көймәсенең көлен ашыкмыйча сыпырып алалар иде. Ә бүген исә утлы күмерләрне бөртекләп тарткач, кызуны әрәм итмичә, тиз арада чүлмәкне таш өстенә шудырдылар. Мич капкачын иртәнгә чаклы ачарга ярамый иде...

Төн уртасында өй эченә таралган куе ис йокыдан уятты. Серкәләнгән арыш, төче күмәч, әче көлчә, яңа киселгән ипи кыерчыгы, кыздырылган сохари катыш шоколад тәме килә иде әлеге истән.

– Сосла исе инде бу, җанашларым! – диде Гөлчәчәк, мактанып.

– Кызым, син анда ничек түзәсең, әле бу якта да чыдар хәл юк, – диде Харис, чүлмәкле мич ягын үз куышы иткән Сөмбеләне үртәп.

– Агач кашык белән үрелеп авыз итимме соң, әни?!

– Шаярма, кызым! Өлгермәде әле ул.

Чүлмәк чыкканны көтеп иртүк торып бассалар да, Гөлчәчәк мич капкачына берсен-бер якын җибәрмәде.

Мал-туарларга печән салып, сыерны савып, казларны ишегалдына чыгарып җим сипкәч, капка биген ачмыйча гына, ниһаять, чүлмәкне мичтән кисәү белән шудырып чыгардылар. Колач буе имән улакны сәке белән урындыкка таяндырдылар. Улакның аскы ягына туры китереп, идәнгә биш литрлы бидон куйдылар. Ике кирпечне янәшә тезеп, сәкедәге чүлмәкне улак авызына утырттылар.

Гөлчәчәк агач бөкене тартып алгач, чүлмәктән кызгылт-көрән сосла бәреп чыкты. Ул көнбагыш мае кебек тавышсыз акты. Бидон төбенә күбрәк җыелган саен кызыл төсе куерды, көрән булып күренә барды. Улактагы гөрләвек тынгач, бүгенге муллыкка сөенгәндәй җырлап утырган самавырдан ике чүмеч су алып өстәделәр. Кайнар су чүлмәк эчендәге саламнарга качып калган куе сосланы юып алып чыкты.

– Ялап карар өчен бөтенебезгә дә шушысы җитә, – диде Гөлчәчәк, тулыр-тулмас бидоннан агач кашык белән чумырып алгач, – сосла салкын килеш тәмле була. Бар, кызым, өстен яп та чоланга чыгарып куй.

Яшьләр кичке уенга киткәч, Гөлчәчәк нигез күршеләре Халидәгә күтәренеп керде: бер кулында бидонлы сосла, икенчесендә колмаклы төенчек.

Булган сосланы җылымса су белән болгатып ике чиләкле имән мичкәгә тутырасың. Эчемлек әзерләгәндә бары тик кайнаган су гына яраганын авыл җирендә артык аңлатып торасы юк... Мич башында бер тәүлек уйнагач, эчемлекнең колмагын сөзеп салкынча урынга – идән астына төшереп куясың. Менә шушы була инде коры сыра, шушы инде ул «чүлмәк утырту»ның сихәтле бәлзәме!

Балантауның яз көне киткән егетләре һәркайсысы аерым-аерым мәҗлес үткәргән иде, алар «сухой закон»га эләкмәде. Ә менә хәзер, өч егет, повестка алгач, җыелып киңәштеләр-киңәштеләр дә, өйдән өйгә йөреп лимонад шешәсенә карап утырганчы Идрисләрдә генә саубуллашыйк, диделәр. Халидә апаларының чүлмәк утыртканын Идрис аркылы ишеткән иде инде яшьләр. Бөтенесенең коры сыра татып карыйсы килде. Яшьләрнең генә түгел, Гөлчәчәк, Сөмбелә, Харисның да авыз иткәне юк иде әле борынгылардан калган яңа эчемлекне. Күршеләргә керер алдыннан Сөмбеләгә нәсихәт тукып алдылар:

– Кызым, Идрис алдында турсаеп утырма, авылдан боегып китмәсен.

– Өмет белән китсенме, әйт әле, әни?

– Бу дөньяда бик күп нәрсәне кеше күңеле булсын өчен генә эшлисең. Сездән көнләшеп җәнҗал чыгарырдай егетләр калмады. Идрис янында дустанә утырсаң, укаң коелмас. Илгә солдат үстергән Халидә апаң да сөенер...

Халидә, мәҗлес алдыннан кибеткә барып, җиде тиенлек кырлы стаканнар алып кайтты. Егетләр ягыннан кем паштет, кем гөбәдия, кайсыдыр каз бәлеше пешереп китерде. Табында ипи куярлык та

урын калмады. Нигъмәт арасында гөнаһ шомлыгы булып качып утырган кырлы стаканнарга кояшта көйгән колмак чәчәкләре төсендәге эчемлек салынгач, кунаклар бер мәлгә шым калды.

Колхоз председателе отчет-сайлау җыелышлары башланганчы дип өч атналык путевка белән ял йортына киткән. Авыл советы рәисенең мунча кереп йөргәнен күргәннәр, баш бухгалтер Шәмәрдән ит комбинатыннан кайтып җитмәгән, диделәр. Юл кирәк-яраклары тутырылган өч рюкзак, хезмәт итү урынына барып җиткәнче юл чыгымнарын капларлык өч конверт, председатель исеменнән бер ай алдан кул куелган өч мактау грамотасы – һәммәсе дә партком секретаре кулында иде.

Бүләкләрне тапшырып: «Исән-сау әйләнеп кайтыгыз, сез колхозга бик кирәк!» – дигән теләкләрне горурлык хисе белән ике кат кабатлагач, Зәкиулла Шакирович кул астына туры килгән стаканлы эчемлеккә үрелде. «Нүжәли эчә инде бу, шушы хәтлек кеше арасында» дигән сынаулы, хәйләле, өметле карашлар аңа текәлде. Парторг, Франциядәге Шампань провинциясенең атаклы дегустаторы кебек, бер йотым эчемлекне иреннәре арасында чәпелдәтеп матчага бакты. Бөтен кеше алдында маңгаеннан иягенә таба йөзе агарды... Тагын берне йоткач, иягеннән маңгаена таба кан йөгерде... Һәм ул, мәҗлестәгеләрне сөендереп, кырлы стаканны илле граммлы йотымнар белән дүрт селтәнүдә бушатты.

– Куаска охшаган! – диде парторг, ялтыратып кырылган мыек урынын сыпырып. – Рөхсәт!

Кунаклар челлә сусавы белән стаканнарга ябышты.

Коры сыра куас түгел шул ул...

Өч егет исәнлегенә өч стакан түнтәреп куйгач, яшьләр җыр эзли башлады.

– Егетләр, кагыйдәне беләсез! Хор белән берне җырлагыз да мин китәрмен, җан көеге булып утырмам, – диде парторг, саубуллашырга теләп.

Дан сиңа, дан, совет солдаты!
Дан сиңа, дан, совет солдаты!

Әлеге җырның соңгы кушымтасын кәефле җырчылар шулхәтле күп кабатладылар ки, Зәкиулла Шакирович үзе дә батыр солдат булып кайтып китте.

Вак-вак йотымнар белән авыз итә торгач, Сөмбелә дә бер стаканны бушатты. Аның елмаюын янында утырган Идрискә багышладылар. Ләкин кызый тәрәзәләр өстендәге кашаганың чигүле пар күгәрченнәренә текәлгән дә күз алдына китергән берәүгә елмаеп утыра иде.

Сөмбеләнең бергә укыган дуслары авылда берәү-икәү генә. Күбесе йә укырга кереп, йә эшкә урнашып Казанда калды. Алар ял көннәренә кунакка кайтып клубка чыгалар, бииләр, уйныйлар, студент тормышы белән мактанышып, укырга керә алмаганнар алдында масаялар да тагын китеп баралар. Повесткалар атна уртасына килгән. Казаннан кайтучылар юк иде. Бер-ике яшькә булса да үзеннән кечерәк мәктәп балалары белән күмәк җыр җырлап утыруны бик өнәмәде Сөмбелә һәм кинәт торып басты. Бу аның үзем генә җырлыйм дигән сүзе иде.

Йә «Резидәкәй»не, йә «Озату»ны җырлап егетне елата бу хәзер дигәндәй, кәефле кунаклар маҗара көтеп Идрискә таба борылды.

Ә Сөмбелә маҗара көткәннәрнең өметен акламады, елар хәлгә җитешеп күзләренә яшь тыгылган теләсә кайсы җан иясен елмайтырлык җыр башлады. Кушымтасы бигрәкләр дә күңелле:

Син сөймәсәң, мин дә сөймәм –
Гөл үсмәгән битеңә...

Җырның мәгънәсен тигез мәхәббәткә юрап, Идрис өчен сөенделәр. Егет, каушавыннан үзен кая куярга белмичә, Ильич лампасы астында җемелдәп торган җитен чәчен ике кулы белән каплап, өстәл читенә таянды. Ояла-ояла куануы ул аның... Арткы өйдә аерым табын корып утырган туганнар арасындагы Гөлчәчәк белән Харисның гына күңеленә шом керде...

Соңгы өч ай эчендә артык күп яңгырады инде бу җыр, чамасы югалды. Һәм ул җыр азатлык яуларга теләгән Сөмбеләнең эчке бер фетнәсенә, каршы дәшүенә, көрәшкә чакыру авазына әверелде кебек. Кыз Идриснең армиягә китүеннән тәм табып тантана итте. Пионер яшеннән бирле «иярчен тай» булып тагылган, «чал чәчле», «әнисе кебек», «тумас борын картайган», иптәш кыз урынына калган күрше малаеннан котыла, ниһаять... Шул ук вакытта Сөмбелә үзенең тәмам аяныч ялгызлыкта калганын белә. Әти-әниләр кичке уеннардан кайткан яшьләргә рәхәтләнеп серләшү өчен дә ярамый бит соң ул. Алар бер яклы вәгазь, киңәш, нәсихәт кенә. Унсигез яшьлек кызлар күп очракта якын туганнары арасында да үзләрен ялгыз хис итә... Һәм ялгызлык аны бермәл һич көтмәгән кискен чараларга этәрә.

Парторгның: «Исән-сау әйләнеп кайтыгыз!» – дигән изге теләге бер атнадан ук кабул булыр дип кем уйлаган?!

Кар ява башлаганны төн уртасында Идрисләрдән җырлашып таралышкан кунаклар гына күргән иде. Ә инде иртән бөтен авыл ак сөенеч белән сөенде. Тәүге кар соры мохитне акшарлап куйгач, Балантауның исеме җисеменә тач туры килде, авылдагы һәр куак, тал-тирәк балан агачына әверелеп чәчәк атты диярсең...

Кар бөртекләре әле ябышкак түгел – бөтерчек җилләр искәндә, алар бизәкләрен саклап кына тәрәзә йөзеннән капка өстенә куна, рәшәткә баганасыннан аяк астына килеп төшә.

Бар тынлыкка берүзе калганмы – Идрисләр түбәсендә сыңар ала карга зарланып утыра.

Идрисләр капка төбенә «ГАЗ-52» килеп туктады. Машинаның әрҗәсенә сыер савучыларны җәйләүгә илтә торган озын урындыклар беркетелгән иде. Каршы искән юл җиле йөзгә туры бәрелмәсен өчен әрҗәнең алгы өлешенә брезент ышык куелган.

Кичәге коры сыраны өчәр стакан каплап өлгергәч, егетләргә тагын байлар чырае керде. Инде районга чаклы ачык машинада җырлап барырлык куәт бар иде. Колхоз идарәсе йортында озак тоткарланмадылар. Озата килгән туганнарның киңәш-нәсихәтләре өч егеткә дә бертөрлерәк яуды:

– Бүрек колакчынын төшереп бәйлә, колактан кергән җил кире чыкмый.

– Рюкзагың аяк астында калмасын, ризыклар сытылыр.

– Документларың онытылмады микән инде, Ходаем?..

– Теге акчаларыңны барып җиткәнче тотасы түгел!

– Өчпочмакларны ашый-ашый барыгыз, суынгач тәме калмый аның...

– Барып җитүгә хат язып сал. Иренеп ятма анда...

Әгәр машина кузгалып китмәсә, үгет-теләкләрнең бетәсе юк иде әле.

«Алмагачы» көенә көне буе җырларга була. Өч урамны яңгыратып әйләнгәндә дә куплетлар кабатланмады. Ниһаять, район борылышына чыгып, күмәк җырны көчәйтер өчен генә әрҗәгә төялгән яшь-җилкенчәкләр коелгач, машина армиягә китте... Яше җитеп килгәннәр сагышланып кул болгады, ә тизрәк үсеп солдатка китү турында хыялланган үсмерләр кызыгып, көнләшеп калды...

Ә бер атнадан Идрис кайтып төште. Сәлперәйгән рюкзагын бер иңенә элгән килеш, юл уңаенда очрардай авыл машиналарына күренмәс өчен карлы сукмаклардан кача-поса, язмышына рәнҗеп кайтып төште... Ул атна буе урамга чыкмады, кеше күзеннән качып ятты. Халидә парторг бүләк иткән рюкзакны эчендәге вак-төяк бүләкләрен барлап кире илткән иде – алмадылар. Бүләк ителгән, акт төзеп гамәлдән чыгарылган, кул куелган, өегездә калсын, диделәр. Әнисе рюкзакны тагын алып кайтып тоттыргач, Идрис үзен каты сугышта фронтовик дусларын ташлап кирегә йөгергән дезертир кебек, антыннан ваз кичкән сатлык җан кебек хис итте... Әнисенең юатырга теләп, «И улым, әйбәт булган ич, ил-җирләр тыныч түгел. Ике ел буе ут йотып яшәгәнче, сөенергә генә кирәк...» дигән сүзләрен урамда очраган беренче егет үк сызып ташлаячак:

– Нихәл, негодный, борып кайтардылармыни?!

Балантауда армия хезмәтеннән «ак билет» белән калган егетләр бар барын. Тик аларның берсенең дә кушаматы «негодник» түгел. Идрискә дә кушмадылар андый сүзне. Ә менә Татвоенкомат комиссиясе куеп кайтарган диагноз кушамат булып бик тиз ябышты. «Әй, аю табаны!» дип дәшсәләр, Идрис ирексездән борылып карый хәзер...

Сөмбелә житен чәчле күрше егетенең кире кайтуына сөенмәде дә, көенмәде дә. Кыз инде август киченнән бирле «мин сине авылдан коткарам» дип алмалар тешләп ант иткән назлы гармунчыны көтә...

## Назлы гармунчы

Кибет күләгәсеннән тагын берәү пәйда булды. Монысы чынлап та көткән кунакка охшаган: ыспай, пөхтә, җыйнаклыгы алагаем гәүдәсенә күрә түгел, тузан кунмаган күн чабатасының ачык челтәреннән ап-ак юка оекбашы балкый – Балантауга килеп төшкәннән бирле урамнарны җәяү гизмәгәне әллә каян күренеп тора. Тыгыз тәнендәге ак теннискасы бер үлчәмгә кечерәк кебек сыланган. Зәлеференнән алып маңгаена чаклы капланган куе кара чәченең һәр бөртеген кызган бишнәгә урап бөдрәләткән кебек. Мыек чолымнары ияк читендә елкылдый. Кысык күзләренең елтырына, калын кара кашларының кыйгачлыгына да игътибар итсәң, бу абзыйның ерак бабалары, көяшкә якынрак тарафларда яшәп, соңрак безнең якларга күчеп килгәнне чамалавы кыен булмас.

Сөмбелә каушамады түгел, каушады – исәнләшергә дә онытып телсез калды. Хәер, тиз арада өненә килеп, кулындагы көшел көрәген мылтык урынына күкрәгенә терәде дә парторг ягына борылып үрә катты:

– Зәкиулла Шакирович, ни боерасыз?

– Боерык алганчы, менә кунаклар белән таныша тор: «Наз» ансамбле җитәкчесе Марат Гомәр абыең бу!

– Абау! – Агач көрәк, Сөмбеләнең кулыннан шуып китеп, сай чүәк эченнән күренеп торган аяк йөзенә калагы белән килеп төште. – «Наз»ны бик яратам мин, сезне дә бик яхшы беләбез. Күргәнем генә юк иде. Менә нинди кеше икәнсез?!

– Нинди кеше? – Марат Гомәр мыек чолымнарын сикертеп елмаеп куйды. Каршы килмәсәгез, күрешер идем дигәндәй, сак кына кулын сузды, аннан нигәдер кызның кулын җибәрмичәрәк торды. – Нинди кеше мин? – дип кабатлап сорады ул тагын һәм, әлбәттә, юри, вакытны сузар өчен генә.

– Матур артист.

– Син дә чибәр кыз. Артист булырга теләсәң, бик тиз хыялыңа ирешә алыр идең. Булышырбыз!..

Сүзгә парторг катышты.

– Берүк күңеленә коткы сала күрмәгез, Марат туган, көч-хәл белән генә тыеп торабыз без аны. Кечкенәдән коеп куйган җырчы ул. Быел укырга керәлмичә кире кайтты.

Артист уч төбендә утлы күмер тотып йөри мәллә – Сөмбеләнең бармаклары пеште, кулын көчкә тартып алды.

– Медицина институтына барып карады, – дип дәвам итте парторг. Кызны һушына китерергә теләгәндәй, аның тавышы кисәк кырысланды. – Бер чибәр кыз авылда төпләнеп калса, аңа өметләнеп, ким дигәндә җиде егет кала. Ә колхозга яшь көчләр һай бик кирәк! Китер әле, Сөмбелә, шул көрәгеңне, казыкка бәйләнгән кебек торма. Үзем күтәрим лутчы.

– Зәкиулла Шакирович, икмәк калагы ул, ташлама!

– Үрәтмә, кызый, беләбез! Ә менә теге кунагыбыз – шагыйрә! Гөлҗиһан апа, килегез әле. Койма тирәсендә бик чиста түгелдер. Дару үләннәре җыясыгыз килсә, мин сезне Спас якларына – Такталга алып кайтырмын. Әйдәгез, клубны карап чыгыйк, кичен чыгыш ясыйсы булыр...

Киң балталы ачкычның юан көпшәсе йозак кендегенә туры килалмыйча интектерде. Тере шагыйрәне күргәч коелып төште Сөмбелә. Аның җырлары модада бит хәзер. Концерт куйсаң да, мәҗлескә җыелсаң да, савымчылар машинага төялеп җәйләүгә китсә дә, гел Гөлҗиһан апаның җырлары яңгырап торыр.

Моңарчы Сөмбелә шагыйрьләрне райком секретарьлары кебегрәк итеп күз алдына китерә иде. Күреп сөйләшәсең килсә, ишек төбендәге сакчыга паспортыңны күрсәтеп керәсең, чират торып үз сәгатеңне көтәсең, кабул итеп кәгазеңә автограф куйган арада, ул әллә ничә начальник белән телефоннан сөйләшеп өлгерә. Рәхмәтеңне әйтеп, вакытын әрәм иткәнгә гафу үтенеп чыгып китәсең. Ә ул, мәгърур гына баш изәп саубуллаша да тагын шигырьләренә чума...

Бактың исә, сукыр кычыткан, кара әрем, меңьяфрак, бака үләне кебек аяк астында түшәлеп яткан чүпне дару үләннәре дип хөрмәтләп җыеп йөри торган башка авыл апасы Гөлҗиһан Зәйнашева үзе икән! Сөмбеләнең аңа Дәү апа дип якын итеп эндәшәсе килде. Шагыйрә шултиклем гади иде ки – аның чүәге Сөмбеләнеке кебек, өстендәге ябык изүле, озын җиңле чуар чәчәкле ситсы күлмәге күрше апасыныкы шикелле, юл тузаны кунмасын өченгә бөркәнгән күгәрчен тамагы төсендәге сатин халаты әнисенекедәй таныш. Августның урып-җыюга ярардай кызу торуына карамастан, баганалы көрән оек киеп килүе белән кариләрчә самими ханымга әверелә иде. Шагыйрә икәнен белгәч, Сөмбелә аны фотога төшергәндәй текәлеп, кызларга гына хас җентекле һәм дә ки көнләшүле караш белән күзәтте.

Куна тактасы өстендә озаклап он иләгән хуҗабикәләрнеке төсле генә итеп йөзенә кершән тузаны өргәннәр. Беренче карашка ук игътибарны үзенә җәлеп итә торган үзенчәлекле борыны да табак битенә килешле генә. Җәенке иреннәре кызгылт иннек белән бөрелгәч, иягендәге тыгыз җыерчыклары да өзлексез елмаю өстәп тора. Кечкенәдән михнәттә үсеп, моң-зарларын кешегә сиздермәскә өйрәнгәнгә охшый бу апа.

Шагыйрә клуб тирәсендәге гарасатта үсә алган әрсез үләннәрне туй чәчәге кебек иркәләп беләгенә салды.

– Авыл халкы аптекада яши. Үз кадерен үзе белми генә. – Һәм шагыйрә килә килешкә үк үләннәрне парторгка сузды. – Менә боларын машинага илтеп куегыз әле, Зәкиулла, бераз кипши торсын. Исән кеше дулаган җирдә зәхмәт юк, завод-фабрика тирәсеннән генә җыярга ярамый. Мин бит өемдә кибет чәен эчмим, сукыр кычыткан төнәтеп эчәм, давлением югары минем. Миңнурдан аерылгач, гипертоникка әйләндем.

Парторг, шагыйрә кочагыннан алган үләннәргә әллә ни исе китмичә генә, янә рәшәткә төбенә илтеп куймакчы иде, ләкин кунак апаның чын күңелдән ачылып китүен күреп, ул уйдан кире кайтты, машинага таба юнәлде.

– Исемең ничек соң, кызым?

Сөмбелә йозакка иелгән җиреннән тураеп басты. Инде шагыйрә дә аңа бик текәлеп сыный карады һәм үз соравына үзе җавап эзли башлады:

– Тукта, исемеңне әйтми тор... Күпчелек кызларның исеме Алсу, Ләйсән, Гөлназ, Гөлнара хәзер. Туры китердемме?

– Юк. Сөмбелә мин... Әнием – Гөлчәчәк, апам – Резидә, Казандагы туган апам – Лилия...

– Тәрәз төбендәге гөлләр кебек икәнсез... Сөмбелә... Гиацинт дигән бик матур чәчәк исеме.

– Дару үләне мәллә, Гөлҗиһан апа?

– Белмим шул, балакаем. Җирдә күпме чир булса – шулхәтле дару үләне үсә, тик кеше үзе яшәгән җирдәге үләннәрне генә файдаланырга тиеш. Сөмбелә чәчәге безгә бик ерактан күчеп кергән ул. Исемең үзеңә бик килешә. Минем дә синең кебек чакларым бар иде.

– И Гөлҗиһан апа, сез әле дә бик чибәр ич!

– Рәхмәт, балакаем, мактауны ялган булса да тыңлавы рәхәт аны. Мине дә чибәр дип әйтә белгәч... синең фантазияң бик көчледер...

– Кем белгән инде, Гөлҗиһан апа.

– Клуб тирәсендә сәләтсез кеше эшләмәс. Җырлыйсыңмы, биисеңме, әллә нәфис сүз остасымы син?

– Бәйрәм кичәләрендә бөтенесенә тотынабыз инде.

– Зәкиулла, Марат! – дип янына дәште шагыйрә. – Алыгыз әле Сөмбелә кулыннан шушы ачкычны, ат башы хәтлек йозак белән сугышканын читтән карап тормагыз.

– Кунаклар алдында юри генә иркәләнә ул! – Парторг шелтәләгән рәвеш китереп сөйләнсә дә, чынында исә тимер аркау белән аркылыга бикләнгән калын ишекне бик теләп ачты. Клуб эчендәге тәртипне күздән кичергәч, алар, ишекне янә бикләп, ындыр табагына очрашуга ашыктылар.

Ындыр табагына менеп җиткәнче шактый таушалган өстәлне кызыл постау белән каплап янына өч урындык куйгач, көшел каршында җыйнак президиум барлыкка килде. Өлкәнрәкләр мәкинә чүмәләсе өстенә брезент җәеп утырды, яшьләр көрәкләргә таянып артка басты. Утны өзделәр – тигез гөрелдәү белән эшләп торган барлык двигательләр берьюлы сүнде, амбар түбәләрендәге тук күгәрченнәр генә, партиянең урып-җыю идеологиясенә үзләренчә өлеш кертергә теләгәндәй, өзлексез гөрлиләр иде.

– Ярты гына сәгатькә! – дип башлады парторг. Әлбәттә, тамашачыларга карап әйтелсә дә, вакыт чамасын сиздерүе килгән кунакларга алдан ук искәртеп кую өчен кирәк иде. – Сезнең алдыгызда җырчы шагыйрә Гөлҗиһан Зәйнашева һәм баянчы композитор, «Наз» ансамбленең җитәкчесе Марат Гомәр. – Ике кунак өчен берьюлы кул чапкач, көчле алкышлардан теге күгәрченнәр шым булды.

Шагыйрә кай арада сатин халатын салып яшергәндер, анысын Сөмбелә сизми калды, ул хәзер яңгыраган һәр шигырьне отып калырга әзер, чөнки алар кайчан да булса барыбер көйгә салыначак, иртәме-соңмы аны җырларга туры киләчәк иде.

– Шигырь язу – елауның бер төре ул, шуңа күрә мин сезгә сагышлы шигырьләремне укымый торам, аларны, боерган булса, бүген кич иркенләп очрашканда тыңларсыз...

Ике кунак вакытны урталай тигезләп бүлешкәннәр иде, ахрысы, шаян шигырьләр төп-төгәл унбиш минут яңгырады.

Баянчы исә, бераз уйнаган саен, бер кавым акланып ала. Районга килгәч, бригадаларын бүлеп авылларга ваклап таратканнар икән. Гөлҗиһан Зәйнашева белән Марат Гомәр Балантауга эләккән кебек, яшь җырчы Кларане баянчысыз гына, язучы Самат Шакирга ияртеп, күрше авылга җибәргәннәр, ди. Районны тизрәк йөреп чыксыннар өчен.

Ындыр табагында үзенең җырлары яңгырый алмагач, шагыйрәнең кәефе төште – йөзендәге елмаюы сүнеп-сүнеп алды. Шаян шигырьләрдән иләсләнгән халык мәкинә өстеннән төшәргә ашыкмады. Авыл җирендә йоласы шундый – гармун уйнаганда җыр кушылырга тиеш.

– Гөлҗиһан апа, үзегез җырлагыз инде, моңыгыз бардыр, юкса бу хәтле җыр яза алмас идегез! – дип ялынды яшьләр.

– И балакайларым, җир йөзендә нинди һөнәр бар – бөтенесен эшли алам, түлке җыр белән бию генә сорамагыз.

– Алайса, әнә Сөмбелә җырласын, «Сәяхәтче»не!

– «Үз илемдә»не!

– «Күңелле ял итегез» дә шәп җыр.

Бәлкем, бу минутта Сөмбеләгә бераз ялындырырга да кирәк булгандыр, ләкин ул, алдан ук сүз куешкандай, исемен ишетүгә, Марат Гомәр янына килеп басты. Чын гармунчыга ияреп җырлыйсы бик килә иде аның. Алай да каушавы хак – ул ялгыш баянның бакалары ягында калган иде. Анысын гармунчы үзе төзәтте, кызның сул кул ягына күчеп басты. Артистларча гына пышылдашып алдылар.

– Нинди тональностьта уйныйм?

– Белмим мин. Башлап җырлыйм, ә сез иярегез.

Юлга чыккан һәр кеше җырлый алырдай гади сүзләр, Сөмбеләнең ләззәтле моңы белән баянның аһәңле иҗекләренә килеп кушылгач, тыңлаучылар гына түгел, хәтта ындыр табагында өелеп яткан август киче дә өнсез калды.

Сөмбелә яңа җырларны тиз отып кала. «Сәяхәтче» җырын ул инде кырыкмаса-кырык башкаргандыр, кирәксә, патефон тәлинкәсе кебек, көннең-төннең кайсы вакытында кушсаң, шунда җырлый ала. Менә хәзер дә үзен иркен тотты, шигъри юлларга уйлары да иярде хәтта... Күр әле син... бөтен яшьлеге авылның мактанчык уенчыларына ялынып үткән икән! Балантау гармунчыларына иң әүвәл, җырны исләренә төшерер өчен, авыз эчендә генә көйләп аласың, аннары кушымталарда сине куып җиткәнен көтеп торасың. Кайберләре исә тик бер генә тирәдә уйный ала – өйрәнчекләрдән өйрәнгән до мажордан ни аска, ни өскә күчә белми. Калынрактан уйна, нечкәрәк кирәк дип терсәгең белән төрткәләүдән һич файда юк, йә чәрелдәп, йә ыңгырашып дәвам итәргә туры килә... Ә чын гармунчы сине, кирәксә, югарыга тартып менә, тавышыңа тәңгәл китереп кушыла, моң борылышларында сабый баланы көйләгән кебек итеп җитәкләп бара икән...

Гармунчы белән җырчы арасында һөнәр күрсәтү бәйгесе башланды кебек: берсе Казан артындагы авылда, музыкаль әзерлеге булмаган килеш, соклангыч тавышлы яңа яшь җырчы очратырмын дип һич уйламаган иде, шуңамы бик сөенеп уйнады; икенчесе маэстро янында җырчы исеме алыр өчен ике-өч минут эчендә бөтен тавыш байлыгын күрсәтеп өлгерергә тырышты.

Төгәл ярты сәгать үтүгә, кунаклар алдында гафу үтенмичә генә утны куштылар. Тыңлаучылар берсе-берсе ун кешегә торырлык итеп кул чапты. Кинәт кабынган моторлар гүелдәвеннән өркеп күтәрелгән күгәрченнәрнең канат кагышлары алкышларга кушылды.

Парторг Сөмбеләне читкәрәк дәшеп алды.

– Син кунакларга авылны күрсәтеп ал. Нәкъ бер сәгатьтән ашханәгә алып килерсең. Ишетсен колагың, төгәл бер сәгать!

– Ярар, Зәкиулла Шакирович, бер сәгатьтән һава сулатып, бит-кулларын юдырып китереп куярмын.

– Әй, әй... канатлы кырмыска! Үз эшләрен күргәч ничек талпына! Матри, кызый, үрсәләнмә! Быел ни-ни-ни! Беркая да китмисең. Киләсе җәйгә, имтиханнарыңны уңышлы тапшыра алсаң, Казаныңа үзем илтеп куям. Пока тынычлап эшлә! Ишетсен колагың! Так, онытмадыңмы, төгәл илле биш минуттан ашханәгә!

– Бая бер сәгатьтән дигән идегез ич, Зәкиулла Шакирович.

– Биш минуты сиңа вәгазь сөйләп үтте, ну әрәмгә китмәде. Шылдымы?!

Сәяси лозунглар өләшкән елларда ике Идел кичеп Татарстанның көньягыннан төньягына күчеп килгән парторгны Балантау халкы бик тиз туганый итте. Елы-елы белән аны колхоз рәисе итеп тә сайлыйлар. Ләкин туры сүзле мишәр егете эш урыны белән исәпләшми, райондагы кимчелекләрне күңеленә бик якын алып, райком пленумнарында чәчрәп сөйли дә... икенче көнне үк аны йә парторг итеп куялар, йә авыл советында калдыралар. Көзге хисап җыелышларында колхозчылар аны тагын рәис итеп сайлый. Нинди генә эшкә куйсалар да, кешедән калган урын дип кимсенми, җиң сызганып тотына үзе. Саратовтагы партия мәктәбеннән җитәкләшеп кайткан хатыны белән, артык бәхәскә кермичә генә, Балантауда бөтенләйгә төпләнеп калдылар. Бүген дисә бүген теләсә кайсы министрлыкны җитәкли алырдай егеткә «Ике башлы Зәкиулла» дип йөзенә бәреп әйтәләр. Мактау гына түгел, кинаясе дә бар – парторгның баш түбәсендәге аркылы буразна аның акыл оясын зур-зур ике ярымшарга аерган. Ул урында хәтта тыгыз чәче дә киртләчләнеп тора. Баштагы мәлләрдә ул, урта звено җитәкчеләре кияргә тиешле ак кепканы кайсы ярымшарына кияргә белмичә, кулына тотып йөри торган иде, хәзер болай гына, гел яланбаш.

Алар авыл артындагы тар урман буйлап атладылар. Ындыр гөрелтесе ерагайган саен, җәйнең икенче ягында сайрар кош булып берүзләре генә калган тургай тавышлары ныграк ишетелә башлады. Кайсы яктан килсәң дә, җил үҗәтләнеп агачлар ягына юнәлә кебек. Алтыннары авырайган каен яфраклары көзне ашыктырып җилгә иярә.

Ике яктан култыклап алырлар дип өметләнгән иде Сөмбелә. Әмма, «уазик»ның алгы утыргычына унике килолы баянын бәйләп озаткач, Марат Гомәр, җиңеллек тоеп, тар урманның күрше рәт арасына күчте. Аның сөйләшеп баруы күбрәк сәхнә монологына охшаган иде.

– Көн сап-сары бүген, ә?! Минем болай алтын-көмешкә бик исем китми. Ну, алтын көзне яратам инде. Ятимлектә үссәм дә, минем яшьлек мул иген кырлары тирәсендә үтте. Безнең Чирмешән буйларында туфрак көчле. Көлтәләрен кочаклап алсаң, хуш исеннән дә тамагың туя, башаклары сары розалар хәтле!

– Җыр язар вакыты җиткән инде моның! Әйдә, комачауламыйк, арттарак калыйк.

– Гөлҗиһан апа, җыр ничек языла соң ул? Шагыйрь белән композитор бергә утырып язалармы? Әллә аерым-аерым язып бергә кушалармы?

– Кем ничектер, балакаем, аның кагыйдәсе юк инде. Менә без Миңнур абыең белән бергә яшәп иҗат иттек.

Шагыйрә Балантау кызын самими дус итеп аңа эч серләрен бушатырга теләдеме, әллә артист булырга сукырларча хыялланган меңләгән баланың берсе итеп алдан ук кисәтергә, сәхнә тирәсендә сагалап торган тигезсез көрәшле, татлы һәм төче, алкышлы һәм күз яшьле, газаплы һәм ялтыравык язмышны күз алдына китереп карарга ярдәм итмәкче идеме – белмәссең. Бактың исә, шагыйрәнең башыннан кичкәннәре сәхнәдәгеләр өчен сер түгел. Пәрдә ярыгыннан борын тыгып залны күзәтүләрен, гармунчы белән аерылышкан чакта гаилә шаһиты Әлфия Авзалованың судта ясаган чыгышын, концертлар белән чыкканда самолет багажнигына капчык-капчык дару үләннәре төяп кайтуын, хәтта китап акчасына сатып алган яңа «Запорожец»ны йөртергә өйрәнгәндә барган көйгә куркудан ике кулы белән күзен каплап «Абау!»лап чуерташ өеменә барып кергәнен дә, яңа маҗараларга өстәп, телдән телгә сөйли торалар. Гайбәткә кергән кешенең гөнаһысы кими дигәннәре хак булса, шагыйрә инде ошбу якты дөньяда ук изге кеше... Ә бүгенге кыз пәрдәнең икенче ягында – Казан артистлары белән чагыштырганда ул әле тамашачы гына. Ләкин затлы һәвәскәр тамашачы. Шагыйрә дөрес яшәде, ялгышлары – теләп алынмаган, хөсетлеләр, әрсезләр, тотнаксызлар дучар иткән җәза гына. Бүген дә,

иртәгә дә Сөмбелә каршында оялырлыгы юк. Ул хәтта кызыйның тел очында эленеп калган соравын да сизеп тора.

– Әйе, сеңлем, композитор Миңнур минем ирем иде.

– Чынлапмы, Гөлҗиһан апа?! – Кызый өчен бу бик зур яңалык иде һәм бу серне Балантауда әлегә бары тик Сөмбелә генә белә!

– Сер түгел инде ул. Без Илһам абыең, Әлфия апаңнар белән концерт куеп йөргәндә, син әле, мөгаен, тумагансыңдыр да. Мин – концертны алып баручы, Миңнур – гармунчы. Ул баянда уйнарга яратмады, гомер буе германский аккордеонын күтәреп йөрде. Шәп иде тавышы, Миңнур өйдә юк чагында да моң бөркелеп тора иде аннан. Артистларның, язучыларның бәйрәм кичәсенә иң беренче кунак итеп Миңнурны чакыралар иде. Уйнаганда гармунына якын килер хәл юк – күрек җиленнән гел мәҗлес табыны исе килә иде. Гармун сулышы иснәгәнең бармы әле синең?

– Ник булмасын инде, Гөлҗиһан апа! Бездәгеләрнең бөтенесе шундый. Сабан туена бишәр гармун җыела. Берсе исән кайтса рәхмәт, калганнары мәйдан читендә батырларча ятып кала. Халык таралгач, хатыннары эзләп таба.

– Гармунчының язмышына шулай язылган. Дуслары күп була, бөтенесе сыйларга тели. Мәҗлестән мәҗлескә йөрсәң, ул арыш маеның исеннән дә исерәсеңдер... Хәер, сәхнә үзе дә исерткеч хәмер шикелле – бер тәмен татысаң, шундук ияләнәсең. Гел-гел ашкынып торасың, кул чабулардан башларың әйләнә, гәүдәң авырлыгын тоймыйсың, танып дәшсәләр, масаясың. Ә берзаман картаеп йә популярлыгыңны югалтып сәхнәдән төшсәң, авыруга сабышасың. Һич көтмәгән чирләрең кузгала, кимсенү хисе биләп ала, алкышларга сусау башлана... Менә шулай, сеңлем, алкыш белән алкаш тугандаш сүзләр алар!..

Шагыйрә, әлеге сөйләшүне шаярту белән түгәрәкләп, күңеллерәк әңгәмәгә күчәргә теләгән иде, ахрысы да, тик үзе куерткан сагыштан тиз генә котыла алмады.

– Өйдән гармун чыгып китсә, аннан да авыр кайгы юк икән, сеңлем!

– Гафу итегез, ул исәнме соң?

– Исән! Аллага шөкер! Яшьрәкләр тартып алды. Бик чибәр нәмәстә тапкан. Тагын мәхәббәт белән исереп йөри.

– Айныгач кайтыр әле, Гөлҗиһан апа!

– Кайтса, бер сүзем юк, гафу итәм... Артистның аерылышуы да үзе бер концерт бит ул... Әлфия Авзалова авылыгызга килсә, фатирга алып кайт, сөйләттер әле бер. Гөлҗиһан апа рөхсәт итте, диярсең, иренми ул, бәйнә-бәйнә сөйләп бирер.

– Гөлҗиһан апа, үкенмисезме?

– Нинди үкенү ди ул! Күр әле син – күпме җыр туды!.. Менә шулай, Сөмбелә кызым, һәр җырда кеше язмышы...

– Ә Марат Гомәрнең шагыйрәсе бармы?

– Үткәне турында ялган сөйләр хәлем юк. Ну бүгенгесе көндә тулай торакта ялгыз яшәгәнен беләм. Шагыйрә белән гармунчы гына кавышырга тиеш димәгән: әнә Әзәл Яһүдин – алып баручы, Зәйтүнәсе – җырчы; Фәрит Хатыйпов – композитор, Рабигасы – җырчы, шигырь язмый; Хәйдәр белән Зөһрә – икесе дә җырчылар... Саный китсәң, татар сәхнәсендә күп инде андыйлар...

Сөмбелә, парторгның кисәтүен исенә төшереп, беләзекле сәгатенә күз салган иде, шайтан таягына баскан баладай чәрелдәп куйды:

– Беттем! Зәкиулла Шакирыч үтерә мине! Кунакларны чәйгә алырга вакыт ич. Әле кире кайтасыбыз бар...

Кичке очрашудан соң шагыйрәне өенә алып кайтып төне буе сөйләшеп чыгарбыз дигән иде Сөмбелә. Ләкин кичке уйлар гамәлгә ашмады, төн хыялларга аркылы төште.

Чәй эчкәндә үк, парторг Сөмбеләнең кәефен бозып өлгерде. Иҗат кешеләре тынычлык ярата, дип, ашханә белән бер түбә астына салынган ике бүлмәле колхоз йортын ачтырган. Кай арада урын-җирен алыштырып өлгергәннәр... Яңгырлы-карлы көннәрдә төрле тарафтан килгән вәкилләр кунгалый торган иде бу йортта. Монда шагыйрә белән гармунчыга күңелсез булмасмы? Төн уртасында уянып чәй эчәргә теләсәләр, кадер-хөрмәт кем күрсәтер?..

Казаннан килгән артистларның бушлай концертын карарга дип җыелган иде Балантауныкылар. Сәхнә уртасына ачык партия җыелышындагыча кызыл постаулы озын өстәл бизәп куйгач, тәмәке тартырга дип урамга чыгып качучылар күбәйде. Тыңлаучы булып күпчелек хатын-кызлар гына калды. Пәрдәне бөтенләй ябып тормадылар. Бу хәл тамаша алдыннан көтелә торган серлелекне бөтенләй югалтты.

Артистлар кием алыштыра торган шакмаклы кысан бүлмәнең кайчандыр мулла намазлыгы җәелгән мөнбәр икәнен абайлап алды шагыйрә. Искереп беткән агач клубларның эчтәлеген, төзелешен, язмышын яхшы белгәнгә күрә, ул бүгенге кичәне оештырып йөрүчеләрне артык сораулар белән йөдәтмәскә теләгән иде... Төбеннән үк кисеп алган манараның эзен яшерер өчен, түбәне төзәтеп, Казан калае белән яңабаштан ябып чыкканнар. Кирпечтәй кызыл төскә буяп кына тарихны каплап

куялмассың... Манара кисүченең язмышы, гадәттәгечә, фаҗига белән беткәндер әле... Шагыйранә кызыксыну барыбер үзенекен итте, клубка әверелгән мәчетнең бәетен Сөмбеләгә сөйләп бирергә туры килде. Илле ел элек, Себер урманнарыннан хат рәвешендә кайтып, Балантау халкының хәтерендә телдән телгә күчеп сакланган әлеге бәет шактый кыскарып, эчтәлегендә фаҗигале күренешләре генә исән калган иде.

Утызынчы елларда кулаклар колхозлашу хәрәкәтенә янаган иң зур куркыныч булып исәпләнде. Тора-бара, колхоз һәм совхозларның саны күбрәк арткан саен, көрәш кискенләшә барды. Инде мулла-мөәзиннәрне дә сыйнфый дошманнар исәбенә кертеп сөргенгә озатырга керештеләр. Дини руханиларны мәхәллә саен чүпли торгач, ниһаять, Балантауның Габдулла мулласына да чират җитә. Хуҗасы кулга алынган мәчетнең манарасы киселергә тиешлекне бик яхшы белә Габдулла мулла. Аның үзен, яшь абыстае белән таң алдыннан чем-кара тарантаска утыртып, Малмыжга алып китәләр, мәхәллә диндарлары белән бәхилләшергә дә ирек бирмиләр. Малмыж пристанена, якын-тирә авыллардан арестантлар җыелганны көтеп, ул бер баржа трюмында өч көн ята. Шунда кәгазь белән карандаш сыныгы табып, үзенең васыятен язып өлгерә. Аларны Полянда Әгерҗе ягына баручы товар поездының бер вагонына күчерәләр. Халыкта артык нәфрәт уятмас өчен, изге колларны Казанга да кертеп тормыйлар, хөкем карарын баржада гына укып, туп-туры Себергә олактыралар. Яшереп сакларга җайлы булсын дип бөгәрле торгач, иман чикләвеге хәтлек кенә калган васыять кәгазе, чуен юлларны, Нократ суларын, атлы сукмакларны кичеп, Балантауга килеп төшә. Язу кисәген кем алып кайтканы билгеле түгел, һәм аны күргән кеше дә юк. Шымчыларга килеп җиткән хәбәрнең ни икәне генә билгеле. Мәчет манарасын кискән кешегә ачы каһәр төшәр, якты дөньяда килеш тәмуг утында янар, бөтен нәселе корыр, дигән Габдулла мулла.

Активистлар хөкем карары чыгарган манарага кул күтәрердәй кеше табылмый. Ниһаять, партячейка утырышында Алкин дигән берәүгә мәҗбүри йөкләмә бирәләр. Көннәрдән бер көнне авылның карт-корысы ахшам намазына керешкән җиреннән, намазлыктан төшеп, мәчет янына килә. Бала-чага, яшь-җилкенчәк, абый-апалар күптән монда икән инде.

Алкин мәчет түбәсенә менгән дә, каланча төбендәге калайны куптарып, айлы манараны күтәргән түбәтәй юанлыгы сигез җепсәнең берсенә пычкы терәгән.

Бәддога Алкин башына кинәт төшәргә тиеш дипме, җыелган халык фаҗига көтә. Манара ауганчы, әүвәл ярым айны алып төшәргә кушалар. Ләкин Алкин җирдәгеләрнең бердәм каргышын тоямы, текә биеклеккә менгәч, кеше күз алдында егылып төшеп җан тәслим кылудан шүрли.

Алкин кулындагы пычкы сигезенче багананы чәйнәп өзгәч, азансыз калган манара халык уртасына гөрселдәп аугач, фаҗигале тамаша күрергә дип килгән халык «аһ!» итеп ике колагын каплый, әйтерсең бу авырлык һәркемнең үз башына ишелеп төшкән кебек була.

Төне буе яңгыр явып чыга. Иртән халык ни күрсен – мәчет нигезенә айлы башын куеп яткан манарадан җилләр искән, яшел чирәм өстенә килеп төшкән эзе дә калмаган хәтта... Кем алып кайтып яшергәндер, кара тарантас хуҗаларын анысы әллә ни кызыксындырмый, чөнки Нократ буенда манаралы авыллар әле бихисап була.

Балантау шым калып Алкин башына төшәсе бәддоганы көтә. Язгы ташулар да хәвефсез генә тына, рамазан чилләсендә өен яшен дә сукмый, көзге караңгы төннәрдә ишегалды тәрәзәсен каерып кулак кавемнәре дә керми... Ә Раштуа суыкларыннан соң, көннәрне сындыргач, Алкин Иске Йөрек урманына буралык агач белешергә дип чыгып китә. Өйләдән соң күтәрелгән өч көнлек буран тынгач, акбүз айгыр әйләнеп кайта. Җигүле атның һичбер җиренә зыян тимәгән, Алкин үзе генә юк. Бүреләр ботарлаган толыбын язгы чәчүгә чыккан агайлар эскерт төбеннән табып алалар.

Себергә сөрелгән Габдулла мулланың бер улы әле дә булса исән-сау килеш Төмәннән йөз чакрымдагы Киндерле авылында яшәп ята, ди. Хрущев тәхеттә утырган елларда, батыраеп, Балантауга кайтып күренгән. Туган авылының бер як капкасыннан керә дә икенче як капкасыннан чыгып китә. Манара язмышын бик нык сорашкан, диләр... Ул Төмән тирәсендәге урман эчендә гел татар авыллары гына, ди. Казан тирәсеннән сөрелгән алпавытлар, үз авылларының исемнәрен кушып, яңа салалар тергезгәннәр, ди. Габдулла мулла малае: «Сөргендәге тормыш сезнекеннән җиңелрәк. Анда урман ишелеп тора, балыклары җимсез кармакка да эләгә, киек-җәнлекләре бихисап, мал-туар өчен печән ишегалдыңа кереп үсә. Авыл исемнәре дә – Киндерле, Айшә, Янтык, Казан, Яркәй, Шыкча – гел сездәгечә», – дип әйткән, ди.

Шул кайтуыннан бүтән күренмәгән үзе...

Сөмбелә «Манара бәете»нең язылу сәбәбен сөйләп биргәч, шагыйрәнең кәефе кырылды.

– И Ходаем, гыйбадәт йортларын күңел ачу оясы итеп күпме гөнаһ җыйгандыр инде безнең буын! – диде ул, бәеткә күчкән гаеп өчен җавап тоткандай. – Әйдә, балакаем, очрашу кичәсен урамга гына күчерик.

Моны ишетеп алган парторг башын кыңгыр салып каршы чыкты:

– Гөлҗиһан апа, алай ук килешеп бетмәс! Хөрмәтле шагыйрәбезне урамга куып чыгарган кебек...

– И Зәкиулла Шакирович, мин гап-гади бер авыл хатыны лабаса. Шигырь язу да шул ук һөнәр инде ул – сыер савучы йә әнә комбайнер кебек! – Һәм шагыйрә югалып калмады, парторг уң кулында йомарланган ак кепкасы белән маңгай сырларыннан тир бөртекләрен сыпырган арада, сәхнәгә чыгып та басты.

– Җәмәгать! Шушындый бөркүдә, ахшам намазына җыелган кебек, мүкәләп утырмыйк әле. Әйдәгез, урамга күченәбез. Урындыклар идәнгә кадакланмаган. Яшьләргә дә тәмәке тартасыбыз бар дип керер-чыгып йөрисе булмас. Шигырь тыңлый-тыңлый тартсыннар, черки килмәс.

Сабантуйларда чыгыш ясаганы бар Сөмбеләнең – урамдагы халыкны тыңлатуы ай-һай кыен. Урам ул – тәнәфес урыны, саф һавада һәркем ирекле, бәхәскә керәсе, узып-узып яңалык сөйлисе, җырлыйсы, хәтта җаен табып сүгенәсе дә килә. Ничегрәк итеп төркемне тамашачы итә алыр икән шагыйрә апасы?..

Ул Балантау халкының чибәрлегенә соклануын шигъри юллар белән әйтеп бирде. Чибәрлекләренә бик үк ышанып җитмәгәннәрне уңганлыкта мактады. Шул минутта төркем, икегә бүленеп, горур тынлыкка чумды.

Шагыйрә сәгать буе шаян шигырьләр укыды, дөресрәге, яттан сөйләде. Ялгышкан-онытылган урыннарда тукталып гафу үтенде дә кабат башлады. Берәр сүзен ишетми калсак мәзәге аңлашылып бетмәс дипме, тамашачылар сөйләшмичә, сораулар бирмичә, арлы-бирле йөренмичә тыңлады.

Ындыр табагындагы чыгыш кабатланмагач, Сөмбелә дә шагыйрәгә ияреп яңа җырлар сайлады, алдан ук әйтеп куймасалар да, ул үзен җырлатачакларын белә иде...

Клуб эчендә сабыр гына тыңлый белгән тамашачы да концерт беткән минуттан йөгәнсез төркемгә әверелеп ишеккә ябырыла. Ә урамда черкиләр талавына бирешмичә, анда-санда машина-тракторлар үтеп киткәндә сискәнмичә, уты сүнгән өйләрдә этләр өрүен ишетмичә түзеп утырган тамашачы «Шушының белән әдәби-музыкаль кичәбез тәмам!» дигәннән соң ниләр кыланыр икән?.. Шагыйрә бу очракны да алдан күреп куйган иде.

– Дусларым, ә беләсезме, моннан ярты гасырлар элек нәкъ менә сез утырган җиргә клубка әверелгән шушы мәчетнең киселгән манарасы авып төшкән... Бу йортның изге урын икәнен онытмагыз. Без киткәч тә бүгенгечә тәүфыйклы авыл булып яшәгез!..

Балантау, бөтен тавыш-тынын томалап, кинәт өнсез калды... Ә аннан соң язгы ташкын шарлавыгы кебек көчле алкышлар шавы авылга таралды.

Мәктәп бакчасыннан уталган бер бәйләм календула чәчәкләрен кочагына алгач, шагыйрә тагын сөенде:

– Балакайларым, бу бит искиткеч шифалы чәчәк. Аракыда берәр атна тотсаң, салкын тигәннән иң шәп даруга әверелә...

Парторг халык алдына чыгып кунакларга рәхмәт әйтте дә китте. Казан мәдәниятенең кичке язмышы мәктәпне быел гына тәмамлаган Сөмбелә кулына калды.

Ана теле укытучысы шагыйрәне үз өенә алып кайтырга күндерә алгач, Сөмбелә бик сөенде, укытучы апасының дәрес аңлаткан чакларда бүленеп-бүленеп шигъри юллар язарга һәвәслеге барлыгын белә бит ул.

Чемоданлы баянын күтәреп Сөмбелә каршына килеп баскач, Марат Гомәр юл күрсәтүчесен югалткан юлчыга охшап калды.

– Гостиницага кайтып китсәм адашмам микән?

– Марат абый, хәзер кызлар сезне вечерга чакырыр. Чын гармунчы белән күңел ачасыбыз килә, диләр. Таң атканчы биетсәгез, гостиницага кайтып торасы да калмый.

– Гармун уйнау авыр хезмәт ул, Сөмбелә. Пот ярымлы әргәнне көне буе сөйрәп йөргәч, бер дә күңел ачасы килми. Казаннан чыкканга бер атна бит инде.

– Алайса, кызлар күргәнче югалырга кирәк.

– Ярый, Балантау Сарытау түгел, ничек тә юлны табармын әле.

– Мин хәзер, Марат абый, клубтагыларга магнитофонны кабызып калдырыйм да чыгармын. Бик тиз, яме!

Мәрхәмәтле августның бөтен йолдызлары да кабынган. Киек Каз Юлына текәлгән авылның ак төннәре, җиңел кырлар өстеннән килеп кергән камыл исе алҗыган гәүдәләрне канатландыра, йокысыз Шушма куенында кунып калган йорт үрдәкләренең мактанчык бакылдаулары су буена дәшә, таушалган урам юлы, бәхетлеләрне яшерергә теләгәндәй, дистәләрчә сукмакларга таркалып читкә кыя, ымсындырып чакыра.

– Марат абый, чемоданыңны күтәримме?

– Мә! – диде гармунчы, кызның тәкъдимен уенга алып.

Шунысы кызык, баянны урыныннан кузгата алмаска да тиешле Сөмбелә, һич сер бирмичә, адымнарын тигез саклап, гәүдәсен төз тотып атлый.

– Бир, бир, бир монда! – диде гармунчы, куркуыннан чемодан тоткасына ябышып. – Йә биленңне сындырырсың.

– Сынды ди, хәзер! Сөмбелә апаңның амбарда симәнә тутырган капчыкларны ничек ташыганын күрсәң әле син...

Гармунчы Сөмбеләнең гадилегенә сокланды. Нибарысы бер-ике сәгать күргән килеш туганнарча якын итә белүе, сөйләшкәндә тел яшермичә ачылуы һәм, ниһаять, олы музыкантка – бөтен Советлар Союзында шөһрәт казанган, хәтта Мәскәү Кремленең Съездлар сараенда Леонид Брежнев каршында чыгыш ясый алган «Наз» ансамбленең җитәкчесе, гәҗит-журналларда макталган, атказанган педагог Марат Гомәргә сүз уңаеннан гына «син» дип эндәшә алуы гаҗәпләндерде, якынайтты, яраттырды, сөендерде. Әгәр шушы урында хәзер башка музыкант булсамы – беркатлы кызыйга кисәтү ясар, оялтыр һәм гафу үтенергә мәҗбүр итәр иде. Ә Марат Гомәр сөенде генә, димәк, кызый инде иртәгесе көннән зур сәнгать дөньясына сәяхәткә чыгачагына бүген үк ышана, музыкант абыйсын гармуны кебек үз итә.

Баян әрҗәсенең кечкенә тоткасына ике кул ничек сыйгандыр – Сөмбелә һаман тотынып барды, үҗәтләнүе түгел, чын күңелдән тантана итүе аның... Шушы ышанычлы кулларны ычкындырмыйча, илаһи канат астында йолдызлар яңгырыннан ышыкланып, Казан каласының илһамиятле балкышына таба барасы да барасы иде...

Балантауда мондый төннәр, бәлки, һәр август саен кабатлана торгандыр, ләкин бүгенгесе ниндидер серле вакыт үлчәменә алып кереп өметне азындыра, хыялларны ашыктыра, язмышка ашкындыра, сөйләшәсене китереп тора.

– Киләсе елга җәй башлангач, сабан туена килегез, Марат абый. Безнең Балантау – табигатьнең колагы бит ул... Шомырт чәчәк аткач, авыл читенә чыгып бассаң, бөтен әйләнә-тирәдәге авазны тыңларга була. Өй түрендәге куак саен оя корган Пижмара сандугачлары дисеңме, атаклы Шалкан тавында батып калган машина ыңгырашуларымы, Карадуганның сыек тал питомнигында котырып яткан бакалар хоры, Каракүлдә тәкәрлек елавы – барысы да ишетелә.

– Ә бәлки, боларны син генә ишетәсеңдер, Сөмбелә?! Иҗат кешесе өчен бик гадәти халәт бу. Мин үзем дә, илһам килеп ялгызым баян уйнап утырганда, колак төбемдә бер кыз бала җырлавын ишетәм. Шул кыз тавышын нотага төшергәч, яңа җыр туа. Мин ул тавышка «Илһамия» дип исем куштым.

– Кызык... Бик кызык... Сез, бәлки, Илһамиягезне ишетәсездер дә, тик мин бит әле иҗат кешесе түгел.

– Җае чыккач әйтим инде алайса... Синдә табигый колоритлы тавыш материалы бар. Музыкаль белем биреп, дөрес итеп җырлау техникасына өйрәтсәң, синнән менә дигән эстрада җырчысы ясап була.

– Кызык, бик кызык. Сез җырчыны җиһаз ясагандай итеп чагыштырасыз.

– Җиһаз түгел, скульптура дияр идем мин, Сөмбелә. Материалың бар, образ бар, каркасың әйбәт... Остаз кулы гына кирәк.

– Гафу итегез, Марат абый, баян тартмасының тоткасында мине кысып тотканы остаз кулы түгелме соң?

Гармунчы барыр сукмагыннан адашып көтелмәгән упкын алдына юлыккан төнге мосафир кебек кинәт туктап калды.

– Сөмбелә, мин бит кызлар ансамблен җитәклим.

– Анысын бик яхшы беләм, Марат абый. «Наз» кассетасы белән дөнья тулган.

– Белмисең шул. Хор белән ансамбль профиле ялгыз җырчы әзерләүдән бөтенләй аерыла. Сиңа консерваториягә керергә кирәк.

– Барып карадым инде быел. Медицина институтына керәм дип алдалап киттем дә, консерваториягә барып, ике җыр җырлап кайттым.

– Музыкаль грамотаң юк дип, махсус мәктәпләренең тугызынчы классына укырга керергә куштылармы?

– Әйе. Күчми калган мәктәп баласы кебек тагын тугызынчыдан башларгамы? Ә сез моны каян беләсез, Марат абый, әллә имтихан комиссиясендә утыра идегезме?!

– Юк. Нәҗип Җиһанов безнең кебекләрне комиссиягә якын җибәрми.

– Кем инде ул сезнең кебекләр?

– «Народниклар», «Наз» халык ансамбле исемен йөртә бит...

– Артист булырга хыялланган кеше өчен башкача юл юкмыни?

– Сиңа сигезне бетергәч тә музыка училищесына керергә кирәк булган. Авылыгызның җыр укытучысы киңәш итә алмадымы шуны?

– Киңәш бирүчеләр күп анысы... Тик әтинең мине артист итәсе килми. Казаннан концертлар килгән саен, берәр артист апа безгә фатирга керә. Аларның язмышларын сөйләттереп кызык таба. Артист тормышын газиз кызыма түгел, дошманыма да теләмим, ди. Үзе артистларны үлеп ярата ул, бер концертны да калдырмый. Тик мине җырчы итүгә теше-тырнагы белән каршы. Авылда гына җырларга куша, гомер буе тыңларга риза, ди үзе... Бик кыен хәл – өйдәгеләр әрли, урамдагылар мактый...

– Мондый тавышны өйдә бикләп асрау ким дигәндә мәрхәмәтсезлек, кәнишне.

– Марат абый, син чынлап әйтәсеңме соң бу сүзләреңне? Әллә мине бала-чагага санап үртәвең генәме? – диде Сөмбелә, тагын «сез»не югалтып.

– Үртәмим дә, юмаламыйм да, минем кызлар язмышы белән шаярып йөрер чагым үткән инде.

Көтмәгәндә хәвефкә калса, чын гармунчы иң әүвәл үзенең гармунына ябышыр, аннан соң гына җанын саклау турында уйлар. Үтелгән юлда фара яктысын абайлап алгач, Марат Гомәр моны әллә ни җитди нәрсәгә юрамаган иде. Ләкин яктылыкның кечкенә «СШ-20» тракторыннан икәне беленгәч тә ул никтер Сөмбелә белән гармунчыны урап узып китмәде, киресенчә, этеп йөртелә торган арбасын терәп тукталды.

– Курыкмагыз, Марат абый, – дип юатырга ашыкты Сөмбелә, – Идрис кенә ул. Беренче класстан бирле артымнан тагылып йөри. Колхоз аңа өр-яңа трактор бирде. Төнлә йөргәне өчен җитәкчеләр әрләсәләр, авылдан китәм, дип кенә куркыта. Шуңа сүз әйтмиләр.

– Җитәкчеләрегез курыксын. Ну мин авыл җирендә курыкмыйм...

Ул арада Идрис, тракторны сүндермичә генә, җиргә сикереп төште. Яктылык эченә кереп, гармунчыга кул биреп күрешкән уңайдан Сөмбеләгә эндәште:

– Парлашып кына Фатих Кәрим экиятеннән кайтып килешегез түгелдер ич? Мин сезгә күчтәнәч китердем.

Фарага бик якын басканга гына Идриснең сүсән чәче кабарып, гәүдәсе олыгаеп күренгән икән, читкә чыгып кабинасына үрмәләгәндә, ул бөтенләй кечерәеп, нәни малай булып калган иде. Аның көзге кыланышларын белгәнгә күрә, нәрсә эшләргә җыенганын сизенде Сөмбелә. Тик:

– Идрис, кирәкмәс, әрәм итмә! – дип кычкыруы арбаның гүелдәп күтәрелүен җиңә алмады.

Текә тау кебек күтәрелгән арбаның алгы борты ачылып китте дә Сөмбелә белән гармунчының аяк очына күп, бихисап күп алма тәгәрәп төште. Трактор китеп баргач та Марат Гомәр тораташтай басып калган урыныннан кузгалырга батырчылык итмәде, кайсы якка атласаң да алмага басарга туры килер иде. Искә төшкәндә бер авыл эченә барып керә торган җил, камыл исен югалтып, бүгенге төн өчен ашыгып өлгергән сары алмалар исен тузгытып алды.

Ә Сөмбеләнең ашыгасы юк, инде колхоз йортының шыксыз шәүләсе күренеп тора, гармунчы кереп китсә, аның белән бергә бүгенге төннең серлелеге дә ияреп китәчәк һәм кыз кичәге авылда тагын япа-ялгызы калачак.

– Марат абый, үпкәләмәгез инде Идрискә, бигрәкләр дә бала-чага бит әле ул.

– Киресенчә, малай чакларыма әйләнеп кайткан кебек булдым.

– Фатих Кәрим экиятеннәнме дигәне дә яратып кына.

– «Гармунчы аю белән җырчы маймыл»ны Фәйзи агай Йосыповка ияреп концерт саен тыңлагач, яттан беләм инде мин. Ияләнелгән.

– Ә без ул экиятне Идрис белән икәү сәхнәләштерә идек.

– Идрис гармун уйный беләмени?

– Уйный дип, экият сөйләр өчен ярый инде шунда. Күрше авылларга концерт белән чыкканда, миннән калмас өчен, юри артистлана. Бүген бөтенләй танырлык түгел ул. Җиргә коелган алмаларны ашамаганымны белә, ачуымны чыгарыр өчен юри кыланды.

– Кем бакчасын ботарлады икән?

– Колхозның Хрущев заманыннан калган ташландык бакчасы бар. Халык бик җыймый аны, һәркемнең өй түрендәгесе дә җитәрлек. Ә Идрис юри шул агачларга тракторы белән килеп бәрелә, күпме кирәк – арбасына шулчаклы коела.

– Бүген мин сине бәхетсез итәм, ахрысы. Яраткан егетең юктан көнләшеп берәр мажара китереп чыгармасын тагын.

– Нинди яраткан егетем булсын инде ул! Күпме әйтәм мин аңа, иярчек тай урынына йөрмә артымнан, дим. Ә ул һаман-һаман сагыз кебек сылануын белә. Армиягә китсә, хәер бирер идем, ичмасам. Авылдан китмичә котыла алмам инде мин аннан.

– Котылу җиңел лә ул.

– Марат абый, коткар син мине бу авылдан. Әгәр теләсәң, син мине алып китә аласың бит, әйеме?!

– Кирәксә, кырык төрле сәбәп таба алам. Ярамас шул.

– «Ярамый» дигән сүздән өйдә дә гарык инде мин. Сезнең кебек танылган, көчле, мөстәкыйль кеше «ярый!» дип әйтә аладыр ич. Әллә хатыныгыз бик көнчеме, шуңа сагаясызмы?

– Мин гаиләмне ансамбльгә алыштырдым. Композитор Александр Ключарев әйтә, Марат, син «Наз»ны оештырдың, ләкин шушы ук «Наз» синең үзеңне харап итәчәк, ди. Минем бөтен куанычым – ансамбль, мин алар белән генә яшим.

– Бөтенесе белән берьюлымы, Марат абый?..

– Һәй, Сөмбелә! Бер карасаң, син шундый самими, ә ныклабрак карасаң, бик акыллы. Килештек алайса, «ярамый!»га карамыйча коткарам мин сине моннан. Бүген үк түгел, язга таба, имтиханнар алдыннан.

– Чынлапмы, Марат абый?! Вәт рәхмәт!

Гармунчы рәхмәтле Сөмбеләне ике куллап күтәреп алды, аның бөтен сизгерлеге кулларына күчте. Баян сәдәфләрендә биеп, җиде йөз төрле моң чыгара ала торган йөгерек бармаклары яңа көй эзләгәндәй тыпырдап куйды, тик җилкә чокырында сәдәф тапмады, ике алма яшереп йөрткәндәй кабарып күренгән күкрәген тәненә сылашкан юка ак күлмәктән гайре берни капламаган иде. Гомере буе ялгыз тимерче кебек күрек тарткан сул кулы тагын да бәхетлерәк икән. Кисәк күтәрүдән итәге җыерылып менгәч куркынып калган аяклары күрек тарта торган кул өстендә иде. Бары тик Шушма тугаенда кызынып ятканда иптәш кызлары гына көнләшеп күз төшерә алган ботлары, кабыгы каезланган сөян агачы кебек елкылдап, йолдызлар яктысында балкый.

– Син бит инде арыдым диден, Марат абый, тузанга егып төшерә күрмә!

– Каешы өзелгәндә дә баянымны кулымнан төшергәнем юк.

– Мине гармун итеп уйнарга җыенасыңмы әллә?

– Сиңнән шәп җыр туар иде бүген, Сөмбелә.

– Җыр гына туса ярый ла...

– Иң әүвәл җыр тусын әле. Гармуннан да җиңелрәк бит син!

Һәм Марат Гомәр, кызның авырлыгын үлчәргә теләгәндәй, һавага чөеп алды. Әллә ялгыш, әллә уй-теләге шул иде – Сөмбелә талпынган арада гармунчы аның кызлар күзе генә төшәрдәй җиренә иреннәрен тидереп алды.

– «Илһамия»нең үзе икәнсең син, Сөмбелә. Ник мин сине ике генә ел элегрәк очратмадым икән?!

– Ярамый, Марат абый, егетләр үбә торган урын түгел ул. Төшерегез мине җиргә. Болай ярамый, дим ич.

Ни өчендер гармунчы кыз алдында гафу үтенергә теләмәде. Киресенчә, ул әле уенны дәвам итеп Сөмбеләне, алмалар әсирлегеннән коткаргандай, юл читенә чыгарып бастырды. Баянын алырга дип кире килгәндә, аяк астында тагын күпме алма сытылды. Ә үзе моңарчы Балантау яшьләренә ишетелмәгән яңа җыр такмаклады.

Марат Гомәр вакытны сузарга булды, туфлиенә сыланган алма сутын чирәмлеккә бик озаклап сөртте. Август аеның төн озынлыгына өстәлгән сәгать ярым вакыты шушындый очракларда кирәк икән. Хәтта декабрьнең соңгы төннәре дә бик кыска булып тоелыр иде мондый чакта. Кача-поса гына килгән, дөресрәге, бөтенләй өмет итмәгән сөенеч вакыйгаларны ашыктыра, тыелып калырлык хәл юк, буйсынырлык акыл, кире чигенерлек чара юк. Рәхәттән исереп ялгышуы шундый җиңел икән ул. Күр әле, нинди кабатланмас, гыйшыклы һәм бик кыска төн бу – үкенеп тә өлгермәссең.

– Мескен чирәм... Бу хәтлек ышкуга туфлиегез тишелеп чыгар! Марат абый, «ярамыйга карамый»ны өйрәтегез әле миңа.

– Урамда җыр өйрәтмиләр.

– Һи, без урамда, фермада, ындырда дип тормыйбыз, кайда ишетәбез, шунда отып калырга тырышабыз.

Тагын бераз гына чирәм таптарга исәбе бар иде әле гармунчының, тик клуб ягыннан янә теге трактор килеп чыкты. Бу юлысы арбага төялгән исерекләр җыры аның гөрелтесеннән көчлерәк иде.

– Ут яктысына кергәнче качып торыйк, Марат абый! Малай-шалайлары да табыла бит аның шундый чакта. Ну иртәгә иманын өшкерәм мин аның. Күрше малае гына ул Идрис, егетем дип уйламагыз тагын...

– Бала-чага шикелле качып калыйммыни инде шулардан?

– Бәйләнешмик, Марат абый, юкса соңыннан сүзе күп була аның, күрше хакы бар бит әле... Райком да урып-җыю өстендә хулиганлыкны бик якламый. Әнә теге бура артына сыеныйк. Эзләп арыгач айнырлар.

Исерекләр хоры үтеп киткәч, Сөмбелә, кабаланып, гармунчыны ашыктырды.

– Колхоз йортына кереп бикләнерсез, – дип әйтеп бетерүе булды, трактор кире борылды.

Кунакханә тәрәзәсен яктыртып тукталгач, Идрис арбадагы исерекләрне җиргә бушатты. Арбаның күтәрелүе чыр-чу, сүгенү, ыгы-зыгыны көчәйтте, төшкән бере тәрәзәгә ябырылды, алкалы йозакны тоткалап ишеккә типкәләде.

Эчтә кеше юклыкка ышангач, тагын авыл буйлап китеп бардылар. Инде кунакны озатып куймыйча чараң юк. Күңеленә шом кергәч, кызый өенә ялгызы кайтырга яхшысынмады.

Эзләп-эзләп таба алмагач, исерекләр колхоз йортына еш сугылырлар. Сөмбелә, гармунчы кулыннан ачкычны алып, өйгә керде. Ут яндырырга ярамагач, кунакның эчке ишекләрне табарлыгына шикләнде. Маңгаен бәреп кара яндырса, иртәгә халык алдына ничек чыгар? Өй эченә күз тиз ияләште, трактор ерагайган арада, вакытны әрәм итмичә, җәһәт кенә тәрәзәне ачып, урам ягына пышылдады:

– Марат абый, мә, йозакны ал. Баяныңны эчтә калдырып, ишекне тыштан биклә. Син тәрәзәдән керерсең.

Тәрәзәне ябып икәүләшеп бикләнеп калгач, бүлмә эченә әкренләп күз ияләнде. Кыл уртада хан заманыннан калган түгәрәк өстәл икән, тирәсендә ике урындык бар. Киң ашъяулык астыннан чәйнеккә һәм дә шикәр савытына, чынаяк-чокырларга охшаш нәрсәләр төртеп тора. Ә инде стенаның тәрәзә

уелмаган ягында урын җирләре пөхтәләп җәелгән агач караватны күргәч, Сөмбеләнең йөрәге жу итеп куйды. Халык телендә аны «полуторка тахта» дип йөртәләр. Ләкин бүрәнә читлеккә үзе очып кергән ак күлмәкле кыз бер мендәрле караватка бер ярым кешенең ничекләр итеп ятарга мөмкин икәнлеген күз алдына китерә алмый иде әле...

* * *

Көтү куар алдыннан гына кайткан кызларын ничек каршы алачакларын бик яхшы белә Сөмбелә. Ә шулай да кайтып күренергә кирәк. Өйдәгеләрне әле җиңелеп кайткан килеш җиңәсе бар. Әйтеләсе битәрләү-әрләүләренә, рәнҗешле нәсихәтләренә, өркетү-кисәтүләренә алдан ук җавап әзерләп, эти-әнисе алдында әхлак имтиханы тотасы бар.

Авылга өй саен тотылган утны саный торган аерым счетчиклар кerткәннән бирле һәр лампочканы бәрәкәт белән генә яндырырга өйрәнгән Харис арткы өйдә утны сүндермәгән. Әти кешенең: «Без сине төне буе йокламыйча көттек!» – дигән беренче сүзе инде бу. Апасы читкә китеп, өйдә олы кыз урынына калган төпчекләренә моңарчы каты бәрелгәннәре булмады. Хәер, мәктәпне тәмамлап, үзенә күрә күңел ачу ирегe яулаганына ике генә ай үтте ләбаса, һәм моңарчы кызның әле таң яктысына кушылганчы ут яндырып көтәрлек фигыльләре шәйләнмәде.

Балантауның бөтен җан иясе изрәп йоклый. Кояш офыктан кубып килә. Тынлыкның шундый сизгер чагы, әгәр Сөмбелә капка келәсенә ялгыш ныграк орынса, абзардагы ишле каз «Как? Как?» дип русчалатып сорау алыр, казлар авазына сагаеп, күрше Җамалыйларның мыжый эте «Ah! Ah!» дип өреп куяр. Шуны гына көтеп яткан күрше урам сарбайлары җавап кайтарыр. Алар һауына сыерлар уяныр, уянган берсе янында чиләк тоткасы шалтырар, урман каравылчысы Рәхмәтулла, мотоциклын пырылдатып, делянка егылган тарафка ашыгыр, хуҗалыктан сөт җыючы Раузалар каршына Идриснең тракторы килеп туктар һәм көтү җыела торган тыкрыкта урын өчен, таш ваткан тавыш чыгарып, кәҗә тәкәләре сөзешә башлар... Авылны уятыр өчен капка келәсенә кагылу җитә...

Гөлчәчәк болдыр ишеген урам ягыннан ачканнарын көтеп торган ахрысы – кулына сөт чиләге, беләгенә чүпләмле сөлге элеп каршыга ук килеп чыкты. Ул көндәгечә коңгырт сатин халатын кигән, тик ни хикмәттер ак яулыкка төренгән, шуның өстенә, чәчәкле-чуклы тагын бер яулыкны эзәр итеп, киң маңгаен каплап будырган. Мунчада кызу тиеп йә челләдә кояш сугып башы авыртса, Гөлчәчәк гел шулай кысып бәйләп куя торган иде. Әни кеше буш сөт чиләгенә бәрелеп калган кызны бөтенләй күрмәмешкә сабышты. Гүя Сөмбелә аның өчен бөтенләй юк ул хәзер... Каладан килгән артистка ышанып үз өен оныткан һәм көтү куганда гына куып кайтарылган газиз кыз бала өчен ягымлы сүзләр кинәт беткән, елмаюы ике каш арасындагы җыерчыкларга кереп качкан, төне буе еламсырап чыккан күзләрнең исән кайткан баланың йөзенә сыный карарлык та хәле юк, бусага аша атлап кереп баручы унсигез яшьлек җан көеге ак күлмәк кенә бары.

Әти кеше, күлмәк җиңенең сәдәфен каптыра алмыйча, идән уртасында катып калган. Сөмбелә аны үтеп китә алмады һәм ирексездән абажур астында калды. Йөз илле ваттлы лампа яктысы кызның бөгәрләнгән күлмәк итәге белән таралмаган чәч арасына тузганакланып ябышкан мендәр мамыкларын фаш итте. Чирәм яшеле йокмаган, кабина дегете тимәгән, кан табы юк – күлмәгенең ак килеш исән калуы эти кешенең кырау төшкән бәгыренә аз гына өмет җылысы бөркеп куйды: бәлки, рәнҗетмәгәннәрдер әле. Куенында төн уздырса да, куркытмыйча, елатмыйча, кул сузмыйча иркәләгәндер генә. Харис белән Гөлчәчәкнең аулак өйләрдә күпме кич утырганы, кочаклашып кунып калганы бар иде. Таң аттырабыз, дип әйләнеп-тулганып, бөгәрләнеп-кармаланып ничәмә-ничә төннәр бергә үткәндә, күпме ястык мамыгы ияреп кайткандыр. Тик Гөлчәчәкнең эти-әни кыйный дип зарланганы булмады. Орышып, әрләп, кул күтәреп кенә Ходай биргән яшьлекне бишпочмаклы бүрәнә читлектә бикләп яшәтеп буламы? Дөрес, Гөлчәчәк белән Харис беренче төнгә тугры калдылар. Аулак өйләрдә аркылы җәелгән түшәк өстендә тезелешеп яткан тынгысыз төннәрдә Харисның гыйшыклы кулы, куенындагы Гөлчәчәкне үтеп китеп, янәшәләрендәге күрше кызының күкрәгенә үрелмәде. Таң атканда сандугач йокысыннан изрәгән кулы саташып озаймасын өчен, ул Сөмбеләнең булачак әнисен биленнән урап кочаклый торган иде. Зөфаф ширбәтен татыгач, аулак өйләр тагын да күбәйде. Ләкин никахка чаклы шаярулар араны суытмады, киресенчә, бер-берсеннән башка яши алмый торган гомерлек ярга әверелделәр. Яучы җибәргәндә, Гөлчәчәкнең тәне кайнарланган иде инде... Олы кызлары Резидәне никтер җиде айдан туды дип хафаланган булдылар. Аның ничә айдан туганын Харис белән Гөлчәчәк үзләре генә белә... Әйе, борынгыдан килгән йолалар никахка чаклы якынаймаска куша. Ни кызганыч, шәҗәрәбезнең өске ботаклары югарырак үрмәләгән саен, затлы йолаларыбыз, искергән кануннарга әверелеп, бездән ерагая бара. Хәзер инде никах туена чаклы кәләшен саф килеш саклап кала алган кияүләр ай-һай сирәк. Ләкин Харис әлеге уйлары белән Сөмбеләне һич акларга теләми, үз балаңа – сөекле кызыңа килеп кагылгач, тотнаксызлык дигән шуклык җаннарны тетрәндерерлек аянычка әверелә икән. Ник дигәндә, эти кеше кыз баланы яратып кына түгел, сокланып үстерә һәм Харисның җаны Сөмбелә җанында. Әгәр Казаннан килгән гармунчы кызның җанын яралаган булса,

димәк, әти кешенең дә җаны яралы. Кызны рәнҗетү – әтине рәнҗетү, кызны мыскыллау – әтине мыскыллау дигән сүз.

Харис хурлыклы уйлар белән үзен-үзе кыздырды. Сабырлыгы үртәлүдән соңгы чиккә җиттеме – үч алу нияте белән ниндидер кискен карарга килеп, кием шкафын ачты. Өстендәге абзар киемнәрен сала торды, җыенда, мәҗлесләрдә, сайлау көннәрендә кияселәрен ала торды. Сөмбелә аны ике тәрәзә арасындагы кыска эргәгә терәлгән ике канатлы озын көзгедән күзәтте. Йокысы туймагангамы – әтисенең тиктомалдан кием алыштыруын нәрсәгә дә булса юрап өлгерә алмады. Бары тик ике-өч ел буе шкаф шүрлегеннән чыкмаган киң читле салам эшләпәне кулына тоткач кына, әтисенең дөреслек эзләргә дип казыйлыкка җыенганын аңлап алды. Сөмбелә көзге каршысында тагын бераз гына оеп торса, Харис гармунчы янынаыргыласы иде.

– Әти! – Кыз үз тавышыннан үзе сискәнеп куйды, ләкин ярсыган тәрбиячене туктатырлык башка катгый сүзләр ялгап әйтә алмады. Әгәр төнлә туган яңа җыр тел очына килеп кунмаса, иртә таңнан бөтен татар дөньясын шаулатырлык гауга чыгасы иде бүген:

> Ә мәхәббәт, ә мәхәббәт дәвам итә
> Ярамыйга карамый, карамый...

Харисның ачуы сүнде. Төпчек кыз, иртә дими, кич дими, җырлап уяна, җырлап эшкә чыгып китә, авыз эченнән көйләп, караңгы өйгә кайтып керә. Җыр аның яшәү рәвеше, җырлый икән, димәк, яшьлеге дә ул дигәнчә уза. Һәм әлеге «Ярамыйга карамый»ның ачу китергеч, инәһне елатырлык җан ачысы белән яңгырый алмастай күңелле җыр булуы сабырлык бөркеп тора. Ул тынгысызлык эшләпәсен яңадан шүрлек түренә – нафталин, лимон-әфлисун кабыклары арасына томырды.

Почмактагы караватка барып аугач, Сөмбелә чаршауны корды. Чишенергә ашыкмады, ак күлмәген салмаганда кичәге төн һаман дәвам итә кебек иде әле. Яңарак кына сизеп алды кызый – күлмәк изүеннән «Шипр» хушбуе катыш тәмәке исе килә, әйтерсең лә шул искә гармунчының җаны ияреп кайткан. Һәм, чишенсәң, ул сине шук күзләре белән эзәрлекләр, гел өстеңә карап торыр кебек. Сөмбелә әнә шул серле халәткә җавап итеп елмаеп куйды. Ак җирлеккә табигатьтә булмастай эре-эре умырзаялар төшкән чаршау, ябык пәрдәгә әверелеп, кызны яшерде. Пәрдә эти белән сөекле кызы арасында беренче таш коймага әверелде. Дәшми калсам, көн саен шулай соңарып кайтырга өйрәнер дип кенә әйтелгән нәсихәтләр умырзаялы койма аркылы бик сүрән вәгазь булып үтеп керә һәм төн хисабына сыегайган йокыны куерта...

– Ансамбльгә бөтен кызларны да шулай җыя торгандыр ул... Җырлар өчен генә булса, синеңише һәвәскәрләрне Казаннан да табар иде... Авылда килеш кунарга кайтмадың, сине читкә җибәрсәң, бер атнада әрәм итәрләр... Төн кызлар башыннан йөри... Җылыга кергәч, нарат күркәсе орлык коя... Гармунчы халкы гомергә алкаш булды, шуңа ышанып йөрсәң...

Чаршау артыннан каршы дәшеп үчекләүче булмагач, Харис берьяклы сөйләшүнең кызыгын тапмады. Шкаф каршына өелгән эш киемнәрен кабат киеп, ишегалдына ашыкты. «Ярамыйга карамый»дан сагаеп, Гөлчәчәк тә кереп килә иде инде. Кулындагы чиләк төбендә ярты литр чамасы сөт.

– Бар, савып бетер сыерыңны! Буш чиләк белән каршыма килмә.

– И Ходаем, кул күтәрдең мәллә, атасы?

– Әллә син мине ул хәтлек... Кыз балага кул күтәрергә... Әрләдем генә.

– Такмаклап җылый түгелме?

– Җырлый ул.

– Шушындый чакта җырлап торырга... ычкынганмы әллә?!

– Төнлә ычкынган булса ычкыныр да, ычкынганмы-ычкынмаганмы, барыбер – бөтенләй кулдан ычкынганчы, Идрискә ычкындырырга кирәк аны, Казанга бергәләп чыгып ычкынырлар.

– Идрисең көзгә повестка көтә әле анда...

Бишпочмаклы, алты матчалы, сигез тәрәзәле, өч кешеле өйнең чаршау чатырлы бер почмагында Сөмбелә исемле яңа дөнья пәйда булды. Пәрдәнең ике ягында гүя хәзер капма-каршы ике телдә сөйләшәләр, берсен-берсе аңламыйлар: эшкә ашыктырмыйлар, йомыш кушмыйлар, артык сораулар бирмиләр, «яме» дигәндә «ярар» дип җөпләмиләр, кара-каршы сүз көрәштермиләр, кайбер ошамаган сорауларны ишетмәмешкә сабышалар. Көндәлек мәшәкатьләр Казан кунаклары килгәнче ничек үткән булса, гармунчы киткәч тә шулай дәвам итте. Һәркем өй эчендә бүленгән вазифаны гадәттәгечә үзе башкарды, вакытында эшенә йөрде, көтү каршылады, юан-юан дүрт агач аякка бастырылган «Беларусь» телевизорының куна тактасы чаклы экранына ябырылып, «Семнадцать мгновений весны» сериалын карады, бер өстәл артына табын көйләнде. Әмма Сөмбелә колхоз өендә кунып кайткан көннән башлап гаиләдәге иминлек икегә бүленеп элек һәм хәзер дигән бәяләмә белән үлчәнде. Мактаулы, сөенүле һәм хуплаулы, мәрхәмәтле һәм яклаулы көннәр вакыт үлчәменең теге ягында калды, ә сагышлы минутлар, офтану һәм көрсенүләр, тынгысыз кичләр бу якка күчте.

Яңа көн тугач, Казанныкылар Балантау кунаклары түгел иде инде. Аларны парторг күрше Субаш авылына илтеп куячак. Сөмбелә клуб ачкычын Идрис аркылы биреп җибәрде. Сөенә-сөенә китте егет. Кызның гармунчыны озата бармавын, аның белән хәтта саубуллашырга да теләмәвен үзенең зур җиңүе итеп тойды ул. Сөмбелә уйлап эшләде моны. Йокысы туймаганга күрә генә йомышчы малай итмәде ул аны. Тагын бер кат күрсен Идрис чын гармунчыны, көпә-көндез, кояш астында күрсен, олы шәхескә карата булган хөрмәтне тойсын, тиңсез көндәше алдында чигенсен, иртәгә дигән ачы хакыйкатькә буйсынсын...

Сөмбелә күрше авылның үзешчәннәрен күз алдыннан кичерде: Субашның гөсләче әбиләре бар, скетчлар куярдай егетләре, биючеләр ансамбле бар. Ә менә гармунчыны җәлеп итәрдәй җырчы кызлары юк... Юк!

## Кар өстендә

Авыл баласы шәһәргә ачкыч эзләп килә. Эшли-эшли, яши-яши җыя ул аларны. Килеп урнашу белән һөнәри училищеның тулай торагыннан дүрт караватлы бүлмә бирәләр. Пыялага төрелгән оясында черем итеп утыручы вахтерша әбине гел ырылдатмас өчен, һәр егетнең кесәсендә үз ачкычы йөрергә тиеш. Бу синең шәһәр кешесе буларак иң беренче ачкычың! Карават янындагы тумбочканың йозагы болай да ачыла...

Эш урыныңнан сейфлы кабинет ачкычы алыр өчен алга таба да укып, күп ачкычлы агайларга ярарга тырышып, шактый үсәсе бар. Кабинетлы кеше ачкычларны тизрәк җыя: фатир ала, машиналы була, гараж сала, дача төзи...

Сиксәненче еллар уртасында, портфель белән почта әрҗәсен санамаганда, дүрт йозак ачардай ачкыч бәйләмең булса, син инде түгәрәк бәхетле «городской» идең. Трамвай тукталышында чиләкле эремчек күтәреп калган авылдашларыңа, машина тәрәзәсен төшереп, куллар болгап китә аласың.

Дөрес, кайсыдыр ки ирләрнең кесәсендәге бәйләмдә өендәгеләргә түгел, хәтта чит кешеләргә дә әйтергә ярамаган серле йозак ачкычы була. Кулына эләксә, хатының ул ачкыч белән шәһәрдәге бөтен йозакларны кытыклап чыгар һәм сереңне гәүдәң белән каплап ятканда өстеңә килеп керер.

Гармунчы әнә шул серле йозак аркасында бөтен ачкычларын бәйләме белән югалтты. Урлатмады, төшереп калдырмады, үз иреге белән югалтты. Һәм яңадан ачкыч җыяр өчен аңа заводның тулай торагыннан урын бирделәр. «Наз» ансамбле җиде ел элек завод клубы каршында оешкан иде. Моңарчы җитештергән товарлары белән әллә ни мактана алмаган заводның даны кызларга ияреп үсте: «Наз», чит илләргә чыгып, телевизорлардан күренеп, гәҗит-журналларда макталып, аңа мәдхия өләште. Шуңа күрә, ачкычлары белән бергә үзен дә югалтмасын өчен, гармунчыны ике караватлы бүлмәгә ялгызын гына керттеләр.

* * *

Клуб ачкычын әнисенә калдырып, Сөмбелә берәр атнага Казанга китте. Туганнан туган апасы Лилиянең сирәк-мирәк булса да хатлары килә иде, шул хатларны кат-кат укый торгач, Сөмбелә шәһәрдәге хәлләрне бик шәп күз алдына китерде. Күчтәнәчкә ниләр алып барасы икән дип баш ватасы юк... Анда ите, мае, шикәре – гел талонга гына. Тамак саен бүлә калсаң, бер айга ике кило шикәр, бер кадак май, кило ике йөз грамм ит, әгәр ит алмасаң, ул талонга сигез йөз грамм колбаса тия. Эремчек белән каймакны молкомбинаттан китергәндә, кибет янында чиратка басып каршы алсаң гына өлгерәсең. Ә сыр кебек нәрсәне кайчан сорасаң да: «Әле генә бетте!» – дип кырт кисәләр. Их, бер сары гына «Москвич»ың булсын иде дә Лилия апага кыш чыгарга җитәрлек күчтәнәч алып килсәң иде... Ә болай, ике кулыңа ит күтәрсәң, йомырка сыймый, бәрәңге янына сөт алып булмый, суган алсаң, эремчек кала...

Юлга чыкканда бер кулың буш йөрергә тиеш, дип, кара дерматин сумканы шыплап тутырдылар: бүтәкәсен, башын-аякларын аерым төреп, бөтен каз салдылар, биш кадак атланмай, ике дистә йомырка сыйды. Чылбырлы йозагын тарттырганда сумка эчендә бушлык калганны күргәч, Гөлчәчәк, чоланга чыгып, ике сәке балан кагы алып керде. «Толчок» базарына барып җитә калсаң дигән булып, егерме биш сумлык сигез акчаны Сөмбеләнең кытыгы килә торган иң сизгер төшенә – култык астындагы кесә төбенә булавка белән эләктереп куйды. Юл чыгымнарына диелгән вак-төякләр косметичка белән бергә иңбашына асылган бәйрәм сумкасына бикләнде. Кирәк-ярак документларны үзе белән алырга әзерләнгәнен сизеп, әни кеше кызының бөтенләйгә китәргә дигән ниятен чамалады.

– Ярар, ерак ара түгел, кирәк нәрсәң булса, сорап хат язарсың, кеше аркылы җибәрербез, – диде Гөлчәчәк һәм, ниндидер бик мөһим эшне капылт исенә төшереп, карават астындагы чемоданнан бер кассета алып бирде. – Онытa язганмын, менә мин магнитофонга хат яздырдым. Шушы кассетаны

сакла, телдән әйтә алмаганнарым шушында. Атаң-анаң киңәшеннән чыкмасаң, Ходай ярдәменнән ташламас сине...

– Син нәрсә инде, әнием...

Сөмбелә «бөтенләйгә китәм» дип кырт кисәргә дә йә «бер атнадан кайтам» дип акланырга да теләмәде, уңайсызланып әнисенең муенына сарылды. Җиденче сыйныфны бетергәннең каникулында ата каз чукыганнан бирле елаганы юк иде кызның. Күз яшьләре, өч ел буе җыелып, дәү үскән баланың әни куенына кергәнен генә көтеп торган икән. Әгәр газиз гомереңнең санаулы елларын башкаларга бүләк итәргә яраса, әниләр иң кыска гомерле кеше булырлар иде...

Икәүләшеп рәхәтләнеп балавыз сыгып алгач, күчтәнәчле сумка җиңеләйгәндәй булды. Хәер, әтисе ишегалдында көтеп тора иде, олы юлга чаклы ул төпчек кызына авыр йөк күтәртмәде.

Чепья автобусы соңармады. Харис сумканы ишек «саңакларына» бәрмичә генә эчкә кертеп куйды. Сөмбеләгә тәрәзә кырыенда ялгыз буш урын бар иде.

«Атна уртасында юлда йөрүче азрак шул. Анысы шәп булды әле...» – дип куанып куйды ул, автобус кузгалып киткәч. Ләкин әче төтен таралып, ак «пазик» күз алдыннан югалгач, әлеге куаныч бөтенләй мескен булып калды. Харис, хәер-фатиха биреп, үзенең иң изге, бүтән бернәрсә белән дә алыштырып булмастай юанычын, яшереп үстергән чәчәктәй төпчек кызын бөтенләйгә озатты түгелме?!

Әти кешене көнозын күз төбендәге төтен ачысы җәфалады.

Автобус юл өстендәге авыл тукталышларында кеше булмаса да туктап-туктап ял иттерде, гүя Казандагы язмышына Сөмбеләне төп-төгәл график буенча алып керергә тиеш иде ул. Һәркемнең үз вакыты, үз юлы, сәгатен белеп кенә көтеп торган үз бәхете бар бу фани дөньяда.

Авылларны үтеп, кырдагы юлга чыккач, күз аллары яктырып кала. Гомердә авыл табигате күрмәгәндәй, тәрәзәгә ябырылды Сөмбелә. Йотлыгып-йотлыгып күзәтте, күңел түрендә ак кәгазьле яңа альбом ачып, туган як манзарасын рәсемләп күчереп барды, ахрысы.

Кыш аклык булып үсә. Туңга сөрелгән басуларның эре-эре түмгәкләре дә кар белән күмелгән инде. Хәлсез тракторлар бер-бер артлы тезелеп салам тарта. Карлы түмгәкләргә аяк терәп карышып-тартышып кына шуышкан эскерткә ферма песиләре ияргән. Аларга тере уенчык булып кыр тычканнары кайта.

Каршы яктан да автобуслар очрый. Кемнәрдер исә, Сөмбелә ашкынган Казан белән саубуллашып, кире кайтып килә. Юлның икенче ягына чыгып, кайтучылар арбасына күчеп утыра аласың. Сине өеңнән беркем куып чыгармады. Җимеш бакчасы уртасында балкып торган таш нигезле, сигез тәрәзәле нарат өйдә эти-әниеңнең кадер-хөрмәтенә, хәләл мөлкәтенә тиенеп яшәргә хакың бар кана. Бәлки, төпчек малайларны үгетләп, кирәксә, ялварып, бурыч, йола дия-дия төп нигездә калдыру мөмкин хәлдер. Мәгәр үсеп буйга җиткән, җиләге пешкән, ялтыравык хыялларына табынган кыз баланы тышауларлык көч юк. Табигать моң иңдергән икән, ул аңа өстәп үҗәтлек, кырыслык, эзләнү, мактауга сусау да бирә. Моңарчы рәсемнәрдә генә күргән, ишетеп кенә белгән шагыйранә сихри дөньяның эченә барып керәсе килә. Һәм бала ләззәтле хаталары белән мөлдерәмә тулы язмышка ашкына, яңа җыр эзләп чыгып китә. Ул инде, Шушма буендагы тал-тирәкле сандугач оясын ташлап, катлы-катлы итеп өелгән шау-шулы ташлар арасында яшәргә дә риза... Сандугач балаларын очарга гына өйрәтә, ояда җырларга өйрәтми. Җырлар өчен үзеңә аерым оя корырга кирәк...

Биектау авылын үткәч, кар керләнде, тора-бара шикәрлеген югалтып, бөтенләй көл төсенә керде. «Казанга җитәбез бугай», – дип уйлап куйды Сөмбелә.

Кат-кат әйткәнне көтмәде, автобус, Дәрвишләр бистәсен чыгып барганда, кирәкле урында үзе белеп туктады. Лилия апасы эштән кайтырга иртәрәк иде әле. Тукталышта кычыткан капчык авызын кочаклап утырган әбидән бер стакан көнбагыш алмакчы иде Сөмбелә, сәгатенә күз салгач, көрсенеп, ике стакан сорады. Өй түбәсе юлдан күренеп торса да, ашыгып атлады ул, гадәте шулай – әкрен йөрергә яратмый, тиз булсын, җитез булсын аңа. Барасы җиреңдә көтеп торсаң тор, әмма җәһәт йөр!

Авылда булсаң, капка төбендә нәүмиз утырган кунакны күреп җиде күршең чәйгә дәшәр иде. Кесә төбеңдә ачкыч булмаса, шәһәр өчен син кунак түгел, ятим килмешәк кенә икәнсең. Подъезд төбендәге рәшәткә урындыкта утырган кызга беркемнең исе китми. Дөрес, кыздырылган көнбагыш ярганын күреп, түбәдәге күгәрченнәр Сөмбеләнең аяк астына күчте.

Урталарына бер уч көнбагыш килеп төшкәч, җим исен сизеп, тыныч кына миһербанлык көтеп йөргән күк күгәрченнәр гаиләсендә этеш-төртеш башланды, әтәчләре чукышырга тотынды. Ул арада, табыш бүлүчеләрне ерактан күреп алып, хуҗаларыннан качкан ак күгәрченнәр төркем өстенә килеп төште. Авызына ризык кергәне туеп китә белми, читтә калганнары баш төртергә куркып ач йөри. Сөмбелә тагын бер уч тутырып алды. Бу юлысы ул көнбагышларны чәчеп сипте, шунда гына һәркайсысы өлешенә туры килгәнне тынычлап чүпләде. «Җимне тигез сибәргә кирәк шул» дип, үзенчә фәлсәфи нәтиҗә ясап куйды кызый... Чүпләп бетергәч, аклы-күкле төркем ызгышны шундук онытты, гөрләшеп әйләнә-тирәдән юкны эзләргә кереште.

Сөмбелә кошлар белән серләшеп алды: «Алай ук күңелсез түгел икән шәһәрегездә. Сез авылга кайтыгыз. Колхоз күгәрченнәре бик тату яши анда. Ындыр табагы җәен-кышын көрпә тагарагы кебек...»

Лилия апасы Сөмбелә белән сөенечен тыеп кына күреште.

– Бөтенләйгә килдеңме? – диде Лилия, өйгә кергәч. Ул, Сөмбеләнең җавабын ишетмичә торып, түргә үтәргә ашыкмады.

Кыз, бармак очында әйләндергәләп, йон береткасын кабартты. Аннан ашыкмыйча гына күгәрчен тамагы төсендәге плащ белән тышланган төлке якалы пәлтәсенең путасын ычкындырды.

– Белмим әле, апа. Авыл советыннан расчет алмадым. Берәр атна отпускы хисабына булыр, дидем. Клуб ачкычы әнидә калды. Әти белән икәүләшеп танцыга йөрсеннәр бераз.

«Ял, әни, әти, танцы» сүзләрен бергә җөпләп әйткәч, Лилиянең кәефе күтәрелде, авыл күчтәнәчләрен мактарга кереште, төп нигездә калганнарның хәл-әхвәлен сорашты.

– Килгән көнне кунак бик кадерле була ул, – дип, кухнядагы өстәлне тарсынып, ике кеше өчен зал уртасына җыелма өстәлне җәеп куйды.

– Җәйгә имтиханнар тапшырып карыйсы булыр. Керү шартларын белешеп, сайлаштырып кайтыйм дидем.

– Бәлкем, читтән торып кына укырсың. Авылда эшең яхшы иде, чиста, дәрәҗәле, күңелле...

– Сандугач белән чыпчыкның аермасын беләсең ич инде син, апа.

– Беләм, беләм! Чыпчык консерваторияне читтән торып бетергән, сандугач көндезгедә укыган... Әле һаман артист булырга хыялланасыңмы, сеңлем?

– Үҗәтлегемне дә беләсең инде, апа!

Казан җылысыннан куркып кына кыш кереп килә. Чын кар тукталышлардагы калай куыш түбәләрендә, телефон будкалары, трамвай билетлары сата торган киоск өсләрендә генә. Киң урамда таш юллар тозланып шулпаланган. Башкалабызны туйганчы күрим әле дип иртүк чыккан иде Сөмбелә. «Кольцо»да кибеткә кибет терәлеп торгач, шәһәрнең үзәгенә ишек саен чират үсеп чыккан. Җентекләбрәк карап торсаң, алҗыган чырайлы әбиләр, әле сөт, әле колбаса, яшелчә, ипи чиратлары алып, кибеттән кибеткә күчә тора. Шөкер, икмәк талонга түгел әле, бер кулга ике бөтен алырга рөхсәт ителә. Казан күмәчен сагынып килгән зур сумкалы апалар, ипи чиратын түгәрәкләп, кереп-чыгып, кереп-чыгып йөриләр.

Көнне бушка уздырмас өчен, Сөмбелә әүвәл музыка училищесына, аннан консерваториягә барып килде – аралары ерак түгел икән. Марат Гомәр әйткән культура институтын да эзләп тапты. Барган бер җирдә кабул итү шартларын, кызыктыргыч бүлекләрнең төгәл исемнәрен күчереп алды. Ниһаять, бүгенгә җитәр дип, яңадан «Кольцо»га төшсә – үзәктәге чиратлар тагын да зурайган, бүселгән, тынгысызланган. Дәрвишләр бистәсенә йөри торган автобуска да чират бик зур иде. Кулында артык биштәре булмагач, баһадир чират аны этәкләп алды да арткы ишектән төеп кертте.

Төне буе урын өстендә боргаланып чыкты Сөмбелә. Чөнки иртәгә бик борчулы көн. Казанга килүенең төп сәбәбе, яшерен уйлары йокы бирми: «Танырмы ул мине, «Наз» кызлары алдында ничек акланырмын? Әрсезләнеп йөри, мескен, димәсләрме? Икәүдән-икәү калган очракта сүзне нидән башларга?!

Клуб дигәч, Балантауның манарасыз иске мәчетен күз алдына китергән иде Сөмбелә, ләкин завод клубы йөз ел элек байлар салдырган өч катлы мәһабәт бина булып чыкты. Бүлмәләр саны бихисап икән үзе, тик «Наз» халык ансамбле дип язылган ишекләре икәү генә иде. Ул ишекләргә якынайган саен, Сөмбеләнең адымнары акрынайды, адымнар акрынайган саен, йөрәге күкрәк читлегенең кысанлыгына үртәлгәндәй усалланып типте... Менә хәзер ишек җилкәннәре киерелеп ачылыр, аннан колачын җәеп Марат Гомәр үзе килеп чыгар да: «Нихәл, Сөмбелә?! Каршы алырга килүең әйбәт булды, Балантауга концерт белән кайтырга әзерләнә идек әле», – дияр.

Ә ишек артында һаман тынлык. Эчке якта җан иясе юк дияр идең, бер өйрәнчеге имән бармагы белән клавишларны санагандай пианинода «Әпипә» көен эзли. Ишекне ачык калдырып коридорга йөгереп чыгучы кеше дә әнә шул дүрт-биш яшьләрдәге малай булды. Сөмбелә өнсез калды, уйлары өсте-өстенә өелде.

«Ходаем, гармунчының малае, ахрысы, бу. Әллә хатыны да шушында микән? Хәер, булса ни, мин ир эзләп килмәдем лә, җырларга теләүчеләр бер мин генәме... Әнисе: «Улым, ерак китмә, хәзер кайтабыз», – дип ишек тоткасына килеп тотынганда Сөмбеләне күреп алды.

– Син кемне көтәсең? – диде ул, малае белән сөйләшкәндәй.

– «Наз»ны... «Наз»га!.. – дип каушап калды Сөмбелә, чөнки ул җырчы кызлар алдында җавап тотарга бөтенләй әзер түгел иде.

– Кер әле монда, кер. Син ансамбльгә язылырга килдеңме?

– Әйе. Белмим шул... – дип, башлаган җөмләсен ерып чыгарга өлгермәде Сөмбелә, пионер сәхнәсе чаклы бүлмәнең уртасында басып тора иде инде.

– Исемең ничек?

– Сөмбелә.

– Тавышың нинди?

– Ул, лирик сопрано, диде.

– Лирик сопрано – бик интернациональ тавыш ул. Җырлап күрсәт!

– Аның тыңлап караганы бар, – диде Сөмбелә, бертуктаусыз сорау яудыручы яшь әнидән котылырга теләп.

«Аның» дигән сүзенә «кем ул?» дип бәйләнмәгәч, сөенде әле кызый.

– Оялма. Әллә ялындырасыңмы? Җырла давай!

Аркылы-торкылы урындыкларда аптырап утырган тагын биш кыз Сөмбеләгә йөзләре белән борылды. Алар никтер урамнан кергән килеш: өс киемнәрен салмаганнар, төймәләре генә чишелгән иде.

Җырларга тек җырларга, җырчы кая баса – шунда сәхнә дигәндәй, кыз береткасы белән пәлтәсен салып буш урындык аркасына элде дә август төнендәге ак күлмәген төзәткәләде.

– Оho!!! – дип тел шартлатты «наз»лылар. Алар, алдан ук ятлап сүз куешкандай күмәкләшеп янә сокландылар. – Оh-оho!!!

– Мондый материал белән җырламыйча да артист булырга була... Җырлыйсыңмы, юкмы инде?! – Яшь әни дә Сөмбелә кебек үҗәт иде.

– Гармунчыгыз кая? Уйнасын...

– Гармунчыбыз юк бүген.

Сөмбелә, кире киенергә теләп, береткасын кулына алды, тик ашыкмады.

– Алайса, иртәгә килермен.

– Иртәгә дә килмәс ул, кичә дә юк, узган айдан бирле...

Һәм яшь әни җан тамырына җиңелчә генә чиертеп куйды. Үңәченә чиертсә, тамагына салкын тигән дип уйлар идең. Җан тамырына чиертүнең нәрсә икәнен телевизордан «Что? Где? Когда?» уенында ишеткән иде инде кызый. Петр I заманында «сухой закон»ны бозган кешеләрнең җан тамыры өстенә мөһер кыздырып басканнар. Шул көннән бирле инде ике йөз елдан артык вакыт үтсә дә, «мөһергә чиертү» сәрхушләр әлифбасы булып сакланган.

Барыбер гармунсыз-такмаксыз гына «Резидәкәй»не җырлап күрсәтергә туры килде. Шуннан соң алты кыз уникe кеше өчен кул чапты.

– Инде танышыйк, – диде яшь әни, ант иткәндәй кулын күкрәгенә куеп, – мин Әлфия, менә Люция, Илсөя, Фәния, Зәйнәп, Резидә... Безнең монда ярты ансамбль дә юк. Әнә теге фотода җырчы егетләребез: Алмаз, Зөфәр, Фаят...

Әлфия бүген репетициягә килмәгән кызларның исемнәрен стенадагы плакатлардан санарга кереште... Ләкин бер күрүдә егермегә якын җырчының исемен хәтерләп буламыни?..

Кайтырга җыенганда, малаена киенергә ярдәм иткән булып кына Әлфияне сөйләндереп өлгерде Сөмбелә.

– Кайда соң ул Марат абый? Өйдәме, бүлнистәме, Казандамы, берәр авылда качып ятамы?

– Аны белмәссең. Йә телевидение тирәсендә, йә филармониядә, йә язучыларның яңа бинасында... Радиога барсаң, анда да очрый. Кайда күбрәк таныйлар – шунда инде ул.

Уйланырлык хәлләр күбәя Сөмбелә өчен. Әгәр үзен танып белүчеләрне эзләп йөри икән, ник соң әле гармунчыбыз янәшәдә түгел?! Аны Сөмбеләдән дә ныграк танып белгән, көткән, кирәксенгән һәм югалтудан куркып эзләп чыккан башка берәү бармы тамашалар Казанында?!

Ике көн эчендә Сөмбелә шәһәрнең бөтен иҗат оешмаларын, театрларны, концерт залларын, радио белән телевидение бинасын эзләп тапты. Эзләп табып кына калмады, дежур торучы абый-апалардан сорашты, күзенә чалынган афишаларны җентекләп укыды, сәгать унбер тулганны көтеп, якын-тирәдәге гастрономнардан бүселеп чыккан чиратларны күздән кичерде... Ләкин гармунчы табылмады. Шунысы сәер, аның югалуы беркемне дә борчуга салмый кебек. «Күренгәне юк», «күптән килгәне юк», «безнең тирәдә бик йөрми ул хәзер», «югала торган кеше түгел, китереп куярлар әле...» дип юатыбрак җавап биргән җавапсыз кешеләр Марат Гомәрнең еш югалып йөрүенә ияләшкәннәрдер кебек. Сөмбеләнең бәргәләнеп эзләп йөрүе читтән күзәтеп торучыларга гайбәт куертырлык артык сәбәп кебек кенә иде бугай.

Өченче көнне, Химиклар мәдәният сарае янында белдерүләр карап йөргәндә, Сөмбелә кызыл исемнәр белән тыгызлап тутырылган бер афишаны күреп алды. Җырлары патефон тәлинкәсендә чатнаган биш-алты җырчыны санаганнан соң, уртага зур хәрефләр белән «Наз» халык ансамбле дип өстәгәннәр. Билетлар соңгы рәттән генә калган иде инде. Сөмбелә, бер сум илле тиеннән сыңар билет алып, тагын уйга калды. Ул Лилия апасын чакырырга уйламады да, ник дисәң, «Наз» ансамбле катнашмаган мәлдә Сөмбелә үзе дә концертны ташлап кайтып китәчәк. Туган апасы кызның кайбер серләрен белмичәрәк торсын.

Башланырга ике сәгатьләп вакыт бар иде әле. Кыска көннәрнең эңгере куерганны көтмичә, багана башларына бәйләм-бәйләм элengән неон лампалар кабынгач, концерт бинасы мәһабәт наратлар арасына салынган әкияти сарайга охшап калды. Электр утын кызганмасаң, карурманнарны да яктыртырга була икән... Алдан килгәннәрне ымсындырып торган ешлыкта һәр куак, һәр үлән нурга коенган, рәт араларындагы сукмакларның кары көрәлгән, чүп савытлары тезелгән, куе чытырманнарның шомы качкан. Сөмбелә башта бер рәттән үтте, аннан икенчесенә күчте, сукмаклар белән телгәләнгән ешлыкның эченә кергән саен серлелек артты.

«Ә бер наратны кискәннәр!» – дип көрсенде кызый, кар астыннан күренеп калган кара төпне ерактан ук шәйләп. Тик, якынайгач, ул төпнең кондыз бүрек кигән башы да бар булып чыкты. Икенче рәткә сикереп трамвай юлына таба йөгерергәме, әллә ярдәм сорап кычкырыргамы дип аптырап атлый торгач, Сөмбелә әлеге бүрекле төпнең янәшәсенә үк килеп җитте. Кызый, капчыклы бодайларны арбага ыргытырлык беләкләрен киереп, горур рәвештә үтеп китәргә теләгән иде.

– Сөмбелә, нихәл? – дигән мыгырдау аны кинәт туктатты.

– Исәнмесез?..

Казанның танып дәшәрдәй кешеләрен без дә танырбыз дигәндәй, кисәк борылып караса – гармунчы! Кар өемен кәнәфи итеп утырган, кулларын ике якка җәеп арка терәвен колачлаган, тезен тезгә чалыштырып бүрекле башын артка чөйгән, чыраен сакал баскангамы – мыегы бөтен иягенә җәелгән кебек...

– Балантауга барыбер кайтам, дип әйттемме мин сиңа? Менә бит, кайттым!

– Юк инде, Марат абый, мин үзем Казанга килдем. Сине көттем-көттем дә.

– Көн саен сезгә кайтам дип чыгып китәм, юлым борылып-сырылып бетә.

– Ауга чыктың мәллә, Марат абый, куак арасында качып ятасың?

– Бик образлы итеп әйттең... Мин чынлап та сунарчы. Бераз көтеп торырга иренмәсәң, үз күзләрең белән күрерсең – ак колагыннан тотып куян баласын китерәчәкләр.

Исерек кешенең тел төбенә төшенер өчен әйткән сүзләрен икешәр кат кабатлатырга кирәктер. Шаяртамы гармунчы, фикер тирәнлеге белән өстен булып күренергә телиме – аңламассың... Тик шунысы аермачык – ул кемнедер көтә. Һәм ак колакчыннарын салындырып куян бүрек кигән сәрхуш килеп басамы хәзер, әллә куян мамыгыннан эрләнгән кыеклы шәлгә төренгән һәвәскәр кызыймы – барыбер, Сөмбелә аны, гармунчы әйткәнчә, үз күзләре белән күрергә тиеш.

– Тор, Марат абый, ояңа салкын тидерерсең.

– Минем пәлтәм калын! Мондый салкыннарны күргән бар! Узган көзне, ансамбль белән Имәнкискә авылына бардык. Концерттан соң колхоз автобус белән кайтарып куярга тиеш иде. Килмәде автобус. Шоферы төнлә Казан юлына чыкмас өчен махсус исергән, диделәр. Урамда тездән кар, клубка ягылмаган. Кем сәхнәгә, кем бильярд өстәленә бөгәрләнеп яттык. Тамашачылар сулышыннан бәс сырган сәхнәдә ике сәгать буе күлмәкчән җырлап күшеккән кызларны җылытыр өчен клуб эчендә төнлә учак ягасым килде... Түздек. Кайткач бөтен ансамбль температура белән аяктан егылды. Ә минем менә шушы пәлтә канатына сыенган ике кыз исән-имин калды... Бүтән Имәнкискә сәхнәсенә аяк басмабыз дип ант иттек.

– Пәлтәм җылы дип кар өстендә төн кунарга җыенмыйсыңдыр ич? Кемне көтәсең соң син?

– Офицерлар кибетенең грузчигын көтәм. Мин аңа ун сумлык кызыл акча тоттырып калдырдым. Талонсыз-нисез генә бер ярты таба алам, диде.

– И Марат абый! Бигрәкләр дә беркатлы кеше икәнсең син! Кулына ун сум акча тоткан грузчикны көтеп кыш чыгарсың әле шушында.

– Син нәрсә, кызый, минем дусларга ышанмыйсыңмы?! Женя грузчик кына түгел, Женя – заманында Вафирә төркемендә соло-гитара уйнап дан казанган кеше! Әнә! Әнә килә ул! Маэстро, тизрәк атла! Окопта салкын!

Каеш табанлы киез ботинкасын лаштор-лоштыр сөйрәп, бер кат күлмәк өстеннән болонья куртка бөркәнеп, ялан башын җилдән саклапмы – бөкшәеп килеп баскан бу грузчикның кайчандыр зур җырчылар янәшәсендә чыгыш ясый алганына ышануы да кыен. Ул иң элек Сөмбеләгә шикләнеп карады, гармунчының «кызый үзебезнең кеше» дигән ым-шымын сизгәч кенә, куенындагы хәзинәсен чыгарып, ватылган ун сумлыкны хисаплап тапшырды.

– Нәкъ син әйткәнчә, бөкесе колаклы. Биш сум утыз тиенлеге. Ундүрт тиенгә ике сыр, ун тиенгә алты карамель. Калган дүрт сумы вагы белән, – дип, Женя сдачаны йомарлап гармунчының кулына тоттырды.

Балантауда бәйрәм саен диярлек мондый гына сәрхушләрне күргәне бар инде кызыйның.

«Болар гурласыннан гына чөмерергә җыеналар ахрысы» дип уйлап өлгерде микән Сөмбелә, юкмы, ул арада Женя курткасының күкрәк кесәсеннән майонездан бушаган банка чыгарып бүлә башлады. Савыт тулган арада, кул калтыравыннан болонья курткасының җиңе өзлексез кыштырдап торды. Женяның күптән баш төзәтер вакыты җиткән иде бугай инде, тик шулай да ул сәхнә кешеләренә хас

горурлык белән, салкыннан поскан муенын яка эченнән чыгарып, махмырлы башын артка чөйде һәм мөлдерәмә бокалны Сөмбеләгә сузды.

– Мадам! Беренчесе сезгә!

Гармунчы, «мадам» дигәне өчен Женяны сүгәргә онытып, Сөмбеләгә текәлде, чөнки кызый, тәҗрибәле сәрхушләрне үртәгәндәй, әүвәл сул кулы белән борын астын пыршылдатып, уң кулы белән кисәк майонез банкасына үрелде.

Мондый гына скетчларны уйнаганы бар инде Сөмбеләнең. Их, шешәләрен тартып алып ярты литрлы юанычларын кар астына агызасы иде! Гитарачы абзагызның кыллары зыңлап өзелер иде, мөгаен, югалту кайгысыннан үз-үзен белештермичә, шешә белән маңгаеңа менеп төшәргә дә күп сорамас, Алла сакласын! Ә гармунчы нишләр иде икән? Яклап сүз әйтерме, әллә икәүләшеп дөмбәсләп көрткә күмеп китәрләрме?.. Күрәләтә хәвеф оештыру булыр иде бу...

– Урамда эчә алмыйм. Минем өлешне шешәсендә калдырыгыз, – диде Сөмбелә һәм, җирәнүен артык сиздермәскә тырышып, хәмерле савытны кире Женяга тоттырды. – Әтием әйтмешли, кичен эчкән аракы агу белән бер.

– Мәктәп баласы әле ул! – дип яклашты гармунчы.

– Нинди бала?! Мәктәпне җәй көне үк бетердем инде.

– Сездән соң әлегә аттестат өләшкәннәре юк. Димәк, мәктәп баласы син... Җәй җиткән саен, чыгарылыш имтиханнары үткән саен олыгаерсың...

Гармунчы конфетларны Сөмбеләгә бирде.

– Мин эчмим! – дип баш тартты гармунчы, мөлдерәмә банкага чират җиткәч кенә. – Концертка кереп үземне тыңлыйсым бар. Афишага язганнар!

– Блин! Шешәне бушатыгыз! «Русская водка» өстенә автографыңны куйдырып алып кайтмасам... хатын ышанмый миңа бүген...

– Ә без аның этикеткасын куптарып алабыз! – дип тотынган иде гармунчы, тик «Русская водка» бик һәйбәт ябыштырылган булып чыкты, ертылып бетте.

Женя югалып калмады, чалбар кесәсеннән сары бер сумлык чыгарып, гармунчыга сузды. Тегесе, бөгәрләнеп беткән акчаны шырпы кабы өстендә тигезләп, автограф куеп бирде.

– Имзаңны бик арзанга өләшәсең! – диде Сөмбелә, үртәлүен тавышына чыгарып. – Һичьюгы унлык булса да ярар иде, кирәксә, миндә егерме биш сумлыгы бар.

– Һе, юк, кызый! Син мине әллә исерек дип беләсеңме ул чаклы?! Беренчедән, унлык белән егерме бишлектә Ленин бабай башы бар. «Перестройка» белән «гласность»ка ышанып, сәяси хата ясар хәлем юк. Икенчедән, Женя бер сумлыкны вакламыйча түзәргә мөмкин, ә зур акча нәфесне гел кытыклап тора ул.

Әллә терелеп хәл керде үзенә, әллә салкынга бүтән чыдар чамасы калмады – Женя килгән сукмагыннан кире йөгерде. Гармунчы, утырган җиреннән җәһәт торып, пәлтә итәгенә ияргән карларны какты да үз урынына эчелеп бетмәгән шешәне батырып калдырды.

– Монда тагын киләсең мәллә, Марат абый?

– Кем белгән?! Күмеп куям әле. Бозыла торган нәрсә түгел. Концертларны карап чыккач килеп китәрбез.

– Шушы хәлдә залга керәсеңме? Анда кеше күп булачак бүген.

– Беләм. «Наз» ансамбле катнаша дигәч халык җыелмый ни... Ә безне афишага кертергә рөхсәт сораучы булдымы – юк!

– Соң, Марат абый, исемегез зал тутырырга ярдәм иткәч әйбәт ич инде.

– Кемгә әйбәт? Аларгамы?! Ике язарлар, өч язарлар... Ә без катнашмыйбыз. «Наз»лар ялганчы» дип бер сүз китсәме... Үзеңә кирәк чакта ялынып та җыя алмассың тамашачыны.

– Димәк, исемең язылган җиргә алдан ук әзерләнеп килергә кирәк... Мондый хәлдә түгел инде... Без авылда да хәтта сәхнәгә эчеп чыккан артистларны сөймәдек... Ә монда, Казан уртасында... Обком шушында, бөтен министрлар, начальниклар, студентлар, гәҗит-журнал корреспондентлары шушында.

– Син нәрсә, кызый, мине тәрбияләргә килдеңме?

– Юк, Марат абый, мин сиңа ышанып килдем.

– Әйе бит әле, синең артистка буласың килә. Синең яшьтә бөтен кызларның да артист буласы килә.

– Алайса, мин буш хыял куып йөрим инде, шулаймы, Марат абый? Әйт миңа хәзер, күземә карап әйт! Балантавыңда яшә шунда, шәһәрдә синең ишеләр буа буарлык, дип әйт. Кайтам да китәм.

– Бик сагынгач... кайтып кил соң...

– Сагынмадым әле.

– Алайса кайтма! Синең тавышың Оркыя Ибраһимованың баяны кебек моңлы. Минем баян синең янда мескен генә.

– Баян сайларга дип килмәдем, Марат абый. Әйдә, өеңә илтеп куям.

– Ә син әле Казанда йөри белмисең...

– Ияреп кайтам. Өеңне тапмаслык ук исермәгәнсең лә.

Җәяүлеләр өчен тап-такыр итеп көрәп куелган киң сукмакка чыккач, гармунчы сумалага ябышкандай, адымын атлап бетермичә тукталып калды.

– Минем өем юк.

– Бөтен кешенең көтеп тора торган өе бар, Марат абый.

– Юк, дидем. Мин калдырам да китәм, калдырам да китәм...

– Бигрәк юмарт икәнсең... Урамда яшәмисеңдер ич инде?

– Кунактан кунакка йөрим. Бүген менә сиңа кайтабыз.

– Мин әле Казан кызы түгел... Сине бу хәлдә Лилия апама күрсәтәсем килми дә. Балантауга дисәң – бер хәл, әти-әни алдында аклануы җиңелрәк. Хет иртәгә үк кайтып төшик.

– Бүген үк! – Гармунчы күкрәк кесәсеннән чылбырлы сәгатен алып ут яктысына ачты да уйнап башланган сүзне чынга борып куйды: – Кичке биш. Җәй көне бу вакытта әле көтү дә кайтмаган була. Хәзер такси туктатабыз, теләсәң, оҗмахка илтеп куя.

– Түлке, Марат абый, авылда аракы юк. Туй өчен дигәндә, район рөхсәте белән ике ящик бирәләр бирүен... Ә болай кибетләрдә корылык.

– Бетте. Күз алдыңда ташладым ич. Кар өстендә калган шешә соңгысы иде. Мин гел шулай, бер-ике атна шаярып алам, сәбәпләре җитди булганда. Бүтән эчмим. Коръән булса, кулыма тотып ант итәр идем. Юк бит. Кесәмдә Шәүкәт Галиевнең шигырь китабы бар. Телисеңме, шуның белән ант итәм.

Һәм гармунчы җырлап та җибәрде:

Күпме күзләр күреп онытылган,
Күпме күзләр чыккан хәтердән...

Җыр бик тиз бүленде. Урам уртасын сәхнә итәргә җыенган Марат Гомәр янына ике милиционер килеп басты. «Гражданин, ваши документы?» дигәне чын урыс иде.

Сөмбелә гармунчының беләгенә чытырдап ябышты:

– Марат Гомәр же это, абый җанашым. Ансамбль «Наз»!

Әле дә ярый фуражкалыларның икенчесе татар егете булып чыкты. Ул юри генә эндәшмичә елмаеп торган икән.

– Беләм, сеңлем. Өйдә кассеталары бар. Ә бу кеше, – диде ул, иптәш егетенә төртеп, – Рауза Рымбаева белән Суфия Ротарудан гайре җырчыны белми. Марат абый, все же урамда кычкырып йөрмә инде син, сәхнәдә генә җырла. Давайте тыныч кына, яме!

Милиционер егетләр киткәч, гармунчының беркавым кәефе кырылып торды. Аннан, кыз алдында уңайсызланыпмы, акланган сыман өстәп куйды:

– Әйтәм ич, безнең илдә һәр урыска берәр татар ияреп йөрергә тиеш. Юкса паспортсыз-нисез урамга чыгам димә.

– Авылда рәхәт ичмасам. Анда участковый һәркемне танып белә.

– Киттек, Сөмбелә, сезнең участковый янына.

* * *

Сөмбелә гармунчыны ияртеп кайткач, Гөлчәчәк белән Харис телдән яздылар. Парторг озатып кермәде, шагыйрә дуслары иярмәгән – кызларына алма корты булып төшкәне аңлашыла ласа!

Һәрхәлдә, өй эчендә, абзар-курада йорт мәшәкатьләре көндәгечә бер көйгә дәвам итте. Һәркем, үзе белеп дигәндәй, капка төбендәге сукмакны себерде, ишегалдындагы карны көрәде, мичкә якты, мал-туарны карады. Бер өстәл артына дүртәүләшеп табын кордылар. Аерым-аерым урын җәйделәр. Гармунчыны коры сырадан да өзмәделәр, якты йөз, кунакчыллык сүзсез генә дәвам итте. Дөресрәге, барысы өчен дә Сөмбелә сөйләште: кирәк нәрсәне сорап алды, кыстый-кыстый сыйлады, яңалыкларны сорашкан булды һәм үз сорауларына үзе үк җавап та биргәләде.

Өч көннән соң, колхоз белән араны бөтенләй өзеп, Сөмбеләнең инде гармунчыга тагылып китәсенә ышангач, әни кеше нәсихәтен әйтерлек көч тапты:

– Анда итәгеңне җыеп йөре, кызым!

## Малайлар чуагы

Телефонда тәүлек буена җыелган язмалар бихисап булып чыкты, автоответчик тагы хәбәрнең беренчесендә тимер тавышлы хатын-кызның катгый кисәтүе: «Шәһәр телефон станциясенә ундүрт сум бурычыгыз бар. Атна эчендә түләмәсәгез, телефоныгызны өзәбез!» – диелгән. Менә шулай коры сөйләшәләр хәзер налог түләүчеләр белән. Газовиклар сүндерәбез ди, электриклар кисәбез ди, элемтәчеләр өзәбез ди, водоканал бетерәбез дип кенә янап тора. Мондый янаулардан котылыр өчен

гади халык бу тормышта нәрсә кисәргә тиештер – монысын белгән юк. Әлегә безнекеләр коммунизмны сагынып-сүгеп базар мөнәсәбәтләренә «йомшак» кына кереп, катыга лып итеп утырды.

Сөмбеләнең ул ундүрт тәңкәлек квитанцияне күргәне юк, бушлай килә торган калын-калын реклама гәҗитләре белән ташланганмы ул, әллә төшеп югалганмы – анысын шылтыратып белешәсе булыр.

Сөмбеләләрнең почта әрҗәсе беренче катның лифт ишеге каршында. Элеккеге елларда сабыр гына лифт көтәргә түземлеге җитмәгән үсмерләр, әрҗәләрне каерып, килгән почтаны ботарлап баралар иде. Хат-хәбәрләр дә күпләп югала торган иде... Инде хулиган малайларга да уй керде, почта әрҗәсен ачкан саен аннан кочак-кочак квитанция, счет, боерык кәгазе йә хәрби повесткалар коеласын беләләр, тимиләр. Атналап гастрольдә йөрсәң дә, төя-төя тутырылган кәгазьләр шул килеш тора. Укулар башлангач, Зәйтүнә гел өйдә, күрше Мөнирә әби белән ике фатирны бер итеп дигәндәй яшәп калалар. Хат ташучылар килгәнче, әрҗәне вакытында бушатып өлгерәләр.

Телефон чыбыгын өздерергә ярамый Сөмбеләгә, һич ярамый. Заманында җидешәр мең түләп тә күп еллар буе чират көтәсе бар иде өеңә телефон кертер өчен. Ярый ла ул чактагы элемтә министры Сөмбеләнең якташы булып чыкты, чиратны алгарак күчерергә ярдәм итте.

Кесә телефоны уенчык кына бит ул, ашыгыч ярдәм өчен генә. Гипермаркетларда адашканда, урам бәйрәмнәрендә югалышканда, бер-береңне эзләргә җайлы. «Син кайда йөрисең? Кайчан кайтасың?» дигән ике сорау аркасында гаиләдә кеше саен кесә телефоны.

Ә чыбыклы телефон гел өеңдә уяу тора, фатирыңны, малыңны саклый, килгән хәбәрләрне язып бара, төшеп югалмый, маршрутлы таксиларда урланмый, аккумуляторы утырмый, элемтәсе нык. Чыбыклы телефон – тугры дус, аның адресы бар. Утыз ел элек кемгәдер язып биргәнсең икән – номерың гел шул. Алты урынлы, хәтта җиде урынлы саннарга күчкәндә дә, телефон номерларының искесен саклап, алдагы санны гына үзгәртергә тырышалар. Теләгән кешеңне эзләп табуы кыен түгел.

Сөмбеләне дә кемдер эзли... Шуңа күрәдерме бу арада аның уйлары күбәйде, берсен-берсе ашыктырып, өсте-өстенә өелеп тора. Ул автоответчиктан икенче хәбәрне ачты. Ләкин икенче «хәбәр» хәбәрсез югалган: ярты минут буе эндәшмичә торган. Сөмбеләнең өйдәме, юкмы икәнен белергә теләгәнме, әллә кара-каршы сөйләшер сүзе бармы? Сулыш алганы да ишетелә хәтта – ир кеше булса, куркак, хатын-кыз икән – мәкерледер ул.

Әйе, кайсыбер көннәрне гастрольгә дигәндә төркемдә унышар кеше җыела. Яшенә-картына карамый, һәммәсенең өендә көткән кешесе бар. Җырчының телефоны бүгенге кебек сораулар, үпкәләүләр, үртәү-шелтәләүләр белән тулган чаклар еш була. Зәйтүнә аларны әнисе кайтканчы сыздырып ташлый торган иде, бүген өлгермәде шул:

«Кичә үк кайткансыз, минеке бүген дә юк әле...»

«Ник аны банкетларда бераз тыймыйсың, эчеп үлгәнен көтәсеңме?!»

«Петербурга чаклы барып әҗәткә җырлап йөрмиләр инде. Башка артистларга шундук түлиләр...»

«Өеңә җыеп күңел ачтырып ятма, балалары көтә!»

Бу хәбәрләр телефон хәтереннән сызылып, яңалары белән алышынгач та, Сөмбелә хәтеренә күчеп, атналар буе тынгы бирми, күңелнең иң тирән төпкелендә дегет булып нахакка җәелеп кала, онытылды бугай дигәндә дә искә төшеп горурлыгын борчый иде. Мәгәр бүген кызның халәте бүтән, аның фикер сөрешендә вазгыять үзгәрде. Салкын сулышы сизелеп торган ярты минутлык язма хакына ул бүген барлык мескеннәрне дә гафу итте. Сары розалар бүләк итәрдәй кеше җырчының уйларын куып тоткан, ул барыбер күрешү чарасын эзләячәк. Чөнки Сөмбелә шулай тели, аның өчен сөенечле күрешүләрнең, серле өметләрнең, мәхәббәт гөлләренең тансык чагы.

Телефондагы барлык хәбәрләргә кул селтәп, рәттән сыздырып ташламакчы иде Сөмбелә, күңеле сизенгәндәй, иң соңгысын тыңлап карарга булды. Анда Хәмзә тавышы.

Хәмзә – бик универсаль артист, кулыннан килмәгәне юк. Ул, кирәксә, җырчы, композитор, язучы, алып баручы, гармунчы, режиссер, сценарист, укытучы да үзе. Бөтенесен дә әз-мәз булдыра. Эстрадага хилафлык китермичә генә «Яшел эшләпә» дигән гәҗит тә чыгарып караган иде. Ел ярым дигәндә күңеле булды, гәҗитен япты, яшел эшләпәсен чөйгә элде. Ул, диңгез сәяхәтчесе кебек, архипелаглар, утраулар, яңа илләр ачарга ярата, ләкин үзе анда озаклап яшәргә теләми. Җитди кичәләрдә парик кия, юмор сөйләгәндә пеләш баштан чыга. Аның бу гадәтен Президент та сизеп алган, сабантуйда күрешкәндә бөтен кеше алдында ул аңа «Ике башлы Хәмзә» дип эндәшкән.

Хәмзә Сөмбеләнең репертуарын яттан белә, «солянка» дип аталган кумәк концертларда бик еш кына бергә туры киләләр.

Сәхнә дөньясының кәмит яклары күпкырлы. Артистлар арасында киң таралган атамаларның тамырдаш мәгънәләрен эзләр өчен тел белгече булу гына җитми, пешекче, балта остасы, тәрҗемәче, хәтта экономист та булырга кирәк. Әйтик, музыкант күзлеге аша караганда «солянка» сүзенең тамырында «соло», ягъни ялгыз җырчы – солистның үз концерты дигән мәгънә ятарга тиеш. Юк, бу очракта ул берничә яшелчәдән пешерелгән солянка ашына кайтып кала, димәк, концертта бик күп солистлар чыгыш ясаячак... Әгәр башкарыласы көй алдан ук тасмага язып куелса һәм сәхнәдә

музыкантлар уен коралларын күтәреп юри генә басып торсалар, бу вакытта инде фонограмма «фанера» дигән төзелеш материалына әверелә. Электр көчәнешендәге полюслар да «уңай» яисә «тискәре» дигән мәгънәсен бөтенләй югалта. Әгәр җырчы фанерага үз тавышы белән кушылып җырлый икән, монысын «минусовка» диярләр. Ә инде анда башкарыласы җыр да язылган булса, ни өчендер «плюсовка» дип уңайга әверелә. Баянга кушылып «тере» килеш җырлау исә «живьем» көчәнү дип атала. Артистлар телендәге «отвертка» ул – исерткеч белән «пепси-кола» кушылмасы, аның шөреп бора торган эш коралына бөтенләй катышы юк. Техниканың исән-имин хезмәт итү елын вәгъдә иткән «гарантия» сүзе артистлар телендә «кеше килмәсә дә, концерт булмаса да, түләнәчәк» дигәнне аңлата. Мәҗлесләрдә артистлар утырган өстәл шар тәгәрәтерлек булып бушап кала икән, монысы «банкет на шару». «даром-шаром»га сыйлануны башкача ничек атыйсың ди инде тагын?!

Хәмзәдән килгән хәбәр артистлар телендә язылган иде:

*«Сөмбелә, җомга көнне гарантиягә бер солянка бар. Минусовой фанераларыңны алып тор, ну күбрәк «живьем» җырлыйсы булыр. Баянчыңны калдырма, безнеке отвертка белән күбенгән. Артистлар өчен «на шару» швед өстәле әзерлиләр. Катнашам дисәң, срочно шылтырат... Хәмзә бу».*

Авызы бер пешкән кеше шикәрне дә өреп кабар, Сөмбелә чакырган һәр җиргә йөгереп бара торганнардан түгел. Ашыгып килгән яңалыкның ялганы күп була. Хәмзәгә шылтыратып вакыйганы төгәлрәк белешмичә ярамас.

– Алло, Хәмзә?

– Сөмбелә, нихәл? Җомга көнне бушмы син?

– Бушлыкка буш. Кайда була соң ул концерт?

– Барыбер түгелмени?

– Мин кайданиләр җырлаганымны язып барам. Кабатланмас өчен. Син чакырган җирдә булганым бармы-юкмы, көндәлектән тикшерәсем килә.

– Кая икәнен үзем дә белмим. Кичке дүрткә «Хантимер» ресторины янына җыелырга диделәр. Зурдан кубып банкет үткәрәләр, ди.

– Банкет?! Ә кемнең бәйрәме?

– Нииндидер мальчишник булса кирәк.

– Ә мин нәрсәгә алайса?

– Әмир үзе киләчәк. Ә ул халык җырларын бик ярата. Жора Хәйбушов урынына чакырам мин сине. Жора Мәскәүдә йөри, кайтып җитмәскә мөмкин. Кайтып өлгерсә дә, борчылма. Бәлки әле, сиңа җырларга да туры килмәс, ну түләү гарантияле. Бер җыр җырлап, сыйланып кайтасың килмиме? Сораган ставкаңны бирәләр.

– Банкетларны җенем сөйми.

– Баедың мәллә, Сөмбелә?!

– Хәерченең иң зур кимчелеге – аның горурлыгы, Хәмзә. Әле унбиш ел элек кенә көтүче булып йөргән яңа байлар алдында шамакайланып мескенләнәсем килми.

– Сәнгать шуның өчен инде ул, теләмәсәң, ихтыярың... Карале, Сөмбелә, сине бенефис үткәрергә җыена диләр. Нинди уңайдан ул? Яшең түгәрәкләнергә иртәрәк бугай әле...

– Иҗатыма – егерме, кызыма унсигез яшь тулу уңаеннан.

– Оригинально! Шәп идея! Ә беләсеңме, ул банкетта спонсорлар күп булачак, мактаулы исемгә кул куярдай кеше дә килә. Яшерен-батырын түгел инде, артистларга званиеләр, орден-медальләр өләшү иң элек банкетларда хәл ителә.

– Синең банкетлардан кайтып кергәнең юк. Ә наградной листыңны ничә тапкыр кистеләр инде.

– Ни бит, Сөмбелә, мин кыек-мыек сүзләр сөйләп кенә күңелләрен күтәрермен дип тырышам да, ялгыш турысын әйтеп атам. Турысын әйткән түрәсенә ярамаган, ди... Хәмзә дигән исемем җитә миңа.

– Миңа да шулай. Җырчы сәхнәгә фамилия белән чыга, ә исем дигәнең соңрак үзе килә ул.

– Ярар алайса. Әле уйланырлык вакытың бар. Акылыңа килсәң, шылтыратырсың. Хәерле төн сиңа, яме... Зәйтүнәңә сәлам әйт. Мин аңа багышлап бер җыр язам әле. Бенефисыңа чакырырсың... Зәй-зәй-зәй-Зәйтүнә асыл кошым, зифа буйлы җитез канатым, Зәй-зәй-зәй...

Сөйләшү кинәт өзелде. Хәмзә яңа җыр язарга утырды бугай.

* * *

Әүвәл электр кыңгыравы шау-шу куптарды. Гадәттә, иртәнге якны мазасызлап, йә хәер сорануучылар, йә махмырлы музыкантлар, йә яшелчә сатучылар килә торган иде. Алар, өйдән өйгә йөреп, бикле ишекләреңне ачтырырлар, «Кишер, кәбестә, бәрәңге кирәкмиме?» дигән мәҗбүри гозерләренә җавап ишетмичә торып тынгы бирмәсләр. Сөмбеләнең шуңа күрәдерме кыңгырауның өзгәләнүенә исе китмәде. Иртәнге хәбәрләргә битараф ул. Әти-әниләреннән хәвефле телеграммалар көтми, әле атна башында гына Балантауга кайтып хәлләрен белеп килде, шөкер, сау-таза калдылар: абзардагы мал-туарның көенә төшеп, бакча-кураны тернәкләндереп, бишпочмаклы өй эчен көр

мөгамәлә белән тутырып яшәп калдылар. Үзләренең Сөмбеләгә кунакка килеп китәргә исәпләре юк. Яңа фатирга күчкәч тә төпчек кызларын хат җибәреп кенә котладылар. «Пенсиягә чыккач айкап кайтырбыз әле, Казаныгызны да бик сагынабыз» дигәннәр иде, ләкин, хикмәти Хода, Гөлчәчәк белән Харисның пенсиягә чыкканнарына бишбылтыр инде, тик Сөмбеләнең бусагасын атлап кергәннәре юк әле.

Кыңгырау тагын тавыш куптарды. Ул да булмады, мазага ишек шакулары өстәлде – ике фатирны аерып торган тоташ тимер ишеккә ачкыч түтәсе белән төяләр иде.

– Әни, бар ач инде, безгә бит, – диде күрше бүлмәдәге Зәйтүнә һәм үзе, көтелмәгән кунаклар өйгә керә калса дип, тиз генә торып, спорт костюмын киеп куйды.

Сөмбелә, өй ишеген бераз ачып, тимер ишек артындагы тавышлар белән аңлашты.

– Кем анда?

– Судебный пристав.

– Чакырганым юк. Адресны бутагансыздыр.

– Сезгә түгел, күршегез Галиевләргә килдек. Ул ишеген ачмый. Без аны ике тапкыр кисәткән идек инде.

– Әгәр ачмасам?!

– Тимер ишегегезне ватып керәбез. Галиевне мәҗбүри рәвештә фатирыннан күчерергә дигән суд карары бар...

Закон белән тимер ишек аша әрләшеп утырудан ни файда?! Ачып кертте. Алар җәмгысы алты кеше иде: икесе – пристав, икесе – милиционер һәм ике эшче.

Хөкемдарлар илчесенең Галиевләр дип күплек санда сөйләшүе бераз сәер тоелды, Мөнирә апаның ире үлгәнгә инде өч айлап бар, ул хәзер бер бүлмәле фатирда үзе генә яши. Сөмбелә монда күчеп килгәндә, Зәйтүнәгә әле ун гына яшь иде. Себер якларына икешәр атналык гастрольләргә чыгып киткәндә, өченче сыйныф укучысы тулаем күршеләр кулында кала иде. Телефонга керешү, суыткычка ит-май куеп тору, бер-береңә ачкычлар ышанып калдыру ише йомышлар урам-подъезд ыгы-зыгысыннан тимер ишек белән бүленгән ике фатир арасындагы дуслыкны туганлык дәрәҗәсенә җиткергән иде. Әнисе гастрольләрдән кайткан чакта да Зәйтүнә, йомшак уенчыкларын күтәреп, бер бүлмәле күршеләренә кереп уйнарга ярата иде.

Мөнирә апа ире белән икәүләшеп шәһәрнең Ленин исемендәге фәнни җитештерү берләшмәсендә эшләде. Яшьли килеп урнашкан эш урынын алыштырмыйча, сау-таза гомерләрен шунда үткәрделәр. Иртән икәүләшеп ашыга-ашыга чыгып киттеләр, кичен бергәләшеп кайтып керделәр. Яшь аермаларын киләчәк өчен алдан ук күз алдында тотып кавышканнар диярсең, пенсиягә дә икесе бер елны чыктылар. Халык телендә «Дары заводы» дип йөртелә торган берләшмәгә Ленин исемен ник кушканнардыр, ул кадәресен эшчеләргә аңлатучы булмады. Анысы хак, бик серле завод иде ул. Бер серләрен Сөмбелә дә сизеп алды. Мөнирә апаларның сулышыннан эфир исе килә, якын торып кара-каршы сөйләшкәндә, бу ис үзен аеруча нык сиздерә иде. Операциягә-мазар эләгә калсаң, Алла сакласын, безнекеләрне наркоз алмый, дип бик еш зарлана торган иде күршеләр. Башка заводныкыларга караганда пенсиягә ун елга алданрак чыксалар да, тигезлек белән картаерга язмаган, Мөнирә апаның ире Ленин яшенә җиткәч җан тәслим кылды. Утыз биш ел тигез гомер итеп тә истәлеккә калырдай бала таба алмагач, Мөнирә апа берүзе яшәде һәм ялгызлыкны бик авыр кичерде. Өендәге ялгызлыктан качып йөргәндәй, йә мәчеткә ашыкты, йә митингларга кушылды. Ленин исемен саклап тоткан Мәдәният сараендагы чараларны калдырмады, өметсезләргә ияреп «Орион» пирамидасына килеп эләкте. Дөресрәге, һәр атна кич үткәрелә торган лекцияләренең берсенә туры килде.

Чибәрләр бәйгесендә җиңеп чыккан кызларга алыштыргысыз бер ханым сәхнә уртасына чыгып баскан да залдагыларны күз уңыннан ычкындырмаска тырышып кына сөйләпме-сөйли: җөмләләре шигырь кеби, фикерләре тылсымлы әкият гүя, тавышы көйгә салынган. Илле сум түләп кергән лекциядән шунысы аңлашылды: бер мең доллар акчаңны кызганмасаң, ел эчендә йөз мең булып әйләнеп кайта, ди! Үзең ише тагын ике кеше алып килсәң, беренче взносыңның яртысын шундук кире кайтаралар, таба алмасаң, мең килеш «Орион» кассасында калып тора. Кыскасы, тиз арада һәркем меңәр долларлы ике кешене тотып китерергә тиеш. Кем алдан языла – йөз меңне дә алданрак ала... Шул көнне үк язылып кайтты Мөнирә апа. Акчасын китереп бирергә ашыкмаган иде, ике көннән теге төзек ханым өенә килеп җиткән, өстәмә лекция укып күндерде. Йөз мең сумлы матур киләчәк сихерләде тәки...

Сөмбеләнең юлда чагы иде. Ул инде язмыштан шактый өтелгән – залдагы халыкның психикасына йогынты ясарга өйрәнгән, кешелекле күз карашын гипноздан аерырлык кына тәҗрибәсе бар. Тик, гөнаһ шомлыгына күрәдер, гастрольдән кайтып җиткәнче, Мөнирә апасы ире белән гомер буе җир астындагы заводта эшләп җыйган барлы-юклы акчасын, «Орион» тирәсендә бөтерелгән дилерлардан алынган әҗәт белән түгәрәкләп, ике битлек килешү кәгазенә алыштырып өлгергән иде. Сүз дә юк, килешү кәгазе үзенең матурлыгы белән Пермь шәһәренең «Госзнак» типографиясендә эшләнгән кыйммәтле документлардан һич ким түгел. Гомер бакый яшәп һәм эшләп үзен гәҗит-журнал битләрендә күрмәгән

Мөнирә апагызның тулы исем фамилиясе шома йөзле каты кәгазьгә алтын хәрефләр белән басылган, аллы-гөлле төсләр белән бизәлгән, тугралы тышлыкка кыстырылган. Мөнирә апагыз ул килешүне, йөз мең сум акчаны хөрмәтләгән кебек итеп, кием шкафындагы шүрлеккә пөхтәләп яшереп куйды.

Бурыч түләүне ашыктырдылар. Атна-ун көн эчендә дилерларның элеккеге тенор тавышы гонорга әверелде. Ала каргадагы йөз меңгә зыян китерәсең килмәсә, Мөнирә апагызга әлеге әҗәтне кайтарыр өчен сулышыннан эфир исе килә торган бик күп танышларын барлап чыгарга туры килде. Шулай итеп, бурычны әҗәт белән, әҗәтне – үтеч, үтечне янә бурычка кереп очын очка ялгап барганда, Мөнирә апаның фатир өчен түләве җыела башлады. Инде «Итого к оплате» дигән шакмак турысына өелгән саннардан котылыр өчен, бер еллык пенсияңне тиененә кадәр чәчми-түкми илтеп бирсәң дә җитәрлек түгел иде.

Эшләр судка барып җитте. Тимер ишек артындагы приставның «ике мәртәбә кисәттек» дигәне рас икән. Ике атна эчендә әүвәл энергетиклар килеп утны өзгәннәр, икенчесендә газовиклар газдан мәхрүм иткән. Пүнәтәй рәвешендә, приставларга ияреп кергәч кенә, Мөнирә апаның керосинка өстендә корымланып беткән яшел чәйнеген күреп аһ итте Сөмбелә. Әйтәм аны соңгы көннәрдә, ялгыз күрше кич утырырга кергәч, бик ашыкмый торган иде: киноларны ахырынача карап бетерер, татар концерт-ларының башланганын көтеп алыр, табынга чакырсаң, баш тартмас, урын җәяргә тотынгач кына капылт саубуллашып чыгып китәр. Ялгыз башы газсыз, утсыз яшәп ятадыр дип кем уйлаган аны?! Чакырылмаган алты кунак җыйнаулашып килеп кергәч, бер бүлмәле фатир эче ипсезләнеп калды. Чакырылган кунаклар булса, ишек төбендә үк туфлиләрен салырлар иде, ә болар урамнан кертә-керешли үк туп-туры түргә үттеләр. Мөнирә апа, стенадагы кадагыннан ипсез егылып төшкән иске портрет кебек, диванның арка терәвенә сөялеп тәрәзә өлгесенә төбәлгән. Сөмбелә аның күз карашына эләгер өчен тәрәзә каршына килеп басты, тик барыбер игътибарын җәлеп итә алмады.

Ул арада пристав хөкем карарын кычкырып укып чыкты, Мөнирә ападан бигрәк чакырылмаган кунаклар кыланышын ишек ярыгыннан күзәтеп торган күрше-күлән колагына гыйбрәт өчен кирәк иде бу.

– ...кисәтүләргә карамастан, фатир өчен түләнмәгән бурычның уналты мең җиде йөз утыз сумга җитүен исәпкә алып, хөкем карары нигезендә, Челюскин урамындагы өлешчә шартлары булган ике катлы йортка мәҗбүри рәвештә күчерергә...

– Кадышев зираты тирәсеннәнрәк юк иде микән берәр бүлмә, иремнең каберенә якынрак итеп?

Мөнирә апа, хәвефне алдан ук сизеп, үзенең иң кадерле киемнәрен: көмеш туена ире бүләк иткән мамык шәлен, ялгыз калгач барып йөри алмам дип сатып җибәргән өйле бакча хакына алган кара тунын һәм беренче пенсия акчасыннан адарынган көрән күнле итеген киеп өлгерсә дә, ясалма теш казнасын, кимичә, кульяулыкка төреп, тунның эчке кесәсенә салган иде. Кечерәеп калган ияге болай да тар маңгайлы, нәни күзле, шома битле әби-апаның йөзенә самимилек өсти. Шуңа күрәдерме аның соңгы гозере фаҗига рәвешендә түгел, ә сабый бала авызыннан чыккан көйсезлек булып ишетелде. Сөмбелә әлеге хөкем карары өчен үзен гаепле сизде. Шөһрәт, дан, мал, дөнья нужасы куып сәхнә тирәсендә буталып йөргән арада, «базар мөнәсәбәтләре» дигән вәхшәт, тимер ишек аша үтеп, инде газиз кызының сөекле дәү әнисенә әверелгән Мөнирә апаның бусагасын атлап кергән. Һәм бу вәхшәт Сөмбеләнең фатирына килеп терәлгән. Ике арада нибарысы унике сантиметрлы бетон стена гына. Стеналарның һай тотрыксыз чагы...

– Туктагыз әле, – диде Сөмбелә, кинәт кенә хәсрәт эзәрлекләвеннән айныгандай булып, – бүтән бернинди дә чара юкмыни соң?

– Бар, ник булмасын, – диде теге пристав, – куып чыгару эшен егерме дүрт сәгатькә чигереп торып була, әгәр шул вакыт эчендә соңгы счет-фактура буенча бурычын түләп өлгерсә.

– Үзем түлим! Кызның укуына дип җыйган запасым бар. Банктан алам да сберкассага кертеп бирәм. Ярты сәгать эчендә өлгерәм. Акча саный торган урыннарда таныйлар мине.

Шунда гына эшчеләрнең берсе чын күңелдән куанып куйды:

– Баядан бирле карап торам, сез җырчы бит, әйеме?!

– Әйе. Таныгач рәхмәт инде.

– Иптәшләр-әфәнделәр! Бу бит Татарстанның халык артисты, – дип мактаулы исем дә биреп өлгерде бу Кеше, – Сөмбелә үзе!.. Сезне халаттан бер дә күргән булмагач, тиз генә танымадым. Гафу итегез! Миндә сезнең кассеталар бик күп.

Эшче шундук кесә телефонын чыгарып өенә шылтыратты.

– Алло, улым, тиз генә Сөмбеләнең яңа компашкасын алып кил әле. Көттермә. Автограф алам. Без Коләхмәтов урамындагы адреста. Ике әйттермә, яме!

– Бер дә автограф өләшерлек кәефем юк шул, кем, энем. Хәер, мин дә шылтыратып алсам була... Президентка! – диде Сөмбелә, ниһаять, батыраеп. – Гади халыкның ни хәлдә яшәгәнен ишетеп белсен.

Сүзгә тагын теге пристав кушылды:

– Без бит сезне чыгарырга дип килмәдек. Закон язылган икән, ул кемнең кем булуына карамастан үтәлергә тиеш.

– Закон язучылар өчен фатир хакын дәүләт түли шул. Телевизордан күреп торабыз, гел гади халыкны елатасыз.

– Алайга китсә, артистлар да начар яшәми. Әнә Мәскәү артистлары килде – билет бәяләрен биш йөз доллар итеп куйганнар. Хатын белән икебезгә өч мең сум түләдек.

– Ә сез татар концертларына йөрегез, өч мең сумга егерме билет алырсыз.

Сөмбелә пристав белән кискен бәхәскә керүдән тыелып калды, эшне бозудан курыкты. Хәер, җырчы күршенең тәкъдименә сөенделәр генә. Иске-москы җиһазларны исемлеккә теркәп, машинага төяп-бушатып, гаепле хуҗаны милиция белән алып чыгып, елатып, күршеләрнең каргышын җыеп китү хөкемдарларның үзләренә дә бик ошамый иде бугай. Сөмбеләнең кассадан әйләнеп кайтканын урамда гына көтеп тордылар.

Автографлар өләшеп аерылышкач, Сөмбелә, минутын да әрәм итмичә, тизрәк Мөнирә апасы янына ашыкты. Зәйтүнә анық туннарын салдырып кабаттан үз урынына элгән иде инде, зур кызларча дәү әнисе итеп кочаклаган да башын башка терәгән. Берсе еларга тотынгач, икенчесе дә түзмәгәндер инде – парлашып үксиләр. Сөмбелә кызы белән бергә Мөнирә апаны кочаклап алгач, өчәүләшеп күңел бушаттылар.

Ут белән газны яңадан тоташтырыр өчен гаризалар биреп оешмаларына ялынасы бар иде әле. Бу кичне Сөмбелә, Мөнирә апасын караңгыда утыртмас өчен, озын чыбык белән ишек өсләтеп кенә үз фатирыннан ут суздь. Күчмә розетканың өч оясына да эш табылды: телевизор кабынды, өстәл лампасы янды, өченчесе буш калмасын өчен «Тефаль» чәйнеге күтәреп керде. Әлбәттә, Сөмбелә күрше апаны алып чыгып кунак итәргә бик теләгән иде дә, ләкин Мөнирәттәй кузгалмады, диваныннан төшмәде, үз куышын шулкадәр дә нык сагынган иде ул бүген...

Сөмбелә кухняга чыккан арада кесә телефоныннан Хәмзә белән сөйләшеп алды.

– Мин риза. Барам, – диде ул, гафу үтенергә теләгәндәй, пышылдап кына. – Банкет булмагае, хет әллә шунда туй булсын. Җитәкчеләрне сагындым.

– Вәт молодчиха! Димәк, җомга кич, сәгать дүрткә! Шунда «Зәйтүнә» дигән яңа җырымны да ишетерсең.

Әлбәттә, Хәмзә артык сораулар биреп төпченеп тормады, җырчының барыбер ризалашасына алдан ук ышанган иде бугай ул. «Түрәләрнең күзенә карап әйтер сүзем бар дигәнен ишетсә, исемлектән сызып ташлар иде ул Сөмбеләне...

«Барам!» дигән ныклы карардан соң Сөмбеләнең үзалдына кинәт кәефе күтәрелеп китте. Банкетларда берәүләр ял итсә, икенчеләр эшли. Аның әлеге халәтен ай буе эш эзләп интеккән кешенең, ниһаять, вакытлыча яңа эшкә урнашып кайтуы белән чагыштырып булыр иде. Вакытлыча эшләп, олы сөенечне ваклап-ваклап, фани дөньяда вакытлыча гына җырлап яшәү кебегрәк.

Килгән бер артистны «Хантимер» ресторанының урам ягындагы ишеге төбендә үк каршы алып тордылар.

Сыйлау бизнесының сәер яклары бар... Гадәттә, ашлы-сулы ханәләрне олы юл өстенә, халык күбрәк бутала торган тыкрыкларга, үзәк урамнарга, базар тирәләренә, һичьюгында билгелерәк тукталыштан күренердәй урыннарда ача торганнар иде. Карурман эчендә супермаркет ачып куйсаң, адашкан аучылардан, качкын-зимагурлардан гайре кем килсен?! «Макдоналдс», «Эдельвейс», «Бәхетле», «Кызыл Шәрекъ» сарайлары, төнге клублар, элеккеге союздаш республикалардан бүленеп калган «кухня»лар, кафе-бистролар, йөремсәк халык ташкынына аркылы төшеп, салават күпереннән яралган нурлы рекламалары белән юмалыйлар, алгысыталар.

«Хантимер» ресторанының өч кенә каты җир өстендә. Берьюлы җитмеш машина килеп туктарлык ишегалды бар. Шәһәрнең төньяк-көнчыгыш өлешендә «Хантимер»дән соң бүтән төзелеш юк. Сыйлану ысулы белән күңел ачарга теләгән урта хәллеләр тиз генә эзләп таба алмасын дигәндәй, бу ресторанны хәрби завод белән тимер юл арасындагы ташландык далага илтеп салганнар.

Җырлаганы бар монда Сөмбеләнең, хәтта бер генә тапкыр да түгел. Кануннары кырыс... Соңгы клиент кайтып киткәнчегә кадәр артистларны җибәрми тоталар. Татарда, вакыт җитте, мәҗлес тәмам, барыгыз, таралышыгыз, димиләр – чәй генә бирәләр. Башка рестораннарда, төнге унике җитте исә, кыстый-кыстый чәй өләшергә тотыналар. Ә «Хантимер»дә кунак чәйне үзе сорап ала, төн уртасында эчәме ул аны, әллә иртәнге якта телиме – официантлар зарланмый, кисәтми, көйләп тик йөри. Килгән саен, Сөмбелә: «Бүтән бармыйм!» – дип тәүбәләп кайта. Ләкин вакыт дигән табиб белән кытлык дигән нужа, уртак телгә килеп, тәки тәүбәдән яздыра тора.

Шөкер, бүгенге банкет «Хантимер» ресторанының үзендә түгел иде. Сәгать нәкъ дүрт тулганда, баскыч төбендәге «Тойота» микроавтобусы ян ишеген шудырып ачты, җыелган артистларны төяп алып киттеләр.

Билгесезлек башланды.

«Кая алып барырлар икән?» дигән шик һәммәсен борчыса да, сораулар биреп төпченеп йөдәтүчеләр табылмады. Ләкин, адашудан курыккандай, тәрәзәгә чыраен терәп, һәркем юлны карап барды. Әгәр автобус шәһәр үзәгенә юнәлсә, димәк, банкет Кремль ашханәсендә булачак... Юк, кирегә киттеләр.

Автобус, соңга калырга ярамаганны белепме, тукталган урыннардан йолкыныт-йолкыныт ыргыла. «Божра» дип халык теленә кергән әйләнгеч юлга чыккач, Сөмбелә күңеленнән генә юрарга керешче: «Әгәр хәзер Мәскәү ягына борылсак... Зөя утравындагы резиденциягә, әгәр уңга китсәк, Идел буендагысына илтәләр булыр...» Ләкин артистлар, божра юлны кисеп, туп-туры урман эченә керделәр. «Димәк, ял базасына» дип соңгы нәтиҗәсен уйлап өлгерде. Капкага җитәргә ярты чакрымнардагы борылышта зәңгәр билле ак «Жигули» кырында үрә катып милиция капитаны честь биреп калды.

Менә монысы инде базага килергә лаек булган кунаклар өчен генә салынган махсус юл – ике урман арасына тарттырылган чем-кара күн тасма кебек шома һәм елкылдап ята, машинадан төшеп сыйпап карыйсы килә үзен. Ул шундый туры – шофер, кесә телефоныннан капка каравылчыларына алдан ук хәбәр җибәргәндә, тизлекне киметмичә генә ике кулын да рульдән алып рәхәтләнеп сөйләште. Өч тарантас янәшә сыярлык капканың тимер читән канатлары ачылгач, ГАИ инспекторлары кулындагы аклы-каралы кәрлә күсәккә охшатып ясалган шлагбаум күтәрелде.

Калибрланган юан-юан бүрәнәләре кояш баегач та алтын төсен югалтмаган, түбәсе зәңгәр черепицалар белән ябылган, чорма тәрәзәләре бизәкле, унҗиде эргәле. Әмир сараедай матурлык янына килеп туктагач, үзеңне мең ел элек тасвирланган борынгы тарихка әсир төшкәндәй хис итәсең...

...Әмирнең сый-хөрмәт бүлмәсе ни өчендер тәрәзәсез, кирәк чакта тәүлек буе янып, өстәлләр өстенә көн яктысына тиң нур чәчеп торган бәллүр шәмдәлләрнең ике бәйләме эленгән. Унҗиде эргәнең бишесе әнә шул шәмдәлләр кунак башына тимәсен өченгә күтәрелгән булса кирәк.

Киемнәрне алыштырыр өчен уенчыларны аерым бурага озаттылар. Шунда ук аларга швед өстәле әзерләнгән иде. Хәтта артист халкының үз ирегенә куеп каты эчемлекләр дә тезгәннәр, Әмир алдына салмыш баштан чыгып басарга җөрьәт итүчеләр табылырмы, янәсе. Үзләренчә сынаудыр инде бу.

Бүгенге ялханәдә бердәнбер хатын-кыз заты буларак, Сөмбеләне мансарда дип аталган чормага яшерергә теләделәр. Өскә алып менә торган әйләнмәле текә баскычка тиз генә өстәл читеннән үтеп китешле иде. Ләкин ул бик тиз үтеп китә алмады, табынга карауга күзе буылып туктап калды. Әле дә ярый Әмир үзенең яраннары белән бильярд залында шар тәгәрәтә иде, юкса егерме дүрт өлешкә бүленгән табынны фотога төшергәндәй текәлеп торган Сөмбеләне гафу итмәс иде.

Озын сәке сыман тоташ өстәлне Мари Иле осталары кулдан ясап биргәнгә охшый. Һәр тактасы бүрәнәдән яңа гына телеп алынганмы – сап-сары килеш. Аның садәлеген капламас өчендер, постау йә эскәтер япмаганнар, хәзинәдә бары ялангач такта өстенә шул килеш кенә тезелгән. Кая килеп эләккәнеңне белмәсәң, аучылар йортындагыча диярсең. Әгәр кибет өстәле булсамы, шушы кадәр нигъмәтне күтәрә алмас, билләһи, сыгылып төшәр иде.

Сөмбеләне этә-төртә өскә ашыктырдылар. Текә баскычтан менеп җиткәнче, чормага кереп киткәнче астан карап калдылар. Әле дә ярый ул ирләр күзен кыздырыр өчен күзәнәкле кара колготки белән кыска итәген кимәгән иде... Ә джинсы чалбарның балак очыннан ак носките да күренерлек түгел, тар кунычлы күн итеге җыеп тора.

Чорма түшәменә почмак саен сүрән ут эленгән. Шушы яктылыкка күз ияләнгәч кенә шәйләп алды Сөмбелә – бу җылытыла торган мансарда бихисап бүлмәләргә бүленгән, тар коридор стенасы гел ишекләрдән генә корылган кебек. Коридорның буеннан-буена ни диван, ни утыргыч, ни өстәл юк. Аптырагач ул берәм-берәм ишекләрне ачып карады – бөтенесе дә бертөрле – поездлардагы купе чаклы гына чолан. Һәммәсендә агач карават, суыткыч, урындыксыз өстәл, төнге лампа. Суыткычлары эчемлекләр, кабымлыклар белән дыңгычлап тутырылган. Ковролин идәнгә җиңелчә баскалап, ишекләрне санап чыкты – егерме дүрт – нәкъ мәҗлес залындагы өлешләр чаклы.

Чакыра калсалар, озак көттермәс өчен, Сөмбелә борылмалы баскычка якынрак бүлмәне сайлады. Ишекне япмады. Урындыклар булмагач, теләсә-теләмәсә дә караватка утырырга туры килде. Чәчәкле бүз белән пөхтәләп җәелгән урын-җир җылыга кинәнгән гәүдәне үзенә тартып тора. Өстәл лампасын яндыргач, ул суыткыч өстендә «Мең дә бер кичә» дигән экиятләр китабын күреп алды. Сәхнә туфлиләрен салмыйча гына ятып торырга ниятләде. Аңа бер уй тынгы бирми иде: «Кем бүлмәсе бу, кем мендәре? Кемне көтеп ятам соң мин?..» Һәр кунакны да исеннән таныгандай, мендәрне иснәп карады. Шөкер, тырышып үтүкләнгән шома тукымадан җиләк сабыны исе килә иде. Сөмбеләнең көмеш читлектә бәргәләнгән кенәри хәтлек кенә йөрәге азрак тынычлангандай итте.

* * *

– Нинди җыр өйрәнеп килергә кушкан идем әле мин сиңа?

– «Җанкай җанаш»ны.

– Өйгә бирелгән эшеңне эшләдеңме?

– Юк шул. Мәскәү кенәзлегеннән яңа гына кайтып төштем. Җыр өйрәнергә вакыт булмады. Телисезме, «Кәвәл авылы көе»н җырлыйм?

– Следующий кем анда?

Җырчыны алып кереп киттеләр. Келәмгә түгәрәк гәүдәле шамакай чыгып басты. Микрофонны чүкеч сабы тоткандай кыскан. Буш кулы белән кесәләрен капшап тарак эзләгәнише кыланды. Ул таракның түш кесәсендә икәнен бөтен татар иле белә юкса... Ә түгәрәк шамакай шул рәвешле уйнап вакытны суза. Тел ачкычы булырдай беренче мәзәген сайлаган арада каш чолымына тарак элеп куя.

Әмирнең кәефе шәп күренә иде. Җәйге ялга әнисе янына кайтып, тау итәгендәге чирәмлеккә сузылып яткан кунак егет кебек, ике кулын баш астына салган да кәнәфидә ял итә. Келәмгә кем арты кем чыгасын алдан ук белә идеме, шаян сүз ишетергә әзерлеге шушы идеме – ул хәтта шамакайга күтәрелеп тә карамады.

– Сүгенеп сөйли торган мәзәкләрне синнән күбрәк беләбез. Сәяси ялганнарың бармы? Халык авыз иҗаты үзенең хуҗалары турында ниләр сөйли?

– Сүгенү дигәннән, сүгенү буенча ярыш үткәргәннәр. Өченче урынны сәүдәгәрләр яулаган... Көтүчеләр икенче урынга чыккан. Ә хакимият башлыклары сүгенү буенча беренче урында, ди...

– Бала чагымда минем дә көтү көткәнем бар... Сүгенү буенча главалар түгел, көтүчеләр беренче урында булырга тиеш.

– Юк, галиҗәнабым, көтүченең сүгендерерлек хайваны йөзләп кенә...

– Ә минеке?! – Үз соравының җавабын үзе үк белгәнгә күрә Әмир мужикларча кычкырып көлеп җибәрде. Бу инде башкаларга да көләргә ярый дигән фал иде. Ниһаять, урыннарына кадакланган балбаллар кебек утырган яраннары да хихылдашты. Әмир көлгән арада берәр чәркәне түнтәреп, кабымлык чәпелдәтеп өлгерәселәре дә бар иде әле аларның...

Әмир, көлүеннән кинәт туктап, шундук боерык фигыльгә күчте:

– Сөйлә!

– Кайсысын икән? Сезнең хакта да яңа әкиятләр күбәйде. Халык бит ул шундый – дөреслекне әйтергә курыкса, әкиятләр чыгара башлый.

– Ә син курыкма! Падишаһ турындагыларны сөйлә!

– Сөләгән өчен берни дә булмасмы соң?

– Булмас. Шелтә дә булмас, янау да булмас... фатирың да булмас, мактаулы исемең дә булмас. Пайтәхеттән куылып, кәмитче сукбай булып тик йөрерсең шунда!..

Яраннарга тагын бер чәркә күтәрерлек җае килде.

– Алайса, куркырлык нием дә калмады инде. Сүлим...

– Сүлим дисең, син мишәрме әллә?

– Тегел.

– Татармыни?

– Да... Сүлим. Менә тыңлагыз...

«Син бер оңгайдан күрше мәмләкәт белән дә идарә итә аласыңмы?» – дип сораганнар Падишаһтан. «Әйе!» – дигән Падишаһ. «Ә барлык шәрык илләре белән?» – «Барлык шәрык илләре белән дә җитәкчелек итә алам...» – «Әгәр бөтен Җир шарын ышанып тапшырсалар?» – «Пожалуй, бөтен Җир шары белән идарә итә алмам, туганнарым җитмәс...» – дип көрсенгән Падишаһ...

Әмир шамакайны шундук туктатты:

– Сине ошбу келәмдә чыгыш ясаудан өч елга мәхрүм итәм.

– Өч кенә елгамы?.. Ә мин әле сезне диваныгыздан тагын биш елсыз төшмәссез дигән идем...

– Следующий!.. Берәрегез «Җанкай җанаш»ны җырлап бирәме инде бүген, юкмы?!

Җыр башланыр алдыннан гына туа торган тынлык урнашты. Ләкин бу тынлык күпме генә сузылмасын – җыр башланмады. Кайдадыр көнгерә тибенгәндәй итте. Сикергәк адымнар якынаеп чормага күтәрелде...

Сөмбеләне тумышыннан бирле шушылай куркытып, әкиятле төшләрен бүлдереп, мыскыллап уятканнары юк иде әле.

– Карале, гырлап йоклап ята! Йоклап акча эшлисең килсә, «Досуг»ка ялланырлар! Без анда көйсез кубызга биибез. Төш тизрәк!

Тавыш җепселләрен карлыктырыр өчен «сандугач йокысы» да җитә. Һәр тамаша алдыннан кыллы музыка коралларын ничек көйлисе булса – йокыдан уяну белән моңны көйгә салу өчен дә «распевка» ясап чыныктырып алырга кирәк. Сөмбеләнең моңа вакыты юк инде, ул чорма баскычыннан төшкәндә чарасыздан тамагын кыргалады, юл уңае гына чәчен төзәткәләде, күлмәген сыпыргалады.

Гармунчы келәм янында иде инде. Сөмбелә «...месез?!» дип кенә күрешкән булып, кунакларны күздән кичерде, дөресрәге, күңел түрендәге хәтер альбомына салынган рәсемнәр белән чагыштырып алды. Күргәне бар инде бу рәсемнәрне, бөтенесе дә таныш. Банкетларда гел бер үк кешеләр. Бүгенге егерме дүрт балбал мәҗлеспәрвәр җитәкчеләребезнең меңнән бере генә...

– Максат, – дип эндәште Сөмбелә киң авызлы, җәенке иякле, калын соры кашлы, керпе чәчле гармунчы егеткә, – до мажордан, яме...

Чалкан яткан Әмир кырын борылды. Ниһаять, яраткан җырын тыңлау сөенеченнән түгел, ә бүгенге малайлар чуагында хатын-кыз тавышы ишетүдән сәерсенгән сораулы карашын яраннарына күчерде.

«Син чакырдыңмы моны?» дигәндәй, ым кагып кайберләреннән аеруча җавап көтте. Әмма яраннар акланып баш какты.

Максат гармун уйнаганда җырчыларның кирәге юк.

Кечкенәдән гармунсыз, җырсыз-уенсыз үскән Әмир аны туктатырга җөрьәт итмәде. Сөмбеләне тыңларга мәҗбүр булды.

...Утырдым да атның, һай, биленә,
Биш әйләндем Казан каласын...

Кемнең авызы буш, шулар кул чапты. Әмир, сул кулына таянган килеш, һаман да әле кырын ята иде, яраткан җыры хакына ашаудан-эчүдән тыелып торды. Озакка сузылган соңгы аккордны да бүлдермәде. Гармунчы бөтен күрегенә киерелеп моңайган баянны кочагына кысып тынып калгач кына Сөмбеләгә сүз катты:

– Каян килдең әле?

– Чормадан төштем.

– Чормада йөрергә син ана мәче түгелсеңдер ич?.. – Әмир бераз кунакларга көлеп алырга ирек бирде. – Кайсы авылдан, дим?

– Балантаудан.

– Балантаудан?! Анда гел караклар гына яши, диләр...

– Ә кем урламый инде хәзер...

«Менә без, мәсәлән!» – дип әйтергә теләгәндәй, Әмир кырын яткан җиреннән тора башлады.

Җыр бетүгә баш иеп, артистлар янына кереп китәсе генә калган иде кана, ә Сөмбелә, җүләр, килгән-килгән, инде тагын берәрне җырлатырлар дипме, саубуллашырга ашыкмады. Инде һич кирәкмәгән җирдән Әмир белән икәүдән-икәү сөйләшүгә күчте. Хуҗа кеше кунакларның кәефен күтәрердәй мәзәк хәл чыгармакчы иде. Ләкин халыктан бөртекләп җыелган казна хисабына көрәйгән түрәләр каршында салымын түли алмаган ялчы хәлендә басып торудан хурландымы, әллә фатирына приставлар килеп төшкән күршесе Мөнирә карчык өчен үчектеме, бүгенге эстрада сәхнәсендә хөкем сөргән хаос өчен әлеге «балбаллар»ны гаепле санадымы – рәнҗүле сүзләре күперде Сөмбеләнең, кара-каршы сөйләшүе Әмиргә каршы дәшүгә күчте. Һәм татлы әкият булып башланган төш әкренләп кырыс чынбарлыкка әверелә барды...

– Кемнең күпме урлаганын эшеннән алынгач кына саныйлар.

– Менә бу әфәнделәрне беләсезме? – дип, Әмир кунаклар тарафына кулын изәде.

– Белмичә. Һәммәсенең диярлек визит ярлыклары бар миндә, шушылай төрле банкетларда күрешкәләп торабыз. Мәҗлес азагында әфәнделәр юмартлана, иганә таулары вәгъдә итеп, телефон номерларын өләшә башлый. Иртәгесен исләренә төшереп шылтыратып карыйсың... ә анда һаман да шул секретарша тавышы: «Ул юк, киңәшмәдә... юлда... чит илдә... сарайда...» Бүген иртән генә берсенә шылтыраткан идем әле: «Федераль округ председателе чакыртып алды, бер атнасыз кайтмас!» – диделәр. – Һәм Сөмбелә җаваплылыгы бик үк чикләнмәгән «Ташлы» фирмасы гендиректорына шундый киная белән карап алды ки – тегесе, урындык аркасына сеңеп, юка гәүдәсен холдинг президенты күләгәсенә яшерде.

– Ә ул әфәндене вертолет белән кызлар куып йөри димәделәрме?

Кунаклар дәррәү күтәрелеп көлешкәч, Сөмбелә җиңел сулап куйды. Ходайның рәхмәте белән аңа: «Кызый, җитәр, тукта, хуҗаларның кушканын кыл, кылганын кылма!» – дигән гакыл килде.

«Вәт гөнаһ шомлыгы, җырчы дигән кодрәтеңә масаеп, Әмир белән әйтештең түгелме? Әрләшкәндә Ходай бәндәсе үзеннән өстен көчләрдән вакытлыча гына булса да азатлык яулап ала, уйлаганын әйтеп, яшергәнен күрсәтеп өлгерә. Әле дә ярый әйткәләшүләр озакка сузылмый. Көчсезләрне исән-имин саклар өчен Тәңрең күп әрләшерлек куәт бирми».

– Чакыруыгыз өчен рәхмәт. Кәефегезне күтәрә алмаган булсам, гафу итәрсез.

– Артист җырласын гына ул. Сөйләүчеләр җитәрлек! – диде Әмир һәм кабат диванына чалкан ятты. Бу аның җырчы белән саубуллашуы иде.

Сөмбеләдән соң келәмгә Хәмзәне чыгардылар. Башка шамакайлардан аермалы буларак ул сөйли-сөйли җырлый, җырлый-җырлый көлдерә белә иде. Аның хәерчеләр өчен язылган «Колбаса» дигән җыры кунакларга бигрәк тә ошады, чөнки табынга бер генә телем колбаса да куелмаган иде.

– Синең җүнлерәк җырларың бармы? – Әмир инде торып өстәл читенәрәк якынайган да, кабыклы бәрәңгене ярып, тоз урынына кызыл уылдык ягып маташа иде.

– Ник булмасын?! – диде Хәмзә, бер күзен японнарча хәйләкәр кысып, икенче күзен яһүдләрчә акайтып. – Әйтик, Зөлфиянең «Миләшкәем» җыры, Әлфис мәрхүм җырлап калдырган «Кил син, кил син, үзең кил», Равил башкара торган «Тымытыгым»... Күп инде алар.

– Да ну! Азаматка да берәр яңа җыр язып бирәсеңме? Болары туйдырды инде.

– Толк никакой. Язганнарына да түләгәннәре юк әле.

– Сиңа күпме тиеш алар?
– Кем санаган инде аны кинәт кенә. «Шаян-шоу»ны авылдан авылга йөртер өчен бер микроавтобус ярап куяр иде...
Әмир Хәмзәгә кул бирде:
– Иртәгә минем управляющий янына килерсең.
Шул мизгелдә егерме дүрт яран арасыннан Азамат килеп чыкты. Ул һәрвакыт иң кирәкле чакта, кирәкле җирдә, кирәкле кешеләр янында була белә.
– Котлыйм, Хәмзә! Мондый зур презент һәркемгә дә тәтеми. Безнең Әмир сүзендә тора белә! Ягымлы сүз – җан азыгы. Безнең Әмир яхшылыкны бәяли белә!
Сәхнәдәш егетнең бу сүзләре бил бөгәргә яратмаганнар өчен җәза рәвешендә яңгырады, чөнки ул Әмир авызыннан тартып алгандай әйтелде.
Дөрес сүз – туры сүз. Турысын әйткән – дусларын югалткан. Туры сүз – утлы корал. Утлы коралны теләсә кем йөртә алмый.
Җитәкче кеше никадәр биектәрәк утырса – туры сүздән шулкадәр тизрәк яралана.
Ялынычлы кеше генә туры сүзгә түзә ала. Сөмбелә ялынычлы кеше. Бүген дә аңа түзгән өчен гонорар түләделәр.
«Мальчишник» ике пәрдәле, җиде күренешле спектакль кебек төгәл ике сәгать барды. Артистлар өйгә киеп кайта торган киемнәрен эзләгән арада, кунаклар утырган урыннарыннан юкка чыккан иде инде.
– Мунчага киттеләр... – дип пышылдады кемдер.
Сөмбелә егерме дүрт кеше сыярлык ләүкәне күз алдына китереп карады: театр сәхнәсе чаклы бардыр ул...
Артистларга капкадагы шлагбаум янына чыгып басарга куштылар. Автобус шунда килеп аласы иде. Мәҗлестә буыны йомшарган тәнне суык куырып алды. Ярты сәгатьләп көткәч, туры сүзен пышылдап кына әйтә торган теге тавыш тагын юатты:
– Олег булса бик төгәл йөри иде. Юраның сменасыдыр бүген – он цехында аның бер кызы бар, шуны утыртып килгәли, урман юлында камыр изәләрдер...
– Ну, җегетләр, иртәгә килгән булсагыз, өр-яңа «Газель» белән генә алып кайта идем үзегезне.
Суыкта авыз үзеннән-үзе ыржаеп торса да, Хәмзәнең бу сүзеннән беркем көлмәде, аның машина отуы бөтенесенең дә кәефен кырган иде.
Ап-ак урманны телеп, яңа каештай тартылган чем-кара асфальт өстенә фара нурлары килеп кергәч тә сөенүләре заяга булды – туксан тугызлы «Жигули»га дүрт кыз төялгән иде. Аларны ерактан ук күреп, шлагбаум үзеннән-үзе күтәрелде. Интим мөнәсәбәтнең төрле юнәлешләре турында артык хәбәрдар булгангамы, Сөмбелә «мальчишник» дигән күңел ачулардан шикләнә дә, өнәми дә. Шөкер, дүрт кыз килде, араларында дүрт егет бар икән бит, дип, бик сөенде әле ул.
Алай да теге пышылдау остасы караңгылыктан файдаланып төрттереп куйды:
– Сөмбелә, әллә син дә боларга иярәсеңме?
Тизрәк җавап кайтарырга кирәк иде. Әгәр «иярәсеңме» дигән сорауны фәлсәфи фигыльләргә таратып карасаң, тузынып китеп гауга чыгарырлык нигез бар. «Әллә яратмаганнар дисеңме? Мин гомер буе бер генә кешенеке булдым. Фатир алыр өчен дә җәелеп ятмадым. Филармониягә дә гинекологлар аркылы урнашмадым. Күпме кеше ялынып йөрде минем арттан, ышанмасагыз, әнә визит карточкаларын килеп санарсыз – туфли тартмасы шыгрым тулы. Микрофонны сүндереп җырлый торган бүгенге йолдызларыгыз кебек имтиханнарны караватъ өстендә тапшырмадым...» Әйтмәде, шөкер, уйлап кына өлгерде. Әйтә калса, зурга китәсе, әшәке сүзләргә батасы, ирләр гайбәтенә быкырдап бетәсе иде. Уйлар арасында туган паузаны телсез корал итте Сөмбелә. Ашыгыбрак ирештергәнен аңлапмы, пышылдаучының тыны чыкмады.
– Машиналарында бүтән урын юк ич! – Менә шушы тапкыр җавап Сөмбеләне саклап калды.
Кышкы төннең кыл бер уртасында галибанә тынлык хөкем сөрә. Шау-шулары, ыгы-зыгылары, мәшәкатьләре белән теңкәгә тигән иске көн, ниһаять, үтеп киткән. Хәл итеп өлгермәгән эшләр өчен борчылдың ни, борчылмадың ни, барыбер шул килеш калган инде. Яңа тәүлек туып кына килә, бар хәрәкәт тирән йокыда, хәерсезлек яктыга чыкмаган әле. Ишегалдында өшеткеч бушлык, подъезд ишекләре ял итә, урамнар хәл ала.
Сөмбелә, артык төнгә калганчы дип, кайтышлый ук күршесе янына кереп чыкты. Мөнирә әби «Гаилә» каналыннан иске заман киноларын карап утыра. Кыстыбый пешергән – тешкә йомшаклыктан түгел, кәефе шәп булганда гына өеп куя ул аны.
Әнисе ауга чыккан песи кебек кенә йөрергә өйрәнде, ишек ачып кергәнен Зәйтүнәсе сизмәде. Кучтәнәчкә тигән кыстыбыен ашап бетермәгән килеш урын өстенә ауган, көне буе имтиханга әзерләнеп нык алҗыгандыр, күрәсең. Кызның сулыш алганы әни кеше сизәрлек кенә.
Урамда да, күршедә дә, өйдә дә тыныч. Сөмбеләнең генә күңеле тыныч түгел. «Юлбарыс» холдингының чираттагы бәйрәменә ник чакырдылар соң аны? Бактың исә, ирләр мәҗлескә кунак

булып ялгыз гына килгән, артистлар да гел ирләр генә, пешекчеләр, хәтта сыйлаучылар да ачык күрән алъяпкыч япкан кысык күзле егетләр иде. Бер җыр өчен кичке корабка хатын-кыз алалар диме?! «Җанкай җанаш»ны җырларга Жора юк икән, Азамат үзе шунда иде ич!.. Ике тәрәзәле өйдә үткән яшь гомер маҗара көтә дә тора. Берәр хәсисен рәнҗеттеме, әллә, киресенчә, өмет бирдеме? Байлар уенымы бу, әллә мылтык көпшәсе аша күзәтүләреме? Берәр эзләүчене ялласаң, эшләгәнең түләргә җитмәс...

Сөмбелә кием шкафы өстендәге шүрлектән рәсемле катыргыдан ясалган тартма алып килде. Утыз җиденче размерлы туфлидән бушаган кап визит карточкалары белән шыгрым тулы – егерменче гасыр азагында башланган базар ислахының соңгы унбиш елы сыйган. Актара башлагач, колак төбендә авазлар яңара: мәйдан ораторлары, сайлау көрәшчеләре, банкет сандугачлары, түрәләр вәгазе берсен-берсе бүлдереп оран сала кебек. Җәмгыять үсешенең нигезендә «бу урында кичә син идең, бүген мин; кичә – сезнекеләр безне, бүген – безнекеләр сезне» дигән сүгенү эпитетлары ята икән. Трамвай-троллейбус тукталышларындагы киоскларның директорлары, кунакханә номерын офис иткән генераль директорлар, хәер-хәйрия акчасына төзелгән фондлар, һавалы компанияләрнең президентлары күбәйгәннән-күбәя бара. Тузга язмаган оешма исемнәрен ташка бастырып визит карточкалары чыгарулар эшләүне түгел, фәкать акча эшләүне максат итеп куйган текә җитәкчеләрнең мин-минлек ярышына, дөньяны яулау хөрриятенә әверелде.

Эстрада ялтыравык утрау булып кыл уртада калды. «Үзгәртеп корунның» бөтен юллары шушы утрау аша үтте. Океан артыннан килеп кергән бер генә яңалык, бер генә термин да сәхнә базарын әйләнеп узмады. Сайлаучыларны артистлар тирәсенә җыйдылар, олылау чараларына җырчы чакырдылар, яңа байларның варислары өйләнешкәндә, туйлар концертка әверелде, һәр яңа вакыйганың рекламасын күренекле, талантлы шәхесләрдән әйттерделәр, сәүдә мәйданнарына җыелма сәхнәләр кордылар, күп кенә холдингларда, АОларда, министрлыкларда тамаша оештыручы методистлар, баянчылар штаты булдырылды. Мәдәният министрлыгы, филармония диктатыннан бәйсезлек яулаган артист үзе дә сизмәстән яклаучысыз калды, ул хәзер чакырган җиргә баручы, түләүчегә күңел ачучы уен коралына әверелде. Нәтиҗәдә җыр белән бию бергә буталды, кендекләр ачылды, нәфис сүзне очсыз мәзәк алыштырды, түләүле фабрикалар йолдыз чүки башлады, сәнгать тәненә сусаган яңа байлар өчен төнге клублар үрчеде.

Җыр яңгырасын өчен чикләр киңәйде. Җырчы кызлар, чит ил байларына кияүгә чыгып, хәзер Казан сәхнәсенә кунакка кайта ала. Алмания, Австралия, хәтта Англиягә барып сабан туйлары үткәреп кайту берни тормый. Татар артистлары Пенза, Төмән, Самара, Башкортстанга барып мәмләкәт башлыкларын сайлауда катнаша алдылар. Әүвәл алар альтернатив кандидат өчен көрәштеләр, ул үтмәгәч икенче турга чыгып, тамашачыларны элеккеге хуҗага тавыш бирергә үгетләделәр...

Сөмбелә катыргы тартманы бушатып берәмтекләп яңадан тутыра башлады. Теге егерме дүрт әфәнденең визиткасын каршысына тезеп күңеленнән генә сорау алырга иде исәбе. Берничә исемгә килеп төртелгәч ниятеннән язды, искә төшереп алырдай шәхесләр болай да шактый иде әле монда. Бәлки, сары табышмакның җавабы табылыр дип җентекләбрәк тукталды. Газ плитәсенә чәй куеп җибәрде. Йокы качкан иде инде... Чәй кайнаган арада кухнядагы биек суыткыч өстеннән амбар кенәгәсен үрелеп алды. Сөмбелә бу калын дәфтәрне үзенчә шаяртып «вахта журналы» дип атый. Ерак гастрольләрдән алҗып кайткач, беркавым хәл җыя да: «Кызым, китер әле теге вахта журналын, тәэсирләре суынганчы язып куйыйм», – дип сорап ала. Кайданиләр җырлаган, кемнәр катнашкан, халык яратып кул чапканмы, нинди маҗаралар булган, кемнәр, нинди спонсорлар белән танышкан – соңгы егерме еллык сәхнә тормышы кәгазьгә теркәлеп бара. Хан мәҗлесе үткәрелгән көнне дә бөртекләп язып куйды. Аннан, чәй эчә-эчә, кайбер визиткалар бүләк ителгән көннәрне вахта журналыннан эзләде. «Мине тап, мине» дигәндәй исем өстенә исем өелде, журнал битләре бөгәрләнде, көннәр-еллар әле алга, әле артка күчте. Язылганын «әһ!» дигәнче укып чыгарлык язмаларга көннәр буена сузылган, гомер буе онытылмаган вакыйгалар сыйган иде.

1993 елның 2 сентябре...

Казан елга портының беренче причалына өч палубалы «Леонид Соболев» теплоходы килеп туктады. Пассажирларның кемлеге алдан ук мәгълүм булса да, кая барасыны беркем белми иде әле. Шәһәр башкарма комитетының мәдәният идарәсе тутырган исемлеккә Марат Гомәрнең исемен үгетләп диярлек яздырды Сөмбелә. Хәниянең баянчысы бар, Зөһрәнең ире баян алып килә, сиңа махсус гармунчы чакыруның бөтенләй кирәге юк, «Уйна, гармун» фестивале түгел – җитәкчеләрнең культуралы ялын оештыру, артистлар саны чикләнгән, дип, бик нык каршы төшкәннәр иде. Сөмбелә һаман үҗәтләнде: «Кеше музыкантлары белән теплоходта репетиция ясап йөрергә мин үзешчән түгел. Марат Гомәр бөтен репертуарымны белә, кайсы кунак нинди җыр сораса да курыкмыйм».

Барыбер ризалашмадылар.

– Алайса, мине дә исемлектән сызыгыз! – диде Сөмбелә, кул селтәмичә генә.

– Тукта, тукта, кызма әле син, Сөмбелә! Ярар соң, алып кил гармунчыңны! – дип, шул минутта ук кире чигенде идарә башлыгы.

Сәер, ул бит хәзер: «Син үзеңне Җир шарының кендеге дип белдеңме әллә?!» – дияргә тиеш иде. Табеевлар заманыннан калган әлеге канатлы шелтәнең телдән телгә күчеп киң таралган чагы иде әле бу. Бүлмәсеннән куып чыгарса да бер сүз әйтә алмыйсың. Горисполком шәһәрдә фатир өләшүче бердәнбер Мәккә. Чакырсалармы – исән чакта престижный фатирга чиратта калган идем дип, билләһи, теге дөньядагы җырчыларың әйләнеп кайтыр... Шәһәр башлыгы имзасыннан башка бер генә кешегә, бер генә оешмага да фатир ордеры бирелми. Юк, идарә башлыгы җикеренмәде, тавышын күтәрү түгел, чыраен да җыермады хәтта, киресенчә, елмаеп озатып калды. Чакыру кагыйдәләренең ниндие юк... Сөмбеләнең теплоходка керүе мәҗбүри булгач, кем соратканын сабыр гына көтәсе кала.

«Кем?» дигәне причалга килүгә үк беленде. «Мөмкинме?» дип, Сөмбелә кулындагы сәфәр сумкасын күтәрешергә алынучы кеше Казанга иң ерак районның хакимият башлыгы иде! Мәктәп баласы булса – ул да сыйныфташ кызыйның букчасын тиктомалдан күтәреп йөрмәс... Ә монда күкрәгенә депутат билгесе таккан, никахка килгән кияү егетедәй чем-кара костюм-чалбар кигән, җете аклыгыннан күз камашырлык күлмәк якасына ут янып торган кызыл галстук элгән алпамшадай әфәнде ниндидер бер Балантау авылында туып үскән колхозчы кызына йөк ташучы сыман иярсен әле!.. Сөмбеләнең җырларына гашыйк микәнни? Алай дисәң, инде сер түгел, җырларыңа гашыйк дип башланган уенның азагы әлеге дә баягы шул – җырчының үзенә гыйшык аңлату белән бетә. Сөмбелә бик күптән мәктәп баласы түгел инде, өйләнергә йөргән егет белән күңел ачарга килгән ирләр холкын гына бутамас.

Басма кичкәндә бер түрәнең шоферга җиткергән әмере колакка чалынды:

– Кичке алтыга как штык килеп баскан бул!

Ун сәгатькә сузылачак сәфәрнең юл озынлыгын күз алдына китереп карады Сөмбелә... Ялыктырасын алдан белә – туйлар да унышар сәгать бармый хәзер.

Төгәл әйтелгән вакытта трапны җыеп алдылар, теплоходның тышавын ычкындырдылар. Мәҗлес Идел уртасына җиткәнче, ярдагы «Волга»лар таралышмыйча торды. Каяндыр капитан фуражкасы табып алган шәһәр башлыгы соңлап булса да команда бирде:

– Отдать швартовы!

Су өстендәге иртәнге җилдә озак бөкшәергә туры килмәде, артистларны, чамасыз ашыктырып, каюталарга урнаштырдылар. Урнашу дип – кеше саен берәр аерым бүлмә, ачкычлары ишектә. Теге Кем, Сөмбеләнең кайсы каютага урнашканын белергә теләп, озатып куймакчы да иде, кают-компаниядән шәһәр башлыгының карлыккан тембрлы баритон тавышы ишетелде:

– Җитәкче составны срочно биш минутлык киңәшмәгә!

Теге Кемнең кают-компаниягә кереп югалуы булды, Сөмбелә, эз югалтыр өчен, иң түрдәге бүлмәгә шылды. Марат Гомәрне, янәшәгә урнаштырып, нигез күршесе итте. Сигез йөз кешегә исәпләнгән ак корабта качышлы уйнавы кыен түгел... Юка пластик стеналар калын тукыма белән тышланган, күршетирәнең сөйләшкәне ишетелмәсә дә, кирәк чакта шакып гармунчыны чакырырга була. Монысы әлеге шартларда бик мөһим.

Шәһәр башлыгы фуражкасын салмаган, артистлар ягына рупор аша гына кычкырды:

– Бөтенегез дә кают-компаниягә!

Артистлар «тревога» белән уятылган матрослар кебек кабаландылар, коридорга чыккач кына чәчләр төзәтелде, төймәләр-путалар каптырылды, туфли йөзләре сөртелде.

Сөмбелә Марат Гомәр белән янәшә утырмакчы иде, өлгермәде, теге Кем килеп, аны кулыннан тотып, үз өстәленә алып китте.

Алдан игълан ителгән биш минутлык киңәшмәдә өчәр йөз-дүртәр йөз чакрымнан иртәнге сигезгә килеп өлгергән район хакимияте башлыклары хөрмәтенә берәр бокал ром бушатылган иде инде. Шуңа күрәдер шәһәр башлыгы оештырган уен кагыйдәсенә тиз күнделәр.

– «Леонид Соболев» Җир тирәли сәяхәткә чыкты. Корабльнең штурвалы минем кулда. Мин кем булам инде?

– Адмирал! – дип кычкырды кырык дүрт район берьюлы.

Шәһәр башлыгы балдаклы бармагы белән өстәлгә өч кат төртеп алды, шымчы юкмы дигәндәй якягына каранды.

– Авызыгыздан җил алсын. Үзе ишетмәсен. Мин капитан гына. Ә сез...

– Без юнгалар!

– Юк, сез мичманнар. Ә менә тегеләр? – диде ул, бер иллюминатор төбендәге ике өстәлгә сыенган артистларга таба имән бармагын төбәп.

– Пиратлар!

– Юк. Алар чегәннәр! – Артистлар ягыннан ризасызлык урынына алкышлар яңгырагач, капитан дәвам итте: – Мин кубрикка кереп ял иткән араларда капитан мостигында үз урыныма өлкән мичманны калдырам, – диде ул, Сөмбелә кырындагы теге Кемнең иңбашына учын куеп. Капитанның уч төбе адмирал погоны чаклы иде...

Сөмбелә вазгыятькә төшенә башлады кебек. Өлкән мичман капитанның ышанычлы кешесе, таянычларының берсе икән ләбаса... Димәк, теплоходка кемне һәм ни өчен чакырасын алдан ук хәл итә алган.

Өлкән мичман – җөмһүрият чигенә терәлеп торган районнарның берсендә мактаулы хуҗа. Коммунизм төзегән чорларда ул КПСС райкомының беренче секретаре иде, «суллар» «уңга» борылып баскач, шул ук районда хакимият башлыгы булып калды. Бүгенге татар түрәсенә хас бөтен сыйфатлар да бар үзендә, ул физик яктан көчле, тик көйсез; авторитар җитәкче, үзе ярдәмчел; рекордлар куярга ярата, әмма кызлар алдында каушый; алыптай гәүдәле, мәгәр йомшак күңелле; законны әйбәт белә, шулай да кирелеге белән дуамал... Сүз ирегенә ышанып, район халкы аның өстеннән бик күп шикаять язып өлгерә. Инде «калага күчереп үстерәләр икән» дигән хәбәр йөри, һәрхәлдә, Сөмбелә шулайрак дип ишетте. Кадрлар миграциясе, сайлауларда җиңәсе кандидатлар, җитәкчеләр шәҗәрәсе кебек четерекле юрамышларның төгәлрәк җавабын артист халкы алданрак белә. Чөнки һәр сәяси яңалык банкетларда туа...

Күчмә утраулар, якорьлы рестораннар, йөзә торган мунчалар, оча торган киңәшмә заллары чоры бу. Бүгенге сәяхәт тә гади бер күңел ачу гына булып калмас.

Капитан кечкенәдән диңгезләр гизәргә хыялланган иде. Хәрби лайнерларда радист булып хезмәт итү теләге белән ул элемтә техникумын да тәмамлады. Ләкин билгеле бер сәбәпләр аркасында армиягә алмадылар. Аның хыялы ун елдан барыбер гамәлгә ашачак, тәвәккәллеге өчен бу капитанны Япон диңгезе ярларына контр-адмирал итеп җибәрәчәкләр... Хәер, бу турыда әлегә беркем дә, хәтта адмиралыбыз үзе дә белми.

– Господа офицеры! Август ае коры килде. Урып-җыю гөрләп бара. Мин сезне бүген махсус җыйдым. Кырларга чыгып, игенчеләргә комачаулап йөрмәсеннәр дидем. Колхозчылар бер генә көн булса да тынычлап эшләсеннәр дидем... Сез дә тынычлап ял итегез, хатыннарыгыз да, кредиторларыгыз да эзләп табалмасын дидем.

Капитан үзенең яңа вазифасын уен кагыйдәсенә туры китереп дәвам итте:

– Лоцман! Лоцман!.. Колак бае...

Штурвал күперчегеннән җавап килде:

– Тыңлыйм!

– Курс Nord-ost, скорость пять узлов в час. Малый вперед.

– Есть, малый вперед!

Идел өстендә штиль хөкем сөрә. Төньяк офыкта күпергән болытлар, вак-вак күбекләргә таркалып, җил чыгармыйча гына теплоход өстеннән үтеп китә. Көнчыгыш иллюминаторлардан кергән кояш баганасы тигез янмаган лампа кебек, янып-сүрелеп, янып-сүрелеп ала.

Кок өстәлдән өстәлгә күчеп кемгә нинди шулпа кирәклеген белеште.

Бу кок ризыкларны бүлеп өләшүче генәдер дип уйлап куйды Сөмбелә. Кухняны термослар белән китергәннәрдер. Шушында ук пешкән ризык булса, симез калҗа, шулпалы өчпочмак, итле бәлеш исе борыннарны кытыклап, нәфесне котыртып торыр иде. Ә кают-компаниядә кипшегән яңа буяу исе эленеп тора. Юкса өстәлләр дәүләт белән тулы, берсе-бер буш түгел.

Тостлар әйтүне, мөгаен, беренче булып амазонкалар уйлап чыгаргандыр. Сугышчы хатын-кызлар гел яуда, гел походта. Ирләре белән бик-бик сирәк, бары тик балага узу өчен генә күрешкәннәр. Малай туса – этиләренә калдырып киткәннәр, кыз баланы үзләре белән алып сугыш кырында тәрбияләгәннәр. Җиңү яулаган көннәрдә, кырда учаклар ягып, күңел ачулар оештырганнар. Бузалы касәләр күтәргәндә амазонкалар бер-берсен мактап купшы сүзләр әйткәннәр... Дәверләр алышынып, яуга чыгу хатын-кыз иңеннән төшкәч, купшы сүзләрне ир сугышчылар әйтергә тиеш булган... Озын-озак, күп сүзле, тапкыр, әмма мактауга корылган комплиментар тостлар хатын-кыз табигатеннән килә түгелме?!

Беренче тостны капитан әйтергә тиеш иде...

– Дошманның су асты көймәсен эзләп табар өчен диңгезне йөз градуска җиткәнче кайнатырга кирәк, ул һичшиксез өскә калкып чыгачак, дигән бер яһүд. Диңгез тиклем диңгезне ничек кайнатып була соң, дип сораганнар моннан... Мин киңәшемне бирдем, ә тормышка ашыра аласызмы, юкмы – анысы сезнең эш, дигән яһүд... Мин бокалларны мөлдерәмә тутырырга киңәш итәм... Ә эчәбезме, юкмы – анысы безнең эш!

– Яһүдә хатыннарыбыз өчен күтәрик!

– Ике башлы бөркет Ак барсны чукымасын!

– Господа офицеры! Сәясәткә кагылмагыз!

– Боцман! Чегәннәр өстәлендә ром бетте!

Марат Гомәрне тыеп торучы юк, тагын исерер инде. Гармунын караватка егылган килеш тә уйный ала ул, анысы өчен борчылмый Сөмбелә. Каюта стенасын шакылдатуга йөгереп керердәй аек булуы кирәк иде...

Ниһаять, капитан «Смирно!» командасы ишеткәндәй үрә катты.

– Господа мичманнар, хәзер Венера җырлый! Венера, әйдә тегене...

Кают-компания тып-тын калды. Талгын музыкага теплоход тирәли нидер эзләнеп йөргән акчарлакларның зарланулы чыелдаулары кушылды.

...Очмыйча син түзеп кара,
Иңнәреңдә канат барда!..
Кый-гак! Кый-гак! Кый-гак!

Җыр беткәнне дә көтмичә башланган көчле алкышлар җиде баллга җиткән шторм дулавын хәтерләтте.

Алкышларны капитан да бик ярата. Мәртәбәсенә күрә аны яңа сәүдә үзәкләре ачканда дисеңме, яңа өйләр саласы буш нигезгә таш ыргытканда, уңыш бәйрәмнәре булып килгән ярминкәләрне каршылаганда, тәбрикләү чараларында, Мәскәү юлыннан кунаклар каршылаганда, башкарма комитет утырышларында чыгыш ясаганда дисеңме... Кыскасы, аны гел кул чабып каршы алалар, алкышлар белән озаталар. Ул микрофонга гашыйк, чөнки һәр вакыйганың халык җыела торган өлешендә аны йә стационар, йә күчмә сәхнә корып каршы алалар, тавышын меңәр ваттлы динамиклар белән көчәйтеп тараталар. Ә инде һәр кичне «Эфир» каналының соңгы хәбәрләреннән күренгәндә, аның каршысына җидешәр микрофон куялар иде.

Капитан, Венерага багышланган алкышларның тынганын да көтмичә, микрофонны йолкып алды, урынбасарын чакырган ише генә җиңеллек белән, имән бармагын изәп, гармунчыны үзенә дәште һәм җырлап та җибәрде. Ни җырлыйсы алдан әйтелмәгәч, Марат Гомәр гармун киеренкелеген тыеп торып беренче иҗекнең яңгыраганын көтте.

Әйтмә син авыр сүз, әйтмә син,
Йөрәк бит болай да яралы...

Капитанның, чынлап та, мәҗлесләрдә җырларлык кына тавышы бар иде. Банкет саен диярлек җырлый торгач, ул вокал буенча ярыйсы шомарды. Мелизмнар белән бизәмичә, борылышларын турыдан гына кистереп җырласа да, бер үк куплетларны өчәр тапкыр кабатласа да, аңа барыбер артистлар көнләшерлек итеп кул чабалар, әле «Афәрин!» дип тә үсендерәләр иде.

Рәттән алты җыр башкарганнан соң, җиденчесенә ул «Әйтмә син авыр сүз»не тагын тулаем кабатлады. Бер балалы хатыны белән тулай торакта яшәп яткан тавыш операторы капитанның репертуарын бүлдереп бию көе кушарга курыкты, ә мичманнарның погоннары «бәләкәйрәк».

– Могҗиза җидәү генә була! – диде капитан, үз вакыты җиткәч. – Тыңлагыз, бер тост әйтәм... Кичә орбиталь станциянең аэронавтлары ачык космоска өч тапкыр чыктылар... Сәбәбе шул – туалетлары эшләмәгән, ди... Әйдәгез, берәрне күтәрик тә ачык космоска чыгып керик. Ярты сәгатьлек тәнәфес игълан итәм!

Җиде җырдан соң җор сүзгә сусаган команданың рәхәтләнеп көлүе капитанның күңелен күтәрде.

Аһ, бу озын тәнәфесләр! Аһ, хатыннарын ияртергә яратмаган агайларның малайларча тугарылуы...

Алданрак торып киткәннәр туалет ишегенә чиратка баскач, соңрак килгәннәрнең көтәрлек чыдамы калмаган иде. Беренче ярусның чыбык читәне аркылы Идел өстенә чәпердәтү ярышы башланды. Һәм һәр мичман, башкалары алдында үзенең егәре, әүхәте, ирлеге белән мактанырга теләгәндәй, ярышып чәптерергә тырышты: кем ераккарак җиткерә – шул сәламәтрәк, аның простатасы да юк, гайрәте дә ташып тора. Әгәр ярышка катнашырлыгың юк икән – димәк, син тумас борын картайган мескен бер җан иясе.

Өлкән мичманның да ярышка катнашырга исәбе бар иде, чыбык читәнгә килеп сөялгәч як-ягына каранып тыелып торды, ник дигәндә, уен белән мавыгырсың да, әгәр шул вакыт Сөмбелә килеп чыкса?! Бүгенге ситуацияне оста файдаланыр өчен җырчы алдында горур, җитди һәм дә ихтирамлырак булып күренергә теләде ул.

– Нәрсә, иптәш өлкән мичман, давлениең юкмы? – дип үртәштерделәр аны.

– Юан торбадан су әкрен ага! – дип, теленә килгән беренче җавапны аклану итеп, бу тирәдән тизрәк китеп барды ул.

Палуба әйләнәсе буйлап оештырылган малайлар бәйгесе шултиклем озак дәвам итте ки, хәтта ватерлиния Идел өслегеннән бер сөям өскәрәк күтәрелгәндәй булды.

Сөмбелә, чынлап та, түгәрәк тәрәзәгә маңгаен терәп, палубадагы тамашаны күзәтте. Мичманнарның аңа җилкә белән басып торуы бу күренешкә әллә ни оятсызлык китермәде. Өлкән мичманның уенга бирелмичә кирәк чакта әдәпле булып кала белүе ошады әле аңа. Якындагы кәмиттән бик тиз ялыгып, Сөмбелә мавыктыргыч манзараны ерактанрак эзләргә теләде. Һәм ни күрсен – елга порты әле һаман да якында гына.

– Ике сәгатьтән бирле ник бер урында таптанабыз соң әле без? – дип сагая калды Сөмбелә.

Җавап эзләп һавага чыгарга ашыкканда, аның юлына аркылы төшкән беренче кеше өлкән мичман булды.

– Сөмбелә, синең белән сөйләшәсе бар иде!

– Ике сәгать буе бергә утырып, сүз башларга җаен тапмадыгызмы?
– Үзен тыңламыйча, өстәл артында юк-бар сөйләшеп утырганнарны капитан бик өнәми.
Өлкән мичман, сул канатын җәеп, ишегә ярым ачык бер каютага таба кулы белән юл күрсәткән иде, Сөмбелә шундук кире какты.
– Юк-бар сөйләшеп утырыр өчен өске палуба шәп. Аннан соң, минем бу трюмда күңелем болгана.
– Диңгез авыруымы әллә синдә?
– Диңгез авыруы диңгез буена еш йөргән җитәкчеләрдә генә була торгандыр ул. Болай диагнозлар куярлык чирләрем юк. Таң тишегеннән башланган шау-шулы мәҗлес кенә башыма капты.
– Профессиональ артист өчен иртә ни дә кич ни? Барыбер концерт инде.
– Кызыл туй белән сабантуйлар да иртәнге уннан башлана. Ә без бүген сигездән үк... Карагыз әле, сез маршрутны беләсезме? Ник һаман Казаннан чыгып китә алмыйбыз? Комга терәлдекме? Фарватер буш түгелме?
– Тс-с-с!
Өлкән мичман ике бармагы белән Сөмбеләнең авызын капламакчы иде. Ләкин кызый чирканып читкә борылып өлгерде. Тәмәке төтене, ысланган балык, суган кыягы исе сеңгән әлеге кулдан җирәнүдән йөзенә чыккан җыерчыкларны яшерер өчен, елмайган булып, тимер басмаларны җиз дагалы үкчәсе белән төя-төя, иң өске палубага йөгерде.
– Йә, кая алып баралар безне? – диде Сөмбелә, аулакта сабырсызланып.
– Әнә, ярдагы теге вак урманны күрәсеңме?
– Бишбалта причалы.
– Ярга якын килмибез. Якорь салып шлюпкалар төшерәбез дә халыкны ярга ташыйбыз. Анда безне шашлык учагы, балык шулпасы, көлгә күмгән бәрәңге көтә. «Иделкәем» ансамбле каршылый. Кичке сигездә кабат елга портына кайтып төшәбез.
– Биш чакрым араны унике сәгать буе йөзәбезме?
– Кая ашыгасың, Сөмбелә?! Ял ит рәхәтләнеп.
– Сезгә ялдыр да, безгә эш инде ул. Унике сәгатьлек эш көне.
– Эш дигәннән, Сөмбелә, сиңа гына сер итеп әйтәм... Шушы көннәрдә мине Казанга күчерәләр. Республика районнары буенча кураторлык эшен миңа йөкләячәкләр... Әгәр үз бригадаң белән районнарны йөреп чыксаң, ә?! Кырык дүрт концерт! Гарантияле! Чыгымнарның бер өлеше бюджет хисабыннан булыр, районнарга хат җибәрербез, шәпләп оештырырлар! Син ризамы шуңа?
«Эрләмәгән-сукмаган, Шаһи, сиңа ыштанлык!», «Тумаган тайга атланма, билен сындырырсың!», «Алдан кычкырган күкенең башы авырткан...» ише әйтемнәр кинәт исенә төшеп, Сөмбелә үртәлгәндер, күрәсең. Өлкән мичманга аның елмаюы бик ошамады.
– Ихтыярың. Теләмәсәң, бүтәннәр килер... Тик халкыбызга мин күбрәк сине тыңлатыр идем. Сөмбелә дигәндә тамашачы сырпалана бит...
– Рәхмәт инде. Килермен мин. Тик бу сөйләшү чакыруга охшамаган әле.
– Әйе, әйе, искә төшерү, ягъни мәсәлән, алданрак килешеп кую!
Ул, Сөмбеләнең кулын кыскан булып, аны үзенә якынрак тартып китерде. Махсус шулай эшләде, чөнки бер төркем мичманның баскычтан менеп килгәнен күреп алды. Ул аларга: «Бу җырчы бүген минеке!» – дип шапырынырга теләде, күрәсең.
Сөмбеләгә бу хәл бер дә ошамады. Җитмәсә, ике ара шултиклем якынайган иде ки, хәтта өлкән мичманның сулышындагы аракы түгелгән салат исе тынын кыса иде. Кызый мәктәп баласы кебек елгырлык белән абзагызның «ике колачлы» тозагыннан шуып кына чыкты. Чыкты да палубаның икенче ягындагы баскычтан аска сыргылды. Өстә мичманнарның көлешкәне, кемнеңдер «Кок! Безгә ром китер!» дигәне генә ишетелеп калды.
Сөмбелә берьялгызы каютага кереп бикләнде. Кием шкафының биге чаклы гына йозак аны шау-шудан аерып куйды. Колакта тынлык чыңлап тора. Шуны гына көткәндәй, инде кайчаннан бирле эзәрлекләп йөргән уй бөтен фикерне биләп алды... Үз биләмәсендә патшага әверелгән, хакимлек итүнең бөтен тантанасын күргән, базарча яшәүнең тәмен белеп өлгергән типик яңа җитәкче бу... Алар сәнгатькә соклана белми. Җырчы кызларны яулау малайлар чуагының бер уены гына.
Ул «Шлюпки на воду!» дигән тавышка уянып китте. Димәк, мәҗлеснең тәнәфестән соң гөрләгән өлешенә йоклап калган. Бәлки әле, капитанның бу әмерен дә ишетмәгән булыр иде – теплоходның двигатель тавышы тынган, шуңа һәр аваз, һәр үкчә тыкылдавы каюта аша үтәли йөри.
Төшәргә исәбе юк Сөмбеләнең. Ул инде ярда шашлык көткәнен белә. Алай да хатын-кызларга хас «күрәсе килүен» тыя алмады, иллюминаторга бик якын килмичә генә, су өстен күзәтте. Капитан биргән команда шаяру гына икән – бернинди көймәне дә суга төшермәгәннәр. Бишбалтаның «Леонид Соболев» теплоходын китереп бәйләрлек причалы юк. Шуңа күрә халыкны ярга якын килә алырдай «омик»ка күчереп төяделәр.

Кунаклар тиз күченде, кают-компаниянең кысанлыгыннан, рәсми табынның протоколларга теркәлердәй тостларыннан ялыккан кунаклар шашлыклы вак урманга су өслэтеп йөгерергә әзер иде инде.

Калды Сөмбелә. Өч палубалы алагаем теплоходта берүзе калды. Учак тирәсендә баян белән эчемлек булса – шул җитә. Өстәвенә әле ярда «Иделкәем» ансамбле көтә. Анда яшь җырчылар гаскәре – Зәлия, Әлфия, Рәмзия, Резидәләр...

Шашлыкчылар десантына ияргән өлкән мичман, учак тирәсендәге ыгы-зыгы тынган арада, Сөмбеләнең юклыгын абайлап алды. Җитәкченең мин-минлегенә көч килде. Һәркайсы чибәрләр конкурсында бәйге тотарлык «Иделкәем» кызлары да күренмәде аның күзенә, күбрәк эчкән саен ныграк айный баргандай тоелды аңа, капкан ит кисәген йоталмыйча интекте, вак урманның һәр күләгәсен тентеп чыкты, аның юклыгына ышанган саен ачуы кабара торды. Ниндидер бер колхоз хәерчесе, үзенең популярлыгына масаеп, бүген-иртәгә расланасы җитәкчене санламаган булып йөз чөереп маташа... Хәерченең иң зур кимчелеге – намуслы горурлык. Ләкин акчасыз горурлык ул – мескенлегеңне танымаска тырышып масаю гына. Масаюны яшәү рәвеше итәр өчен акча, акча кирәк, кызый. Ә күп акча эшлим дисәң, намусыңны онытырга, горурлыгыңны кырыкка чатнатып сындырырга туры килә... Безнең җәмгыятьнең иң зур хакимияте хәзер – акча.

Өлкән мичман, «омик» белән берүзе килеп, теплоходның каюталарын актарып чыгарга бик тели. Сөмбеләне барыбер эзләп табар, ай-ваена карамыйча акыртып көчләр иде... Концерт кулмәген кигән килеш! Назлыйсы килмәсә – җырлап ятсын, җырлыйсы килмәсә – еласын!..

Ләкин капитан алдында дуамаллану килешеп бетмәс. Субординациянең кануннары кырыс. Үсешкә дучар ителгәнсең икән, карьера баскычында үзеңнән өстәрәк торганнарның сүзе-имзасы, мөнәсәбәтенә тешеңне кысып булса да түзәргә, хөрмәт итәргә мәҗбүрсең. Идарә итүнең диалектикасы гадел түгел, әмма бик гади: бүген – син мине, иртәгә – мин сине!..

Ниһаять, шашлык учагы сүрелде, вак урман эче тынды...

Яны белән килеп сыенган «омик»тан «Леонид Соболев» бортына сикереп төшкән иң беренче кунак өлкән мичман иде. Тар, озын коридор буенча тезелгән ишекләрне рәттән ача барып ул, ниһаять, эчтән биклесенә килеп төртелде. Ныклап тартса, сувенир йозак шартлап ачыласы, тик ул эчтән бикләнү мөмкинлегенең аңарга әле һичшиксез кирәк булачагын исеннән чыгармады.

Теплоход ирләр белән хатын-кызлар арасындагы интригаларны тавышланып хәл итә торган урын түгел. Каюта ишеге йодрык ягына таба ачылды, төбенә чаклы ачылганын көтмәде өлкән мичман, гүя ярыктан шәүләдәй шуып керде дә эчтән бикләп куйды. Ятып торган чагы булса, ул бәреп кергән хутка аның өстенә авасы иде. Шөкер, Сөмбелә аягында нык тора, ул аучыны һөҗүмгә әзерләнгән боксчы рәвешендә көтте.

Өзәргә дип үрелгән кулга чәчәк каршы тора аламы? Комарлы ир колачы, келәшчә сыман кысылып, Сөмбеләнең кулларын бөкләде, әмма йодрыклары ике гәүдә арасында йомарланып калган иде.

– Йә, нишлибез, Сөмбелә, бил сызганып эшкә тотынабызмы? Әллә тагын качышлы уйнап алабызмы?

– Шушындый бәйрәм көнегездә дә гел эш турында сөйләшмик инде.

– Алайса, «әбәк-әбәк» уйныйбыз?

– Юк, сездән качар өчен бу теплоход кына түгел, мәркәзебез бәләкәй.

– Күптән шулай дип әйтәләр аны! «Риза» дигән сүзеңне дә кешечә әйтә белмисең бит син. Бәлки, шуңа күрә кызыгамдыр да әле мин сиңа. Сөмбелә ул – минем өчен чибәрлек, горурлык, нәфислек һәм җырлый торган йолдыз символы.

– Ялганлап мактау түрәләр белән, үзеңнән көчлеләр белән сөйләшкәндә бик файдалы. Ә мин соң... гади бер җырчы... сезнеңчә әйтсәк – иске йолдыз.

– Түрәләр, көчлеләр, имеш! Хатын-кыз белән мактаусыз сүз башлап буламы? Ләкин сиңа башыңны җүләргә салсаң ныграк килешер иде. Акыллы булып әллә кыланасың, әллә үзең шундый...

– Үзгәрә алмыйм инде мин. Сезнең күңелне күрер өчен генә шамакайланасым килми.

– Акыллы-акыллы! Әйт әле, кыйммәтле артисткам, үз гомереңдә ничә ир белән йокладың син?

– Санап торучысы юк инде аның. Су белән газ торбасына счетчик куялар куюын, ә ирләр белән хатыннар арасына уйлап тапмаганнар ди әле.

– Димәк, коммерческая тайна!.. Әһә, ниһаять, ачуыңны чыгардым, күзеңнең кешесе зурайды! Юкса салкын канлы булып кылануың кайнар тәнеңә күрә түгел иде.

– Ачуланып торырга, мин әллә юмагайлар студиясенә контракт төзергә килгән яшь җырчымы?

– Гөнаһларың күп инде синең, ә?!

– Унсигез яшьлек кыз үстергәч, сезнең каршыда гөнаһсызга сабышып торыр хәлем юк. Беләм, ирләрнең кайсын гына алма – бөтенесенең дә беренче буласылары килә... Унсигез ел элек кайда йөргәнсездер? Бүген гөнаһларым өчен каршыгызда гафу үтенергә генә кала.

– Кыз баланың гөнаһлары рухландыра мине. Ят әйдә! Юкса көчлим!

– Нинди көчләү ди ул?! Үземнең дә күптән сөеләсем килә. Бүген гел кызлар тирәсендә бөтерелдең, шуңа көнләшүемә чыдый алмыйча әрләшәм.

– Алайса сузма.

– Хәзер. Син чишенеп ята тор. Мин бер минуттан әйләнеп керәм.

– Нәрсә-ә?!

– Ярамаган ризык эләкте. Эчем китә минем. Теплоходта берүзем ник бикләнеп калды дисең. Тиз генә эшне бетереп тәһарәт алып киләм.

Азгыннар кулыннан качып котылу дигәндә, әлеге авыруны телгә алу кыз бала өчен һич түбәнсенүгә саналмый. Киресенчә, ирләрнең әүкатен сүндерә торган, сыналган алым бу. Өлкән мичман да ниятеннән кире чигенә язды. Язды, әмма чигенмәде, Сөмбелә чыгып киткәч, чишенеп, ишекне бикләмичә генә, караватка менеп ятты. Башы мендәргә тию белән гәүдәсе авырайды, бөтен әчкәне, ашаганы ике потлы гер булып күкрәк читлегенә басты. Һәм ул, яклаусызларны сөендереп, гырлап йокыга китте.

Озак йокламады, күп дигәндә ун-унбиш минут черем иткәндер, сәфәренә соңга калган юлчыдай сискәнеп уянды.

Сөялгәнсең чатта баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрең;
................................
................................
Күрәм, ике ир(е)нең селкенәдер:
Кайсы татар баен каргыйсың?

Унбиш минутлык йокыдан тәүлек буена җитәрлек көч туплап, тынычланып һәм айнып уянган чын совет җитәкчесе «Кайда син?! Ник ялангач? Булдымы-юкмы? Коридорның теге башында нинди туй?» дигән сорауларга җавапны Сөмбеләнең җырлавыннан тапты. Җавап белән бергә тагын ярсуы әйләнеп кайтты. Кызыйның тавышына түгел, Тукайның шигыренә үртәлде ул – ишетәсеңме, мөнәҗәт җырлар хәлгә төшкән мескен җырчы хәерче шагыйрьдән яклау эзли?!

Теплоход, кырлардагы хәлне искә төшергәндәй, буш элеваторлар тирәсендә борылыш ясап, пристаньга кайтып бәйләнде. Кунаклар командасы, төрле илләрдән җыйналган туристлар кебек бер-берсенә артык илтифат күрсәтмичә генә, трапка ашыкты. Һәм җиргә төшкән бере яңадан үзенең элеккеге халәтенә кайтты: капитан инде шәһәр башлыгы булган, ике урынбасарын ияртеп иң алдан бара; мичманнар хакимият башлыкларына әверелде; чегәннәр, иң азактан чыгып, шәһәр коймаларына ябыштырылган плакатларына охшарга тырышып, тыелгысыз елмайдылар. Ярдагы бөтен машина берьюлы кабынды. Күрсәтмә буенча алар автовокзал янындагы тимер юл күперенә чаклы эскорт ясап тезелешеп киләчәкләр, аннан инде һәр хакимиятне каладан чыгып кача торган үз юлы көтә.

Елга порты кырындагы троллейбус тукталышына килеп баскач, Сөмбелә никтер яр буена әйләнеп карыйсы итте. Чөнки аның инде теплоходтан ерагайганына, ниһаять, иреккә чыкканына чын-чынлап ышанасы килде бугай... Вәт, гөнаһ шомлыгы... Элеккеге мичман эскорттан бүленеп калган – машинасы кабынмый!

Стартерның кушылырга теләмичә бушка әйләнүеннән туйдымы, әллә хурлануы чиктән ашкан идеме, ул машинадан кинәт чыгып, шоферны селтәп ыргытты да руль артына үзе утырды. Хакимнең холкыннан чыныккан шофер, егылган җиреннән тиз генә торып, авырайган кара «Волга»ны этә башлады. Машина кабынган уңайга аны калдырып китеп баргач та, вакыт әрәм итмичә, тез башларын ашык-пошык сыпырып, әче төтен артыннан йөгерде...

* * *

Сөмбелә кухня тәрәзәсенең авыр өлгесен ачты. Амбар кенәгәсенең 1993 елыннан йокы тәмам качты. Чәйнек кайнарлыгы бөтен бүлмәгә таралды. Чикләвек оны белән куертылган сөт төрелгән как рулетыннан бер телем кисеп алды. Әлем кагының ачысы чәйдә эреп бөтен тәненә ут булып таралды. Вакыйгалардан тизрәк ерагаерга теләп, ул үзенең «вахта журналы»н тоташлап актарырга кереште. Бер-ике елны җәһәт кенә үтеп китсә дә, ул әле барыбер теплоходтан котыла алмады. Өч палубалы мәҗара күз алдыннан китми, офыкта эленеп калган ак мираж булып еллар арасында очып йөри, күптән таралышкан йөгәнсез малайларның шаукымы әле һаман колак төбендә... Теге абзый калага килгәч тә озак тоткарланмады, «башка эшкә күчү сәбәпле» тагын районга җибәрелде. Ул кардәшләр җөмһүриятенең төньягында яңа тормыш күтәрү белән мәшгуль... Юк, дистә елдан артык вакыт үткәч тә Сөмбеләгә сары розалар сибә торган шаһзадә түгел ул...

## Коры сихер

Сары табышмакның җавабын коммунизм кырларыннан эзләмәде Сөмбелә. Дөрес, элек тә һәр җитәкченең күңеленә ятышлы «үз җырчысы» була торган иде. Әдәбият һәм сәнгать көннәре, мәдәният декадалары, классикларыбызның юбилей кичәләренә әзерлек башланса, делегация җитәкчесенең кем булуыннан чамалап, бәйрәмгә кайсы җырчыларның барасын алдан ук белеп торалар иде. Мәскәүдәме, Уфада-Чабаксардамы, Каракалпакта-Ижаудамы – кемнең кайда йөргәнен мактаулы исемнәренә, почет грамоталарына карап чамаларга була.

Малайлар чуагы чын-чынлап туксанынчы елларда башланды. Пролетариат диктатурасының җитмеш ел буе туплаган бөтен байлыгы, җәмгыяте белән шәхси мөлкәткә әверелеп, җитәкчеләр кулына күчте. Базар юлына чыкканчы кем кайда утырган – шул үзенең кабинеты тирәсендәге малга, җиргә, җитештерү тармакларына һәм хәтта эшче көчләренә дә хуҗа булды. Ә кабинетсызлар ваучер тотып калды.

Берара акчаның нольләре калькуляторларга сыешмады, кулдан-кулга «пачкалап» кына йөри башлады, билен буган штамплы кәгазе исән торса, кибетләрдә дә санамыйлар иде хәтта. «Эмиссия, дивидент, дисконт, девальвация, деноминация, валюта, дефолт, дотация, банкрот» ише әйтеп бетергесез терминнар арасында кыйналган тинтәк акча артистлар язмышын мөлкәтлеләр хәйриясенә калдырды.

Филармониянең эстрада бүлеге ябылгач, җырчылар «Ура!» кычкырган иде. Өч ай эчендә кырык биш тапкыр җырларга мәҗбүр итә торган концерт оешмасы юк хәзер! Шуның белән бергә план үтәмәгән өчен шелтә бирүчеләре дә, һәр җырыңны тикшереп, көе-эчтәлеге, башкарылышына бәя куеп утыручы худсоветлары да, кассага күбрәк акча җыя алган артистларга гына мактаулы исемнәр, фатирлар бирүне берүзе хәл итә торган директоры да юк...

Җырчы халкы тамашачы белән бергә-бер калды. Медиа-магнатлар экраннарда кемне әйләндерсә, тамашачы шуларны көтте. Кемгә кул чапсалар – шул эшләде. «Йолдызлар фабрикасы» шомарткан чибәр, нәфис гәүдәле, сөйкемле кызлардан, ыспай малайлардан унсигез яшьлек эстрада йолдызлары кабынды. Нәфислек сәхнә алдына чыкса, классик тавыш хәзер арткы планда. Афишаларны ертып йөрүчеләр, концерт булмый дип шылтыратучылар күбәйде. Һәр тамашачы өчен «йолдызлар сугышы» башланды. Филармониянең эстрада бүлеге мәдәният сарайларында айга бер генә концерт куярга җөрьәт итә иде. Ә хәзер көн дә бәйрәм: афиша өстендә плакат, игълан астында белдерү. Хәләл акчасын түләп керердәй апаларның гайрәте чикте, азмы-күпме халык йөрердәй заллар бармак белән санарлык кына калды.

Филармониядән киткәннән бирле Сөмбеләнең хезмәт кенәгәсендә бүтән мөһер юк. Каян килсен ди инде ул?! Календарьдагы бәйрәмнәр, сабантуйлар, юбилейларда җырлатыр өчен кем штатка алсын сине?

1994 елның март азагында урам бәйрәмнәре, җыеннар, ерак гастрольләр оештыру буенча шактый тәҗрибә туплаган Манс шылтыратты. Ул атказанган баянчы, күп кенә матур җырлар авторы. Базар синдромы башлангач, эш коралын читкә куеп, менеджмент кәсебенә тотынды. Үзен кызыксындырган шәхесләр белән итагатьле сөйләшә белә. Сорауларын рәттән тезсәң, хәл белешүдән һәм яңа эш тәкъдим итүдән гыйбарәт иде.

– Исәнмесез, Сөмбелә!.. Кызыгыз әйбәт кенә укыймы? Бер проект тәкъдим итсәм, ничегрәк уйларсыз икән? Экстрасенс Фаил абый публичный сеанслар үткәрергә җыена, аңа ассистент кирәк иде. Сәхнәгә чыкмыйча гына, авырулардан килгән сорауларны тәртипкә салып, пәрдә артыннан укып торырга... Фаил абый аларга җавап бирәчәк. 1 апрельдән башлап өч көнгә икешәр сәгатьлек унике сеанс. Билетлар күптән сатылып беткән. Көн саен дүртәр аншлаг, «УНИКС» залында!.. Түләүне алдан әйтмим – ну гонорары мәскәүләрчә... Әйбәт кенә узса, алга таба эшләргә дә өмет бар. Уйлагыз, ризалашыгыз, ун минуттан тагын шылтыратам.

«УНИКС» залында унике аншлаг ул – унике мең тамашачы дигән сүз. Авыру, гарип, саулыкка сусаган бичаралармы – концерт залына җыелгач алар барыбер тамашачы инде. Тулы залның шаулавы, язгы ташкын белән тулган елга яры кебек, пәрдә аркылы да ишетелә. Риза, әлбәттә, риза Сөмбелә, ләкин Манс ун минут көтәргә куша, ул башка берәүләрне дә үгетләп, үзенчә кастинг үткәреп маташамы? Һәм ни өчен сеанслар 1 апрельдә – алдалау көнендә башлана?

Ун минуттан дигән тынлык биш минуттан арыга сузылмады. Иң беренче җавап итеп Сөмбелә ризалыгын белдерде. Тик сораулар бирмичә түзә алмады.

– 1 апрель шуткасы түгелме?

– «Биш татар» районга чыгып киткән. Залның ул көннәре буш.

– Мине кем урынына чакырасыз? Берәрсе кире уйладымы?

– Сездән башкага әйткән юк әле. Җырчылар арасында медицинаны азмы-күпме белгән бер Сөмбелә, диделәр.

– Мин бит ике ел гына укыдым.

– Белештек. Сез анатомияне өч семестр укыгансыз, Фаил абыйның ассистенты булыр өчен әлегә шул җиткән.

Колхоз базарыннан ерак түгел бер ишегалдында ике бүлмәле янкорманы арендага алып, Фаил абый экстрасенсорик дәвалау эшенә ныклап керешкән иде. Ул ишегалдында һәрчак урам бәйрәменә килгәндәй халык булыр. Фаил абыйга эләгер өчен авыллардан килеп көннәр буе чират торалар. Фаил абыйның хатыны, малае, хәтта күршеләре аша танышлык кылып чиратсыз үтүчеләр дә күбәйде. Сырхау тәнгә кул белән кагылмыйча энергетик массаж ясап сихәтләндерүе хакында бик күп гәҗитләр язды, Казан телевидениесе көнаралаш диярлек әңгәмәләр үткәрде. Журналистлар, артистлар аның фатир телефонын үз кулыннан алып, әкренләп дус-ишләргә, таныш-белешләргә тарата торды. Өйгә шылтыратучылар, урамда очрап сихәт сораучылар шултиклем күбәйделәр ки – ачык сеанслар үткәрү котылгысыз ихтыяҗга әверелде.

Ниһаять... Менә ул 1994 елның 1 апреле. Иртәнге унда башланасы сеанска әзерләнер өчен Сөмбелә алтыда ук уянды. Концерт күлмәкләренә күз йөгертеп чыкты да рәсми очрашуларга дип сакланган киң озын итәкле, ябык изүле көрән бәрхет костюмын киде.

Дулкынлануын җиңәр өчен ул, тайгак тротуардан вак-вак атлаган килеш борын тишекләрен киңәйтеп, кояшлы иртәнең язгы һавасына ябырылды. Университет үрен менгәч ни күрсен – башланырга ике сәгать барын белә торып, мәйдан халык белән тулган. Әйтерсең лә колхоз базары, «УНИКС» янына күченеп, кырмыска оясына әверелгән. Җентекләбрәк күзәтсәң, шәһәрнең арбалы, култык таяклы, зары йөзенә чыккан меңнәре хәвефтән котылып каядыр эвакуациягә әзерләнгән кебек. Ни елмаерга, ни еларга белмәгән сау-сәламәт артистның бикле ишеккә килеп шакылдатуы бик күпләрнең чыраен сыттырды. Бу минутта алар Сөмбелә дигән җырчыны, популярлыгы белән сырхауларны санламыйча, татар Кашпировские янына чиратсыз үтәргә маташучы сәхнә кыланчыгы дип кенә уйлыйлар иде.

Шөкер, озак шакып мескенләнергә туры килмәде, эчке якта кизү торучы апакай, аны танып, тиз генә ишекне ачып-ябып алды.

Микрофонлы киң өстәлне каплап торсын өчен, пәрдәне махсус ачып бетермәгәннәр иде. Манс моны Фаил абый белән киңәшеп алдан ук әзерләп куйган. Шунысы әйбәт, Сөмбеләнең эш урыны күз алдында тормаячак икән.

Башланды...

Ул, исеме алдан ук игълан ителгән сөекле артист кебек башын югары тотып, күкрәген киереп, ышанычлы, тигез ритмнар белән җәһәт атлап, сәхнә алдына чыгып басты. Ян пәрдәләр арасыннан шәүләсе күренү белән башланган овация биш минутлап дәвам итте. Дегет төсендәге костюм чалбары, өске төймәсе кара канатлы күбәләк белән капланган җете ак күлмәге, биек үкчәле ялтыравык туфлиләре, иң мөһиме – меңнәрне әсир итәрлек серле күзләрне каплап торган әңгер пыялалы, алтын кысалы тар күзлеге... болар барысы да, базар мөнәсәбәтләре башлангач, Фаил абыйга көтмәгәндә генә Ходайдан иңгән әүлиялык кодрәте өстәп торалар иде сыман. Ул, терсәген турайтмыйча гына ике кулын күтәреп, алкышларны туктатты. Күпләр инде аның тирәсендә салават күпере, төньяк балкышы, таң нурлары күреп сабыйларча еларга тотынды, йөткерүләр, тамак кырулар көчәйде.

Иң әүвәл ышандыра алырлык сүз кирәк иде...

Фаил абый, газеталардан өземтәләр укып, үзенең уңышлары белән сихәтләнгән, чирләреннән котылган кешеләрнең исемнәре-адреслары белән сөендерде...

Зал тынычланды, Сөмбелә тәмәке уты белән өтелгән тишектән пәрдәнең теге ягына күз салды: тирән эчле, комач түшәкле утыргычларда мең төрле хаста – башлары иелгән, кыйшайган, чөелгән, сәхнәгә баккан... Кызгану катыш куркуданмы Сөмбеләнең иртән эчкән сөтле чәе маңгаена тир булып бәреп чыкты.

– Минем кулларымнан нур таралганын күрәсезме?

– Әйе! Күрәбез!

– Мәгез! Ходай миңа сезне савыктырырга кушты.

– Безнең якка да... Безгә дә җибәр нурларыңны.

– Һәммәгезгә дә барып җитә! Ышанган кеше савыгыр...

Беренче сәгатьтә Фаил абый залга учлап-учлап нур өләште. Ягымлы сүзләр белән туктаусыз юатты. Карлыккан тембрлы, тигез моңлы тавышны микрофон йотып ала, көчәйткечләр аша күпертеп, сандык чаклы колонкалар залга коя.

Сөмбеләне йокы баскан иде инде.

– Сорауларыгыз булса, язып җибәрегез. Залдан кычкырмагыз! – дигән тавышка ул сискәнеп китте.

Килде сорау... Килде сорау...

«Колак авыртуым басылмый... Күзләрем сызлый... Йокым юк... Бот төбеннән аягым туктаусыз сызлый... Үпкә... Бавыр... Бәвел куыгы... Бөер...» Сөмбелә гүя, анатомичкадагы практикант кебек, авыру «әгъзаларны» өстәлгә тезеп салды. Ул сорауларны укый башлады, Фаил абый җавап биреп торды:

– Авыртуың басыла... Сызлаудан туктый... Бүгеннән башлап йокларсың... Бүсерең юкка чыга... Бөереңдәге ташлар уалып чыгачак...

Сораулар ялыктыра башлагач, Фаил абый үзгәреш кертергә теләде. «Атналап башым авырта», «Ирем кыйнаганнан кул сөягем калтырый торган булып калды...» дигән сорауларның кешесен сәхнәгә чакырды. Вакыт бетеп килә, икенче сеанс өчен залны җиллэтеп өлгерәсе һәм кодрәтне күрсәтеп, үзенә күрә реклама ясап аласы бар иде.

Фаил абый янына ике хатын чыгып басты. Аларга карап залдагыларның көнчелектән күзләре елтырады. Урамда җәйгә охшаш көн иде инде, көндезләрен залны җылытмыйлар, шуңа күрә авыру халыкка өс киемнәрен салмаска рөхсәт ителгән. Чандыр гәүдәле, очлы иякле, илле яшьләрдәге ханымның кулы туктаусыз калтырап балонья курткасы кыштыр-кыштыр килеп тора иде. Фаил абый аны сыпырды гына – кыштырдау шундук туктады. Залда кул чабулар көчәйде...

Какао төсендәге пәлтәсен киң пута белән буып куйган, калын толымлы, киң маңгайлы егерме яшьләр чамасындагы кызның башын кушучлап тоткач, зал тагын тынып калды. Фаил абый бер учын баш чүмече ягыннан, икенчесен маңгайдан ерагайта барып читкәрәк китеп басты.

– Йә, ничек?! – дип сорады ул, тыныч кына, җавапның нинди буласына алдан ук ышанган кешедәй.

– Абау, сызламый! Туктады! – Кызның сытык чырае язылды, йөзенә елмаю кунды. – Билләһи, бетте! И абый, Ходайның рәхмәте яусын сиңа! – диде дә, сөенеченнән тыела алмыйча елап, сәхнә читендәге баскычка таба китте. Ул залга төшеп өлгерә алмады, сабырлыгы төкәнгән сырхаулар дәррәү кубып сәхнәгә ыргылган иде инде. Кыз читкә тайпылып чак егылмый калды.

«Мине дә сыпырып кара! Бер генә булса да сыйпа!» дигән ташкын Фаил абый өстенә ябырылды. Таянган таякларын кылыч итеп януачылар да күренде.

Фаил абый микрофонны авызына кабардай булып кычкыра башлады:

– Җәмәгать, дәвалау өчен тынычлык кирәк! Мин болай эшли алмыйм! Вакытыгыз бетте! Тагын килерсез! Урамда яңа авырулар көтә!

Ишектәге кыңгырауның өзгәләнүенә исе дә китмәгән халыктан чак котылып, сәхнәдән югалып торды Фаил абый. Ул арада Сөмбелә дә аның янына грим бүлмәсенә кереп бикләнде.

– Фаил абый, гафу ит, мин кайтып китәм. Ике сәгать үткәнче көчкә түзеп утырдым. Бик авыр...

– Әллә миңа җиңел булды дисеңме? Берьюлы мең сырхау белән эшләп караган кешеме мин?!

– Бу сезнең сольный концерт. Гафу итегез, сезнең проект дип әйтәсем килә. Мине алыштыруы берни түгел.

– Ун минутлык тәнәфестә шушындый катлаулы эштә ассистент эзләп табып буламы! Әллә син аларны ишек төбенә тезелеп басканнар дип уйлыйсыңмы? Синең белән дә ике атна алдан сөйләшеп куйган идек, онытма шуны! Алга таба сорауларга җавап бирүне туктатырга и берәүне дә сәхнәгә чакырмаска кирәк... Монысы минем ялгыш. Ярты чокыр гына чәй эчеп алыйк та эшкә тотынабыз. Син ничегрәк җырлыйсың әле:

Яратмагач башламыйлар,
Башлагач ташламыйлар! –

дипме?

– Мәхәббәт турындагы җыр ул, Фаил абый, темасы туры килми.

– Бик туры килә. Тамашачының авыруларын да, кølә торган сәламәтләрен дә яратырга кирәк.

– Нинди тамашачы?! Болар бит концерт залына ялгыш җыелган мең сырхау!

– Әйе, бик дөрес әйтәсең, миңа сырхау, ә синең өчен тамашачы. Билет алып кергәннәр. Урыннары Азамат концертыннан да кыйммәтрәк тора. Унике сеансны да эшләп чыгыйк. Иншалла, соңыннан тагын сөйләшербез.

Гипнозы бардыр инде Фаил абыйның – кайтырга дип җыена башлаган Сөмбелә яңадан ризалашты, бөтен борчылуларын онытып, зур-зур йотымнар белән чәй эчәргә тотынды.

Бик күп кеше икешәр-өчәр сеанска рәттән билет алган булып чыкты. Алар инде Фаил абыегызның «Сораулар бирегез!» дигәнен көтеп тормадылар, тигезсез ертылган һәм төрле төстәге кәгазь кисәкләрен дәвалаучының аяк астына өя башладылар. «Икенче коймак» та төерләнмәсен өчен шактый көчәнделәр: сорауларга гомумирәк җавап кайтардылар, чакырмаган килеш сәхнәгә ыргылучыларны үгетләп кире урыннарына утырттылар. Көн азагына таба Сөмбелә үзен меңәрләгән җан иясеннән чир йоктырган сырхау кебек хис итте. Башы, муены, умыртка баганасы, кул-аяк буыннары – бөтенесе сызлый һәм эчке әгъзалары дәррәү кубып сулкылдый сыман иде. Сорауларга ияреп килгән ялварулар, пәрдәнең теге ягындагы гозерләр, нәүмиз өметләр – барысы да аның җаны аша үтә торды бугай...

Икенче көн дә «скорый»лар чакыртмыйча тыныч үтеп китте. Залдагыларның киемнәре, йөзләре-тавышлары үзгәрде, тик елаулары, ыңгырашулары, зарлары үзгәрмәде.

Өченче көнне исә... Ниһаять, соңгы сеанска тотындык, җиңәбез, дигәндә генә, Сөмбелә бер сорауны укыгач кинәт тотлыгып калды:

*«Зинһар өчен, дип әйтәм, кычкырып укыгыз. Миндә аю табаны. Бүген сезне дүртенче тапкыр тыңлыйм. Тагын ничә көн килергә кирәк миңа?*

*Идрис».*

...Аю табаны... Идрис!..

Шушы өч сүзнең кайтавазы көчәйткечләр аша үтеп, бөтен залны айкап, сәхнәгә килеп, Сөмбеләнең үз тавышы белән үзенә әйләнеп кайтты... Балантауныкы... Классташы... Күрше егете...

Ул арада исен-акылын җыеп, Фаил абый белән киңәшмичә генә, Идрисне сәхнәгә чакырды, дөресрәге, кемлеген тизрәк беләсе килде.

Идрис сәхнәгә менәрмен дип көтмәгән иде бугай, эре буразналы вельвет курткасының төймәләрен боргычлады. Аның җитен чәче коңгырт киеменә бик килешеп тора иде. Гәүдә җыйнаклыгы, йөзенең кызларныкыдай аклыгы һәм шомалыгы белән ул әле гел мәктәп баласыдай... Идрис үзе!

Фаил абый Сөмбелә капризына буйсынырга мәҗбүр булды. Егеткә сәхнә буйлап арлы-бирле йөрергә кушты. Аннан, көтмәгәндә: «Тукта!» – дип кычкырды.

– Идрис! – дип өстәде Сөмбелә дә. Һәм тавыш җепселләре коргаксыса йотып куярга диелгән стаканлы суны тотып, егеткә таба атлады. Кыз кулындагы су ике арада эленеп калды.

Идриснең кызны танып өнсез калуын, өч йотым белән стаканны бушатуын, тирән сулап озак көрсенүен һәм Сөмбеләнең аны җитәкләп сәхнә артына алып чыгып китүен залдагылар йөрәк өянәге дип аңладылар. Шуңа күрәдер Фаил абыйга сыйпатыр өчен сәхнәгә ашкынучылар күренмәде...

– Нихәл, Идрис, нихәл?!

Сөмбелә аны ике иңбашыннан тотып күкрәгенә кысты, аркасыннан сөйде, җитен чәчләрен тузгытып башыннан сыйпады, үзенең күз яшьләрен сеңдергән зәңгәр бизәкле кулъяулыгы белән егетнең томаулы борынын сөртте...

– И балакаем, авылда нишләп яталар анда?

– Белмим, – диде Идрис, кырыс кына. Ул һаман тораташтай катып калган. Зарыгып сагынуын йөзенә чыгармый.

– Ничек белмисең? – дип өзгәләнде Сөмбелә аның саен.

– Күптән кайтканым юк.

– Монда каян килеп эләктең?

– Аякны төзәтәм.

– Сау-таза егет бит син!

– Аю табанын бетерәм. Аннан армиягә китәм.

– Ник?

– Егет булыр өчен.

– Менә дигән егет бит инде син болай да.

– Армиядән кайтам да сиңа өйләнәм.

– Идрис, минем инде мәктәптә укый торган кызым бар, Зәйтүнә исемле.

– Беләм. Балаң белән бергә алам. Балантаулылар аны минем кыз дип беләләр. Ачулансаң ачуланырсың, гайбәтен үзем чыгардым.

– Зәйтүнәм сиңа тамчы да охшамаган. Ул бит чем-кара чәчле, калын кара кашлы, каратутлы...

– Аттан ала да туа, кола да туа...

– Кияүгә чыгарга җыенмыйм инде мин. Җырчы кирәк дисәң, мин сине ябь-яшь кызлар белән таныштырам.

Залда урындыклар дөбердәве, аяк тавышлары, кычкырып сөйләшүләр ишәйде. Фаил абый, гүя өч көнгә сузылган бәрелештә җиңү яулаган батыр солдат кебек, сугыш кырыннан елмаеп чыкты. «Рәхмәт. Бирешмәдең. Бөтенләй шомардың» дигән гади сүзләрне тантаналы мактауга корып, Сөмбеләне күрше бүлмәгә алып китте. Идрисне бәйләнчек бер сырхау дип уйлап, аннан тизрәк коткарырга теләде, ахрысы.

Сөмбеләнең: «Хәзер киләм, китмичә тор, яме», – дигәнен чынга алмагандыр, биш минуттан әйләнеп килгәндә Идрис анда юк иде инде.

Фаил абый үзенә ассистент итеп бер журналист егетне ияртте. Сөмбеләгә үпкәләмәде, дебютта түккән көчен гадел бәяләп, кирәгем чыкса, тел яшереп торма, синең исемнән килгән кешеләрне чиратсыз-нисез кабул итәрмен, дип тә өстәде хәтта.

## Март айлары

Сәхнә артистны эзләмичәрәк торса, артист сәхнәне үзе эзләп китә.

Март айлары сискәндерә Сөмбеләне...

Көн белән төннең тигезләнгән мәле. Саба җиле кояшны болытлар белән томалап куйса да, җиһанда күңел сөенердәй язгы яктылык. Борынгылар яңа ел дип атаган вакыт исәбе белән астрономик яз башланды.

Мәдәният сарайлары тирәсендәге коймалар Нәүрүз бәйрәменә чакыручы афишалар белән тулды.

Сөмбелә бүген Академия театрына Нәүрүз бәйрәменә китте – тыңлаучы булып. Бәйрәм дигәч тә, шул ук концерт инде ул. Онытылып калган йолаларны сагынган моңлы халык «Нәүрүз», «Җыен», «Сөмбелә», «Каз өмәсе» кебек тамашаларга күбрәк җыела. Елның фасылына күрә үз бәйрәмен алдан ук көтеп тә тора хәтта...

Ул иртәрәк чыкты. Зәйтүнәнең мәш килеп өй җыештырганын карап утырмас өчен ашыгыбрак кузгалды. Фатирны икәүләшеп бизәмиләр, үзенчә матур булсын дисәң, анда бер генә кеше кулы керергә тиеш. Өй җыештырганда, хатын-кыз рәссамга әверелә.

Зәйтүнәнең язгы каникулы башланды. Соңгы каникулы. Алга таба укырга керә алса, яз көне бүтән каникуллар тәтемәячәк инде аңа. Керә алса... Сыйныфташларының күбесе, инде югары уку йортларын сайлап, әзерлек курсларына йөри башлады. Ә Зәйтүнә исә «Укырга кая барырга?» дигән сорауга соңгы каникулга чыккач кына җавап бирә алды. Авиация институтына керәсем килә, диде... Бала, әгәр төсе-бите белән әти-әнисенә охшамаса, һичьюгы, холкы белән, инде холкы килмәсә, хыяллары, уй-шөгыльләре белән булса да охшарга тиеш. Беренче сыйныфта укыганда ук Зәйтүнәне музыка мәктәбенә йөртте Сөмбелә. Үзе гастрольләргә киткән чакта күрше Мөнирә апасы иренмәде, ике мәктәп арасында йөгерде. Сигез ел укып, кызыл катыргы алып чыкты Зәйтүнә. Ә бит кызның киләчәге турында уйлап сарыф ителгән иде ул вакыт. Урта мәктәпне тәмамлау белән алга таба да музыка буенча укырга китәр, җырчы Сөмбеләнең бердәнбер кызын консерваториянең ишек төбеннән үк елмаеп каршы алучылар табылыр, шуның белән югары белем турындагы матавыклы проблема җиңел генә хәл ителер дип торганда, Зәйтүнә кырын басты: «Минем авиация институтына керәсем килә», – диде. Һәм, музыка мәсьәләсендә бөтенләй икеләнерлек урын калдырмаслык итеп, «Кулдан-кулга» дигән базар газетасына әнисе белән киңәшми-нитми генә пианино сату турында игълан биреп кайткач, кызны бүтән үгетләмәс булды. Әмма пианиноны сатмады. Әйе, Сөмбелә гомер буе хыялланып та үзе җыр яза алмады; әйе, панель йорттагы күршеләрнең тынычлыгын бозмас өчен ул өйдә тавышка күнегүләр дә ясамый; әйе, пианинода уйнап җырлашып утырырдай дусларның да күптән җыелганы юк инде. Тик барыбер өйдән музыка чыгып китәргә тиеш түгел, бу – өлкәннәр сүзе! Пианиноның һәр телендә Марат Гомәрнең бармак эзләре саклана... Соңгы җырын ул нәкъ менә шушы пианинода язды.

Уйлары бәргәләнгән чакта, кызы белән гармунчы исеме янәшә туры килсә, Сөмбеләнең күзләреннән яшь бөртеге тибеп чыга. Әле дә ярый күз төпләрен сөртеп алу урамда узган-барганнарның игътибарын җәлеп итми, болытлар сыегайган чактагы күз ачкысыз яктылык бик күпләрнең күзлеген салдырта, кулларына кульяулык тоттыра.

«Бәхетле» супермаркетының икенче катында затлы киемнәр бүлеге ачканнар. Кесәдә акча юклыкны бик сиздермичә генә карап чыгарга кирәк дигән уй күптән тынгы бирми иде инде. «Сим-Сим, ач ишекне!» дип әйткәнне дә көтмәде, Сөмбеләне күреп алу белән пыяла дивар, уртага аерылгандай, ачылып китте. Эчке ыгы-зыгысы белән базар күренешен хәтерләтсә дә, бу кибеттә байлар тынлыгы – кычкырып сөйләшүче юк, бәхәсләшмиләр, зарланмыйлар, адашкан иптәшләрен тавышланып эзләмиләр.

Икенче катка күтәрелү өчен, Сөмбелә, үз кадерен белеп кенә, пыяла лифтны көтеп алырга булды. Күреп ияләнгән нәрсә булмагач, кызыксыну дигән үҗәтлек күзне гел лифтка ияртә. Әкәмәт җайланма инде, билләһи – үтә күренмәле алагаем торба эчендә дүрт кеше сыярдай пыяла банка, гигант пешкәк сыман, аска-өскә йөреп тора. Кем төшкәне-менгәне, кулына ни тотканы – барысы күз алдында, хәтта сатып алган малларын да үтә күренмәле сумкага салганнар.

Идән белән тигезләшә дигәндә генә, Сөмбелә пыяла лифт эчендә Венераны күреп алды һәм, аның белән күзгә-күз очрашмас өчен, янәшәдәге кара гранит баскычтан өскә йөгерде... Җитешмәгән җире юк примадонnаның... Әллә кай арада яңалыкны эзләп таба, һәр ачышка башкалардан алдан барып өлгерә, кем әйтмешли, соңгы җөйне төенләп бетергәнен дә көтмичә, модельерларның кулыннан тартып алып өр-яңа үрнәкләргә төренеп сәхнәгә дә чыгып өлгерә. Көрәш девизын яшермәс: «Һәрбер «ноу-хау» минеке булырга тиеш: эксклюзив күлмәк, радио-телеаппаратура, яңа җыр, машина, затлы фатир, мактаулы исем!» – дияр ул... Менә хәзер дә кара-каршы очрашсалармы?! Венера, үзенең каядыр ашыгуына да карамыйча, Сөмбеләгә ияреп тагын пыяла лифтка керер, Алман коллекциясе бүлегеннән күлмәк сайларга булышыр һәм, шуларның берсен яучылап, мактый-мактый, барыбер сатып алырга мәҗбүр итәр, акчасы җитмәсә, әҗәткә биреп торыр, артык кыйммәткә төшсә, кредитка кәгазьләр тутырырга булышыр.

Казан базарының борынгы бабасы – Печән базары, атасы – «колхоз», урта буыны – «толчок», бүгенгесе – «Вьетнам базары»... Сатучылары куштан, үлчәүләре ялгыш, ярлыклары ялганчы, эксклюзивлары – игезәкле... Сөмбелә, артык сайланып, Венераның үтә күренмәле сумкасындагы кебек үк күлмәк сорап алырга мөмкин. Ә пардан киенеп, икең дә бертөрле күлмәк белән чыгу эстрада җырчысының йолдызын кечерәйтә, сәхнәне «Вьетнам базары»на әйләндерә...

Сөмбелә кием-салымнар бүлегенә керүнең кызыгын тапмады, әле яңа гына Венера сайланып йөргән күлмәкләргә гыйшыгы сүнгәндәй булды. Чыгып китәргә ашыкмады. Кафетерийдан бер чокыр сөтле каһвә белән пицца кисәге алып, мансард тәрәзәсенә терәп куелган өстәл артына килеп утырды. Үзенчә,

тагын танышлар очрамагае дипме, кибет эчендәге баягы сатып алучыларның яңалары белән алышынып беткәнен көтте...

Гадәттә, август тамашачысын ярата торган Азамат, ни хикмәттер, Нәүрүз көннәренә туры китереп, ике концерт куярга теләгән. «Ник? Ни өчен? Нәрсә булган? Әллә, Ходаем, быел җәйге концертлары булмый микән?!» дигән сорауларга җавап таба алмаган халык Камал театрына агыла. Азаматның ни уйлаганын, ниләр майтарганын Азамат үзе дә белми, диләр... Маҗараларны уйлап чыгара тора егет: йә ул үз исемен язып Казан күгенә дирижабль күтәрә, йә Татарстан урамының бер ярыннан икенче ярына концерт көннәрен күрсәтеп транспарант тарттыра; Пушкин урамы чатына, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты тәрәзәсеннән күренерлек итеп биш катлы өй хәтлек фоторәсемен элеп куя; дүртәр конферансье катнашында театральләшкән концертлар сәхнәләштерә башлый; үзе турында тузга язмаган гайбәтләр тарата да, пресс-конференцияләр үткәреп, шул гайбәтләргә ышанган хәбәрчеләр алдында үзе җавап тота... һәм Азамат булырга теләгән башка җырчылар Агыйделнең аръягыннан килгән егетнең бөтен яңалыгын кабатларга тотына. Инде кыланышларын куып тоталар дигәндә генә, Азамат, түрәләр тарантасына утырып, автораллига чыгып кача.

Мин-минлеген җиңә алган җырчылар Азаматның яңалыкларын сәхнә артыннан түгел, билет сатып алып тамаша залында утырып карый, ә риялылар, үз горурлыкларын җиңә алмыйча, коридорларда өерелә.

Сөмбелә театрның хезмәткәрләр ишеге аша үткәндә, сакта торучы агайларның икесе дә баш иеп сәламләде. Алар: «Чакыру билетыгыз бармы?» – дип сорарга кыймадылар. Бу хәл кызыйның кыюлыгын арттырды.

– Азамат подвалда, унөченче бункерда ял итәме? – диде ул, батыраеп.

– Әйе, – диде сактагылар, – тик ул борчымаска кушты, бераз ял итә.

– Хатыны җиденче гримерныйдамы?

– Әйе, әйе, шунда менегез...

Грим бүлмәләрен тезеп торучы коридорның ял почмагы бар. Теләгән кеше, йомшак диванга чумып, телевизор карый, вакыты иркенрәкләре өслеге паркет идәнгә охшаган киң мәйданлы өстәлдә, балбал чаклы фигураларны күчергәләп, шахмат уйный. Бүген бу почмакта басып торырлык та буш урын юк. Сөмбелә, биючеләр янында чишенеп, бик эшлекле кыяфәт белән уты сүнгән сәхнәгә ашыкты. Аяк астында сайгакларга тишеп куелган сүрән лампалар, якты сукмак булып, фойега алып чыга иде.

Театр тамашачысы алданрак йөри.

Күңел ачу сарайларында, концерт башланып яртышар сәгать үткәч тә, килеп ишек шакучылар табыла. Ике-өч җырын тыңласаң, җырчының кем икәнен белеп була, бардым, күрдем, белдем өченгә шул җитә, дип яңалыктан яңалыкка йөрүчеләр бар әле. Шуңа күрә дә бикләнергә ашыкмыйлар, тамаша залы белән фойе арасына бармак калынлыгы гобеленнан ике канатлы чаршау элеп куялар.

Ә театрның кануннары кырыс. Өченче кыңгыраудан соң спектакль бикләнә, тамашачы, өлешенә тигән кәнәфигә сеңеп, сәхнә дигән серле дөньядан яңгыраячак беренче авазны, артистлар теле белән әйткәндә – беренче фразаны көтә. Әнә шул беренче җөмләне ишетми калган тамашачы спектакльне тулаем аңлый алмыйча үзенә-үзе рәнҗеп кайтырга мөмкин. Менә шуңа күрә өченче кыңгыраудан соң хәтта драматург авторың үзе килсә дә, ачылмаска тиеш ул ишек.

Концерт башланырга ярты сәгать чамасы вакыт бар. Киләсе тамашачы инде килеп беткән. Дивар тирәли тезелеп баскан сәүдә рәтендә нәзакәтле ыгы-зыгы. Кем җыр сата, кем дини китапларны кодалый, тәм-том, халык һөнәрчеләренең бизәкле товарлары, ике буфет, кем әйтмешли, кулга-кул тотынып баскан. Фойедагы татар дөньясы, киртә эчендә калгандай, әле бер, әле икенче сәүдә сәкесенә килеп сарыла.

Сөмбелә, кемнедер эзләгән кыяфәт чыгарып, төркем араларында тизрәк йөрергә тырышты, танып дәшкән кешеләрнең «...месез?!» дигәне генә ишетелеп калды. Һәр исәнләшкәне белән тукталып күрешә башласаң, ялыгып бетәрсең. Һәммәсенең дә сорау-йөдәтүләре бертөрле:

«Бу араларда сине никтер телевизордан күрсәтмиләр?!»

«Кызыңның җырчы буласы килми, ди, ахрысы?..»

«Азамат кебек, Камал театрында да концертлар куярга вакыт инде сиңа».

Мондый сораулардан: «Әйе, әйе, әйе...» – дип кенә котыла алмыйсың, халыкка иркенләп, эчкерсез, кинаясез, төшенерлек итеп аңлатырга кирәк.

Әйе, телевизордан сатыла торган чагы үткән инде Сөмбеләнең. Продюсерлар үзәгенә барып, мескенләнә-мескенләнә контракт төзеп йөрергә әллә ул күзе ачылмаган өйрәнчекме?!

Кызының язмышына күрәзәче булыр хәле юк Сөмбеләнең. Әйе, дөресе шул – Зәйтүнәнең җырчы булуын һич теләми ул. Ләкин Сөмбелә үзе дә әти-әнисенең ай-ваена карамады, хыялына буйсынды. Табигать бүләк иткән моңны алкышлардан яшереп саклыйм димә. Сәләтле балага «юк, ярамый, кирәкми!» дигән саен ул ныграк киреләнә. Әйе, бүгенге көндә сәхнәгә ыргылу популярлык өчен буш көрәш кенә булып кала. Ул популярлык байлык белән ныгытылмаган. Иҗат төркемнәре эреле-ваклы АО, ОАО, ОООларга ялланып кәсеп итәргә, юбилейларга, бәйрәмнәргә һәм ачылу тантаналарына

чакырганнарын көтеп, билгесезлектә көн күрергә тиеш. Вак-вак ханлыкларга бүленгән зур илнең бөтен байлыгы җитәкчеләр һәм җинаятьчеләр кулына күчте. Җыр яраткан, китап сөйгән, спектакльләргә ышана торган халык өлешсез калды. Бүгенге тамашачы көйсез, иркә, ялкау. Концертлар белән алгысытып өеннән чыгарыр өчен, аны рекламалар белән юмалап, гәҗитләрдә алдалап, гайбәтләр белән соклandырып, төшләренә кереп чакырырга кирәк. Сөймәгән җырчысына, билетын бушлай өләшсәләр дә, йөрми халык. Ә Азаматка дигәндә, килә...

Азамат феноменын аңлар өчен Башкортстанда туып, Татарстанны сагынып яшәргә; җырчы булырга ашыкмыйча, әүвәл үзешчән төркемнәрдә конферансье рәвешендә шомарып сүз магиясенә өйрәнергә, Чаллыдан торып Казан тамашачысын яуларга, сәхнәгә чыгасы чыраеңны кызганмыйча машиналарда яньчелергә, осталык белән хулиганлыкның уртасында яши белергә кирәк. Азаматның һәр фигыле – матбугатта, һәр җыры – машинада, төркемендәге һәр артисты кеше телендә, бүләккә тигән һәр ядкәре һәм һәр уенчыгы Камал театры музеенда. Ул музейга эләгер өчен электрон сак куелган катлы-катлы ишекләрне ачасы юк. Идәннән түшәмгә чаклы калыккан тоташ тәрәзәләр диварына терәлгән пыяла музей ул. Кояш баешында, тамашачылар җыелгач, шәфәкъ нурлары кызылсу алтынга маныла да, Камал театрының икенче ягыннан чагылып, нәкъ Азамат музееның пыяла шүрлегендәге хәзинәләре аша фойега килеп керә... Бу музей гомер буе шушы театр сәхнәсендә эшләп-яшәп картайган халык артистларына да тәтемәгән үксез сөенеч һәм шул ук вакытта камаллыларның үз артистына әверелгән эстрада җырчысы Азамат тудырган, кырык елсыз чишелмәслек олы сер иде.

Сөмбелә фойеда сыенып торырлык буш урын тапмады, кире китте. Сәхнә артында аңа иң беренче очраган кеше әле узган атнада гына Финляндиядән спорт костюмы киеп кайткан композитор Хәсән булды.

– Син дә катнашасың мәллә? – дип чатябышты ул Сөмбеләгә, яңалыкларга сусап килгәнен яшермичә.

– Юк, – диде Сөмбелә, юмагайланып, – Азаматның берәр җырын чәлдереп булмас микән дип йөрүем.

– Ышандым ди... Сиңа Зәлия җырларын чәлдерергә кирәк, тембрларыгыз бер...

– Ә син үзең нишләп йөрисең сәхнә артында? Автограф алырга дип килмәгәнсеңдер ич?

– Мать, ну ты сказанула! Между прочим, ул мине үзе чакырды. Партердан ике урын бирде. Ышанмасаң, менә кара, җиденче рәттән, – дип, Хәсән спортивка кесәсеннән җырчының сурәте басылган ялтыравык билет чыгарып күрсәтте.

– Ничек җиденче рәттән?! Vip-liter түгелме соң ул?!

– Ато белмисең инде. Җитәкчеләр белән телевидение икенче көнгә генә чакырыла. Концертның беренче көне генераль репетиция генә бит ул. Без – авторлар өчен...

– Алайса тыңларга дип килдең?

– А как же! Үзен хөрмәт иткән любой артист һәр яңа программаны карап барырга тиеш. Ну, минем особый случай, ел саен аңа ике-өч яңа җыр өлгертеп торам. Почти бөтен шлягерлары да минеке...

– Ә Фирзәр белән үпкәләшкәннәрме?

– Фирзәр хәзер семейный подряд белән эшли. Шлягерлары үз гаиләсеннән артмый... Ә синең бригадаң исәнме?

– Чабата Зәлияләргә күчте. Калганнары чакырганымны көтеп тик ята.

– Да, хәзер төркем асрау не выгодно. Әллә нигә бер буласы концерт өчен аларның гаиләсен кайгыртып, исерекләрен көйләп, фатирларын ипләп йөгерә торгач, үзең өчен вакыт та калмый.

– «Без һәрвакыт әзер!» дип, чакырганда ялындырмыйча килә торган үзеңнең даими төркемең булуы ышанычлырак түгелме соң?

– Да ты че, Сөмбелә! Хәзер буш җырчылар бихисап, күпме төркем таркалды. Теләсә кайсысына сызгыр гына – минут эчендә йөгереп килеп җитә. Артистлар күбәйгән саен, бүгенгечә концерт оештырырдай чын администраторлар азая. Чабатаны зрә ычкындыргансың, кыен җирдә җыен оештыра ала торган чи каешлы чабата иде ул.

– Миннән торамыни?! Чабата акча исен өч мең чакрымнан тоя. Зәлия белән Зөфәр кассовый җырчылар шул, халык егылып йөри үзләренә. Ә мин инде икенче сортлы җырчы, бәям төшеп бара. Сиңа рәхәт, син – автор. Җырлар язасың да иң отышлысын үзең әйләндерәсең. Әйбәт шлягер үлгән җырчыны да торгыза.

Сөмбеләнең мактаулы саламыннан соң Хәсәннең салпы ягы хәйран турайды, үзе дә сизмәстән, әңгәмәдәшенә яхшылык эшлисе килеп китте бугай.

– Слушай, мать! Мин сине эзли идем әле... – дигән булды ул. – Син бу җомга көнне бушмы? Бер спирт магнатының түгәрәк бәйрәменә чакыру бар.

– Әйбәт түләсәләр, көне буш булыр! – диде Сөмбелә, бу арада эшсез ятканын артык сиздермәскә теләп. – Акчасын шундук түлиләрме, әллә күчерү юлы беләнме?

– Шул кичне үк, «Сарман» кафесы түли. Минем анда, ачуым килмәгәе, йөз кат чыгыш ясаганым бар инде, кем әйтмешли, ул залда прописката торабыз. Кунаклар солидный, урыны аулак, артистлар күп...

Хәзер пролетар җырчыларның өерләргә берләшә торган чагы. Так што, чакырган кеше сискәнмәслек итеп кенә бәяңне әйт тә, киттем, юкса өченче звонок булды, әнә концерт башлана. Минем әле ул җомга көн ашына синең кебек тагын ун кеше җыясым бар.

Һәм Хәсән, сул кулы белән күкрәк читлегенең йөрәк турысын угалап, сәхнә артындагы караңгылыкка кереп чумды. Сөмбелә аңа сокланып та, шикләнеп тә һәм шул ук вакытта кызганып та карап калды... Егет үзен бер дә иркәләп тормый, туктаусыз юлда, сәхнәдә, көрәштә. Кайдан шулчаклы көч табып җиткерә дә кайчан өлгерәдер. Соңгы унбиш ел эчендә татар эстрадасы өчен иң күп җыр язган кеше ул. «Йолдызлар фабрикасы»ның Казан филиалын да ул оештырды. Төмән өлкәсенә бер вагон кунак төяп килеп татар әдәбияты һәм сәнгать көннәре үткәрүче дә Хәсән. Мәскәүнең симез борынлы оештыручылары белән уртак тел табып, авторлар хокукын саклаучы бүлекчә ачу буенча да тәки җиңүгә ирешә. Концерт залларының берсендә сәнгать җитәкчесе булып эшләргә дә өлгерә... Шәһәр эчендә ике катлы коттедж салып чыкты, хатыны белән икесенә ике иномаркасы бар, ике бала үстерәләр... Самосырово чокырыннан илле чакрымдагы бер караңгы авылдан нинди якты шәхес чыкты!..

Кызгану белән соклану хисен тиз арада алыштырып Сөмбеләне шикләнү дигән җан кимергеч халәт биләп алды. Моңарчы Хәсән Сөмбеләне үзенә ияртми иде. Түрәләр мәҗлесенә әйдәләве дә сәер, анда, мөгаен, калын кесәле агайлар җыеладыр. Үзенә даими ярдәм итә торган иганәчеләрне, меценат-спонсорларны күрәләтә башка җырчылар алдында фаш итүнең ахыры ике яклы. Артист халкының күргән нәрсәне сорый торган гадәте бар. Ярдәмчел куллы, текә холыклы, сүзе үтәрдәй абруйлы дусларының берәрсен Сөмбелә үз ягына авыштырып куйса, Хәсәнең нишләр?! Әйтик, Төмәннең күренекле меценаты – доктор Шакиров – биш ел буе аның иң якын дусты иде... «Утлар яна учакта»ны җырлап кайт әле, дип, Зөһрәне Төмән филармониясенең мең урынлы концерт залына алып килгән иде... Хәзер әнә доктор Шакиров Зөһрәләрнең гаилә дусты... Хәсәнгә Себер якларыннан салкын сәламнәре генә килә.

Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер дигәндәй, Сөмбеләнең күңелендә һаман шөбһә томаны: «Миңа түлисе гонорарга ул ким дигәндә биш студент кызны җырлата алыр иде. Хәсән үз кесәсенә зыянга эшли торганнардан түгел, аның һәр уе, һәр фигыле, һәр шөгыле табышлы. Нәкъ менә мине чакыруында ниндидер әйтелеп бетмәгән хикмәте бардыр аның. Мәгәр мин ул халтурага барам!..»

Хәсән җырчылар язмышын һәйбәт үк белә – «Сарман» кафесы Сөмбелә өчен юк-бар урын түгел.

Моннан биш ел элек тә нәкъ шушындый март ае иде... Сөмбеләне бәйрәмгә Нәүрүзбикә итеп чакырдылар. Ә гармунчы Марат Гомәргә Уңышнур булып киенергә туры килде. Концерт азагында барлык катнашучылар сәхнә түренә тезелешеп бастылар да бертавыштан: «Нәүрүз мөбарәкбад!» – дип кычкырдылар.

Күпертмә җиңле озын яшел күлмәк, чәчәкле-чуклы такыя кигән Сөмбелә белән уңдырышлы туфрак төсендәге чем-кара кәчтүменең түш кесәсенә биш башак кадаган баянчы Марат Гомәр икесе ике яктан чыгып уртага бастылар. Нәүрүзбикәдән башка яши алмый торган Уңышнур «Яз шатлыгы» көен уйный башлауга, тамашачы аягүрә басып кул чабарга кереште, җыр тәмамланганчы туктаусыз алкышлап, әйтерсең лә язны каршылады...

Бу күренешне яздырып шул көнне үк кичке яңалыклар программасыннан күрсәттеләр. Иртәгесен «Ватаным Татарстан» гәҗитенең беренче битенә зур сурәт итеп урнаштырдылар... Өченче көнне шунда ук некролог чыкты...

Нәүрүз пәрдәсе ябылып, таралышырга рөхсәт ителгәч, Марат Гомәр, баянын иңеннән алмыйча гына, Сөмбеләнең юлына аркылы төште.

– «Сарман» кафесына керик әле, ашыкмыйк әле бүген.

– Нәрсә булды сиңа? Беләсең ич, Зәйтүнә өйдә үзе генә калды. Кафега көндез иркенләп барып килербез.

– Зур кыз инде ул, түзәр... Синең белән бик җитди итеп сөйләшәсе сүз бар.

Сөмбелә сагая төште: «Әллә дәваланырга тәвәккәллиме егетебез?»

– Ярар. Киемнәрне алыштыргач, вахтер янында очрашырбыз. Баяныңны аласыңмы?

– Юк. Грим бүлмәсендә калдырам. Монда әйбергә тимиләр. Иртәгә килеп алырмын әле. Безнең бүген җырлап сөйләшә торган сүз түгел.

Марат Гомәрнең уйнаган җирендә баянын калдырып китүе туй булган җирдә юри бүрек онытып китү ише генә: икенче көнне махмырдан эзләнеп килер өчен.

«Сарман» кафесы Мөштәри урамының аулак бер ишегалдына урнашкан. Ул Язучылар берлеге, Актерлар йорты, Рәссамнар фонды, Композиторлар союзы, филармония, радио, Драма һәм комедия театры кебек яңгыравык оешмаларның үзәгендә тора. Шагыйрьләрне йә артистларны тере килеш күрәсең килсә, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында рәхим ит, кафеның йорт иясенә әверелгән шәхесләр көтеп утыра сине. Марат Гомәр монда бик хөрмәтле кунак, кайчан керсә дә аны: «О-о! Назлы-сазлы дустыбыз килде!» – дип, ихластан сөенеп каршы алалар, ярышып-ярышып сыйларга керешәләр.

Сөмбеләне култыклап килеп керүен бик өнәмәделәр, бу кафеда хатын-кыз затына ияләнелмәгән, гармунчы белән җырчыны кул изәп кенә сәламләделәр. «Йорт ияләре» быел Тукай премиясенә кемнәр лаек дигән аптыраштан шултиклем ярсып бәхәсләшәләр иде ки, хәтта зал түрендәге аерым өстәл артында кычкырып сөйләшсәң дә, әңгәмәдәшеңне чак кына ишетерлек.

Өстәлгә яшел кыяр салаты килү белән, гармунчы, челләдә җәяү кайтып әлсерәгән юлчы кебек кабаланып, бер бокалны су урынына түнтәреп куйды. Пычак калынлыгы телемнәре арасыннан кыяр төбен сайлап, тирән итеп иснәде дә киредән тәлинкә читенә куйды. Һәм бокалларны яңадан тутырды.

– Әйдә, берәрне күтәрик әле!

– Нәрсә, дустым, рюмкаларыңны санап утырыр өчен алып килдеңме мине монда? Егерме ел буе саный-саный исәбен югалттым инде.

– Вакланма әле, Сөмбелә. Телисеңме, бу графинны әнә тегеләргә илтеп бирәм.

– Һаваланма, зинһар. Ник чакырдың?

– Бер рюмка җиффәр, аннан әйтәм.

– Аек баштан сөйләшә торган сүз түгелмени?

– Оялам.

– Миннәнме? Гомердә булмаганны.

– Гомердә булмаган – Гомәрдә бар. Шутка... Сөмбелә, әйдә мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерик.

– Нотариус аркылымы? – дигән булды Сөмбелә, гармунчының тел төбен аңламаганга сабышып.

– Загс аркылы. Өйләнешик әйдә...

Әллә өйләнешү турында сүз башлады гармунчы, әллә һава торышын тәфсилли – Сөмбеләнең чыраенда һич дулкынлану әсәре сизелми, кеше язмышын тамырдан үзгәртердәй тәкъдимне күптәнге таныш шигырь ише генә кабул итте.

– Хатыныңны кая куясың?

– Беләсең лә. Сине очратканда, мин гаиләдән киткән идем инде. Кызымны ярдәмемнән ташламам.

– Әйе. Унбиш ел буе паспортыңда тамгасын йөрттең, рәсми төстә аерылмадың. Хатының кичерер дә кире кайтырга рөхсәт итәр дип өметләнеп яшәдең... Ә мин бу сөйләшүне бик күптән үк көткән идем. Яшермим, яшьлек җүләрлегем белән кеше көлдерерлек батырлыкларга әзер идем. Соң инде, хәзер акыл керде – мин бит синең гармуныңа гына гашыйк булганмын икән.

– Гармуннан бала тумый.

– Җыр туган җирдә бала да туа ул.

– Вәт. Бер кызымны ташлап китәм, икенчесенә киләм.

– Нәрсә, Зәйтүнәне синнән дип уйлыйсыңмы әллә?

– Уйламыйм, беләм.

– Мин сиңа күпме әйттем: Зәйтүнәнең әтисе Идрис исемле. Яшьләй сөйгән ярымнан. Кызым – Идрисовна! Маратовна түгел... – Ул, кайда утырганын кинәт исенә төшереп, тегеләр төркеменә карап куйды. Шөкер, ишетмиләр икән.

Гармунчы Сөмбеләнең кызып-кызып ялганлавына сүзсез, елмаеп кына җавап бирде.

Сөмбелә әлеге аңлашуны күңелсез халәттә төгәлләргә теләмәде, бергә-бергә эшлиселәр бар бит әле.

– Әгәр менә бу шөгылеңнән котылсаң – бөтенләй ташласаң, бәлки, ризалашырмын да. Юкса икәүләшеп эчәргә туры килер, сиңа азрак эләксен дип...

– Ташлыйм. Бүген мин аракы белән бәхилләшәм, әйткән иде диярсең. Иртәгәдән баш төзәтмим – и бетте-китте. Врачка бармыйм, үзем җиңәм. Дәваланып караучылар күп булды... берсе-бер исән түгел... Урыннары оҗмахтадыр.

– Күңелеңә авыр алма, моңарчы сораганым юк иде, әйт әле, зинһар, ник шулхәтле эчәсең син? Бөтен дусларыңны югалтып бетердең. Бу кафе санитарларына таянма, ышанычлы багана түгел алар.

– Алайга китсә, башкаларны тикшермә, үзеңне бел. Һәр барган җиреңдә берәр җитәкчене югалтып кайтасың. Спонсорлар турында әйткән дә юк. Исерек айныгач кеше була ул. Ә син аек килеш телеңне тыя алмыйсың. Җыр ярата торган лидерлар бар чагында, җәелеп эшләп калырга кирәк. Сәясәт гел шушылай Мәскәүдән күчә торса, килер бер көн, татар кәнәфиләрен маңкортлар яулап алыр. Ярый да пенсиягә чыгып өлгерсәк.

– Ә яшьләр нишли?

– Яшьләр акчалылар кулында уенчык була белә. Алар өчен борчыласы юк.

– Сүзне кирегә бордың. Алайса, синең туктаусыз эчүеңә мин генә гаепле? Минем аркада «Наз»ны тараттың, мактаулы исем алалмавыңа да мин гаепле.

– Әйдә, тартып керик әле.

– Әнә бит «йорт ияләре» өстәл артында гына пыскыта.

– Чыгып сөйләшик.

Баскыч төбенә чыккач, ул рәшәткәләп кагылган урам эскәмиясенә утырырга кушты. Тәмәкенең бөтен төтенен берьюлы сыйдырырга теләгәндәй бик тирәнгә сулыш алды. Тончыкмады, йөткермәде, тамак кырмады.

– Ышанмасаң, сорый аласың, әнә Илһам абый белән Әлфия апа ялганларга ирек бирмәс, мин утыз биш яшемә чаклы бер грамм хәмер капмадым. Исерекләр күрсәм, җенем котыра иде хәтта!

– Балантауга Гөлҗиһан апа белән кайткан мәлне кибет тирәсендә йөргәләдең лә, «сухой закон» дип тормадың...

– Ул чагында кырык тулган иде инде миңа...

– Биш еллык «стажың» булган алайса.

– Уенга бормыйча гына тыңла. Аңласаң – тыңларсың, тыңлыйсың килмәсә – бүлдерерсең... Безнең «Наз» төркеме оешуга ун ел тулган көннәр иде, рәхмәт, «Халык ансамбле» исеме бирделәр. Яшермим, состав бик көчле иде, мин кызларны җыр укытучылары, музыкаль студия педагоглары арасыннан җыйдым. Башка ансамбльләр студентлардан оеша торган иде: беренче курста укучылар килеп кушыла, диплом алганнары китеп бара, состав гел алышына, яшәрә – ләкин бишәр ел буе түгелгән хезмәт әрәм була. Безнең «Наз»ның составы егерме ел буе үзгәрмәде – егерме ел буе чарландылар, өйрәнделәр, шомардылар, кызларның башкару осталыгы әнә шуннан килә... Ул елларда унҗиде мең һәвәскәр иҗат коллективы бар иде, ил буйлап санаганда аларда өч йөз егерме мең кеше җырлап йөргән дигән сүз! Мин моны төгәл беләм, «Агитатор блокноты»ннан укырга мәҗбүр иттеләр.

– Лекция укыргамы?

– Юк. Мәскәүдә үтәчәк «Халык иҗаты» фестивалендә катнашыр өчен. Татарстаннан ике коллективны сайлап алдылар. Берсе – Актанышның «Агыйдел» бию ансамбле иде бугай. Икенчесе – безнең «Наз»...

– Һәм син сөенечтән эчә башладың, әйеме?

– Эчәрсең, бар... Иртән обкомның культура бүлегенә чакырталар, кичен репетициягә КГБ офицеры үзе килә. Җыр текстларын тикшерәләр, үгет-нәсихәт бирәләр, әдәпкә өйрәтәләр.

– Мәскәү чит ил түгел ич инде, ул хәтлек бәйләнмәсәләр.

– Анысы башка мәсьәлә... фестиваль лауреатлары Кремльнең Съездлар сараенда йомгаклау Концерты белән чыгыш ясарга тиешләр икән, СССРның дүртенче конституциясен кабул итү уңаеннан җыелган депутатлар каршында. Әлбәттә, безнең җиңәсебезгә шикләнүче юк, шуңа күрә дә зур сәхнәгә ныклап әзерләделәр. Чит илләргә чыкканда да ансамбль репертуарына шултиклем бәйләнми торганнар иде.

– Берәр хикмәте булгандыр.

– Хикмәте шул, мең ике йөз делегат арасында Л.И.Брежнев та бар иде. «Татарстан таңнары» дигән җырны ничек башкарганыбызны хәтерләмим, ник дисәң, мин, баянлы дирижер буларак, залга кырын баскан идем, күбрәк делегатларга елмайганмындыр. Дирижерлык канунын үзгәртеп, тыңлаучыларга арка белән торырга рөхсәт итмәделәр... Берзаман, җырлап бетерүебез булды...

– Ак баяныңның каешы шартлап өзелде...

– Сиңа көлке... Съездлар сарае бер мәлгә тып-тын калды... Уникe кыз миңа карап өнсез тора. Әйтәм ич, күп булса, нибарысы күке өчкә хәтлек санарлык вакыт үткәндер... куркудан хәлемне үзем генә беләм. Шул вакыт КПССның Генераль секретаре, СССР Верховный Советы председателе, Советлар Союзы Маршалы Леонид Ильич Брежнев аягүрә басып кул чаба башлады. Әйтерсең лә державаның Беренче Дирижеры таякчыгын югары күтәрде – шуны гына көткәндәй, мең ике йөз музыка коралы Аңа буйсынды, зал тигез ритмлы алкышларга күмелде. Бу турыда бөтен ил буйлап сиксәнгә якын язма басылып чыкты. Ул гәҗит-журналлар завод клубы адресына ай буе килеп торды... Йә, горурланырга, мактанырга хакым бар идеме минем моның белән? Минем «Наз» бит ул! Бөтен Казан буйлап сибелгән сәләтле кызларны эзләп тапкан, төркемгә җыйган, җырлар язган, репертуар ясаган, онытылган җырларны заманча яңгырашлы итеп партияләргә бүлгән, дүрт тавышлы вокаль ансамбль төзегән, мин бит ул! Мин барында ансамбль бар, мин юк икән – алар да юк!

– Йә, йә, кычкырып мактанма, мин ишеткәч бик җиткән. Димәк, син сөенечне, җиңүләрне, уңышны күтәрә алмадың?

– Нинди уңыш?! Җиңү шатлыгы сүрелгәнче дип завод клубы исеменнән Мәдәният министрлыгына хат яздык. Наградной лист тутырдылар, «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем сорап.

– Калганын беләм. Синең исемең юк ич.

– Ник булмасын, бар.

– Бер дә әйткәнең юк.

– Нәрсәсен әйтәсең инде аның... Мин хыялланган зурлау чәлпәрәмә килде. Теге, авыл клубында эшләүче китапханәчеләргә, киномеханикларга өләшә торган «Мәдәният хезмәткәре»н тоттырдылар.

– Ник алай кимсеттеләр икән? Бәлки, Мәскәү Кремленнән кайткан горурлык белән үзебезнең Кремль тирәсендәгеләргә катырак сүз әйткәнсеңдер?

– Әйтмәдем. Хәзергәчә әйтәсем юк, эчемдә яна гына... Мин дипломлы баянчы түгел бит, үзешчәннәр исемлегендә йөрим. Теләсә кайсы профессиональ җырчы белән гастрольгә чыгарга ярыйм... Ә артист исеме алырга хакым юк. Нотага карамыйча урам көе уйный алмастай дипломлылар

атказанган артист булып йөри, ә мин партия номенклатурасының эчке циркулярына туры килмим. Коммунистлар властьтан төшкәч ничек сөенгәнемне күрсәң!..

– Перестройка башлангач, ул исемне яңадан сорап карыйсың булган.

– Кая инде хәзер... «Наз» таралды... «Гел исерек» дигән ярлык тагылган... Ну мин төзәләм. Иртәгәдән санаторийга китәм. Бүген шешә белән бәхилләшәм, сәрхушләр белән саубуллашам. Син бар, кайт. Мин кафега сугылып чыгам әле.

Гармунчы белән соңгы күрешү иде бу. Әгәр шушы сөйләшүнең азагы ни белән бетәсен сизенсәме, Сөмбелә аны урамнан керәсе килмәгән малай-шалай кебек итеп алдалап-юмалап уенынннан аерып, өенә алып китәр, Зәйтүнә белән икәүләшеп ашказанын юдырырлар, белгән кадәре ярдәм итәрләр, кирәксә, таныш врачны чакыртырлар иде. Ә инде Балантауга кайтып, әнисенә чүлмәк утырттырып коры сыра белән берәр атна дәваласаң, санаторийларың читтәрәк торсын кана...

Асыл ирләрне инсульт кыра...

## Уенчык әти

Яңа көн туды исә яңалык көтә хәзер Сөмбеләне.

Бүген аны телефон сыбызгысы куркытып уятты. Төнге уйларыннан тәмам изелеп, ниһаять, йокыга китеп өлгергән кебек кенә иде әле. Күзен ачкач бераз аңышмыйча ятты, өйдә сыбызгылар күп: кызы плитәгә куйган чәйнек борынын сызгыртамы, сумка кесәсендә калган мобильникмы, домофонныкымы, әллә будильник өзгәләнәме? Шәһәр челтәре белән тоташкан радиотелефон сыбызгысы икән, ул әле өй эчендә яңа техника, тавышына һаман иялəшә алмыйлар. Иртүк килгән хәбәр юньлегә булмас, тизрәк җавап бирергә кирәк дигән уй белән юрган эченнән чыгу уңаена стенадагы сәгатькә күз салса – йа Хода, өйлә вакыты җиткән ләбаса! Көн белән төн буталган... Зәйтүнәнең укырга киткәнен дә сизми калган... Телефоннан уятучы да улдыр, берәр конспекты онытылгандыр да шуны китереп китәргә кушадыр.

Телевизор караучылар бик тиз танырлык ягымлы кыз тавышы иде телефонда.

– Сөмбелә апа, исәнмесез!

– Исәнме, сеңлем. Телевизорым кабынып калган дип торам, тавышың телефонга күчкән икән.

– Күптәннән бирле эзлим инде мин сезне, һич өегездә туры китерә алмыйм.

– Җырчылар сайрар кош кебек – күчмә халык бит инде ул. Өйдә тик ятсаң берәү дә китереп бирмәс. Акча бик тирәндә хәзер, сеңлем, еракка барып аласы.

– Сөмбелә апа, бер-ике соравыма тамашачылар өчен кызыграк итеп җавап бирә алмассыз микән?

– Кызыклы җавап ишетәсең килсә, сорауларыңны кызыграк итеп бир әле, сеңлем.

– Сез бәхетле кешеме?

– Бәхетле җырчының моңы булмый, сеңлем.

– Үзегезне кичәге җырчы дип саныйсызмы, әллә бүгенге җырчымы сез?

– Мине «җырчы халыкчан булырга тиеш» дип тәрбияләделәр. Бүген сәхнәнең беренче таләбе – сексапильность! Тән беренчел икән, җыр – икенчел, димәк.

– Кызыгыз Зәйтүнә үзегез кебек матур җырлыймы? Аны да җырчы итәргә исәбегез юкмы?

– Кошлар үз баласын сайрарга өйрәтми, очарга гына өйрәтә.

– Җырчыларны сайрар кошларга тиңләргә яратасыз икән, бүген бит без аларны эстрада йолдызлары дибез.

– Элек сандугачка тиңләү модада иде: Сарман сандугачы, Актаныш сандугачы, Арча сандугачы... Шуңа күрә дә сандугачларыбызга йолдыз авыруы йокмый.

– Йолдыз дип атасаң да, сандугач дисәң дә – барыбер шул җырчы инде ул.

– Барыбер түгел. Йолдызларны фабрикада шомарталар, ә сандугач – табигать баласы.

– Спонсорларыгыз күпме? Һәм сер димәсәгез, кемнәр алар?

– Сер түгел. Юк алар минем. Булмадылар да. Хәзерге яшьләр спонсорларны сөйдергеч ясатып әсир итәләр... Ә минем – тамашачым исән-сау булсын.

– Сезнең хакта никтер гәҗитләр бик сирәк яза.

– Артистның язмышы халык телендә.

– Клипларыгыз юк. Телевизорлардан күренмисез.

– Чакырмыйсыз ич, сеңлем.

– Вәт, вәт, Сөмбелә апа, мин сезне «Адәм белән Һава» тапшыруына чакырам. Сез бик фикерле әңгәмәдәш икәнсез. Чакырам дип әйтү бик үк төгәл булмас, өегезгә килеп төшерәбез. Проектның бөтен хикмәте дә шунда: йолдызларның, ягъни сандугачларның шәхси тормышын бик якыннан күрсәтәбез.

– Абау, сеңлем, төшереп күрсәтерлек әллә нәрсәм юк ич минем... Фатирым да кооператив бүлмә, җиһазларым да социализм чорыннан калган.

– Аеруча талантлы кешеләр генә гади тормышның тәмен белеп яши ала дип уйлыйм мин.

– Сеңлем, гади булып күренер өчен генә иске-москы бүлмәдә шоу ясый алмыйм инде.
– Бенефис алдыннан бушлай реклама кирәкмимени?
– Нинди бенефис?
– Миңа шулай дип әйтәләр.
– Ә-ә, бенефис! Әле аның афишасы басылмаган, кайсы залда үткәрәсем дә билгеле түгел... Аннан соң, ни бит, сеңлем, сезнең ул тапшыруыгыз парлылар турында, ә минем Адәмем юк бит...
– Сез ялгыз яшисезмени?
– Япа-ялгыз түгел, зур кызым бар.
Тапшыруга кодалаучы Сөмбеләнең төгәл фикерле төзек җөмләләреннән тәмам иләсләнде. Ул инде «Адәм белән Һава»ны оригиналь ток-шоу итәргә әзер иде, шуңа күрә җырчыны кулдан ычкындырырга һич теләмәде.
– Сөмбелә апа, балаларның җилдән тумаганын беләбез. Әйдәгез, этисен эзләп табыйк. Чакырыйк. Вәт интригалы, бик көчле тапшыру булыр иде бу!
– Сеңлем, кызымның этисе исән түгел инде.
– Танылган кешеме, Сөмбелә апа?
– А как же...
– Сер итеп кенә әйтегез, зинһар, кем ул?
– Пушкин! Гафу ит, сеңлем, өметегезне акламадым. Хушыгыз. Кияүгә чыксам, үзем эзләп табармын сезне.
Икенче көнне телевидениедән тагын шылтыраттылар. Бу юлысы «Киң күңел» редакциясеннән, Сөмбеләгә кунакка килеп, берәр тәмле ризык пешергәнен язып алырга телиләр икән. «Киң күңел»дән үзенең кухнясын күрсәтмичә бер Сөмбелә генә калгандыр инде, бөтен җырчы яраткан ашы белән мактанды. Ярты еллык эш планын начальство раслый, сезнең янга үз белдегебез белән килмибез, дип ышандырырга бик тырышсалар да, Сөмбелә ризалашмады. Җан тынычлыгы табардай соңгы сөенече – Зәйтүнәсенең сабыйлык авазлары сеңеп калган куышны гайбәт хөкеменә ыргытырга теләмәде.
Татарстан телевидениесе икегә бүленгәч, программалары үзара ярышка чыкты. Моңарчы күз алдына да китереп булмаган турыдан-туры элемтәләр, яшь тамашачылар өчен ток-шоулар, җыр бәйгеләре, бәйрәм трансляцияләре үтеп керде. Яңа дикторлар, яшь алып баручылар, еш алышына торган редакторлар, продюсер үзәкләре пәйда булды. Яшьләрнең Сөмбелә язмышындагы сикәлтәләрне белеп бетермәвенә гаҗәпләнәсе юк, алар эстраданы күбесенчә хит-парадлар, клиплар, шлягерлар, конкурслар, чамадан ашкан шәхси гәҗитләр аша гына белә. Бүген язылган җырлар зәңгәр экран яктылыгы белән, радиодулкыннар тизлеге белән тарала... Сөмбеләләр исә һәр тамашачыга күзгә-күз карап, тавыш таралу тизлеге белән, гармун моңында үсте.
Телефон аша сюрпризлар килә торды.
Инде тимер юл вокзалы каршындагы өч катлы ательедан шылтыраттылар һәм Сөмбеләне аяктан ега яздылар: «унмеңенче заказ» дигән акцияләре көтелә икән, ул бәхетле кешене Зәйтүнә итеп, бушлай күлмәк тегеп, прессаны чакыртып, зурлап бүләк итәргә телиләр. Ризалыкны тиз арада хәбәр итәр өчен телефоннарының номерын әйттеләр.
Шушы хәбәрдән соң Сөмбелә бенефисны ашыктырырга булды. Билгесезлектән эзләүгә караганда, эзәрлекләүченең үзенә ау кору җайлырак. Хәлиткеч вакыйгаларны ашыктырыйм дисәң, бенефис – иң кулай тамаша: дус-дошманың, көткәнең-куралмаганың, ихласың-мәкерең – бөтенесе җыела, сәхнә белән зал бергә кушыла, кичәге сөяксез җырчы бүген мактаулы чәчәккә күмелә... Моның өчен күп кирәкми: залыңны эзлә, арендасын түлә, афиша бастыр, чакыру билетлары эшләт, тамашачыңны җый, телевидение килерлек программа төзе, катнашучыларны барлап исемлек тутыр, банкетлык акча җый...
Яңа гына бенефис үткәргән җырчылар аңа шәп киңәш бирделәр, матди ярдәм эзләп мескенләнеп йөрмә, иң бай спонсор – хөкүмәт үзе, диделәр.
Артист кешенең хөкүмәте Мәдәният министрлыгы булыр, әүвәл аларның фикерен тыңлап карыйм, диде дә кабул итү көненә чиратка язылып кайтты Сөмбелә. Көне-сәгате җиткәнче күңеленнән генә министр ханымга әйтәсе сүзләрен кабатлады, җөмләләрен шомартты, вакыт-вакыт әрләшеп тә карады хәтта...
«Быелгы смета әллә кайчан расланган, өстәмә чыгымнар хакында сүз була алмый. Түгәрәк дата түгел, гади иҗат кичәсе өчен зурдан кубарга кирәкми. Солидный залларда үткәрер өчен мактаулы исемең юк. Наградной лист тутырсаң да, тиз генә өлгермәячәк, чират бик зур. Аннан соң, нинди исем бирәләр бит әле. Юбилейлар үткәрү бумга әверелде. Җырчы шагыйрәләр анда елына икешәр-өчәр бенефис үткәрәләр, ну акчаны үзләре эзлиләр, бюджет кесәсенә кермиләр...»
Сөмбелә, парта өстенә терсәген куйган мәктәп баласы кебек, кул күтәреп сүз сорады. Министр, мондый әрсезлектән аптырап, яңадан татарчага күчте:
– Әйе?!
– Бөтенләй үк бенефис түгел. Мин бу кичәне гармунчы Марат Гомәр истәлегенә багышларга телим. Афишада күрсәтмичә генә. Ул эшләгән завод клубына дусларын җыеп.

– Бик яхшы беләм Марат Гомәрне. Ләкин бит аның юбилее түгел.

– Арабыздан киткәненә ун ел булды.

– Ә сезгә кем соң ул Марат Гомәр?

Әйтергә ярамый торган җавап күзгә яшь булып тыгылды. Сөмбелә, мөмкин кадәр башын читкә борып, кульяулык белән күзләрен каплады.

– Сорамыйм, сорамыйм. Әйтергә ярамый икән, әйтмәгез. Барыбызның да яшь чагы булган.

Министр, туган апага әверелеп, тавышын йомшартты, телефоннан номер җыеп, ике касә чәй сорады. Бүлек кызлары кайсы кая йомыш белән таралганмы, чәйне бер егет кертте. Чәй йотып куйгач, баягы сорау бик ерагайганчы дигәндәй, Сөмбелә аклану рәвешендә әйтеп куйды:

– Минем гармунчым иде ул...

Үзенең эчәсе килмәсә дә, чәйне ике касә итеп иптәшкә генә сораткан иде министр. Сөмбелә эчкән арада, ул кара тышлы атналык көндәлеген ачып бер-ике җөмлә өстәде.

– Сез борчылмагыз. Премьер исеменә бүген үк өстәмә хат язып акча сорарбыз. Нәтиҗәсен лично үземә шылтыратып белешерсез. Бер атнадан.

Министрларның «кабинеты» дип тикмәгә генә аталмыйдыр, бу бина гаять зур кабинет рәвешендә салынган, бүлмәләрен саный китсәң, исәбенә чыкмалы түгел. Инде чыгып җиттем дигәндә, ишек төбенә дә кабинет ясап куйганнар, кителенең иңбашына «МВД России» дигән мөһер сугылган егет саф татар телендә: «Хушыгыз!» – дип калды. Ялыныч белән килгән китек күңел киребеткән уйлардан һич арына алмас, Сөмбелә «Хушыгыз!» дигән сүздән дә гаеп эзләп маташты, «бүтән килмәгез» мәгънәсендә бәхилләшеп әйтелә түгелме соң бу? «Сау булыгыз!» дияргә кирәктер, дөрес өйрәтмәгәннәр үзләрен...

Мәрмәр баскычлардан йөгереп төште ул, «Азатлык» мәйданында аны танырдай кешеләрнең очравы бик мөмкин, бенефисына акча соранып йөри иде димәсеннәр... Ленин һәйкәле янына җиткәч, никтер туктап калды. Ничәмә-ничә еллар шушы бакчада йөреп, пролетариат юлбашчысының йөзенә туры караганы юк икән әле Сөмбеләнең... Бактың исә, скульптор әлеге сынны киләчәк өчен коеп куйган – күрегез, әнә Владимир Ильичның күзләрендә реформаторларга карата нәфрәт, йөзендә яшь буын өчен борчылу... Хәер, һәйкәлләрнең елмаеп торганын күргәнебез юк әле... Һәйкәл тирәсендә күпме мәһабәт бина: Опера һәм балет театры, Ратушалар йорты, Зур концертлар залы, Министрлар Кабинеты, Дәүләт Советы, Милли Мәдәният үзәге... Ә Сөмбелә шәһәрнең җимерек йортлары арасында кысылып калган завод клубын сагынып йөри. Яшьлек еллары исенә төшкән саен, җиңү юлларын ныграк сагынган сугыш ветераны кебегрәк...

Бенефис көне якынлашкан саен, ыгы-зыгы арта барды. Соңгы унбиш ел эчендә лекцияләр, җыелышлар, киңәшмәләрдән гайре чаралар күрмәгән клубның урындыклары җимерелгән, пәрдәне ачып яба торган лебедкалары күгәргән, люстраларын тузан баскан, лампочкалары сукырайган иде.

Шәһәр буйлап көнаралаш диярлек йөреп, кемнәрдер сыдырып ташлаган афишаларны яңартырга туры килде. Өйдәге телефонны ташлап китәр хәл юк, Зәйтүнә белән чиратлашып, хәлдән килгәнчә, янында торырга тырыштылар. Туктаусыз чакыру билетлары сорыйлар, катнашырга теләүчеләр арта, телевидение сценарийны ашыктыра, рәсми оешмаларга, котлау өчен, Сөмбеләнең иҗат биографиясе кирәк. Радиолардан укыла торган белдерүләрне яңартырга кушалар...

Ун көн кала тагын ательедан эзләделәр. Инде, шәт, күлмәкләр турында кайгыртыр чак җиткәндер, дип, кызын ияртеп, игелек эшләргә никтер атлыгып торган тегүчеләр янына йөгерде.

Осталарның Сөмбеләгә бик исләре китмәде бугай, эксклюзив үрнәкләр арасыннан классик стильдә тегелгән ике күлмәк сайлап бик тиз күндерделәр. Ә менә Зәйтүнә янында мәш килделәр... Кызның үлчәнмәгән җире калмады... Гәүдәсен тыгыз кара челтәр белән капладылар, алтын җепләр белән күпертеп чигелгән алтын тафтага төрделәр, муенына роза чәчәкләредәй сары ефәктән эрләнгән шарф урадылар.

Алсу тасмалар белән бәйләп көзгедәй елтыр кәгазьләргә төрелгән ике күлмәкне тез өстенә куйган килеш утыра торгач, Сөмбеләнең сабырлыгы төкәнде:

– Вообще-то минем бенефис иде. Кызым кунак булып кына бара.

Үз баласыннан үзе көнләшкәндәй килеп чыкты...

– Кыз бала ахырдан әнисенә чәчәк бәйләме чыгарса, бик эффектлы күренәчәк, – диделәр осталар, әни кешегә бәхәсләшергә ирек бирмичә.

– Алай ук алтыннан коймасагыз да ярар иде. Түләргә туры килсә, бюджетым җитмәс.

– Алдан сөйләшкәнчә, Зәйтүнәгез ун меңенче клиент буларак реклама акциясенә эләгә, «Золотая лихорадка» коллекциясе белән җәйге сезонны ачып җибәрәбез.

– «Алтын бизгәк» дигәч, кызымның түбәсе күккә тиде. Үзегезгә карагыз инде алайса.

Билетлар сатылып беткән, чакырулар күпләп таратылган, телевидение килгәч ишек төбендә артык урын сорап торучыларның төркемен ажиотаж итеп күрсәтер өчен татар теле бүлекләренең студентларын дәштеләр. Ә шулай да Сөмбеләнең тынычлыгын җуйган күңелен агач корты кебек итеп тымызык шик кимерә – буп-буш залга җырларга мәҗбүр иткән үчлеләр тагын берәр этлек әзерләмәсме?

Шәһәрдә кар югалды. Көздән тырмаланмыйча калган сарут камыллары шакыраеп кипкәч, тротуар читләреннән тузан исе күтәрелде. Кышкы аклыкта масаеп утырган ялангач тирәкләр, күләгәләрен югалтып, кояш баешыннан оялышып утыралар. Куе кызыл, баллы шәфәкъ нуры тамак төбенә утыра.

Кыш көне калын пәлтәләрен, мамык шәлләрен, җылы кофталарын, йон оекларын, кунычлы итекләрен салдырыр өчен хатын-кызларны күпме үгетләргә кирәк булыр иде?! Яз чишендереп куйды үзләрен. Тамашачылар юкарып, нәфисләнеп, канатланып калды.

Артистлар тиз җыелды. Килгән берсенең ике генә соравы бар: түрәләрдән кемнәр котлый? Мин кем артыннан җырлыйм?

Кием алыштырып өлгергән артистлар ябык пәрдәле сәхнәгә ашыкты, бизәлешне күрәселәре килде. Бер читтә урындык өстендә «Rigonda» радиоласы тора, ә икенче читтә чәчәкләр җыяр өчен кыска тәпиле журнал өстәле. Суперпәрдәгә җөй тегүчеләр энәсе белән утыздан артык төрле афишалар эленгән. Бөтен бизәлеш шушы! Гап-гади, образлы һәм иң мөһиме – арзан! Ул афишаларга Сөмбеләнең бөтен иҗади биографиясе сыйган.

Грим бүлмәсенә Рөстәм йөгереп керде. Ул «Гран-при» алган чагыннан гәүдәгә хәзер ике тапкыр чамасы артса да, җиңел сөякле, өлгермәгән эше, җитешмәгән җире юк, маҗараларга гел алдан барып эләгә.

– Җәмәгать, кем ничек киенеп өлгергән, шул килеш әйдәгез әле, пәрдә ачылганчы бер кызык күрсәтәм!

«Кызык күрсәтәм» дигәндә, артистларда дөнья гаме бетә, кайсы ярым киенгән, кайсы ярым чишенгән килеш ияреп китте.

Сәхнә артында тагын бер калын пәрдә бар – ул һичкайсы якка да ачылмый, түрне томалап тик тора, артист халкы аны үзенчә «задник» дип үртәп йөртә. «Задник»ның бу ягында уен, ә теге ягында чынбарлык хөкем сөрә. Ике хакыйкать арасына эленгән әлеге пәрдә белән тоташ стена арасында киң юл кала, концерт барышында, кирәккәндә тамашачыларга сиздермичә генә, сәхнәнең уң ягыннан сул ягына арлы-бирле йөрер өчен җайлы ул. Борыслардан мүкләп күтәрелгән тоташ стенаны калын фанер белән тышлап акка буяганнар – нәкъ дәфтәр бите кебек кызыктырып тора... Артист халкы ручкасыз йөрми, фанер дәфтәр түзә. Мактаулы кунаклардан калган чуар язмаларда татар әдәбиятының һәм сәнгатенең соңгы илле еллык шәҗәрәсе: берсе-бер җавапсыз калмаячак адреслы үртәүләр, кинаяле теләкләр, имзалар, рәсемнәр... «Задник» сүзен татарчага турыдан-туры тәрҗемә итсәң, әлеге язмаларның бик күбесе җисеменә тәңгәл килер иде. Әйе, клублар дәүләтнең оптимизация программасына эләгеп, бөтенләй сүтелеп беткәнче, бәлкем әле, дивар иҗатының фанатлары табылыр, күчермәләрен туплап аерым китаплар чыгарыр, шушы имзаларны, сурәтләрне, такмакларны бизәк итеп, иҗат кешеләренең фатирына ябыштырырга ярардай обойлар сатыла башлар...

Хәзер яз җиткәнне шуннан белеп була – боз катлавы эрегәч, җир өстенә... сыра сатучы палаткалар калка, карагыз. Ә элек шәһәргә язны язучылар оештырган «Казан язы» әдәби-музыкаль кичәләре алып килә иде. Мәркәзебезнең уникe клубына һәм дүрт сарайга (театр биналарында концерт кую модасы юк иде) шау-гөр килеп халык җыела, җыр белән шигырь, музыка белән юмор үрелеп бәйрәмгә әверелә иде. Филармониянең эстрада бүлеге оештырган концертлар завод клубына керми калса – бу инде хаҗга барып сәҗдә кылмыйча кайтуга тиң хафа булыр иде... Дивардагы имзаларның күплеге әнә шуннан килә.

Йөзәрләгән исем арасыннан Марат Гомәрнең автографын эзләп таптылар. Этешә-төртешә укыдылар. Телдән телгә кабатладылар. Никтер Сөмбеләне чакырып китерделәр, ул укыганда, аңа комачауламаска тырышып, читкәрәк китеп бастылар. Язуы бик кыска булса да, никтер озак укыды:

*«Күпме күзләр күреп онытылган...*

*(Имза) 1987 ел, 1 март».*

...Балантаудан сихәтләнеп килгәч язган. Бәйрәм алдыннан кызлар репетициягә җыелгандыр дип ашыгып кайттык. Якшәмбе көн иде, ахрысы. Күчтәнәчкә дигән коры сыраны биш литрлы бидоны белән клубка күтәреп кердек. Репетиция беткәч, Хатын-кызлар көне итеп алдан ук бәйрәм үткәреп куйдык... Уйлар дәрьясына иркенләп чумарга ирек бирмәделәр, авыл мәктәпләрендәгечә электр кыңгыравы чыңлады, өченче тапкыр... Беренче имтиханына, ачык дәрескә килде Сөмбелә. Аудитория шыгрым тулы, басып торырлык урын юк, ишек каерылган килеш ачык калган – анда да халык өелгән. Бүген соңгы имтихандыр, бәлки, егерме еллык иҗат мәктәбенең чыгарылыш кичәсе...

Габдулла Рәхимкулов җырлавына пәрдә ачылды. Утлары сүнгән залга сәхнә яктысы таралды. Кул чабып каршы алырга өйрәнгән тамашачыларны сискәндермәс өчен, Сөмбелә вак-вак, әкрен адымнар белән чыкты. Радиола янына килеп «Дим-дим» җырын Таһир Якуповның «Карачлы авылы көе» белән алыштырды. Грампластинка бик иске иде, адаптерның энәсе:

Җиталмый дуслар, җиталмый
Өзелеп сөйгән ярга... –

дигән буразнаны сикереп чыга алмыйча «Сөйгән ярга... сөйгән ярга... сөйгән ярга...» сүзеннән тотлыга башлады. Сөмбелә, аны бөтенләй сүндереп, уртага чыкты. Миләүшә чәчәгедәй куе зәңгәр йөнтәс күлмәгенең озын итәге идәннән сөйрәлеп килгән килеш бераз тартылып калды. Чәчәк бәйләмедәй кысып алган бил путасына сул кулын куеп баш иде. Ул гәүдәсен турайтмыйча кул чабулар тынмады... Ялтыравык шыпка беркетелгән өч аяклы микрофонга якынайды. Уң кулында Рәхимкуловның җыр тәлинкәсе иде.

– Исәнмесез, сөекле тамашачыларым, туганнарым, якташларым! Моннан егерме ел элек мин менә бу күлмәгемне киеп беренче тапкыр шушы сәхнәгә чыккан идем, җиңе дә озын, изүе ябык. Чорына күрә бик модный иде ул. Бер җире дә кысмый – биле дә, күкрәге дә...

«Фигураңны шәп саклагансың!» – дип әйтергә теләүчеләр кул чапкан иде, аларга бөтен зал кушылды.

– Рәхмәт! – дип тагын баш иде Сөмбелә. – Әүвәл Габдулла абый Рәхимкулов, аннан Таһир Якупов бригадасына куштылар. Соңрак Илһам абый белән Әлфия апа да ияртколи башлады... Кулымда аларның патефон тәлинкәләре генә калды... Ә бүген әнә теге афишаларга, минем исем янына кемнәр язылган – барысы да катнашачак. Җыр индустриясе шулкадәр тиз үсте ки, бенефиска әзерләнгәндә менә шушы тәлинкәләрне уйнатырлык ни патефон, ни проигрыватель таба алмадым. Ижаудагы җизнинең дачасында менә шушы радиола сакланган. Әле егерме ел элек кенә һәр өй саен яңгыраган тәлинкәләрне магнит тасмалары, компактлы кассеталар алыштырды. Инде синтезаторларны, мини-сиди дискларны җайлы дибез. Саннар белән музыка язабыз. Ә барыбер чын гармунчыны алыштыра торган техника юк һәм булмас та. Баянчыларны каршы алыгыз!

Ике баян тавышы Сөмбеләнең җырын күтәреп алды:

Күгәрчен гөрлидер
Баласын уятырга.
Әле дә ярый сез дуслар бар
Күңелне юатырга...

Телевидение тоташтан йөз минут кына яздыра ала икән. Ике тапкыр зурлап тәнәфес ясарга туры килде. Сөмбелә алты костюм алыштырды. Ул киенгән арада дуслары җырлады. Төркем-төркем кунаклар чыгып бүләкләр бирде, конвертлар тапшырылды, сәхнә чәчәккә күмелде. Кайчандыр банкетларда, теплоходларда, бәйрәм кичәләрендә сөйкемсез сөяккә әверелгән түрәләр исеменнән телеграммалар укылды... Якташлары залдагыларны Сөмбеләнең туган ягында кабат үткәреләчәк иҗат кичәсенә чакырдылар...

Ниһаять, бенефис үзенең финалына якынлашты.

Катнашучылар сәхнә түренә тезелде. Сөмбелә кыл уртада калды. Бергә җырланасы соңгы җырның музыкасы башлануга, залда ут кабынды. Сул яктан алтыннан коелган Зәйтүнә, ак розалар бәйләме күтәреп, сәхнәгә менеп килә иде. Шул вакыт сәхнәнең уң як баскычыннан тагын бер кыз күтәрелде. Ул нәкъ Зәйтүнә кебек киенгән, чәчендәге ефәк тасмасына чаклы алтынсу төстә. Артистлар турында яңалык, гайбәт һәм имеш-мимеш укыр өчен генә дә өчәр-дүртәр гәҗиткә языла торган җанатар тамашачы мондый яңалыкны көтмәгән иде. Сәхнәгә чыкканда һичкайчан күзлек кими торган Сөмбелә үзе дә, бу «игезәкләрнең» кайсысы минем кызым соң әле – ак чәчәклесеме, әллә сары розалар тотканымы дигәндәй, әле уңга, әле сулга борылып каушап торды. Парадка тезелгән артистлар да, Сөмбеләнең ике кызы юклыгын белә торып, иңбашларын җыерып бер-берсенә караштылар.

Иң нык гаҗәпләнгәне Зәйтүнә булды. Ул күзгә күренмәс көзге каршына басып, төсе, бите, авыз-борыны, каш каралыгы, чәч бөдрәлеге белән үзенең алтын күчермәсенә килеп орынырга, аның кулыннан тотып әнисе каршысына икәүләшеп барырга мәҗбүр иде.

Сөмбелә бәйләмнәрнең агын да, сарысын да кулына алмады. Ул, кызларның уртасында калып, чәчәкләре белән кочагына кысты... Әлеге сюрпризның бүләк түгеллеге, ә сәнгатьчә үч алу икәне аңлашылса да, рәнҗүен йөзенә чыгармады... Пәрдәсе ачылган сәхнә ул – артистларның үзара татулык мәйданы, язмышың башкарган ролеңә караганда аянычрак булса да, тамашачының күз алдында син театральләшкән уен уйнарга мәҗбүрсең. Телевидениенең өч камерасы да бер ноктага төбәлеп, пардан киенгән кызларны бүгенге бенефисның азагына «стоп-кадр»* итте. Елмай, Сөмбелә, җиңелсәң дә, җиңүче булып күрен...

Пәрдә ябылгач, сәхнә чынбарлыкка әйләнеп кайтты... Интригага сусаган артистлар, кием алыштырырга ашыкмыйча, никтер, җанга тиеп, таралышмыйлар да. Өчәр-дүртәр кешелек төркемнәргә бүленеп маҗара көтәләр. Хәзер ул, үги кызны якасыннан алып, теге автографлы фанер стенага терәр, «Кем котыртып җибәрде сине?» дигән соравына җавап ишеткәнче өзгәләнер...

Ә Сөмбелә пәрдә ябылып беткәнне сабыр гына көтте, кызларның икесенең дә маңгаеннан үпте, рәхмәтен әйтте. Барыгыз, ял итегез дигәндәй аркаларыннан сөйде.

– Зәйтүнә, музыкантларга әйт әле, бүләкләрне грим бүлмәсенә ташысыннар. Чәчәкләр шунда торсын, – дип кычкырып калды ул алар артыннан. – Йә, сценарий шәп чыктымы? Үзем яздым, лично!

Ну, кызым булышты инде бераз, финал өлешендә. – Сөмбеләнең куана-куана сөйләнүе сәхнәдәге төркемнәрне чәчте. – Ә хәзер банкет! Сәхнәдә үткәрәбез. Әгерҗенең Кодаш авылында бер шундый банкетка эләккән идек. Егетләр өстәл күчерә, кызлар урындык ташый. Тагын ун минуттан рестораннан «полевая кухня» килеп төшә! Клуб безнеке бүген, арендасы иртәнгә чаклы түләп куелган...

Уйларның таралу тизлеген исәпләрдәй галим тумаган әле. Әмма, борчулы кешенең сизгер уе гайбәттән, тавыштан, хәтта яктылыктан да тизрәк йөри... Аноним хат язармы, телефоннан шылтыратырмы, әллә Сөмбеләне урамда көтеп торачакмы ул ханым?! Ел буе эзәрлекләгән сары табышмакның, ниһаять, җавабы табылды. Ә шулай да көндәше белән сөйләшәсе килә, бик килә Сөмбеләнең. Ул үзенең егерме ел буе кылган бөтен хаталары өчен бары тик шушы ханым алдында гына гаепле һәм бүген җавап тотарга әзер.

Ханым коридорда көтеп тора иде. Тәрәзәгә баккан җиреннән кисәк борылды, ләкин урыныннан кузгалмады, көндәшенең килгәнен көтте. Сөмбелә каушавын сиздермәс өчен аңа таба атлады... Ниһаять, ике арада үрелеп чәчләрне йолкышырлык кына бушлык калды. Ханымның нәфрәте юк. Йөзендә бөтен бәхетсезләр нужасын үзенә алган кебек хәлсезлек, алҗыганлык сизелә. Кичке Казанга курыкмыйча ничек чыккандыр – бөтен хәзинәсен элгән: колагында, муенында, бармакларында, беләгендә алтын да энҗе генә. Сөмбеләгә ул ерак сәфәрдән таланып кайткан хезмәткәре итеп, баш бухгалтер күзләре белән карап тора.

– Таныдыңмы? – диде ханым, сүрән тавыш белән.

– Таныдым. Тик еллар буе теңкәмә тигән кешене синдер дип һич уйламадым.

– Бераз үртисем килде.

– Шактый кыйбатка төшкәнмендер: чәчәкләр, концертлар, Зәйтүнәнең көлмәге...

– Мин банкта эшлим. Зарплатам әйбәт, эшмәкәр дусларым күп. Зәйтүнә аның кызы... димәк, миңа да якын кеше... Кызларыбызның яшь аермасы ике генә ел. Әгәр син Балантавыңда фермада гына калган булсаң, без аның белән тыныч кына парлашып яши идек әле.

– Арагызга кермәдем. Гармунчыңны кар өстеннән табып алдым. Ялгышмасам, син куып чыгарган идең инде аны.

– Ирләре кайтып-китеп йөргән гаиләләр күп лә...

– Сүз виртуоз музыкант турында бара, аны, гади мужиклар белән чагыштырып, урам сәрхушләренә тиңләмик. Миңа үпкәләрлегең юк, гастрольләрдә сабый бала урынына көйләдем, сәхнәдән аермадым, өстен-башын карадым, хәлемнән килгәнчә әҗәлдән сакладым...

– Ярар, үпкәләшмик. Кызларыбыз аралашып яшәсеннәр иде.

– Анысын үзләре хәл итсеннәр, мин сөенермен генә. Ә син ник банкетка калмыйсың? Монда гармунчының дуслары бик күп, искә төшереп утырырбыз.

– Ул истәлекләрдә мин юктыр инде. Җан көеге булып утырганчы, китәрмен генә. Альбина кызым калсын, әгәр теләсә...

Озын өстәлнең ике генә урындык сыярлык тар ягында чөкердәшкән Зәйтүнә белән Альбина табындагыларның гел күз уңында иде. Ризыкка үрелгән арадамы, рюмкаларны чәкештергәндә дисеңме йә күршеләренә баккан булып, һәркем җаен таба, аның саен кан сеңелкәшләргә күз сирпеп алырга өлгерә. Кызлар бу хәлне сизмиме – бик сизә... сынаулы карашларны тоеп һәм җыеп утыра торгач, Зәйтүнә зур яшел алманы уртага ярып, берсен Альбинага тоттырды:

– Әйдә, – диде ул, пышылдап кына, җиңеннән тартып, – әнигә килгән бүләкләрне күрсәтәм.

Җыелган бүләкләр күрмәгән хәзинә түгел, кызларга серләшеп алырга бер хәйлә генә кирәк иде.

– Әтинең чын йөзен хәтерләмим. Өйгә сирәк кайтты, кайткан саен төрле-төрле кыяфәттә була иде ул, – диде Альбина.

– Минем бер уенчык өем бар, әни аны фотоательедан эшләтеп алып кайтты – пластмассадан ясалган сувенир, тәрәзәсе урынына калын линза куелган, якын килеп карасаң – өй эчендә әти утыра, нәкъ тере кебек, күзгә текәлә, – диде Зәйтүнә.

– Кызык... икебезгә бер әти.

– Ә беребезнең дә әтисе юк...

## Шамакайлар

Тамак кипкән, карын ачкан чак. Бенефиста тир түккән халык салатларга ябырылды. Ананас, алма, томат сокларының кәгазь савытлары берәм-берәм җиңеләеп, өстәлдә таба куярлык урын бушады. Борай бәлешенең күмәч бөкеле капкачын ачкач, сәхнәгә итле шулпа салып пешергән ярма боткасы исе таралды. «Симез агай» кафесыннан килгән официант кыз өлеш тәлинкәләренә бүлгәләгән арада, Сөмбелә, залга төшеп, рәт арасына кереп басты.

– Бер бәлеш исе бөтен залга таралды! – диде ул, бөтенесенә ишетелерлек итеп. – Эврика! Башыма яңа уй килде! Иҗат кичәләрен нәкъ менә шушылай үткәрергә кирәк: сәхнәдә сый-хөрмәт, бәлеш,

өчпочмак, шашлык, эчемлекләр. Тамашачы мәҗлесне күзәтеп утыра. Юбилярга багышлап тост әйтүләр, җырлау-сөйләүләр микрофон аркылы бөтен залга җиткерелә. Чынбарлыкка бик якын, тормышчан ситуация, тамашачы үзен мәҗлестә катнашкан кебек хис итәчәк.

– Һәм бөтен зал, бәлеш исенә түзалмыйча, сәхнәгә күчеп бетә! Мен тизрәк, ризык суына. Икенче бәйрәмеңне шулай оештырырсың, – диде кәефле дуслар.

– Ә минем бүтән бенефисым булмаячак!

Өстәл арты җавап көтеп тынып калды. Сөмбелә тынлыкны озакка сузмыйча дәвам итте. Сөйләнә-сөйләнә табын янына килде, урынына утырырга ашыкмады. Аягүрә тост әйтергә теләдеме?

– Бу соңгы кичәм. Саубуллашу вальсы кебек. Тамашачысы югалып беткәнне көтмичә, артист сәхнәдән үзе матур килеш югалырга тиеш. Хәвефне алданрак сизәргә кирәк. Әти-әнием янына кайтып китәм. Авылыбызда укытучы булып эшкә керәм... Бүген мине бик зурладыгыз. Гомерем буена ишетмәгән матур сүзләрне берьюлы ишеттем. Мактасалар, рәхәт икән ул! Күңеле булсын дип юри генә әйтелгән сүзләрегезгә сөенеп утырдым. Рәхмәт. Сезнең өчен бәлеш астына берәрне күтәрик әле...

– Рәхмәт өчен күтәрәбез. Калганнарын ишетмәдек...

Сүз иясе белән йөрми дигәндәй, алга таба куерган туры сөйләмнәрнең иясен исемнәре белән аерым-аерым атап тору кирәк түгелдер – бәхәстә барысы да катнашты.

– Мактау – әҗәт ул. Син, бурычыңны түләмичә генә, зур сәхнәне ташлап, пионер сәхнәсенә күчмәкче буласыңмы? Әле безнең дә иҗат кичәләре үткәрәсебез бар, килерсең, җырларсың, мактарсың.

– Сәхнәсез яши алган егетләр күптән бизнеска күчеп бетте. Чын җырчы соңгы татар белән бергә китәр. Әнә Әлфия апа да ун ел элек «Саубуллашу» гастрольләренә чыгып киткән иде. Әле һаман кайтып керә алганы юк. «Бәхил бул, халкым!» дия-дия, кайбер шәһәрләргә дүртәр-бишәр тапкыр килгән инде... Афишасын күбрәк бастырган, таратып бетерерлек түгел, диләр. Чын җырчыга эш җитәрлек... Хәзер банкет заллары да сәхнәле. Байлар күбәйгән саен мәҗлесләр арта. Шөкер, яңа татарлар җыр ярата. Яраткан кеше акча кызганмый ул, чакырсыннар гына.

– Чакырырлар... Көтеп утыр... Казанның меңьеллыгын уздырганда, татар җырчылары телевизор карап утырды! Ну, меңьеллыгыбыз дөньякүләм вакыйга иде, бәйрәмебезне иярченле элемтәләр аша бөтен Җир шары күзәтеп торгандыр. Дмитрий Хворостовский, Николай Басков, София Ротару кебек федераль йолдызлар, Алманиянең «Скорпионс»ы татар сәхнәсенә килеп җырлагач, дәрәҗәбез үсте. «На-на» төркеме «Умырзая» җырын үзебезчә башкаргач, тамашачы бөтенләй җебеп төште.

– София Ротаруның Казанда берәр туганы бардырмы, еш килә. Әле Президентыбызның җитмеш яшьлеген үткәргәндә «Пирамида»га да килгән иде, Михаил Боярскийлар белән. Татар җырчыларына чират җитмәде. Сәхнә артында дүрт сәгать буе көтеп йөрделәр. Бәширә чыккан иде, Рөстәм баянына ияреп, аны да ике генә куплет җырлаттылар.

– Аның каравы, Мәскәү Президентлары килгәч, мәйданда гел татар эстрадасы гына чыгыш ясады. Ельцин да, Путин да безне түбәтәй киеп тыңладылар.

– Тукта! Аркылы-торкылы сүләмик. Порядок белән, Сөмбеләгә кагылган эпизодларны гына. Әдәгез, по кругу. Да... Бу хәтлек үгетләвегезгә разве түзәргә мөмкин, үзем башлыйм... Так. Тәхеттән коелган патшаларны оныттык...

– Кара аны, монда сөйләгәннәрең репертуарың кебек билдән түбән булмасын!

– Бәйләнмә юкка! Минем мәзәкләр билдән түбән генә. Ә сезнең йолдызларыгыз анадан тума килеш җырлый...

– Сандугачлар чишенмәс...

– Значит, 2000 елның 24 июнендә Казанның алты төшендә сабантуй бара. Путин иртән сабантуй күрергә чыга, диделәр. Кая икәнен төгәл әйтү юк. Алты мәйданга да приказ бирелгән: «Көтәргә! – и все!!!» Безнең бригада Дәрвишләр урманында, көнңелем сизә, нәкъ менә шында киләчәкләр. Автобустан төшкән зевакларны коридор ясап сафка тезелгән милиция коридоры аша үткәрәләр, аэропортлардагы дуганы капка итеп куйганнар. Халык әллә кичтән үк килеп урын алып калган – аланда аяк басар җай юк, сукмак өсләренә дә ашъяулык җәеп табын корганнар. Ошбу сират күперен кичеп мәйданга еттек. Тагын ОМОН кардоны... Детектор белән сыйпыйлар, кофр эчендәге пинжәккә кидергән инсәләрне: «Бу ниткән каты әйбер?» – дип тотып-тотып карыйлар... Ярый, хуш, концерт башланды. Мәйдан хәттин ашкан зур: икенче ягында аттракционнар – уеннар бар, уртада көрәш.

Әкренләп бәйрәмнең кызуы сүрелде: чүлмәкләр ватылды, саламлы капчыклар сытылды, арканнар тирләде, көрәш батыры тәкәне күтәрде, концерт тәмам – Сәхәби, Миндияр, Алсу-Фәридә, Ибраһимовлар белән Сөмбелә инде, сәхнә күлмәкләрен салып, прогулочный чалбарларын киделәр. Китәргә рөхсәт юк, «садаканы» өләшмәделәр әле.

– Гонорар дип әйт инде...

– Гонорар тегел, садака! Мәскәү артистлары ала торганы гонорар – йөзәр мең, бакс белән. Ә безгә урыс акчасы белән өч мең сум садака, аны да бирми торалар әле, артистлар таралышмасын дип... Абау, апакайгынам, берзаман Президент командасы килеп төшмәсенме?! Ельцин агайны күзсез кешене йөрткән ише җитәкләп йөртәләр иде, ә монысы җиңел сөякле – элдертә генә, командасы чак җитешеп

бара артыннан. Зур Хуҗа килсә, кечерәк хуҗалар Хуҗа Насретдинга әверелә бит ул... уеннарны яңарттылар, батылмаган чүлмәкләр чыкты, көрәш батырларына бил алышның финал өлешен кабатларга куштылар, артистлар киредән күлмәк-ыштан алыштырып микрофонга ябыштылар.

Бөтен җыен халкы тын да алмый, яшь патшаны күзәтә – Ельцин батырлыгын кабатлап чүлмәк ватамы, әллә дзюдоистлыгын күрсәтер өчен келәмгә чыгамы, быть может, колгага үрмәлисе кели? Ул арада казус чыкты, көрәшнең ахырын кабатлаганда, абсолют батырны кемдер сыртына салды. Китте бәхәс, китте этеш, китте төртеш. Әле дә Мәскәү кунаклары татарның үзара талашына күнеккән инде – шаулы шоуга исләре китмәде. «Бог с ними» дигәндәй, беләкләренә юри генә кызыл тасма бәйләгән гражданский киемле спецслужба егетләре көрәшчеләрне аерды. Иң кызыгы хәзер башлана, моңарчы сүләнгән өлеше увертюра гына үзе әле, кереш өлеше, так сказать... Яшь патшаның каршысына «Вамин» катыгы белән мөлдерәмә тулы агач кәнди китереп куйдылар. И папарацияне күрсәң, астан-өстән, уртадан-яннан, алдан-арттан кинога төшерәләр, фотоаппарат яшеннәре ялт та йолт!.. Боларны күреп Сөмбелә миңа әтә: Мәскәү Президентының катыклы битен сөртәм, тарихка керәм, ди. Үзбәк кызы Мәмләкәт бармы, бала чагында Ленин бабай белән фотога төшкән өчен, үскәч Социалистик Хезмәт Герое исемен биргәннәрие, да... И, Сөмбеләне туктатып өлгермәдек, җиң очыннан кульяулык алды да китте. Ул Сөембикә ханбикәгә охшатыбрак киенгән иде, урта гасыр колориты белән, тән сакчылары туктатырга базмадылар, гәүдәсе төз – күреп торасыз, биле нечкә, күкрәге җыйнак – корал яшерерлек һич шикле җире юк. Путинны әтәм, кечкенәдән сабан туйларында уйнап үскән диярсең – йөзе белән ялт теге кәндигә! Сөзә торгач, алтын акчаны табып алды да катыклы чыраен уңга-сулга боргалап, теш арасындагы хәзинәне халыкка күрсәтте. Сабантуй аланы рәхәтләнеп көлә-көлә алкышлады... Да, миңа хәзер бу халыкны көлдерүләре кыенгарак төшәчәк, мин әйтәм.

– Ә Сөмбелә нишләде?

– Өлгермәде. Алдан ук билгеләнгән ике мәктәп баласы чүпләмле сөлге китереп тотырды... Ну, шулай да Сөмбеләнең кыюлыгына шаклар катканыем мин ул көнне, иртәгесе көннән курыкмыйча, йөрәге җитеп, тәки барып басты бит опасный зонага... Әйдәгез, батыр йөрәкле Сөмбелә өчен берәр чәркә кымыз күтәрик, катырагын да эчәр идем – давлением тиз күтәрелә шул...

– Тостың бик озынга китте. Күп сүз ул арзан бүләкне зурлап тапшырганда гына әйбәт. Табын мулрак, кунаклар күбрәк булган саен буш сүзләр күбәя.

– Янда синең шикелле критиклар утырганда, ял итүләр дә авыр эшкә әйләнә. «Сүз әйт» тә «сүз әйт», дидегез, әйтмәсәм дә эчәсез инде үзегез! Сөмбелә, тый әле яңа баянчыңны, исерсә, гел дөресен сөйли башлый, мәлгунь! Сабантуй аланында йоклап, онытылып калганын белми...

– Тост чираты миндә.

– Чират көтү көткәндә генә була.

– Син хайван түгелдер ич?

– Хатын-кызга хайван димиләр. Хайванның имие койрык астында, ә хатын-кызларныкы менә монда – муен тирәсендә!

– Тост әйтергә теләүчеләр күп. Чиратсыз кермәгез.

– Зур бәйрәмнәргә эләксәң, андагы халык массалары хәтердә калмый, гомумән, төзек гәүдәле, гадәти чырайлы, дөрес холыклы яңа танышлар тиз онытыла, хәтердә озаклап тормый. Ә менә кыек-мыек, кәкре-бөкре, кимчелекле гаепле кешеләр гел истән чыкмый. Кешеләр генә түгел, вакыйгалар да шулай...

Сөмбеләгә кагылышлы ике маҗарам бар: берсе күңелле, икенчесе рәхәт түгел. Кайсысын сөйлим?

– Сорап торма, күңелсезе үзеңдә калсын.

– Ие... Килеп җиттек Актанышка. Чәйләп-нитеп тору юк, туп-туры Агыйдел буена төшәбез. Көймә белән зур бер утрауга алып керделәр. Күрсәгез... малай! Оҗмах!.. Табигать кочагында нәмәдән аш пешереп була – барысы да әзер тегендә. Шундук җыйнак кына сала корганнар, ә урам буйлап местный гармунчылар авыл көе уйнап йөри. Июль башында түтәлдәге җиләк пешкәнен беләм, ә монда... Кая карама алмагачларда – зур-зур өлгергән алмалар, зирекләрдә – груша, шомырт куакларында төче чияләр эленеп тора. Парлашып актан киенгән ике президент гаиләсе җәннәт бакчасында җимеш чемченеп йөри... Саф татарча гәпләшәләр, алар бик якын дуслар икән бит!..

– Булды, булды! Дүрт кеше өчен самолет куып Анталиягә китмәгәннәре өчен рәхмәт әйт...

– Алайса, тегесен сөйләргә кала... Мин әле ул вакытта Сөмбелә янында антураж булып кына җырлап йөрим. Үсәсе килә, лично үземнең бригаданы оештырасы иде дигән хыялым эчтән кимерә. Концертлардан соң, чәйләр-мәйләр эчкәндә, хуҗалар хәтерендә калыр өчен кыек-мыек җырлар, кәкре-бөкре пародияләр җырлыйм, җитәкчеләрнең тавышына охшатып үртәмешләр сөйлим. Кайбер район главаларына Президент булып шылтыраткан чакларыбыз да бар иде: күбесенең шәхси телефоннарын беләбез... Кыска-җыйнак сораулар биреп, хәлләрен сорашкандай кыланабыз да соңыннан: «Давайте, - Сөмбеләне поддержать итегез әле, пчему-потомушто, бик шәп җырчы ул, ни әйтергә теләгәнемне аңлыйсыздыр?» – дип тизрәк саубуллашабыз. Урындагы «первый»ларның үрә катып: «Ярый! Ярый! Әлбәттә. Һәйбәтләп чакырырбыз!» – дигәннәре телефон төребкәсеннән дә күренә иде, билләһи!

Сөмбеләне чакырып, гарантиягә унышар концерт оештырган районнар да булды. Ул вакытта әле элемтә техникасы бик алга китмәгән, определительләр бик сирәк кешедә генә иде...

...И-йе!.. 1990 елның мае бугай... Точно, иртәгә Җиңү бәйрәме дигән көн иде! Бер машина йолдыз төяп Пәрәү авылына киттек. Анда минем классташым Нуретдин яши. Без аның белән күрше авыл интернатында бергә укыдык, почти егерме биш ел күрешкән юк. Әйбәт яшәгәнен, нык гаилә корганын ишетеп беләм, чәйгә керергә дә исәп юк түгел. Афишада конферансьеның мин икәнен күрсә, йөгереп киләчәк, соңыннан чәйгә дә алачак, урман каравылчысы ла ул – өе иркендер, бөтенебез сыярбыз, дим...

Пәрәү клубындагы кешене күрсәгез – кечке трамвай кебек өелеп төялгәннәр! Башланырга ярты сәгатьләп кенә калгач, китапханәче кыздан, Нуретдиннең өе еракмы, дип сораган идем... Ужас!!! Кичә кич үтергәннәр, бүген күмгәннәр классташны... Коелып төштем, хәл китте, йөрәгем яртылаш сүнде, күзләремне чытырдатып йомдым – ачсам яшь түгеләсен беләм... Мин бит концертны юмор белән башлап җибәрергә тиеш. Юмор сөйләү түгел, сәхнәгә чыгып бәхилләшү сүзе әйтерлек тә рәтем юк. Ярамый да... Кайгылы туганнары килмәгәндер, бәлкем, ә бит зал тулы халык концерт карарга дип җыелган. Нишлисең инде, үлгән артыннан үлеп булмый, кемдер китә, кемдер килә шушы кабахәт дөньяга, тормыш дәвам итә. Сөмбелә үзе башларга булды, борынгы җырлар, халык көйләре белән. Җиде җырны рәттән җырлап бетерде дә, сәхнә артына чыгып, минем каршыга килеп басты: «Бар, эшеңне эшлә! Залның күзенә карама, лампочкага карап сөйлә! Безнең язмыш шушы! Егет бул!» – дип, йодрык та күрсәтеп алды хәтта.

Чыктым да юмор сөйли башладым. Халык көлә... Ә мин соңгы чиккә җиткәнче еламыйча түзәм. Тыелган яшьләремнән күзләрем бүртте, яңакларым өрелде, баш түбәм шаулады. Биш минутлап түзгәнмендер... Күз яшьләре бәреп чыкты. Елый-елый көлдерәм, халык бүлдереп-бүлдереп кул чаба... Соңыннан сәхнәгә менеп аркамнан сөйделәр: «Күздән яшь чыкканчы көлдердең!» – диделәр... Менә шушы инде безнең язмыш, Сөмбелә. Әйдәгез, ачы да, татлы да булган артист язмышы өчен берне күтәрик әле.

– Тукта, сабыр ит! Сиңа сүз бирер алдыннан иң кыска тостка конкурс игълан итәбез. Җиңүчегә приз-сюрприз!

– Иң кыска тост – конверт! Конвертлар юк.

– Миңа чират җиткәч кенә ашыктырасыз... 2000 елның февраль ахырында Рәсимгә ияреп Пензаны йөреп чыктык. Казаннан сөрелгән кырык тугыз депутатның берсе анда министр урынбасары иде – ул чакырды. Әйбәт йөрдек, шәп оештырганнар. Индирка авылында гына безне көтмәгәннәр булып чыкты. Февраль бураннары. Юл өзеге. Афиша килеп җитмәгән. Киләсебезне белмәгәннәр. Гостиница юк. Мишәрләр артист халкын фатирга бик алмый хәзер. Без анда детсадта кундык. Хәтерлисеңме, Рәсим, балалар караватында йоклаганыңны?

– Хәтерләмәскә. Әлбәттә. Ну мин бөгәрләндем дә яттым.

– Син җиңел сөякле, чыдый беләсең. Ә администратор Рамай – йөз утыз алты килолы, ике метрлы гәүдәсе белән нишләргә тиеш? Өч бала караватын аркылы тезеп менеп ятты бахыр... Таң аткач, тәрбияче апа йөгереп кергән: «Торыгыз! Оятсызлар, һаман йоклап ятасыз, хәзер оланнар килә башлый!» – ди бу, һава тревогасы күтәреп. Күрсәгез, Рамай, өч бишек кабыргасында төн уздырып, терсәкле валга охшап калган иде... әле бүген дә бик үк тураеп бетмәгән. Сөмбелә сынатмады, аркасына мендәрләр терәп утырып кына йоклады. Ну суты бу түгел... Килдек, зритель юк. Казаннан тикле чыгып бушка ашап ятасыңмы?.. Сөмбелә, концерт күлмәген киеп... февраль аенда, ак шәлен бөркәнгән килеш кенә, урам буйлап... кибеткә барып килде. Ун минут йөреп кайтты микән... кичкә клубта битковый аншлаг иде! Генерал Карбышев батырлыгына тиң Сөмбелә өчен...

– Синең тост та озын. Кыскасын үзем сөйлим. Ноябрьск. 1996 ел. Апрель азагы, ак төннәр... Дүрт артистны Себергә озаттылар. Илһам абыйга ирдек. Зурладылар. Кар өстендә учак, шашлык пешә, сауна кызган – бик җылы каршыладылар. Концерт «Ура!» кычкыртып үтте. Крутой братлар Сургутка озатты. Казанга билетлар юк. Самолет атнага ике генә оча. 1 Май аркасында билетлар сатылып беткән. Илһам абыйның поезд белән кайтасы килми. Тагын өч көн буе көтеп утырырга риза. Утырабыз. Тагын ике сәгатьтән шыплап тулган бер самолет китәчәк. Сөмбелә түзмәде. Җир шарында татар кешесе булмаган почмак юк, дип рюмочныйга юнәлде. Алюмин банкалы адреналин алып эчте. Артык шик тудырмыйча гына, буфетчы ападан сорап куйды: «Сездә татарлар эшлиме?» – янәсе.

– Күпме кирәк? Әнә икесе йөри! – диде ак түткәй, зәңгәр комбинезонлыларга таба ымлап.

Сөмбелә, минутларны әрәм итмичә генә, тегеләрнең уртасына килеп басты.

– Егетләр, сезне Илһам Шакиров эзли иде, күрдеме әле?

– Илһам абый?! Мондамы? Точно үземе? – дип ышанмый маташа бит тегеләр.

– Димәк, күрешмәгәнсез әле. Әйдәгез таныштырам, – дип, Сөмбелә егетләргә икеләнерлек хут калдырмады, икесен берьюлы култыклап, җилтерәтеп алып килде.

Илһам абый:

– Ике бизнесмен, инәләрен поп еккыры, алдалап-юмалап Сургутка илтеп ыргытты. Билетлар беткән. Шул тукмакбашлар аркасында Май бәйрәмен аэропортта каршыларга туры килә, – дип, әйтәсен

әйтеп тә бетерми калды, егетләрнең берсе шундук каядыр йөгерде, икенчесе йөз меңлек купюрага автограф куйдыра торды... Кыскасы, посадкага ярты сәгать кала безне, багажга ияртеп, буш самолетка кертеп яптылар. Летчиклары Казан авиалиниясеннән иделәр. Илһам абыйга шлем кидереп икенче пилот урынына утырттылар. Артык мавыгып, рольгә керә күрмә, кнопкаларга баскалама, юкса самолетыбыз мәтәлеп төшә, дип, инструкцияне бик ныгытып үткәрдек үзе белән. Рөстәм, Ельциннарны, Путиннарны биеткән гармунын кочаклап, лимонад шешәләре өстенә утырды. Сөмбеләне стюардесса иттеләр. Ә мин туалет тирәсендә йөренәм. Кыскасы, бишәр йөз мең акча төртеп, дүрт «куян» исән-имин Казанга кайтып төштек. Мин, гел аягөсте торгач, җәяү кайткан кебек булдым. Ике миллион түләдек, акчаларның өч ноле сызылмаган чак иде әле ул. Әйтәсем килгәне шул... Сөмбеләнең олы укытучылары – зур дуслары бар... Мулла кушкан исем ул метрикәгә язып куяр өчен генә ярый, талантлы кешегә исем соңрак килә, Сөмбелә дигән матур исем өчен...

– Кайсыгызның сүзе кыска?

– Бәйлисе бар йөрәкне...

– Сөмбелә турында бер-ике кәлимә сүз белән генә булмый, ул бит сәхнәдән китәргә җыена.

– Үзем әйтәм. Иң кыска тост: «Китмә, китмә, сандугач!»

* * *

Балантауга газ кергәнгә бишбылтыр. Яңа пәлтә кидем дип искесен тиз генә чыгарып ташларга күнекмәгән халык ипи мичләрен сүтәргә ашыкмады. Газ ул – бик сәяси ут. Җир шарына тамырланган торбалары көйсез илләр, афәтле дәүләтләр белән бәйләнгән. Ә утын – үз урманың хәзинәсе, ягылмаган килеш тә сарай читенә өелгән әрдәнәсе җылытып, сөендереп тора.

«Әни, чуен белән мичтә пешкән борчак штие ашыйсым килә, елкы ите турап...» – дигәч, Гөлчәчәк ике сорарлык итмәде, өйлә вакыты җитәрәк мичкә якты. Мич көймәсенә тигезләп тутырылган нарат ботаклары утка өерелгәч, Сөмбелә бер телем арыш ипиенә тоз сибеп, күмер кызуына тәрәде. Әйләндереп-әйләндереп ике ягын да кыздырды. Кайнар сохарины кулдан-кулга сикертеп, урамга йөгереп чыкты, капка төбендәге бүрәнә өстенә менеп утырды. Үзе кетер-кетер кимерә, үзе авыл сәхнәсендәге язгы симфонияне тыңлый... Шушма буендагы таллыкта каргалар хоры... Капка баганасына колга белән кагылган оядагы бәхетенә сөенеп сыерчык сайрый, җырчы тавыклар тояк эзендәге кояшлы су белән тамагын чайкый... Абзар кыегындагы калай әтәч янына менеп җиткән чуаркайның «кикрикүге», сыртында мамыгы күпергән кәҗәнең тарак сорап ялварган теноры, гомерендә беренче тапкыр көтүгә чыгарга хыялланган кысыр тананың быргысы барысы-барысы бергә яшәешнең дәвамы, язларның кабатлануы булып җиһанга хәбәр сала. Һәм Сөмбелә җырланмаган җырларын тоеп, күңеленә сеңгәннәрен чак тыеп, шушы җиһанның кыл бер уртасында яшәреп утыра. Болар туган йорт мендәренә чумган нарасыйның озын-озак саташуы кебек тоела. Таныш, бик тә таныш авылдаш апаларның ара-тирә артистланып эндәшеп китүләре генә әлеге халәтнең һичшиксез өндәге чынбарлык икәненә инандырып тора.

«Әләй, нәни Сөмбелә кайткан түгелме соң? Ә Идрис абыең мәктәптә физкультура укыта!»

«Сохари кимерә берәү. Казан күмәченнән үтләгән...»

«Ал әйдә чиләкләреңне. Чишмәгә ияртәм...»

«Телевизордан чыктың мәллә? Әле бик матур итеп «Кыр казы»н өздерә идең».

«Үзең капка төбендә, гәүдәң телевизорда. Менә сиңа мә! Ышанып карап утыр концертларын...»

Шунда гына һушына килде Сөмбелә, бенефисның язмасын күрсәтәселәр иде ләбаса... Өйгә керсә, сервант шүрлегендә онытылып калган кесә телефоны шылтырый... Альбинаның әнисе эзли Сөмбеләне. Бер банкир өстәмә исемлек белән депутатлыкка сайланырга җыена, альтернатив кандидатлар бик күп, ди, ышанычлы кешесе рәвешендә ай буе концерт куеп, яклап йөрергә кирәк икән. Ризалыгын сорыйлар.

Бик тиз генә: «Юк!» – дип өзеп әйтсә дә, җавабын әллә кайчан уйлап куйган иде инде Сөмбелә. Сәхнәдән матур килеш, тамашачының сагынасын белеп, кызганыч көнгә калганны көтмичә, горур төстә җырлап китәргә кирәк! Джунгли елгаларында үрчегән бизәкле балыклар аквариумда яши алган кебек... Кискен үзгәрешләрдән курыкмаска! Садә җанны җыр җитәкләп йөртер...

Ул телевизор каршындагы кәнәфидә куанып утырган әнисе янына сыенды. Экрандагы шәмәхә күлмәкле Сөмбелә тамашачы Сөмбелә өчен өзгәләнеп җырлый иде...

# ХИКӘЯЛӘР ҺӘМ ЮМОРЕСКАЛАР

## СУНАР ВАКЫТЫ

Килә...

Күзгә күренеп яз килә!

Язның үз тизлеге бар. Фасыл манзарасында көн саен бер яңалык. Әле кайчан гына шәһәр урамнарындагы карның дегетен чыгарырлык җылы көннәр башланган иде... Инде җирнең кыштан калган чокыр-чакырлы шадраларын тигез үлән каплады... Каен сулары кипте... Аяк асты такыр... Үтә күренмәле җилләр нигез тузанында ауный да күзгә күренеп-күренеп ала. Авылдан адашып килеп кергән бал кортларын әлсерәтеп тал песиләре бәргәләнә. Майның унбишләрен дә көтмичә, алмагач чәчәкләренә гыйшык кергән. Тирәк очындагы тирән ояларда, якты дөньяга чыгачак чебиләренең тавышын ишетеп, каргалар саташа... Бер ай эчендә карлы-бозлы искергән кыш сары чәчәкле яңа җәйгә әверелеп бара...

Эшем кешесенең кайтыр сукмагына киртә булып чат саен корылган каеш чатырларның берсе тәки ымсындырды Рифатны. «Тәки» дип әйтү бик үк дөрес тә булмас, кулга җиңел акча керсә, яз кояшыннан ышыкланып утырган яшьләр арасында бер кәеф-сафа корасы килгән иде аның. Сыный карагач кына сизде ул – урам ягындагы уенчык өстәлләрдә шешәгә тотынып утырган яшьләр уку елын төгәлләп килүче студентларга охшаган, кызык табардай затлырак халык эчтә булса кирәк.

Ике баланы тәмам «өлгерткәнче» укытып, аерым тормыш корырдай яшькә җиткергән арада, Рифат белән Тәлига гаиләсенә «беренче сентябрь», «соңгы звонок», «имтихан» дигән котылгысыз вакыйгалар алып килгән тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр һаман саен ерагая бара. Чыгарылыш кичәләренә чакыручы юк, «укырга кая барырга?» дигән фәлсәфи сораулар борчымый инде аларны. Быел исә, киресенчә, бөтенләй чит кешеләр мәшәкате һич көтмәгән, өмет итмәгән җирдән яшерен сөенеч алып килде әле.

Рифатның түш кесәсендә яшел катыргысы таушалып, төпләм җепләре өзгәләнеп беткән блокноты бар. Әнә шул куен дәфтәрендәге адресларны, телефоннарны, эш урыннарына карап, теркәлгән кирәкле кешеләрне санасаң, элемтәчеләр чыгарган букча калынлыгы сары белешмәләрең бер читтә торсын! Егерме биш ел буе төзелештә эшләп үзеннән-үзе җыелды ул исемнәр. Байлар күбәеп, сыйнфый көрәшләр көчәйгән саен, фатир ремонтлау, өй алмаштыру, җиһаз яңарту кебек мөлкәт ярышлары кискенләшә. Кайбер хуҗаларга Рифат инде икешәр, хәтта өчәр кат хезмәт иткән. Күпләр аны урамда танып эндәшә, йомышың төшсә, ярдәм итәргә дә әзер үзләре.

Дусларны көз санайлар дигәндәй, ике бүлмәле «хрущевка»ның балконына тәрәзә куйган чакта, хуҗабикә күңелендәге зарын әйтеп салды. Моның бердәнбер кызы унберенче сыйныфта икән, укып бетергәнен – аттестат алганын көтмичә, бүгеннән үк ярдәм итәрдәй кешене эзләргә кирәген белә тол хатын, хәләл көчен кызганмыйча эшләп, ришвәтлек мәхәрен дә туплаган, тик кем кулына илтеп бирәсен генә белми. Ә Рифатның куен дәфтәрендә нәкъ шундый кирәкле кеше бар, җәйге каникулга чыккан саен, ул, аны дәштереп, Салмачыдагы ташпулатына берәр яңарыш кертә.

Уку елы дәвамында телефоннан шылтыраткалап, хуҗабикә белән кафедра мөдире арасында урталыкта торды Рифат. Кызның билгеләре әйбәт иде, гимназияне медальгә бетерә алмаса да, имтиханнарда югары балл җыярга тора. Алдан килешенгәнчә, Май бәйрәме үтүгә, хуҗабикәдән тиешле сумманы алып, Рифат үз куллары белән мөдиргә илтеп бирде. Мөдир, озын конвертны күз алдында ертып, унөч озын меңлекне Рифатка сузды: «Налогын синә түлим, киләчәктә шундый клиентларны күбрәк тап!» – дип, аркасыннан сөйде, кире борырлык итмәде, язылмаган законы шулайрак куша икән.

Акчалар озынайган саен, почта конвертларының да озынаерга тиешлеген аңлады Рифат.

Абзагыз төзелештә җигелеп үткән гомеркәйләрен үртәп, озын меңлекләрне кызганмыйча, язгы кызлар күз салырлык итеп, текә егетләр кебек һаваланып, яшьләрчә ял итәргә әзер бүген. Унбиш ел буе дөнья базарында яшәп тә, аның әле гел искечә көн күргән мәле. Ә бит хәзер җаның ни тели, шул бар. Бактың исә, чынбарлыкның муллыгы телевизорларга сыймый: бу базарда сүзлекләргә кергән исем-җисемнәр, фигыль-шөгыльләр, тән вә тәм – бөтенесе дә товар; татулыкны, чибәрлекне, мәхәббәтне, рәхәтне, хәтта яшьлекнең үзен дә сатып алып була.

Хатын-кыз, ирләрне кызыктырыр өчен яшәрергә теләсә фитнес-клубларга, бассейннарга йөри, ясалма кояшлы ванналарга кереп ята, косметологларга иялэшә. Ә ир кешегә яшәрер өчен... йөз грамм арыш мае җитә дисәләр, ышанмагыз... Рифат акча алган көннәрдә яшәрә. Касса тәрәзәсеннән өенә чаклы араны ул яшьлек хыялларына күмелеп, аккош канатларында талпынып кайта. Хәләл эше китергән кәгазь сөенечләрне хатынының халат кесәсенә салгач, Рифат тагын гадәти хәленә килә... Тик

бүгенге меңлекләрнең хәләл кесәгә керергә хакы юк, хәрәм мал – әрәм мал... Әгәр ул хатын кулына бер эләксә, Рифат өчен кәсепкә әвереләчәк.

Әлеге чатыр колачлап алган бер катлы биек йортны вак-вак соры кирпечләрдән күтәргәннәр. Бу тирәдән көн саен диярлек үткәләп йөрсә дә әллә ни игътибар итмәгән иде Рифат. Салым җыючы, ризык сыйфатын тикшерүче оешмалар алдында берәр хәйлә корганнармы – олы ишекләренең урам ягына вак хәрефләр белән генә «Клуб» сүзе язылган икән. Клуб дигәч, өрлегеннән купкан ярык идәннәргә тимер урындыклар тезелгән авыл клубы күз алдына килгән иде. Ә монда туй үткәрерлек ресторан залы, челән аяклы күн банкеткалар каршысында бар-буфет, чаршаулы бүлмәләр, бильярд залы. Түшәмнән төшкән миләүшә нурлар баганасы клуб эчендәге эңгер-меңгерне куерта сыман.

Акчалы халык кояш баеганны көтәме – кичке ыгы-зыгы башланмаган әле. Ике өстәлдән гайресе буш. Кеше әз булгач, сыйлаучылар да кабаланмый. Алъяпкыч итәкле официант меню өләшеп чыкты да кунакларны онытты.

Түрдәрәк ике агай-эне бизнес-план корып маташадыр, ахрысы. Утырган килеш тә буй аермалары күзгә ташлана: озынрак чандыры сорау билгесе кебек бөгелгән – уч төбендәге микрокалькуляторга авторучка төбе белән төртеп санап тора; базык гәүдәлесе, өстәлгә җәелгән кәгазьләрдән сайлаштырып, тегеңә саннар эзли... Алардан ике өстәлгә читтәрәк өч кыз төпләнгән: өчесе дә урам сәүдәсендә чыныккан, самимилеген югалткан, яшь чактагы портретларын шактый үзгәрткәнгә охшый. Берсе, кесә телефонын иңбашы белән колагына кысып, ике куллап тәмәке кабызды. Тәмәкесен имеп бетергәнче, биш-алты тарафка шылтыратып өлгерде. Ул арада иптәш кызлары гел аңа йотлыгып карап утырдылар... Кемнедер, нәрсәнедер эзлиләр бугай болар...

Рифат та эзли, романтик маҗара көтә. Гүя серле бер чибәркәй белән яңа танышып, күрешергә сүз куешканнар, ә ул һаман килми дә килми. Залда кунаклары әкрен җыелган мәҗлестәгечә бушлык урнашты. Эшмәкәрләр кеше игътибарын җәлеп итмәстәй соры фонга әверелде. «Тагын бер җаен табып чумара эшләргә дә, Тәлига белән керергә кирәк икән монда», – дип, нәүмиз күңелен юатырдай чара эзләп, киң тәрәзәләрне каплап торган авыр калын пәрдәләр ярыгыннан урам яктылыгына текәлде Рифат. Фонтанны кабызганнар, су чәпердәве тәрәзә аша да күңелне сөендерә. Каргаларның аласы, күгәрченнәрнең агы, быелгы чыпчыкларны түгәрәккә кертеп, тал песие, бөре сүрүе белән тулган таш чынаяктан ахшам чәе эчәләр. Урман-күлләрдә язгы ау чоры бара, ә боларның сунарчыларга кирәге юк. Меңьяшәр каланың гөрелтесе, асфальт ватучы чүкеч тыкылдаулары, биек коймалар артында җир тетрәтеп субай дөпелдәүләре бу кошлар өчен иң тыныч урын.

Ниһаять, Рифат каршындагы өстәлгә дә кеше килде. Ике кыз – икесендә дә ботның иң юан җирен генә капларлык джинсы итәк, чөй үкчәле кызыл туфлиләре таш идәндә тыпырдап тора, балачактан бирле тузмый калган кыска сары футболкаларын кигәннәрме – кендекләре анадан тума килеш. Пардан киенсәләр дә, кызларда шактый ук аерма бар: тукылган җитендәй толымын баш чүмеченә төенләп куйганын малайларча кыска китәртелгән җирән чәчлесе этеп-төртеп йөрткәндәй көйли. Урын тәкъдим итте, иңбашына эленгән яфрак рәвешендәге кызыл сумкасыннан дымлы салфетка чыгарып утырасы урыннарны сөртеп алды, өстәл өстен дә сыпыргалады.

Җирән чәчле кызның, кинәт торып, ишек төбендәге банкеткадан бер гәҗит алып килүен Рифат та кабатларга мәҗбүр булды. Курьерлар, хат ташучылар бушлай таратып йөри торган реклама өеме иде бу. Рифат әйләнеп килгәндә, тегеләрнең калын гәҗите житен чәчле кыз кулына күчкән иде, ул егерменче битнең аскы өлешенә текәлгән дә рәттән игълан укый. Рифат та шул битне ачты. Бик шәп белә ул бу гәҗитне, бигрәкләр дә «Вакансия» дип язылган төшен... Алай икән, житенчәч эш эзли, димәк. Студент буларак җәйге каникул өченме, әллә төшемлерәк урын сайлавымы? Ашык, кызый, ашык! Җәй уртасы җиткәч, эшсезләр армиясенә конкурслардан үтмәгән абитуриентлар килеп кушылачак.

Нәкъ шушы мизгелдә Рифатка килгән ялган бәйрәм белән житен чәчле кызның күңелсезлеге ике арага күзгә күренмәс күпер корып куйды. Һәм бу күпердән икенче ярга әүвәл Рифат чыгарга тиеш.

– Кызлар, исәнмесез?! Ә менә бу игъланны мин бирдем, – диде ул, килә-килешкә үк, туп-туры житенчәчкә текәлеп.

– ...Идән җәям, ишекләр уям...– Кызый игъланны кычкырып укый башлаган иде, пышылдауга күчте. – Сез дә эшсезме?

– Бу бер хәйлә генә. Бригадабыз бер объектны бетергәнче, яңасын эзли торабыз. Плотник эшләрен эзләп минем телефонны бирәбез, тимер-томырлар буенча икенчебез. Кирпеч-бетон буенча өченче кешебез җаваплы, кафель җәю, су кертү эшләрен калганнарыбыз эзли. Ә эшне бергәләп башкарабыз.

– Эштән соң «ауга» чыгасызмы?! Фирмачларның акчасы кычыта инде аларның, – дип, усаллашып сүзгә кушылды җирәнчәч тә.

– Юк. Бүген минем сөенечем бар. Бер танышымның кызын институтка кертергә булыштым.

Житен чәчлесе сискәнеп куйгандай итте. Бер иптәшенә, бер Рифатка карап алды.

– Сез утырыгыз, утырыгыз безнең янга! – Һәм ул, Рифатны ялган өстендә тотарга теләгәндәй, муенына эленгән телефонын ачып гәҗиттәге номерны җыйды.

Рифатның яшел чалбарына кыстырылган кыска җиңле җете ак тенниска кесәсендә «Әпипә» көе яңгырады. Алар, өстәл аркылы күзгә-күз карашып, телефоннан сөйләшә башладылар:

– Алло, кем әле бу?

– Минме? Мин – Лилия, дус кызым – Римма. Ә сез кем?

– Аллу, мин ни, Рифат исемле...

Танышу вакыйгасы, күп дигәндә, ике-өч минутка сузылгандыр. Ул арада инде официант кыз да чыгып җитте, сорау алуны эшмәкәрләрдән башлады:

– Ни телисез, әфәнделәр?!

Рифат бил каешына таянган булып кына, бармак очларын уйнатып чалбар кесәсен капшады – акча урынында! Күңелдә гармун уйный... Күптән, бик күптән чормаңда тузан җыеп яткан гармунның каптырмалы путасы шартлап өзелә дә күреге бар кодрәтенә тартыла... «Авыл көе» яңгырый. Ул, өшегән җанның иң түренә үтеп кереп, йоклаган теләкләрне уята, онытылган әкиятләрне яңарта. Гармун сулышында мәҗлес исе: токмачлы аш, өчпочмак, бастырма, казылык, бәлеш ... лагман, шаурма, лангет, жульен...

– Безгә өч жульен!

– Тагын? – Кәгазь белән каләм тотып килгән шагыйранә официант сабыр кыланды, кабаланмады. – Тагын нинди закуска аласыз? Эчәргә ни китерим?

– Кызлар, җаныгыз ни тели, сорагыз! Бүген минем көн!

– Алайса, җиләк-җимеш салаты, лангет... тозланган форель, әйбәтрәк вино...

– Ике... юк, безгә өч шешә инвестиция! – дип өстәде Рифат.

Бер шешә бушаганчы, Рифат, Лилия, Римма дигән исемнәр, кыскарып, Риф, Лиль, Римм булып үзгәрде, «сез»ләр «син» белән алышынды.

Һәр табигать почмагы, һәр мохитнең үзенә генә хас җан асраучы ияләре була, урам ягындагы чатыр тирәсендә «җирле халык»ка әверелгән шешә эзләүчеләр, чүпрәк бала күтәреп килгән каратутлы, озын, чуар күлмәкле хәер эстәүче түткәйләр, өйдәге бурзайларына сөяк-санак җыючы агайлар залга үтеп керә алмый, ишек төбендә сугышчан киемле әзмәвер тора, ул хөрмәтле вә кыйммәтле кунакларның иминлеген саклый. Риф бүген ышанычлы кулларда, уйнасын гармунның, сайра кызлар алдында, ял итә торган җирдә эшләп утырасыңмы, эш урынында ял итәсеңме – монда сиңа кемнең дә исе китми.

– Риф, синең тирәдә минем кебекләргә эш бармы?

– Икегезгә дәме?

– Юк. Римм әйбәт урын тапты, ул... – дип дәвам итәргә ирек бирмәде, Римм дустының касыгына терсәген терәде: серне ачма, янәсе. Ләкин Лиль башлаган җөмләсен өзеп өлгерә алмады. – Ул фатирлар белән алыш-биреш фирмасында риэлтор.

– Бик әйбәт. Дуслыгыбыз бәрәкәтле булыр. Без ремонтлаган фатирларның күбесе сату өчен әзерләнә.

Римм, Рифның соңгы сүзләрен егетләрчә килешүгә авыштырып, кулындагы шәраблы бокалны чәкештерер өчен өскә күтәрде. Моңарчы Риф белән Лиль арасындагы туры сөйләмне өнәмичә утырган җирән чәчле кыз ачылып китте:

– Сатарга дип әзерләнгән фатирның алучысы да алдан ук билгеледер. Бизнеска исе китмәгән гамьсезләрне табарга кирәк... Әйтик, менә синең фатир ничә бүлмәле?

– Дүрт! – диде Риф, мактануын яшермичә.

– Ә пропискада кемнәр?

Риф, көтелмәгән сораудан каушап, ялган җавап эзләгән малай-шалайише як-ягына каранды, тел очына килгән җаваптан әйтмәгән килеш оялды. Хатын белән дисәң, әлеге кызларны бик тиз югалтыр төсле тоелды. Риэлтор моны бик тиз сизеп алды, соравын шундук үзгәртте:

– Ничә кеше дип әйтүем.

– Ә... ә! – Риф сөенеченнән җиңел сулап куйды, елмаеп та өлгерде хәтта. – Икәү.

– Дүрт бүлмәле фатирда ике кеше?! Бу бит үз-үзеңне талау! Уйлап кына кара: кешегә фатир ни өчен кирәк? Кайтып ашыйсың, телевизор карыйсың и... ятып йоклыйсың... Димәк, кухнясы, ваннасы белән бер бүлмә бик җиткән. Калган өч бүлмәне акчага әйләндерәсе...

– Миңа андый акча нәрсәгә?! Шөкер, эшләп торам.

Карале син бу дивана мужикны дигәндәй, Римм җитен чәчлегә мыскыллы караш сирпеп алды.

– Акчаның андые-мондые юк. Машина алырсың.

– Бар ул минем.

– Классикамы?! Синдәй беркатлылар «Жигули»га ябыша. Ә солидный күренәсең килсә «Мерседес», «БМВ», «Ауди»лар бар: көзгедәй елтыр кузовлы, чем-кара тәрәзәле, кондиционерлы, телевизорлы, суыткычлы...

– Караватлы! – дип үртәмәкче иде Риф, кыз ирек бирмәде.

– Әйе, алгы урындыкларын җәясең дә диван итәсең. Ул чагында бер бүлмәле фатирың да кирәкми!

– Аны да сатып җибәрәсеңме?

– Сатмыйсың. Метро төзүчеләр гаиләсенә арендага бирәсең.

Соңгы чирек гасыр эчендә, ниһаять, бер көйгә салынган гаилә тормышында ул кадәр үк кискен борылышлар ясарга әзер түгел иде әле Риф. Шуңа күрәдерме, җирән чәчле кызның табышлы тәкъдимнәренә ризасызлык күрсәтеп, шәрабы эчелеп бетмәгән бокалны үзеннән читкәрәк этеп куйды. Җитен чәчлесе моны шундук сизеп алды.

– Вау! Безнең инвесторның кәефе кителде. Риммга исең китмәсен, ул сүз уңаена гына иярде. Син бүген миңа кызыктың, әйе бит?! – Һәм ул, Рифның «әйе!»сен дә көтмичә, үзенекен җөпләде: – Вәт сөйләш минем белән.

Лиль шәрабның тәэсиреннән яңа танышына тәмам ияләшеп җиткән иде, үҗәт сорауларына җавапны күз карашларын төбәп таләп итеп торды. Мондый чакта аның күз зәңгәрлеге бер сыегая, бер куера кебек иде.

– Син миңа репетитор эзләргә булышасыңмы? Юк, репетитор гына түгел, доцент, профессор йә проректор булсын. Миңа югары белем кирәк. Болай да бер ел вакытымны әрәм иттем, ниндидер аферист арадашчы аркасында. Үз көче белән кергән балаларны «минем ярдәм белән керделәр» дип мактанган. Ә минем ише «проходной балл» җыя алмаганнарның акчасын кире кайтарды, быел педагогларның үз туганнары күп җыелды, дигән була.

– Әле дә рәхмәт, акчаңны кире биргән. Бик үк әшәке аферист булмаган икән.

– Акчанымы?! Мин аның кесәсен ерттырып ала идем.

Һәм житен чәчле кыз, үзенең артык кызып киткәнен сизеп, чак кына тынып торды. Шушы тынлыкта сыек зәңгәр күзләре куерды, ачулы йөзе юмагай елмаюга алышынды.

– Әйт, син миңа ярдәм итәрсеңме-юкмы?!

Яшьлек, чибәрлеге, ялгызлыгы белән синнән күпкә өстен тәвәккәл һәм көчлерәк җитен чәчле бер өмет күзгә карап туры җавап көткәндә: «Әйе!» – дип котылуы җиңелрәк. Көчлеләргә каршы төшеп: «Юк!» – дип әйтә алыр өчен зур көч кирәк. Риф баш изәде.

– Син шигырен өйрәнмәгән мәктәп баласы шикелле ым кагып утырма, «әйе»ңне өзеп әйт!

– Әйе.

– Килештек. Бир бишне! – Җитен чәч бокалдан бушаган кулын Рифка сузды.

Кызның кичә генә чәчәк аткан шомырт чугына тиң кулын эш бияләедәй учына алгач, Риф бер мәлгә өнсез калды. Аннары сизгер җанына күптән онытылган наз, яшьлегеннән бирле тынгы бирмәгән яшерен сусау, мәрткә киткән күбәләкне дә уятырлык җылылык күчә барганын тойды. Бу нәни бармакларның әле үз гомерендә йодрык күрсәткәне юктыр.

– Римм, өз әйдә бәхәсне! Ул миңа укырга керергә ярдәм итә. Ә мин бәрхет сезонда аңа ияреп диңгез буена барам!

– Тагын бер шешә китерсеннәрме? – Рифның бу соравы саубуллашуга сәбәп булды.

– Бүгенгә җитәр. Син безне такси белән кайтарып куясыңдыр ич?

– Ник, сез шушы тирәдән генә түгелмени? – Ул көтелмәгән яңалыктан теге реклама гәҗитен бөтәрли башлады.

– Оя янында кем шаяра инде?..

Такси чакырту йә кул күтәреп юл читенә чыгуның кирәге юк, мондый хезмәт күптән көйгә салынган, чатыр читендәге фонтанлы мәйданчыкка җыелган музыкалы машиналарның көндәлек эше икән ул.

Шунысы хак, кызлар Риф белән төн уртасында качышлы уены уйнарга җыенмыйлар, таксины олы юл читендә калдырып, җәяүләп кенә озатырга куштылар. Арча кырыннан сөенә-сөенә килгән җитен йомгактай айны түбәсенә алган күпкатлы йорт янына җиткәч туктадылар. Римм «чау! чау!»лап саубуллашты да керә торды. Лиль, башта бер сүз дә дәшмичә, юри киткән булды. Кире килде.

– Әнә җиденче катта, иң кырый тәрәзәдә ут янганны көт. Кул болгармын.

– Римм сездә кунамы?

– Юк. Без бер катта яшибез. Тәрәзәләре теге якта.

Кыз аның ияк очыннан пәп итеп үбеп алды да йөгерде. Баягы шәраблар Рифны әле генә исертте: уйлары кыюланды, фикерләре җетеләнде, өе онытылды... Бүген кызлар белән нәкъ кинодагыча чүкердәште, туйдагыча күңеле иләсләнде, юбилейдагыча шәраб эчелде, өч-дүрт сәгатькә генә яшьлеге дә әйләнеп кайткан иде кебек... Ә күңеле һаман нәүмиз калды. Туздырырга дучар ителгән хәрәм акча хисабына кабынган өмет тынгы бирми, ниндидер иң мөһим теләк гамәлгә ашмый калды. Риф кайтып китәргә ашыкмады. Ул кызның телефонына язма хәбәр җибәрде: «Китәсем килми. Әйдә, түбәдә таң аттырабыз. Чакыр мине».

Әпипә көенә «Юк. Ярамый» дигән җавап килде.

Риф үртәлде, кулындагы гәҗит уклавы белән тезләрен кыйнады, ачуы чыкты хәтта... Юк, имеш... «Юк!» дип әйтүләре җиңел ул кызларга, син менә үҗәтлегеңне җиңеп «Әйе!» дип әйтеп кара. Ярамый, имеш... Алайса нәрсәгә ымсындырасың? Сиңа, бәлкем, ярамыйдыр да, ә миңа ярый!..

Абзагызның тел очында «әйе!» белән «юк!» бәрелешкә керде.

«Әйе, сине бүген иягеңнән үбеп кочтылар. Шуның өчен күпме вакытың, акчаң әрәм китте».

«Юк. Мин бит чатырга сыра эчәр өчен генә килдем».

«Әйе. Башка көннәрдә син ул сыраны өеңә алып кайтып эчә идең. Акча коткысына бирелдең. Бу җитен чәчле чибәркәй бик күп ирләрнең чәчен агартыр әле».

«Юк. Хатынымның чәчен җитен төсенә буяттырам».

«Әйе. Кайткач кендеген дә кара син Тәлиганың...»

* * *

Такси хуҗасы Рифның юмартлыгыннан канәгать иде бугай, кайтыр юлда бик куаламады. Күрер күзгә артык гади, риясыз юлчының кәефен күтәрер өчен ниндидер изгелек эшләргә дә әзер иде хәтта.

Нәкъ шул вакытта, фара нурлары абайларлык ераклыкта гына, җәяүлеләр сукмагыннан олы юл читенә бер кыз сикереп төште: караңгы төн төсендәге колготкие елкылдап тора, түшенә сыланган кызыл күн курткасы таң алсулыгы белән балкый, биле нечкә, аяклары төз, йөзе төзек, күзләрендә тулган ай нуры, кулында хәрбиләр плащыннан тегелгән колак мендәре чаклы брезент сумка. Бу кадәр сөйкемлелеге белән төн уртасы таңга авышыр чакта берүзе ничекләр итеп курыкмыйча йөри ала икән ул?..

Кызны күрү белән, машина үзе дә, йөртүчесенә буйсынмыйча, тизлеген киметте.

– Җиңү проспекты! Озын аяклар эшкә бара, алабызмы?

– Алабыз, әгәр иярсә.

– Иярә дә, ияртә дә, саклана белмәсәң... Шутка! – дип, акцентын кавказлаштырып шаяртып куйды йөртүчебез.

«Төнге күбәләк» тукталган машинага ялт кына очып кермәде, ачык ишектән үрелеп салондагы ирләрне җентекләде.

– Малайлар! Минем шампанский эчәсем килә...

Маҗаралы юлчы буларак, кыз белән Риф сөйләшер дип көткән идеме, аның каушавын күреп, шофер үзе җавап бирде:

– Юл уңае икән, нәкъ кибеткә бара идек. Кунак янына утыр!

Юл уңаена алынган «Алтын шампан» кыз кулына күчте. Әгәр ачсаң, газлы шәраб утыргычларны күбеккә батырыр дипме, ул аны брезент сумкасына шудырды.

Риф урталыкта калды, кайсы якка аварга да белмәде, сулга борылсаң, хатын-кызны өнәмәгән әкәү кебегрәк килеп чыгар, уңга борылсаң... Ул инде кызның билен дә, күкрәкләрен, йөзен, хәтта чәчен дә күрмәс булды. Күз алдында кара колготкиның ялтыравык күзәнәкләреннән балкып торган бот та бот кына. Соңгы елларда кичләрен икәүдән-икәү генә калгачмы, ял көннәрендә дисеңме, бергәләшеп айлык отпускага чыксаң да шул ук – хатынының сары фланель халатыннан гайре матурлык күрмәгән ир өчен никах антыңа кул селтәрлек, тәүбәләрдән ваз кичәрлек, юлдан яздырырлык, хыянәткә мәдхия җырларлык алгысыткыч халәт иде бу. Рифның сабыр йөрәге, кинәт тибешен кызулатып, бөтен кан әйләнешен бил тирәсенә куалый башлады, уяулыгы йөгәнсез, аңы хуҗасыз калды. Рифның, машинада барган көйгә, чалбар балакларын сызганып кына булса да, ялангач аягын шушы ботларга тидереп карыйсы килде. Кыз сизгер идеме, шулай тиешлеген беләме – туфлиен салып шома тәпие белән абзагызның балак очына тыгылып маташа... Салондагы чит ил музыкасын җиңмәслек итеп кенә пышылдый үзе.

– Хатының бардыр инде... Тартынма. Өйләнгән ирләргә күбрәк ышанабыз без... Гайрәтле ирләрне бала табып алҗыган хатыннары тоткынлыкта асрый... Гаилә наркотик кына ул, ташласаң, ломка башлана... Хәзер яратышып уйнарбыз... Моңарчы төшеңә дә кермәгән ләззәт алырсың... Нибарысы өч меңгә...

– Шушындамы? Кеше алдындамы?

– Яратышыр өчен машинадан да җайлырак урын юк... Диваны йомшак, җылы, түбәбез ышанычлы, үзе тибрәтә... Тәрәзәләре ни өчен каралтылган дисең – безне беркем күрми...

– Юынмаган килешме?

– Ә менә бу нәрсә, сәфәр комганы гел үзем белән.

Ышандырыр өченме кызый, сумканы ачып, газлы суы яртылаш бушаган пластик шешәгә ымлады.

Йә Хода! Ниндиләрне генә күрмәгәндер инде бу комган?! Гомереңә баллонын күтәреп газлы су эчүдән ваз кичәрсең!..

Светофор төбендә кинәтрәк туктагач кына аңына килде Риф – сихерле пышылдауларга каршы торырга теләгәндәй баягы реклама гәҗитен уклау итеп чытырдатып кыскан икән ул. Баганадан төшкән ут яктысында кызый шул кәгазьне сыйпап ыңгырашып куйды:

– Ух ты какой!..

Риф өчен шушылар җитә калды: кичтән эчелгән шәрабның көче бетте; икенче сменадан әллә кайчан кайтып җиткән Тәлигасы күз алдына килде; иртүк эшкә барасы исенә төште.

– Кызый, минем акчам юк.

– Әйеме?! Әнә безгә бер «девятка» тагылганмы? «Әни» анда өч «әти» белән. Өеңә хәтлек ияреп барачаклар. Өч меңне биш итеп хатыныңнан сорап алырлар.

– Лутчы хәзер үк түләргә инде, – дип җөпләде шофер да.

Акчаны күкрәк арасына кыстыргач, «төнге күбәләк» гүя очып кына чыкты. Чыкты да күз ачып йомган арада сумкасыннан шампан шешәсен алып бот арасына кыстырды. Бөке шартлап ачылуга, пыяла гаурәттән күбек ургылды. Кузгалып киткәндә машина көзгесеннән карап барасыларын белә иде ул, шуңа күрә шешәне болгап-болгап торды...

* * *

Хатынының тәрәзәгә ябырылып көтеп ала торган гадәтен белә Рифат. Шуңа күрә ул таксины өй янына якын китермәде.

Йокымсыраган шәһәр өстенә офык ярыгыннан язгы таң кереп килә. Кояш чыгышына өелгән көяз болытлар иннеккә баткан. Күпер төбендәге әрәмәлектә ялгыз былбыл өзгәләнә. Табигать кочагында сәер бер үзенчәлектер – бары тик ата кошлар гына сайрый белә. Ана кошлар ояда утырганда, әтәч кошлар япа-ялгыз кала. Шушы ятимлек аларны сайрарга мәҗбүр итә. Моңлылары сайрый, сайрый белмәгәне сөйли. Тутый кошның ялгызлыктан интеккән әтәче хәтта кеше телендә сөйләшә ала. Ана үрдәкләр бәбкә көтеп ояда утырганда, ата үрдәкләрне атарга рөхсәт ителә. Комарлы сунарчылар көтеп алган өч атналык язгы ауда үрсәләнеп, сабырсызланып, эзләнеп очкан ата үрдәкләрне ядрә чүпли. Камышлыктан чыкмыйча, оясы янында гына йөзеп йөргәннәре исән кала. Бактың исә, кеше дә табигатьнең шушы кочагында яши икән...

Рифат төнге базардан кайтып килә. Күңелендәге теге гармунны путасына бикләп янә чормага ыргытты ул. Шәһәр урамында җырлап йөрергә ярамый. Тутый кош әтәче кебек үзалдыңа сөйләнеп барсаң гына инде... Туздырылган кадәрлесен өстәп, бу озын меңлекләрне кире илтеп бирергәдер. Тәлигамның кара колготкие бар микән? Ялангач тәненә кын куртка кидереп, шул колготкидан ишекле-түрле йөртеп карыйсы булыр әле үзен... Кеше өендә, чит мендәрләрдә йоклый алмаслык яшькә җиткәч, төнге базарга чыгалармы?!

Рифатның тамагы чатнады. Сөйләнеп бара торгач, сүзләре кипте. Юл читендә тәүлекләп эшли торган калай кибет бар. Тик абзагыз бу минутта сыра да, шәраб та, хәтта газлы су шешәсен дә күрергә теләми. Аның Тәлигасы тирән эчле касәгә куе итеп ясаган сөтле чәй эчәсе килә...

Шулчак, язгы тынлыкны сискәндереп, Казансуның Дәрвишләр бистәсе ягында ике көпшәле мылтык аткан тавыш ишетелде.

Рифатның колак төбеннән генә ядрә сызгырып үткәндәй булды...

# ЯШЬЛЕК БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Бер, бер, бер...

Йокыга киталмыйча азапланганда, арыганчы санарга кушалар, шуңа саный башладым. Үзем саныйм, үзем йокысыз төннең сәбәбен эзлим.

Мин берүзем төн белән күзгә-күз карашып ятам. Сәламәт кәефне тик торганда гына йокы ташлап китми...

Ышанычлы дус түгел син, йокы! Кичке унбер тулуга соңармыйча килеп җитә идең дә, иртәнге җидегә кадәр уятмыйча, тормыш ыгы-зыгысыннан алҗыган җанымның тынычлыгын саклый идең, беркемне дә якын китермичә, бүлдермичә, борчымыйча... Бүген син мине дезертирларча ташлап качтың. Ә уйлар шуны гына көтеп тора да. Йокысызны уйлар әсир итә.

Бер, бер, бер...

Бер башыма мең төрле уй, меңе мең килеш тора. Сайланып кына уйлыйммы, әллә рәттән тотыныйммы? Хәтер, син берүк горур була күр, вак-төяген искә төшереп ямьсезләмә.

Уч төбемдәге кәгазь кисәге зур могҗизага әверелер төсле. Кулымнан очып китә күрмәсен дигәндәй, мин аны йодрыклап кысам.

*«Мәхәббәт турында бик күп сөйләдегез. Ә үзегезнең яратып караганыгыз бармы? Бөтен зал алдында җавап бирергә уңайсызлансагыз, телефоннан гына хәбәр итәрсез.*

*Илсөяр...»*

Берәрсенең шаяртуы гына түгел микән бу?! Исеме туры килә дип, өметемне генә ялгыш азындырамдыр, бәлки. Ачык сорау биргәндә берәү дә үз исемен атап әйтергә тырышмый...

Мин – «Белем» җәмгыятенең күптәнге лекторы. Баштагы мәлне укыган нәрсәм, сөйләгән сүзем табигатьне саклау турында иде. Соңгы елларда бу темага сөйләшүләр лекция сыман түгел, ә дөресрәге, бәхәс рәвешендәрәк бара.

Тора-бара мин лекциямнең темасын алыштырдым. Иң тансык темага – мәхәббәткә күчтем. Укыдым, өйрәндем, анкеталар тутырдым. Мәхәббәт ул табигать кебек күзгә күренердәй нәрсә түгел. Ә күзгә күренмәс нәрсәләр хакында теләсәң ничек сүз уйнатырга була. Көндезге лекцияләр училище-техникумнарда, мәктәпләрдә үтә, әллә ни шаккатырлык бәхәсле түгел. Ә менә кичке очрашулар бөтенләй башкача. Дөрес, залда күбрәге мәктәп балалары – алар белән көндез парта арасында очрашкан инде мин. Кичке очрашуда аларга лектор да бала-чага дип түгел, мәхәббәткә сусаган яшьләр дип карый. Шуннан, укучы дәфтәренә язылган сораулар... Ул сорауларны мин алдан ук белеп торам, җавабы да күптән әзер: «Бар ул мәхәббәт... Ярату бер генә була. Бервакытта да соң түгел. Горурлык һәм тугрылык кирәк. Барыгыз да чибәрләр...»

Залда әллә адашып, әллә кызык эзләп кенә килеп эләккән бер-ике олыкайдан гайре һәммәсе дә яшьләр. Яшьләр дигәч, шаяртып, үртәп, бөтенләй тузга язмаган сораулар да була... Бәлки, Илсөяр дигәннәре дә болай гынадыр әле.

Ник соң үз-үземне юатырга тырышам? Шылтыратып карарга кирәк... Әгәр чынлап та Илсөяр үзе язган булса... ул чагында инде уйлар гына ярдәм итә алмас.

Стенадагы сәгатькә карамаска тырышам, вакытның соң икәнлеген болай да беләм. Телефоннан чит тавыш, дөресрәге, ирләр тавышы ишетелсә, алло, дежурныймы бу, диярмен. Төн уртасында мазасызлап ялгыш шылтыратучылар азмы, кайвакытта өеңә әллә нинди тавышлар килеп керә.

– Алло!

– Әйе.

– Илсөяр, синмени бу?

– Нәкъ үзем. Әллә каушый да беләсең инде.

– Шулай кинәт җавап бирерсең дип уйламаган идем.

– Шылтыратасыңны белдем. Көтеп утырдым.

– Кызык. Ә үзең телефон номерыңны язмагансың. Бала чагыңдагы фамилияң белән эзләдем.

– Ә минем фамилияне үзгәрткәнем дә юк.

– Минем дә фамилиям шул ук... көлмә, Илсөяр, көлмә, бар да искечә дип әйтүем.

– Катырак итеп тә көләр идем, күршеләр уяныр.

– Ничек искә төшердең син мине, Илсөяр?

– Урамда каңгырап йөргән чагында афишаңны күрдем. Мәхәббәт турында лекция дигәненә исем китмәде, лекторы син икәнне белгәч шаккаттым. Мәхәббәт буенча зур белгеч икәнсең. Кай арада шулхәтле тәҗрибә туплап өлгердең? Яшь чагында да алай осталыгың сизелми иде. Кызлардан курка торган кеше идең бит син.

– Үз башыңнан кичкәннәрне генә сөйләргә димәгән. Мәхәббәт фән бит ул. Хәзер аның үз философлары, язучылары, хәтта классиклары да бар.

– Ә син кеме буласың инде?

– Лектор гына, лектор! Фәндәге байлыкны гомумиләштереп, тыңлаучыларга җиткерүче, аңлатучы.

– Алайса, соравымны тагын кабатлыйм: үзеңнең яратып караганың бармы?

– Телефон ялыкмасмы?

– Ярый, өемә килеп аңлат. Лекцияләрнең андый формасы да бар бугай...

* * *

Ике, ике, ике...

«Йокы чүлмәге» дигән сүз иң борынгы әйтемнәрнең берседер. Туйганчы ашау гына түгел, туйганчы йоклау да кешенең гомерлек ихтыяҗы, йокы иң тансык һәм иң арзан ризык. Нинди кадерле төннәр бәрабәренә киләдер ул! Бүгенге төнемдә язмышымның иң мөһим борылышы хәл ителер сыман.

Ике, ике, ике...

Әгәр бер-берсен сөйгән ике йөрәк кавыша алмаса, җирдә бәхетсезләр арта. Бәхетен югалткан кеше кем белән генә кавышса да бәхетсез инде ул. Үзе дә бәхетсез, шуның аркасында янындагы кеше дә бәхетсез. Нәтиҗәдә бәхетсезләр күбәя...

...Мин сине ярата идем, Илсөяр. Ярата идем... Ярата идем. Идем?! Сәер. Яратуга үткән заман хас түгел, ул гомерлек, ә бәлки, мәңгелек заман фигыле. Мәхәббәт хакында «булган, беткән» дип сөйләргә ярамый. Ул... ул гел синең хәтереңдә. Әгәр югалтсаң, онытсаңмы? Димәк, хәтереңне дәвалыйсы бар. Исеңә төшерсен. Ярату өчен, тугры булу өчен онытуны белми торган яхшы хәтер кирәк.

Мин сине кайчан оныттым соң әле? Хәтер буразнасында ничек кенә күмелеп калдың да бүген тагын шытып чыктың. Хәтер дигәнең, ерак юлдан кайткан сәфәрче сыман, тузаннарын кага.

Яшьтәшләр, юлдашлар, урамдашлар, әйтегез әле, сез мәхәббәтегез белән кайда таныштыгыз, иң беренче тапкыр кайда күрештегез? Мәктәптә укыганда укмы, юлдамы? Паркта, кинода, ресторанда, больницадамы? Барыбер...

Ә менә без Илсөяр белән кара урман уртасында...

Яшьнең унҗидегә җитеп, балалыкның чыгам-чыгам дип торган чагы. Күңел нидер эзләнә, суларга керә, болыннарга чыга, карурманнарга бара.

Без аны карурман дип атадык. Еракка күрә, көн саен барып җиталмаслык булганга күрә. Анда онытылып йөрсәң, бурсык, бүреләр, поши, кабаннар, хәтта күрше авыл кешеләрен дә очратырга мөмкин. Утыны – имән, җиләге – кура, куагы – чикләвек! Туфрагы кара, гөмбәсе ак, чишмәләре саф. Комбайннардан иген ташучы машиналарга ябышып барыбыз да биштәр асып җәяү кайтабыз.

Чикләвек тәгәрәп уңды быел. Иртә-кичен тиеннәр җыя, көндезләрен – без.

Карурман уртасында, безнең инешнең башында, бер чишмә бар. Әгәр иренмичә, җәяүләп кенә инеш буйлап югарыга таба атласаң, нәкъ шушы чишмәгә, карурман уртасына килеп керәсең. Ә чишмә яны гел чикләвек кенә. Әллә уйнап, әллә чынлап сөйлиләр, имеш, карурман уртасында элек шомырт, гөлҗимеш куаклары, таллар гына үскән, ди. Ә хәзер аларның берсе дә калмаган, һәртөрле куаклар, кавыша торгач, чикләвеккә әверелгәннәр, тоташ чикләвеклек кенә.

Шулай итеп, җитмешенче елның карурман уртасы.

...Өлгереп кишәнкәдә саргайганын да көтеп тору юк, җыя башлаганнар. Авылда ялгыш кына берәр чикләвек кабыгы күрендеме, шул көнне үк бөтен халык дәррәү күтәрелеп урманга ябырыла. Хәтта тиеннәр дә, бабаларыннан килгән шартлы рефлексны бозып, кышлык хәзинәләренә өлгереп җитмәгән чикләвек җыялар хәзер. Соңга калсаң, карурманның бөтен чикләвеге капчык-капчык булып авылга күчә.

Чикләвек җыю чишмә суы эчүдән башлана. Телисеңме-теләмисеңме, сусадыңмы-юкмы, барыбер, иң элек чишмә янына килеп баш иясең, учыңа алып суын эчәсең. Бу чишмә шулкадәр саф ки, хәтта авылыбызның инсафлы кызлары да су эчәргә дип иелгәндә, оялудан күзләрен йомалар иде.

Һәм менә шушы саф чишмә ерак юл китеп, борылмалар кичеп авылыбыз аша үтә дә болганчык инешкә әверелә... Хәер, вакланма, хәтер...

Җимешчән түгел без, малайлар, ялкаурак димме... Чишмә тирәсенә тезелешәбез дә арабыздан кемнеңдер: «Әйдәгез инде, без монда ял итәргә килмәдек бит», – дип, ялынганын көтеп тик утырабыз. Ул арада кызлар да килеп җитә. Тезелешеп киләләр, иңнәрендә чиләк-көянтәләре генә юк, барысы да биштәрләп капчык аскан. Алар килгәч, карурман да яктырып китә. Чикләвек куаклары сыйпый башласа, бу ап-ак күлмәкләре, чәчәкле кыйгач яулыклары нишләр инде? Безнең өчен шулай киенеп-ясанып килгән кызлар дигәндә үзебезне аямыйбыз, юан-юан ботакларның очына үрмәләп җиргә сыгып төшерәбез дә – рәхәтләнеп җыегыз, кызлар!.. Без барында агач башына үрмәләмәссез бит! Ак күлмәкләрегезне кызганудан түгел, безнең күлмәкләр дә сандыктан бүген генә чыккан, эш шундадыр, бәлки, беләсез бит инде, уналтыны тутырып унҗидегә чыктык.

Рафаэль миңа төртеп куйды:

– Озак сайланма, өлешсез кала күрмә. Әнә «минем» Өлфәйдәләргә кайткан кунак кызга гына кара...

– Мин кояшка каршы карый алмыйм, күзем чагыла.

– Вот даешь! Үгетләп маташам тагын, әллә кайчан сайлап өлгергәнсең. Кояшка тиңлисеңме? Алайса килештек, икебез бер булып Өлфәйдәләр тирәсендә бөтереләбез.

Карурман дип юкка гына рәнҗетәбез икән, урман эчендә яшел ут яктысында йөрибез сыман. Әнә кырдан ялгыз тургай күчеп килгән, гел безнең тирәдә генә өздерә.

Рафаэль кыю малай:

– Тургай телен аңлыйм мин, сез – яшьләр – минем кебек ялгыз моңаерга калмагыз, – ди ул.

Кызлар көлешә. Аларны хуплап без дә пырхылдашабыз. Кайсы куакка кызыксалар, шунысы «баш ия» тегеләргә. Рафаэль, Өлфәйдәне ияртеп, шушы тирәдә генә юк булды.

Биек бер чикләвек агачының очына ябышып җиргә сикермәкче идем, бөгелмәде, бирешмәде, һавада эленеп калдым. Шулчак кунак кызның: «Һай, күзем», – дип әйтүенә, агачның бөгелүе, минем шап итеп җиргә мәтәлеп төшүем булды.

Гел өскә карап йөрсәң, шулай инде ул – күзеңә чүп коела. Кирәк чакта без дә Рафаэль кебек кыю әле.

– Кулъяулыгың бармы?

Ак күлмәкнең күпертмәле җиң эченнән зур бизәкле күбәләк очып чыккандай булды. Чигүле кулъяулык иде ул.

Көч-хәл белән генә күзен ачтырдым. Бер генә карады, әллә урманда, әллә урамда мин: әйләнә-тирәмдә әллә бар дөнья, әллә юк, белмим. Өнем дә кебек, төшем дә кебек. Моңарчы болай булганым юк иде... Шушы минут ничек үткәндер, анысын хәтерем язып өлгермәгән. Күзләренең нинди төстә икәнлеген дә хәтерләмим хәтта... Соңыннан бер күз сирпеп карармын әле дип, күпме җыендым, тик үзе белән очрашкан саен мин бу турыда оныта торган идем.

Шулай итеп, без җитмешенче елның карурманында...
– Исемең ничек әле?
– Илсөяр.
– Ә минем исемем...
– Беләм, Өлфәйдәдән сорадым.
– Илсөяр, син салмак җилгә каршы да карап тора алмыйсыңдыр, әйеме?
– Ник алай дисең?
– Керфекләрең...
Илсөярнең озын керфекләре күз төбенә күләгә салган. Бәлки, шуңа күрә дә мин аның күзләренең төсен абайлап өлгермәгәнмендер.
Ә кулъяулык миндә калды.
Карурманның болыннарында балга манылган чәчәк кенә. «Сабирҗан чүнниге»нә килеп чыктык. Бу умарталыкны колхозга шактый зур табыш китерә дип сөйлиләр. Сабирҗан агайның табыштан артып калган балы да бар. Ул балга түрәләр ияләште. Районнан да килләләр, каладан да. Түрәләр барында безнең ише «авылныкылар»га сан юк. Ә бүген Сабирҗан агай үзе генә. Безгә дә, кала түрәләрен каршылагандай, елмаеп торган була. Килгән кешене чәй эчермичә җибәрми инде ул үзе.
– Тартынмагыз, – диде ул, кунак кызга төбәлеп, – туган йортың бусагасын ничек атлап керсәң, шулай бул.
Илсөяр, балавыздай сап-сары нарат идәнгә басарга кыймыйча:
– Идән таптала бит, бигрәк тырышып югансыз, – диде.
– Ә син аңа басма, сеңлем.
Мин, нишләргә икән дип, тагын әз генә баш ватып торсам, Илсөяр оятыннан кире карурманга кереп югаласы иде. Ярый әле мин үзем ушлы, Сабирҗан агайның тел тебен аңлап өлгердем. Илсөярне күтәреп алдым. Ак күлмәге җилфердәп барды.
Өстәлдә күпне күргән самавыр, агач табакта кәрәзле бал, тәрәзә артында Сабирҗан агай чүнниге, күз алдымда Илсөярнең бал тигән иреннәре...
Чишмә суына ияреп, инеш буйлап җәяү кайттык, Илсөярнең биштәрен мин күтәрдем, ә ул – минекен. Рафаэльнең дә, минем дә чикләвекләребез кызлар күтәрерлек кенә иде шул.
– Кунак кыз безнең урман чикләвеген урлап китте димә, мин аны сабан туенда үзеңә дә бүләк итәрмен, кулъяулыкка өстәп.
– Илсөяр...
Кара гына урман, караңгы төн...
Карурман ерак инде... Төне генә яңәшә.
Төн уртасында хәтер белән өнем таган атына.
Бер, ике, өч... Өч, өч, өч...
Арабызга өченче кешеләр кергәләде. Алар әле онытылып та өлгермәгәннәр, хәтернең иң якынында гына. Алар назы Илсөяр исемен яшерде...
Мәктәпнең озату кичәсеннән без зур-зур хыяллар белән таралыштык. Әгәр ул хыялларның барысы да тормышка аша калса, берничә елдан ук диплом алып, кагыйдәсенә туры китереп кавышасы кешеләр идек без.
Медаль белән килгән абитуриентлар беренче имтиханны «бишле»гә тапшырырга тиешләр. Ә минем бер балл җитмәде. Теләсәң, башкаларга ияреп, имтиханнарны ахырынача тапшырырга да була иде. Күпләр шулай итте дә. Минем генә горурлык дигән үҗәтем ирек бирмәде. Бәлки әле, тәбрикләргә дип килгән Илсөярнең күзләрендә чагылган елмаю үртәүдән түгел, юатудан гына булгандыр.
– Институтка керү чикләвек җыю ише генә түгел ул сиңа.
– Китәм мин, Илсөяр.
– Кая?
– Миңа барыбер. Болай классташлар алдында оят.
Без хушлашмыйча гына аерылыштык. Илсөяр «Тукта!» димәде, мин борылып карамадым. Менә шулай юктан гына мәхәббәт формуласын чәлпәрәмә китердек. Институт баскычыннан төшүемә, мине буталчык юллар сагалап тора иде инде. Кердем мин ул институтка, соңрак булса да, барыбер кердем. Үземә җитәрлек белемем дә бар. Ләкин Илсөярне югалтуым иң зур югалтудыр дип башыма да китермәгән идем... Институтка керү дигәндә, бер урынга уникешәр кеше килә. Берәүне студент итсәләр, унберәве борылып кайтып китә. Әгәр шушы унберенең һәркайсысы Илсөярен югалта башласа, бүгенге төндә минем кебек йокысызлар бигрәк күптер...
Уйларымның уйланган кадәресе калып торсын... Кинәт кенә, менә кинәт кенә өзелеп-өзелеп, сулкылдап-сулкылдап, җаным-тәнем белән сусап, Илсөярнең тавышын ишетәсем килде.
Кайнар кулларым белән салкын телефонга үрелдем. Шунысы сәер, сәер дә, рәхәт тә, номерлар җыелып бетүгә, ул җавап та кайтара.
– Нихәл, Илсөяр?

– Күрештек ич инде бүген.
– Бүген түгел, әллә кайчан. Мин теге чакларга кайтып килдем.
– Йокламыйча искә төшереп ятасыңмы?
– Әйе, Илсөяр.
– Мин дә.
– Кай тирәдә йөрисең?
– Сабан туегызда. Сезнең авылда.
– Ә мин аны үтеп киткәнмен.
– Ярый, исеңә төшер. Комачауламый торам.
Телефондагы тавыш, кит-кит-кит дигәндәй, өзелеп калды.
Гашыйклар кавышсын өчен генә оештыралардыр бу сабан туйларын. Яше-карты, чибәре-әрсезе, толы-ятиме – барысы да бер мәйданда кайнаша. Ялгызлар пар эзли, бәхетлеләр янәшә, йөри алмастайлар да хәтта, каенлыкка утырган килеш кенә, яннарындагы хәләлкәйләрен дә онытып, мәйдан тирәсендә оныкларын эзләгән булып йөргән карчыклар арасыннан яшьлек мәхәббәтләрен күзлиләр. Алар өчен дә көтеп алынган бәйрәм бу.
Ялындырмаса-көттермәсә, кунак кыз буламыни ул?! Илсөяр килгәндә, мәйдан җыелып, беренче көрәшчеләр сөлгегә уралганнар иде инде. Рафаэль белән без аптырап басып торабыз. Ә Илсөяр килә-килешкә Өлфәйдәсеннән беразга аймылды да минем беләгемә тотынды, култыклап алган кебек. Илсөярнең сүзсез-нисез генә исәнләшүеме, гафу үтенүе микән?
Без егетләрнең гадәте шул – җае чыгып бер тирәгә җыелсак, дус кызларыбыз белән мактанышырга тотынабыз. Тыңлап торсаң, һәркайсыбызның да кызы дөньяда бер чибәр, бердәнбер сылу. Иптәш малайларны да мактанчыклар дип гаеп итәргә җыенмыйм. Дөрестән дә, дөньяда бөтен кеше дә сокланырдай, тел шартлатып гаҗиз калырдай кызлар бар. Бер генә кеше гашыйк булырдайлары да бар. Илсөяр яныма килеп баскач та, иярләнмәгән ат шикелле баш чөйдем: ахирәтләрем күрәләр микән?! Күрәләр, гел безгә генә карап торалар. Әнә мәйдан батыры да, Илсөярне күргәч, җилтерәтеп күтәргән көрәштәшен ялгыш кына кулыннан төшереп җибәрде. Миңа Илсөярне кеше күзеннән читкәрәк алып китәргә генә кала.
Инеш ярындагы сукмак тарайды. Бәйрәм шау-шуыннан ераклаштык.
Егылган карт өянкегә җайлашып, сүзсез-нисез генә туфли очына карашып утырган арада, шактый инеш суы аккандыр.
– Шушы инешкә каршы атласаң, теге чикләвекле аланга барып җитәсең, – дидем мин, тынлыктан котылырга теләп.
Илсөяр кинәт кенә нәрсәнедер исенә төшергәндәй итте, колак мендәре хәтле асылмалы сумкасыннан тәмәке янчыгы хәтле генә төенчек чыгарды. Янчык эчендә нәрсәдер шыгырдап тора.
– Каруманыгызның чикләвеген алып килдем. Сыйлыйм әле бер...
Күрсәң... түгәрәк конфет хәтле эре, яңа аерган бал төсле сап-сары чикләвекләр!
– Әллә өзеп алгач та кыш буе үсеп ятканнармы болар?!
Ә Илсөяр кеткелдәп көлә генә... Беләм инде, базар чикләвеге. Йоласына туры китереп «сабантуй чикләвеге» алып килгәч, рәхмәт дими ни дисең.
Инеш суыннан юылып ялтыраган ике таш алып килдем дә шарт да шорт чикләвек ватам. Бер төшен аңа, берсен үзем кабам. Сабан туеның иң рәхәт минутлары инде бу! Биш стакан чамасы бар, безгә күпкә җитәр әле...
– Гашыйк тиеннәр шикелле агач башына кунакладык та чикләвек ярабыз, – ди Илсөяр, – ә иртәгә химиядән экзамен, кайтып җитәсе бар.
– Безнең авылда гына кал, бергә тапшырырбыз. Мәктәптән справка бирерләр...
– Аттестатны да сездән алырмынмы?
– Карале, Илсөяр, алай була микән ул?
– Әллә тагы... Әйдә, лутчы тик утырганчы укыштыра торыйк. Әзерләнерлек җае гына чыксын, китап-дәфтәрем гел үзем белән йөри. Син кайсысын аласың, неорганик химиянеме, әллә органигынмы?
– Укы син, укы, Илсөяр, мин чикләвек ватам.
– Да, отличниклар шикелле чикләвек ватып кына утырып булмады инде... укыштырырга туры килә.
Ну, сыйса да сыя икән бу кызлар сумкасына... Чикләвек янында өч-дүрт китап, биш-алты дәфтәр дә булган әле.
Ник шушы сабан туйларын имтихан вакытларына туры китерәләрдер? Башка бәйрәмнәр бер дә алай түгел. Хәер, сабан туе безнең як бәйрәме генә бит ул. Ә имтиханнар бөтен ил буенча... Безгә дигән сабан туйлары алда әле.
Илсөяр мине бөтенләй онытты: укый да укый. Игътибар итмичә генә, учына салган чикләвекне каба тора: ватып өлгертер хәл юк. Инде үзем дә капмыйм, аның кулына кагылуы кызык. Утыра торгач, теге «биш стакан» дигән чикләвекне ашатып бетердем мин моңа. Ташларны да урынына илтеп куйдым. Илсөярнең исе дә китми, укый да укый...

– Чикләвек бетте, Илсөяр.
– Жәл, – дип куйды бу.
Әле ярый, мин әйтәм, күбрәк алып килмәгәнсең, дим эчемнән генә, тәки таң атканчы чикләвек сытудан баш чыкмас иде.
– Илсөяр...
Китап ябыла.
– Илсөяр, мин сине кеше яшәми торган утрауга алып китәр идем.
– Хәзер үкме, китап-дәфтәрләремне алыйммы?..
– Кирәкми. Без анда икәү генә.
– Ул утрауның бер башыннан икенче башына свиданиегә йөрербез.
– Гел, гел бергә, Илсөяр!
– Миннән туйгач, башка утрауга китәрсеңме?
Шулчак әллә аяк астындагы туфрак күтәрде, әллә Илсөяр утырган өянке гәүдәсе сыгылып куйды... Мин аны үбеп алдым бугай...
Безне күзәтеп торган яшь таллар, бөгелә-сыгыла сөенешеп, бер-берсенең иңнәренә орындылар. Инешебез Иделгә охшарга тырышып җитдиләнеп калды. Сабан туе бетмәс, ахры, бүген дип, баш очындагы ояларга каргалары әйләнеп кайтты. Буш абзарларда бәйрәм сылтавы белән көтүчесез калган кәҗә-сарыклар кычкырыша, сыерлар мөгри. Ябылуга күнекмәгән казлар алгы бакчада бәбкәләрен тыя алмыйча каңгылдаша... Барысы да хәтердә...
Бер, ике, өч... Өч, өч, өч...
Уйларымның кодрәтен беләсем килә. Өченче бер кешенең тавышы, киңәше кирәк. Рафаэль!.. Минем өчен бүген вакыт дигән чик тә, еллар дигән газаплану да юк. Хәзер мин моннан мең чакрым ераклыктагы Рафаэль белән сөйләшәчәкмен. Башка вакыттагыча хатлар язарлык та чарам юк.
Ерактагы шәһәр кешесен уятуы җиңел түгел. Телефоннан йокы аралаш «Ал-ла-а-о» дип мыгырданулары авыз ачып иснәү белән бергә кушылды.
– Рафаэль, мин әле бу!
– Әйтмәсәң дә беләм. Шушы вакытта кем шылтыратсын тагын.
Кадерен генә белмибез телефонның. Уйдан да җитез йөри ул.
– Өлфәйдәңә, улларыңа сәлам әйт.
– Анысы иртән, уянгач. Ни булды?
– Йокы качты.
– Дару эчәрләр.
– Илсөярне очраттым. Очраттым дип, ни...
– Тукта, яшьти, кухнядагы телефонга күчәм, хатын уянмасын. Бераз гына көтеп тор.
Пауза. Ике шәһәр арасында төнге тынлык.
– Кайсы Илсөяр ул, хәтерләмим.
– Өлфәйдәңнең дусты инде, теге, чикләвек җыйганда...
– Ә-ә-ә! Синекеләр икән әле. Мин әллә яшьлек мәхәббәтләремнең берәрсе синең аркылы эзләтәме дип сөенгән идем... Йә, шуннан, туйга чакырасыңмы?
– Нинди туй ди әле, Рафаэль?! Илсөярнең тавышын гына ишеттем.
– Тавышы чыккач булган инде, калганына сине өйрәтәсе юктыр. Әллә киңәш сорап шылтыратуыңмы?
– Шулайрак иде. Ничек уйлыйсың, көрешергә микән?
– Юри ачуны китерер өчен сорыйсың инде син моны. Төн уртасында мактанасың килдеме?
– Кирегә борма әле, Рафаэль, мин бит чынлап сорыйм.
– Чынлапмы? Ике дә уйлама, көреш. Җае килгәндә файдаланып кал.
– Мең чакрымнан өйрәтеп торуы җиңел ул... Әгәр мине шушыныңчы ярата торган булса, ник соң моңарчы эзләмәгән?
– Син прав, көрешмә. Горур булып кал!
– Тол ир булып кал, дисеңме?
– Хатын-кыз күрергә мәхрүм диярсең.
– Яраткан кешең белән яшәүгә ни җитә...
– Карале, синең Илсөярең чибәр нәмәрсә иде бугай ул!
– Чибәр генәме соң! Озын керфекле, калын толымлы, нечкә билле.
– Ике дә уйлама, көреш! Андыйлар сирәк очрый хәзер.
– Синең Өлфәйдәң дә шундый иде ич.
– Һәй, көлдермә әле, нечкә бил... караватка сыймыйбыз хәзер, ашыгыбрак өйгән печән кибәне шикелле.
– Менә бит ничек. Әгәр Илсөяр дә шулай булса... Юк, көрешмәскә кирәк. Мин аны яшьлегемдәгечә хәтерлим. Очрашабыз дип, нечкә билле, калын толымлы, озын керфекле Илсөярем янына атлыгып

барырмын... ә ул, маңгаена җыерчыклар тезеп, киселгән чәчләрен тырпайтып, алтмышынчы размерлы кофтасын иңенә салып каршыңа килсә... Ул чагында яшьлегемнән Илсөярне сызып ташларга туры килә, картайгач хыяллана-хыяллана искә төшереп утырырдай кешем дә калмый.

– Ну син шаккатырдың әле мине. Кияүгә чыккан көнне үк үзгәрә башлый бит ул. Үзгәргән саен хатын аерасыңмы? Үзең ничегрәк соң? Гел шулай мәктәп малае кебекме? Көзгегә кара – күз төпләреңдәге чикләвек биштәре каян килгән дисең? Сиңа матур хатын кирәкме, әллә тормыш итәрдәй якын дус эзлисеңме? Менә шуны ныклап ачыкла да яңадан шылтыратырсың. Ә мин йоклый торам.

– Әй, әй, Рафаэль, ашыкма, әрләсәң дә риза, телефоның сөйләп торсын.

– Гомереңбуе мәхәббәт турында фәлсәфә өләшеп, кешеләр язмышын көйләп йөрисең. Ә үзеңнең тормышыңның рәте-чираты юк. Өйләнер идең, акылың гыйшыгыңны бугазлап тоткан. Курыкканга күрә сайланасың: тегесенең белеме юк, монысының дуслары күп, чәче кыска, буе озын, көлә белми, алгы теше юк, аягы нәзек, биле юк... Өйләнер өчен батыр йөрәк кирәк шул... Әйт әле, иптәш лектор, мәхәббәт белгече, мәхәббәтнең барлыгына ышанасыңмы соң син?

– Яшәү – ярату бит инде ул, яратмаган кешенең кемгә кирәге бар!

– Максим Горький сүзләрен сөйләмә миңа. Син менә үзең ничек уйлыйсың, үзең?!

– Бар бугай ул, Илсөярнең тавышын ишеткәч, исемә төште...

– Хәзер үк очрашыгыз!..

Әгәр мин Илсөярне бу юлы да югалтсам, үз-үземне гафу итмәм. Мәхәббәт мине барыбер эзәрлекләр. Вак-төяк юанулар белән онытылып торган булыр да авыр бер тынлыкта, кичке ямансулыкта, төн уртасында япа-ялгыз чагымны туры китереп, хәтер өеменнән бәреп чыгар. Мәхәббәт ул – мәңгелек заман фигыле. Таң атканны да көтмичә барып ишеген шакырга, тәвәккәлләргә, хәзер үк!

Бер, ике, өч!

# АВАЗЛАР

Рәхәт тә соң җәй куенында! Сулышыңда саф һава, баш өстеңдә юмарт кояш, тургай сайравы...

Риф колак төбендә кемнеңдер мышнавын сизде. Мышнау гынамы, затсыз ис тойган җан ияседәй еш-еш борын пырхылдатып, аның колак артын кемдер исни иде. Риф, ялкаулыгын җиңеп, күзен ачты һәм ни күрсен! Рифтан да ныграк шаккатып, ямь-яшел күзле, кәкре мөгезле, күпертмә сакаллы кара кәҗә карап тора! Сүгенүдән чак тыелып калды Риф. Авылдан киткәндә ашыгып сатып җибәргән үз кәҗәсен таныды ул.

– Йә, дүрт аяклы шайтаным, көтүчеңне әлсерәтеп, нишләп кәеф-сафа корып йөрисең? Кешеләр янында ни калган сиңа?

«Кешеләр җәйге челләдә аяк өстендә, син чучкадай аунап ятасың».

– Шәһәр кешесенең бер атнага ике көн ял итәргә хокукы бар.

«Тереклек ял итми... Якшәмбедә дә иген үсә, печән өлгерә, яңа бәрәнге ярала».

– Шәһәрдә көн саен уттай эш өсте.

«Әллә утка да барып кердеңме?»

– Әйтик, утта ук түгел, бераз күләгәсендәрәк ди, шуннан?

«Хәзер таныдым. Син – Рифкать, минем беренче хуҗам».

– Рифкать түгел, Риф! Сыпырт моннан, мөгезең бәйгә куяр өчен синең, күземнән югал!

«Өч хәрефле исемең белән кеше рәтендә йөргән буласың, өркетмә! Сөзмәсәм, рәхмәт диярсең. «Кырык капка»га без кәҗәләр хуҗа хәзер. Сез һичбер хокуксыз мәхлуклар».

– Кит, диләр, юкса сакалыңа ябышам!

«Тавышыңны күтәрмә, миннән артык берниең дә юк, хатының үзеңә «мөгез куйды», сакалың шәп, мин печәннән генә, ә син икмәктән тирес ясап ятасың. Ачуымны китермә лутчы, юкса Шәмсине чакырып чыбыркы белән ярдырам үзеңне».

– Кайсы Шәмсине әйтәсең?

«Көтүне йорт башыннан чиратлашып көтәләр хәзер. Бүген Шәмсинең чираты. Хәтерлисеңме, ул безнең нигез күрше иде».

– Онытырлык итмәде.

«Чакырыйм әле үзен. Шә-ә-әмси!»

– Шәмси, бу синме?

«Мин».

– Ник килдең?

«Яныңнан киткәнем дә юк. Үзең дә бит «Кырык капка»га соңгы көннәрдә бик еш кайтасың».

– «Жигули»ема утырсам, гел шунда каера.

«Сагынганга шулай ул. Киткәндә, күршеләр белән тынышмадым, дип әйтеп калдыргансың. Шәһәрдә ничек соң?»

– Авылда ике якта ике күршең и бетте-китте! Ә шәһәрдә – дүрт як стенада, идән астында, түшәмдә, бөтен йорт тулы күршеләр.

«Күршеләрне сөймәс кешегә көпчәкле вагонда яшәргә кирәк: ошамый икән, күчеп утырасың, тагын ошатмасаң, янә күчеп китәсең».

– Аның каравы шәһәргә килгәч кушаматымнан котылдым. Кечкенә чакта эткәйгә ияреп каравылга йөри идем, берничә хәрефне генә кулланып сөйләшә торган чак. Шулай бермәл телефон шылтырый, эти күргәнче дип, трубканы алдым. Кем бу, диләр. Мин этинең исемен әйтәм – Яхъя! Әйтүен әйтәм дә, ә ул «Я-я!» килеп чыга икән. Тегеләр кабатлап сорый, мин тагын «Я-я!» дип җавап бирәм икән. Шуннан «Я-я!» дип куштылар.

«Ә беләсеңме, йортын сатып шәһәргә киткән һәр кешене: «И, Я-я!» – дип сүгәләр хәзер. Сиңа тиңләп сөйләүләре. Әллә кайчан совхоз үзәгенә күченеп беткән «Кырык капка»ның тузанлы бусагасына кайтып егыласың. Җимерелер сәгатен көтеп яткан соңгы йортны да быел утынга сүтеп алып киттеләр. Ә син һаман кайтасың, качып кайтасың. «Жигули»еңны караштырырга чыккан җирдән, яшь хатыныңа да әйтеп тормыйча чыгып сызасың. Ә хатының синең кайда икәнлекне белә, чөнки соңгы елларда юлларыңның һәр тармагы «Кырык капка»да төенләнә. Эзләмәсләр иде, хатының өчен син «җенләнгән» кешеләр исемлегендә. Бертуктаусыз үз-үзе белән сөйләшеп, күзгә күренмәс кешеләр белән бәхәсләшеп йөргән кеше машинага утырып чыгып китә икән, бәла-каза булмас дип кем гарантия бирә ала?»

«Тукта әле, Шәмси, барын да әйтеп бетермә, миңа да бер-ике сүз калдыр».

– Сине дә таныдым, директор, сөйлә, давай, сөйлә, сүзләреңнән куркасым юк. Мин совхоз белән якалашып китмәдем.

«Хәтерең алдамыймы? Исеңә төшер әле... «Кырык капка» совхозның бер бүлекчәсе иде. Ятимәдәй гел читтә яшәп алҗыган халык үзәккә күченә башлады, тиз генә түгел, әкренләп, әлбәттә. Иң әүвәл яңа өйләнешүчеләр башлап җибәрде бу эшне. Башка чыгарга, нигез күтәрергә дип хәстәрләнеп тормадылар алар, чөнки һәрберсен үзәк усадьбада типовой йортлар көтеп тора иде. Яшьләргә ияреп, олылар да үзәккә тартылып торды. Ә менә урта яшьтәгеләр... Алар бик озак тарткалашты: күпләргә калай түбәле гүрнәчәсе, кемнеңдер алма бакчасы җәл, ак мунчасын телгә алучылар да табылды. Шулай да күпчелекнең тарту көче аларны суырып алды. Ә менә синең кебек аксөякләр, утка сарылган төнге күбәләкләр төсле, шәһәрнең реклама яктысына ыргылды... Тыңла, кем, Риф, тыңла, йоклама, эшеңә кайткач йокларсың».

– Нинди йокы ди ул сез барында?.. Шушындый җәннәттә, газраилләр кебек, мин кайтканны сагалап йөрисез.

«Жигули»еңа утырып кына җәннәткә кайттыңмы?»

– Кем ничек булдыра ала бит...

«Мактанырга рөхсәтме, диген. Туган йортны сатып алган машинаны малга санамыйм мин».

– Вакытында сатып калдым, юкса әнә күпләрнеке утынга сүтелгән.

«Вакытында, бик вакытында...»

– Машина дәрәҗәле итте мине! Руль артында берүзем, ә каядыр ашыгучы халык, сарык көтүедәй бер читкә укмашып, минем «Жигули»ның үтеп киткәнен көтеп тора... Ул төркем арасында син дә бик еш туры киләсең, директор, теге, калага килгән чакларыңда дип әйтүем.

«Жигули» ничә ат көчле әле ул, Риф?»

– Түгәрәкләп әйткәндә, җитмеш, директор, җитмеш.

«Җитмеш ат, дисең инде алайса, ә менә утызынчы елларда җиде ат тоткан кешене дә «кулак» дип атый идек».

– Тиле тукран кебек, яшь имәннән бөҗәк эзләп маташма! «Жигули»лы мин генәме?

«Кырык капка»ише авыллар күптер күбен, кәнишне, синең ишеләр дә. Ләкин бу дөньяда һәркем үзе өчен үзе җавап бирә!»

– Нәрсә бирер иде миңа шушы черек «Кырык капка»? Калага буш кул белән килдем. Монда алган тәрбия анда ярамады, белемемне калада яңарттым, дәрәҗәмне калада күтәрдем. Амбар үлчәүчесе идем, хәзер бүлек начальнигы, фәнни дәрәҗәм дә бар!

«Әйтмичә түзәрменме дигән идем, юк, әйттердең инде. Чынлап та, әллә кем син хәзер. Колхоз базарыннан фольклор җыеп, «имеш» белән «мөгаен» темасына диссертация яклады да дәрәҗәле рудиментка әйләндең. Зур-зур түрәләр, шөһрәт казаныр өчен, җае чыккан саен, мин авылда тудым, көтү көттем, чабата кидем, дип мактаналар. Син дә шулай, җае чыккан саен... Ә үзең нигезең хакын, атаң-анаң хакын саткансың».

– Әллә гел белмәдең, директор, мин бит этисез үстем, исеме генә сукыр эчәге кебек ябышып килгән шунда. Мине әни үстерде, әни исеме белән атагыз, ишетәсезме?! Риф Салихович түгел, ә Риф

Әлфинурович дип!!! И вообще, төкерәм мин череп таркалган «Кырык капка»гызга! Менә хәзер шырпы сызам да черек калдыкларын утка өерәм.

«Ташла, өр-яңа кешедә ниткән иске гадәтләр инде ул тагын».

«Рифкать абый, җан кисәгем... Риф Әлфинурович, нишләвең бу?»

– Син барысын да тыңлап тордыңмы, Зөһрә?!

«Әлбәттә».

– Ник соң бүлдермәдең?

«Минем белән иң соңыннан гына сөйләшәсең ич».

– Ачуланма, әллә кайдан гына кызыл әтәч очып килде дә кычкырыпмы-кычкыра! Кикри-күк! Кикри-күк!

«Кикри-күк түгел, кәк-күк, кәк-күк! «Кырык капка» урманында күке кычкыра. Ул безнең аймыл үткән елларны саный, Рифкать абый, җан кисәгем... Онытылма, Риф Әлфинурович, магнитофоныңа язып кал. Кышкы бураннарда, шәһәр тәрәзәсе аша буранга бармак яный-яный, магнитофон тасмасыннан «Кырык капка» тургайлары тавышын тыңлаганда, шушы күкене дә ишетерсең. Ишетерсең!»

– Ник без бергә түгел, Зөһрә?

«Киләчәкне алданрак күз алдыңа китерә белмәдең син, Риф. Миннән аерылуны авыл тузаныннан котылу дип кенә карадың. Шуның өчен дә мин сине күралмыйм!»

– Ник соң әле яныма килдең?

«Кәҗәбез көтүдән кайтмады, шуны эзләп кенә йөрүем».

– Ләкин син нигәдер кәҗәгезне мин монда чакта гына эзләргә чыгасың.

«Нәрсә калган инде сиңа? «Кырык капка» күптән совхоз үзәгенә кушылды. Монда аның тузаны гына калды, йортсыз нигезләр, урамында бала-чага авазы да яңгырамый, тавыкларны яклап әтәчләр дә сугышмый, майлы таба исе дә таралмаган».

– Һәм шушы авыл сагындыра.

«Авыл – кешеләр бит ул, Риф. Ә кешеләр – без. Син безне сагынасың».

– Зөһрә, хәзер сиңа иярәм дә үткәннәребезнең кыл бер уртасына барып керәм. Хезмәт кенәгәсенә бүлек мөдире дип язылган кешене көрәк мөдире итеп булса да алырлар әле.

«Кеше гомерендә югалтулар бик күп инде ул. Барысын да кайтарып буламыни? Хуш, Рифкать абый, җан кисәгем. Сау бул, Риф Әлфинурович, миңа китәргә вакыт. Әнә маңгаена тавык тәпие сурәте төшерелгән кызыл билле машинага утырып яшь кәләшең килеп җитте. Кара аны, карышасы түгел, юкса тагын аяк-кулыңны бәйләп салырлар».

– Тукта, Зөһрә, хушлашма, без ул кәҗәне бергәләп эзләрбез, тукта-а-а...

* * *

«Риф Салихович төш күрдеме?» – дип сорарсыз. Уй һәм хыял үзе бер төш бит ул...

# КУЕН ҖЫЛЫСЫ

Бу дөньяда эч сереңне сөйләргә тилмереп йөргән чаклар да еш була икән. Бер уйлаганда, күршетирәңдә дә, эшеңдә дә дуслар гына инде, сөйлә сереңне, рәхәтләнеп тыңласыннар... Сернең серлелегенә карап кына сөйлибез дә бугай: дусларыбызны, таныш-белешләребезне очратсак, эндәшмичә үтеп китмибез, сер сөйлибез, сер алабыз; үз серебезне сакласак, кеше серен чишеп булса да әңгәмәдәшебезне куандырырга, шаккатырырга тырышабыз. Еш һәм бик еш кына адресы ялгыш язылган хат шикелле, үз серебез үзебезгә кире әйләнеп тә кайта...

Ә син менә вокзалга бар. Берәр буш урын тапсаң, кил дә утыр, сабыр гына көтеп тор. Эндәшмичә калмаслар. Курыкмыйча ачыл син боларга, вокзалдагы күршең барысын да күтәрә. Дөрес, сүз башладың исә, мондагы һәр кеше тизрәк үз зарын сөйли башлый. Сөйләр өчен сиңа да чират тияр. Ул арада инде соңга калган поездлар да килеп җитә. Һәм, берегез әшрикъ, икенчегез мәшрикъ якка дигәндәй, китеп тә барасыз. Сөйләгән сүзләрегез хат булып та, таш булып та әйләнеп кайтмас.

Эш урыны юлда Фәйзелнең. Заводны кирәкле җиһазлар, чимал белән тәэмин итү өчен тырыша ул; күрше шәһәрләрдәге заводларга заказлар илтә; тегесен эзли, монысын таба, алыштырасыны алыштыра. Эшенә күрә танышлары да җитәрлек Фәйзелнең – юлга чыккан саен яңалары арта. Әлбәттә, һәр танышка да дус булып калырга диелгән әмер юк, күбесе әнә шул бер күреп сөйләшкән таныш килеш кенә бераз истә торган була да, әкренләп хәтер өеме арасында бөтенләй күмелеп кала. Еллар үткәч кабат очрашсаң да, алар белән инде яңадан танышырга туры килә. Иренми Фәйзел, кирәксә ярты көн вакытын да кызганмас – тик юлга чыккач серле танышлар тел шартлатып тыңларлык маҗаралар гына

сөйләсен аңа. Юлда күңелсезләнмәс өчен, ул күргәненең туганы, күрмәгәненең дусты, бабайларның яшьтәше, ханымнарның мәхәббәте булырга да әзер.

...Фәйзел ике ягындагы күршесен дә җентекләп күзәтеп чыкты. Берсе әбиләр яшендәге хатын-кыз – сентябрь башы гына дип тормаган, сырма киеп, шакмаклап сугылган калын шәл ябынган, ярты капчыклы биштәренә таянып, рәхәтләнеп йокымсырый. Юк, дип уйлап куйды Фәйзел, бу түмгәктән ни он, ни йон, ни запчасть, танышу ул һәрвакыт җимеш бирергә тиеш. Менә икенче яктагы күршесе болай күрер күзгә эшлекле генә кеше, ахрысы. Ыспай гына киенгән, күзлекле, галстуклы дигәндәй. Ике йозаклы портфелен, алдыннан төшермичә, өф! итеп кенә тора. Иптәшләре дә, хатыны-мазар да янында юк. Ир кеше ялгыз гына юлга чыкса, бел дә тор: ул командировкада, ә командировкага теләсә кемне җибәрмиләр.

– Бу вокзал тирәсендә кеше бер дә бетеп тормый, – дип башлады сүзен Фәйзел, күршесен сөйләндерергә теләп. – Карасана, нихәтле эшсез әрле-бирле чемодан ташый. Ярый хет ашыгучылары да бардыр инде. Ә менә болары, – диде ул, хатынының алдына башын куеп эскәмиягә сузылып яткан бер агайга таба ымлап, – мөгаен, тәүлекләр буе шушында аунап ятадыр... Әгәр мондагы халыкны поезд көткән арада гына эшкә кушып торсаң, ә?! Вокзал белән янәшәгә берәр комбинат салып куясы да эшләтәсе үзләрен. Билет бәясен дә капларлар, вакыт та тиз узар иде.

Гадәттә, Фәйзелнең бу фикере һәр яңа танышны да елмайта торган иде. Әлеге кешенең генә кырыс йөзе һаман үзгәрмәде.

– Минем эшләп торырга вакытым юк, тиздән поездым килеп җитә, – дип кенә җавап бирде ул.

– Кайсы якларга юл тотасыз? – Фәйзел, кәприз ханымнар белән сөйләшкәндәй, тавышын йомшартты.

– Саратовка.

– Эш беләнме?

– Юк. Язмыш кызык итте бит мине: бер хатыным – Казанда, икенчесе – Саратовта. Икесендә дә берәр балам бар. Тәки йөрим менә шулай, ике шәһәр арасында.

– Ә син билетыңны югалт та Казанда кал йә, киресенчә, Саратовтан чыкма.

– Әйтергә генә җиңел. Уйлап карасаң...– дип, абзыйның ачылып китәргә исәбе бар иде дә, тик Фәйзел күңеленнән генә кул селтәде, ир белән хатын турындагы хикәяләрнең һәммәсенең дә эчтәлеге бертөрле.

Ул арада ике ханым үтеп бара иде, Фәйзел күршесеннән гафу үтенде дә аларга иярде. Ханымнарның берсе бик нык ашыга иде, озата килүе дә итагатьлек өчен генә бугай, дустын поезд туктыйсы платформага алып килгәч, үзе тиз генә олагырга ниятләде.

– Менә, – диде ул китәр алдыннан, – алтынчы вагон шушы тирәдәрәк туктар, үпкәләмә инде, вакытым юк, поездың килгәнче көтеп тора алмыйм.

Ханымнарның исемнәрен дә ишетеп калды Фәйзел: озата килүчесе – Сания, ә китүчесе – актан киенгәне – Роза икән. Тагын Фәйзелне кызыксындырганы «алтынчы вагон» дигән сүз булды. Аныкы да алтынчы лабаса. Шушы кызыксыну Роза белән саубуллашып киткән Санияне эзәрлекләп барырга һәм аулаграк дигән урында аның юлына аркылы төшәргә, иптәш кызы турында сорашырга мәҗбүр итте...

Ярты сәгатьләп вакыт үтте.

Фәйзел әйләнеп килгәндә, хат ташучы поезд килеп туктаган иде инде.

Алтынчы вагонга кергәч, Фәйзел үз урынына утырырга ашыкмады, башкаларга сиздермичә генә ак күлмәкле ханымны эзләп тапты. Вагон эчендә һәркем урнашып, җайлашып беткән иде инде. Бер әби генә «ак ханым» тирәсендә зарланып тора:

– Вәт тамаша, билетны өске катка биргәннәр, ни хәл итеп менепләр ятармын икән?!

Ә Фәйзелгә нәкъ шул гына кирәк тә.

– Әбекәй, пожалысты, менә минем урынга килегез, – дип, әбигә икеләнерлек вакыт та калдырмыйча, билетларны алыштырып куйды. Һәм шулай итеп Фәйзел, шакмаклы юл сумкасын тотып, «ак ханым» янына килеп басты.

– Роза! – Фәйзел бу исемне шундый итеп әйтте, хәтта «ак ханым», янындагы ирне танымаса да, аның, һичшиксез, иске таныш булуына ышана иде.

– Әйе, мин Роза, – диде «ак ханым», оялып кына, – тик сезне хәтерли алмыйм.

Бу оялу ир кешенең шушылай тилмереп, йотлыгып һәм бер үк вакытта сөенеп каравыннан кыенсынып калу гына түгел, ә Фәйзелне исенә төшерә алмаудан уңайсызлану да иде. Ак күлмәгенең ачык изүеннән сафлык бөркеп, кызыктырып торган тәненә алсу төс йөгерде. Әйтерсең аңа әле Фәйзелгә кадәр бер генә ир-атның да күзе төшмәгән булган.

Фәйзел җавап бирергә ашыкмады. Хатын-кыз дигәнең җавапсыз калган сорауларны бик өнәп бетерми, җавап тапмый торып тынычланыр дип уйлама да. Кем-кем, ә Фәйзел инде моны яхшы белә.

Роза поездның кузгалганын сизмәде дә. Башка вакытларда ул, телевизор экранына ябырылган нарасый төсле хирысланып, тәрәзәдән карап барыр, кул болгап калган озатучыларның аерылу сагышларын күңеленнән генә кичереп карар, тәгәрмәчләр тыкылдаган саен ерагая барган Казан

каласына үзе дә: «Сау булып тор!» – дип пышылдап куяр иде. Юк, бүген болар барысы да онытылды, ник дисәң, каршысында күзгә-күз карашып серле билгесезлек утыра.

– Танымавың да гаҗәп түгел, унбиш ел вакыт үткән...

– Унбиш ел элек мин авылда яши идем әле.

– Салкын Чишмәдә. Карале, ул чишмәгез һаман шулай шаулап агып торамы?

– Әйе... Кызык, сез мине чынлап та беләсез. Мин генә хәтерләмим. Хәер, иртәдән кичкә кадәр күз алдыбыздан күпме кеше чагылып үтә, барысын да ничек искәреп каласың?.. Назландырып тормагыз инде, әйтегез, кем сез?

– Син авылга бер чибәр кыз идең. Сиңа күз тутырып караган өчен генә дә кайбер егетләр бер гаепсезгә тукмала торганнар иде.

– Анысы дөрес. Клубка гел абыема ияреп кенә килә идем.

– Сез, салкын чишмәлеләр, Аппакай авылына йөри идегез, аларның клубы да зуррак, егетләре дә шәһәрчәрәк. Ә мин читтән генә күзәтеп торам да шуның белән юанам.

– Якын килергә курыктыгызмы?

– Мин курка белмим. Хәзер дә менә үземне сиздермәскә кирәк булгандыр. Унбиш ел буе ничек түзгәнмендер, белмим, тик хәзер сөйләшәсем килә, сине бүтән очрата алмам төсле.

– Исемегезне дә белмим, ичмасам.

– Фәйзел мин.

– Фәйзел, Фәйзел... Фәйзел... Юк, исемә төшерә алмыйм.

– Аппакайда кошчылык комбинаты төзегән идек. Тирә-яктагы колхозлардан бик күп җыйдылар безне. Ул вакытта йомыркадан чыккан әтәчләр дә бүген унбиш яшь тутыргандыр инде... Эштән кайткач, арыганнарны да онытып, Аппакай юлына чыгып басам, хыялланып-хыялланып сине күзәтәм.

– Килеп дәшәсегез калган. Егетләрем арасында алай артык өзгәләнеп сөя белүчеләр юк иде.

– «Исәнме, Роза, мин сине яратам» дисәм, мөгаен, «мине бик күпләр ярата» дип кенә җавап бирер идең әле... Гомерем буе сиңа охшаган кеше эзләдем.

Ярату сүзләрен кем генә яратмый икән! Роза да йотлыгып тыңлады. Фәйзелгә караган саен күңеле сөенде. Роза ир алдында үзен бурычлы итеп санады... «Элеккеге игътибар юк инде хәзер миңа, олыгаям, ахрысы, трамвайларда яшьләр урын да бирә башлады» дип, өлкәннәр гаме белән яшәүгә күчкән ханым мәхәббәткә авваздаш сүзләр ишетә бүген. Ялгызлыкта үткән һәр көн үзен нык сиздерә, һәм менә бүген аның янында Фәйзел исемле өмет. Хәер, ниткән өмет булсын ди инде, юлаучы гына ич. Розаны да кем беләндер бутавы гынадыр. Бәлки, кайда ачык күңел күрсә, шунда бәреп керә торган берәр хәсис кенәдер. Тәүбә, тәүбә, анысы кирәкми...

– Чәч толымым элек нинди иде, әйтә аласызмы? – Роза, үз соравыннан үзе оялып, читкә борылды һәм җавап көтте. Артык кыен түгелме бу сорау, дөрес җавап бирә белерме? Ялгышмаса гына ярар иде. Күпертеп таралган куе кара чәчләремә сыный карасаң, кисеп ташланган толымымның озынлыгын чамалап та әйтә алырсың...

– Җиргә тиеп тормаса да, тел шартлатып үтәрлек иде...

– Дөрес. Клубка киеп чыга торган чәчәкле ак күлмәгемне хәтерлисезме?

Поезд әкренләп төнгә килеп керде. Тәрәзәгә якынайган урманнарда карурман төсе...

Пассажирлар урын-җир иплиләр. Тәгәрмәчләрнең тигез тыкылдавы һәркемне йоклатыр сыман. Пышылдашып кына сөйләшер чак якыная. Ә Розаның бүген көчле сүзләр ишетәсе килә.

Тамбурда көзге төн җиләслеге.

Розаның иңендә Фәйзел пинжәге.

Ике башка йөз төрле уй.

– Ак күлмәгең сиңа бик килешә иде.

– Ул миңа бик килешә иде.

– «Иде дә иде» дибез. Кайда эшлисең, Роза? Нәрсәләр майтарасың?

– Сөйли калсам, тыңлап арырсыз. Болай да инде күзләрегездә йокы бар.

– Минем күзләр гел шундый ла ул, игътибар итмә.

– Ирдән уңмадым. Бер кыз үстердем, техникумга укырга керде. Баласын очырган кош төсле, җиңел сулап ялгызым гына ял итеп кайтырга исәп.

Сүз уңаеннан гына «һәр кешенең бәхетле булуын телим» дип купшыланырга яратса да, Розаның ирсез яшәве Фәйзелнең өметен азындырды, хәтта куандырды да бугай.

– Роза, син бер дә үзгәрмәгәнсең. Мин сиңа әле дә сокланам, ә соклану ул – ярату билгесе...

– Мондый сүзләрне ишетүе рәхәт. Сөйлә, Фәйзел, сөйлә.

– Хат язасым килә.

– Хат... Хат очрашу бит ул – берең сөйли, берең тыңлый.

– Кая языйм соң, адресыңны әйтәсеңме?

Фәйзел, Роза иңендәге пинжәкнең кесәсенә тыгылып, куен дәфтәрен алды. Ул моны шундый тиз эшләде, кесәгә үрелгәндә Розаның куен җылысын да тоймый калды. Әйтә-әйтелешкә үк урам исемен,

йорт номерын да язып алды. Тиз язды, әйтерсең, бер мизгелгә генә тоткарланса да, Розаның кире уйлавы мөмкин иде.

Хатларга гына языла торган аерым сүзләр бар, телдән әйтеп бирүе кыен аларны. Розаның әнә шул зарыгып көткән очрашуларга тиң хатлар алганы юкка яшьлекнең үзе кадәр гомер үткән инде. Һәм менә яшьлек тагын әйләнеп кайтты. «Аккан сулар кире кайтмый» дип җырлыйлар тагы...

Киноларда күреп, китаплардан укыса да, очраклы күренешләргә юлыккан кешеләргә шикләнебрәк, ышанмыйчарак карый иде Роза. Фәйзел белән очрашу да очраклы хәл түгелме соң?! Бәлки, болар һәммәсе дә алдавыч төш кенәдер. Була бит шулай, әллә кайдан гына кошлар сайравы ишетелеп китә – урманда да, болында да кебек. Куышып йөрисең, ул сине тотып ала, иреннәреңә орынып үткәндәй тоела. Уянсаң, куеныңда исерек ир бөгәрләнеп ята... Һай, татлы төшләрнең бигрәк тансык чагы!..

– Фәйзел, ачуланмасагыз, сорыйм әле, ник соң моңарчы ялгыз яшәдегез? Ирләргә гаилә яңартуы җиңел ич...

– Кичә өйләнсәм, бүген нишләр идем, сиңа читтән генә кызыгып карап утырыр идемме? Ир кеше өчен иң зур бәхет ирек бит ул. Минем менә теләсә кайсы чибәркәйнең аяк астына егылырлык ирегем бар.

– Ничә тапкыр егылдыгыз инде? – дип ялт кына сорап куйды Роза. Шаяртудан бигрәк ул Фәйзелнең тел төбен аңларга теләде.

– Блокнотымда ничә адрес булса, шулхәтле, – диде Фәйзел, комарланып, һәм шул арада, болай мактануның тиешсезлеген аңлап, сүзне кирегә борырга теләде: – Ә блокнотым чип-чиста!

– Әйтегез әле, дөресен генә әйтегез, сез бит мине белмисез, әйеме, бу әкиятне уйлап кына чыгардыгыз?!

– Хатын-кыз белән танышу үзе бер сәнгать бит ул, – диде Фәйзел, Розаның күзенә туры карарга куркып.

– Ялган сәнгатьне җенем сөйми!

Шушы берничә сәгать эчендә күз алдында әкияттәгедәй сихри шәһәр калкып, ул шәһәрдә Фәйзел белән Роза өчен дә бер йорт корылган иде. Тәрәзәләре якты, ишеге киң, атлап керәсе дә гөрләшеп яши генә башлыйсы. Бактың исә, шәһәре дә, йорты да балалар мәйданчыгындагы төсле, комнан гына өелгән булган икән. Җимерелде дә төште, җир белән тигезләнде.

Роза, үзенә-үзе сораулар яудырып, аларга җаваплар да табарга тырышты. Адресым нигә кирәкте икән? Хат язар өченме? Юк, Фәйзел хат язарга ярата торган кешегә охшамаган. Эш юктан, кызык өчен генә хатлар язышырга унҗиде яшьлек чагыбызмы? Яшьлек дигәннән, Фәйзелнең кайчандыр безнең якларда булуы миңа кызыгып йөрүе кебек үк чеп-чи ялгандыр әле. Ирләр, тол хатын икәнеңне белсәләр, сөйләндереп карар өчен әллә ничә төрле ысулын табалар. Салкын Чишмәдән икәнлегемне дә берәр ничек ишетеп кенә калгандыр... Сания озата килгән иде, аннан сораштыргандыр әле, җаен да тапкандыр, шундый әрсез иргә охшаган бу. Ә Сания ике дә уйламас. Мине күптәннән бирле сөяркәле итәсе килә иде инде аның. Чәчең озын иде, дип әйтүе дә, шикәргә карап, баллы ул, дигән кебек кенә, чәч үсәр өчен бирелгән, кыска чәчне кем киссен?! Ирдәге хатын булсаң да, ялгыз чагыңны туры китереп, тәрәзәңне чиртеп үтәргә иренмәс. Абау, нинди чиркангыч кеше. Адресымны ник алганын да беләм хәзер: тамагы туйган эт тапкан ризыгын күмеп куя, карыны ачкач эзләп ала. Фәйз... бу хәсис тә шундыйдыр, исемен дә искәрәсем килми хәтта. Их, блокнотын ачып карарга, хатын-кызлар адресы белән тулган микән?!

Розаның җаны өшеде, гүя әкренләп куен җылысы суынып бара иде. Гомердә булмаганны йөрәге авырткандай тоелды.

Роза, кинәт кенә яшерен бер карарга килеп, сагаеп калды: ничектер җаен табып, блокноттагы адресны юк итәргә...

Роза, күзен йомса да, Фәйзелнең өске ятактан аңа каерылып карап барганын тойды. Карасын әле, карасын... Роза Фәйзелне сынарга теләп одеялны читкә этәрде, җәймә генә ябынды, болай юка аклык аша нәфис сынның бөтен барлыгы беленеп тора.

Фәйзел песи җитезлеге белән ятактан төште дә, аяк очларына гына басып, Розага якынайды, аның ачык муенын үбәргә теләдеме, әллә тән җылысын тоеп карарга ниятләдеме – белмәссең. Тик Роза ир кеше сулышыннан оеп, чирканып куйды һәм, йокы аралаш кына борылгандай, мендәргә йөзтүбән капланды. Аяк тавышларын ишеткәч кенә Фәйзелнең тамбур ягына таба киткәнен аңлады.

«Адресым язылган блокнот якында гына!» – Шушы тынгысыз уй Розаның бөтен холкы-акылы белән идарә итә башлады... Ул кесәдә. Алырга. Бер мизгел җитә. Әмма бит кеше кесәсенә керәсе!.. Ләкин ул ир синең өметеңне алгысытты. Намуссызга җәза бирү – намус эше. Озак уйлап икеләнеп ятсаң, Фәйзел килеп җитмәгәе... Ул кесәдә. Алырга. Бер мизгел...

Роза, урыныннан торып, күршеләрен күзәтеп чыкты: йоклауларына тәмам ышангач кына, өске ятакка үрелеп, элгечтәге пинжәкнең куен кесәсен эзләп тапты. Куен дәфтәренә кул тигәч, әллә куркудан, әллә артык сагаюдан маңгаеннан чеметтереп-чеметтереп салкын тир бәрде. Хәтта күңеле болгангандай булды. Тиз генә актарып, йөзәрләгән хатын-кыз арасыннан үз адресын ертып алды.

«Абау, усаллык эшләве дә кыен икән, бөтенләй хәлдән тайдым», – дип уйлап куйды ул һәм башка берни дә уйламаска тырышты. Йокларга яткач та башыннан ук бөркәнде: Фәйзелне күрсә, гафу үтенмичә түзә алмас кебек иде...

Вакытның тизрәк үтүен теләгәндәй, поезд тизлеген арттырды.

* * *

Фәйзелнең ятактан сикереп төшүе сискәндерде Розаны: «Әллә сиздe микән?» Станциягә килеп җителгән иде. Фәйзел кабыл-тибел киенде дә, аерылышу газаплары кичермичә генә, саубуллашып чыгып китте.

Роза, сиздермәскә тырышып, Фәйзелне күзәтте. Тәрәзә экранында ватык телевизордагы кебек тавышсыз-тынсыз аксыл сурәтләр – куе томан таңны бастырып куйган. Әнә «тегe», ялтыравык ботинкасына карап, перрон буйлап йөренде дә пычрак юлга төшеп, томан эченә кереп югалды. Шуны гына көтеп торгандай, поезд кузгалып китте. Роза, тәгәрмәчләр теркелдәвенә сөенеп, мендәргә ауды да кулын күкрәгенә куйды.

Сул күкрәк астында ярсынып-куанып йөрәк тибә иде.

# КАРУРМАНДА КАРА ПЕСИ

– Йөз сум акча биреп тор әле?

Энгель агай салам түбәсе бер якка авышкан абзар кыегына космос аша телевизор карый торган тәлинкә кагып маташа иде. Күрше малаеның гозерен ишетмәмешкә сабышты, үтеп китәр дип уйлады. Ләкин гозерле Ирис ашыкмады.

Ириснең чын исеме Идрис булырга тиеш иде. Гөнаһ шомлыгына күрә, җирле үзидарә советы секретаре Мирумир абзый таныклыкны тутырганда бер хәрефне төшереп калдырган. Мирумир абзый, гомер буе яшәгән Ташкент каласыннан гаиләсе белән куылып, туган авылына качак статусы белән кайтып төште. Шуңа күрә ул, бүгенге исемнәрне язганда, насвай иснәп төчкерә торган иде.

– Сиңайтәм, Энгель агай!

Сабыр ит бераз дигәндәй, Энгель агай, уң кулы белән ишарәләп, Ирисне тынычландырды. Һәм шул арада соңгы кадагын кагып өлгерде. Алай-болай көчле җил чыгып очырмасын өчен, тәлинкәле антеннаны дилбегә кисәге белән кайчылыкка да тарттырып куйды.

Салам түбә ишегалды ягына авышкан иде, шуңа күрә Энгель бабай урам ягына шуып төште.

– Әллә син дә пожарныйдагы казинога йөри башладыңмы? Апулей малае уенга да кертми бит сине йөз сумың белән... Фердинандның төпчеге, каладан кайтышлый ялгыш сугылган булган, менәтерәк, бозау саткан акчасын калдырып чыккан.

– Акча үземә кирәк, Энгель бабай. Каникул бетә, укулар башланганчы шәһәргә барып разливной сыра эчеп кайтасы иде.

– Әниең беләме акча эзләгәнеңне?

– Белә. Синнән сорап торырга кушты.

– Кушты, имеш... Кемне очратсаң, шуннан сора, дигәндер әле. Күрешергә теләп кул суза дисәң, очраган бере акча сорарга тотына. Шуңа күрә хәллерәкләр өйләрендә бикләнеп ята, өмет булмагач соранучылар да чыкмый. Авыл урамнары тып-тын, һич адәм заты күренми... Узган атна кичтә Алекс абыең югары очтагы досугтан кайтышлый адашып йөргән. Яучы Луараның шайтан өермәсеннән туган кызлары берәр ярамаган нәрсә биреп миңгерәйткәннәр, ахрысы, Алекс таң атканчы эзләп тә үз өен таба алмаган. «Кайсы тирәдәрәк яшим соң мин?!» – дип сорарга урамда ник бер кеше очрасын ди...

– Боларын беләм лә... Акча бирәсеңме? Төрек төзүчеләренә дә ялландың, пенсия дә аласың, йөз сумлык кына рәтең бар инде синең.

– Рәт, имеш... Бер ел буе төзелештә кирпеч ялаган өчен төрекләр әнә НЛО белән түләделәр, – диде Энгель агай, салам түбәгә арканлап куелган тәлинкәгә имән бармагы белән төртеп күрсәтеп. – Ә пенсия килергә иртәрәк булыр. Хат ташучы Октябринә түткәңнең безнең ишеләрдән качып ята торган чагы.

– Ике җирдән акча алып, кесәңдә йөз сум да йөртмәскә инде. Укып бетереп эшли башласам, мин сезне акчага күмәм әле.

«Күмәм» дигән сүзне колагына элмичә генә, Энгель агай үзенекен тукыды:

– Әниең Римма эштәме?

– Ие. Дуңгыз фермасыннан тирес түгә, ат белән.

– Ну, пенсиягә чаклы түзсә, аннан Римманың акчага өзеклеге бетә инде... Ниме, алиментыгыз да килмиме бу арада?

– Ие. Минем әтидән дә юк, сеңелкәшнекеннән дә. Октябринә түткәйнең безнең өйгә кергәне юкка инде өч ай бардыр.

– Хат ташучыбыз качып ята торгандыр. Авылда пенсияне дә, алиментны да ул түли шул. Халык кичә алган акчасын бүген оныта, икенче көнне үк тагын сорый башлый.

Ул арада Энгель агайның тезмәсендә тавыклар куркынып кытаклашты, нәрсәдер «шарт!» итте һәм, күп тә үтми, дегеткә баткан крокодил сыман бер нәрсә урам аша икенче якка шуышты.

– Ну, заразы, тагын ояга менгән. Регина әбинең мәчесе бу. Әле узган атнада гына кереп ике йомырканы эчеп качкан иде. Тавыклардан грипп йоктырып, тезмәдән мәтәлеп төшкәнен күрсәм иде шуның... Бәреп кенә үтерер идем, ырымыннан куркам... Кыямәт көнендә, фәрештәләр сорау алганда, өстеңнән әләкләп торалар икән алар... Мин өйрәтте димә, Ирис, бар, кер Регина әбиенә, ул сине акчалы итәр.

– Кеше өенә ничек керәсең ди инде?!

– Әйе, хәзер авылда андый гадәт бетте. Минем дә беркемгә кергәнем юк. Кемнең өй эче ничек бизәлгәнен күз алдыма да китерә алмыйм. Күрше-күләннең йорт җиһазларын машинадан бушатканда күреп калсаң гына... Син аңа кермә, капка баганасындагы домофонга бас, Регина әбигә ничә яшь икәнен беләсеңме?

– Юк.

– «87» санын җый, үзе эндәшер. Әйт, мәчеңне адаштырырга килдем, диген. Йөз сумнан да кимгә ризалашма.

Күршеләрнең өй эчен бөтенләй күргәне юк дип өздереп әйтсә ялган булыр, Ириснең Клара карчык өенә күз салганы бар. Клара карчыкның өе чишмә юлы чатында. Комбайнер Рафинад, мунча өмәсеннән кайтышлый, эчкән спиртына тизрәк су кушу өчен, чишмә юлын кыскартмакчы булган. Тик комбайнның алгы терсәге белән Клара карчыкның өенә ышкылып үткән. Совнархоз карары белән салынган йортның бер бүрәнәсе торыгы белән кубып төшкән... Мәктәптән кайтышлый, бөтен бала-чага тезелешеп, ачык эргә аркылы өй эчен караганнар иде. Клара карчыкның, ковролин намазлык өстендә кесә телефоныннан SMS-хәбәрләр җибәреп, башка чыккан сыңар малае белән хат алышып утырган чагы булган. Авылга ике шпана килеп җир пайларын җыеп йөрде. Җитмеш яшьлек Клара карчыкның колхозны раскулачивать иткәндә өлешенә тигән ун гектарлы җир паен кулыннан алып, акча урынына кул куйдыртып, кемнәндер урланган мобильник тоттырып киткәннәр иде. Кинәнде. Улы белән сөйләшеп туя алмый. Инде пенсиясен «Экспресс-карта» белән генә ала.

Ирис, «кара крокодил» сукмагыннан тайпылмаска тырышып кына, Регина әбинең өй түренә килеп басты. Бала-чага шаяртмасын дипме, домофонны өскәрәк куйдырган, әгәр капка баганасы авыш булмаса, Ириснең буе җитәсе түгел иде.

– Кем икәнеңне күреп торам, кер, матальщик, капкамны ачтым.

Ирис кергәндә, Регина әби компьютерда пасьянс, авылча итеп әйткәндә, кәрт уйнап ята иде. Аны бу зәхмәткә, калага кунакка баргач, оныгы өйрәтеп җибәргән иде... Авылга ит җыючы әрмәннәр килгәч, абзардагы бөтен мал-туарын тапшырса тапшырды, барыбер шул компьютер дигән уенчыкны сатып алу бәхетенә иреште. Әле, Интернетка тоташтырып бирсәләр, Регина әбинең оҗмах белән элемтәгә кереп карарга да исәбе бар...

– Беләм, йөз сум акча эзләп йөрисең, – диде Регина әби, Ирискә акча сорауны җиңеләйтеп.

– Каян беләсең?!

– Минем менә бу интернатта барысы да теркәлгән. Әниеңнең ат белән дуңгыз тиресе түккәне дә, атагызның ник алимент җибәрә алмаганы да.

– Интернат түгел, Интернет, дип әйт.

– Үрәтмә! Сез порнуха эзли торганы Интернет аның... Ә менә авыл эчендәге элемтә интернат дип атала. Авылда ни бар – бөтенесе мәгълүм.

– Алайса, этине әйт.

– Атаң, балык тотучыларга кушылып, гастарбайтер булып киткән җиреннән паспортын урлаткан. Хәзер Сахалинда бомж булып йөри, аякка басса, хәбәр бирер... Сеңелкәшеңнең этисе – күрше авыл кешесе, август ае өчен дигән бер йөк саламын әниең кире борган. Июль аена, ичмасам, печән белән түләгәние алиментын...

– Регина әби, сөйләп торма, акчаңны гына бир.

– Нишлисең йөз сум белән? Дөресен әйтсәң, бирәм...

– Калага барып салкын сыра эчеп кайтам. Юкса каникул бетә.

– Үзебезнең гипермаркетта да эчемлекнең беткәне юк. Ипи кайтмаса кайтмый, әмма исерткечсез тотмыйлар.

– Бездә шешәле сыралар гына. Салкын мичкәдән акканын эчәсем килә.

– Шешәле дип, җиденче класс баласына ярамаган тагы!

– Сигезенче!

– Сигезенчегә күчтең генә әле син, укый башламадың.

Регина әби, пасьянс уйнавыннан бүленмичә генә, сул кулы белән үрелеп, принтер ярыгыннан йөз сумлык акча алып бирде. Ирис, сөенеченнән бусага аркылы сикерәм дигәндә, никтер шикләнеп калды – акчаның икенче ягында сайлауларга чакырып язылган өндәмәләр иде.

– Ялган гозереңә ялган акча ярамаган тагы.

Дөресен әйтергә теләмәде Ирис. Чыбык күпер янындагы Ганс абзыйның төпчек кызы Эльзага бүләк аласын әйтеп ташласаң... Оятын кая куярсың?! «Бурычка кереп сөйгән кызына бүләк алган» дип күз дә ачырмаслар...

– Алайса, Энгель агай әйтмешли, песиеңне адаштырсам, йөз сум түлисеңме?

«Песи» дигән сүздән Регина әбекәйнең кулы капылт кына тавык йомыркасы чаклы йодрыкка әверелде. Ул ашыгып-ашыгып экрандагы карталарны җыеп алды да уенчыгын сүндерде.

– Иң әүвәл адаштыр. Әгәр өч көннән кайтмаса, түлим...

– Каникул беткәч акчаң ниемә кирәк? – диде Ирис, үз ялганы белән дөреслекне аклап.

– Ярар, ике көннән керерсең.

«Пес! Пес! Пес!» дигән чакыруга, Иристән соң ябылып калган имән ишекне уң тәпие белән каерып ачып, теге кара песи килеп керде. Ул, педсовет утырышына чакыртылган тәртипсез укучы кебек, үз урынын алдан ук белеп, хуҗабикә белән яшь тәрбияче каршына килеп утырды. Койрыгын мич казнасына терәп, чарасыз күзләрен буш тәрәзәгә төбәде.

Песиләрнең яшен кешеләр яше белән чагыштырып карар өчен, аның бер елын чама белән бишкә тапкырларга кушалар. Бу кара-чутыр район сабан туенда өч ел рәттән батыр калган йөз дә ун килолы Флоридны хәтерләтә иде.

Регина әби, аяк очы белән генә үрелеп, караватастындагы кычыткан капчыкны идән уртасына шудырды. «Ә бит чем-кара песине асрамаска кушалар», – дип уйлап кына өлгергән иде Ирис, тегесе, аның ни уйлаганын сизгәндәй, тамак астындагы ак табын күрсәтер өчен, муенын сузып капчык авызын иснәп алды.

– Исеме ничек соң моның? – дигән сорау Регина әбине чыгырыннан чыгарды.

– Ниткән исем аңа?! Таныштырырга алып бармыйсыңдыр ич?! Авылдагы һәр мәчегә исем куша башласаң, саташырсың. Каланыкылар гына ул фатирда асраган һәр киек-җәнлеккә исем-фамилия кушып, паспорт ачып кылана... Минеке сигез ел инде мәче. Көнаралаш кетәклеккә менеп йомырка эчә, сальмонелла кыргыры. Күршеләр белән әчелешле итеп бетерде инде... Сезнең ояга менгәне юкмы әле?

– Юк, Регина әби, сизсәм, койрыгын кисәм ич мин аның.

– Шуннан котыла алсам, йөз сум акчам садака гына булыр. Мә, капчык авызын бәйләрсең, – дип, иске халат путасы тоттыргач, Ирискә кире чигенер җай калмады.

Ирис казалы песине Энгель агай кушканча адаштырырга теләде. Песиләр өйдәге кимерүчеләрне тотып бетергәч, эшсезлектән котыра икән. Андый чакта кайсысы чеби тотарга, кайсылары урлауга, бер ишләре йомырка эчүгә сабыша икән...

– Сыерлар җәйләүдән кайтмаган, сәнәк күтәргән терлекчеләр юк, шуңа күрә фермаларда күсе-тычканнарның башбаштакланган чагы, – диде Энгель агай, кычыткан капчыкны кайда бушатырга кирәклеген аңлаешлы итеп әйтеп.

Беренче сәяхәт бик кыска һәм дә хурлыклы булды. Ирис, фермадан кайтып, капчыкны хуҗабикәсенә тапшырыйм дип керсә, теге «йөз сум» акча салкын мич башында утыра, күзләре агач кашыкка салынган зәйтүн мае кеби ялтырый. Адаштыручы малайны күргәч, кашларын җыерды: «Синең аркада ач күселәр чак кына тотып ботарламады үземне!» – дип әрләвedер инде үзенчә.

Бу юлысы ул фән кушканча адаштырып карарга булды. Мыраужаннар суга керми, димәк ки, инешнең теге ярына чыгарып селкесәң, шунда калачак, димәк ки, авылның теге ягыннан үзенә яңа хуҗабикә эзләячәк.

Чыкты Ирис теге якка.

Җиргә селкер алдыннан, бераз саташсын, морҗаларны буташтырсын дип, капчыкны баш очында болгап күп тапкырлар әйләндерде... Йомырка бирәне, утын турый торган кузла шикелле, дүрт аягын дүрт читкә җәеп, беркавым һушсыз торды да, хәл алуга, инеш кичүенә йөгерде. Таштан ташка нәкъ Ирherнең үзе кебек томырылып дүрт-биш сикерүгә, ул инде кайту сукмагына чыгып баскан иде. Егет ачуыннан тешләрен кысты, әмма рухи яктан бирешмәде:

– Барыбер юк итәм! Миңа бүген акча кирәк! – диде ул, күз алдыннан юк булган дошманга бармак янап.

Ырым белән адаштырып карауны Регина әби үзе әйтеп бирде:

– Өйдән ризык алып барасың. Карурман уртасына җиткәч песи ризыкны ашаса, минем яңа нигезем икән бу, дип, шунда яшәп калачак, – диде.

Капкадан өченче кат капчык күтәреп чыгып барганда, Энгель агай үртәп калды:

– Нихәл, киллер?! Шиһап чүннигеннән кайтканы бар инде аның. Торна күленә, Тугаш сазлыгына, Пәрәү урманына да илткәнем бар...

Адашырдай урыннарны санаганда Бимә кырын телгә алмавы Ирисне сөендерде генә.

Лаеш юлы өстендәге аркылысы унбиш чакрымлы карурман авыл теленә Бимә кыры дип кереп калган. Анда көтүләр барып җитми, җиләк җыючылар йөрми. Печән чабучылар болынына кермәсләр, ә утын әзерләүчеләр диләнкәсен алмас өчен кырыкмаса кырык хәйлә табып, якынгарак елышырлар иде. Чөнки Бимә кыры адаштыра. Элек анда, яшенле яңгыр алдыннан яшел аждаһалар төшеп, тузбаш еланнарны һавага ашыра торган булган, имеш. Имеш-мимешле чорлардан егерме буынга сикереп, инде аждаһалар, җен-пәриләргә ышанмастай кыю малай булып үскән Ирис өчен ырым-шырымнар буш әкият кенә. Ул Бимә кырына туп-туры керәчәк тә, күрше песиен калдырып, туп-турыга кире борылачак...

Карурман эченнән атлый торгач, каникулның сары көне кызыл кич белән алышынды. Тирәнрәк-төпкелгәрәк кергән саен кичнең кызылы куера барды. Бимә кырының уртасына җителгәндер инде, шәт... Яшел хәтфәле ат юлыннан чирәмле поши сукмагына, печәне чуаланып беткән болыннардан җәнлекләр таптаган аланнарга күчеп, аркадагы әсир муйнакны шактый әлсерәткәч һәм кыйблалар буталырлык итеп зыр-зыр әйләндергәч, Ирис, ниһаять, путаны сүтеп капчык авызын ачты... Ул аны кумады, йомшак кына сыйпап өйдән алып килгән йомырка сытыгына борыны белән төртте. Ләкин, ырымның хикмәтен сизенгәндәй, Регина әби симезенең сытык йомыркага исе китмәде, мыегына чыланганын ялмаштырды да тәпиләрен яшереп, коелган ылыс өстенә менеп ятты, колак очына тиеп торган кыяк үләнне өзеп чәйнәде.

Ирис, җиңел сулап, кайтыр якка таба чигенде, ә үзе юатыр өченме, сөйләнеп барды:

– Керпеләр нишләсә, шуны эшләрсең. Кошлар да гел җиргә төшми тормас, алар да яз көне күкәй сала, бераз ябыккач ояларына менгәләрсең. Тамагың тук булыр, нинди этлек кылсаң да, әрләүче юк монда.

Печәне чуалып беткән болын никтер яшел хәтфәле ат юлына кушылмады. Үтелгән юлда кешенең өне кала. Ирис уңга да, сулга да тайпылып карады, ләкин күңелне юатырлык, өмет белән канатландырырлык һичбер таныш күренешкә юлыкмады. Кояшсыз һәм офыксыз кичке урман төбендә кыйблалар буталган, алга атласаң да, артка чигенсәң дә гел билгесезлек, авыл эзенең әсәре дә юк, кыскасы, бу адашу иде. Адаштырам дигән кеше үзе адашты...

Ирис, ачудан селтәнеп, кулындагы капчыкны сыңар абага төбенә ыргытмакчы иде, кинәт кире уйлап, тыелып калды. Урманның елан түше кебек дымлы һәм кар базыдай салкын куышы, шикле кыштырдаулары, төнге авыл урамында һич очрамастай ят авазлары: «Монда кунып калсаң, сине һичшиксез һәлакәт көтә», – дип оран сала, малайның йөз тәңкәлек җанын үртәп, сагыш белән отыры күмә тора иде... Бу халәттә төнге урман тотыгының, әсирлектән котылып, үз өенә кайтасы килү теләге көчәйгәннән-көчәя барды.

Биләп алган сагаю һәм курку хисе акыл өйрәтә башладымы, малай, үзендә күтелмәгән әүлиялык чалымнарын тоеп, тын калды. Гүя ул үзен-үзе тыңлый иде... «Капчыкны ташлама, кирәге чыгар, йә мендәр, йә җәймә итәрсең, бөркәнсәң, җылынырсың, эченә керсәң, черкиләрдән котылырсың... Песине тап! Кайтыр юлың дөрес булса, ул синең артыңнан килер. Әгәр юк икән – кире борыл, аңа ияреп кайтырсың. Песиләр урманда курыкмый, качып китәргә ашыкмагандыр. Чакыр син аны...»

– Песи, песи! Пес-пес! Пес!

– Ми-яуу!

Нинди ягымлы тавыш бу?! Нинди аһәң!.. Ириснең әле шушы яшенә җитеп моңарчы песиләр мияулавына шулхәтлек тә сокланганы, сөенгәне һәм атлыкканы юк иде. Кешеләр белән яши-яши акыл туплаган, бары тик кешеләр белән генә янәшәдә яшәргә хаклы җан иясе дер бу! Карурман төпкелендә Ириснең җиңелгәнен көтеп торган хәвеф шушы аваздан өркеп ераккарак китте. Мәрхәмәтле, өметле, тантаналы аваз иде бу! Өйгә кайткач, сөенә-сөенә сөтләп чәй эчү, тагын өч көннән башланачак өр-яңа уку елы, үскәч, калага китеп күп-күп акча эшләүләре, сөйгән кызының туган көне, сөю һәм сөелү белән тулы яшьлек маҗаралары, җыйнап кына әйткәндә, малай әлегә үзе дә күз алдына китереп бетерә алмастай олы бер киләчәк бар иде әлеге авазда!..

Карурман аланындагы кара йомгак Ириснең аягына килеп сырпаланырга ашыкмады. Ике ара үрелсәң кул җитәрлек кенә булып калгач та, аның күзләрендә мәкер, хәйлә, ышанмау һәм сагаю катыш сизгерлек уйный иде. Гүя ул әле малайны гафу итәргә әзер түгел, ялынып килгән дусның дуслыгын тагын бер кат сынарга исәбе бар кебек, мәҗбүри татулыкка чакырган икейөзлелек түгелме, янәсе... Бит малайны карурман белән күзгә-күз калдырыр өчен аның читкә бер сикерүе җитә!..

Кулына алгач, Ирис аны сөенеченнән иң якын туганы итеп сөйде. Тегесе, күрше малайның тирләгән футболкасы аркылы тән җылысын тоеп, күзләрен йомды. Аның тигез мырлавы үзенчә «ташламам» дигәнне аңлата иде булса кирәк. Бергә булгач, кайсы якка таба адашсак та барыбер, диме, кайту гаме юк әле бу җан иясендә.

Малай, капчык бавын чалбар каешы белән озынайтып, песине арканлады. Арканның ныклыгына ышангач, каен толымы белән чалбар балагына шапылдатып, юмагайлап куа башлады.

– Әйдә, кара-чутыр-аппагым, моның ише генә урманнардан кайтканың бар ич инде синең. Әйдә, йөгер, бөтенләй караңгы төшкәнче ашыгыйк. Безне өйдәгеләр эзли торгандыр... Яңа өй салып чыккач, бусагабыздан кертәм әле мин сине...

Песи башта ризасызлык белдереп җиргә ятты, аннан, тирә-яктан кеше күзенә күренмичә генә якынлашкан карурман җанварларына колак уйнатып, як-якны тыңлап алды һәм борылып йөгерергә кереште. Ирис аның артыннан чак өлгерде.

Авыл бөтенләй кире якта булган...

Урам утлары күренеп, үз авылын таныгач кына, арканны ычкындырды. Шулай да песи аны ташлап качмады, бер чама читтәнрәк теркелдәде, ул авыл эченә ашыккан кара төнне үзенә ияртә иде.

– Кайда йөрисең син?! – Сеңелкәшнең гөрелдәвек тавышында икеләтә сөенеч бар иде. – Атаң өч айлык алиментын берьюлы җибәргән. Әни кибеткә китте...

Икенче көнне кич Ириснең әнисе тавык оясыннан буш төште.

– Дүртесен дә эчкән, мәлгунь! Әле моңарчы безнекенә тими торган иде... Шул дошманның башына җитүче табылырмы, юкмы инде?!

# ЮГАЛГАН МАЛАЙ ЯЗМАЛАРЫ

Ышанмыйм...

Нигә әле көндәлек язу гашыйклар эше генә булырга тиеш? Минем, зур абыемнар кебек кемнедер сагынып, төннәр буе йоклый алмыйча изаланып, аерылышу газаплары кичергәнем юк. Чөнки мин әлегәчә яратып караган кеше түгел. Яшемә күрә ашыгасы да юк. Ләкин соңгы көннәрдә никтер көндәлек язасым килә. Абый әйтә, көндәлек яздыра торган өч сәбәп бар: аның берсе – зур югалту, икенчесе – хәвеф, өченчесе – билгесезлек; шушы өч авырлыкның берсен татып карамыйча, кеше көндәлек яза алмый, ди. Ни өчен яратуны да сәбәп итеп алмыйсың дип сораган идем, көлде генә, мәхәббәтнең өч сәбәпкә дә катнашы бар, ди.

Мин көндәлек язарга телим, тик сәбәбен белмим әле, бәлки, минем өчен югалту белән хәвеф һәм билгесезлек өчесе бергә буталгандыр?..

Безнең Дустайда утыз гына морҗа утырып калган. Әле мин туганда гына да ике йөзләп иде, диләр. Ышанмыйм. Шулкадәр кеше каян килсен ди ул Дустайга? Әгәр булган икән, кая соң алар? Үлеп беткәннәр дияр идең, үз-үземне хәтерли башлаганнан бирле авылыбызда ике генә кеше үлде, алары да хәвеф корбаннары. Берсен Әфганстанга хезмәт итәргә киткән җиреннән табутка салып кайтардылар, икенчесенең гәүдәсен тапмадылар, Әгерҗедән кайтышлый буранга юлыгып адашкан, диделәр. Ә безнең якта адашкан, кешене эзләп таба алганнары юк әле. Чөнки ерганакларда кыргый этләр өере яши. Әллә кайлардан күчеп килмәгән ул этләр. Күрше-тирәдә күпме авыл таралып беткән. Калага киткән хуҗалары этне үзләре белән ияртә алмыйлар. Менә шуңа күрә күп инде ул безнең якларда кыргый этләр. Бүредән дә хәтәррәк, ди, алар. Бүре хет уттан курка. Ә бу этләр, гомер буе кеше тирәсендә яшәгәч, уттан да, чурттан да, кызыл төстән дә, мылтыктан да курыкмыйлар, ди.

Кич җитеп, кояш офыкка сыеныр җай эзли башласа, тәрәзәдәге бозлар калыная, ишек тупсасына кагылган эшләпәле кадакны бәс сара, өй эчендәге җылы кисәк тартыла. Шулчак бер-бер артлы мичләр ягыла. Утыз морҗадан ургылып-ургылып төтен чыга. Яхшылабрак санап карасаң, тагын унбишләп морҗа бар әле. Аларыннан илле градуслы суык килсә дә төтен чыгасы юк. Күптән кеше яшәми инде ул өйләрдә. Китеп беткәннәр. Хуҗаларының кайсы Ижауның корыч кою заводында, кайсы атом электр станциясе төзи, кайсыберләре Түбән Каманың химия заводына урнашып калган. Минем абый да, Әфганстаннан исән-сау кайткач, тиешлечә ял да итмичә КамАЗга китеп барды. Абый әйтә, кайда фатир тиз бирелсә, адәм баласы бәхетен шуннан эзли, ди. Ышанмыйм! Югалган әйберне генә эзләп була. Бер дә белмәгән калаларда эзләп йөргәнче, шул бәхетне авылда гына эзләп карарга иде. Югалса да, шушында гына югалгандыр...

Ул өйләрне без җәй көне дә суык өйләр дип йөртәбез. Уен белән мавыккан чакта маҗара эзләп тә кермибез, ташландык бакчаларында кыргыйланып үскән кура җиләген дә ашыйсы килми, хуҗасы булмагач, алмаларын да урлавы кызык түгел. Кызганыч өйләр алар. Дөрес, икешәр морҗалы кешеләр әлеге салкын өйләрне утынга сүтеп яга торалар. Абый әйтмешли, өй өйне ашый.

Без Дустайның соңгы малайлары...

Җиденче класста укысак та, безне, нәниләрне чакыргандай, бәбкәчем, кил әле, дип дәшәләр. Кызыграк сүз ычкындырсак, башыбыздан сыйпап, аркабыздан сөяләр, йоклый алмыйча интексәк, берәр конфет бирәләр. Азрак булышыйк дип, балта-пычкыга тотынсак, кулыбыздан алалар. Уйнап калыгыз, янәсе, эшне үзебез генә җиңәрбез. Уен якшәмбе көнне генә тәти ул миңа. Башка вакытны мин юлда – Дустайдан Табылдыкка йөреп укыйм. Яшьтәшләр белән авылда ял көнне генә күрешәбез.

Үзебездә укыганда рәхәт иде лә ул...

Безне, ягъни Дустайның унбиш малай-шалаен, тугыз укытучы укыта иде, аның да берсе директор булып исәпләнә. Директор тарих дәресләрен алып бара. Калганнары өчәр төрле фәннән керә. Әйтик, Зәет Сәетович рус теле һәм әдәбияты дәресләрен берүзе үткәрә. Калган укытучыларга да фәннәр җитәрлек, чөнки мәктәбебез сигезьеллык дип атала.

Бар иде рәхәт чаклар... Ялгыш дәрескә килми калсак, әти-әнине мәктәпкә чакыртып тору юк, укытучылар үзләре көненә икешәр тапкыр хәлне белеп торалар, шул уңайдан калган дәресләрне дә аңлатып китәләр. Мин әле салкын тиеп авырган кайбер очракларда терелеп беткәч тә берәр атна урын өстендә ауный торган идем, рәхәт ич, иртүк торып интегә-интегә мәктәпкә йөгерәсе юк, дәресләреңне әзерлә дип йөдәтмиләр, ормыйлар-сукмыйлар. Сигезенче классны тәмамлап шәһәргә чыгып качканчы шулай яшәргә исәп. Ата-аналар җыелышын да мәктәптә үткәрү юк, әйтәсе сүзләре булса, өй саен йөреп, укытучылар үзләре килеп әйтә торганнар иде. Мәктәптәме? Әгәренки берәрсе безгә ошап җитмәгән сүз әйтсә, куйган билгеләре белән ризалашмасак, йә дәрестә сөйләшеп утырырга рөхсәт итмәсәләр, өйгә кайткач әтигә генә әйтәсе... Шулай, безнең якларда сигезьеллык мәктәпләрнең үз законнары бар... Әле без, малайлар, җыелып киңәштек тә укырга гадәттәгечә иртәнге сигезгә түгел, ә тугызга йөрергә дигән карарга килдек...

Тик рәхәтебез озакка бармады...

Ел ахырында алты агай-эне сигезне тәмамлап бөтен эшне бозды. Җитмәсә, яңа уку елында беренче класска килерлек бер бала да юк иде. Әйтәм ич, бүтән малайлар юк безнең Дустайда – иң соңгылары без... Шулай итеп, укытучылар белән тугызга-тугыз калдык. Мәктәбебез беренче классыз гына эшли башлады. Безгә игътибар тагын да артты, һәр укучы исәптә, класс саен берәү генә без, күккә генә чөймиләр. Иртән килүебезне мәктәпнең баскыч төбенә чыгып көтеп торалар. Хәл-әхвәлне, әти-әниләребезнең, күрше-күлән, туган-тумачаларыбызның исәнлеген сорашалар, бәйрәмнәрдә конфет-прәннекләр белән сыйлап чәй куеп эчертәләр. Бервакыт, кызык өчен генә, парталарның утыргычы каты, көне буена бик ардыра, дигән идек, икенче атнаны ук районнан ялтыравыклы язу-сызу өстәлләре кайтарттылар, укытучылар бүлмәсендәге тугыз йомшак утыргычны безгә бирделәр, ә үзләренә сайгактан озын эскәмия ясаттылар...

Кемдер каядыр исемен күрсәтмичә генә жалу язган да, һич көтмәгәндә комиссия килеп төште.

Укытучыларыбызны күрсәгез, Ижау базарында акча янчыгын югалткан Әгерҗе хатыннары шикелле тыз-быз йөгерештеләр. Безне шундук өйгә куып кайтардылар. Урамга чыккач, сигезенчедә укучы атаманыбыз аңлатып маташты. Аңа ышансаң... Имеш, мәктәбебез иртәгәдән «башлангыч» дип йөртеләчәк, ике баланы укытырга бер генә укытучы калачак. Дүртенчедән алып сигезенчегә хәтле класслар, ягъни без, Табылдыкка йөреп укырга тиешләр икәнбез. Дустайда калган ике малайлы ике классны җитәкләү хокукы өчен укытучылар арасында «классовый» көрәш бара, имеш...

Ышанмыйм...

Атаманның күп сүзе хак булды. Икенче көнне үк безне, машинага төяп, Табылдыкка илтеп куйдылар. Комиссияне әйтәм, һичьюгы, бер генә ел – мин сигезне бетергәнче генә түзмәделәр. Хәзер шулар аркасында җиде бала алты чакрым йөреп укы инде... Үзебез дә сизмичәрәк калдык. Әгәр алданрак белгән булсакмы, без ул сигезенчене бетергән малайларны үгетләп, классларында берәр ел күчми кала торган итә идек.

Безнең Дустайдан киткәнне генә көткәннәр, мәктәбебез бинасы фураж складына әверелде. Ә башлангыч дип үзгәртеп аталган Дустай мәктәбе суык морҗалы өйләрнең берсенә күчте.

Укытучыларыбыз кайсы кая чәчелеп бетте. Математика укытучысы кибетчене эшеннән алдыртып аның урынына калды, физигыбыз, комиссияләр үтә торгач, икенче группа инвалид таныклыгы алып пенсиягә чыкты, татар теле укытучысы яңа фураж складына мөдир һәм каравылчы булып урнашты. Калганнары, гаиләсен ияртеп, төрле шәһәрләргә туган-тумачалары тирәсенә чыгып китте. Араларыннан берсе генә – рус теле укытучысы Зәет Сәетович кына – безнең белән Табылдыкка йөриячәк, укырга түгел инде, укытырга. Мин аның сигезенче класста укып йөргән чакларын хәтерлим әле, ул чагында алар безнең – октябрятларның – вожатыйлары булып йөриләр иде. Кайту белән җыр укытучысына өйләнде. Хәзер бер кечкенә бәбиләре бар. Җырлап кына яшәп яталар...

Баштагы мәлне Табылдык мәктәбенең беренче дәресенә барып өлгерер өчен без сөт машинасы янына җыела идек. Сөт заводына барышлый ул безне алып китә, кайтышлый алып кайта. Сентябрь айларында әллә ни юл газабы күрмәдек. Иртәнге дүрттә уянырга да өйрәндек, ферма яныннан кузгалганда, көн яктысы машина кузовындагы сөт бидоннарын санарлык кына була әле. Без менеп утырган бидонда иртәнге сөт җылысы Табылдыкка барып җиткәнче суынмый, йөзгә салкынча җил бәрсә дә, туңарга ирек бирми. Хәер, безнең Әгерҗе юлларында әллә ни җилләнеп барырлык түгел. Машинабыз бер чокырдан чыгып икенчесенә төшкән чагында, савымчылар ныклап беркетмичә йокы аралаш кына япкан капкачлардан сөт бөркелеп чалбарыбызны, ә кызларның итәкләрен юешли. Шунысы бар, без Табылдык мәктәбенә килеп төшкәндә дәресләр башланырга өч сәгать вакыт кала, ике класска бүленәбез дә чишенеп чалбар, итәк киптерәбез. Чалбар кипкәнне көтеп без йокыга китәбез. Табылдык малайларының аяк тавышларыннан уянып чак киенеп өлгерәбез. Алар, класска килеп

керүгә, сездән көтүдән кайткан сыер исе килә дип, җанга тияләр. Көн саен көлүләренә түзәрбез анысы, интернатта кунып укырга гына кушмасыннар.

Октябрь аена кергәндә рәтләребез сирәгәйде – соңгы ике кызыбыз Әгерҗедәге апалары янына китеп утыз бишенче мәктәпкә кергәннәр. Авылга каникул вакытларында гына кайтачаклар икән. Ике малаебызны Ижаудагы туганнары үз янына алган. Без Зәет Сәетовичка иптәшкә нибарысы өч бөртек кенә калдык.

Сөт машинасы өстендә ачык җыелыш үткәреп, өчебез дә уртак бер карарга килдек – таң йокыларыбызны әрәм итеп сөт машинасы белән чиләнмәскә, велосипед белән йөрүгә күчәбез. Табылдык белән Дустай арасындагы алты чакрымны нибарысы ярты сәгатьтә үтеп, йокыны өч сәгатькә озынайттык. Экономияләнгән вакыт ярап куйды, йокы белән булышмыйбыз, укудан соң кайтырга бик ашыкмыйбыз – Табылдыкта көн дә кич кино күрсәтәләр. Киноны без «җиденче дәрес» дип йөртәбез, юкса Дустаебызга гомергә кино килгәне юк, теләгән кеше кинога да, концертка да, җыелышларга да Табылдыкка йөри.

Көннәр янып торган шәм кебек, күзгә күренеп кыскара хәзер.

«Җиденче» дәрестән соң гел караңгыга калабыз. Кыргый этләр очрамагае дип шүрлибез. Зәет Сәетовичка гына сиздермибез. Интернатта яшәү мәсьәләсендә сүз һаман ешрак чыга. Ашау мәсьәләсе генә куркыта, интернатта ашханә ризыгы шул, беләбез аның ни икәнен! Узган елны Әгерҗегә слетка баргач, тимер юл вокзалындагы ашханәгә кереп тамак ялгаган идек, икенче көнне мәктәпкә бара алмадык, шомырт суы эчә-эчә көч-хәл белән котылдык... Ә өйдә көн саен таба ашы!

Зәет Сәетович үгетли үк башлады:

– Үз кадерегезне үзегез белмисез, интернатлары менә дигән! Сезнең көн саен кайтып-китеп йөрүегезне яңа директор миннән генә күрә. Имеш, сез миңа ышанып кына юлга чыгасыз икән, әгәр иптәш булмаса, Табылдыкта каласы икәнсез. Үзегезне кызганмасагыз, мине кызганыгыз хет. Өемдә хатыным белән күкрәк баласы тилмереп көтеп ятканда, сезнең аркада интернатта кунып кала алмыйм ич инде мин!

Малайларның җелекләре җебеде, кызганудан пырыш-пырыш борын тарталар.

Мин Зәет Сәетовичны сүз белән якларга телəдем:

– Калыйк интернатта, рәхәтләнеп йокларбыз, туйганчы кино карарбыз, өйдәгеләр дә сагыныбрак көтеп торырлар...

– Табылдык кызына күңелең төшкәч, сиңа шул гына кирәк инде, – дип, Зәет Сәетович алдында авызымны ябып куйдылар.

Бу малайларга һич серeңне сөйләрлек түгел икән. Кайтарып әйтергә җаен гына көтәләр.

Күңелең төшкәч дигәннәре Алсинә инде ул. Күрше класстан.

Шулай бервакыт, гадәттәгечә, җыйнаулашып Табылдыкта кино карарга булдык. Карын ачкан чак иде, үч иткәндәй, киносы да кызык түгел – фильм башында ук җыелышка җыелганнар иде, иң соңгы кадрында гына таралыштылар. Ниндидер премияне алмыйча әрләшеп беттеләр. Күңелсез инде безгә, боргаланып утырабыз. Сул ягыма унбиш, уң ягыма егерме борылганмын. Егерме беренчесендә ни күрим: Табылдык кызы Алсинә, бөтенебезгә үч иткәндәй, экранга карап утыра, селкенми дә! Ул – экранга, ә мин аңа карап, егерме беренче борылышымда катып калдым, Алсинәне күреп карыным ачканы да онытылды. Залдагы экран яктысында китап укырга була. Тукта, нишләп шулай искитмәле тоела соң әле бу кыз? Мин, маңгай чәчләрен артка тарап, толымнарын баш түмеченә өеп куйган кызларны яратам. Аннан, миңа сөт кебек ак чырайлылар түгел, күбесенчә каратутлылар ошый. Кызларга кечкенә, печтик яки төймә борын килешми шикелле, минемчә алар күтәртмә борынлы булсалар матуррак күренәләр. Күз мәсьәләсендә бәхәсләшергә җыенмыйм, беләм, кара чәчле кызларга коңгырт күз килешә. Менә шушы мин теләгән сыйфатларның барысы да бар Алсинәдә! Узган ел зур сабантуйда күргәнием мин аны, алай искитәрлек түгел иде ул. Карасана, ничек тиз үсә бу кызлар, җитмәсә, үскән саен матурланалар... Әгәр бүген маҗаралы яки берәр сугыш турындагы кино булса, мин тәки Алсинәне күрмичә кала идем. Менә ни өчен кирәк икән ул кызыксыз кинолар...

Юлда кайтканда шатлыгымны уртаклашкан идем шул, әгәр кайтарып әйтәселәрен белгән булсаммы?..

Өчәү идек, Табылдык интернатына күчкәч берүзем калдым. Теге ике малай Можга дигән кечерәк бер станциягә туганнары янына киткән, шунда ук училище да бар, ди. Тиздән әти-әниләре дә күчеп китәселәр, ди. Минем китәр җирем юк шул. Абыем әле тулай торакта гына яши, аңа ышанып җәһәннәмгә олагасым килми. Сигезне бетергәнче түзәргә инде...

Табылдык интернатында миңа утыз алтынчы урынны бирделәр. Бөтенебез бер бүлмәдә, кызлар ничәүдер, белмим әле, санамадым, алары күршедә. Төрлебез төрле авылдан җыйналсак та, бер мәктәптә укыгач, читсенеп-ятсынып тору юк икән ул. Килгән көнне үк җыйнаулашып кәрт суктык. «Исәр» калганнар җиңүчеләргә урын җәйде. Иң соңгы «исәребез» мичтәге кисәү башын сакларга калды, юкса кисәүле килеш япсаң, бүлмәгә сөрем исе чыга. Ә инде янып беткәнен көтеп калакларны

ябарга онытсаң, бөтен җылы урамга очып бетә. Шуңа күрә соңгы «җүләрнең» эше бик тә җаваплы, имеш... Ышанмыйм!

Кичке ашка итсез генә дөге боткасы белән яртышар кружка сөт каплап куйгач, караватларга таралыштык.

Минем моның ише пружиналар өстендә йоклаган юк иде, кибет одеяллары ябынмаганга да бишбылтыр. Матрасы җиде түмгәкне корамалап җыйган сыман. Хәер, таралып китәрлек түгел, караватның пружиналары салынган, яту белән матрасның җиде кисәге бергә өелә. Мендәрне аңламадым – никтер баш тәгәрәп төшә. Сүрүен ачып карасам, механизаторларга кул сөртергә бирә торган төрле төстәге бер төенчек мамык. Тәмам йокы качты.

Өйдәге үрдәк мамыгыннан тутырылган ястык, үзебез сырган түшәк, ялтыр тышлы калын юрганыбызны күз алдыннан җибәрмичә сәгатьләр буена интеккәч кенә йокыга кителгән.

Ике авыл арасында ләмәк ерып йөргән эзләребезне калын кар каплады. Якты көн озын тәнәфес хәтле генә калды. Дәресләр беткәндә караңгы төшә башлый.

«Яшисез рәхәттә, ата-анагыз янызда түгел, җаныгыз ни тели, шуны эшләп тик ятасыз, абзар-кура җыештырасыгыз, утын турыйсыгыз, бала карыйсыгыз да юк», – дип, Табылдык малайлары безгә кызыгалар. Ә без, интернатныкылар, аларга кызыгабыз. Әти-әни хөрмәтендә яшәп, үз рәхәтләренең кадерен үзләре белмиләр.

Кич җитүгә, тәрбияче әби, мич ягасым бар, дип, өенә кайтып китә, аны төнге унберләрсез көтәсе дә юк. Шул арада интернатның асты өскә килеп ала, колхозның йөри алырдай нинди техникасы бар – һәммәсе безнең тирәгә җыела. Табылдык егетләре безнең бүлмәгә кереп тула. Күрше бүлмәдән кызларны чакырып чыгарырга яисә хат кисәге тапшырырга кушалар. Үзебезгә кирәкмәгәннәрен чакырабыз инде. Кичтән үк бик күп итеп хәйләләр табып куябыз да үзебезнең арадагы малайлар кызыгып йөргән кызлар хакында сүз кузгалса, тотлыкмыйча гына ялганлыйбыз: «Көне буе ютәлләп тора иде; туганнарына утырмага китте; эче авырта бугай; кичләрен өйдә утырмаган өчен әтисе килеп пыр туздырып китте... һ.б.».

Табылдык егетләре безне мич авызы тирәсенә җыеп тәмәке тарттыралар. Мин катышмыйм әле, Алсинә белән күрешеп сөйләшмичә торып тәмәкегә өйрәнмәскә булдым, бәлки, ул исен сөймидер?!

Алмаш-тилмәш тәмәке суырган арада, әллә ниткән мәзәкләр сөйләп алалар. Мәзәкләрен тыңлыйм, анысының исе юк. Мин дә берне сөйләдем...

Әгерҗенеке берәү хатынын ияртеп Казанга барган. Базарда йөргәндә адашып хатынын югалткан. Агай аптырап калмый, якында гына бер милиционер була, шуның янына килә дә: «Ярдәм итә күр, зинһар, хатыным югалды», – ди. «Ярар, эзләрбез, – дигән милиционер, – хатыныңның портреты нинди?» Агай «портрет» сүзен аңлап җиткермәгән. Шуннан соң милиционер үзенчә аңлатмак булган: «Әйтик, менә минем кызым чем-кара чәчле, бит алмасында миңе бар, керфекләре озын, елмайганда ияк очына мәхәббәт чокыры чыга, биле нечкә, гәүдәсе...» Абзый аны ахырынача тыңлап бетерә алмаган: «Иптәш милиционер, әйдә лутчы синең кызны гына эзлик», – дип җавап биргән.

Мин сөйләп бетергәч, берсе дә көлмәде, чөнки мин тәмәке тартмыйм. Кемдер: «Әйдә, лутчы синең Алсинәне генә эзлик», – дип өстәп куйган иде, әй тотындылар көләргә!.. Ирексездән киендем дә Алсинәләр өй түренә киттем...

Кызны күреп булмас инде, анысы хак, өй тирәләрендә башкалар юк микән, шуны гына беләсем килә... Һәй, мондый суыкта кем йөрсен соң? Тынычланып, кайтыр юлга борылган идем, баскан саен кар шыгырдатып Алсинә килә... Ул инде, билләһи ул – иңендә чиләк-көянтәсе. Мин аны куркытмас өчен баганадагы лампочка яктысына килеп бастым. Ул да яктыга сыешып кына тукталып калды.

– Нихәл, Алсинә?

– Исәнмесез, Баязитов...

Әгәр «нишләп йөрисең» дип сораса, оятымнан көртлек кебек карга чумам хәзер. Алдан ук җавап эзлим, Алсинәнең чиләгенә бозлар эленгән, мамык шәленең яңак тирәсен бәс сарган.

– Ярый, – ди бу, – болай да чиләгемә боз утырды, Болын чишмәсенә барган идем.

– Ай-һай, бигрәк еракта бит соң ул сезнең Болын чишмәгез. Бүреләр өне янында, курыкмыйсыңмы?

– Нәрсәдән куркыйм ди, интернат ачканнан бирле бүреләр безнең авылдан качып беттеләр инде алар... Син, Баязитов, дәрес әзерләмичә нишләп урамда йөрисең әле?

– Менә, геометрия китабы кирәгие, шуны эзләп чыккан идем. Үземнеке авылда онытылып калган.

– Хәзер, көтеп тор, алып чыгам, мондый суыкта китап эзлим дип капка санап йөрмә.

Әллә инде китапны куенында йөрткәнме? Икенче чиләге капкаларыннан кереп өлгермәде:

– Баязитов, мә! – дигән тавыш ишетелде.

– Сау булып тор, Алсинә, рәхмәт инде, син булмасаң, иртәгә геометриядән... – дип вакытны сузмакчы булам.

Ә ул:

– Хушыгыз, Баязитов, – дип, капкаларын ябып та куйды.

Төне буе Алсинәнең геометрия китабын укып чыктым. Йә тумбочка өстендәге лампочка янып төшәр, йә үзем сүнәм... Үзем сүнгәнмен. Җәелмәгән урын өстендә киемнәр белән эреп киткәнмен. Уяныргa ашыкмый идем әле, көтмәгәндә йөземә мендәр килеп төште. Мин аны-моны абайламыйча тотып аткан мендәр кемгәдер тиде бугай, аны да кемдер ай-вайлап бүтәнгә тотып орды. Ул арада әле бер, әле икенче якка әллә ничә мендәр очты – кемгә һәм ничек тисә дә барыбер инде, тик мендәр очуы гына дөрес булсын. Күпләребез мендәрен югалтып уеннан чыга барды. Минем кулда да буш сүрү генә калган иде, шуңа күрә, эш юктан эш булсын дип, ишек янында сакта тордым. Иртәнге мичкә ягарга утын күтәреп кергән тәрбиячебезне күргәч, малайларга кычкырдым-кычкырдым – тик ишетмәделәр.

Соңгы мендәр утын күтәреп кергән тәрбияче әбине бәреп екты. Уен кырт өзелде, шау-шу көне буе тукталмас кебек иде – бер мизгелдә тынлык урнашты. Һушына килгәннәребез мендәребезне тутырырга дип ашык-пошык идәннән мамык җыя башлады. Мин ары чаптым, бире чаптым, әмма мендәр сүрүемә салырга бер уч мамык тапмадым. Куркудан чамасыз күп төйгәннәрдер – миңа калдырмаганнар.

Әбиебез чәчелгән утынын да җыймыйча чыгып китте...

Сырмаларыбызның эчен йолыккалап мендәр тышларын бераз кабартсак та, җәзадан котылып булмады – минем ише биш малайны бер атна буена киногa җибәрмәскә, урамга чыгармаска дип әмер бирелде.

Бердәмлек дигән нәрсә көчле бездә анысы. Ни өчен әле «мендәр сугышы» өчен бишебез генә җавап тотарга тиеш ди?.. Калганнарыбыз да урамга чыкмас булды. Бер кич утырабыз, ике кич утырабыз бик астында... Өченче көнне Муса Җәлилнең Моабит шигырьләрен кычкырып укыйсы килә башлады.

Соңгы җырым палач балтасына
Башны куйган килеш языла...

Без, малайлар, ялгыз гына йөргәндә ничава болай. Ә инде бер тирәгә җыйналсак, әллә кайдан арабызга маймыл килә дә керә, керә дә безне үрти, этлеккә өйрәтә, котырта, этәчләндерә.

Бер атна буе йозак астында уйланып яткач, шундый нәтиҗәгә килдем – холкыбыз-фигылебезгә караганда уку елы беткәнче интернат сакларга туры киләчәк безгә... Әле алда нинди җәзалар көткәнен кем белгән?! Хуш, тимер караватым, сау бул, буш мендәрем, газиз башкайларымны сиңа бүтән салмам...

Хәзер, Зәет Сәетовичка ияреп, көн саен чаңгы белән килеп-китеп йөрим.

Расписаниеләрдә физкультура гел беренче сәгатькә куела, минем ике авыл арасын килүем дәрескә чутлана, өйдән берәр сәгать соңрак чыгарга була дигән сүз.

Вакыт кына җитми.

Зәет Сәетович артыннан йөгереп барам, аңардан калышмаска тырышып кайтам.

Алсинәләрнең өй түрен таптарлык та ара калмый.

Ул кыз гел күз алдымда минем.

Кайсы гына дәрескә керсәм дә: һәр кагыйдә, формула, закон һәм теоремада Алсинә бар! Әгәр укытучы, эндәш сүзләр җөмлә уртасында ике яктан да өтер белән аерыла, дисә, мин Алсинәне кино карап утырган җирендә ике як күршесеннән зур өтерләр белән аерып куям. Формула дигәннән, $A^2 + B^2$ дигән формула ошый миңа – Алсинә плюс Баязитов – матур яңгырый, әйеме? Квадратларыбыз ничек буладыр, анысын иркенләбрәк уйлап карыйсы бар. Закон мәсьәләсендә Алсинә теләсә кайсы законга да сыя. Физиканың соңгы дәресләрендә гел Архимед законнарын күз алдыма китереп утырдым. Алсинә зур сыеклыкка – Туен елгасының киң төшенә сикереп төшә, ә як-якка Алсинә зурлыгындагы дулкыннар йөгерешә... Җәй генә җитсен, ул дулкыннарны туйганчы кочарбыз әле. Җирнең тарту көче турында Ньютон бер дә юкка гына баш ватмаган, дөрес бит, әй, Алсинә булган җир мине гел үзенә тартып тора... Ә геометрия! Ул гел Алсинә турында гына язылган бугай. Һәр теорема да дөп-дөрес исбатланган... Ике нокта арасында бер генә туры сызык үткәреп була... Әйе шул, Алсинәләр өе белән интернат арасында бары тик минем сукмак кына булырга тиеш. Исбатларга кирәксә, теләсә кайсы егеткә исбатлап күрсәтермен... Алсинәне ныграк белер өчен тизрәк укыйсым килә.

Ә әлегә, тәнәфес саен юк сәбәпне бар итеп: җиденче «А» пунктыннан җиденче «Б» пунктына барып җитәргә, кара-каршы бәрелешмичә, һичьюгы, янәшәсеннән генә булса да үтеп китәргә!

Ә беркөнне кояш чыкмады...

Ишегалдында капкаңны эзләп табарлык түгел– буран күзне сылый. Көч-хәл белән Зәет Сәетовичларның өй түренә барып бастым. Дөресен генә әйткәндә, мин бүген аның: «Мондый буранда юлга чыгып тормабыз», – дигән сүзен ишетер өчен килгән идем. Дөнья хәлен белеп булмый дигәндәй, эни мине кызганып озата килде. Шушындыйлар итеп интегепләр алган белемеңнең игелеген күрергә язсын, ди. Мәҗбүри уку хакында башкача ни әйтәсең инде...

– Син кал, – ди Зәет Сәетович, – мондый буранда дәрескә килми калсаң да гаеп түгел. Миңа карама – мин эш кешесе, әгәр буран чыккан саен прогул бирә башласаң, коммунизмны кем төзер?!

Мин өйдә калыр идем дә, тик Зәет Сәетовичны юлга үзен генә чыгарасым килми. Аннан Алсинәләр ни әйтер? Әле буранның тиз генә басылып куя торган гадәте дә бар. Классташлар икенче кыш җиткәнче үртәп йөрерләр, аяз көнне бураннан куркып өендә калган дип.

Әнинең күз яшьләре юеш карга әйләнеп күз төбенә ягыла, әйтерсең мине соңгы юлга озата... Түзмәдем, чаңгыларымны салмыйча гына әнием янына килдем дә аны кочаклап күз төбендәге тозлы кар бөртекләрен үбеп алдым... Ник болай сагышлы соң ул бүген?..

Зәет Сәетовичның чаңгысына тагылып дигәндәй барам, аның пырыш-пырыш борын тартканы ишетелә, үзе сирәк-мирәк кенә артына борылып мине барлый. Дустайны чыгып текә тауны менүгә, буран тагын да көчәйгән кебегрәк булды, битне кычыткан белән чаккан шикелле итә, туры карап барырлык түгел. Ичмасам, ботинкам чаңгыдан чыгып интектерә. Аны яңадан эләктергән арада, Зәет Сәетович ун-унбиш метр киткән була. Көчкә куып җитәм үзен. Чаңгы ычкынган саен, укытучы кешегә: «Туктагыз инде!» – дип, һаман кычкырып та булмый.

Зәет Сәетович юлны ничек чамалыйдыр – анысы башка сыймый. Мин ияреп барырга риза... Бераздан ул да туктап калды.

– Кайсыбызның сәгате дөрес? Минеке нишләптер тугыз тулып килә, – диде ул, аптырап.

– Минеке дә шулай.

– Кызык, әллә кайчан Табылдыкка килеп җитәргә тиеш идек бит инде без.

– Алдаштык микәнни, абый?

– Әллә куркасың?

– Юк, кире кайтып китик, интегеп йөрмик, дип кенә әйтүем.

– Кайтыр юлыңны таба алгач, адашу буламыни ул?! – диде Зәет Сәетович, елмаеп.

Аның елмаюы миңа да күчте.

– Себердә яшәмибез лә, абый, барыйк та барыйк, берәр авылга чыгарбыз әле. Тик басып торгач буран куенга керә.

– Өермә буран кешене бер тирәдә бутап йөртергә дә мөмкин. Юлны турырак тотарга тырышыйк.

Кузгалып биш-ун минут киттек микән, тагын чаңгым ычкынды. Бу юлы икенче аяктан... Үземчә тиз генә каптырган кебек идем... ул арада чаңгы эзе күмелгән, Зәет Сәетович юкка чыккан. Кайсы якка киткәнен чамалап адымнарымны тизләттем. Барам да барам, ә укытучым һаман саен күренми. Ярты сәгатьләп бара торгач, кычкырып та карадым... Тик җавап бирүче генә юк.

Минем сәгать белән тагын ике сәгать атлый торгач, сыерлар кычкырган тавыш ишетелде! Сөенечтән тәнемә яңа сауган сөт җылысы йөгерде.

Мин бер генә өйне күрдем – ишегаллары капкасыз, йөзлегенә буяу тимәгән тәрәзәләре җирдән хәтсез биектә – буй җитәрлек түгел, түбәләре такта... Башка йортларны күрерлек түгел, шулай да чит авыл икәнен әллә каян тоеп торам.

Чаңгы таягы белән үрелеп кенә тәрәзәләрен шакыган идем, өй эченнән аңлаешсыз мыгырдаулар ишетелде. Хуҗаның озак чыкмавыннан сабырсызланып өйләренә кереп киттем. Тыштан ап-ак мамык өеменә охшап торса да, өй эче яңгырдан каралган такта төсендә иде.

Безнең Дустайдан сигез чакрымда гына Ямиташ авылы барлыгын ишетеп белә идем, тик моңарчы барып күргәнем юк иде. Күрдем шул...

Ар җиңгие белән көч-хәл аңлаштык: ул татарча, мин арларча белгәннәремне әйтә торгач, шунысын аңладым, биш өй аркылы гына мәктәпләре бар икән.

Мәктәп сүзен аңлап алу белән бөтен арганнарым гәүдәмне берьюлы басты... Керосинкада җиңгинең чәе кайнап чыкты. Күмер төсенә кергән чуеннан тавыкларга дип пешерелгән бәрәңгене калай мискәгә салып өстәл өстенә китереп куйгач, миңа көч керде. Кыстаганнарын да көтмичә бәрәңгегә ябырылдым.

Ямиташның мәктәп дигәннәре, бездәгечә, утынга сүтеләсе бер өй иде. Бер өйдә ике малай укып утыра. Укытучылары мине бәрәңге белән сыйлаган җиңгидән дә картрак. Фамилиясен Вахрушева диде. Чәче аксыл-кызгылт төстә, алсу йөзендәге шадралары ясмык төйгән куна тактасы шикелле. Елмайганда кисәк кенә егерме яшькә яшәреп киткәндәй була. Аның белән русча сөйләштек. Әлеге ар малайларының берсе өченчедә, берсе дүртенчедә укый икән. Вахрушева түти: «Утыр әйдә, сине дә укытам», – ди. Утырдым да, сумкам эчендәге карны бушаткач, көндәлегемне алып бүгенге маҗараларны язып куйдым.

Мин караңгы төшкәнче үзебезгә кайтып китәм, бераз хәл генә керсен дә... Зәет Сәетович кайтып минем юклыкны әйтсә, әнием нишләр? Дустайның кайсы якта икәнен чамалыйм, юлны туры тотыбрак атлармын. Буран басылганны көтсәң, бәлки, ул өч көнсез туктамас.

Көндәлегемне язып, Вахрушева белән хушлаштым да тагын чаңгыларымны кидем. Көпшәк карга чаңгылар нык батса да эзем калмый, шундук буран күмеп бара. Шунысы рәхәт – җил уңаена атлыйм. Бер сәгать чамасы үткәч, чаңгыларым җиңеләйгән кебек тоелды – тау төшәм. Бу – ике авыл арасындагы олы ерганак иде.

Кинәт ерганак төпкеленнән кыргый этләр өргән тавыш ишетелде. Алар күбәү, бик күбәү иделәр һәм тавышлары миңа иярде. Күңелем котылгысыз хәвефне сизенеп, буранны бөтенләй тоймас хәлдә идем.

Этләр өрүе һаман саен якыная бара. Аларның кешегә үчләре бар. Кыргый этләрдән котылырмын димә! Безнең якта адашкан кешене эзләп тапканнары юк әле. Бу этләргә кемнәр генә юлыкмаган һәм тагын кемнәр юлыгыр икән? Алар мине куып килә. Әгәр кар өстендә чаңгысыз калган булсам, мине ике сикерүдә куып җитәрләр иде инде. Ерганак яры текәләнде бугай – чаңгыларымны тыяр хәл юк. Аягымда чак басып торам. Менә чаңгымның берсе көрткә төртелде, икенчесе читкә каерды. Мәтәлеп китеп кулбашым белән бер агачка килеп бәрелдем. Агач! Кочагыма сыярдай гына каен агачы мине үзе күтәреп алды бугай. Кәрлә, кәкре, карт каен гына булсаң да, нинди көчле син, каеным! Әнә ул этләр минем сумкамны ботарлый. Китапларымны, көндәлегемне буран алып китте. Каен төбендә кыргый этләр өрә, әле ярый табигать сезне агач башына менәргә өйрәтмәгән... Сез минем егылып төшкәнемне көтеп котырасыз. Тәнемдә кан җылысы бар чагымда мин бу каенны кочагымнан чыгармам. Мине өйдә газиз әнием көтә, мин әнигә бик кирәк, мин аның соңгы улы.

# ЯШЕЛ ЧИТЛЕК

Алар инде үзләренең өченче көзен каршы алырга җыена. Җәйнең соңгы ае коры килде быел – көн кызулыгы нарат күләгәсендә дә сизелә. Ләкин балаларның үсеп җитүенә караганда ул салкын көннәр бик якын инде.

Узган ел да шулай булды... Август челләсе янган учак шикелле дөрләп торды-торды да тоташ яңгырлар килеп сүрелдереп куйды. Чыланган туфрак, юеш урман барыбер җәй уртасындагы кебек шакыраеп кибә алмый инде аннан соң.

...Үткән җәйдә алар өч кенә бала үстерде.

Быел яз көне, алар башка керпеләргә дә хас хәстәрлек күреп, наратлык белән болын тоташкан җирдә бурсыклардан бушаган бер өнне үзләренә оя итеп сайлаганнар иде. Болын тирәсендә ризык табу җиңелрәк – юллар такыр, үләннәр коры һәм сирәк, бөҗәкләр күбрәк, җиләкләр тәмлерәк... Ләкин бу тирәдә кешеләр күбәя башлады. Әле кар сулары бетеп, җир ныгып та өлгермәгән иде, кешеләр килеп, болында казыклар кагып йөренә башладылар, өзлексез ызгыштылар, күч күтәргән кырмыска оясы шикелле кайнашып төзелеш материаллары ташыдылар. Кайчакларда бу тирәдә кешеләр шулкадәр күбәя – кичекмәстән ояны күчерергә кирәк. Ләкин ана керпе йөкле иде. Шуңа күрә мондый җайлы ояны ташлап китәргә һаман тәвәккәлли алмадылар.

Аларның биш баласы туды – биш шәрә керпе.

Бәхеткә каршы, кешеләр урманны бик борчымадылар, вакытлары бик тар иде бугай – һәркайсы ашкынып дача төзи. Бу ояда, балаларның күзләре ачылганчы гына, ике-өч атна яшәп булыр әле. Аннан соң күченерләр – урман калын, биш балалы керпе гаиләсе генә сыяр.

Алар, үч иткәндәй, ауга парлашып киткәннәр иде. Төн шундый тыныч, җылы. Оя эченә ай яктысы төшеп калды... Кыр тычканнарын куа-куа шактый юл үттеләр алар. Кинәт аларның оясы янында машина үкергән тавыш ишетелде. Кайтсалар... оя өстенә кара, шыксыз, олы машина туктаган да бер яшь наратны тамырлары белән йолкып маташа. Ике кеше төз наратның каерылган ботакларын өзә, ай яктысында балталарының йөзе елкылдый. Авыр машинаның арткы көпчәге астында оя, ә ояда күзләре дә ачылмаган, энәләре дә тырпаймаган биш бала...

Алар шул төнне үк, балалары күмелгән ояны ташлап, нарат урманының иң түренә күчеп килделәр. Машина көпчәге менә алмаслык биек төп астына оя корып янә бала көтә башладылар. Һәм бүтән керпеләрнең балалары, оялары белән хушлашып пар-пар таралышкан чакта, табигать аларга тагын... җиде бала бүләк итте...

...Нарат урманында көзнең сары яктылыгы сизелми, шуңа күрә ана керпе көн саен диярлек каенлы аланга барып килә.

Каеннар көзне алданрак тоя, аларга карап башкалар да, җәйге мәшәкатьләрдән тизрәк арынып, кышка хәстәрлек күрә башлый... Китәр кошлар төркемнәргә оеша, җанварлар өн тирәнәйтә... Һәм ана керпе дә, үз парын ашыктырып, калынрак итеп яфрак коелган чокырда кыш кичәрлек урын сайлар. Ә балалары... Алар да парлашып таралышыр, монысына инде аларны өйрәтеп торасы юк – табигать тәрбияләгән гадәт. Бер баласы – дүртенче малае гына так калыр һәм үзенә пар эзләп китәр. Урман эченәрәк үтсә, әлбәттә, табар ул аны. Ана керпе балалары тәпи йөри башлаганнан бирле урман авызына чыкмады. Әгәр бу җиде шаян йомгак урман авызына юнәлсә, шундук аларның юлларына аркылы төшеп, «фырт! фырт!» иткән тавыш чыгарып, кире ояга, ягъни нарат куелыгына таба куалый торган иде. Урманнан чыгарга ярамый, анда үлем көтә, хәтәр сагалап тора. Балаларның җидесе дә шуны нык хәтерләп калырга тиешләр, аларның балаларының балалары да онытмаслык булсын.

Көндез алар – тугыз җан иясе – гел бер тирәдә, оя яныннан ерак китмичә генә җир иснәүдә. Өйлә вакытында кинәт әлсерәп, энәләрен артык тырпайтмыйча гына, бөтенесе бер күчкә оешып дигәндәй, ял

итәләр. Кичләрен исә, төрлесе төрле тарафка тәгам эзләп чыга. Җәй ахырында тамак туйдыруның һич кыенлыгы юк: борыныңны җилгә каршы күтәрсәң, тәмле гөмбә исе килә, ә гөмбә булган җирдә һәрвакыт бөҗәк бар. Дөрес, хәзергә баллы гөмбәләр генә чәчелеп үсә. Килер шундый чак: усак, каен, нарат гөмбәләре, гөреҗдәләр баш калкытыр, майлы гөмбәләр кабарыр, һәм керпе гаиләсе шул гөмбәләр тирәсендә чемченеп йөри торгач, шактый ризык табып, симергәнче сыйланыр. Симергәнче – кышкы йокыга җиткәнче.

Мәгәр әлегә җәй бирешми әле.

Җиргә коелган ылыслар шакыраеп кипкән, атлаганда чыртлап сынып кала, йөргәнең әллә кайдан ишетелеп тора. Ипсезрәк бассаң – ылыс тәпигә кадала да керпе кисәк авыртудан сискәнеп читкә сикерә. Һәм шундый кыштырдау куба – җирдәге дошманнарың гына түгел, һавадагы козгыннар да ишетер...

...Ояның авызы кояшка карый, шуңадыр, ояда иртүк бөркүләнә. Аннан соң кысан да. Җиде бала эти-әнисе тирәли кысылып ята торгач, кайчак берсенең энәләре икенчесенекенә чуалып бетә, балалар укмашып, куба алмыйча изалана. Шуннан әниләре пошкыра-пошкыра көч-хәл белән оя авызына чыга, ә аңа, тигәнәктәй сарылып, җиде бала ябышкан була. Балалары инде үз тамакларын үзләре туйдырырга өйрәнеп килә. Шулай да көн эсседә алар бик ялкауланалар. Әниләрен яңгыр суларыннан бушаган коры канауга тәгәрәтеп төшерәләр дә комсызланып имәргә ябышалар. Көн озын, һава эссе, төнге ау бик кыска – әниләренә бу хәтле гаиләне туйдырырлык сөт каян килсен. Тамаклары кибә торгандыр шул.

Коры канау буйлап түбәнгә төшсәң, чишмә суы челтерәп ага, әллә ни ерак та түгел, әйләнеп килгәнче ярты сәгатьлек юл. Туйганчы су эчсәң, балаларга җитәрлек сөт төшәр иде. Әтиләре күз-колак булып торыр иде әле.

Чишмә суы артык киң җәелеп акмый. Аның бу яры тау сыман текә иде, бик сакланып кына төшәргә туры килде. Су янына ук килеп баскач та ул, үзенең сусавын тыеп, бермәлгә иснәнеп торды – ят ис килә кебек тоелды аңа. Шикләнүе заяга булмаган икән – агымсуга карап бераз атлауга тәмәке төпчегенә юлыкты. Ул кинәт сискәнеп аякларына басты да үрелеп-үрелеп тагын һаваны иснәде. Юк, кеше-мазар күренми. Тәмәке төпчеген узып агымга каршы шактый менгәч түзмәде: ниһаять, урман чишмәсенең чеплә ярсуыннан яшеренеп яткан салкын суына телен тидерде.

Керпеләр суны мәче шикелле тел белән эчәләр. Бик сусаган чакларда һай озак чупылдатырга туры килә керпеләргә.

Ул әле суның тәмен дә тоеп өлгермәде. Кинәт колак тондыргыч гөрелте ишетелә башлады, ишетелде генә түгел, бик тиз якынайды да ул. Кичекмәстән качып өлгерергә кирәк иде. Ана керпе җәһәт кенә өскә үрмәләде. Кабаланып атлагангамы, әллә ярның текәрәк җире туры килдеме – аяклары чалынды. Менеп җитәм дигәндә генә баскан җирдә яр ишелде дә ул балчык түмгәге сыман су уртасына тәгәрәп барып төште, анда да түше белән түгел, ә чалкан капланды. Аяклары белән күпме генә тыпырчынмасын, башын ничаклы гына боргаламасын, гәүдәне әйләндерер өчен таяныр урын юк иде. Җитмәсә, суы да сай булып чыкты, ул энәләре белән ләмгә кадалды, ә гөрелте, көчәйгәннән-көчәя барып, ниһаять, кып-кызыл мотоциклга әверелде дә су читенә үк килеп туктады. Оста туктады, алгы тәгәрмәче аз гына кыймшана калса, алар инде өчәүләшеп – кыз, егет һәм мотоцикл – керпе өстенә килеп төшәселәр иде.

– Хәзер, мин сине сугарам, – диде кыз.

– Миңа су кирәкми, – диде егет.

– Урманда башкасы юк, – диде кыз.

– Аның каравы портфельдә бар.

– Кирәкми. Мин аның өчен килмәдем, – диде кыз.

– Барыбер түгелмени? – диде егет.

– Түгел. Син мине табигать кочагына дип алып килдең. Ә үзең әлләниләр сөйли башладың.

– Минем кочак та табигатьнекеннән ким түгел.

– Тагын шундыйрак берәр сүз әйтсәң, кайтам да китәм.

– Җәяүме? Юлны белмисең, вәт!

– Менә шушы суга ияреп китәм, йә берәр авылга барып чыгар, йә зуррак елгага. Шәһәр дә ерак түгел моннан, – диде кыз.

– Алайса, мин сине агачка бәйләп куям.

– Куркыныч кеше икәнсең син.

– Тугыз ел бергә укып шуны белмәдеңме?

– Бүген белгәч тә җиткән, әле соң түгел...

– Соң инде.

Егет «эһ» дигәнче кызны беләгеннән эләктереп алды да кулларын каерып җиргә егып салды һәм, кызның кайсы җиреннән үбәргә белмәгәндәй, әле битләренә, әле иягенә, маңгаена үрелде. Үзе ашыгып-ашыгып нидер әйтеп калырга, нәрсәгәдер ышандырырга тырышты. Җөмләләре өзек-өзек, сулышы еш-еш иде аның.

– Бу безнең соңгы каникул... Киләсе җәйгә син миңа тәтемәячәксең. Хәзер ычкындырмыйм... Аннан соң хет теләсәң нишлә.

– Җүләр мин, җүләр, сиңа ышанып... Җибәр, юкса кычкырам. Ачуымны чыгарма, юкса берәр хәл эшлим үзеңә.

– Эшләгән диярләр.

Ике арада аңлаешсыз һәм шыксыз тынлык урнашып алды.

– Абау, су эчендә әллә нәрсә чыпырдый. Елан бака тотты бугай.

– Китче, каян килсен монда елан? – диде егет, сагаеп.

Егет, кызның сүзенә ышанырга теләмәсә дә, әлеге тавыш белән кызыксынмыйча булдыра алмады һәм, максатын онытып, тиз генә ярдан төште. Әгәр кыз шушы минутта аннан котылыр өчен генә ялганлаган булса, егет икеләтә усаллык белән һәм кире уйланырлык урын калдырмыйча, яңадан кызга ташланачак иде... Чыннан да, су эченә чалкан капланып, ярдәмгә интегеп яткан керпене күргәч, җиңел сулап куйды ул:

– Мишәйт итеп йөри шунда...

– Ә ул мине коткарырга килгән, – диде кыз, үз сүзләренә үзе ышанып.

– Коткарды ди, аягына да баса алмаган килеш.

– Коткарды, коткарды, коткарды, – диде кыз, көйсез генә такмаклап. – Ә хәзер мин аны коткарам.

Кыз кроссовкаларын да салып тормыйча керпе янына кереп басты, аның йомры тез астына чаклы тартылган ак гольфасына су сеңде. Керпене песи баласын иркәләгәндәй сыйпый-сыйпый кулына алды ул.

– Ничек пычранган. Хәле беткән, күптән интегә бугай, – диде кыз.

– Аны төлке тәгәрәтеп төшергәндер әле.

– Төлкедән түгел, синнән куркып төшкән ул, – диде кыз, ачуланып.

– Китер әле монда.

Керпе егет кулына күчте. «Кулына» дип, кыз шикелле кушучлап тотмады ул аны, ә бер генә энәсеннән чеметеп күтәрде. Авыртуга чыдамыйча, чәнечкеле йомгак тагын да ныграк кысылды, кечерәеп калды. Егет аны суның тирәнрәк төшенә ыргытты да туп юган кебек әйләндерергә керештерде.

– Нишләтәсең, керпеләр су яратмый бит, – диде кыз, өзгәләнеп.

– Яратмаса, суга төшеп ятмасын иде. Кем кушкан...

– Ул ана керпе.

– Бәлки, атадыр.

– Ата керпеләр сусамыйлар. Ризыктагы дым җитә аларга.

– Отличниклар барысын да белә инде... Ә мин әйтәм, бу ата керпе, күрәсең киләме?

– Оятсызланма. – Кыз борылып басты.

– Син хаклы, ана керпе бу, – диде егет бераздан.

– Димәк, балалары көтә аны, – диде кыз, яңадан егеткә текәлеп.

– Ниткән бала тусын ди бу чәнечкедән?

– Күрәсең ич – энәләре соры төстә, яшь керпе түгел инде ул. Җибәр син аны.

– Җибәрмим. Өйгә алып кайтып туныйм да бүрек тектереп киям. Бер кеше дә урламый торган бүрек булачак ул.

– Җибәр.

– Җибәрсәм, нишләрсең.

– Керпе сөенер, – диде кыз.

– Ә син?

– Мин дә.

– Су уртасында басып тору килешә сиңа, чиләнгә охшыйсың. Кая, бер үбеп алыйм әле.

– Якын килмә.

Кыз капылт кына су төбендәге лайны учына алды да үзенең маңгаена, битенә, иягенә сылады.

– Мә, үп!

– Фу, дура!

Егет, кесәләрен актара торгач, җептән үрелгән сетка чыгарды да керпене салып һавада әйләндерә башлады. Керпене түгел, кызны үчекләве иде үзенчә. Янәсе, кызганасыңмы, кызгансаң, ялын, бәлки, кайбер шартларда син дигәнчә булыр.

– Нишләтәсең, башы әйләнә бит! – дип өзгәләнде кыз.

– Йомгакның башы буламыни?! – Егет әйләндерүен белде.

– Син үзең башсыз! Туктат, үтерәсең мескенне.

Кыз түзмәде, судан атылып дигәндәй чыкты да, лайга баткан кроссовкаларын лычтырдатып, егет янына ашыкты.

Ә теге керпене һаман әйләндерә, урыныннан очып китә алмаган ватык вертолет шикелле, «р» авазы кергән сузынкы тавыш чыгарып әйләндерә. Кыз аны туктар дип ышанып әкренләп-әкренләп якыная торды. Кыз якыная, ә теге туктамый, кыз якыная, ә сыңар канат әйләнә дә әйләнә. Кыз якыная... һәм яңагына кисәк кенә керпе килеп томырылгач чайкалып артка чигенә, абына, ләкин егылмый.

– Ой! – Кыз ике кулы белән ике яңагын каплады. Дөрес, керпенең йөзәрләгән энәсе аның бер генә яңагын иләкләгән, ләкин ул, егетне күрмәс өчен, күзләрен капларга теләгән иде. Сул уч төбеннән кан саркып чыкты.

– Гафу ит, сизми калдым, якын килмәссең дип уйлаган идем.

– Ә мин сукмассың дип уйлаган идем.

– Гафу ит, авыртамы? – Егетнең тавышында үкенү сизелде.

– Тавышыңны да ишетәсем килми. Керпене үтердең.

– Хәзер беләбез аны. – Егет керпене сыйпап күрсәтмәкче иде, бөгәрләнгән йомгак үзалдына кисәк сикереп куйгандай итте.

– Ай, ой-ой! – Егет кычытканга чагылган баладай уч төбен ялый башлады.

– Шул кирәк сиңа, дошман! – диде кыз, нәфрәтләнеп.

– Үлмәгән дидем ич. Берәр төлке йә бүре тәпиен сузса, керпеләр гел шулай – энәләре белән чәнчеп-чәнчеп ала. Иммунитет, рефлекс, саклану чарасы. Йә, ярый, кайтыйк тизрәк, битеңә йод сөртәсе бар.

– Матаеңа бүтән утырасым юк.

– Ашыгырга кирәк, каның агып бетсә...

– Үләрмен, ичмасам, – диде кыз, ышандырырлык итеп.

– Киребеткән. Үҗәт хан кызы. Синең үлемеңдә минем гаебем булмас. Пока!

Егет керпеле сетканы рульгә бәйләде дә агачлар арасына кереп югалды. Мотоцикл артыннан томанга охшаш, әмма әче, зәңгәр төтен өермәсе генә бөтерелеп калды... Беркавымнан соң егет тагын чишмә янына сугылды, кызны тагын бер кат сынап карарга иде, ахры, исәбе, ләкин кыз анда юк иде инде.

Урман аша олы юлга чыкканчы мотоциклга шактый сикәлтә кичәсе бар иде әле. Руль уйнаклаган саен, сеткадагы керпе як-якка бәрелде. Җитмәсә, урманнан кыйный-кыйный озаткандай, яшь наратларның түбәнге ботаклары әрсез мотоциклны, гамьсез егетне һәм шул исәптән керпене дә уңлы-суллы камчылый иде.

Ниһаять, олы юлга асфальтка чыккач кына мотоцикл тигез гүләп җәһәтрәк йөгерә башлады. Керпенең энәләрен аралап бөркү җил агымы килеп бәрелде. Бөркү булса да, ул рәхәтләндереп, тәндәге бөтен авыртуларны онытырлык итеп җиләсләндерә иде. Тора-бара урман манзарасы өчен таныш булмаган ят тавышлар ишетелде. Баштарак машина, трактор гөрелтесе, аннары трамвай тыкылдавы, җан өшеткеч гудоклар, этләр өрүе һәм керпе өчен иң хәтәре – куплаган кешеләр сөйләшүе артканнан-арта, көчәйгәннән-көчәя барды.

Өйгә кайту белән егет шәрран ярып мактанырга тотынды:

– Нинди оригиналь мәче алып кайттым, күселәрнең, тычканнарның җан дошманы – тере керпе.

– Шул гына җитмәгәние, өйне абзарга әйләндердең инде, – дип каршы төште хатын-кыз тавышы. – Аквариум дидең – карышмадым, попугай сорадың – сүз әйтмәдем, керпең нәрсәгә кирәкте тагын?

– Яшәп карасын. Кызык ич, бөтен кешегә дә элəгә торган нәрсә түгел.

Аны сеткадан идәнгә селкеп төшерделәр. Кечкенә тәлинкә белән сөт куйдылар һәм диванга утырып, керпенең ачылганын көтә башладылар. Өй эчендә бөркү тынлык урнашты, ачык балкон ишегеннән урам тавышы гына гөрелдәп тора иде. Аның бик нык тамагы кипкән иде, ул урман чишмәсеннән дә туйганчы су эчеп өлгермәгән иде. Тәлинкәдәге сөт исе бөтен куркуны җиңәргә мәҗбүр итте.

Аның иң әүвәл башы җанланды, әкренләп гәүдәсе язылды. Һәм чәнечкеле йомгак күз алдында сөйкемле җан иясенә әверелде. Ул, тәлинкәгә алгы тәпиләрен тидермичә генә үрелеп, сөтне иснәде. Аның әле бервакытта да сөт эчеп караганы юк иде, алай да бу ак сыеклыкның бик тәмле икәнлеген исеннән сизенде ул.

Рәхәтләнеп сөт эчкәч яңадан йомгакка йомарлануын кирәксенмәде, үзен ирекә чыккандай хис итеп буяулы шома идән буйлап аулак почмак эзләп китте. Шулчак, баш очында ялгыз кош тавышы ишетелде, ләкин урмандагыча түгел, ниндидер ят сайрау – сакау сандугач шикеллерәк интегә, әллә кылана шунда...

– Гел сөт белән генә яшәр дисеңме? – Хатын-кыз тавышы йомшарды.

– Без ашаган аңа да ярар әле, – диде егет тавышы.

– Урманда кешечә яшәп яткан дисеңме?

– Филләрне дә кеше кулыннан ашарга өйрәтәләр.

– Ниләр белән туена икән соң бу дүрт аяклы кактусың?

– Белмим, – диде егет.

– Нәрсәгә генә укыталар соң сезне?

– Һәрбер җәнлекнең ашказанын өйрәнә башласаң, мәктәптә ун гына түгел, утыз ел укырга кирәк.

– Белгән кеше барысын да белә... Шылтыратып сорап кара әле.

Егет телефонга ябышты. Шактый көтеп тә җавап ишетелмәгәч, ышандырырлык итеп энисенең авызын япты:

– Урманнан кайтып җитмәгән әле ул.

Керпе идән ырмавы буенча чабып диван астына кереп качты. Ошамаслык урын түгел икән – караңгылыгы да җитәрлек, юылган такталардан чын агач исе аңкып тора. Нинди генә ис юк монда... Кайчандыр, шушы бердәнбер аулак урында песи дә яшәгән, ахрысы. Бик күптән түгелдер әле. Пәрәвезгә ябышып калган каурыйлар да әле артык нык кибеп өлгермәгән. Кем каурые соң бу? Песи дигәнең диван астына тере тавыкны сөйрәп керә алмагандыр. Аннан соң, каурыйлар да бик вак, йомшак, төрле төстә. Бүлмәдәге читлектә тыпырчынган ялгыз кош күз алдына килә. Песине дә бөтенләй олактырганнар. Төтене чыгып тормаса да, якында гына, күзләрдән яшь агызырлык һәм баш әйләндергеч көек исе килә. Керпе аны да эзләп тапты – тәмәке төпчеге җыя торган тәлинкә сыман нәрсә иде бу. Ул аны ачу белән этеп җибәрде, диван астыннан төрткәләп чыгарырга иде исәбе, ләкин савыт, тактага бәрелгәч, әйләнеп кенә капланды. Керпе үзалдына кинәт сискәнеп куйды, әлеге савыт шакмаклы-шакмаклы таш гөмбәзне хәтерләтсә дә, кайчандыр аның җан иясе булганлыгы сизелеп тора!.. Керпене үз язмышы ачындырды – ни көтә икән аны? Мөгаен, бу өйдән исән-имин килеш чыгып котылучы юктыр...

Ишек ябылды.

Әнисен озаткач, егет, ишекне ике йозагына бикләп, диван почмагына килеп утырды.

– Әй, аяклы кактус, чык әле монда, чәнечкеләреңә бигуди куям. Төпчек савытын әнигә күрсәтә яздың бит. Ул аның нәрсәдән ясалганын белми әле.

Егет идәнгә ятып керпене эзләде, тик тапмады, тегесе, алдан ук саклык чарасы күреп, диван астына кагылган аркылы такта өстенә менеп качкан иде. Шуннан соң егет ташбака кабырчыгыннан ясалган төпчек савытын үрелеп алды.

Өйгә тагын да зәһәррәк булып теге көек исе таралды... Беркавым утыргач, егет балкон ишеген ачып җилләтергә теләде. Пәрәвез оясындагы тутый кош мамыкларын тибрәндереп, җылымса җил килеп керде. Җил генә түгел, урам исе: җәйге иркенлек, җан рәхәте, сөенеч – һәммәсе дә бар анда. Шушы җилгә каршы атласаң, һичшиксез иреккә чыгарсың шикелле...

Ул кыр тычканнарын кугандагыча җитезлек белән ачык ишеккә ыргылды һәм, тәбәнәк бусаганы атлауга, балкон рәшәткәсе аша упкынга охшаш бушлыкка очты. Бераз очып, аскы балконнан тарттырылган кер бавына бәрелгәч, ул, читкә атылып, чәчәкләр түтәленә барып төште.

Җиргә бәрелгәч, авыртудан хәлсезләнгәндер, аның инде тыгыз йомгак булып йомарланырлык хәле юк иде. Ул өнсез калды.

Егет өченче каттагы балконга чыгып карагач, чәчәк түтәлендә өнсез яткан керпегә кул гына селтәде. Җитмәсә, телефоны да шылтырый.

– Тыңлыйм, – диде егет, иренеп кенә.

– Керпене миңа бир әле, – диде кыз, ялынмыйча.

– Ә-ә, кайтып җиттеңме? Җәяүле кешегә биш сәгатьлек юл икән.

– Бир керпене.

– Ул үз-үзенә кул салды.

– Ничек?

– Өченче каттан, балконнан сикерде. Урыны чәчәктә булсын.

Сөйләшү өзелде. Егет кулындагы трубкада кыска гудоклар гына ишетелеп калды.

Керпе озын кышкы йокыдан уянгандай әкрен генә күзләрен ачты. Бөтен тәне изелгән сыман, аяклары гәүдәгә буйсынмый, бик нык изалана торгач кына түшенә ята алды һәм ышанмаслык хәл: аяк астында көпшәк җир – купшы урманнарда гына очрый торган хуш исле кара туфрак! Ул үз күзләренә үзе ышанмыйча борынын күккә чөя-чөя, пыр туздырып, җир казырга кереште. Казый торгач, аннан зепелдәвек канатлы зур яшел коңгыз да актарып чыгарды. Нәкъ үз урманындагыча! Димәк, ул иректә! Сөенеч зур көч икән, ул мыркылдый-мыркылдый энәләрендәге тузанны какты. Аның хәзер урманга чабасы, ятим калган җиде баласы һәм ялгыз калган әтиләре янына ашыгасы килде... Ләкин юлы бик кыска булып чыкты: әлеге урман туфрагы буй җитмәслек рәшәткә белән уратып алынган иде. Бәлки, эзләнә торсаң, керпе сыярлык кына юлы табылыр да, тик анда – рәшәткәнең теге ягында, шомартып җәелгән чем-кара таш юл, хәвеф-казадан качып котылырлык куе куаклыклар да, һичьюгы, карчыгадан котылыр өчен посып калырлык күләгә дә юк. Ә иң хәтәре – таш урамда килбәтсез машиналар үкерүе, теге егеткә охшаш кешеләр. Димәк, караңгы төшкәнне көтәргә туры килә... Ул әрекмән яфрагы астына яшеренеп җиргә елышты. Бертоташтан ярты гомерен йоклап үткәрә ала торган җан иясе өчен әлеге тынычлануны йокы дип атасаң күбрәктер, черем итү генә бу – аның да иң кыскасы...

Егет, кызның өйгә кермәслеген белепме, әледән-әле балконга чыгып чәчәк түтәлен күзәтте, дөресрәге – кызның килүен көтте... Ә бер чыгуында ни күрсен – чәчәк түтәле актарылган, керпедән җилләр искән! Димәк, сиздерми-нитми генә кыз алып киткән.

Башка вакытта егет өченче кат кына дип тормас, лифт көтәр иде, бу юлы баскычлар буйлап кына йөгереп төште. Алай ук ашыгасы калмаган икән, кыз бакча янында иде әле, куллары буш.

– Кая соң ул? Мине юри чакырдыңмы? – диде кыз, бөрчек-бөрчек кутырлар белән сипкелләнгән сул яңагын каплап.

Кызны күрүгә, җикеренер өчен тирән итеп сулыш алган иде егет, кирәге чыкмады:

– Эт алып китте аны, – дигән булды.

Кызның күзләре йомылды, иреннәре тартыша башлады.

– Җылама! Ерак китә алмагандыр. – Һәм ул, зәһәр сызгырып, туп тибеп йөргән малайларга дәште: – Керпе күтәреп киткән җан әсәрен күрмәдегезме?!

Тегеләр җавап бирәсе урынга, тупларын онытып, егет белән кыз янына өерелделәр.

– Алайса исән? – диде кыз, елмаюын яшерә алмыйча.

– Кем белгән инде аны. – Егет, рәшәткәне атлап, чәчәк түтәле тирәли эзләнергә кереште. Малай-шалайлар артык якын килергә куркып кына егетне күзәттеләр, маҗара көттеләр...

Маҗара, чәнечкеле йомгакка әверелеп, әрекмән яфрагы астында ята иде. Егет аны кулына алырга уйламады да, аяк очы белән типкәләп тәгәрәтеп китерде.

– Сатам, кайсыгыз ала? – диде егет.

– Мин, – диде тупны алып килгәне.

– Ун тәңкәсе кесәмдә, этидән сорасам, тагын өсти.

– Аукцион!.. – диде егет, алыш-бирешне уенга борып. – Ун сум бер, ун сум ике...

Малайлар, муен күтәрә алмаслык булып авырайган башларын аска иделәр.

– Берегезгә дә юк, – диде кыз, өзгәләнеп, – үзем алам!

– Акчагамы? – диде егет, башкаларга көләргә кушып. – Шушы шаһитлар алдында «Яратам!» дип бер әйтсәң, керпе синеке.

Малайлар кызның дәшми торуына хәйран калдылар: вәт җүләр кыз, бушлай керпе бирәм дип торганда... Сорасын иде ул менә алардан – хор белән яңгыратып: «Яратабыз», – диярләр иде.

– Юк! – диде кыз.

– Юкмы?! – Егет кесәсеннән зажигалка алып кабызды, газдан яна торган икән, ялкынын зур итеп ачты. Сул кулы белән керпене бер энәсеннән күтәреп уң кулындагы ялкынны якынайтты.

– Тимә!.. Яратам!!!

Бу изге сүзне ничә төрле мәгънәдә әйтергә мөмкин икән...

– Күрдегезме, лампочка борыннар, апагыз мине өзелеп ярата икән...– диде егет, шамакайланып, – ә хәзер сыпыртыгыз моннан, юкса кулымда ут уйнап тора.

Малайлар, керпе гамен тиз генә оныта алмасалар да, туп артыннан йөгерешергә мәҗбүр иделәр. Егет аларның ераграк китеп таралышканнарын көтте. Аннан соң башындагы кепкасын салды. Иләмсез озын козыреклы зәңгәр кепка өч яшьлек керпе өчен тап-таман гына иде.

– Кара син бу аяклы кактусны, нәкъ минем баш чаклы икән.

– Әйткәч, керпе синеке, дидең...

– «Яратам» дигән сүзең ышандырмады мине.

– Инде кая алып киттең?

– Зоомагазинга. Сатам мин аны, ичмасам, сигаретлык акча тияр. Артымнан йөрмә!

Сәер хәл, әмма кыз калмады, киресенчә, үҗәтләнеп тагылды. Кимсенүләр, рәнҗүләр баштагы мәлне генә кыен икән ул, ә бер ияләнгәч, исең дә китми, әрсезләнәсең... Кешенең асылы шулайдыр: коры күлмәгенә сыңар тамчы яңгыр тамса, кабаланып ышык урын эзли башлый, әгәр ул ачык кырда яңгырга юлыкса, киемнәрем җебеп тәнемә ябышты дими, юлын дәвам итә.

Зоомагазинда җәй көне кеше азрак була, һәркем табигать кочагында – тоткындагы җәнлекләр, кош-кортлар белән күңел юатыр чак түгел. Сатучы ханым кереп-чыгып йөргәннәргә игътибар итәргә дә теләми, син ул бала-чаганы сатып алыр өчен керә дип беләсеңме? Каникулның соңгы көннәрендә шәһәр эчендә «кысылып» калганнары зоомагазинны зоопарк итә. Өендә мәче асрарга да курыкканнар өчен күз явын алырлык нәрсәләр бар монда...

Кыз әллә ник ошатмады бу кибетне. Моңарчы кереп күргәне юк иде – эче тулы сагыш икән моның... Әнә кенәриләр сайрый-сайрый саргаешып беткән. Африкадагы кардәшләрен сагынып, тутый кошлар көн ягына баккан. Диңгезен оныткан бәләкәч дуңгызлар чөгендер кимерә. Тимерчыбыктан эшләнгән ялтыравык читлектә сувенир кебек ак тычканнар, баш сыярлык ялгыз ташбака ята... Аквариум дигәннән, кибетнең бер ягына стена итеп, баскычлап өйгәннәр аны. Йөзәрләгән микрокомпрессор ясалма балыклар өчен һава өрдереп тора. Ә бу якта сатылырга дигән буш читлекләр, заводның үзеннән, сыйфат билгесе сугып, калын кәгазьгә төреп пөхтәләп китерелгән. Нидиләре генә

юк – кечкенәсе, зуррагы, тагын да зуррагы, хәтта кеше сыярлыклары да бар! Хәер, бу кибет үзе дә зур пыяла читлеккә охшатып салынган.

– Керпе сатам арзанга гына, – дип башлаган иде егет.

Сатучы ханым балыкларга җим сибеп йөргән җиреннән тукталып калды.

– Апа, ала күрмәгез, зинһар, ул аны урманнан урлап кайтты, – дип, кыз кенәриләрне сайравыннан туктатты.

– Керпе, – дим, – сатам.

– Урман җәнлекләрен товар итәргә рөхсәт кәгазебез юк.

– Күп сорамыйм, арзанга гына...

– Бар әле, баш авырттырып йөрмә, гарык бүген, илле мең үрдәк бәбкәсе саттык.

Кошлар гына сайрашып торырга тиешле кибеттә әйткәләшү ишетеп, чаршау артыннан бер агай ишелеп төште. Өстендәге кара халаты ерткаланган, чәче керпе сыман.

– Кая, нәрсә? Керпеме? Күрсәт, аягы бар микән? – Керпе агайның кулына күчте. – Тәк, әпәйт-тәки корткычлык. Син, малай актыгы, боларның особый исәптә икәнен беләсеңме?! Кызыл Китапның иң беренче битендә алар хәзер. Анда әйтелгән: Даурск керпеләренә кагылырга ярамый, сан ягыннан бик нык кимеделәр, диелгән. Шушы кәгазьгә адресыңны яза тор, хәзер мин сиңа Кызыл Китап алып чыгам. – Һәм агай ашыкмыйча гына чаршау артына кереп чыкты. Аның уенча, егеткә кибеттән чыгып качарга вакыт җитәрлек иде.

– Ә син ник качмыйсың? – диде агай ялгыз калган кызга.

– Сез алдашасыз, – диде кыз, үҗәтлектән усаллыкка күчеп. – Даурск керпесе Биектау урманында яшәми. Аны оясында ятим балалары көтәдер. Бирегез, илтеп куям.

– Менә монысына рәхмәт. Миңа үпкәли күрмә тагын, егетең белән бүлешә алмаганыгыз өчен генә әртисләнүем. Урманга, дим, бүген өлгерерсең микән?

– Өлгерәм, өлгерәм. Көн озын әле.

Керпене кыйгач яулыгына төреп алгач, кыз сөенеченнән әлеге агайга рәхмәт әйтергә дә онытты. «Теге егет минем егетем түгел, мин аны күралмыйм, гомумән, икенче мәктәпкә күчәм әле», – дип тә өстәмәкче иде, ярар, әйтеп тормады инде.

Электр поездына утыргач, кыз баштарак, эче пошып, гел тәрәзәдән як-ягына карангалады, мотоцикл белән кемдер куалый чыгар кебек тоелды аңа. Поезд, кызның күңелен тойгандай, тизлеген арттырды.

Күпме генә эзләсә дә, кыз теге аланны таба алмады. Инде күк гөмбәзе йолдызлар кабынганны көтә. Агач арасында күләгәләр күбәйде – арттан кемдер ияргән, ә алда кемдер сагалап торадыр шикелле. Тирә-як шом белән тулды. Урман эче көнне төн белән алыштырырга әзерләнә иде.

Артык эзләүдән мәгънә юк. Кыз керпене җиргә куеп бераз читкәрәк китеп басты. Ә керпе озак көттермәде, тынлыкның игелеклелегенә ышангач, тиз арада язылып, тирә-юньне үрелеп-үрелеп иснәде дә күз алдыннан юкка чыкты... Аңа әле таң атканчы күп нәрсәләргә өлгерәсе: этиләрен эзләп табасы, җиде баланы имезәсе, куркыныч турында кисәтәсе, тамак туйдырасы һәм, ниһаять, тагын чишмә буена төшәсе бар. Ә иң мөһиме, ояны күчерәсе бар. Ояны күчерәсе, урман төпкеленә, ераккарак.

# ДҮРТЕНЧЕ РАУНД

Кышкы бураннар тырышып-тырышып күперткән купшы кар өемнәре язның беренче яңгырыннан соң ук сулыгып төште. Кыш куенынннан бәреп чыккан гөрләвекләр, көртләрне эретеп, ашыга-ашыга, Киндерле елгасына ташый башлады. Ак таулар җир белән тигезләнгәч, юл читләре бөтенләй киңәйде, урамнар артык җиһазлардан бушаган бүлмә сыман иркенәеп калды.

Елның өч фасылы бергә кушылган чак. Мәктәпкә барам дисәң – иң алдан урамдагы һаваның холкы белән танышасы. Таң атканчы яңгыры да, кары да явып китәргә мөмкин, көтмәгәндә генә шыкырдатып туңдырып та куя. Шуңа күрә чөйләрдә кеше саен ике төрле кием – кышкысы, язгы-көзгесе.

Наилләр яши торган поселок шәһәрдән бер чакрымлап читтә. Совхозның клевер басуын кичеп мәктәпкә барып җиткәнче нибарысы ярты сәгатьләп вакыт җитә. Үләнле сукмак язын да, көзен дә чип-чиста, туфлиең мәктәпкә өйдән чыккан килеш барып керә. Әгәр инде үләнле сукмак нык тапталып лыҗырдый башласа, андый чакларда бераз читтәнрәк яңа сукмак салына, искесенә әкренләп үлән үсә тора. Басуны кайчанга хәтле таптарлар – анысы билгесез, поселокның үзе өчен генә ачылачак мәктәбе һаман салынып бетми бит әле. Аның нигез ташын сала башлаганда Наилне бакчага йөртәләр иде... Инде булачак яңа мәктәпнең канау балчыгына килеп кунган өрәңге бөтерчеге дә, яфрак ярып, Наил хәтле агачка әверелде. Нигә шулай әкрен төзелә икән бу мәктәпләр? Юкса әнә химия заводы поселокка таба йөгерә-йөгерә дигәндәй килә – көне-төне төзиләр тегене.

Басу таптарга теләмәгән малайлар өчен мәктәпкә алып бара торган асфальт юл да бар барын, тик ул бераз әйләнгечтәнрәк шул, ун минут кына дисәң дә вакыт әрәм була. Ә инде дәресләр башланганчы ун минут алданрак килү бик зур нәрсә ул! Ун минут эчендә тактага моңарчы берәү дә ишетмәгән яңа мәзәк язып куярга, өйдә эшләнеп бетмәгән күнегүне күчереп өлгерергә, телевизордан малайлар йоклап беткәч кенә күрсәтелә торган аңлаешсыз кинолар турында бәхәсләшергә, кызлар белән үртәшергә һәм тагын әллә ниләр эшләп өлгерергә була... Менә шуңа күрә дә малайлар гел туры юлдан гына йөри. Чөнки аларның апалары, абыйлары да, хәтта совхоз җитәкчеләре үзләре дә нәкъ шулай иткәннәр... Юкса, малайлар интекмәсеннәр дигәндәй, ишелеп-ишелеп икмәк уңардай басуны көтүлек итеп күпьеллык үлән чәчеп куймаслар иде...

Югарырак класска күчкән саен, вакыт агы кысанлана икән ул. Класстан тыш эшләр, түгәрәкләр белән мавыксаң, Ләйсәннәр сүзенә карап киногa да калсаң, караңгы сукмакка юлыгасыңны, ярты сәгать буе караңгы төн белән күзгә-күз карашып кайтасыңны көт тә тор. Әллә инде маҗаралы китапларны бик яратып укыганга – караңгы төн гел тымызык күл төсле – шомлы да, тылсымлы да. Ә инде япа-ялгызың калсаң, шүрләтә дә сыман.

Төнге юлда күкрәк киереп йөрим дисәң, син үзеңне иң көчле кеше итеп тоярга тиешсең. Ул чагында бөтен кызлар да синең тирәдән китмәс. Көчле малайлар турында сөйләү – аерым бер маҗара. Әйтик, Наилләр классында Ренастан кала бөтенесе дә үзен иң көчле малай дип исәпли. Ренасның мәктәпкә ияреп килә торган кушаматы бар: Җебегән дип үртиләр аны. Класста кушаматсыз малай юк югын: Кырыктартмачы, Шпингалет, Пискәр һәм шуныңише ямьсез кушаматларын санап күрсәтсәләр, әллә мәктәпнең бөтен алама укучыларын гына сайлап шушы – VII класска тутырганнармы дип уйларлыгың бар. Хәер, башкалар класстан класска үсә торгач, элеккеге кушаматлары әдәби геройлар исеме белән алышынса да, Ренасныкы шул килеш калды. Ак чырайлы, ябык, әмма авыр сөякле, кыюсыз булганга, ахрысы, врач бокс секциясенә йөрергә рөхсәт бирмәде аңа. Менә шунда ул көчсезләр исемлегендә калды. Ә көчлеләр – VII классныкылар – барысы да бокс секциясенә йөри.

Малайларны кай ягы белән генә җәлеп итә соң әле бу бокс уены?

Телдән телгә күчеп кыскарса да, бер вакыйга яши. Имеш, моннан берничә еллар элек, поселокның Илгиз атлы малаен шәһәр киносыннан чыгып барганда тәртипсез малайлар туктатканнар. Итле пәрәмәч кебек кабарып торган яңаклысы Илгизнең күкрәгендәге «Ну, погоди!» значогын йолкып алып йодрыгына төйнәгән дә: «Мин I разрядлы боксер, мә кулымнан алып кара!» – дигән. Илгиз аны-моны уйлап тормый: «Мин үзем дә йөгерү буенча мәктәп чемпионы, әйдә, куып җитеп кара», – ди дә значогын калдырып бәла-казадан исән-имин качып котыла. Шуннан соң Илгиз бокс секциясенә йөри башлаган. Аңа иптәшкә дип кенә ике классташы да ияргән. Инде Илгизләрдән сакланырга кирәк дип, башка малайлар да бокска йөриләр. Хәзер мәктәптә физкультура дәресләре гел бокс ярышларына әйләнә. Туп уйнаганда да, кузла аркылы сикерергә тезелсәләр дә, биеклеккә сикерергә кирәксә дә, чаңгылар кигән килеш трассага чыгып баскач та, иң әүвәл хәлдән тайганчы дөмбәсләшеп алалар. Хәтта калынрак бияләй кигән кызлар да бу уенга бик теләп кушыла. Ләйсән генә уенга катышмый, малайлар дөмбәсләшкәнне генә карап йөри. Тегеләренә масаерга шул җитә кала инде. Ләйсән бит ул, Ләйсән! Аның күз карашыннан беренче класста алган икелеләрең өчен дә оялырсың. Ул коридорга чыкса, тәнәфесләр кыскара. Әрсезрәк малайлар, ишек катындагы класстан урамга чыгарга кирәксә дә, ашыгычлык белән генә – VII «А» тирәсеннән бер урап киләләр. Ләйсәнне күрмәбезме дип, янәсе. Шундый һуш китмәле кызның Наилләр классына туры килүе үзе зур горурлык.

Наил иң беренче тапкыр спортклубка килеп кергәндә, җәйге каникулдан соң бер атна чамасы гына укылган иде әле. Бокс бияләе киеп карарга теләүчеләр йөздән артык җыелган икән. Бу хәтле кешегә өйрәткәч, боксның кызыгы бетәр бит дип, баштарак ниятеннән кире чигенергә уйлаган иде дә, тик төнге сукмакларны күз алдына китереп, Илгизнең «Ну, погоди!»ен исенә дә төшергәч, чыдарга булды. Тренерлары (күн йодрыктан тукмалып караган малайлар аңа Асан Саныч дип кенә дәшәләр бугай) кырыгар кешедән өч группа төзеде дә, җиткән кадәренчә бияләйләр өләшеп, кара-каршы бастырды. «Кем ничек булдыра ала, сугышып карагыз», – диде ул, ә үзе сәгатенә караштыргалап читтән генә күзәтеп йөрде, кул сугышы белән мавыгыбрак китүчеләрне аерып фамилияләрен сораштырды. Хәлдән тайганнарының бияләйләрен алып тик торучыларга бирде. Асан Санычның «Җитәр!» дигән сүзе бик сагындырып кына яңгырады. Алҗып егылганнарга да, борыныннан кан китүчеләргә дә эче пошмый бу тренерның. Берни булмагандай бөтенесен үз тирәсенә җыйды да һәркайсының йөзенә туры карарга тырышып, тыныч кына сөйли башлады:

– Берегезне дә командадан куып чыгарырга җыенмыйм, тренировка саен рәтләрегезнең сирәгәясен болай да беләм...

Асан Саныч дөрес әйткән. «Зенит» командасы арифметик вакланма шикелле күзгә күренеп кыскара барды. Беренче күнегүдән үк авыз-борынын җимереп кайткан малайларның күбесен эти-әниләре инде спортклубка якын да җибәрмәделәр. Имеш, хулиганлыкка өйрәткәч, нәмәдәй спорт булсын ди ул... Берике күнегүдән соң туктаучылар да табылды, күн йодрык белән башкаларга кизәнгәндә генә кызык ул, ә үз башыңны тукмый башласалар, бер дә рәхәт түгел икән... Начар укыган өчен исемлектән сызып

ташланучылар да бар. Алгебрадан «3»леләре күбәя башлагач, Наилгә дә кырын карый башлаганнар иде дә, тик тренер аны сызып ташлауга катгый рәвештә каршы чыкты, – чирегенә «4»ле чыкканчы көтәргә түземлегем җитә, диде. Чөнки Наил шартлы төстә генә «А», «Б» дип атап йөртелә торган группаларның беренчесендә, ягъни бик өметлеләр арасында. Ә мондый бәхет Марсельгә дә ел буе дөмбәсләшкәч кенә эләкте, «резерв» группасында шактый йөрттеләр аны.

Мәктәп сукмагын уртага бүлеп аккан Киндерле елгасы янына килеп җиткәч, Наил тимер күпернең аркавына сөялеп ташу акканны күзәтеп торды. Ак күбәләкләр өередәй очып килгән кыш инде елга ярларына сыеша алмыйча ташуланып китеп тә бара. Тургайлар да килеп җиткән – җырлары яңа, тавышлары көр. Тиздән, бик тиздән күпер төбендәге таллыктан былбыл чутылдавы да ишетелер. Аннан, күп тә үтмәс, малайларны су коеныргa өндәп күке хәбәр бирер. Җәйге каникулны да күкеләр алып килә. Ертык болытлар арасыннан кояш нурлары коелды, алар еракта-еракта бер атауга ут төрттеләр бугай – шул ут монда таба агып килә башлады... Күп тә үтмәде, Наил кояш нуры эчендә калды. Ирексездән җәйге озын каникул күз алдына килә.

Быелгы каникулда авылга кайтырга җыена ул. Кайтып, кайчандыр җәйге ялларны бергә үткәргән малай-шалайларга «атаман» булып йөрисе килә. Быел, күкрәгендә III разрядлы спортчы значогы күргәч, башкачарак сөйләшерләр әле аның белән. Юкса шәһәр малае дигән булып бөтенләй санламыйлар иде үзен, бөтен эшләгән эшен-кыланышын мәзәккә әйләндерәләр дә куялар. Ә хәзер кызыгырлар... Алар түгел, өйдәгеләр дә тел шартлаталар әле. Табын янында, назландырмыйчарак кына тирән эчле тәлинкә белән тутырып аш сораган чакларда – Наилнең җилкәсенә әтисенең кулы орыныр: «Маладис безнең семья, – дияр, – мин бишенче разрядлы слесарь, улым өченче разрядлы боксчы!..»

...Наил тимер күпердән аерыла алмый торды. Никтер Ләйсән дә килеп җитми. Әллә артык иртәрәк уяныллы микән? Булыр да, бүген пүчтәк көн түгел – бүген команда беренчелегенә ярыш үткәреләчәк. Әгәр җиңүчеләр исемлегенә эләксәң, шәһәрнең берәр танылганрак командасы белән дусларча очрашуда катнаштырачаклар. Ә бу инде үзеннән-үзе – шәһәр беренчелегенә, зона ярышларына, республика, Бөтенсоюз күләмендә... Европа... Дөнья чемпионатына илтә торган юл!.. Дөрестерме, юкмы, җиңүче кешегә Ләйсән үзенең фотосын бүләк итмәкче, ди. Менә бу приз ичмасам! Шушындый җаваплы көндә, ятланмаган шигырьләр, чишелеп бетмәгән мәсьәләләр өчен дәресләрдә дер калтырап утырырга ярыймы соң?! Бер тапкыр гына мәктәпкә бармый калган өчен әллә нишләтмәсләр әле. Марсель, Ренаслар дәрестә интегеп утырсыннар, ә мин киногa... иртәнге сеанска кереп чыгам. Азрак көч җыярга кирәк, бүген зур җиңүләр көне! Ә җиңүчеләрне хөкем итмиләр.

Әтисе бүләк иткән электрон сәгатькә текәлеп вакытны чамалап үзенчә план коргач, Наил мәктәп юлыннан куаклы сукмакка борылды. Бу сукмак аулактан гына кинотеатрга алып бара иде.

Спортклубка ул бераз алҗыбрак килеп керде. Тик йөрүләр дә арыта икән. Кием алыштырып малайлар арасында чуала башлагач кына тәндәге эленкелек әкренләп югала барды. Ә инде түшәмгә тарттырылган күн грушаны дөмбәсли башлагач, кәеф дигәнең бөтенләй алыштырып куйгандай үзгәрде.

Асан Саныч Наилгә нидер әйтергә җыена. Әләкләп тә өлгерделәр микән үзенә? Әгәр спортклубны мәктәп белән чагыштырырга ярaса – хәзер менә Асан Санычның Наилне читкә чакырып алуын тәртип бозучы укучыны укытучылар бүлмәсенә алып керүгә тиңләп булыр иде. Тренер әти-әниең кебек җайлап-майлап тормады, турысын әйтте:

– Дәрестән качтыңмы?

Наилнең «юк» дип әйтергә көче җитмәде.

– Әйе.

– Команданың уставын хәтерлисеңме?

Мондый эшләр өчен гафу итмиләр – менә шул инде аның уставы! Көне буе җил куып йөргәндә акланырдай сәбәбен дә уйлап куясы калган.

– Бүген аңлата алмыйм, сәбәбен иртәгә әйтермен. Иртәгә хәтле генә гафу итә күрегез...

Иртәгәме? Җиңүче Наилне вак-төяк сораулар белән борчып тормаслар! Әгәр җиңелә... Җиңелсә, ул күн йодрыкларны салыр да Асан Санычка тапшырыр – бөтенләйгә!

– Асан Саныч, мин бүгенге ярышта катнашырга тиеш!..

– Асан Саныч түгел, ә Александр Александрович диләр мине! Бар, рингка әзерлән!

Нинди җилкендергеч урын ул ринг! Скрипка кылларыдай арканнарны аралап керәсең дә калын киез өстенә тарттырылган брезентка килеп басасың. Каршыңда – синең кебек үк җиңүгә өметләнгән тагын берәү. Гонгның саңгырау чыңы гүя сине шул партнерга таба этеп җибәрә. Һәркемнең җиңәсе һәм бары тик җиңәсе генә килә. Ә бер мәйданда ике батыр калмый!

Кайбер көч сынашуларда партнерыңның кемлеге нәтиҗәне ярыш башында ук хәл итә ала. Әйтик, авырлыгы, буе, яше белән тәңгәл килгән Ренас кебегрәк берәрсе эләксә, Наил җиңә дә җиңә инде. Ләкин бүгенге шобага аның каршысына Марсельне китереп бастырды. Күнегү вакытларында шартлы ярышларга күбесенчә үзең теләгән кеше белән чыгасың. Ә Наилнең Марсель белән, ичмасам, ялгышып

та көч сынашканы булмады. Бүген җитди ярыш – шобага сүзе генә сүз! Рингта Марсель белән калу, бәлки, яхшыгадыр – бөтен холкы-гадәте, көче белән таныш малай ла ул. Әгәр башка мәктәп укучысы килеп басса, аның кем икәнен абайлап өлгергәнче үк оттырып куюың бар.

Гонг яңгырады.

Наил ышаныч өчен болельщиклар арасыннан Ләйсәнне эзләп тапты... Ләйсәне дә, шуны гына көтеп торгандай, аягүрә басып фотосын күрсәтеп алган булды. Наил генә түгел, Марсель дә күрде моны.

Мускуллар җәядәй киерелде, йодрыклар ук булып очарга әзер. Аяклар терәү кебек... Күзләр күршенең йодрыкларында гына, аны егарлык итеп сугар өчен көч тә, сулыш та җитәрлек, тик ярсу гына җитенкерәми... Беренче раундта исәп ачылмаса да, әнә шул ярсу дигән хәлиткеч талпыныш уянып калды.

Икенче раундта йодрыклар ешрак кизәнделәр. Наил һөҗүмгә күчте – Марсельне почмакка кысрыклады. Шулчак Марсель икенче яны белән басты, уң ягын алгарак чыгарып сул йодрыгы белән йөзен саклады. Болай итеп сулагайлар гына баса иде. Марсель сулагай түгел лә... Аның бу кыланышы ярсынган Наилнең ачуын чыгарды, хәзер икеләтә саклык белән көрәшергә кирәк, чөнки хәтәр йодрыкның теләсә кайсы кулдан «килеп төшүе» бар.

Наилнең ачуы басылганын көтеп тормады, өченче раунд башланды. Марсель һаман да тыныч күренә, хәтта йөзендә сизелерлек елмаю да чалына, ләкин әллә кай арада гына көч җыеп килгәндәй, һөҗүмен ешайтты әле ул. Аны җиңәр өчен судьяларны, уен барышын гөж килеп күзәтеп торган болельщикларны шаккатырырлык итеп бер сугарга кирәк... Баягы ачу инде хурланулы нәфрәткә әверелде. Наил бөтен нәфрәтен бер йодрыкка туплады, көченең сулкылдап-сулкылдап җыелганы йөзенә үк чыккан иде.

Дөрес, Марсель егылмады, Наил көткәнчә тораташтай катып та калмады, шулай да шактый ук нык сугылды... Әле дә ярый гонг яңгырады, юкса бу мизгел Наилнең бөтен көчен йолкып алган иде инде.

Аннан соң бөтен зал сүзсез калды.

Тынлык хөкем карарын көтә.

Укудан соң беркем дә өенә кайтып китмәгән, ярышны карарга килгән икән. Аларның күз алдында, Ләйсән алдында Наилнең кулын өскә күтәрделәр... Ур-ра кычкырдылар... Бияләйләрне салмыйча гына кул бирештеләр... Калганын Наил хәтерләми... Иптәшләре басу сукмагына сыеша алмыйча әлеге ярышны тикшереп кайттылар – мактадылар, якладылар, бәхәсләштеләр. Наил боларын да хәтерләми. Җиңү рухы аны иптәшләре арасыннан әллә кайларга алып китте сыман... Шау-шу арасыннан ул бер генә тавышны – Ләйсәннең гөрелдәвек тавышын гына сайлап алды, шуны гына тыңлап барды. Әле генә бокс бияләйләрен салган кайнар кулда Ләйсән фотосы.

Наил бүген Марсельне укырга килмәс дип уйлаган иде. Килгән бит...

Әле мәктәп эчендә тавыш-тын сизелми. Итекләрне юарга дип куелган калай тагарактагы су да күл суыдай тонган. Бу тирәдә чиста су бик тәтеми, шуңа күрә Марсель резина итеген сөенә-сөенә юды. Юып бетергәч тә керергә ашыкмады... Наилне көтте ул.

Әлбәттә, Наил мәктәп йозагы ачылганчы ук ишек төбендә басып торасы, сәламләшкән һәр берәүдән кичәге җиңүе өчен мактау сүзләре ишетергә тиешле кеше иде. Өйгә кайткач, бокс ярышын башыннан ахырынача сөйләп мавыгылган, ахрысы – соң ятылган. Әтисе дә ул кичне бик ягымлы иде – «Көндәлегеңне күрсәт», «Телевизорга ябышма!», «Сүз җыеп йөрмә монда, марш бүлмәңә!» дип, көндәге кисәтүләрен ник бер әйтеп карасын.

Соңрак уянуын кайтарырга теләгәндәй, ул йөгерә-йөгерә килде. Килешкә үк тагаракның болганчык суына итекләрен манып алды да Марсельне күрмәмешкә сабышып кына, әле җиргә бер дә басмаган, өр-яңа шыгырдавык кедаларын чыгарды.

– Бүген, – диде Марсель, сәер бер тынычлык белән, – кич күпер төбендә очрашабыз.

– Әллә Ләйсәннең фотосын бирермен дип өметләнәсеңме?

Тик Марсель бу сүзләрне ишетмәде. Коридор ишеге ачылып ябылганда аның ап-ак оекбашлары гына чекерәеп күренеп калдылар.

Наил көләргә дә, уфтанырга да белмәде... Кеданың озын шнуры чуалып интектерә – әллә көтелмәгән тәкъдимнән каушады, әллә ачудан шулай, куркудан түгелдер инде, шәт...

Поселок читендәге калын урман ягыннан сизгер тынлык булып эңгер-меңгер җәелеп килә. Менә ул күпер төбенә кадәр җитте... Җилпәзәк җилләр офыкның әллә кайсы төшеннән генә болытларны актарып чыгарды.

Минутлап-минутлап арта торгач, язгы көннәр шактый озын хәзер. Инде малайлар да мәктәптән кышкы кичләрдәгечә төркем-төркем түгел, ә батыраеп ялгыз-ялгызак кына таралышалар.

Кеше-кара тынганчы, аяк атлаулары басылганчы куаклар эчендә ярыйсы гына көтеп утырырга туры килде Наилгә. Әле дә ярый Ләйсәнне озаткан булып тиз генә өйгә кайтып тамак ялгап өлгергән иде. Белмәссең дөнья хәлен, тукмашырга туры килсә, ач карынга кыенгарак төшәр.

Калай күпердә үкчә тыпырдавы ишетелде. Куак арасыннан үрелеп карагач, Наил капчык күтәргән кеше шәүләсен абайлап алды. Бокс күнегүләрендә «шәүлә белән сугышу» дигән төшенчә бар. Наил дә йодрыкларын йомарлап күпер янына чыгып басты.

– Төнге сәяхәткә чакырдыңмы? – диде Наил, дорфа гына.

– Сугышабыз.

– Хулиганнар шикелле, яңаклашыпмы?! Пожалысты, мин әзер.

– Кагыйдәсенә туры китереп. – Һәм Марсель капчыктагы бокс бияләйләрен күпергә селкеде. – Йә, сайлап ал. Ринг урынына шушы күпер дә ярап торыр. Тик, берәребез ташуга егылып төшсә, коткарыштан булсын.

Шунысы сәер тоелды: Марсельнең тавышында нәфрәт тә, ачу да, хәтта үпкәләү дә сизелми – ул һаман да тыныч.

– Асан Саныч ишетсә, икебезне дә командадан куачак, кәнишне, – диде Наил, бияләйләрне кияргә ашыкмыйча.

– Шүрләсәң, үзеңә кара, кыстамыйм.

– Кем шүрли, минме? Давай, судьяң кайда?!

– Реферимы? Ул монда. – Марсельнең сызгыруына, күпер астыннан калыккандай, Ренас килеп чыкты.

– Алай икән... Унга хәтле саный белсә, шул җитәр дисеңме? Минемчә, Ренасның монда кирәге юк. Иртәгә бөтен каланың шау итүен телисеңме? Сүз урлап йөрмәсен, кайтып китсен. – Наил бу сүзләрне этисе кебегрәк итеп әйтергә тырышты.

Ренас күздән югалгач, тиз генә бияләй кисәләр дә, алар әле нидән башларга белмичә битараф басып тордылар.

– Кичә җиңгәнем генә җитмәгән идеме сиңа? – диде Наил, һаман да татуланырга ниятләп. Һәм, Марсельне тагын бер кат җиңәргә теләгәндәй, кесәсеннән Ләйсән фотосын алып куен дәфтәренә яхшылабрак кыстырган булды. – Күкрәккә бик сукма, бөгәрләнә күрмәсен.

– Син мине җиңәргә тиеш түгел идең... Бокс!!!

Алар раундлап тормадылар, бертоташтан гына сугыштылар. Әйе, аяклар чалып, терсәкләр белән төрткәләшеп, башлар белән бәрешмәсәләр, бу көрәшне бокс дип түгел, бары тик кул сугышы дип кенә атап булыр иде. Чөнки бокстагы иң төгәл, иң мәҗбүри кагыйдә – тәнәфес бозылды. Чиста җиңүгә хәтле түзәргә, ахрысы, исәпләре.

Һәр көрәштә ике якның бәхәсен ачыклардай хәлиткеч бер һөҗүм бар. Әнә шул һөҗүм Марсельнең маңгай читенә килеп бәрелде... Ул ауды да йөзен бәрелүдән сакларга теләп терсәкләренә таянды. Тик күпернең калай идәненә бәрелгән терсәк гәүдә авырлыгына түзә алмады.

Наил Марсельнең җиңелү сүзен гамьсез көтеп торды. Санамады. Унга хәтле санагач та аягына басмаса, нокаут инде анысы – чиста җиңү. Марсельнең җиңелүе – Наилнең тагын бер кат җиңүе. Ләкин Марсель күзләрен йомып хәрәкәтсез калды. Шушылай ятуын санасаң, биш тапкыр «ун» булыр иде инде. Димәк, бу егылу юньлегә түгел...

– Тор әле, Марсель... Үзең уйлап чыгардың бит.

– Барыбер җиңәргә тиеш түгел идең син мине...

Малайның сүзләреннән соң Наил җиңел сулап куйды.

– Тор инде, кеше күрүе бар. – Иңбашыннан тотып аягына басарга ярдәм итмәкче иде – бияләйләре комачаулады. – Шушы күн йодрыкларны җенем сөйми.

– Буыным тайпылмаганмы, кулны кисәк кенә тартып кара әле?

Тартуын тартты Наил, тик соңыннан үзе дә үкенде, хәтәр авырттырды бугай – ыңгырашып өлгермәсә дә, малайның күзләреннән яшь атылып чыкты. Бәрелгән-сынган саен кулны шулай йолыккалап кына төзәтерләр иде ул...

Алар әкрен генә атладылар. Капчыкны Наил үз иңенә алды. Сөйләшәсе килә, тик үч иткәндәй, юньле сүзе генә табылмый.

– Ләйсәнне сагынмадыңмы? Мә, фотосына күз сал. Бәлки, сызлавың онытылыр.

– Кирәкми. Син боксны кызлар өчен сугышу дип кенә аңлама. Бокс ул – спорт. Сәнгать тә әле ул, бик беләсең килсә.

– Марсель, ә бит нокауттан соң өч ай ял итмичә ярышларга катнаштырмыйлар.

– Авыртуына караганда болай да өч айсыз бияләй киеп булмас әле... Ә шулай да син мине җиңәргә тиеш түгел идең! Табигать биргән көч кенә бит синдә. Ә мин көчне үзем җыям, җиңәрлек итеп җыячакмын.

Бәлки, Наил бу сүзләрнең мәгънәсен тиешенчә аңлап та җиткермәс иде әле, шарты килде. «Улларын кыйнаган өчен кирәкне бирмәсләрме?» дигән уй сагайтса да, Марсельләрнең ишек төбенә кадәр килеп җиткәч кермичә булдыра алмады ул.

Өйдәгеләре Марсельнең кәефен бик тиз сизенделәр. Әнисе шундук әти кешене чакырып китерде. Аның бияләйдәй күпертмә таза кулларын, мускуллары бүлтәеп торган беләкләрен, мәктәп ишегедәй

киң җилкәсен күреп Наил бөтенләй шиңеп төште, гәүдәсенә каз тәне чыкты. Менә курку дигәнең кайда сагалап торган икән.

– Әллә җимереп кайтардылармы?.. Спорт ул сиңа уен-муен гына түгел, спорт – эш ул, бик беләсең килсә...

– Кулны авырттырдым, – диде Марсель, искитәрлек берни дә булмагандай.

Бер класста укысалар да, Наилнең бу йортка бик күптәннән бирле кергәне юк иде. Өч бүлмәнең берсе Марсельнеке икән – шаккатырлык хәл – бөтен җирдә спорт кирәк-яраклары. Кыл уртада – идәннән түшәмгә кадәр тарттырылган арканда «груша», шунда ук пружиналы штативка беркетелгән туп, герләр дә шактый гына. Монда карават куярлык урын да калмаган.

– Ә мин идәндә йоклыйм, гәүдәгә файдасы тия, – диде Марсель, классташы алдында акланырга теләгәндәй.

Шулчак Наил стенага текәлеп катып калды. Почет грамотасы белән янәшәдә үк Ләйсән фотосы иде – нәкъ Наилдәге кебек үк!

– Бусы кем рәсеме, этиеңә дә охшамаган?! – диде Наил, карашын көч-хәл белән генә башка фотога күчереп.

Марсельнең шаркылдап көләргә исәбе бар иде дә, тик дусты үпкәләр дип кенә тыелып калды.

– Борис Лагутин ул! Ике тапкыр Дөнья чемпионы исемен яулаган боксер!

– Боксер... Боксерлар... Немецларда этләрнең бер төре...

Ләкин бу сүзләрдән мәзәк килеп чыкмады.

Марсель урыны буш иде. Терсәген күрсәтергә барган җирдән аны больницага алып калганнар икән. Ә инде аның терсәк буыны чатнаган дигән хәбәрне дә ишеткәч, Наилнең ике терсәге берьюлы сулкылдап куйды: күпер төбендә кулын тарткалап «дәвалап» та маташкан идек, ичмасам, ничек түзде икән ул?!

Уку елын гипсланган кул белән тәмамласа да, Марсель үзен кызганып юатырга маташучыларны бер дә яратмады. Физкультура дәресләреннән азат ителгән килеш тә классташлары арасында чуалды: сул кулында герләр уйнатты, сикерү-йөгерү кебек күнегүләрдән дә курыкмады. Иптәшләре дә әкренләп аның кул авыртуына ияләнә бардылар, уеннарга катнаштырдылар, күмәкләшеп шаярыштылар.

Сентябрь күптән өмет иткән зур яңалык белән килде. Поселокның үзендә теге, әллә кайчаннан бирле төзелә башлаган мәктәп, ниһаять, беренче уку көненә җилпенгән саен хуш ис бөркеп торган нарат такталы ишекләрен ачты.

Мәктәп янда гына булгач, малайлар бөтенләй рәхәткә чыкты: йокыны да күбрәк йоклыйлар хәзер, дәресләрдән соң да караңгыга калабыз дип ашыкмыйлар – мәктәп ишегеннән өй ишегенә биш кенә атлыйсы.

Шәһәр мәктәбенә илтә торган болын сукмагы җәй буе ял итә. Ләкин сукмак бөтенләй үк югалмас югалуын. Әнә Марсель бокс секциясенә китте. Күр әле, аңа Ренас та ияргән түгелме, әйе шул, Ренас! Ашыгалар. Күнегүләр дәрес бетүгә башлана шул. Наилләр кая соң? Ә-ә... Кемдер, бүген урманга керпе тотарга китәбез, дигән иде, шунда йөгергәннәрдер әле...

# ТИМЕРГАЛИ БАБАЙ ХИКӘЯТЕ

...Дугасына сөлге уралган кыңгыраулы ат чабып үтте. Йорт бүрәнәләренә тальян моңы сеңеп калды. Тәрәзәне яртылаш кына ачып, мәйданга алып төшә торган тыкрыкка карадым: колгада сабантуй эләме – чүпләмле сөлге җилферди.

Чормадан юкә исләре аңкып торган чабата алып төштем, бәрхет түбәтәемне чистарттым. Яратып кигән кием тиз туза шул ул – ак киндер күлмәгемнең чигүле якасына ямау салырга туры килде. Алыштырыр идем, монысы да әле абыемныкы гына. Борыны китек чәйнектән ел буе җыйган акчаларымны алып, суккан ыштанымның ямаулы кесәсенә салдым. Ыштан тагын да авырайды. Икенче кесәмдә – кульяулыкка төрелгән түгәрәк көзге. Бар да әзер.

Көн яктырарак янә колгага күзем төште: сөлге урынында! Йөгерәм Әсәтләргә.

Әсәтнең миннән артык киенмәслеген беләм, шуңа да гел бергә йөрибез.

– Тимер, дим, Тимер, Шакир белән Мөхәммәтне дә үзебезгә иярткбезме? Кичәдән бирле теңкәмне корыталар, сезнең белән күңеллерәк, диләр.

– Кирәкми, Әсәт, үземнән дә күбрәк сөйләшкән кешене яратмыйм. Ә Мөхәммәтнең киреләнә торган гадәте бар – бер кәҗәләнсә, мөгезе сынганчы тартсаң да кыймылдамас. Аннары, ни бит... аларның өс-башлары да шәһәрчә, берсе – мәзин каргасы, икенчесе – мулла мәчесе.

Узган ел чикләвекле ел иде. Сабантуйда безгә эш күп булыр инде.

Әсәтләрнең капкасын ябып та өлгермәдем, каршыбызга Зәйтүнә апа килеп басты. (Унҗиде яшь тулган кызлар бигрәк тә сылу булалар икән, безнең кызларга да кайчан унҗиде тулыр! Их, өч ел бар шул әле!)

Дәшмәсә дә ни әйтергә теләгәнен беләбез: шушы чикләвекләр белән чигүле кулъяулыгымны Хәбибрахманга тапшырыгыз әле, димәкче була. Кесәләребезгә дә чикләвек тутыргач, ничек ризалашмыйсың ди. Хәбибрахман абыйның да күлмәклек атласын Зәйтүнә апага алып килеп тапшырсак, тагын бер олы мәшәкатебез кими. Чикләвек яра-яра йөгерәбез, сабантуй көнне без чикләвек кенә ашыйбыз.

Кояштан алда уянган булсак та, уеннар башланганчы чак өлгердек. Безнең мәйданның шунысы җайлы – яшьләр үзәндә бәйрәм итә, ә яше тулып узганнар кашлакка утырышып түбәндәгеләрне күзәтә. Без – түбәндә...

Шәһәр байлары гына кия торган күн итек эленгән багана янында тукталдык. Халык югары карап авызы белән йолдыз тота. Шәрәфи малае күн итекләргә кулын тидерәм дигәндә генә кире шуды. Баганасы да шома шул – староста Гыймади пеләшемени, ялт-йолт итеп тора. Без басып торган арада, тагын өч егет ыштаннары белән багананың сабынын сөртеп төштеләр. «Ачык авызлар» төркемен ике кешегә киметеп, китеп бардык.

Берсенең мәтәлүен генә көттем дә бүрәнәгә менеп атландым. Кулымда – ярты пот чамасы печән тутырылган капчык, алдымда – Мөхәммәт. Шундый итеп селтәндем үзенә, теге бәрәңге капчыгы кебек авып төште. Ауды, тик аякларын ычкындырмый, шәп ябышкан, мулла нәселе шул, тагын бер-икене өстәгәч кенә каршымда урын бушап калды. Ул урынга Әсәт менеп атланды... Мин капчыгым өстенә барып төштем. Читкәрәк чыгып аңлатып бирде: Мөхәммәтне сугып төшергәнемне яратмаган икән. Быел тагын өерләре белән безне сагалап йөрерләр инде, ди. Һәй, без бит әле инеш балыклары, кулдан шуып чыга беләбез.

Кесәдән көзгене алып, артка карамыйча гына кашлактагыларны айкыйбыз. Көзгедә Шәмсенурның шәүләсе күренде. Бер ягында әнисе, икенче ягында әтисе. Көрәш башлангач әтисе мәйданга төшәр дә бит, тик менә көрәш тизрәк башланса иде.

Ахрысы, Әсәт тә Мәрфугасын эзләп тапты – көзгесе бер урында хәрәкәтсез калды.

Мәйдан тирәли бераз йөреп килергә булдык.

Һәр гармунчыны биергә теләүчеләр камап алган. Без биеп тормабыз инде, вакыт та юк, күреп өлгерәсе нәрсәләр дә күп.

Карт өянкеләрне сыйпап су буенда йөри идек, кинәт Әсәт җиңемнән тартты, туктарга ымлады. Алдыбызда бер кызык хәл иде. Теге мәзин каргасы – Шакир, Мәрфуганы читән буа өстендә тотып алган да, ялынып-ялынып ислемай бүләк итеп маташа. Мәрфуганың ычкынасы килә, тегесе җибәрми. Безне күргәч, Шакир хурлыгыннан ислемаен ташка бәреп ватты... Әсәт белән Мәрфуга инешнең икенче ягына чыгып киттеләр. Шакир халык арасына йөгерде. Мин алар киткәнне генә көтеп тордым да таш тирәсендәге ислемайлы балчыкны акчалардан бушаган кесәмә тутырдым.

Малайлар көрәшкәндә катнаша алмыйм: «кытыклыйм» дигән сүздән дә кытыгым килә. Берәрсе сөлге белән урап тотып алса – һе-һе-һе!

Кашлакка менеп, Шәмсенурны эзләп табыйм әле, ул монда йөридер, бәлки, ә югарыдан бар да яхшы күренә...

Халык таралыша башлады. Ел буе көткән сабантуй үтте дә китте. Күңелле минутлар тиз үтә шул. Инеш тә бит сай урында ничек тиз ага, ә тирән урында киресенчә...

Шәмсенур да кайтыр юлга чыга. Рөхсәт итсә, мин аны өенә кадәр озатып куйыйм әле.

* * *

– Тимергали бабай, сезнең йорт бу якта түгел бит! – дигән тавыш ишетәм.

Сары Кәрим малае Әхмәтша бу. Бабай дип дәшеп, тәмам зиһенемне чуалтты. Ул арада Шәмсенур да ераклашты...

# ТАЛЛАР КИЧЕРЕР МИКӘН?..

*(Юлъязма)*

Киткән чакта, мин үсеп кайтыр өчен китәм, дип, авылдашлар алдында сүз биргән идем. Ә үзем шәһәр туфрагына җайлашып киләм. Яшьтәшләр авылда.

Соңгы ун ел эчендә мин барып күргән авылларның бөтенесен бергә җыйнап Иделебез тирәсенә тезсәң, Казан кадәрле бер кала үсеп чыгар иде. Калада йортлар да, урамнар да төрлечә: охшашлар, үзгәләр. Шул каланың бер урамы Шәле... Шәлегә кайтып барышым.

**I**

Сәфәр чираттан башлана. Чират – инеш буе. Авылга кайтучылар күп. Бер уйласаң, ялга каршы көн дә түгел. Кояш та кыздырмый, чәчәкләр дә инде тамырдан төште. Мишә ярының мич башыдай җылы «Шәвәли комлыгы» да бәс белән капланды.

Кассадан алган кечкенә генә кәгазь кисәгенә куана-куана перронга чыктым. Резина иреннәрен турсайтып, ишек ябылды. Ябылды бит тәки! Димәк, кузгалабыз! Иркен, яңа юлга чыккач, автобус тизлеген арттырды. Әллә бара торгач урыннары ипләнде, әллә алгы тәрәзәдән Шәле наратлары күренә башлаганга, пассажирларның теле ачылды:

– Карале, Җәмилә, каладагы улың нихәл соң, тәүфыйклы гынамы?

– Мулла кебек!

– И-и, шулай ук нык эчәмени?!

– Китсәнә, грамм да эчми, Аллага шөкер. Әле менә үземне үгетлиләр. Улым әйтә, тотам да кайтам и алып китәм сине, машинага төяп, ди. Мин әйтәм, мине алмага кайтсаң, зур машина белән кайт – авылыбыз сыярлык булсын, дим. Җәннәттәй Шәлене ташлап таш арасына барып кирәргә диванамыни мин!

Алдагы рәттә җитмеш ике яшьлек Нурания әби белән күршесе Хәдичә:

– Суң, Хәдичә, калага барганым юкка бишбылтыр ич инде... Менә шул, машинадан төшкәч сорыйм берәүдән, кызым, дим, икенче Гурки поселогына ничек барасы? Бәхетемә күрә, миһербанлы кеше булып чыкты. Менә, әби, утыз икенче, утыз сигезенче автобусларга утырырга кирәк, ди. Мин әйтәм, кызым, икесенә дә берьюлымы, дим. Кызым рәхәтләнеп көлеп алды да, утыз сигезенчесенә генә утырыгыз, әнә туктый торган җирләре, ди. Тукталышта ярты көн буе басып тордым. Берзаман ни күрәм, теге кызым яныма килеп баскан, әби, ник шул гомердән тикле басып торасыз, автобуска утырмыйсыз? ди. Утыз сигезенчегә генә утырырга куштың ич, менә утыз җиде автобусны үткәреп җибәрдем инде, киләсесенә утырам, дим. И көлде кызым, и көлде. Гурки ягында тора икән үзе дә, бергә кайттык. Укый белмәгәч, һәр адымыңны сорап басмасаң, адашасыңны бел дә тор. Тәсбих тарта торгач, санарга өйрәндек, ә яңалифне өйрәнеп булмады шул.

Автобуста күбрәк картлар икән, шаккатмагыз, яшьләр эштә ләбаса. Казаннан Шәлегә дүрт тапкыр автобус килгәч, кем дә булса утырып йөрергә тиештер бит инде.

Шәледә көзге ямансулык юк. Авылны уратып алган нарат урманы аша көзнең сары төсе үтеп керә алмый. Шулай да күчмә кошларга ияреп җәй китә бугай. «Норма» кашлагына казлар тезелгән – шушы кашлактан гына күтәрелеп, кыр казлары төркеменә иярмәкчеләр, ахрысы.

Колхозда урып-җыюлар төгәлләнгәч киеренкелекнең сүрелгән чагы. Һәркем кышка әзерләнә, үз хуҗалыгы тирәсендә кайнаша. Урманнан дыңгычлап нарат ылысы төялгән сарбалар* кәрваны килеп чыкты. Нигез ипләсәң дә, баз авызына тутырсаң да, мич кабызып җибәрим дисәң дә, ылыс гел кул астында булсын.

Анда-санда балта кайраган тавышлар ишетелә. Шәледә һәр ир кеше – балта остасы. Ә Мөхәммәт абый кебекләрнең гаиләсендә бишәр-алтышар малай. Балта остасының йорт салып карыйсы килми димени?! Мавыга торгач, Шәледә тугыз йөздән артык йорт салынган. Шуның өстенә әле икешәр катлы ике мәктәп, утыз алты койкалы больница, административ үзәк, алты кибет, терлекчеләр бинасы, ике дистәләп терлек фермасы һәм башкалар. Төзүчеләр бригадасының җитәкчесе инженер-төзүче Харис минем яшьтәш. Авылның бүгенгесе минем яшьтәшләр кулында.

Егет булган өйдә чүлмәк утыртсалар, кызлы өйдә сандык малы әзерлиләр. Коры сыра өлгертү – туй хәстәрлегенең башы. Сосласыннан авыз итәм дисәң, башкода бул. Шәледә өйләнешү дигән нәрсә еш кына «кыз урлау» сүзе белән алышына. Авылга кунакка дип кайткан купшы шәһәр кызлары, юкка гына куркасыз, кем урласын сезне?! Әгәр берәр кызны урлаганнар икән, димәк, ул Шәледә туып үскән, җәйләүләрдә җыр җырлаган, «Түгәрәк каенлык» җиләгедәй кызарып пешкән, «Кояшка каршы чишмә»дән су эчеп сафлык алган. Димәк, ул егетнең армиядән кайтуын сагынып көтеп торган, әнисеннән рөхсәт сорагач: «Үз теләгең белән барсаң, кызың кияүгә ябышып чыкты, диярләр, берүк йөземә кызыллык китермә», – дигән җавап ишеткән. Шуннан соң толып табылган, кыз белән егетне сөйләшенгән урында тарантас йә түрле чана көтеп торган. Иртәгесен чишмәләрдә чиләк тулган арада, колактан-колакка хәбәр таралыр: «Галимәнең Наиләсен урлаганнар». «Урлаганнар». Кызыл туйлар үткәч, килен төшкән өйдә бизәкле сандык ачылыр. Ул сандыктан берөзлексез чигүле кашагалар, зур-зур чәчәкләр чигелгән чаршаулар, тәрәзә пәрдәләре, көзге өслекләре, стена бизәкләре чыга торыр. Килен төшкән өй эче чәчәк атар. Тора-бара матчадагы чөйгә сиртмә эленер, ә сиртмәдә талдан үрелгән тирән бишек тирбәлер. Бишектә Шәленең биш меңенче кешесе аваз бирер...

Ә шулай да бер атның юлына аркылы төшкән идем. Толып эчендәге кыз ярдәм сорап кычкыргач, йөрәгем түзмәде. Тавышы да таныш: толыпны ачып җибәрсәм, бергә укыган кыз – Зөлфия. Ул арада дус-ишләрем дә килеп җитте. Зөлфияне арбадан йолкып алдык... Хәер, соңыннан барыбер кавыштылар үзләре. Мин генә менә шул көннән бирле алар өчен чит кеше булып калдым.

...Без өйләнгәч, төн кыскарды, дигәннәр җәй көне өйләнүчеләр. Ә Шәледә көз. Яше җиткәннәр туйга әзерләнә. Яше җитәр-җитмәс кызлар Сәфәри чүннигендә чикләвек җыя. Базда бәрәңге, келәттә икмәк. Җил тегермәне эчендә мотор гөрелтесе...

## II

Мин атлый торган поши сукмагы урман авызында юк булды. Каршымда – ак җирлектә агач авыл, минем генә түгел, тагын биш меңгә якын кешенең туган авылы.

Агач чанасын җитәкләп Низам килә.

– Исәнмесез!

– Исән чакка туры килдең.

– Ник як-ягыңа каранып алдың?

– ...сез дисең ич. Әллә тагын берәрсе миңа ияргәнме дип торам.

– Кичкырын урманда нишләмәкче буласың? Орешкино аркылы гына җәяүләп калага китеп барышың түгелдер ич?

– Безгә калган ди тагы калага җәяү йөрү, күршегә керер өчен дә матайга атланабыз хәзер. Минем делянка егучылар янына барышым. Кәҗә-сарыкларга кимертергә нарат ботаклары алып чыгасые.

– Караңгы төшеп килә, курыкмыйсыңмы?

– Че! Кеше куркытырлык нәрсә бар соң инде хәзер урманда?.. Син Шәленекеме соң? Кем малае дип әйтим икән?..

– Әдһәмнеке.

– Кайсы?

– Корыч!

– Ә, Корыч малае дигәч, исемә төштең. Танырлыгың калмаган. Авылда кигән тиреңне салгансың. Город город инде ул. Анда килеп кергәч, безнең чирләшкә сарык тиресе дә затлы тунга әйләнгән, ди. Ә көтүче малаеның министр буласын көт тә тор.

– Әти көтү көтмәгән лә.

– Ат духтыры гынае инде... Ярый, караңгыга калам бугай.

Ничек танымас итте соң әле ул мине? Кушаматымны сорап торган була. Шәле белән аймыл булган ун ел эчендә нәрсәм үзгәрде икән? Өстемдәге чүпрәкләремме? Мин бит инде калада сырган чалбар, киез итек, биленә эзәр будырып бушлат, колакчынын артка каерып бәйләп күн бүрек киеп йөри алмам. Әле дә инде монда кайткач, хәлемнән килгәнчә, авыл агайлары сыманрак киенергә тырышам. Югыйсә авыл бөтенләй үги итәр. Шулай бервакыт силос курганы өючеләр янына килдем. Әбәткә утырган чаклары. Курган төбәсенә менеп утырган да дистәгә якын ир-ат акыл сата. Сиздермичә генә алар янына күтәреләм.

– Гәҗитәгә наруш үзем өчен генә язылам; радиобыз ябылмый, боргычы да кителеп төшкән; телевизорга да күз-колак, каршысында йокыга китсәм китәм, программалары бетмичә сүндермим.

– Шуннан?

– Никтер бер генә хатын-кыз да министрлар постына сайланмаган.

– Нишләп икән?

– Белсәм әйтерием.

– Ә мин беләм, хатын-кыз ул ирләргә караганда да катлаулы, ягъни катлаулырак маймылдан азынган. Ну...

Агайның фикере шушы җирдә өзелеп калды. Мине, шәһәрчә киенгән авыл малаен күргәч, җеп очын бөтенләй башкача төенләде:

– Шаккатырлык берние дә юк: минем хатын күп сөйләшә. Күршегә кереп китсә дә икешәр сәгатьсез әйләнеп чыга белми. Әгәр дә мәгәр йомыш белән күрше дәүләтләрнең берсенә җибәрә калсаң... ел буе көтәрсең үзен.

Икенче кайтуымда тракторга җигелгән чанага очрадым. Туктале, дим, кая бара икән, мине дә алып китсен. Бара торгач, Питрәч юлы өстендәге торфлыкка килеп чыктык. Өстемдә сырган телогрейка, арзанлы чалбар, башта малахай бүрек, кулда йон бияләй, аякта олтанлы итек. Җитмәсә, трактор чанасындагы торф тузаны да ягылган иде. Учак тирәсенә тезелгән агайларның урталарына ук килеп утырдым. Ә алар мине сизмәделәр дә.

Низам танымады. Мин аларны миллионлы кала халкы арасына килеп керсәләр дә эзләп табам, таныйм, сәламнәремне әманәт итеп җибәрәм.

Күк йөзе – юылган тәрәзә. Шул тәрәзәгә кунган кар бөртекләре төсле йолдызлар кабынды. Җилләр нарат урманында адашып калган. Яңа ай нурыннан йолдызлар яктырып китте. Җирдә ак шәүләләр хәрәкәтләнә. Төнге тынлык якынлашыр алдыннан авылда ыгы-зыгы.

Әгәр яшьләр Культура йортыннан зур-зур төркемнәр булып таралса – ияр дә кит берсенә. «Икәмән очындагы Мәһирә апай итек бастырырга киткән», «Әпри Сажидәсен кызлар үгетләгәннәр...». Егетләр сайлана: «Кич утыру» булгач, күңеллерәгенә барыйк, әйдәгез, лутчы Татцикка, анда «Бер-ике-өч!»не күбрәк уйныйлар, шул хәйлә белән матур-матур кызларын кинәнәбез үбеп». Кызлар турында сүз кузгалса, никтер «Татцик» сүзе алгарак чыга шул. Бәлки, Рәшидә, Зөлфирә, Минзифа, Шәйдәләре кияүгә чыккач, алай булмас әле.

Урам ягыннан тәрәзә саен бала-чага ябырылган. Аларны тыйган кеше юк, йөрсеннәр, күрсеннәр әйдә, барыбер гармун тавышы тирә-юньгә йокы бирми. Өй эчендәге абый-апалар да заманында тәрәзә артыннан гына карап йөрүчеләр иде. Хәзер әнә ничек өлгереп пешкәннәр, өзелеп төшәргә генә торалар.

Ә өй эчендә бәйрәм! Стена тирәли икегә бүленеп утырган егетләр һәм кызлар такмак әйтешеп «кич утыру»ны башлап җибәрәләр. Кызлар – хуҗалар, ни дисәң дә, оештыручылар инде.

Алдыр ыштан балагы,
Гөлдер ыштан балагы.
Кыз күзләргә килгән булган
Ике дистә салагы.

Егетләр дә мескен түгел:

Тупыл-таллар да агач,
Эт миләше дә агач.
Нихәл итик, карт көнегез
Салагаларга калгач...

Такмакларның барысын да язып тормыйк, тыңлыйсы килгән кеше кич утырырга үзе килсен.

Идән уртасына буш шешә тәгәрәп чыкты. Әйдә, Ислам, әйләндереп җибәр, әнә Сәлимәнең күзләре синдә генә. Әйләндер шешәне, бөкесе Сәлимәгә төбәп туктап калсын. Аннан соң икегезне урамга куып чыгарырлар. Анда салкын, караңгы. Туңасыңмы, дип башларсың сүзеңне, яме! Кәбир абый да әнә шулай дип башлаган икән... Хәзер Рабига апаң белән бер дистә бала үстерәләр.

Шешә тәгәрәттек, йөзек салдык, барыбыз да күгәрчен ашаттык. Хәзер күз бәйләш уйныйбыз. Менә яулык, бәйлә күзеңне. Тукта, таң әтәче кычкырды түгелме? Һай, хәерсезләр, егетләр тагын сәгатьне кирегә борып куйганнар. Нинди таң әтәче кичке унда кычкырсын ди юкса!

Җыр, уен-көлке урамга таралгач, өй эче бушап калды.

Ах, шушы тулган айга пәрдә корып куясы иде. Йокыга китәргә ирек бирми Сәлимәгә. Ике бит алмасы кызыша. Әллә искә алалармы? Ай нурына өстәл лампасының сабыр яктысы кушылды. Тәрәзә артындагы караңгылык куергандай булды. Тынлык. Сәлимә. Кыш. Салкын бушлыкта этләр өрүе. (Моннан ун еллар элек туздырылган ферманың тавык-үрдәкләрен эзләп төлкеләр авылга килә. Этләр шуларга өрә.) Ничек җиңәргә шушы бушлыкны? Сәлимә кулында киергегә тарттырылган ак түгәрәк яктырды. Исламның күзләре зәңгәр икән ләбаса... Ак сатинда зәңгәр җепләрдән пар кыңгырау чәчәк атты...

Тамагы карлыкканчы кычкырмаса, әтәч буламыни ул? Мең әтәч авазына Шәледә таң ата. Таң яктысында караңгылык эреп, биш мең тәрәзәдән көн яктысы килеп кергәч, берәм-берәм капкалар ачыла. Эш кешесе ашыга.

Төркемнең бер өлеше мәчеткә ашыга. Шәле мәчете ике сменада эшли. Иртәнге җидедән өчкә кадәр бер смена, өчтән төнге унбергә тикле икенчесе. Мәчетнең мөгаллимәләре дә, шәкертләре дә хатын-кызлар. Әйтергә кирәк, Шәленең мулла-мәзиннәре мәчеттән уңмады. Алтмышынчы еллар башында ук инде анда интернат-мәктәп укучылары яшәде. Хәзер «Кызыл көн» берләшмәсенең тегү цехы. Мәчет эчендә йөздән артык хатын-кыз. Хатын-кызга мәчеткә керү дин буенча тыела, диләр. Шәленекеләр алладан-фәләннән сорап тормадылар шул, керделәр дә тулдылар. Шунысы хикмәт: кызлар бер тирәдәрәк булгач, егетләрне авылдан куып та җибәреп булмый хәзер.

Ашыгучыларның меңнән артыгы мәктәпкә. Трамвай-троллейбуслар юк бит, дәресләргә өлгерим дисәң, өч чакрымлы авылны үтү өчен ярты сәгать алдан кузгалырга кирәк. Бүген февральнең беренче шимбәсе – мәктәп карлыгачларының очрашу көне. Кемнәр килер икән? Әгәр Шәле мәктәбен тәмамлаган барлык кеше бергә җыела алса?! Әле дә ярый җыелмыйлар, очрашу кичәсе ике йөз кешелек залда гына үткәрелә. Ә нигә җыелмыйлар? Залда урын җитмәсә, Культура йорты бар, анда кысан дисәң, урам иркен.

Бу мәктәпне без дә тәмамладык. Чыгарылыш кичәсеннән соң класс җитәкчебез Сәкинә Мөхәмммәтовна һәрберебезгә характеристика таратып чыкты. Бу белешмәдә һәр Шәле кешесенә хас уртак сыйфатлар әйтелгән иде: хәрәкәтчән, көчле, принципиаль, кызу канлы, хезмәт сөючән. Раслау өчен Сәкинә апамның имзасы өстенә мәктәпнең түгәрәк мөһере дә сугылган. Сәкинә апа безне соңгы кат урамга кадәр озата чыкты. Саубуллашып, таралышып та өлгермәдек, укытучыбызның тавышын ишеттек:

– Туктагыз!

Тукталдык, яңадан җыелдык.

– Бөтенегез дә мондамы? Тагын бер кат карыймчы үзегезгә.

– Фатих күренми.

– Фатих!

– Фа-тих!..

Хушлашып та өлгермәдек, ә инде беребез юк. Кайда ул? Нишли? Ник югалды? Мең-мең сорау тагы. Мәктәпне моннан егерме-утыз еллар элек тәмамлаучылардан кемне көтәргә?

Агач авыл көн агышына кушылды. Биш мең тәрәзәдә кояш яктысы. Мәхәлләдә кызлар җыры...

**III**

Мин – кеше, язны яратам. Ә язлар Шәледән башлана. Язның иң-иң беренче тамчысы мондагы мең түбәнең берсеннән өзелеп төшәдер. Кар астында гөрләвекләр челтер-челтер. Бу гөрләвек иң беренчесе, беренче булып инешкә килеп төшәр. Баш өстендә төсле болытлар кар белән яңгырны бергә бутаган. Болытларны пыр туздырып кояш килеп чыкты. Барлык җан иясе, көн җылысына күмелеп, нурга сыена. Яз башланды!

Юл башымда кояш.

Бу кайтуымда мин үзем генә түгел. Бер-беребезне шактый күптән белсәк тә, туган авылымның исеме, асылда, аны кызыксындырмый иде. Кайтып төшкәч, хәл үзгәрде:

– «Шәле» ни дигән сүз ул?

– Миңа калса, бу әлегә шартлы исем генә, башка авыллар белән бутамас өчен.

– Кеше исемнәре дә тиктомалдан гына куелмый. Шәле – поселок хәтле авыл.

– Авылдашларның өлкәнрәкләреннән дә, шәһәрдәге белгечләрдән дә сораганым бар. Күбесе «шәл бәйләү» сүзенә кайтарып калдыра, чөнки Шәледә мамык кәҗәсе асрап шәл бәйләүчеләр шактый. Кемгәдер ул шаяру сүзеннән килеп чыккандыр төсле. Шәле, ягъни русчалап әйткәндә, Шали – «шальной народ».

Шәледә яз.

Җигүле атларны өркетеп, «Кировец» тракторы үтеп китте. Тояклардан тишкәләнгән чана эзен баһадир көпчәкләр тигезләде.

Авыл халкы, кояш эреткәнче дип, туры түбәләрдән кар төшерә, өй тирәсендә адашып туктап калган гөрләвекләргә юл ачып бирә. «Мәдрәсә бакчасы»ндагы тупыл-таллар сусылланып кулга-кул тотышканнар.

Һәр чор үз агачын утырта. Ә менә авыл уртасында инеш тирәли тезелгән таллар – безнең яшьтәшләр. Аларга утыз яшь чамасы: гәүдәгә таза, тамырга нык, баш очлары – болыт. Яшьрәк чакларында аларга кошлар биектән генә карап үтәләр иде. Хәзер исә ныграк ботак саен карга оясы. Инеш тирәсендәге таллар – каргалар каласының олы урамы.

Кичен каргалар тавышы тынгач, «Мәдрәсә бакчасы»на яшьләр җыела. Кояш яшьләрне артыграк ярата бугай, иң беренче булып шушы аланны кардан арындыра ул. Кайда ничектер, Шәледә кичке уенга чыгуны «авыл артына чыгу» дип атыйлар: аулакка, олылар күзеннән читкәрәк ягъни. Уенга иң элек кызлар җыела. Онытканчы әйтим әле, кызлар бик күп Шәледә. Һәр кыз – яңа исем! Балта күтәреп күрше авылларга йорт салырга киткән ирләр, гадәт буларак, яңа матур исемнәр дә ишетеп кайталар. Кемнең соң инде үз кызына яңа, кабатланмаган исем кушасы килми?!

Кызлар җыелып бетүгә, уенга гармун күтәреп егетләр килеп кушыла. Шәле гармунчылары ялындыра белми, ник дисәң, монда һәр егет гармунчы. Гармунда уйнарга өйрәнмичә торып, кыз күзләргә чыкмый чын Шәле егете. Уенда елдан-ел үзгәреш. Хәзер инде без яраткан «Наза», «Зәкәрия», «Миләүшә», йөзек салыш уеннарын кысрыклап, магнитофон тавышлары, «Кем ничек булдыра» дигән танцылар килеп керде. Хәер, кичке уенга бар да килешә. Яшьләр үсә, «Мәдрәсә бакчасы» кебек тагын дүрт җирдә берьюлы кичке уен гөрли.

**IV**

Автобустан төшеп җиргә аяк басу белән, рәхәтләнеп бер төчкертте – яшь наратларның хуш исе тулы Шәле һавасы күкрәгемнән шәһәр һавасын кысрыклап чыгарды. Саф иркенлек, серле бер чор. Әллә яз, әллә җәй инде...

Яз белән җәйнең ызаны бар микән? Җәй башы – борнап чыккан үләннәрне каз бәбкәләре йолка башлаган көннән, диләр. Күбәләкләр очып килгәч, дип тә шаярталар. Тузганак чәчәкләре кабынгач, диючеләр дә бар... Без җәйне сабантуйдан башлап җибәрик. Колгадагы чүпләмле сөлге – сабантуй әләме җәй белән яз ызанында.

Кайта алырдай кешеләр кунакка кайткан; мөмкин булган җирдә эш тукталган; хәтта больницаның утыз алты койкасына ике авыру калган. Бөтен җан иясе мәйданда – «Мәдрәсә бакчасы»нда. Кеше күплектән алан тарайган. Яшел күләгәдәге тупыл-таллар да кысылыбрак, бер-берсенә сыеныбрак басканнар.

Кашлакта тамашачылар сыман картлар, мәйдан читендә чабышка китәсе атлар кебек ярсу яшьләр. Уртада – көрәш. Рәссам Харис Якупов үзенең Шәле кешеләренә багышланган альбомын «Көчле кешеләр» дип бик дөрес атаган. Көрәш озакка сузылса, белегез: көчлеләр бил алыша. Ә көчленең көчлесе – батыр! Шәледә елга алтмыш биш-җитмеш бала туа икән, алар арасында кимендә ике батыр бар дип исәпләгез: берсе сабантуй батыры икән, икенчесе кыр батыры булыр.

Иң соңыннан чүлмәк ватышка җыелалар. Күзең – бәйле, кулда – күсәк, алда – күмер чүлмәге. Бәр, Габбас абый!.. Һәй, көч тә соң үзеңдә – Җир шарын уртага яра яздың, чүлмәк кенә исән калды... Габбас абыең күзен бәйләгән яулыкны алып атты да, үртәп торучыларга үч итеп, чүлмәккә ташланды.

– Дөрес түгел!

– Уенны боздың!

– Чүлмәк ватылгач, пускай кешнә!

– Бүләк бирегез үзенә!

Кичке җил картларны хөрмәтләп кенә өйләренә озатып куйды. Тальян моңына яшьләр назлана. Исламның куен кесәсендә бер читенә «Сәлимә» дип язылган кыңгырау чәчәкле чигүле кулъяулык һәм шул яулык белән бергә Сәфәри чүннигеннән җыелган алтын чикләвекләр. Сәлимәнең бит алмасы төн түрендә нур сибә. Шул нурга җәйнең беренче таңы кушыла. Җыр дәвам итә.

Җәй башы. Игеннәрнең яшел сай дулкыны яңгыр сорап игенче каршына килә. Көн аяз... Шулчак чүмеч, чиләкләр күтәреп балалар җыела:

– Карга боламыгы!

– Карга боткасы!

Чиләкләрдәге су чүмеч-чүмеч булып урамнан үтеп баручы кешеләр өстенә сибелә. Халык чылана, чылана да көлә, көлә дә күккә карый. Офык артыннан кулга-кул тотынып болытлар килә.

– Ур-ра, без яңгыр китердек!

– Безнең яңгыр ява!

Өй түрендәге күлдәвекләргә шыбыр-шыбыр яңгыр коела. Өстәл тирәли тезелешеп балалар ботка ашый.

* * *

Кала юлында йөрүчеләрне өч төргә бүләргә мөмкин.

Беренчесе – кайтып-китеп йөрүчеләр. Алар тумышлары белән Шәленеке булып, җае чыккан саен: «Мин Шәледә тудым», – дип масайсалар да, авыл эчендә никтер ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә генә күренәләр.

Кайтып-китеп йөрүчеләр арасында язучылар, рәссамнар, артистлар да бар. Шәһәргә якын торгангамы, әллә тамашачылар күпкәме, Шәлегә артистлар еш килә. Килгәне берсе, залны сокландырырга теләп, сайрарга керешә. Кайберләре сайрый-сайрый да, гамьсез халык ла бу, дип китеп бара. Шәле кешесе бер үк җырчыны да ике төрле алкышларга мөмкин, дөресрәге, җырына карап җырчысына кул чаба. Шәле халкының таләпчән булуына ышанмасагыз, Шәле премиясе лауреатлары язучылар Вакыйф Нуруллин белән Хәниф Хәйруллиннардан сорап карагыз.

Халык туган авылына охшаса да охшар икән. Шәле кешеләре Харис Якупов полотноларына чак сыйган. Сынлы сәнгать музеена кергән кеше: «Булган бит элек көчле кешеләр!» – дип сокланыр. Ләкин Миңзифа Галиуллина, Фәүзия Гәрәева, Мәрзия Исламова, Нәриман Җиһаншиннар – колхозның бүгенге кешеләре. Әйе, әйе, дүртпочмаклап япкан яулыклары, бәби итәкле күлмәкләре, челтәрләп керфекләнгән алъяпкычлары, хәтта беләкләрендәге көмеш беләзекләре дә бүгенгечә. Театр сәхнәсендә мондый киемнәрне күрсә, әй шатлана шәһәр кешесе! Әллә Шәле тормыш дигән олы театрның бер сәхнәсеме? (Авыл уртасында яңа Культура сарае өлгерә, иске клубны нишләтерләр икән?)

Юлда йөрүчеләр арасында кайтыр өчен китүчеләр дә бар. Болары инде канатлы өметләр. Мәктәпне тәмамлагач, шәһәргә укырга кергәннәрне дә, армиягә китүчеләрне дә кайтырга тиешләр дигән өмет белән озаталар. Һәм алар кайтып та керерләр. Тик соңгы сугышка китүчеләрнең генә 272 се әйләнеп кайтмады.

Юл кешесенең өченче төре – китмәскә дип кайтучылар. Болары күпчелек. Каладан әрдәнәләп төяп кайтса да, автобус Шәледән ярым буш китә. Китмәскә дип кайтучылар Шәленең җитәкче көчләре, укытучылар, белгечләр, игенчеләр.

Мин гел юлда. Ничаклы гына тырышсам да, китмәскә дип кайтучылар төркеменә кушыла алмыйм. Кайтам – китәм, кайтам – китәм, кайтам – китәм... Таллар кичерер микән?..

# БӘХЕТЛЕ КЕШЕ

Иртәгә төш вакытларына гына килеп җитәр әле дип көткән кунак бүген төн уртасында ук кайтып төште.

Капка келәсе шалтырады. Рәхәтләнеп йоклап яткан Нурулланың бер-ике бөртек чәчен йолкып алды Минҗиһан. Аны да сизмәгәч, тагын йолкыйм әле дип, янә ябышкан иде – бу юлы күбрәк учланган, ахрысы:

– Пеләш калдырасың инде, кытыклап кына уятсаң ни булган, – дип зарланып куйды Нурулла. – Нәрсә бар?

– Капкада кеше.

– Әй, язгы лыжырда багана саен бәрелеп-сугылып йөрүче сәрхушләр беткәнмени?

– Шакылдата бит ул. Әнә тагын. Бар әле, чыгып кычкыр, йөрмәсеннәр.

– Иренәм, үзең генә чык.

– Ирләргә ирләрчә кычкыру кирәк. Хатын-кыз тавышына чәер күк сылана торган берәр хәсисе булса...

Шунда гына Нурулланың йокысы качты:

– Кем бар анда?

– Капкаңны ач, танырсың.

– Танырдым инде, тавышың үзеңнеке! Бикле капка белән каршы алганга үпкәләмә, Тәлгать, без әле сине иртәгә генә килеп җитәр дигән идек.

Бәла-казасыз гына килеп җитү шатлыгыннанмы, Тәлгать бер урында таптанды. Нурулла да дулкынлана иде, капканы ачып җибәрүе булды – маңгайлары бәрелеште. Бер партада утырып музыка училищесын тәмамлаганнар иде алар. Икесе ике районда эшкә урнашып, оя корыштырып нигез ныгыта башлагач, өч ел вакыт үтеп тә киткән.

– Сөйлә, ничек таптың безне? Ни дисәң дә, район үзәгендә яшибез, тыкрыклар күп, йортлар тагын да күбрәк.

– Тел ни өчен бирелгән? Шушындый чакта да файдаланмагач. Сораштым инде. Өйрәтеп җибәрделәр. Соңыннан, менә шушы рәшәткәдән аерылмыйча барсаң, Нурулланың капкасына төртелерсең, диделәр. Озатып куймакчылар иде, табачагыма ышандым.

– Рәшәткәгә ябышсаң, кайтасың, кәнишне, пычраграк көннәрдә үземнең дә тотына-тотына кайткан чаклар күп була.

Табын артына утыргач, Нурулла кунак алдында үзен хуҗаларча тотарга теләп, өстәлгә тәлинкә китереп куйган Минҗиһанына эндәште:

– Нәрсә бу?

– Аш, – дип җавап бирде Минҗиһан, тыныч кына.

– Нурулла, кем бу кеше? – диде Тәлгать. – Үз тиңебезме?

– Бөтен яктан да килгән. Язган идем ич инде.

– Язмадың шул.

– Ну, тегенди кәгазьнең беткән чагына туры килгәндер.

– Сөйлә әле, каян таптың?

– Сөйлә дип... Санаторийда ял иткәндә инде. Минҗиһан анда техничка булып эшли иде. Әйдә, мин әйтәм, кулына себерке тота белгән кешегә бездә дә эш бетмәгән, киттек, дим. Икеләнгәнен сиздем дә, әһә, икеләнү ул «юк» дигән сүз түгел, үгетлә, Нурулла, үгетлә, дим, үз-үземә. Шуннан кичләрен пансионда баян сыздырып җибәрәм – Минҗиһан килә дә керә. Ниятләде, ияреп кайтты. Әнкәй, мәрхүмә, әй шатланды, куана-куана үләм, синең өчен җаным тыныч китә, диде... Менә, гаиләбез ишәергә тора. Минҗиһан, кил әле!

– Яныңда ич инде.

Янымдамы икән дигәндәй, Нурулла хатынының чәчен сыйпады, кочаклап алды.

– Игезәк булырлар, ахры, – диде Нурулла, мактанганлыгын сиздереп, – кушаяклап тибенә, вакыты да җитте бугай инде, әйеме, карчык?.. Карагыз әле, әйдәгез иртәгә күл буена, ял итәрбез, ичмасам.

– Синең белән миңа күл ни дә, ләгәндәге су ни, барыбер, – дип кырт кисте кунак.

– Күл генә түгел, Кара күл ул.

– Күлнең карасы да була микәнни?

– Зәңгәре, яшеле, сарысы да була, ахрысы. Ну, син курыкма, су коеныр чак түгел, иртәрәк әле. Барабыз, кояш чыккач, берәр төркемгә ияребез шунда. Халык дигәнең рәхәтнең тәмен белә, бер көн бара, ике көн буе кайта. Күл тирәсендә таралышып бетәләр. Күрәсең, кайтыр юлларын да тиз генә таба алмыйлардыр.

* * *

Кара күлгә дип әзерләнеп йөргән җирдән Минҗиһан кинәт сыгылып төште. Өч елга беренче мәртәбә ял итәргә бару шатлыгыннанмы, әллә инде кунакка хөрмәт күрсәтергә теләп артыгын йөреп ташлады, белмәссең...

Хатынын больницага илтеп, кайту юлына чыккач кына Нуруллланы культмассовик кыз тотып алды. Кунагым бар, берьялгызы нишләр, ул да бит минем ише кеше, дип, күпме генә киреләнсә дә, кызлар кулыннан ычкына алмады Нурулла. Ярар, хатыным юк чакта азрак сагышларым таралыр, дип, соңыннан ризалашып та куйды тагы үзе. Карышып ни кырасың инде, Культура йортына баянчы булып яллангач. Ә район үзәгендә, билгеле инде, көн саен бәйрәм: иртән репетиция, көндез генераль репетиция, кич концерт. Бүген исә министрлыктан: «Фәлән көнне, фәлән сәгатьтә чәчүчеләр янына агитбригадалар белән чыгарга әзер торыгыз», – дип күрсәтмә килгән, ди. Дөрес, баянчылар бик күп районда, тик Нурулла кебеге – ялындырмый торганы гына юк. Ялындырмавы бер хәл, һәвәслеген күр син аның! Беркөн иртән эшкә килгән дә баянда әллә нинди сәер көйләр чыгарып маташа. Нәрсә уйныйсың син, дип сорыйлар тегеннән. Өй түрендә сыерчык тавышын тыңлап торган идем, шуны кабатлап карыйм, ди бу. Ул колакка сизгерлеген күрсәң, тыныч көндә кар яуганны да ишетә, билләһи менә, һич ялгансыз. Шушы матур гадәтләре дә яраттыра бугай аны.

Нурулла көнозынын культура йортында үткәргәч, кунак кеше өйдә хуҗа булып калды. Әйдә, кунак, үзең сыйлан, дип, пыр туздырып ризык эзләргә кереште һәм шулчак кулы белән таянган җирдә стенаның эче куыш икәнен сизеп алды. Бүрәнәләр тәмам көпшәкләнгән – бармак белән төртсәң, тишелеп чыгасы әллә тагын?

– Әһә, сез әле Нурулла тикле Нуруллланы черек өйгә куандырдыгызмыни?!

Ул, үзалдына ярсып, ашыйсы килгәнлеген дә онытты. Кирәге чыга калса дип, бөгәлҗәле тимер таягын эләктерде дә урамга атылып чыкты. Райбашкарманы эзләп китте ул.

* * *

Минҗиһан өйдә булмагач, өй эчендә ут кабынмады, кирәге юк иде. Хәер, Минҗиһан үзе дә, Нурулласын ныграк аңлар өчен, күп вакытларны караңгыда калырга тырыша.

– Райбашкарма председателегез ничава мужикка охшый, – дип, Нуруллланың боек күңеленә үтеп керде кунак, – тавышы да мөлаем, сүзләре дә сары май кебек ягылып кына тора.

– Каян табыштыгыз?

– Синең йомышны йомышлап инде. Өч ел иске өйдә яшәгәнсең, җитмәсә, гаилә үрчетергә җыенасың. Председатель әйтә, сорап кергәне юк ич аның, ди.

– Соранып йөрүне рәхәт дип беләсеңме? Йортыбызга ни булган? Искеме, яңамы – кулга сизелерлек аермасы юк.

– Бәхәсләшергә соң инде. Бәби туегызны яңа нигездә үткәрерсез.

– Минҗиһан куаныр инде. Куансын! Хатын шәп минем. Һәр көн эшкә илтеп куя, каршы ала. Клубка кадәр генә араны яттан да беләм инде анысы, шулай да ул килмичә өйгә кайтырга ашыкмыйм. Бөтен рәхәте дә шунда бит аның...

Көтмәгәндә генә культмассовик кыз килеп керде:

– Ник караңгыда утырасыз? Малаймы, кызмы дип сорагыз!.. Малай!!!

– Малай?! Кешегә охшаганмы? Күзлеме?

– Ике күзен мөлдерәтеп, эти ник монда түгел дигәндәй елап ята.

– Башта ук шуннан башласаң! Училищеда укыганда бер мөртәте: сукырдан сукыр туар инде ул дип, бик нык хәтерне калдырган иде, күзле туган бит, ә! Их, Тәлгать, эшләр болайга киткәч, бәби туен үткәрмичә сине җибәрде юк.

Алар өчәүләшеп больница юлына чыктылар. Нурулла кулына тәмәке алган иде дә, тик сабые яратмас дип, кабы-ние белән язгы пычракка ташлады.

– Их, яшәве рәхәт бит дөньясында! Айны карагыз әле, ничек яктырта, тулган...

Тәлгатьнең дә нидер әйтәсе килде:

– Сандугачлар безнең якка юлга чыктылар бүген.

Культмассовик кыз хәйран калды:

– Күзлеләр дә күрмәсне каян белеп әйтәсез соң сез?!

– Күңел белән сизәбез.

– Бәхетле кеше тоя икән ул, сеңлем...

# КАПЧЫК ТӨБЕ

Безне аңламаганга сабышалар...

– Чырык-чырык, чирик-чирик, чем-чем...

Иң матур җыр бу! Карлы шәһәрегездә башка сайрар кошлар юк, без үзебез генә. Ә сезнең исегез дә китми, күтәрелеп карарга иренеп, арлы-бирле йөренәсез. Төркемнәрегезнең рәте-чираты юк, кулларыгызда йөк, иңнәрегездә авырлык, чыраегыз җиргә баккан. Кайтып килешегезме, китеп барышыгызмы? Ник тукталып тыңламыйсыз? Бу дөньяда кошлар сайравына исе китми торган кырмыскалар гына була иде. Сезгә сандугач җыры кирәк! Сандугачларыгыз бәсле, сөремле, шыксыз, зәмһәрир көннәрегездән качып җиде диңгез аръягында кызыналардыр, бәлки. Бик беләсегез килсә, безнең җыр шәһәрегезгә күрә артыграк та әле. Сайрар кошлар сезне җәй көне дә әйләнеп уза, тузгыган бакчаларыгызда оялар сирәгәйде хәзер. Ә без сезгә тугрылыклы – сез ашаганны ашыйбыз, сез эчкәнне эчәбез, сез сулаганны сулыйбыз. Бездә дә сезнең гамь, сезнең чир, сезнең җәза.

Менә быел да бергәләшеп кыш кичәбез. Көннәр суынган саен сезгә якынрак киләбез. Кесәгездән бияләй алганда берәр көнбагыш сыныгы коелмасмы дип аяк астыгызда тапталабыз. Ай-һай сирәк коела шул... Бияләй эчендә кулыгыз – сулыш өреп җылытасыз. Ә бит без шул бияләйнең баш бармагы хәтлек кенә... Туңсак та сер бирмибез. Балконыгыздагы шкаф өстенә кунып ашавыгызны күзәтәбез: малай-шалайларыгыз көчәнеп-көчәнеп ботка чәйнәп утыра, өстәл астына ипи валчыклары өелә. Бәлки, безгә сибәрләр... Юк шул, аларның безне тотасылары гына килә. Матур инде без анысы, шуңа кызыгалар.

Шәһәрнекеләр безне үги итә...

Мин үзем авылда туып үстем.

Әти-әнием сыерчыктан бушаган иске ояны ашык-пошык кына төзәткәләп куыш иткәннәр дә шунда вакытлыча яши башлаганнар. Без бишәү үстек. Ул елны кура җиләге нык уңган иде, көне-төне ашаттылар. Тиз ныгыдык. Оядан чыгып очарга өйрәнгәндә кытай шомырты да җыелмаган иде әле. Йорт хуҗасының абзар-курасы кырык терәүле, ишегалды хәйран иркен, җитмәсә, чирәм генә. Нишләптер ул мал-туар күп асрамады – бер карт кәҗәсе бар шунда. Ул аны көтүгә куганда зур кәлүшләрен көч-хәл белән сөйрәп капкага гына озатып кала. Хуҗа йокысыннан уяна алмаганда кәҗә дә өйдә кала... Тагын тавыклары бар. Алары инде безнең ише генә, безнең чаклы, безнең көндә. Ишегалдына бер тагарак көрпә чыкса, без тавыклардан алда тамак туйдырып өлгерәбез. Аннан соң, томшыкларыбызны яшел чирәмдә корытып, кырык терәүле абзарда качышлы уйнарга керешәбез. Уйнаган булып кына оя корырдай җайлы төшләрне искәреп барабыз. Андый көннәрдә ишегалдында кәҗә үзе хуҗа. Төн чыкканчы аның сыртына тезмәдәге саламнан бөртек коелган була, без ябырылып шуны чүплибез. Кәҗәгә дә рәхәт, сыртын чукыганда гел койрыгын селкеп тора. Аның койрыгы да безнең койрык шәе генә.

Кышларыбыз рәхәт үтәр дип торганда гына...

Ишегалдына бихисап кеше җыелды, үзләре ни көлмиләр, ни еламыйлар, ни кычкырып сөйләшмиләр. Озак юанмадылар – хуҗаны кабыкка төреп алып чыгып киттеләр. Шул көнне үк кәҗә көтүдән кайтмады. Тавыкларны күршеләр үзләренә чакырды... Көрпә тагарагы коргаксыды.

Без башка ишегалдына күчтек. Дөрес, анда безнең ише ятим өйләрдән сөрелгән бер-ике төркем чыркылдашып йөри иде инде.

Шактый бәхәсләшә торгач, араларына керттеләр тагы...

– Чырык-чырык, чирик-чирик, чем-чем...

Бу йорттагыларының тавык-казлары симез, иртә-кич бодай чүплиләр. Аларның туеп киткәнен көтсәң, аяк астында җир генә кала. Көтеп тормыйбыз, без аларныкы ла... Түткәй безне сөйми, җим сипкәндә ата казларыннан да болайрак ысылдый. Мин шәп итеп очарга өйрәндем – этәчнең борын төбендәге ипиен алып китә алам.

Өй тирәсендә кычыткандай сарылып үскән миләш бар, көн ачылгач, шунда күч алыш уйныйбыз. Уйнап туйгач, кара каргалар белән саубуллашырга барабыз, җыр өйрәнәбез.

Өйләдән соң түткәйнең малае кайтып керә. Кулында букчасы. Кайту белән безне эзләп таба, тавыклардан яшереп кенә сыйлый, чүпләгәнебезне бер читтән күзәтеп утыра, сиздермичә генә безгә якыная. Иярләшәбез инде үзенә, ярattыра белә: сызгырып куркытмый, таш атмый, песине якын китерми, көн саен безнең янда.

Соңгы көнемдә ул ипи урынына кыздырылган көнбагыш сипте. Такмаклый-такмаклый сырпалана үзе: «Ашагыз, сикертәннәрем, каланыкыларга гына тәти торган ризык бу», – дигән була. Һай тәмле дә соң бу кыздырылган көнбагышлары! Шәһәр чыпчыклары кинәнәләр икән, дип уйлап та өлгермәдем... өстемә лап иттереп авыр иләк капланды. Тәмле ризыкның тозак икәнен кем белгән соң ул чакта... Яшь гомерләр җәлке, дөньяга килеп ике ай да очмаган, кем әйтмешли, рәхәтләнеп чыпчык кызларын да кочмаган килеш әрәм булырмын микәнни?!

Малай мине пыяла савытка салып өстән томалап куйды, аяк астыма көнбагыш ыргытты. Әсир кошның ризык өстендә ачтан үлгәнен белми бугай ул! Канатларым авырткачы бәргәләндем, тик котылырлык түгел – стенасы калын. Пыяла зиндан икән бу.

Ул миңа Чемчен дип исем кушты.

Шулай бер-ике көн яшәдем бугай әле. Берзаман өй эчендә китте ыгы-зыгы: җиһазларны ташыйлар. Өй эче бушый бара, аның саен мине күчерәләр, өстәлгә куйганнар иде – аны алып чыгып киткәч урындык өстенә, ул да чыгып киткәч, сандык өстенә куйдылар. Теге малайны туктаусыз үгетлиләр: «Калада чыпчык бетмәгән, тилмертмә моны, барыбер исән калмас». Малай нык карыша, калдырмыйм, авылыбыз истәлеге булыр, ди. Ниһаять, малай мине күтәреп урамга чыкты. Өй эчен машинага төяп бетергәннәр. Малай да шунда сыйды. Ялган сөйләр хәлем юк, ул миңа кул тидермәде, өф-өф итеп кенә саклап алып барды. Үзе юл буе минем белән сөйләшә: «Чемчен, Чемчен, калада көн саен колбаса белән сыйлармын, ашый-ашый этәч хәтле булырсың», – ди. «Җибәр инде, зинһар, авылда гына калыйм», дип ялварам үзенә, ә ул ишетми. Безне беркем ишетми – табигать сөйләшүдән мәхрүм итеп яраткач... Сөйләшә белсәк, без дә кеше белән бер рәттә булыр идек! Хәер, һәр тереклек сөйләшә белсә, җирдә гел зарлану, ялыну, ыңгырашу гына яңгырап торыр иде.

Калага күчеп килгән көнне үк малайның әти-әнисе арасында низаг чыкты. Әниләре кала бичәсе булдым дип масайды, әтиләре аңа, шушы чыпчык көненә калып, тамак туйдырырга интегеп, «Чем? Чем?» дип йөрерсең әле диде. Ике фикер бер-берсен җиңәргә тырышып гаугага әверелде. Ләкин гауганың азагы минем өчен искиткеч куанычлы бетте: әниләре малай кулындагы банканы тартып алды да идәнгә бәрде. Уллары «Әни!» дип авыз ачканчы, ачык тәрәзәдән кала иркенлегенә томырылдым.

Әсирлектән котылган көнне шәһәр миңа искиткеч матур булып күренде. Монда очар кошка оя кытлыгы юк икән. Кая карама, өере-өере белән куыш бүрәнәле өйләр, түбәләре теткәләнеп беткән чормалар. Монда авылдагы кебек түгел, өйләрнең тәртибе юк. Монда бер-берсенә терәп салынган ярым таш, ярым агач, ярым такта алачыклар салып бетергәннәр. Монда ишегалды саен абзар исе килә. Кыл уртада булыр юынтык сулар җыя торган әрҗә. Әрҗәнең түбе иләкләп тишелгән – суы аска агып бетә, бәрәңге кабыклары, ипи катылары, тозлы кыяр телемнәре буш шешәләр белән күмелеп иләктә утырып кала.

Пыяла зинданнан котылган көнне мин ап-ак йортлар тирәсеннән дә оя эзләп караган идем. Алар биек, түбәләре төзек һәм сумалалы, чормалары томалаулы, томшык төртер урын юк. Юынтык сулар түгә торган әрҗәләрен дә таба алмадым. Андагы кешеләрнең ни ашаганы, ни түккәне безгә мәгълүм түгел. Чүп-чарын да бикләп тоталар, иртән-иртүк машина килеп төяп алып китә – анысы да бөркәүле. Әйтсәм әйтим, халыклары мәнсез: җиргә карап этне күрми, күккә карап безне сизми.

Менә, ичмасам, үзебезнең ярым йортларда рәхәт! Бала-чагалары ишле. Туган-тумачалары күп, дуңгыз симертәләр, эт үрчетәләр, чыр-чу, уен-көлке, көн саен тамаша, көнаралаш мәҗлес – яшәве күңелле! Ходай кушып, буранлы озын төннәре, чатнама суык көннәре генә үтсен.

Мин шифер түбә астындагы сиртмә уентысына мамык коеп тамгаладым да, үземә пар эзләп киттем, ояны икәүләшеп коралар бездә. Көне буе эзли торгач, бер чыпчыкны ияртеп кайттым. Ул да минем ише ятим, килеш-килбәте бик ялтырамаса да, өзелгән-йолкынган җире юк. Бергә-бергә тернәкләндек. Ничәмә-ничә оя очырдык.

Быелгы суыкның һаман сынарга исәбе юк...

Чорма саклап тәк ятулары ялыктырды. Ашыйсы килә. Ишегалдындагы әрҗәгә бүген дә чүп түгүче булмаса, тәгам эзләп еракларга очарга туры килер. Бер дә канат астына суык кертәсе килми шул. Ичмасам, мондый көннәрдә чормага менүчеләр дә юк. Буранлы айларда безнең янга йә парлап-парлап, йә өерләре белән менәләр менүен... Морҗа төбенә җәелгән сырмаларда туйганчы ял итәләр, арыганчы ауныйлар, көлешәләр, ыңгырашалар, пышылдашалар, тагын көлешәләр, тагын ыңгырашалар... Без аларга карап сөенәбез генә, китүләре була – сырмага ябырылабыз. Кесәләреннән коелып калган валчыкларны чүплибез.

Кайсыбер көннәрдә безнең ояларны эзләп чормага малай-шалай җыела. Аларга кошлар базары кызык кына. Телләрендә сүгенү, кулларында таяк, эшләгәннәре юньсезлек. Күршедәге күгәрчен оясына йомырка да салып киткәннәр. Мескен күгәрчен оясыннан таеплар төшә язды... Тавык чебиләре дөньяга килгәч тамашаны күрсәң... Тавыкныкылар безнекеләр шикелле ояда тик кенә утыра белмиләр бит алар, чорма буйлап йөгерешеп йөрделәр. Күгәрченнәре талашып бетте. Үстерергә генә насыйп булмады, икенче көнгә ул чебиләр өшеп җан тәслим кылганнар иде.

– Чырык-чырык, чирик-чирик, чем-чем...

Әгәр көннәр иртәгә дә җылынмаса, теге тавык чебиләре шикелле өшеп тәгәрәшербез инде. Әҗәл килгәнне ояда көтеп ятасы килми. Кузгалдык. Икебезнең беребез әйләнеп кайтыр әле. Чүп өемендә тукталып тормадык, туп-туры олы урам коймасына килеп кундык. Күзәтәбез. Кемнән нәрсә коелыр? Урам тулы машиналар мыш-мыш килә – безнең сыман нәрсәдер эзләнәләр. Әнә тар юлдан бер абзый бара, чана тарткан, тимер табаны карны чината. Ник чыпчыклар ияргән әле аңа? Чанадагы олы капчык өстендә бөтереләләр. Без дә иярдек. Исеннән үк сизелеп тора – кыздырылган көнбагыш! Бара торгач,

базарга килеп терәлдек. Дөресен генә әйткәндә, базар тирәсендә бик йөргәнебез юк безнең, анда чыпчыклар ашардай нәрсә бик сатылмый. Сатсалар да, сакчылары кырыс, алучылары саран.

Ит сатучылар тирәсен ала каргалар каравыллый, тәм-том сатучылар түбәсендә күгәрченнәр өере, безнең ишеләргә якын килерлек түгел.

Абзый капкадан керде дә тугарылды. Шундук стаканлап көнбагыш өләшә башлады. Без, йөзләгән чыпчык, базар түбәсенә кунып абзыйның капчыгы бушаганны көтәбез, чөнки сатучылар, нинди генә саран булсалар да, барыбер капчык төбен безгә сибәчәкләр.

Һай озак бушый ул капчык... Чираты өзелми өзелүен, капчыгы зур шул, ә стаканы бәләкәй.

Кинәт чиратта таныш йөз күзгә чалынды. Таныш йөз... Мин моңа ышаныр өчен танышның йөзенә якынрак килеп бер мәлгә һавада эленеп калдым. Ул да мине таныды: «Чемчен, Чемчен!» – дип, сөенеченнән чиратын югалтты. Әйе, ул мине әсир итеп калага алып килгән теге авыл малае иде. Ничек зур үскән – сумка асып базарга чыгардай егет булган. Ул кабаланып кесәләрен капшады, миңа сибәрдәй валчык эзләде. Түбәдәге чыпчыклар минем дустым булып күренергә теләп тирәмә сарылдылар. Ләкин күпме генә эзләнмәсен, мине сөендерерлек берни табалмады ул. Шуннан соң кулындагы каеш сумкасын ачып карады, анда биш-алты чи бәрәңге генә иде. И, егет, егет, дусларым алдында бөтенләй оятка калдырдың бит син мине.

– Чемчен, Чемчен, хәзер мин сиңа көнбагыш алып бирәм!

Ләкин егетне баягы чиратына кертмәделәр. Күршеләре, әрләшеп, сүгенеп, танымаганга сабышып яңадан озын чиратның койрыгына басарга мәҗбүр иттеләр. Минем ачуым чыкты, күчне ияртеп әле капчык өстендә, әле чират өстендә очына башладык. Егет моны үзенчә кабул итте, түзмәде, сатучы янына килеп чиратсыз гына акчасын сузды. Ә абзый күрмәмешкә сабыша. Учына сыярдай стаканы белән тәртип буенча көнбагыш саный. Ул да булмады, кемдер егетне пәлтә якасыннан сөйрәп читкә селтәде. Егет, эт өстенә җикеренгән песи шикелле күперенеп әүвәл кул күтәргән кешегә таба атлады, аннан кинәт кенә борылып янә капчык янына ашыкты. Кулындагы кәгазь акчасын, йомарлап, абзыйның стаканына томырды да капчыктан бер уч көнбагыш иелеп алды һәм әлеге хурлыкны базарда калдырып урам ягына чыкты. Ерак китмәде ул, аяк астындагы карны таптап шунда учындагы көнбагышны сипте. Барысын да түгел, беразын үзенә калдырды. Ачлыгымны җиңеп җимгә якын килмичә түзеп торам, аның читкәрәк киткәнен көтәм. Кешеләрдән сагаерга кайчандыр ул мине үзе өйрәтте лә!

Кинәндек көнбагыш чүпләп. Көннәр җылынганчы түзәргә була хәзер. Тамак туйгач җитәкләшеп һавага күтәрелдек, оябыз бәсләнгәндер... Офыкта кызыл төс кимегән инде. Кич җитте. Ояга җитәрәк мин кире борылып карадым – еракτан караганда базар түбәсе зур иләккә охшаган иде. Теге егет анда көнбагыш чүпләп калды.

# КӨМЕШЕМ

Сәлимгәрәй гадәтенчә өй алдындагы кәнәфидә ял итә, дөресрәге, вакыт үткәрә. Көзге кояшның сүрән яктысы, аз гына җылыткан булып, тәнгә сизелерлек көч өстәп тора. Чал болытлар никтер өерләре белән Сәлимгәрәйнең баш өстендә генә бөтереләләр төсле.

Ял итү дә алҗытты. Өйгә кереп китмәкче иде, кемнедер күреп алды. Якынлашучы кешенең йөзен танып өлгермәде, шулай да дуга кебек кырт бөгелгән сыгылмалы көянтәсеннән чамалап, Закирәгә охшатты ул аны. Аралар якынайган саен, бу уена ныграк ышанды. Закирәнең Сәлимгәрәйләр каршысындагы коега суга килеше, ахры.

Кинәнделәр коега. Кое гына түгел, тутырып куйган самавыр инде. Суы эчеп туйгысыз. Бер ташландык нәрсә генә иде юкса. Сәлимгәрәй яңа бура белән ныгыткач, эшкә ярап куйды.

Закирә чиләкләрен чирәмгә куйды. Коега төшеп китмәсен дип, бармагыннан көмеш балдагын салды һәм Сәлимгәрәйгә эндәште:

– Ни хәлләрең бар? Кәефең ничек?

– Зарланмыйм. Үзең нихәл?

– Хәл дип, шөкер, чиләк-көянтә күтәрерлек рәтем булгач, канәгать инде.

– Рас әйтәсең.

Алтынчы дистәсен тутырып килсә дә, бирешми Закирә. Кое чарыгын кызлар кебек җиңел әйләндерә. Сулы чиләкләрне дә элеп кенә алды. Атлавын күр әле син аның! Унҗиде яшьлек кызларың бер якта торсын.

...Яшьнәп яшәр чакта гына тол калды Сәлимгәрәй. Хәер, япа-ялгыз ук түгел дә түгелен. Бер түбә астында улының гаиләсе, шул гаиләдә яраткан оныгы Ислам да бар.

Кич җитте исә, Ислам клубка чыгып сыза; улы белән килене чаршау артына ябыла; кече онныклары көне буе урамда йөгерүдән алҗыган аякларын юрган эчендә ял иттерә. Сәлимгәрәйнең берүзенә бер йорт дигәндәй, караваты арткы өйдә. Йокы бик ялындырып кына, төн уртасы җитеп узгач кына килә...

Закирә суга көн саен бер вакыттарак йөри. Сәлимгәрәй, аның бу гадәтен исендә тотып, кое янына чыгып басты. Каен тузына ягып алып килгән дегетне бармак очы белән генә чыгырның күчәренә тидергәләде, әйләндереп карады, тагын майлады, тагын әйләндерде. Закирә килеп баскач та чыгырның тоткасын җибәрми торды.

– Төзәтәсеңмени, Сәлимгәрәй?

– Коргаксыган тегермән шикелле шыгырдый.

– Тавыш-тыны ишетелми иде бугай...

Закирә бадьядан чиләгенә су бушатмакчы иде, тик өлгермәде. Бу юлы да чиләкләрнең тулганын карап кына торырга туры килде.

* * *

Кичен бераз һавада йөреп керергә булды Сәлимгәрәй. Урам тыныч. Тупыл очларындагы саргайган яфракларны кыштырдатып караңгылык иңә. Йолдызлар Сәлимгәрәйгә күз кыса.

Сукмакның өзеге юк дигәндәй, инешкә барып чыкты ул. Инеш тирәсе җәйдә әле, көз бу тирәгә кагылмаган. Инеш яры, атлый торгач, Закирәләрнең бакча башына алып килде. Әгәр кыюлыгы җитсә, ызан буйлап туп-туры Закирәләрнең ишегалдына килеп керергә була иде. Була иде...

Озак йөрде Сәлимгәрәй бу төндә. Кайтып җиткәндә генә үзе ясаган кәнәфидә кыз белән егет тавышын ишетте. Канат астындагы чебиләр кебек чүкердәшәләр бит тегеләр. Исламны таныды ул, ә кызны юк. Яшьләр күзенә чалынырга кыюлыгы җитмәде аның, төнге урам иркен әле, Сәлимгәрәй сыенырлык кына баганасы табылыр...

* * *

Сәлимгәрәй кайтканда, Ислам өйдә иде инде. Оныгы белән рәхәтләнеп бер сөйләшәсе килгән иде, җае чыгуын күр әле, Ислам аның караватына яткан, мөгаен, үзенең дә сөйләшергә нияте бардыр.

– Исламетдин, аең иртә баеган бүген.

– Иртәгә район үзәгенә барасым бар, ди.

– Нинди кыз ул, мин беләмме аны?

– Тәскирәне белмәскә. Теге...

– Ә-ә... Аны әйтәсең икән. Әйбәт кыз. Яратасыңмы?

– Әй, бабай, Тәскирәне күрсәм, йөрәгем үзалдына бокс уйный башлый.

– Ә ул яратамы соң?

– Сорамадым. Тотасы кошны кычкырып куркытмыйлар. Аны шыпырт кына, үз җаена, әкренләп кенә...

Бабай кеше оныгының соңгы җөмләсен хәтеренә сеңдереп куйды һәм иртәгесе көн турында, кое, Закирә турында уйларга кереште.

* * *

Сәлимгәрәй өзелеп көткән көнне генә Закирә коега килмәде. Болын чишмәсенә китте, дип сөйләделәр. Бу хәл икенче көнне дә, өченче, дүртенче көннәрне дә кабатланды.

Өенә бару уңайсыз, суга килми, кичен урамга чыга белми. Нишләргә тиеш иде соң Сәлимгәрәй хат язмыйча?..

Ике көн буе язды хатны Сәлимгәрәй. Язды да калага баручы бер ышанычлы кешегә биреп җибәрде.

Һәм Закирәгә каладан хат килеп төште. Хат көтәрдәй кешесе булмаса да, тиз генә укып бир әле, дип, күршесе Фәһимәгә керде ул. Кермәс тә иде, гәҗит-мазар укый торган күзлегенең пыяласы төшкән, хәерсез, төзәттерергә кул тими.

*«Исәнме, Закирә!*

*Язам әле. Күңелсез. Тәрәзәнең рамнары да рәшәткә булып күренә. Син суга килгәч сөйләшеп юана торганыем. Суга да килмисең. Ялгызың күңелсез түгелме соң? Карале, Закирә, син дөньяга килгәндә, мин инде каз көтәрлек малай булганмын. Яшь әле син...»*

Нәкъ шушы урында Закирә Фәһимә кулыннан хатны йолкып алды.

– Сырлаган... – диде Фәһимә, тел шартлатып.

– Күпертмә, Фәһимә, күпертмә. Минем гамәл дәфтәрем тулган инде.

Фәһимәнең ишегалды капкасыз, сере тоткасыз дигәндәй, дус-ишләрен күргәч, башындагы уйларын барлап чыга торган гадәте бар иде.

Сәлимгәрәй хатның барып җиткәнлеген кеше теленнән ишетте.

* * *

Тупыл, таллардан яфрак ява. Урамда көр казлар каңгылдаша. Китәсе кошлар китеп беткәч, хуҗа булып калган чыпчыклар, төркемнәргә бүленеп, бәйрәм итеп йөри.

Шундый көннәрнең берендә ишектән сулышы капкан Ислам атылып керде. Керде дә зур сөенечле хәбәр пышылдады:

– Бабай! Килә!..

Әллә нәрсә булды Сәлимгәрәйгә. Җылы башмаклары аяктан очып кына чыкты; бүрек, кул тигәнне дә көтмичә, баш түбәсенә менеп кунаклады, бишмәтенең бер җиңе урамга чыкканда да киелмәгән иде әле.

Закирә кое баганасына сөялеп басып торган Сәлимгәрәйне күрмәде дә диярсең. Күрешми-нитми генә бадьяны төшерә башлады.

– Закирә, син суга килгәлә. Көн саен димим, хет көн- аралаш.

– Ник?

– Ник дип, җаныма ятыш кеше син, Закирә. Аннары, син дә ялгыз, мин дә ялгыз дигәндәй, әллә, мин әйтәм...

– Чынлап торып исәрләнүең, ахры. Картайган көнебездә...

– Алай дип үк әйтеп әйтмә.

– Хәер, кем белә, гамәл дәфтәреңнең берәр бите буш калган булса...

Шулчак чылбыр дерелдәп куйдымы, бармакларының хәле киттеме, Сәлимгәрәй: «Балдагың!» – дип әйтеп өлгергәнче, Закирә кулындагы көмеш балдак йолдыз булып кое төбенә атылды.

– Ашалды, – дип өзгәләнде Закирә һәм кое төбенә таба кулын сузды, әйтерсең лә Сәлимгәрәй коесы чиләк тирәнлек кенә. – Ашалды... ябык бармакта сызган балдак торамыни!..

– Әрнемә, Закирә, алтынын алып бирермен.

– Миңлевәлием төсе иде.

Тынлык, аз гына тынлык кирәк иде бу минутта. Каяндыр урман артыннан күтәрелеп баш өстеннән очып киткән торналар төркеме сыман гына Закирәнең үткәннәре күз алдыннан узып китте.

– Алайса, төшәм кое төбенә, алып менәм.

– Суын болгатырсың.

– Болганса инде, чистартырмын. Без аны хәзер, кулдан килмәс эш түгел.

– Салкын тидерерсең, берүк тотына күрмә... Карале, Сәлимгәрәй, – дип дәвам итте Закирә, кинәт нәрсәнедер исенә төшергәндәй, – ник соң әле без бадьяны күтәреп карамыйбыз?

Кое бурасына бәрелергә куркып, тавыш-тынсыз гына бадья күтәрелә. Ул Закирәнең күзләредәй мөлдерәмә һәм көн яктысын үзенә җыйгандай яп-якты. Көмеш балдак яктысы иде бу. Бадьядагы су тынычланып, аяз көзге җәелде. Ул көзгедән Сәлимгәрәй белән Закирә карап тора иде.

# КӨЗНЕҢ СОҢГЫ ТӨНЕНДӘ

Төнлә генә эшләнә торган эшләр бар. Хәер, төн көннең дәвамы бит ул, шуңа күрә көннән башлыйк.

Солдат, туган авылына кайткач, иң әүвәл югары очтагы сөйгән кызының өй түреннән үтеп китә. Кайтуы турында хәбәр тизрәк таралсын дип, ике урам арасындагы үзәнлеккә җәелгән бердәнбер кибеткә дә килеп керә. Кибет ишеге төбендә, мин сине таныйм бит дигәндәй, каравылчы Сираҗи абзыйның кәҗә хәтле эте өреп кала, көндез һәркемнең дусты да ул, төнлә генә менә туганнарын да танымаганга сабыша, кибеткә якын китерми, Сираҗи абыйны бу эткә исеме белән дәшми диләр, башкалар отып калмасын өчен. Юкса исемен бик матур итеп әйтсәң, эт халкы дошманына да койрык болгый, имеш.

Солдат үзенең җыйнак һәм тыйнак кына язган хатында: иртән өябез, көндез тезәбез, кич йөгерәбез, төнлә сакта торабыз дисә, һич икеләнмәгез – улыгыз стройбатка эләккән. Чик буенда хезмәт итүчеләр, туган авылларын сагынсалар, көтмәгәндә генә берәр батырлык эшләп күрсәтәләр дә ун көнлек ял алалар. Ә стройбатта хезмәт итүче егетләр авылны сагынса, кайтып күрергә теләсә, икеләтә күбрәк өяргә, тизрәк төзергә, җитезрәк йөгерергә, уяурак сакларга тиеш була.

Салих та бик сагынып кайтып килә. Солдат кеше иң әүвәл туган авылын, икенче булып әнисен, аннан әтисен, дүртенчедән, әби-бабасын сагынырга тиеш. Йоласы кушканча инде. Тик, сер итеп кенә әйтсәк, солдатка иң кадерле кеше әнисе, аннан туган авылы, аннан кала сөйгән кызы, шушы тәртиптә әтисе, әби-бабасы һ.б. Салих авылга кайту белән сөйгән кызының өй түренә килгән икән, монысын инде һәркем үзенчә аңласын.

Бер ел гына түгел, бер гомер буе югалып торган диярсең; капкадан керүгә, үзгәрешләр көтеп, күз карашы белән кая барып бәрелергә белмәде Салих. Бар да искечә; капкалар чүгеп, ишегалды бераз

тарайган сыман, бозау ияртеп чуар тана йөргән була, алмагачлар иңгә киңәйгән, миләшләр буйга күтәрелгән, ботакларында шул ук узган елгы чыпчыклар берән-сәрән очып төшкән соңгы яфракларны кызганып утыра.

Самавыр каршысындагы рамда элек ике генә солдат рәсеме иде, инде бабакае белән әтисе янына Салихның фотосын да куйганнар.

– Салих, улым, кайтып җиттеңме? – дип, әни кеше үзенең «сабыен» кочаклап алды.

– Хәзер армиягә кайтмаска дип китү юк. – Әтисе белән кул кысыштылар.

– Урыныңа ышанычлы кеше калдырдыңмы, Салихҗан? Син постта чакта тынычлап йоклый идем! – Бабакай «бәләкәченең» чәченнән сыйпады.

Самавыр янында, әйе, юк, белмим, соңыннан сөйләрмен әле, дип утыра торгач, ун көнлек ял тагын ике сәгатькә кимеде. Салих, табын артында утырганын да онытып, кинәт кенә «смирно!»га үрә катты. Әнисе, нидер сизенеп:

– Ашыкма инде, җанашым, кояш та баемаган бит әле, – дигәч, Салих:

– Урамда баетам мин аны, – дип, ашыгып чыгып та китте.

Көннәр суынып, әрәмәлек, җәйләү-болыннарга кар сарылгач, күңел ачу урыны бер җирдә генә кала – ул да булса, ике бураны кушып салган агач клуб. Кысан дигән кеше юк, яше тулып, өйләнешүчеләрдән урын бушагач, алмашка мәктәпне тәмамлаучылар өстәлә тора. Гел шулай...

Көзнең кышка отчет бирер чагы. Көне буе пыр тузынып йөргән кар бөртекләре кичке салкында түбәләргә, бүрәнә өсләренә, агач кәүсәләренә ягылганнар. Көзнең соңгы киче...

Бу төндә уң кулың сул кулыңны табалмас дисәләр дә, Салих Дилбәрне эзләп тапты.

– Бер ел буе үпкәләшеп йөргән кеше төсле булдык, күрешеп сөйләшә алмагач... – дип башлаган иде Салих.

– Хат языштык ич...

– Хат түзә ул. Тукта, мин әйтәм, Дилбәрем көтә белә микән, кайтып күрим әле.

– Күрдеңме инде?

– Аңлавы кыен сине. Армиягә хәтле дә бик исең китмәде.

– Өйләнеп китәм дип куркыттың. Башта хезмәтеңне үтә, мин беркая да качмам. Карале, Салих, ул стройбат дигәнең берәр төзелеш конторасымы соң?

– Хәрби сер!

– Абау. Мылтык тотарга өйрәтәләрме хет? Әллә кулыгыз кирпечтән бушамыймы?

– Өлгерәбез – тегесенә дә, монысына да.

– Авырмы?

– Бер өйрәнгәч әллә ни түгел. Ике ел үтә дә китә ул. Менә безнең бабай патшага егерме биш ел хезмәт иткән әле.

– Шул тазалыгы белән йөз яшенә җитә алды да инде.

– Мин башкасын әйтергә теләгәнием, бабайны әбиебез егерме биш ел көткән... Әни әтиебезне биш ел көтеп торган, нинди еллар диген әле!.. Ә менә мине бары тик ике генә ел көтәсе.

– Кирәксә, артыграгын да көтәрбез, исән-сау кайт кына.

Шушы сүзләрдән соң ничек инде таң атканчы йөрмәскә?!

Дөрес, «таңны каршылау» дигән сүз ул җәйдән калган нәрсә. Көз көне шәфәкъ белән таң арасы эш көне кадәр. Тик бүгенге очрашуның вакытта эше юк.

Көзге төннең миче ягылмаган, бер урында гына тик басып торсаң, Дилбәрне туңдыруың бар.

Авыл чите иркен дә ул, теләсәң күпме гашыйкны да сыйдыра. Көзнең уңышы амбарларга күчеп бетте. «Кавышырбыз» дигән вәгъдәләрнең үтәлер чагы. Парлар-ярлар бер-берсенә чатнап ябышкан, тыкрык саен чәчелгәннәр, өянке күләгәсеннән дә килеп чыгалар, инеш ярында да чүкердәшәләр, авыл советы секретареның тәрәзәсе янына килеп тә чыркылдашалар. Егетләр – ярсу, кызлар – иләс-миләс.

– Йә, нихәл яшәп ятасыз, мин югында бик күңелсез булмадымы? – диде Салих, сүз уңае гына Дилбәрне шинеленең сул канатына төреп.

– Бик күңелле яшибез. Ишетмисеңмени?! Тыңлап кара әле...

Чынлап та, авыл урамы тынычлыгын җуйган, әле бер, әле икенче яктан исерекләр җыры ишетелә, кушымта рәвешендә генә сүгенүләр дә өстәлә.

– Әллә көн саен шулаймы?

– Бүген колхоз акча өләште, получка юалар. Ышанасыңмы, юкмы, кассир, бүген колхозчылар унике мең сум акча алдылар, дип әйтә ди, кичкә инде кибетебездә сигез мең сумлык аракы сатылган.

– Мин киткән арада бөтен авыл эчүгә сабышмагандыр ич?

– Туйлар вакыты. Әллә быел кияүгә чыкмаган кыз калмый да бугай инде.

– Син дә китеп барма тагын.

– Кеше ярлары кемгә кирәк?!

– Дилбәр, кайнар кеше син, баскан җиреңдә кар эри.

– Һи, җүнләп яумаган карың белән.

– Явачак, бүген көзнең соңгы төне, аннан кыш башлана. Язы да җитәр, җәе дә үтәр, бөтенләй кайтыр чагым да җитәр.

Йолдызларны болыт йотты, күк йөзе ябык, баш очында гына карлы-буранлы кыш эленеп тора сыман. Җилләр ашыгып-ашыгып авылның төньягыннан көньягына суык кучереп йөри, алар күбрәк искән саен, шинель канаты Дилбәрне ныграк кыса.

Этләр өрә дә капкалар ябыла. Дилбәр аларны барлап тора:

– Рәшидәләр капкасы... Сәрия дә кереп китте... Төне суык булгач, Тәнзиләне дә озак тотмадылар... Минзифалар йөри әле. Әниләренең рөхсәте юк икән, туйны язга калдырырга кушалар, ди, үгетли-үгетли кызны туңдырып бетерә инде. Әһә, әнә алар да хушлаштылар. Урамда без генә калдык.

Дилбәрнең соңгы сүзләре суыктан калтырабрак ишетелде. Сагынган күңел сусавын басар өчен барыбер көзнең соңгы төне генә җитмәс. Алда әле икәүләшеп аттырасы таңнар – җылы таңнар күпмедер! Авыл тирәли җиде әйләнеш ясап, Дилбәрләрнең бакча турысына килеп җиткәч, адымнар әкренәйде, әйтер сүзләр түгәрәкләнде, иреннәр җылынды... Дилбәр шинель канатыннан Салихның куен җылысын алып кереп китте.

Эт өрде, капка ябылды.

Армиягә кадәрге чак булса, Салих хәзер, бүгенге салкынны да җиңдек дип, үкчәсе пәлтә итәгенә тигәнче өй җылысына чабасы иде. Иренмәгән кызлар мәзәк өчен генә бер сынап карасыннар иде, капканың теге ягында калгач, егетләре нишлиләр микән? Ләкин Салихка килешеп бетмәс шул, ни дисәң дә, солдат кеше: үзенең кемлеген һәр адымда тоярга тиеш.

* * *

Авылның яртысын үтеп, ике урам арасындагы үзәнлеккә җиткәч, Салих кибет тәрәзәсендә шәм ялкыны кадәр генә ут шәүләсе күреп алды. Ай яктысында әлеге шаян ут кисәге, бәлки, сизелмәс тә иде, ләкин төн чем-кара, очкын гына чәчрәсә дә күрше авылдан күренерлек. Салих тукталып калды, атласаң да саграк кыланырга кирәк. Шулчак бабакаеның үгет-нәсихәтләре искә төште: «Дошман күрсәң, артыңа карап өлгер – камалышта түгелсең микән?» Юк. Тирә-як тып-тын, кеше-кара сизелми, димәк, кибет тәрәзәсендә ялт-йолт иткән нәрсә каяндыр килеп сирпелгән фонарь яктысы гына түгел. Үзәндә аулак: Салих, кибет һәм... Салихның бу очракка шикәеп карарга хакы бар.

Нишләргә? Үзәнлектән күтәрелеп иң якындагы өйгә барып әйтер идең, кем белә, бәлки, ялгыш күренгәндер. Ул чагында иртәгә үк бөтен авыл, авылга кушылып Дилбәр дә көләчәк үзеңнән.

Салих кибеткә терәп салынган такта сарайга килеп сыенды: күз-колакка чалынырлык хәрәкәт сизелми. Ул тәрәзәсез стена буйлап ишек ягына елышты. «Хәвеф каршында коралсыз калма», – ди торган иде командир. Кесәдә пәке йөртә торган гадәте юк, кул чыныктыргыч резина гына бар. «Һичьюгы, учыңа шырпы кабы кадәр генә нәрсә кыссаң да, йодрыгың биш килога катырак сугачак», – дия идең, рәхмәт, иптәш командир!..

Салих кибет ишегенә шулкадәр якынайды ки, хәтта боҗрага эленгән асылмалы йозак та беленерлек иде инде. Димәк, ишек тә бикле. Получка юган агайлардай бер сүгенеп, туган йорт җылысына ашыксаң да ярый иде дә... ләкин төненә күрә күңелнең тынгысыз һәм сизгер чагы. Әтиең нәрсә ди: «Күзеңә ышанмасаң, колагыңа таян, колагың алдаса, кулың бар...» Әйе шул, кибет эчендә сөйләшәләр! Тынып торуларын күр, Салихның аяк тавышларын ишеткәннәрдер әле.

«Ниткән кеше йөрсен бу вакытта, әйтәм ич, бу авылның этләре күп...»

Шушы минутта Салихны бабакае, әтисе, командиры да – өчесе бер булып күзәтеп торалар, киңәш бирәләр төсле: «Ышанычлы урынга урнашмыйча, дошманга үзеңне сиздермә... Кирәккә-кирәкмәскә күкрәгеңне утка куярга ашыкма, дошман синең гомерең хакына тормый ул... Үзеңне соңгы мизгелгәчә сиздермәскә тырыш, кинәт бул...»

Инеш ярына караган стена буенча китте. Башта борынга колбаса исе бәрелде, һәм ни күрсен: аяк астында каравылчы Сираҗи абзыйның эте хәрәкәтсез ята иде. Менә ни өчен өрмәгән икән ул. Агулаганнар! Ә Сираҗи абзый, этенә ышанып, бүген кайдадыр «уҗымда йөри» бугай, бар аның ул гадәте. Авыл җирендә төннәр тыныч, дия торган иде.

Кибетнең бер почмагы «авызын ачып тора», бүрәнә арасын домкрат белән каерганнар да кибет эченә юл салганнар. Моннан эчтәге сөйләшүләр дә ныграк ишетелә: «Әллә каян эзләп азапланма, шикәр капчыкларын селке, беләсең ич инде, гадәттә шунда яшерәләр алар».

Болар акча эзләп интегәләр икән. Дилбәр, сигез мең сумлык сатканнар, дигән иде, бу кадәр акчаны икәүләп эзләсәң дә таманга туры килә шул, мал белән мавыгып, домкрат янында сакта калырга онытканнар.

Домкратны кул белән генә күтәртеп булмый, монтажкасы да бардыр... Әйе, ул да урынында. Хәзер инде һөҗүмгә күчәргә вакыт.

Салих сакланып кына домкратта калган монтажканы тартып алды. Хәзер домкратка шундый итеп сугарга кирәк – бүрәнә арасына кысылган җиреннән атылып чыксын да кибет почмагы авызын япсын,

һәм бер генә сугарга, икенче тапкыр кизәнергә өлгермәссең. Кибет эчендәгеләрнең кулында ни барын кем белгән?!

Домкратның очып төшүе булды – бүрәнә арасы олы капкын төсле гөрселдәп ябылып та куйды. Кибет эчендәге ләгән шалтыраган тавышлар, сүгенүләр, стенага тибенүләр Салих өчен бер мәлгә мәзәк тоелды, рәхәтләнеп көләсе килде. Ләкин һәртөрле мәзәк кыска булырга тиеш, ә бүгенгесе озаккарак сузылырга охшый. Караклар эчтә калды. Шуннан?! Хәзер нишләргә? Ярдәм өметләнеп берәрсенә йөгереп килсәң – өйләрнең иң якын дигәне дә моннан илле метрлар бардыр. Җитмәсә, тәмле йокы вакыты, тәрәзәләрен шакып йокысыннан уятканчы, хәлне аңлатканчы... караклар әллә кай төштән чыгып сызарлар – куып тот аннан син аларны... Кычкырыргамы?.. Кем ишетсен, тәрәзәләр ике катлы – кышны көтәләр. Ишетеп уянганы да, исерекләр авазы гына дип, икенче ягына борылып ята. Аннан соң, солдат егеткә «Каравыл!» кычкырып утыру килешмәс тә, бәет чыгарулары бар. Киңәшләре колак төбендә ишетелеп торган бабакае, этисе белән командиры да әллә кая гына юкка чыккандай булды, гүя, без сине күп өйрәттек инде, үз башыңа төшкән сынауны ничегрәк үтәп чыгарсың икән, диләр.

Чара бер генә: Салих кибетне ракларны качырмыйча төне буе каравыллап чыгарга тиеш, таң аткач, берәр әмәле табылыр әле. «Командирский» сәгатьнең якты циферблатында хәзер төнге берләр тирәсе иде. Түзәргә! Көтәргә!

Салих, бүрәнәгә колагын куеп, тыңлап торды.

– Домкратны юньләп куймагансың.

– Әйтерсең лә беренче тапкыр гына, моңарчы сынатканым булдымы?

– Алайса ничек, очып чыкканмы?

– Чыкылдаган тавыш ишетелдеме?! Сугып төшерделәр аны.

– Ник соң ультиматумнары ишетелми.

– Димәк... Бер генә «калай этәч»нең эше бу. Акчаны эзлә. Безне тотардай тозак юк әле ул...

Болытлар багана башына терәлеп тукталды, җиргә кар коела башлады. Кар яуганда җил уйный да уйный инде ул. Салих, шинель якасын күтәреп, фуражкасын батырып киюдән гайре нишләсен... Аякның баш бармагы туң җиргә тиеп-тиеп ала кебек.

Кибет эчендә көндез күргән товарларны күз алдына китереп карады Салих. Авылда башка кибетләр юк: азык-төлеге дә, тимер-томыры да шушында сатыла. Караклар нәрсәгә ябышыр икән? Тәк... авылга дефицит товар бик тәтеми инде, көндездән хәтерләвенчә, балта, төртке ише кирәкле әйберләр күзгә чалынмаган иде.

Суык белән көрәшүнең бер генә чарасы кала: кибет тирәли йөгерергә... Кеше көткәндә вакыт бик әкрен үтә, диләр, йөгергәндә дә шулай икән ул. Хәлдән тайганчы йөгерергә ярамый, дошман белән якалашырлык көч тә калырга тиеш.

Әйләнә-тирәне күзәтеп утыру өчен түбәдән җайлы урын юк. Салих сарай өстенә сикереп менде, аннан түбәгә үрмәләде. Түбә текә түгел, сандык капкачы кебегрәк ябылган, калай дисәң дә, аяк шумый. Буранга охшаш нәрсә муенга кар тутыра башлаган иде, морҗаны кочаклагач, эчкә җылы керде. Салих морҗа авызына колак салды. Сөйләшәләр.

«Тик йөгерсен теге».

«Колагың тонды мәллә, түбәдә йөри бит ул! Эзлә син, эзлә. Тоз ящигын шәпләп кара, андый зур акчаны өенә алып кайтмагандыр».

«Чыгып сызу ягын карасак?»

«Курыкма, тәрәзә коткара безне. Син тап кына. Эзлә, тизрәк эзлә. Мин утны өзеп куям, ишек өстендәге звонок чәрелди күрмәсен. Эзлә, актар...»

Ашыкмыйлар, һаман эзлиләр болар.

Морҗа җылысыннан йокыга исергән иде, тәрәзә пыяласы коелган тавышка кинәт айнып китте Салих. Карлы түбә буйлап шуышып, тәрәзә турысына килде. Кайсы чыкса да өстенә сикерергә! Монтажка белән берсен сугып ексаң, икенчесе белән көч сынашуы җиңелрәк булыр.

Ләкин тәрәзәдән чыгып качуы да алай ансат кына түгел, тимер рәшәткәне каерасы бар икән әле.

«Бу нәмәрсә кәнфит ящигы ватудан башкага бармый».

«Без паники! Каеруыңны бел, кадаклап кына куелган ул».

Салих тәрәзә кырыендагы ящиклар өеменә барып төште, егылып түгел, махсус. Тегеләрнең берсе тәрәзә рәшәткәсен каерып алмакчы иде, уң кулының бармакларын монтажка яндырып алганны сизми дә калды. Нык авыртты, ахрысы, коймага кысылган кәҗә төсле кычкыра.

«Улама, бер бармак өзелгәнгә Госстрах та утыз сум гына түли. Акча эшләү җиңел түгел ул, сигез меңне бигрәк тә».

Җикеренсә дә, үз бармакларын кызганды, рәшәткәгә үрелмәде. Салих бу минутта тегеләргә психик атака ясап алды:

– Тәрәзәдән тыгыласы түгел, ябылуга күнегә торыгыз. Җинаятегезне зурайтмагыз. Әле дә тәрәзә ватканыгыз өчен бераз өстәмичә калмаслар.

Тегеләрнең чаярагы Салих сүзләреннән хурланды бугай.

– Салага бит әле син! Безне буш кул белән генә тота алмассың!
– Әйтүем дөрес булсын, тыгылсагыз, башыгызны ярам!

Караклар бер мәлгә тынып калдылар, пышын-пышын киңәшеп карадылар... Вакыт тагын да акрынрак үтә башлады. Буран да көчәя. Кеше-кара күренми. Тавыш-тын юк, этләр дә буранны өнәмичә ышыкка качтылар. Ярсудан кысып тоткангамы, тимер салкыны уч төбенә кушылды, бармаклар тимердәй булып тыңлаусызга әверелде.

– Туңасыңдыр, мә, җылынып ал, бездә запас җитәрлек, – диде елак тавышлысы һәм, Салихны үчекләгәндәй, ватык тәрәзә аркылы бер шешә аракы сузды.

Салих тәрәзә каршысына ук килеп басты:

– Сузма кулыңны, юкса...

Елак тавышлысы, фуражкалы кеше күреп, бөтенләй каушап төште.

– Мильтон ич бу!

– Тинтәк, – дип кырт кисте чаярагы, – солдат белән милиционерны бутагач...

– Икесе дә бер иш инде алар.

– Юк! Аңгыра башың белән кибет басам дип йөрисең! – Ул, йөгереп килеп дигәндәй, рәшәткәгә тибенә башлады.

Боларда хәзер курку катыш үч ярсуы, рәшәткә кубып төшсә, зурга китәсе... Салих җайлырак чакны сагалап торды да күзенә чалынган аяк табанына шундый итеп китереп сукты, әллә рәшәткә тимереннән, әллә чаярак дигәненең күзеннән очкыннар очты.

– Ярый, безне җиңдең дә ди. Акчалар әрәм була бит, эзләп тапкач кына... Телисеңме, сиңа да өлеш чыгарабыз... Сигез өчкә дә бүленә ул.

– Миңа солдат акчасы да бик җиткән, урламасам да...

– Кем әйтә аны урлау дип, кешенеке түгел, хөкүмәткә тапшырылмаган, так што иясез хәзинә бу.

– Молчать!!! – Аптырагач кычкырды инде Салих, юкса бөтенләй үз ишләре кебек сөйләшә башладылар.

«Каптык... Эчик хет рәхәтләнеп. Акчаларны аска җәй. Соңгы бәйрәмебез булсын...»

Алар бүтән тыпырчынмадылар. Иректәге соңгы сәгатьләрендә күңел ачып калырга исәпләре... Хәер, нык бүрәнә стена, рәшәткәле тәрәзә, бикле ишекне исәпкә алганда, иректә дип әйтеп булмый иде инде боларны.

Тагын берәр сәгатьтән эш кешесе уяныр чак җитә. Салкын буран гына менә, караклар белән бер сүзгә килгәндәй, Салихны өшетеп посттан алмакчы. Карлы җил туп-туры тәнгә үтеп керә сыман, әйтерсең лә өстә бер кием дә юк. Тез буыннары бөгелеп төшәргә тора, кулдагы монтажка хәлсез бармаклардан котылырга теләп җиргә таба шуыша. Хәрәкәт, бары тик хәрәкәт кенә коткара ала, йөгер, сикер, бие, чүгәләп-чүгәләп ал, туктама гына!..

Ә караклар күңел ача, кызганыч тавышларын яшерергә тырышып, акырып-бакырып җыр сузалар...

Көзнең соңгы төнендә шул,
Мал табасы көнемдә шул,
Төштә күрсәң, уянырсың,
Уяналмыйм өнемдә шул...

Туктарга исәпләре дә юк.

Ниһаять, кибетнең рәшәткәле тәрәзәсеннән яңгыраган бозык җыр авазына фермага эшкә дип чыккан авылдашлар җыела башлады...

*** * ***

Үпкәсенә салкын тидергән кешене ун гына көндә дәвалап өлгерә алмыйлар икән. Салихның отпускасын озайттылар.

Дилбәр көн дә больницага килә, авыл белән больница арасын өйләре белән клуб арасына да күрми. Очрашуларының берсендә Салих: «Кыш дип тормабыз, больницадан чыгу белән бергә таң аттырырбыз әле», – дигән иде. Дилбәр каршы дәшмәде: «Түлке җылырак киенеп чыгарсын», – дип кенә куйды.

Салих стройбатка «Батырлык өчен» медален тагып килде. Хәер, бу турыда газетага да язып чыгарлар әле, менә күрерсез...

# САНСЫЗ ФИРГАВЕН

## I

Бу хикәя язылган арада Җир шарында яшәргә теләүчеләр саны дүрт миллиард ярым кешегә җитте. Аларның бер миллиарды мин уйлап чыгармаган сәбәпләр аркасында эш урыннарын алыштыру хакында хыялланып йөрде.

Бер эшсез профессор әйтә, имеш, иренмичә эзләсәң, планетабызда һәркемнең көзгедәге сурәте кебек охшаш тагын ике ише табылыр, ди. Димәк, нәкъ минем кебек тагын ике кеше бар дигән сүз!..

Берсен беләм мин аның – Мәскәү Кирмәненең урам ягында, ягъни Кызыл Мәйданга салынган пирамида эчендә ята ул. Һәм ул Кызыл фиргавен миңа шултиклем охшаган ки, хәтта әтиемне Илья, әниемне Мария дип үртәп йөртәләр иде. Буем кечкенә, баш пеләш, танышларны күргән саен уң кулым каш өстендә кагына башлый, ә «р» авазына бөтенләй исем китми – сөйләшкәндә әллә бар, әллә юк ул минем өчен. Хатын-кызлар белән мавыкмыйм... Шушы охшашлыкларның ярдәме тиде – пионер яшемдә үк мине лектор иттеләр, студентлар театрында юлбашчы ролен башкарыр өчен генә өстәмә стипендия түләп тордылар. Диплом алу белән охшашымның исемен йөрткән райкомга инструктор итеп билгеләделәр. Башыма гел кепка киям, ике кулым жилет түшендә. Таныклык, пропуск, паспорт ише дукаментларга фотографияне кызыл акчалардан кисеп кенә ябыштырам. Бер көйгә эшләп торам, артык тырышмыйм – чөнки ярамый, миңа да совнарком председателе булырга димәгән, калын чәчле, куе кашлы аек башлыларны үстерсеннәр әнә...

Ә беркөнне безнең райкомны эшкә кертмәделәр. Хәтта кабинетымда онытылып калган кепкамны да бирмәделәр – партия мөлкәте дигән исемлеккә теркәгәннәр.

Эшсез дигән яңа статус өчен ике айлык пособие алырга килгәндә миңа тиз арада йортлар идарәсенә кереп чыгарга куштылар, анда урам себерүче урыны бушаган, ләкин кичәге коммунист икәнлегеңне берүк сиздерә күрмә, диделәр. «Эшкә» дигән сүздән эчкә җылы керде. Мондый сөенечле хәбәрне юарга кирәк, мин әйтәм...

Бүген пролетарийларның өчәрләп-өчәрләп берләшә торган көне – заводларда узган квартал өчен хезмәт хакы өләшкәннәр. Муенымдагы галстукны салып тиз генә кесәгә яшердем – рюмочныйда бик өнәп бетермиләр аны. Тыпырдап торган чиратның койрыгына бастым...

Ишегалдында өч борын тәмам туганлашып, аерылыша алмыйча торабыз. Аракының арзан чагын сагынып башланган сүз шәрә кендекле кызлар тирәсенрәк җитеп килгәндә, капкадан шадра капитан килеп керде... Үз балаларын яраткандай аркабыздан сөеп, өчебезне дә тигез күреп, калай савытлы машинага төяделәр.

Бүлеккә китереп бушаткач мин чиратымны югалттым. Шадра капитан детсад баласы урынына кулымнан җитәкләп түрдәге түрәнең аерым бүлмәсенә алып керде. Керсәм – бөтен коньяк шешәләре бер күчкә өелгән диярсең – йолдызлы начальниклар утыра. Мине күргәч башта сагайдылар, аннан соң үзара пышылдаштылар. Туган елымның 1870 ел түгеллеген ишеткәч, ышанмыйчарак тордылар. Ә инде Петроградта бөтенләй булганым юк, дигәч, күмәкләшеп егыла-егыла көлделәр. Татар икәнемне белгәч, шым булдылар. Туганнарча сорау ала башладылар.

– Айныткычка җибәрикме? Әллә эш урынына протоколмы?

– Мин эшсез бит әле.

– Эшсез дисең, ә үзеңнең кесәң тулы акча!

– Пособие ул, эшсезлек өчен, – дидем мин, ярамаган статьялардан арынырга теләп, – эш белештем инде, әйе, белештем. Урам себерәчәкмен...

– Урам себерүче?! Юләр! Синең бу башың белән акча күрәргә була хәзер. Күптән пеләшме?

– 1991 елның егерме беренче августыннан...

– Горурлан! Без синең үзеңә лаек эш таптык!

– Инструктор итеп җибәрсәгез, бармыйм – мин беспартийный.

– Ерунда! Без сине һәйкәл итеп куябыз! Ирек мәйданына!

– Анда берәү бар ич инде.

– Урлаганнар шул, әле яңа гына хәбәр иттеләр, күтәреп киткәннәр. Үч иткәндәй, иртәгә мәйданда митинг – халык суверенитет таләп итә. Әгәр һәйкәлнең юклыгын белсәләрме – өстәгеләрнең йолдызларын чүпләячәкләр! – Һәм сорау алучым «өстәгеләр» дигәндә погон астыннан үсеп чыккан кулын шундый итеп күтәрде ки, хәтта имән бармагы түшәмгә тия язды...

Мин көзге каршына килеп бастым. Кулны алга суздым, башымны югары тотып күзләремне җәһәннәмгә төбәдем. Охшаган, кәнишне...

– Охшамаган ич, – дигән булам үзем, юри генә. – Мыегым да кара, пеләшем дә алай ук зур түгел, буем кыскарак, аягым кәкре...

– Пеләшеңне зурайтыбрак кырабыз. Ә мыегыңны тотып карамаслар әле. Әллә син андагы халыкның һәйкәлгә исе китә дип беләсеңме?! Сине без таш өсте буш тормасын өчен генә бастырып куябыз. Һәйкәл каракларын тоткач алыштырырбыз.

– Кулын обком бинасына таба сузып тора идеме әле ул?

– Юк, кулыңны Черек күлгә таба сузарсың, ә обкомга артың белән борылып бас, һәйкәле шулай салынган иде. Килештекме?!

– Юк! Оклад мәсьәләсен сөйләшмәдек ич әле.

Йолдызлар тынып калды. Тимерчыбык тыгылган стаканда чәйнең шашып кайнавы гына ишетелә.

– Бер көн өчен инде...

– Бер көн эчендә нинди җинаятьне ачканыгыз бар соң әле сезнең? Иртәгә митинг башланса, һәйкәл эзләп йөрерлек рәтегез калмас. Так што совнарком председателе окладын куегыз да, вәссәлам! Ник әллә шунда ел буе эзләмисез һәйкәлегезне. Теләмәсәгез, ихтыярыгыз, мин барыбер Мәскәүгә китәргә җыенып тора идем әле. Анда һәйкәлләр дә күбрәк, акчасы да мулрак, мавзолей хакында да сөйләшеп була, ди...

– Ярар, ярар, сиңа түләмибез дигән кеше юк бит әле.

Килештек, антлар бирештек, эш урынын кабул итү-тапшыру турында журналлар ачтык. Түбәсендә ут уйнатып торган машина белән тупикка кадәр озатып куйдылар. Хатынга иртән-иртүк уятырга кушып мендәргә капландым, яңа эш хакында ләм-мим. Юкса ул, авансы ал, дип аптырата башлый.

## II

Уяну белән ярты чуен итсез борчак боткасын ялтыраттым. Чәй эчмәдем – юк-бар йомыш белән һәйкәлдән төшеп-менеп йөрү килешмәс. Эш җиңеләйсен дип, шадра капитан өйрәткәнчә, уң кулымны күтәреп гипска катыргач, хатын караватыннан тормаган килеш һушын югалтты. Кичә алган эшсезлек акчасын түшенә куйгач кына кашлары тартыша башлады җимешемнең.

Аллага тапшырып, таш нигезгә менеп бастым – күңелемне шундук бөеклек тантанасы биләп алды. Йөрәгемдә җыр ташый... Бер горурлык хисе яши миндә... Менә без дә үсеп җиттек, әни... Сөясеңме, дип ник сорыйсың?.. Торам һәйкәл булып! Август аеның мәкерле кояшы шәһәр эченә кермәгән әле. Кичәге бәйрәм төненең калдык-постык йолдызлары сүнәргә азаплана. Үзәктән искән җилдә суверен болытлар безнең Иделдән су ташый. Торам һәйкәл булып! Акыллы уйларга чумып! Тәмәке кабыздым, сул куллап кына, уңы каткан инде.

Тәмәкемне күкрәк киереп бер суырдым микән, килә берәү – зәңгәр бәрхеттән тегелгән кәчтүм-чалбар кигән, муенында алтын җепләр йөгертелгән тар кара галстук, аягында ялтыравык лаклы кара туфли, кулында скрипка футляры. Тәки уйнап минем аяк төбендә хәер сорашып утырыр микән? Ичмасам, борчак боткасы эчне көйдерә, митинг башланганчы берәр стакан газлы су эчеп килермен дигән идем. Бу кеше җиргә куеп футлярын ачты һәм аннан җыелма саплы урам себеркесе чыгарды! Үзе бераз алышынган дип әйтимме – минем белән сөйләшә.

– Дөньяда күпме пеләш бар – берсе дә революция дип җенләнми. Нинди зыяны тиде соң сиңа ул капиталистларның?! Ник безнең илдә тугансыңдыр син?! Башка дворниклар әнә яфрак кына себерә, ә миңа яфракка караганда партбилетлары күбрәк. Элегрәк хет иртән килүгә бәйләм-бәйләм чәчәк җыеп ала торган идек, хәзер анысы да юк – нәрсәгә дип тоталардыр карачкыңны?! Кызык итәм бүген, җыештырмыйм, күрсеннәр утопистларың! Ну фатир аласы булмаса...

Һәм ул барыбер түзмәде – аягым астындагы яфрак катыш билетларны борын төбемә китереп өйде. Ачуым чыкты, күч өстенә тәмәкемне ташладым.

– Җебегән, – дидем мин, тавышымны күктән төшереп, – тәмуггагыларның гөнаһын оҗмахтагыларга сылтама!

– Әй Аллам, шырпы да ыргыт әле, пожалысты, – дип, күккә табынды себеркеле скрипачым, сүнгән төпчегемне имезлектәй суыра-суыра... Күктән шырпы төшмәгәч, ул ут эзләп китеп барды һәм шуннан әйләнеп кайтмады.

Ике диннән коры калган шәһәрдә һәйкәл булулары җиңел түгел икән. Мин моңа тора-бара гел ныграк ышандым...

Көн ачылышы мәйданга ыгы-зыгы өстәде. Башта машиналар аяк астындагы җирне чылатырга су сипте, бәби тыкрыкларны ябарга тимер киртәләр ташыды, алҗыган әләмнәр китертелде, куян тавышын бүренекедәй итәрлек көчәйткеч аппаратуралар бушатылды.

Аннан соң ач торучы көрәшчеләрне чыгарып куйдылар. Митингка халык бик тиз җыелды, әйтерсең лә алар шушы тирәдәге бер ишегалдында гына төн кичергәннәр дә сәгатьләре җиткәч тагын чыгып басканнар. Иртәнге мәлдә мине һәм мәйданны сакларга дип куелган ярым хәрбиләр белән митингтагылар саны тигезләшкән иде. Ә инде бункер эчендә сессия башлангач, эчке эшләрнең бөтен резервы тышка чыкты. Мин кыйбламны үзгәрттем – гипслы кулымны микрофон ягына төбәп Черек күлгә артым белән борылып бастым.

Митинг кинәт башланып китте. Ораторны – оратор, милләтне – милләт, әләмне әләм алыштырды. Чыдасын колак, түзсен тел...

«Иптәшләр, әфәнделәр!!! Бүген дә кояш чыкмаячак, чөнки аяз күгебезне һаман империя байрагы каплап тора. Без дүрт йөз ел буе Мәскәүгә алимент түләдек. Азатлык дигәннәре талонга гына. Балтыйк буе республикалары талоннарын атаваривать итте инде. Гафу итегез, «атаваривать» дигән сүзнең татарчасы юк, урыслар уйлап тапкан аны. Азатлыктан курыкмагыз! Күрми күргән кешегә генә

куркыныч тоела ул, бер ияләшсәң, аның берние дә юк. Ач булырбыз, ялангач калырбыз, әмма азатлыкны яуларбыз... Азатлыкка килеп җиттек инде, әфәнделәр! Азатлык! Азатлык! Азатлык! Митингны ачык дип белдерәм. Татарны күпме печәргә була инде, әфәнделәр?!»

Урамдагыларга кушылып, мин дә өч тапкыр «Азатлык!» дип кычкырдым. Пьедестал биек минем, ишетмәгәннәрдер әле. Бөтен кеше кычкыра монда.

«Туганнар! Безгә өч президент кирәкми, икесе җитә. Безнең җөмһүрият мөстәкыйль яши ала. Башкаларга караганда хәлебез авыррак... КамАЗны сатып бераз акция эшләдек. «Акция» – татар сүзе ул, туганнар, ягъни мишәрчә «акца»-акча сүзеннән алынган. АЭСны сүтеп бераз төзелеш материаллары этмәлләдек, нефтебез агып бетте дип тә пошынмыйбыз – җир астына күмелгән торбалары үзебезгә калды. Алабуга заводында машина чыгара башласак, металлга ярап тора ул безгә. Мөмкинлекләр бар әле... Мари, чуваш, мордва, удмурт, башкорт дәүләтләре белән чиктәш авылларның көтүләрен суеп тапшырсак, партиянең мөлкәтен конфискацияләсәк, депутатларның окладын киссәк, Кабан күле төбендәге алтынны эзләп тапсак – финанс хәлләребез яхшырыр. Алдагы кышны исән-имин чыгарбыз упшым... Аллага шөкер, чират торырга иренмәгән кешегә кибетләребездә ит тә, май да җитәрлек. Америка татарларына үзебезгә кайтыр өчен рөхсәт бар, кайтучы гына юк әлегә...»

Урланган һәйкәлне тапсалар да, көндез мине алмаштыра алмаслар инде. Митингның таралганын көтәрләр. Ә митинг кызганнан-кыза бара... Олы микрофонны вак микрофоннар сырып алды. Микрофон-мегофон җитмәгәннәре болай гына кычкыра. Тегендә хор бәхәсләшә, монда трио, анда дуэт, кайдадыр солисткалар акыра.

«Яшәсен анархия! Бөтен байракларны бергә кушсаң – кара төс чыга. Автономияләрне союздаш итәргә, союздашларны союздан чыгарырга!»

«Мөселман кардәшләр! Дуңгыз фермаларын ябыгыз! Бөтен ирләргә никах ирег! Маржа хатыннарыгызны аерыгыз!»

«Яшәсен КПССка дан! Ленин идеяләре мәңгелек! Капитализм төзүчеләрнең мораль кодексы юк!»

«Яшәсен демократия! Илдә 1917 елгы ситуация. Россия 1919 елгы чолганышта калып бара. Алда 21 нче елгы ялгышны кабатламаска! 37 нче елда кергәннәрнең хәзер илле ел партстажы бар. 41–45 нче елда кырылган самолетлары-танклары өчен дустыбыз Германиягә контрибуция түләргә! Тарих 85 нче елдан башлана. Безгә тагын 500 көн кирәк. 7 плюс 1 ничә белән бетте? 9 плюс 1 нең җавабы кайда? 15 не 15 кә бүлгәч ничә кала? 2 апрель 1 апрельне өшкерде...»

«Шалишь! Беләбез демократларны! Милли мәсьәлә турында сүз кузгалса, эче киткән мәктәп баласы шикелле 93 демократ сессия залыннан чыга да китә, чыга да китә. Казан трамваенда утырып йөргән Рәсәй патшасы Иван Грозный нәселеннән! Безгә бердәмлек җитми. Җөмһүриятебезнең яшь партияләре байракларны еш алыштыра. Һава торышына карап үзгәрә торган япон материалларын гына күтәрәсе калды инде. Ә безнең кибетләрдә байрак тегәрлек тә яшел чүпрәк юк. Халыкны ыштансыз калдырдылар. Мә сиңа алтмыш тәңкә – бир миңа меңне. Эт көне. Этләр белән гомер-гомергә тәҗрибә үткәргәннәр. Павловлар әйтә, имеш, ач эткә ризык бирер алдыннан ут яндырып өйрәтсәң, аның селәгәе ага башлый, ди. Шартлы рефлекс, ягъни мәсәлән. Ахыр чиктә ризык бирмичә ут кына яндырсаң да селәгәе ага, ди, этнең. Павловлар теориясенең дөреслеген тикшерер өчен хәзер бөтенебез дә зәңгәр ут яктысына карап утырабыз. Тигезлек юк, тигезлек мунчада гына була, мөхтәрәм милләттәшләр, чөнки мунчада демократлар да ялангач...»

Көз озын килде быел. Аяк астында коелган яфраклар уйнашмаса, тәки җәй дип белер идең. Августның егермеләрендә үк саубуллашып йокыга талган чебеннәр яңадан уянып мәйдандагы эчке эшлеләрнең күн итек балтыры тирәсендә бөтерелә. Микрофон тирәсендәге кансыз халыкны черки талый. Шөкер, миңа черки каныкмый, алар да һәйкәл дип уйлыйлар, ахрысы.

Кичкә таба акча эшләүләре кыенлышты... Кулның гипсы күтәргесез авырайды. Аяк арыды, алҗыган гәүдәмне әле бер, әле икенче аягыма авыштырып басам. Мәйдандагыларның таралырга исәбе юк. Әле дә ярый бәхетем бар икән – сессия йокларга кайтып китте һәм ораторлар комарланып аларга иярде, көне буена яңгыраган чыгышларның кыскача тезисларын депутатлар күз алдыннан таралганчы кычкырып бардылар.

Ирек мәйданы умарта күче чыгып качкан оя кебек тынып калды. Мин җиргә сикереп төштем. Шадра капитан килгәнче шушы тирәдә йөреп торам. Кекин ашханәсенә кереп тамак ялгап чыктым, Тинчурин театры буфетына кереп кайнар кофе эчтем – арыганнарым онытылды. Эш урыныма кире килеп, һәйкәл төбендәге горзеленхоз түтәленә сузылып яттым. Шадра капитаның килгәндә йоклап ятма, хезмәт хакыңны кисәр дип әйтергә теләгәндәй, черкиләр ябырылды. Төнге сменада эшләүләре җиңелрәк инде анысы... Төнлә белән һәйкәлләрнең бөтенләй кирәге юк, теләсәң бас, теләсәң ял итеп утыр, теләсәң пьедесталыңда ятып йокла...

Ятам шулай ял итеп, күккә карап, йолдызлар үзләрен санарга ирек бирми – җем-җем килә. Баш астымда өченче кат чабылганнан соң тырпаеп калган печән камылы. Бер кулым күкрәктә, гипслысы – читтә ята... Кинәт борын төбемдә өч пар «Спартак» ботинкасы килеп туктады. Күземне ярым ачып

ярыктан гына күзәтеп ятам тегеләрне: өчесенә бер калфак, ике чалбар, бер трико ыштан, бер күлмәк, бер футболка, бер майка...

– Бәреп төшергәннәр, – диде күлмәксезе.

– Монысын кечкенәрәк иткәннәр, – диде чалбарсызы, мине адымлап үлчәп, – безнең хәтлек кенә бу, култыклап алабыз да кеше итеп апкайтабыз.

– Нишләп җәяүләп? Таныйлар бит аны, – диде кепкалысы. – Тегесе шикелле самосвалга ыргытабыз. Син, – диде ул, күлмәк кигәнгә ымлап, – саклап тор, без хәзер машинаны алып киләбез.

Күлмәклесе үзе генә калгач, иптәшләренә эшне җиңеләйтергә теләпме, мине аягымнан тотып юл читенәрәк сөйрәмәкче иде. Кеше-фәлән күзәтеп тормый микән дип як-ягына карануы булды, минем сикереп торып гипслы кулым белән иңсәсенә тондыруым булды... Ул «үтерәләр!» дип бер якка, мин мыштым гына икенче якка тайдым. Куак аллеяларын чыгуга, пинжәгемне салып урталай бөкләгән килеш гипслы кулыма элдем дә берни белмәгәндәй, тамашаның дәвамын карарга дип янә һәйкәл янына килдем. Килсәм – юл читендә «ГАЗ» самосвалы, номеры хәтердә калырлык. Ә һәйкәл төбендә, шадра капитанга теге өч адәм... Юк, икесе дәшми, күлмәк кигәне генә тотлыга-тотлыга аңлатма бирә:

– Аны бәреп төшергәннәр, мин чәчәк бәйләме китергән идем. Кемдер арттан килеп күсәк белән томырды да пеләшбашны сөйрәп китте.

Мине күрүгә, шадра капитан шаркылдап көлмичә чак түзеп калды.

– Ярар, – диде ул, – бу агайлардан тизрәк котылырга теләп, – төн озын әле, яңасын койдырырбыз.

– Алайса, сез аны көмештән ясагыз, – диде күлмәкле, – күтәреп китмәслек булсын. Юкса бүгенгесе калай гына иде.

– Каян беләсең, – диде шадра капитан, күлмәкледән мәзәк ишетергә теләгәндәй елмаеп.

– Белмәскә, шалтыр-шолтыр өстерәп киттеләр бит аны.

Өйгә кайтыр алдыннан бүлеккә кереп постны тапшыру турында журналга кул куясы бар иде әле. Шадра капитан минем алда гаепле кеше кебек юл буе сөйләшмәде. Беләм инде гаебен – минем калай игезәкне тапмаганнар. Тиз генә тапмаслар да! Мин исә теге машина хакында ләм-мим... Әйтмим! Авырлыкка авыр булса да, төшемле эшне тиз генә югалтасым килми. Хәзерге заманда җиңел эш юк. Менә, митинглар беткәч, бераз отпускы алырмын. Сессияләр, митинглар юк чагында минем дә кирәгем юк. Теләсәм – һәйкәл булырмын, теләсәм – кеше. Тыныч көндә әллә бар син, әллә юк. Бик ялыктырса инде, эш урынымны алыштырырмын, һәйкәлне түгел, урынын гына. Минем чырайга эш бетәсе юк, әйтәм ич, безнең калада гына да алтмышлап игезәк сыным бар минем. Теләсәм, башка шәһәргә дә күчеп китәм, валютага кызыксаң, элеккеге дус дәүләтләргә чыгып керергә дә була. Кыскасы, мин үз гомеремә җитәрлек эш табам. Ә сез, үз җаегызны үзегез карагыз инде, иптәшләр, товарищлар, милләттәшләр, якташлар...

**III**

Бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы кайдадыр «себерелеп» кайткач, җитмәсә, табындагы ризыкка ис китмәслек итеп ашап та кайткач, хатын иртә белән дә дәшмәде. Бик теләсә, ул унбишәр көн буе сөйләшмичә түзә ала. Артыграк та түзәр иде – айга ике тапкыр коры зарплата апкайтып өйрәттем үзен. Учына салган акчаны бер кат санап чыккач, сораулары күбәя аның.

Коры-сары белән тамак ялгап көнозын аяк өсте торырга чыгып киттем, әмма хатынга сер бирмәдем. Мин Ирек мәйданында һәйкәл булып эшлим дип әйтеп кара син аңа... Өйдә телефон бар, тота да психушкага шылтырата. Беркөнне мин аңа ялгыш Надюша дип дәшкән идем... бәбәген өшегән бәрәңге шәе акайтып, тизрәк телефонга барып ябышты. Ул бер нульне җыйганчы шнурны кисеп кенә котылдым.

Хатын белән иртә таңнан заочно әрләшеп йөреп эшемә соңга калганмын. Килсәм, митинг инде башланган, мине көтеп өмете өзелгән шадра капитан мәрмәр пьедесталга үзе менеп баскан. Ичмасам, фуражкасын да салмаган, бөегем. Килбәтен күр син аның – килештерә бит тәки. Кулын да дөрес итеп Европа ягына сузган, учын гына өскә таба каратып тоткан, хәерсез... Мине күргәч, сөенеченнән авып кына төште теге.

– Кайда йөрисең син?! Прогульщик! – ди бу, мине һәйкәлгә таба этә-төртә. Мәйдан халык белән тулы. Бар инде, кеше кара күргәнче мен тизрәк куначаңа.

– Хезмәт хакымны арттырыгыз, аннан соң менәм. Совнарком председателе окладына хатын риза түгел, – дигән булам һәм үзем ашыкмыйча гына тәмәке кабызам. – Даешь президент окладын, митингка барам да фаш ителәм.

– Мин сине хәзер менә шушы ОМОН таягы белән үзем фаш итәм!

– Алайга китсә, мин баскан урынымда унике сәгатьлек байкот ясыйм! Мин... мин... мин, шагыйрьләргә кушылып, ачлык игълан итәм, белдеңме?!

– Ну, ярар инде, ярар, син дигәнчә булсын. Үҗәт! Бу хәтлек һәйкәлеңә охшасаң да охшарсың икән. Мәйдандагы авазлар боза сине. Бар инде тизрәк менеп бас!

– Менеп басам, ләкин килешү ышанычлырак булсын өчен төш вакытында ярты окладны кесәмә аванс итеп саласыз, юкса...

– Ярар, ярар, дидем ич инде, бар!

Иренеп кенә менеп бастым. Эшлисе килми бүген, әллә больничный аласы инде, таныш логопедым да бар, яза да бирә больничныйны. Белмим, аванс алгач кына үзгәрмәсәм...

Бик тавышлы мәйдан бу. Җитмеш ел буе халыкны шушында җыеп ура кычкырттылар, инде җиде ел буе кычкыртып сүгәләр. Кайда нинди яңалык ишетелсә, шушы мәйданга йөгереп киләләр. Көн саен мәйданга йөреп, митингдашлар инде тәмам туганлашып беткәннәр, килү белән үзара кул бирешеп күрешеп чыгалар.

Митинг дәвам итте.

«Яшәсен гуманизм! Радикаллар партиясенә язылыгыз! Бер еллык взносы нибарысы 25 сум. Курыкмагыз, мондый взнос белән безнең партия бервакытта да рулевой була алмаячак. Барлык илләрнең люмпен-пролетарийлары, берләшегез! Демократларга иярмәгез, центристларга ышанмагыз, коммунистларны идән астыннан чыгармагыз, либералларга таянмагыз, милләтчеләрне тыңламагыз!.. Без һәрвакыт сезнең белән!»

«Бөтен влач сельсоветларга! Базары – шәһәргә! Фермерлар сезне ач-ялангач итмәс. Җир барыбызга да җитәрлек. Без күрше дәүләтләр белән горизонталь мөнәсәбәттә. Кулга тигән байлыкны вертикаль файдаланмыйк. Җир барыбызга да җитәрлек – көрәк калынлыгы туфрагы арендаторларга, метр ярым тирәнлегендәге катламы «Водоканал»га, йөз метргача тирәнлеге карьерларга, ә инде мең метрдан соңгы катламнары нефтяникларга. Эш сүзенең аваздашлары күбәйде, ә авылда кызу урак өстендә авызга бер кашык су салырлык та кеше юк! Менә мин әле дә янып-көеп авылдан килдем. Шәһәрегездә җитмеш сырахәнә бар – әйтергә оят, шушы көнгә кадәр сыра сөючеләр партиясе төзи алмыйсыз...»

Обком бинасына альтернатива итеп салынган Опера театры янына егерме «Икарус» килеп туктады. Күрсәгез икән!.. Чулман аръягындагы тугандаш шәһәрләрдән яшь гвардиячеләр килгән! Аларны иллеләп вездеходка төялгән сенат укчылары елмаеп каршы алды. Яшь гвардиячеләр «Икарус»лардан таш бушаттылар, аларга җавап итеп укчылар калкан тезде. Моңарчы гамьсез генә сагыз чәйнәп фәрман көтеп йөргән омончылар күз ачып йомганчы тезелешеп тимер бәдәннәрен киереп басты. Мин камалышта калдым. Гипслы кулымны төшереп хәл җыям, кирәге чыгар. Дулкынланудан муеным – якага, күкрәгем – жилетка, аякларым туфлиемә сыймый башлады. Мин көрәшкә әзер, ләкин баррикаданың кайсы ягына басарга?! Теге якка чыгар идем – яшерен-батырын түгел, Рәсәй министрына буйсына торган эчке эшләрдән зарплата алам, уң якта калсам, Иҗтимагый үзәкнең күзенә ничек күренермен?! Икеләнеп торуымны сизделәрме – яшь гвардиячеләр иң беренче ташны миңа томырды. Ну, җегетләр, башны иеп калмасам, пеләшемә кутыр чыгаралар иде. Болайга китсә, иманымны укыталар минем, төшеп качарга кирәк лутчы исән чакта. Юлбашчылар өчен баш белән таш чүпләп торыр хәл юк монда... Сикереп төшәм дигәндә генә шадра капитан килеп җитте, ул үзенә кассирша кызны иярткән.

– Син, ярты получканы алдан ук биреп куешлы дигән идең. Пожалысты, менә монда гипслы кулыңны куй.

– Вакытын белеп кенә йөрисез инде түлке, – дидем мин, авыр кулым белән ведомостька имза куеп.

Кассирша кыз үрелеп кенә минем кесәгә акча төргәге салмакчы иде – буе җитмәде. Җиңел сөякле икән үзе, яныма сикереп менде дә шалт кесәгә акчаны! Янәдән җиргә сикерергә өлгермәде... Хатын сөйрәп төшерде тегене... Ну, шадра капитан да югалып кала торганнардан түгел икән: синең ишеләрне генә күргән без дигәндәй, минем хатынны читкә селтәп ыргытты... Әле ярый мәйданның бездә гаме юк, халык яшь гвардиячеләрдән мажара көтә. Мин дә озак уйлап тормыйм – хатынга ярдәмгә дип аяк астыма сикерәм. Ә хатыным шуны гына көткән икән – эләктереп алып, сарык кыркыгандай, муенымны бот арасына кыстырып, барлы-юклы чәчемне йолкып, пеләшемне зурайта башлады.

Безнең илдә кичә генә цензураны бетерделәр. Шулай да хатынның миңа атап әйткән башка сүзләрен кабатлый алмыйм. Башны хатынның бот арасыннан көчкә тартып алдым. Шул шатлыктан патетик рух белән укчылар боҗрасын өзеп, яшь гвардиячеләр ягына чыгып бастым. Хатын минем арттан! Кемлегемне онытканмын, карт юләр, яшьләр мине шундук уң якка очыртып чыгардылар. Хатын яшь гвардиячеләр ягында калды, калды гынамы – «Икарус»ларга Киндер карьерыннан төялгән кырлы-кырлы ташларны минем өскә томыра башлады, аннан күреп башка гвардиячеләр дә пролетариат коралын укчылар өстенә яудырдылар. Китте атыш, китте дөмбәсләү, китте куышу... Кем кемне кулга алырга белми, чөнки граждански киенгән кешеләрнең бик күбесе үзләре кулга алучылар булып чыкты. Мәйданны сирәгәйтер өчен сул якны калай савытлы машиналарга төяп ташыдылар.

Мин, ыгы-зыгыдан файдаланып, әкрен генә үземнең эш урыныма менеп бастым. Нишлисең бит, бу болгавыр заманда һәркемнең үз эше... Хатын юкка чыкты – аны да калай машинага төяделәр, ахрысы, ичмасам, мин эшне бетергәнче генә тотсалар ярар иде.

Кайтып кесәдәге акчаны биргәч, бәхилләттем мин аны.

Мәйдандагы чуалыш митингка дәрт өстәде. Аз гына фикере булган кешенең дә хәзер микрофонга барып җитәрдәй сабырлыгы юк – кайда баскан, шунда сөйли... Алла каргаган мәйдан булды бу! Иртәгесе көн минем өчен ни белән бетәр? Җае килүгә, эшне алыштырырга кирәк, эшне түгел инде, урынны, дип уйлап бетерүемә, шадра капитан килеп җитте. Кыяфәте – туктаусыз ике машина утын төягән диярсең!

– Бүген табабыз синең һәйкәлне. – Ул аяк чолгавы хәтлек кульяулык белән бит-кулларын сөртте, формасын тәртипкә китерде. – Тапкан кешегә ике президент оклады күләмендә премия игълан иттек.

– Кемгә кирәге бар ул акчаның! Сез лутчы төсле телевизор бирегез, – дидем мин, өемдәге кылка «Рекорд»ымны искә төшереп.

– Телевизор?! Ә нишләп тузан суырткыч түгел?

– Ул да ярый. Холодильник белән кер юу машинасы бирсәгез дә риза.

– Тапсыннар гына, ни теләсәләр, шуны бирербез.

– Алайса, үзем табам һәйкәлне! Миңа комачаулама! Әнә олы микрофонга кил дә демократлар исеменнән берәр нотык сөйлә. Калганы минем эш.

«Мөхтәрәм милләттәшләр! Җөмһүриятебезнең статусын тагын да күтәрү өчен тәхет белән идарә итүгә күчәргә һәм беренче королева итеп сайлау өчен үзебезнең Ана төрекне, айлар буе ач торып та үлә алмаган чын совет гражданкасын – депутат...»

Микрофонны шадра капитан йолкып алды.

«Без – бүленмәс Россия!!! Татарлар, уйланыгыз, сезне өйдә марҗа хатыннарыгыз көтә! Коммунистлар коткысына бирелмәгез!»

«Коммунизмга юл юк! Социализм үз-үзен акламады! Капитализм безне күчтәнәчләр белән сатып алмакчы! Африка илләре белән киңәшеп карарга кирәк!»

«Дары заводларын ябарга!»

«Нефтьне туктатырга!»

«Болыннарны су астыннан чыгарырга!»

«Бөтен һәйкәлләрне җыеп алырга, ура!!!»

«Демонтаж! Демонтаж! Демонтаж!!!»

Тагын кич җитте. Эш сәгатем бетәргә ике сәгать чамасы вакыт калды. Мәйдандагы караңгылыктан коты алынгандай, баганадагы лампалар һәр куак төбен тикшерергә теләп яктырта. Шунысы гаҗәп: миңа бүген чәчәкләр китерделәр, дөрес, кемнәрдер аны җыеп та алып китте. Киң чалбарлы малайлар, пумаланы буяуга манып, минем нигезгә тыелган сүзләрнең исемлеген теркәде. Көн саен шулай. Бу мәйданның этләренә чаклы аполитичный – ул ана этләрне куып тоткач, ник минем аяк астына сөйрәп алып килергә кирәктер инде?!

Этләр белән ырылдашып торган арада, күземә дүрт прожектор китереп терәделәр: алагаем автокран белән теге таныш «ГАЗ» самосвалы. Иске танышлар: өчесенә бер калфак, ике чалбар, бер күлмәк, бер майка... Килә-килешкә үк вакыт әрәм итмичә, билемә аркан урап, кран белән самосвалга күтәреп салдылар. Күптән, бик күптән ачык машинада утырып йөргәнем юк иде инде, аска салам җәйгәч, аунарга рәхәт икән үзе. Шулай да рәхәт белән мавыгып онытылмыйм, юлны карап барам, кире кайтасы да бар бит әле! Казанны чыктык, Аккош күленә җиттек, сулга борылдык... утыз җиденче елларда төзелгән ярым җимерек дачалар арасында тукталдык. Озак маташмадылар, ике эт өргән арада, өч борын җиргә коелып, минем һәйкәлдән урланган калай юлбашчыны машинага ыргыттылар. Өстемә төшеп изә иде – читкә тәгәрәп өлгердем. Өч борынның берсе «Кайсыбызның гаражына яшерәбез?» дип сораган иде, бәхәс китте. Ник сиңа да ник миңа, кая да кая?! Туйдым бәхәсләреннән.

– Алга, иптәшләр, коммунизмның тулы җиңүенә! – дидем мин, һәйкәлдәгечә горур басып, гипслы кулымны алга сузып.

Тегеләрне күрсәгез, куркуларыннан өч якка чәчелеп, караңгылык эчендә эреп юкка чыктылар, ыңгырашулары гына ишетелеп калды. Ә миңа шул гына кирәк тә: малксизм-ленинизм идеяләле мәңге яши!

Кузовтан тиз генә очып төшеп кабинага үрмәләдем. Машина йөртергә безгә куш! Аккош күленнән Черек күлгә ун минутлык юл, шикләнә-нитә калсалар, бернинди инспекторларга да туктап тору юк, үзебез милициядә эшлибез.

Милиция бүлегенә кайтып кергәч, шадра капитанымны танымадым – чырае айсыз төн кебек. Ә стена тирәли тезелгән урындыкларда Дзержинский, Маркс, Вахитов, Җәлил, Горький, Тукайларга охшаган агайлар тезелешеп утыра. Беләм мин аларны, партҗыелышларда күрешкәнем бар. Чорыбызның бөтен даһилары, каһарманнары милиция бүлегенә допроска җыелган кебек.

– Университет каршындагы мәйданнан тагын юлбашчыны урлаганнар, – диде шадра капитан, теге һәйкәлгә охшаган агайларны журналга теркәгән арада. – Сине алмаш-тилмәш ике урынга куя алмыйбыз бит инде...

– Телевизорыңны давай! Алып кайттым мин аны. Ирек мәйданында үзе басып торыр. Ә мин – университет янына. Әллә боларның һәйкәлләрен дә урлап бетергәннәрме? – дидем мин, яңа һәйкәлдәшләремә таба ымлап.

– Авызыңнан җил алсын! Әлегә ул-бу юк. Дөнья хәлен белеп булмый, хәстәрен алдан күреп таныша торабыз.

Төсле телевизорны күтәреп кайтып кердем өйгә. Иртәгә тагын эшкә әзерләнәсе. Күрше малайларның туган тел китабыннан юлбашчыбызның яшь чагын табып, бераз образга керә тордым. Хатын да әзерләнә. Иртәгә Ирек мәйданында демократлар митинг үткәрмәкче була, ди, шунда күрше мәмләкәтнең президенты портретын күтәреп йөрергә җыена. Не позволю! Бер өйдә ике төрле партия яши алмый!

Телевизорны кабыздык. Анда Ирек мәйданын күрсәтәләр. Минем эш урынымда чын һәйкәл хәзер. Булса ни! Миңа эшнең бетәсе юк. Иртәгә университетка, ә салкыннар башлангач, мемориалга...

Так што, агайлар, дус-ишләр, туган-тумачалар, күрше-күләннәр, таныш-белешләр, һәйкәлләргә таш ыргытканда берүк саграк кыланыгыз!

# МӘХӘББӘТ ХАРАП ИТТЕ...

– Сез кем буласыз әле? Гафу итегез, соравым кинәтрәк килеп чыкты. Ләкин үзегез беләсез, хәзер документ күрсәтеп турысын әйтеп сөйләшә торган заман.

– Мин «Коммунистларча» газетасының хәбәрчесе, иптәш председатель. Килә-килешкә үк, сезнең «Коммунизмга» колхозын айкап, җан тетрәндергеч фактка юлыктым.

– Анысы шулай, хәбәрче кешене һәр үзгәреш тетрәндерергә тиеш инде ул. Тыңлыйм, журналист дускай, йә, күземә карап әйт – кайсы ягыбызны ошатмадыгыз?

– Сез председатель булып сайланган елны колхозыгызда алты авыл булган. Ә бүген ул өчәү генә. Яхшыр, Саклан, Аклан авыллары юкка чыккан. Политик карталарда исемнәре язылган, чынлыкта исә ул авыллар инде җир йөзендә бөтенләй юк.

– Политика ул, иптәш член-корреспондент, политика ул... юк әйберне дә бар итеп сөйләргә ярата. Чит ил радиоларын йокы алдыннан тыңлап ятасыңдыр: безнең СССР турында булмаганны бар итеп күпме ялган сөйләделәр алар! Имеш, капитализм ул – оҗмах, капитализм ул – хөррият, демократия, муллык. Имеш, социализм ул – коммунистлар утопиясе... Позор! Ә бит үзләренчә тоже политика.

– Иптәш председатель, сез читкәрәк киттегез, сүз башыбыз илләр арасындагы политика турында түгел иде.

– Анысы шулай, безнең колхоз Европа белән Америка арасына урнашмаган, без бераз гына читтәрәк яшибез, шуңа күрә читкәрәк китеп сөйләшү кирәк тә. Энгельс бабаң нәрсә ди? Политика белән шөгыльләнгәнче башта тамак туйдырырга кирәк, ди. Сез юлдан килгән кеше, ач карынга... Ач карынга иптәш член-корреспондентлар һәрвакыт усал була... Алло, Мәчтүрә апай, ике гурлалык кына кабымлык әзерлә әле, хәзер киләбез... Алло, Сәкинә апай, бүген кичкә теге мунчаны ягып куй, көтү кайткачрак килеп җитәрбез... Алло, Гайфулла, теге игезәк бәрәннең берсен ак серкәгә батыра тор әле, яме, тозын күп салма, суганын мулрак турагыз!

– Гафу итегез, иптәш председатель, вакыт юк. Газетага срочно мәкалә өлгертәсе бар. Туры соравыма туры җавап бирегез дә хушлашырбыз. Әйтегез менә, кая куйдыгыз сез ул авылларны?!

– Ниме, иптәш член-корреспондент, калада тормышлар ничек соң? Балаларыгыз көр үсәме, хатыннарыгыз үзегездән бик зарланмыймы? Һи, туганый, хатыннарны сөендерим дисәң, колхоз председательләре белән дус бул инде син! Быел еллар авыр килде, кәнишне, ну безнең колхоз муеннан бурычка батса да, алай бөтенләй үк хәерче түгел, хатыннарны сөендерерлек кенә карабодай да җыеп алдык, умарта кортларыбыз да коммунистик хезмәт ударниклары кебек эшләде, сарыкларыбыз да, Ходайның рәхмәте, икешәр бәрән китерде.

– Иптәш председатель, сез минем сорауны юри ишетмәмешкә сабышасыз. Мин юл уңае сезнең халык белән сөйләшеп кайттым, сез ул авылларга радио кертмәгәнсез, кибетләрен яптыргансыз, клуб белән мәктәпне утынга саткансыз, кешеләр көн саен алты чакрымдагы үзәк усадьбага йөреп яшәргә тиеш булган, ди.

– Син, энем, күптән эшлисеңме әле?

– Быел диплом алдым гына, бу беренче иҗади командировкам.

– Ә-ә-ә, шулаймыни?! Әйтәм аны сорауларың кешечә түгел... Алло, Сәкинә апай, мунчаңа су алмый тор әле, яме, онытып җибәргәнмен, бу атнада көн саен мунча керелгән ләбаса: хакимиятнең урынбасары да, налог инспекциясеннән дә, сельхозхимия кешесе дә, главврач та, райпо бухгалтеры да, шөкер, мунча өчен үлеп торалар... Алло, Мәчтүрә апай, ашыңны суыт. Хәбәрчебез, Казанга кайткач ашармын, ди... Алло, Гайфулла, бәрәннәргә тимә әле, яме, бераз үсә торсыннар, зурайсыннар, дим,

зуррак кунакка җитәрлек булсын. Хәбәрченең шашлыктан колагына тимгел чыга икән... Да, син кайсы стена газетасыннан диден әле үзеңне?

– «Коммунистларча» газетасыннан, махсус хәбәрче...

– Внештатный, значит...

– Юк, махсус...

– Махсус килгәннәр өчен махсус җавап әзер безнең. Әйе, әйтик, Яхшыр авылы юк инде. Ләкин аны син әйткән сәбәпләр түгел, ә мәхәббәт харап итте.

– Мәхәббәт... харап итте?!

– Әйе. Ун ел элек башланды бу хәл. Иң әүвәл авылдан солдат Нури китте, армиядән кайтып килешли үк юл уңае калада бер марҗа кызы белән танышкан икән, шуңа өйләндем диде. Паспорты кулында – китте. Нуриның ике ел буе хат алышкан Мөршидәсе бар иде. Егетнең өйләнүен авыр кичерде, тәмам сулды. Бетте бит бу кыз дибез. Ярты ел үтмәде, Нурины барыбер аерып алам, аннан башка яшәрлегем юк, дип китеп барды. Нури армиядән кайтканчы Мөршидәгә Яхшырның шәп кенә бер егете Хәкимҗан бәйләнеп йөрде, шаяртып түгел, яратып. Ышанасызмы, юкмы, Мөршидә авылдан китеп егерме дүрт сәгать тә үтмәде, Хәким аның артыннан чыгып качты, паспортны да бер айдан соң гына кайтып алды әле ул. Ну шуннан кул китте безнең: Хәкимгә күз салып, башкаларга сер бирмичә генә Нәкыя йөргән икән, юк хәйләләрен бар итеп китте бит теге. Ә Нәкыя өчен җанын бирергә әзер булып Гыйлаҗи йөри иде, кәнишне, Гыйлаҗине беркем тыя алмый, китте Нәкыясен эзләп. Гыйлаҗинең эти-әниләре Шаһидәнең эти-әниләре белән туй турында сөйләшеп йөриләр иде, тикмәгә генә булмаган икән, китте Шаһидә. Ну Яхшырда Гарәф атлы бик тә булган егет бар иде. Шаһидә кайда – мин шунда дип, китте бит тәки. Гарәфине эзләп Әнисә, Әнисәне эзләп Мөхәммәт, Мөхәммәтне эзләп сразы дүрт кызыбыз чыгып качты...

– Бу киткән кешеләр гаилә кора алганнармы соң?

– Хикмәт тә шунда. Берсе-бер кияүгә чыкмаган. Нигә дисәң, Нури марҗа кызы белән рәхәтләнеп яшәп ята. Нурины аерттыра алмагач, Мөршидәсе ялгыз картаерга сүз биргән. Мөршидәне ала алмагач, Хәким буйдак калган. Хәкимсез Нәкыя тилмергән, Нәкыяне көтеп Гыйлаҗи картая, Гыйлаҗисез Шаһидә, Шаһидәсез Гарәфи, Гарәфисез Әнисә, Әнисәсез Мөхәммәт. Ә Мөхәммәт өйләнмим дисә, үзегез беләсез, сразы дүрт кыз тол кала...

Әле мин бер өлешен генә сөйләдем, иптәш юнкор, бик теләсәң, әлеге исемлекне туксан хуҗалыкка хәтле санап күрсәтә алам.

– Рәхмәт инде, мин сезнең легендагызны бик ошаттым. Шунысы гына аңлашылмый: киткән кешеләрнең Яхшырдагы туган-тумачалары кая?

– Балалар кайда – туганнар шунда инде ул... Туган-тумачасыз яшәр чакмы? Балаларны институтка кертәсе бар, эшкә урнаштырасы, дачасын төзеп бирәсе, машинасын-фатирын юнәтәсе, һичьюгы, фатирдагы бала-чагаларга күз-колак булып торсаң да файда. Хәзер аерым яши торган заман түгел. Менә шулай итеп Яхшыр авылы бөтенләе белән китте дә барды.

– Ярар, Яхшыр авылын мәхәббәт харап итте дип санийк. Ә Саклан белән Аклан кая киткән?!

– Сакланны көнчелек харап итте. Ә Акланы хыянәт корбаны булды. Бик теләсәң, тәфсилләп аңлатып күрсәтәм...

– Сөйлисе әкиятегезгә алдан ук ышанам. Калганын үзем уйлап чыгарырмын, фельетон язганда.

– Хуш иттек, яшь иптәш, калага кайткач, редакторыңа миннән сәлам әйтергә онытма!

– Ә сез иртәгә газетаны укырга онытмагыз.

* * *

Иртәгесен, эшкә килүенә, приказлар тактасында хәбәрчене редакторның яңа әмере көтеп тора иде инде: «...«Коммунизмга» колхозына бәрәңге чүпләргә җибәрергә!..»

# МАТАЙЛЫ КЫЗЛАР

Клубка без гәҗит укыр өчен генә җыелабыз. Укырга дип инде, безгә гәҗитнең беренче битләре кирәк түгел – анда ниләр язылганын укымасак та беләбез. Политика кайгысы юк, малай, кияүгә чыгып булмый. Ходай кушып, башлы-күзле булсам – ирем белән икәүләшеп үзгәртербез дә, корырбыз да әле дөньясын, Алла боерса... Гәҗитнең соңгы битләрендә, теге алыш-биреш рекламаларыннан соң урын калса, белдерүләр чыга: танышырга теләүчеләр турында, әнә шуларны укыйбыз. Гәҗит чыкмаган көннәрдә ял итәбез. Клубыбызда башка нәрсә эшләп булмый. Биюләр оештырыр идек – егетләр юк. Ну интегәбез түлке, егетләребез булмагач... Җитмеш хуҗалыклы авылыбызда чаң сугып, пүнәтәйләр белән эзләсәң дә, имгә ярарлык егет табалмассың. Әле кыш көне генә ике егетебез бар иде. Берсе, җылы яктан очып килгән шабашникларга ияреп, озын берлек артыннан чыгып китте. Икенче егетебез...

Өйләнә торган нәмәрсә түгел. Инде бөтенебез белән дә берәр кат... урам әйләнде, яшен кырыкка тутырды, ә өйләнергә уенда да юк. Хәзер клубка бөтенләй чыкмый, гел өендә – кофта бәйләргә өйрәнгән, ди. Армиядән кайтырга тиешлесе бар барын, шуны егерме кыз бер булып көтеп торабыз. Егерме кыздамы хикмәт, араларында иң өлгергәне мин – солдатның кайтып керүен ике ел гына түгел, утыз ике ел көтәм инде... И солдатым, кайтсын иде тизрәк! Мылтыктан бушаган куенына сыенып идем дә өлешсез калган унтугыз кызны туема чакырыр идем. Туй беткәч, кунаклар таралышкач, киявем белән икәүдән-икәү генә калгач... ничегрәк... нитеп... нишләргә микән? И, әнә Нәсимә әйтә, кияү генә тап, калганын үзем өйрәтермен, ди.

Күңелсез шул, егетләрсез күңелсез. Көзге яңгырларда, кышкы буранлы төннәрдә, язгы кичләрдә ялгыз башыңны ике мендәргә салулары... Хет гәҗиткә белдерү бир! Белдерү дигәннән, укыгансыздыр, гәҗиткә бер хат җибәрдек без, басылып та чыкты. Хәтерлисезме: «Егетләр талон белән, кызлар эшелон белән». Шул, безнең авылның егерме кызы имза куйган хат иде ул. Гәҗиттә басылып чыккач, «Мин сезнең белән танышырга телим» дип, күп кенә хатлар килде. Фотоларын җибәрәләр, бәйрәм белән котлап открыткалар салалар, күрешү-өйләнешү турында гына ләм-мим. Әллә барысы да хатынлы кешеләр – юри безне кызганып кына язышалар шунда... Кызганыч кызлар түгел без: печән чабабыз, утынын кисәбез, атын җигәбез, өен салабыз. Ул спорт ярышларын оештырып җибәрдек... Мин үзем гер күтәрү буенча район беренчелегенә чыккан кеше, ә ыштангы күтәрү-төшерүдә безнең кызлар республика чемпионы исемен ала язды.

Бүгеннәрдә клубта тагын кызлар артты: унынчыны тәмамлап, бер елга авылда калырга сүз бирәбез дип, ярты команда кыз безгә килеп кушылды. Шул гына җитмәгәние... Адәм көлкеләре – яше унсигезгә җитәр-җитмәс бала-чага, җыенысы бер хатынга тормый: битләре агарган – дәфтәр бите шикелле, чәчләре тузгыган, муеннары пионер галстугы тага-тага муйнакланып калган, билләре билсез, ботлары итсез, күкрәкләре әчтерхән чикләвеге хәтлек кенә.

Менә ичмасам без!..

Безнең Юшмыда кызлар исеме гел «мә»гә бетә: Сә-ли-мә, Фәһи-мә, Нәси-мә, Әкъли-мә... Алай саранңар түгел без.

Атналык гәҗитне яңабаштан укып чыгып, клубны бикләп китәбез дигәндә генә, инде кияүгә бару өмете бөтенләй өзелгәч, кич йөрүдән туктаган яшь пенсионеркабыз Вәсимә очып керде. Без аны калага разведкага җибәргән идек, баганаларны, белдерү такталарын карап йөр, танышырга теләүче юньлерәк ирләргә юлыкмассыңмы, дигән идек.

– Кызлар, – ди бу, лотарыйга мужик откандай сөенеп, – бер белдерү таптым: Балъягар дигән авылда егетләр эшелон белән, кызлар талон белән генә икән.

– Киттек шунда, егетләрен төяп алып кайтыйк!

Шундый кыен икән ул кияүгә чыгасың килә башласа...

Бильярд өстәленә географик картаны җәеп салдык та Балъягар авылын эзләп таптык. Ерак ара түгел икән, бездән матай белән барганда биш кенә сәгатьлек юл.

Сигез матайга атланып Балъягар ягына сыздык. Коляскалар буш – егетләр сыярлык кына. Әкълимәбез генә бераз киреләнеп маташты: миңа бер генә мужик җитми... Хуҗалыгым зур, арендага 15 гектар җир алдым, ди. Матай белән түгел, арбалы трактор белән барам, ди. Бер нәфесен тыя алмады инде тәки...

Өйдәгеләр никах мәҗлесенә әзерләнеп калдылар. Эшебез уңышлы гына барып чыкса, Юшмының калган кызлары да берәр рейс ясарлар.

Юлда килгәндә Әкълимәнең матае сүнде, кабызырлык түгел. Каравыллар кычкырып елап калды. И, ялгыз картаюлары...

Балъягарга килеп җиткәндә, төн үткән, таң аткан, инде көтү куар чак җиткән иде. Вәт җайлы вакытка туры килдек, ичмасам, егетләрнең мал ияртеп чыгуы була... Ә без аларның кәҗә-сарыгын бер якка, үзләрен кочакка дигәндәй, капчык кидереп матай бишегенә «дың!». Аннан соң әниләре түгел, этләре дә куып тота алмас.

Безнең киләсене берәрсе хәбәр итеп куйган мәллә, бүген егетләр көтү озатырга чыкмыйлар, кәҗә-сарыкларга гел бабайлар гына ияргән... Ярый, көтәбез әле, утыз ике ел көткәнне утыз ике минутка калгач кына үлмәбез. Эшкә җыенган чакларын сагаларга исәп... Торабыз. Шул ук бабайлар сәнәк-чалгы күтәреп болынга китте. Ә без һаман көтәбез... Ник чыкмыйлар соң инде егетләребез? Койма ярыгыннан чырайларыбызны күреп, котлары алынып, капкаларын эчтән бикләп куйдылар микән? Белдерүгә ялганлап язмаганнардыр ич?! Юктыр ла, Вәсимә обком каршындагы баганадан куптарып алдым дигәние, өй саен берәр егет әрәм картая, диелгән. Әллә, Ходаем, егет дигәннәребез шушы бабайлар микән? Булмастыр, бу бабайларга без нәрсәгә инде? Хәер, белмәссең, өйләнәсе килә дип белдерү язарлык хәлгә калгач, үзләренекен үзләре белә торгандыр. Алай да өйләренә кереп карыйк әле, егетләр качып ятмый микән?

– Әйдәгез, кызлар, җидебезгә җиде капка, җиде капчык, җиде никах.

Пластунский шуышып, яу кырын кичәбез, безгә әсир төшәсе дошманнар сизмәсен...

Шунысы сәер: капкалары эчтән бикле түгел. Үземә тиешлесенең өенә керсәм – мин аны дуңгыз баласы мыркылдый дип торам – булачак ирем юрганы белән башыннан бөркәнеп гырлый-гырлый йоклап ята. Төнге сменадан кайткандыр инде. Бигрәк шәп, йокласын, дулап интектермәс. Юрганы-ние белән төреп алдым да аркама салдым.

Шөкер, беребез дә тавыш-гауга куптармадык. Балъягарда тузан гына тузып калды.

Юшмыга җиткәч, җил тегермәне күләгәсендә җиде матайны бушатып, җиде капчыкны җиргә селкедек. Ходаем, һаман йоклап яталар. Ниткән йокы булды соң бу? Авыллары белән мәрткә китмәгәннәрдер ич...

Вәсимә һәммәбезгә дә никах укып чыкты. Хәзер уянсалар да ярый...

Туйны һәммәбез дә бергә үткәрдек. Туйда кызлар үзебез биедек, үзебез җырладык, үзебез гармун уйнадык... Ә тегеләр, болар... безнең ирләребез ашап эчәләр дә өстәл артында гырлап йокыга китәләр, уяналар да ашап-эчеп тагын йокыга китәләр.

Туйдан соң, өч көн үткәч, ниһаять, көч-хәл белән көн яктысына чыгып бастык. Әйдә, картым җанашым, тормыш көтәсе бар, капиталист агайлар һаман-һаман ярдәм итмәсләр, ал көрәкне, бир чиләкне – бәрәңге басуына киттек, дим. Картым Балъягар ягына карап авыз киереп бер иснәде дә:

– Ә раскладушка алып барабызмы соң? – ди.

Мин дә алай таш бәгырьле түгел, ярар, дим, ял итсен, көч җыйсын.

– Бар, картым, бар, болында бозау сакла, бәрәңге алырга бергәләшеп иртәгә барырбыз, – дим.

Кырдан кайтсам, ирем, дәфтәр энәсеннән кармак бөгеп, бала-чагалар белән инештә балык тотып ята.

Икенче көнне дә, өченче көнне дә шул ук хәл.

Эш рәтен белми, кочаклашып яту дигәндә... белә. Хәер, минеке хет йокласа да куенымда йоклый, әнә Нәсимәнеке, кочакларга тотынсаң, каравыл кычкырып елый башлый, ди. Вәсимәнеке Балъягардагы әнисенә елап хат язган, ди. «Вәсимә мине урлап алды, көчләгән өчен закон каты, судка бирик» дип әйтеп әйткән, ди.

Җыйнаулашып киңәштек тә ирләребезне авылларына илтеп куйдык. Кияүгә чыгып кергән исеме күтәрдек, күпләргә монысы да тәтеми әле.

Хәзер инде баганаларда, гәҗитләрдә белдерү күрсәк, гел көләсебез генә килә. Егетләр эшелон белән, кызлар талон белән, имеш, талон көненә калгач, юк инде ул, малай!

# ӘҖӘТ БУЛЫР...

Каравыл!

Кунаклар килеп төште! Мич җылысына арка терәп тыныч кына яшәп ятканда, әзмәвердәй өч тамак килеп төшсен әле! Җитмәсә, каладан үзләре – суык мунча чикерткәләре шикелле бөрешкәннәр, күзләре саеккан, яңаклары бөрешкән, аякләре очлайган, авызлары гына лакан хәтле.

– Әллә сез берәр концлагерьдан качтыгызмы? – мин әйтәм.

– И, туган апа, – ди хәллеләрәге, – бу айның купоннарын югалтканыек, шуңа атналап-атналап туган-тумачаларның хәлен белешеп йөрибез.

Шулайдыр да... Танымыйм бит үзләрен, төсмерләгән дә кебек. Кала җирендә туганнарың күп булмасын икән ул, әгәр һәрберсе, «купонымны югалттым» дип, хәерчеләрен сөйрәп кунакка кайта башласа, җүләргә сабышырсың. Ә мин, чынлап та, кирәк чакта җүләргә сабыша беләм: өянәкле кешедәй күзләремне менә болай калайландырам да егылам... Әйтеп йөрми шул хәзерге кунаклар. Ну, ярар, без үзебез дә буявы уңганнардан түгел, Буада туып, Чистайда үскән кызлар без. Егерме беренче елгы корылыкта да кунак сыйлаганыбыз бар. Беткән баш беткән – инде бусагадан узган кунакны борып чыгармассың, бер төнгә җитәрлек итеп кенә якты йөз күрсәтергә тырышырбыз. Юкса базарда әйрән үтмәгән көннәрдә үземнең дә калада куна калган чакларым бар. Ярлы көнең – ялыныч!

Кунакларны алгы өйгә озаттым да өстәл артына тезеп алларына симәнке куйдым. Чемченә торсыннар, вакыт үткәрергә ярап тора ул.

Авызларына җим кергәч, кунакларымның теле ачылды.

– И, рәхәт авылда, – дигән булалар, – кибетләрдә дә чират торасы юк, бөтенесе дә ишегалды белән абзарыгызда, базыгызда запас, келәтегездә байлык, кыш буе эшләмичә ашап кына ятасыз.

Йөрәгем жу-у итеп куйды – кыш буена килмәгәндер ич болар?

– Алай димә, туганым, – мин әйтәм, – авыл халкы бәрәкәт белән яшәргә өйрәнде, мал-туарны да көнгә ике генә тапкыр ашарлар дип иртәнге йокыларыннан уятмаска тырышабыз, үзебез дә, аш пешерсәк, итен – көндез, шулпасын кич чөмерәбез. Ботка-мазар пешерсәк, тозлырак итәргә тырышабыз – соңыннан су эчә-эчә рәхәтләнәсең, һич ашау гаме калмый. Күрше-күләнгә үтечкә әйбер сорап керүләр дә бетте, ник дисәң, бурычны түләрлек гарантияләр калмады. Гәҗит-журналны көн яктысында

укып өлгерергә тырышабыз, залдагы зур утны югалган әйберне эзләгәндә генә кабызып алабыз. Хәтта яшь киленнәребез дә юкка-барга расход ясамый, битләренә иннек урынына кызыл чөгендер ышкый, иреннәренә карлыган вареньесы сөртә – тәнгә дә зыяны юк, үбешә-нитә калсаң, тамагың да туя. Нишлисең бит, бер шырпыны дүрткә телеп яндыра торган көнгә килеп терәлдек.

Борчак шулпасы чөмереп, бер-ике самавыр чәй бушатып, кеше төсенә кергәч кенә таныдым туганнарымны – кияүдәге олы кызымның иренә туганнан туган тиешле кешеләре икән. Ун ел элек кызымның туенда урыннарыбыз өстәл аркылы кара-каршы туры килгән иде. Туйдан бирле күрешкәнебез юк, шуңа кисәк кенә танымыйчарак тордым.

Савыт-сабаларны юарга да өлгермәдем, ишегемнән тагын ике пар кунак килеп керде. Бүген каушавымнан ишекне бикләргә дә онытканмын, кисәк кенә бусагаңнан кунак килеп төшсә, бигрәкләр дә котың оча икән, каравыл кычкырырга да өлгермәдем. Бу ике пар дигәнемне танырлык – калада йортка кергән уртанчы малаемның соцгородта яши торган баҗасы. Баҗа дигәнебез керә-керешкә үк ашау дәрте белән ниятләнде: чәйне зур самавыр белән куегыз, кечкенә кодалар билет алалмыйча икенче рейска калдылар, ди. Безнең авыл калага якын анысы, сәгать саен автобус килеп тора. Элек ялга каршы көннәрдә генә авылга агылып, эш көненә каршы кире олагалар иде. Хәзер, малай җанашым, кала халкы авылга кайтса, куып та җибәреп булмый, эш көне турында түгел, аш көне турында гына уйлый алар. Җитмәсә, үзебез дә дивана: тамыр җәяргә җайлырак булсын дип, ике кызым белән өч малаемны каланыкылар белән кавыштырган идек. Күрәселәр бар икән әле, сәгать саен кунак кайта башласа...

– Сез дә купоннарыгызны югалттыгызмы әллә? – дим баҗа тиешле кунагыма, һич оялып-нитеп тормыйча.

– Юк, – ди бу, – ике айдан бирле зарплата ала алмыйбыз, банкта кәгазь юк, – ди.

– Ә кече кодаларга ни булды икән, сагынып кайтышларымы?

– Юк, – ди баҗа тиешлебез, – кече кодаларның кайгысы зуррак – алар икесе дә сокращениегә эләктеләр.

– Заводларын япканнар мәллә?

– Заводлары ябылганы – уртанчы малаеңның бабасы.

– Тагын кемебезне нинди мур кырган? – дидем мин, баскан җиремдә егылып китмәс өчен караватбашына тотынып. Соравыма күрә җавабы: кемебездер трамвай-троллейбуслар начар йөри, дип, якыннанрак яңа эш урыны эзли, кемдер эшен югалткан, кемдер кооперативка китеп азаплана, кемебездер банкрот, кемебезнедер армиядән списать иткәннәр, стипендиягә яши алмыйча укуын ташлап йөри, фатир сатып алмакчы, өйләндермәкче, ике катлы йортын җылытырга ташкүмер беткән...

Адәм баласы михнәткә тиз ияләшә лә ул, сәгать саен төркем-төркем кунак кайтканга да исем китмәс булды. Миңа гынамы әллә – әнә бөтен авылны каланыкылар басты, басып алды дип әйтүем. Мичләребез тәүлек буе сүнми, морҗалардан ургылган төтенгә җилләр ютәлли башлады. Чишмәләрдә суларыбыз кимеде, таң атканда әтәч тавышлары сирәгәйде, кәҗә-сарыклар тавыш чыгарырга куркып, сыерлар мөгрәмәс булды. Авылдагысы җанга тисә, өйдәгесе малга тия. Картым-җанашым язгы чәчүдә йөреп өч капчык борчак, биш капчык солы, ике капчык карабодай алып кайткан иде, бушаттылар. Он бетте дигәч, кофемолка таптылар – шуның белән бодайны тарттырып он итәләр дә коймак коялар. Мич авызына чират, газ плитәсенә чират, керосинка өчен сугыш, хәтта үтүк өстендә йомырка кыздырган көннәребез дә бар. Йомырка дигәннән... тавык оясына да чират хәзер, сыер имчәгенә дә чират – савым вакытын көтеп торган юк, исләренә төшкән саен, сөт төшәме дип тормыйлар, стакан белән генә савып керәләр. Әйтәм ич, бөтенебезне каравыл кычкыртып талыйлар. Әле дә ярый ике айлык бозауны күршедәге ялгыз карчык Һадияттәйгә кертеп яшердем, юкса аны да савып азапларлар. Мин генә түгел шул... аның абзарына егермеләп бозау яшергәннәр инде... И, бар түлке дөньяда бәхетле кешеләр, Һадияттәйне әйтәм, бер бала-чагасы, туган-тумачасы юк, җаны тыныч. Бала үстереп кем рәхәт күргән соң бу дөньяда? Кем әйтмешли, күчтәнәчкә яулык тотып кайталар да чишендереп китәләр.

Каравыл, каравыл бу кунаклар белән! Вокзалда яшәгән кебек, валлаһи, кем алдан өлгерә, шул урын алып кала. Өлгермәгәне йә урындыкта төн кичерә, йә караватастына... раскладушка җәеп. Яткач та бер-берсенең йокыга киткәнен көтеп яталар. Кеше бит ул тамагы туйгач кармалана башлый... Өр-яңа караватларымны да шыгырдый торган итеп бетерделәр инде...

Өйдән чыгып китәр хәлем юк – актарынырга тотыналар. Беркөн шулай мич аралыгына яшергән «Татар ашлары» китабын табып алганнар да ясследәгечә, әкият шикелле итеп, шуны укып утыралар. Кайтып керсәм, ач бүреләр өере шикелле миңа акайдылар. Тәки бер сарыкны суярга туры килде ул көнне. Юкса мин бит аларны бәрәңге белән генә сыйлыйм: шулпалы бәрәңге – первыйларына, второйга – чикмәнле бавырсак, сезнеңчәрәк итеп әйтсәк, кабыклы бәрәңге була инде ул, третийга крахмалдан кесәл болгатам. Зарланырлык чаралары юк, идән астындагы бәрәңгенең дә төбенә төшеп җиттек инде, ә урамдагы базны кар күмде – эзләп таба алмаслар, боерган булса.

* * *

Кем дә булса идарәгә кереп зарлангандырмы, өй саен колхоз председателе кереп йөри башлады. Бусагадан атлауга, ишек ябылганны да көтмичә, минем туганнарымны үз туганнарыдай кочаклап күрешеп чыкты.

– Үзегезгә мәгълүм, – ди бу, – безнең эше хәерче колхозларны бетерәләр, арендага бүлгәләп тапшырмыйча исән чыгып булмас, әйдә, бөтен туганнарыгыз бер булып дуңгыз фермасын алыгыз әле, ашаганыгыз – ит тә май, йотканыгыз – сөт тә бал булыр, – дип әйтүе булды председатель мескеннең, тегеләрнең тавыш-тыны юк булды...

Төне буе пышылдашып чыктылар... һәм... иң беренче автобус белән биш балам җитәкчелегендә минем туганнар китеп тә барды. Аннан соң сәгать саен берәр өй бушады. Җәяү чыгып качучылар да булган дип сөйләделәр. Тәки китеп беттеләр бит шул хәерче калаларына. Мин булсам, ул калада күптән каравыл кычкырып ачка үлгән булыр идем инде, ә алар һаман исән, Ходайның рәхмәте.

Кунаклардан котылгач, картым белән күзгә-күз карашып «тындым» чаен эчтек тә җитәкләшеп колхоз амбарына эшкә киттек. Күселәр куыштырып, капчыклар ямаштырып көн үтә анда. Ни бит, эшкә чыкмасыең – колхозны да сөйрисе бар, келәтемдә бушаган ларны да тутырып куясым бар, каланыкылар әйләнеп кайтсалар. Кунакларыма караңгы чырай бирергә исәп юк, ярлы көнең – ялыныч, бу дөньяда авылны ни язмыш көткәнен белгән юк әле. Каланыкыларга барып егылмагаең. Кем әйтмешли, сыйлауларым әҗәт булсын...

# ШӘЛИНСКИЙ БӘРӘҢГЕ

Юныс Шәлегә кайтты, бөтенләйгә кайтты. Утыз яшенә чаклы тапкан-табынган малы әүкатлерәк ирләр мунчага күтәреп йөри торган бәләкәй чемоданга сыйган, артып калган кием-салымы – өстендә. Автобус аны калдырып шәһәр ягына юл алгач, Юныска әллә ничек кенә ямансу булып китте. Тик Галимәләргә таба алып бара торган сукмакка борылгач ук күңеле яктырды, аязды егетнең. Бу сукмак таныш инде Юныска, ял саен диярлек кайта торгач, хәзер Шәле яклары туган ягы кебек якын аңа.

...Алар колхоз базарында таныштылар. Галимә бәрәңге сата иде. Юнысның көтүгә чыкмаган кәҗә төсле анысын кабып, монысын тешләп, тәмле ризык чемченеп йөргән чагы. Базар зур, ял көне озын... Җылы яктан очып килгән агайлар белән телләнеп-сатулашып арыгач, Юныс бәрәңге сатучылар янына якынайды. Һәркем үз бәрәңгесен мактый: «Миранус, лорх, рощипочный, тимер кебек таза, әфлисун кебек тәмле...». Араларында бер яшьрәге исә, мактап сатучыларга исе китмичә, ике генә сүз кычкырып куя: «Шәлинский бәрәңге!» Теге ханымнарның үлчәвенә үрелгән сумкалылар, ялт кына борылып, әлеге кыз янына килеп басалар. Юныс та барып басты.

– Шәлинский дигәне берәр яңа сортмыни?

– Авылыбыз исеме ул. Әллә шушыңача ишеткәнең югыемы?

– Юк шул.

– Менәтерәк! Татарстанда Шәлене белмәгән кеше дә бар икән! Бүген генә айдан төшкәнсеңдер син.

– Сез базарга гел киләсезме? – диде Юныс, кыюланып.

– Быел базыбызга су төшмәде, бәрәңге шикәр кебек сакланган. Тагын бер-ике тапкыр чыгарып сатарлык запас бар.

– Кайчангарак көтәргә соң?

– Фермада без дүрт көн саен чиратлашып ял итәбез. Вәт, калганын үзең санап чыгар инде шуннан.

Юныс тагын нәрсәдер сорашмакчы иде, өлгермәде, Галимә: «Шәлинский бәрәңге!» – дип кычкырып җибәрүгә, берничә кеше Юнысны үлчәү яныннан кысрыклап чыгарды.

Икенче юлы, Юнысны күргәч, Галимә каушавыннан кемгәдер биш кило бәрәңгесен бушлай биреп җибәрә язды.

– Бәрәңгегез чынлап та тәмле икән, – диде Юныс, бер уңайдан Галимәнең үзен дә мактарга теләгәндәй.

– Җиребез шәп безнең!

– Кайтып күрәсе иде бер...

– Туп-туры үзебезгә кайт. Иске почта урамы белән барсаң, безнең өйгә килеп терәләсең.

Кызлар дигәнең, егерме биштән узса, әрсезләнә икән ул, Галимә Юнысны чын-чынлап чакыра иде.

– Шәлегә кунакка кайтучылар вакытында китә белмичә интектерә. Син дә эшләгән урыныңда кисәтеп куй, Шәлегә кайтам, диген.

Бер кайтты Юныс Шәлегә, ике, өч кайтты. Тора-бара «Әйдә, бөтенләйгә кайт инде» дигән сүзләр дә ишетелә башлады. Мин җирсез зимагурга кайда яшәсәм дә барыбер, әйе... завод общагасында мыек үстереп ятканчы, синең тәрбиядә яшәрмен, ичмасам, дип матурлап җавап бирсә дә, Юныс баштарак кала белән авыл ызанынннан кайсы якка да авышырга белмичә икеләнебрәк йөрде.

Бүгенге кайтуында ул, ниһаять, Шәледә яшәп калырга тәвәккәлләгән иде сыман. Бер айлык отпускысының көнен дә әрәм итмичә, Шәлегә элдертте. Ә менә сукмак буйлап Галимәләр өенә килеп терәлгәч, капкада ат башы кадәр йозак та күргәч, артык борчылмады ул. Авылга кайтып яшәү мәсьәләсен тагын бер кат уйлап карарга кирәк иде әле аңа.

Шулай итеп, Юныс кала юлына элдертте.

* * *

Икенче көнне үк аны Галимә эзләп килеп җитте. И орышты, и орышты соң Юнысны:

– Шунда хәтле кайтып, ачык ишектән керә алмагансың. Ялган йозак кына эленгәние, кул тидерүгә, ачыла да китә. Утыз яшеңә хәтле хөкүмәт караватында аунап, чистый өдеһеткә әйләнеп беткәнсең икән.

Әйтәсен әйтеп бетерде дә бүлмә ишеген төбенә хәтле ачык калдырып чыгып китте. Үпкәләведер инде үзенчә. Юныс аны-моны уйлап тормады, хәтта теге чемоданын да алырга онытып, Галимә артыннан йөгерде.

Ул Галимәгә ияреп кайтты. Бу юлысы инде бөтенләйгә дип кайтты.

Бер-ике көн чамасы кызның йорт-курасы тирәсендә юангач, колхоз эшенә чыгарга ниятләде Юныс һәм бригадирга әйтеп куйды. Иртән-иртүк, колхоз радиосыннан эш бүлгәндә, Юнысның да исеме телгә алынды. Кайсыдыр ки абзаң калага бәрәңге сатарга киткән дә, аның урынына дилбегә тотарга кирәк икән...

Атны җигеп бирделәр. Арба төяргә дә өйрәтеп маташтылар. Юныс ферма читендәге эскерттән сыерларга печән ташыды. Галимә сыерларына да өлеш тиде. Тегеләр, мөгезләре белән сыртларын кашыган булып кына, башларын бора-бора, гел Юнысны күзәттеләр – яраттылар бугай.

Эш киемнәрен салып, табын янына килеп утыргач кына, Галимә телевизорны кабызды. Ә анда Казан сөйли иде. Галимә, нәрсәдер сизенгәндәй, Мәскәү программасын ачты... Тик Юныс экранда күренеп калган шәһәр ыгы-зыгысын шәйләп өлгергән иде инде.

– Иртәгә Казанга барып килергәдер, ахры, – диде ул, шактый вакыт сүзсез утыргач.

– Кайтып-китеп йөргәнче, лутчы шунда гына калырсың инде, – диде Галимә, кырт кистереп.

– Чемоданны алып кайтасы бар. Шушы бер күлмәк белән эшкә дә, ашка да йөрмәм ич инде...

...Тәки каласына олакты бит Юныс, юкса Шәленекеләр үз итеп кушамат та тагып куйганнар иде инде. Иртәгә үк кайтып җитәм дигән кеше юк та юк... Галимәсе эзләп килсә дә табылырлык түгел иде. Ике көн эчендә унбер кинофильм, өч спектакль карады Юныс. Дүрт музейда, планетарийда, хәтта зоопаркта да булды. Шәһәр шаукымыннан тәмам гарык булгач кына, Шәле автобусына килеп керде.

Галимәләр капкасындагы йозак кул җылысыннан урталай бөгелеп төште. Ишегалдында бәрәңге тутырган капчыклар аунап ята. Бакчага чыкса, Галимә ялгызы – сызгыч эзен таптамыйча гына казып ала да чиләктәге бәрәңгегә үрелә, тагын казый, тагын үрелә.

«Азаплана» дип уйлап куйды Юныс һәм Галимә кулыннан көрәкне тартып алды. Тегесе карышып-нитеп тормады...

– Көрәгеңне тирәнрәк батыр, – дип кенә әйтеп куйды да шуннан соң ләм-мим!

Кабарып торган хуш исле җылы туфрак чәчүлек бәрәңгене күтәреп тора иде.

Юныс инде бөтенләйгә кайтты, менә күрерсез, бөтенләйгә...

# ЯҢГЫРЛЫ САБАНТУЙ

Яңгырның сабантуйга каныга торган гадәте бар, шуңа күрә дә аны хәзер алдан ук көн тәртибенә теркәп куялар, яңгырсыз бәйрәмнең кызыгы юк, диләр.

Өсте-өстенә болыт өелде. Төш вакытында ук кич җиткәндәй итте – көн караңгыланды. Сизгер шоферлар машиналарын кабызган арада, уяурак хатын-кызлар бала-чагалары белән төялеп тә өлгерделәр.

Беренче мәлдә исле гөлгә су сипкәндәй генә сибәләгән иде, аннан яңгыр дигәнең үләннәрне егарлык итеп көчәйде. Тигез җирдә гөрләвекләр акканда да егәрлеге сүрелмәде. Ахыр чиктә сабантуй аланы шарлавык астында калгандай булды, көрәшчеләр диңгез төбендә көч сынашкан Алып батырлар сыман яңгыр эчендә иделәр.

Сәеткә тукталырга да, җиңелергә дә ярамый. «Сабантуй тәкәсен туйга алып кайта алсаң, быел ук синеке булырга риза», – дигән иде Зәйтүнәсе.

Ниһаять, Сәетнең җиңеп, сөзгәк тәкәне җилкәсенә күтәреп салганын күргәч кенә, авыр болытлар җиңел сулап таралыша башлады.

Юл кызык итте әле, авыл читендәге Сөлчә елгасына китереп җиткерде дә өзелде – бердәнбер күпер ташуга ияреп агып киткән. Актарыла Сөлчә, гомерендә яңгыр күрмәгән диярсең, ярларына бу кадәр ташкын ничек сыйган?!

Шулай итеп, машина белән китеп өлгергән кешеләр дә, үз гомерендә илле-алтмыш сабантуй үткәреп, инде өйләреннән чыкмый ятучылар да теге ярда. Сәетнең көрәшүен ел саен күрми калам, дигән иде Зәйтүнә, ә үзе, Сәетне калдырып, машинага утырып качкан. Сабантуйга дип тектергән аклы күлмәге яңгырга чыланыр дигәндер инде.

Һәр ике яктагылар да ташкынга карап көлешеп торды. Көлми ни, бөтен тормыш теге ярда, ә бу якта Чистайга алып бара торган олы юл гына.

Сөлчә аркылы сөйләшүләр башланды.

– Гайрәте беткәч тынар әле, атлап кына чыгарбыз, – диделәр бу яктан.

– Әллә яр саклап төн кунарга җыенасызмы? – дип кычкырдылар теге ярдан.

– Иртән эшкә чыгасы бар дип, ташкынга сикермәбез бит инде.

– Утлар-сулар кичәргә әзер чакларыгыз үтте шул...

Бу яктагылар сүзне тиз генә икенчегә борды:

– Бәйрәмнән туеп кайтмадык, сабантуйны дәвам итәбез. Гармуннарыбыз бар, кызлар да җитәрлек.

Өч гармун бер булып өздереп җибәргән иде, кызлар биюеннән көнләшеп, Сәет җилкәсендәге тәкә дә тыпырчына башлады.

Теге ярда да бию көе яңгырады, бабайларның берсе күрегенә гыжылдавык йоккан иске гармунын алып чыккан да әби-апаларны, малай-шалайларны, кыз-кыркынны җилкендереп азаплана.

Сәетнең Зәйтүнәсен уртага алдылар, бакчи, курчак иттеләр тегене, картлачы да бөтереп ала, яше җитмәгәннәре дә каршысында сикергәләп биленнән кочып әйләнә.

Ә ташу бәргәләнә, берәр батырыгызны тотып алсам, менә болай агызып китәрмен дигәндәй, әйләнчекләр ясап шаулый. Түзмәде Сәет, теге ярга җикеренде:

– Зәйтүнәнең аягына кан саумасын!

– Борчылмагыз, пожалысты, медпункт үзебезнең якта.

– Биеп егылганга дәва юк, ди...

– Мичебездә бәлеш пешкән, тирләп-пешеп чәй эчсәң, үзе бер сихәт. Менә сез нишләрсез икән?

– Сәетнең сөзгәк тәкәсе җитә безгә.

– Тәкәсе сезгә, Зәйтүнәсе безгә, – диде дә бер шалапае, кызның җилкәсенә пиджагын бөркәде.

Бу хурлыкны түзеп карап торыр өчен сабантуй батыры булу гына җитми. Сәет ачуыннан сөзгәк тәкәне җиргә ташлады. Тәкәнең дә егетлек мин-минлегенә көч килде, ах, әле син шулаймы дигәндәй, мөгезе белән кизәнеп торып, Сәетне Сөлчә ташкынына сөзеп төшерде, ә үзе, бу тирәдә берәр сарык фермасы бардыр әле дигәндәй, салмак кына Чистай ягына сыпыртты.

Сөлчә ташкыны Сәетне сөенә-сөенә эләктереп алды. Алды да, тиз генә йөзәргә ирек бирмичә, эчкәрәк сөйрәде. Бу яр якын гына, азаплансаң, йөзеп чыгарга да күп кирәкмәс иде. Ләкин Сәет теге ярга таба борылды.

Уеннар өзелде, гармуннар сүрелде. Кеше-кара хәлне аңлап өлгергәнче, Зәйтүнә инде ташкын артыннан йөгереп киткән иде, Сәет турысына килеп җиткәч: «Тукта, мине көтеп тор, бергә агабыз», – диде дә суга сикерде. Алар агым уртасында очраштылар. Икәүләшеп, кулга-кул тотынып йөзүе җайсызрак икән, агып киттеләр болар. Әй агалар, әй баралар күрсәң – авылдашлары тигез җирдән йөгереп тә куып җитә алмыйлар. Җылы яңгыр ташкыны яшьләрне иркәләп кенә бер утрау сыман калкулыкка китереп куйды. Ул арада ике яр буйлап бәйрәмдәшләр дә килеп җитте.

– Ни бит, бер-берегезгә сыеныбрак торыгыз, юкса туңарсыз.

– Анысын гына белербез инде.

– Барыбер чыландыгыз, чирканчык алдыгыз, йөзеп чыгыгыз тизрәк.

– Ашыктырмагыз әле, монда да бик рәхәт.

Гармуннарга моң керде. Ике ярдан килгән туй җыры утрау өстендә бергә кушылды.

# ТӘНӘФЕС

Колхоз рәисе халыкның кичке ашка утырганын көтеп кенә торган диярсең:

«Тыңлагыз! Колхоз радиочелтәре сөйли. Хәерле кич, хөрмәтле колхозчылар. Ашыгыз тәмле булсын! Белдерүләр тапшырабыз.

Иптәшләр, механизаторлар җитешмәү теңкәгә тия, шуны исәпкә алып, авылда техник мәктәп ачарга булдык. Уналтыдан утыз биш яшькә кадәр булган егетләр-кызлар, ирләр һәм хатыннар бер ел эчендә киң профильле механизатор таныклыгы алачаклар. Стипендия ел дәвамында алтмыш сум, махсус кием-салым биреләчәк. Укулар ноябрьнең 15 еннән башлана. Кабатлыйм...»

Сатирә, Гомәрнең ачык авызы янында туктап калган кашыкны күргәч, җәһәт кенә урыныннан торып, радионы сүндереп килде.

– Аша, эч! Әнә чәеңә бәке уярлык булган, шулхәтле суытмасаң соң?

Гомәр боткалы кашыгын кире тәлинкәгә куйды һәм тиз генә бер йоту белән чынаякны бушатты да торып китте.

– Кая барасың?!

– Тартып керәм.

– Өйдә генә тарт, чыгып йөрмә! Мич алдына утыр да...

– Хәйдәрләргә кереп чыгасым бар, тәмәкем беткән.

Әгәр бу минутта өй эчендә берәр чит кеше булса, бәлки, гаҗәпләнерлек берни дә күрмәс иде. Гомәр өчен шаккатарлык хәл иде бу. Төтен исе сизсә, тәрәзәләрне ачып, башындагы яулыгы белән өй эчендә давыл чыгаручы Сатирә хәзер үзе үк мич алдында тартырга рөхсәт итә! Алай гына да түгел, кунаклар алдында тартыр дип, яшереп куйган «Беломор»ны да кызганмады.

Ә Гомәр кулындагы тәмәкедән тизрәк котылу ниятендә. Мич авызына сыймаган төтен Сатирәнең сулышына иярде.

Сатирә – сыер савучы. Ул ат җигүче Гомәргә караганда күбрәк хезмәт хакы ала. Шуңа күрә үзен гаиләнең иң баш хуҗасы дип исәпли.

– Шул гына җитмәгәние. Ике балаңа ияреп укырга йөрисең киләме? Булмас!!!

Хуҗа кешенең сүзе – закон. Гомәр каршы эндәшеп торуны кирәк дип тапмады. Закон чыгаручы кичке савымга, фермага киткәч кенә күршесе Хәйдәрләргә кереп чыгарга булды.

Хәйдәрнең күтәрә алмаслык бүкәнгә балтасын чабып уйга калган чагына туры килде.

– Балтаң кысылдымы?

– Кысылды... Ишеттеңме?

– Ишеттем. Алтмыш сум түлибез, ди. Ул акчага бер ай буе дилбегә тартырга бит... Ә монда парта арасына утырып кайткан өчен. Гомер буе ат җигәргә димәгән. Безнең ишеләр техниканы җигә.

– Сатирәңә шулай дип аңлаттыңмы соң?

– Әйтергә ирек бирмәде.

– Минеке дә.

– Нишлик икән, Хәйдәр, ә?..

Хәйдәрнең беләгенә тагын бер ир-егет көче кушылган кебек булды. Ул, көчәнеп тә тормыйча, балта чабылган бүкәнне җилкәсенә салды һәм баш аркылы әйләндереп төпкә бәрде. Ничәмә еллар бирешмәгән бүкән урталай ярылды.

– Гомәр, иртәгә үк язылабыз!

Хәйдәрнең иртәгесе бик тиз килеп җитте. Авыл советы нәкъ үзәктә, бара башласаң, ярты авылның күзенә чалынасың. Кешегә хәзер ыржаерга гына булсын, сакаллы сабый дип көлмәгәйләре...

Секретарьның төшке ашка кайткан чагын тыкрыкларның берсендә сагалап торып, исемлеккә телдән генә язылдылар.

Октябрь аеның беренче таңын Гомәр тезмәдәге печән эчендә каршы алды. Рәхәт. Урын да җыеп торасы юк. Баскычтан төшешли, юл уңае, абзардагы терлекләргә печән култыклап аласың. Чәч арасындагы печән вакларын гына тарап төшерәсең дә ишегалдындагы баганага кадакланган юынгычка үреләсең. Суы бозланып каткан икән, аптырамыйсың, бит-кулыңны кыйбла яктан искән җилдә җилләтеп алырга була. Өйгә су эзләп кермәссең ләбаса. Сатирә ястыгын бусага төбенә салып ятты бугай. Бар, кереп кара!.. (Сер итеп кенә әйтик: Гомәр белән Сатирәне «Юмор белән Сатира» дип үртиләр бездә.)

Төрле урамнардан ике дистәгә якын кеше җыелды.

Дүрт бүлмәгә бүленгән иске өйне мәктәп дип, егерме биш ел тракторчы булып эшләгән Каюм абыйны класс җитәкчесе дип атап, беренче дәресне башлап җибәрделәр.

Укытучыга тиз генә күнегә алмадылар. Гел мазутлы комбинезоннан күреп ияләнгәнгәме, Каюм Әхәтович кара костюм-чалбар, ак күлмәк һәм бизәкле галстуктан булгач, күбәләкне хәтерләтә иде.

– Бүгеннән башлап сез курсантлар. Сезне фамилиягез белән генә атап йөртермен. Танышуга вакыт әрәм итеп тормабыз, сразы тракторлар китабының беренче битен ачабыз. Кәгазь алып килгәннәр язып барыгыз... Һәрбер үзйөрешле нәрсәнең иң кирәкле өлеше ул – кәкре-шиплы, шатунлы механизмнар. Алар түбәндәгеләр...

Гомәрнең күңеле тынычсыз. Иртәнге савымнан кайткач, Сатирәсе эзләп килмәгәе. Оятка калдыруы бар. Күренә калса, тиз генә янына йөгереп чыгу һәм читкәрәк алып китеп тагын бер кат аңлатып карау уе белән ул гел тәрәзәнең урам ягын күзәтте. Сатирә күренмәде. Аның каравы мәктәп ишеге төбенә курсант Әюповның олы кызы Сәлимә килеп басты.

– Фатих, кызың ашарга алып килгән!

Чираттан тыш тәнәфес ясап Сәлимәне алып керделәр. Күкрәк тирәсенең әллә кайсы төшеннән генә дәфтәр тартып чыгарды, укырга килүе икән... Фатихны көч-хәл белән тынычландырдылар.

Тәҗрибәле укытучы Мәгъсүм Хәбирович дәресендә генә мәктәпчә тәртип урнашты. Ул арифметика белән геометрия дигән җисемнәрдән торган математика фәненә өйрәтергә тиеш иде.

Курсантларны парталарга икешәрләп таратып чыкты. Алгы рәткә утырырга теләмәүчеләр дә табылды. Хөснулла Сәлимәгә ошардай егет булганга, Фатихның үтенүе буенча, аларны аерым утырттылар. Гомәр Сәлимә белән, Бәдретдин Хәйдәр белән бер партада.

Сер түгел, Хөснулла берничә тапкыр Сәлимәне таң атканчы урамда тоткан иде. Кызның укырга килүе дә икесе тарафыннан гына уйланылган эш түгел микән әле?! Урта мәктәпне тәмамлагач, шәһәргә китеп бармаулары да сәер.

Мәктәп ишеге янына көпчәкле трактор килеп туктады. Рульдә Каюм Әхәтович. Урамнан көнгә әллә ничаклы трактор үтеп китә. Сыный карагач, монысы никтер бик сәер төсле.

Хөснулла Фатихның иңсәсенә төртеп алды:

– Беләм мин моны, Вахитныкы бу. Шәп трактор!.. Әз генә этеп җибәрсәң дә кабына. Вахит аны гел тау башына менгереп сүндерә иде.

– Өр-яңаны бирмәсләр инде, йөри бит...

– Таудан төртеп төшерсәң, син дә...

Хөснулла җәйге айларда прицепщик булып эшләп алды. Шуңа күрә тракторларны тануы бер дә гаҗәп түгел. Аның инде руль тотып утырганы бар. Руль дип, чылбырлы тракторның руле юк, рычаглары гына, кайсысын тартсаң, шул якка борыла. Прицепщикның җир сөреп карыйсы килми димени?! Каюм абый иде аның тракторчысы (Әйе, Әхәтович). Бик сорагач, бар соң, бер-ике буразна гына сызып кара, диде... Ә үзе чөйне тартып алып, сабанны ычкындырып куйган. Әй китте Хөснулла алдырып, әй бара, күрсәң, тузан да чыкмый. Бер әйләнеш ясап туктаса, ни күрсен – буразнада дүрт канатлы сабан. Арткы тәрәзәнең нәрсәгә кирәклеген шунда аңлады инде ул.

– Егетләр, – дип, Каюм Әхәтович якындагыларны күздән кичереп чыкты. – Тракторны класска алып керергә кирәк. Бу безгә күрсәтмә әсбап – тимер китап.

– Булдырса, Хөснул гына булдырыр. Трактор белән өйгә керергә ул оста...

Андый хәл булды. Тик Хәйдәр нык арттыра инде, өйгә түгел лә... Хөснулла бермәл трактор кабызып карамакчы иде, ә тегесе беренче тизлектә калган икән. Кабынды да каршыдагы бура эченә кереп тә китте. Болай җимермәде үзе, чәчте генә. Күрүчеләр бар иде шул...

– Сүтеп алып керәбез дә класста яңабаштан җыябыз, – диде Каюм Әхәтович.

– Җыйгач кына чыгып китсә?

– Курыкма, Хөснул, көпчәкләрен алып бүкәнгә бастырырбыз.

Ник дәресләрне көне-төне тоташтан алып бармыйлар икән? Гомәр укыр да укыр иде, өйгә генә кайтасы булмасын. Ә кайтырга кирәк...

Кайтып килә Гомәр... Сатирә, бар ачуын чыбыкка өстәп, ишегалдында келәм кага. Чыбыктан артып калган ачуы көйгән бәрәңге исе булып урамга таралган. Капка кул тидергәнне дә көтмичә ачылып китте. Кояш та гүя шаһит булырга теләмәде, болыт артына кереп посты.

– Укып кайттыңмы, атасы?.. (Мыскыллавы, билгеле.)

– Башлап җибәрдек...

– Нәрсәләр өйрәндегез соң?

– Бүгенгә күп түгел әле, Сатирә. Пешкәк, шатун, терсәкле вал.

– Мин сиңа хәзер күрсәтәм терсәкле-йодрыклы валларыңны.

Һәм Сатирәнең әчтерхан чикләвеге кадәр йодрыклары Гомәрнең җилкәсендә биеп алды. Гомәр кузгалмады да. Җилкәсенең кычытып йөдәткәли торган урынын йодрык астына туры китереп тик басып торды... Әйдә, ачуы басылсын. Кеше ләбаса, җаны булырга тиештер.

– Эшең менә дигәние. Әнә, атыңны Гаптелвәлигә биргәннәр.

– Ну, җиксен инде. Аты да, Гаптелвәли дә бер чама.

– Әз булса да, арба төбендә печәне, утыны кайтты.

– Быелгы кышка җитәрлек әзерләдек.

– Киләсе елга нәрсә?

– Трактор арбасына җәеп алып кайтырмын.

– И-и! Җүнләп дилбегә тота белмисең, трактор тагын...

– Атның үз уе, минем үз уем. Ә трактор ул башка, Гомәрнең уе – аның уе.

– Бер көн мәдрәсәдә укыды – инде мулла булган.

– Мәдрәсәдә түгел, мәктәптә, карчык...

– Гомәр, дим (бусы инде һичбер мыскыллаусыз), соң, егет чагында укып калырга идең.

– Хәзер нәрсә җитми? Хезмәт хакым килеп торыр, үзем өйдә, йорт эшләренә булышам...
– Ә балалар?!
– Әй, ат хәтле ике кызың өчен ничу...
– Әкрен, өйдә бит, дәрес әзерләп утыралар.

Класста гына түгел, авылда да бер генә ул Бәдретдин. Аның вак-вак кына атлап йөрүе, атлаганда бөтен буыннарының да хәрәкәтләнүе беркемнекенә охшамаган... Эче тулы җыен юк-бар мәзәк булыр – авызын ачса, сулышына ияреп мәзәк чыгара, ә үзе бер дә көлмәс. Җәй айларында физкультура укытучысы булып эшләде, ә курс ачылу турында хәбәр таралгач, иң беренче булып исемлеккә язылды. Авызына капкан тәмәкесен гармун күреге кебек сырлар. Суырганда чырае әллә ничә төрле кыяфәткә керер. Әгәр шулчак салпы ягына берәр уч салам да кыстырып куйсаң, тәмәкесен ирененең бер читеннән икенче читенә әүмәләргә керешә, җилкәсендәге бөкресе турая, буе тагын да озынаеп китә.

Ул Хәйдәр белән бер партада. Мәктәпкә иң беренче булып килә. Килә дә ишектән кергән берсенә Бәдретдингә генә хас сәламен бирә:

– Хәйдәр «телевизор» дигән клубта озаграк утырган, ахры, мәктәпкә килеп җиткән, ә үзе һаман йоклый.

– Гомәр, чалбарыңнан очып чыгасың ич, каешыңны тарттыр...

– Фатих, газиз башыңны ник түбән идең, тапкырлау таблицасын тагын өйрәнә алмадың мәллә?

– Җәмәгать, сүгенәселәрегез сүгенеп бетерегез, Сәлимә килә!..

Дәрестә дә Бәдретдин үз «манерын» саклый белә: сөйләвен тыңлап торсаң, тракторга караган саен көләсең генә килер. Җитмәсә, һәр җөмләнең бер-ике сүзен төшереп калдырган була – кыскалык, янәсе.

Каюм Әхәтович бүгенге көнне Бәдретдиннән башлап җибәрде.

– Өйгә нинди эш бирелде әле, Бәдретдин?

– Дизельнең дүрт такты!

– Нинди тактлар инде ул?

– Кертү, кысу, эш эшләү һәм чыгарып җибәрү.

– Тактсызрак сөйлисең.

– Кертү такты, кысу такты, эш такты һәм чыгару такты... Барыбер түгелмени...

– Барыбер түгел шул, – диде Каюм Әхәтович, тыныч кына, – барыбер булса, тракторны циркта күрсәтерләрие... Ярый... Хәйдәр, шул тактларның тәртип номерын санап чык әле.

Хәйдәр Бәдретдингә партадан төшеп тор дип баш кагып кына ымлап алды.

– Партаны күтәрмә, Хәйдәр, янга чыгып бассаң җайлырактыр, – дигән иде дә, тик соңыннан кире уйлады Каюм Әхәтович. – Тукта, Фатихтан гына сорап карыйк әле.

Фатих хәзер көннәрне тәнәфесләр саны белән генә саный. Бүгенгенең тагын ике тәнәфесе бар. Вакыт дигәнең акрын үтә, сәгатьләр никтер авыр кыймылдый, әйтерсең тел итеп гер асып куйганнар. Булырмы икән ул соңгы тәнәфес дияр көн?! Өйдән дә рөхсәт юк, тракторлар да катлаулы нәрсә, геометрия дигәне дә бик шома – тотыныр җире юк. Әллә казылган кадәренчә коесы белән энәсен дә калдырып китеп барасы микән?! Китүен китәрсең, иптәшләр кала. Трай тибеп бер елың үтәр дә китәр, ә дуслар һөнәрле булырлар. Шәт, арабызда Ислам абыйдан остарак җир сөрүчеләр дә бардыр әле. Телевизор, мотоцикл, радиола кебек күчтәнәчләр гел аңа гына димәгән. Ашка сала торган яфрактан үрелгән такыяны Фатихның да киеп карыйсы килә.

– Бәдри, нәрсә булса да ялганла хет, син кызык итеп ялганлыйсың, – дип ялварды Фатих.

Бәдретдин сөйлә дип әйткәнне дә көтми сөйли башлый:

– Түлке бүлдермәгез... Кырык алтынчы елларда колхоз амбарыннан кемдер ике капчык бодай урлаган. Авылга следователь килә. Рус була, кәнишне, шунсыз какой мәзәк! Урамда иң беренче очраган кешене туктата да сорый бу: «Дедушка, как думаешь, кто у вас большой вор?» – ди. Бабай әйтә: «Иди прәме, большой вор через двор, малинький вор каждый двор», – ди.

– Ул хәтле карак хәзер дә юк бит ул бездә, – дип бүлдерде Гомәр.

Бәдретдин аңа шундук җавап кайтарды:

– Ат җигүченең бүреге яна!!!

...Дәрескә чакырып кыңгырауны ике кат шылтыраттылар.

Бәдретдиннең керпе тиреле телен йомшарту нияте белән өч кеше бергә берләште. Югыйсә ул гына фәлән, ул гына төгән, ул гына күп белә, күпне күргән, аның Мәрзиясе генә иренең укып йөрүенә шат, алар гына чүкердәшеп яшиләр, имеш. Иң яхшы тәкъдиме өчен Гомәр бригадир итеп билгеләнде. Хәйдәр аның ярдәмчесе, Фатих – ярдәмченең булышчысы.

Математика дәресләре урта мәктәп күләменнән артмаганга күрә, Хөснулла белән Сәлимәгә күңелсезрәк иде. Мәгъсүм Хәбирович класс журналын актарганда, Хөснулла Сәлимәгә хат яза торган дәфтәрнең уночтенче битен ертып алды. Һәм нидер язып, кызның кабыргасына төртте. Сәлимә дә

кәгазьне алып нидер язды һәм киредән Хөснуллага бирде. Бу – дәрес вакытында тавышсыз-тынсыз гына сөйләшү ысулы. Укытучы Хөснулланы такта янына чакырып чыгарды:

– Пифагор теоремасын исбат ит.

– Теорема: туры почмаклы өчпочмакта ике катетның квадратлары суммасы...

Фатих Хөснулланың дәфтәре арасыннан хатны алып Хәйдәргә тапшырды. Ә Хәйдәр сиздермичә генә Бәдретдиннең кесәсенә салып куйды. Бүген стипендия алдылар, акча белән янәшә яткач, хатның Мәрзия кулына керүе көн кебек ачык иде.

Хөснулла, «5»ле билгесенә хозурланып, башкалардан ныграк белүенә тагын бер кат ышанып һәм хат турында бөтенләй онытып, башын беләгенә куйган хәлдә «черем итеп» алырга булды.

...Вакыйга дәрес вакытында барганга, пышылдап сөйләшәләр.

Сәлимә. Хөснулла. Хөснул, дим... Хөснул.

Бәдретдин. Хөснул уснул.

Гомәр. Сәлимә, ике бөртек кенә чәчеңне өзеп бир әле.

Сәлимә. Нәрсәгә ул сиңа?!

Гомәр. Юрап карыйм, бабайдан калган осталыгым бар.

Сәлимә. Мә... Әйтеп кара, быел кияүгә чыгам микән?

Гомәр. Бер уч бирмәсәң дә әйтә ала идем. Чыгасың, быел ук. Чәчәк аткансың инде, орлык бирмичә калмассың, Хөснул җиңел кулдан өзәр әле, боерган булса. Менә дигән егет.

Сәлимә. Хөснулны һаман белеп бетерә алмыйм әле, әллә нинди, катлаулы ул...

Гомәр. Өйләнешкәч өч көн ял бирелә, яхшылап танышырсыз.

Сәлимә. Син бигрәк инде, Гомәр абый...

Мәрзия керләр үтүкли. Бәдретдин аның каршысына килеп басты.

– Җимеш, бүген стипендия алдык.

– Чынлапмы?!

Бәдретдин күбрәк булып күренсен өчен тәртипсез бөгәрләгән акчаларны ак дәфтәр бите кебек үтүкләнгән сатин яулык өстенә куйды. Учына ияреп чыккан кәгазь кисәген аралап алмакчы иде, өлгермәде...

Кәгазьгә менә нәрсәләр язылган иде:

«Сәлимәкәй! Ник кичә миннән качтың? Төне буе күзгә йокы кермәде».

«Көн саен күрешкәч кызык түгел, сагынылмый».

«Бүген килимме?»

«Үбәм дип җаныма тимәссеңме?»

«Юк!»

«Алайса, өй түренә килмә, кешедән яхшы түгел. Өч аерлы тал янына».

«Вакыты?»

«Гайбәтчеләр йоклагач инде».

«Унгамы?»

«Унбергә хәтле генә, эти әрли...»

Көнчелек врачлар тарафыннан чир итеп билгеләнә алса, Мәрзиянең диагнозына «тумыштан килә» дип тә өстәлер иде.

Дөньяда Адәм абый белән Хава апабыз гына көнләшмәгән, диләр, чөнки алар Җир шары хәтле фатирда бары тик икәүдән-икәү генә яшәгәннәр. Ул вакытларда Сәлимәләр дә, башкалар да булмаган... Тыеп кара инде хәзер Мәрзияне.

– Фатихның иранай Сәлимәсеме?!

– Каян белим, һич катнашым юк.

– Икейөзлеләнмә, кем икәне кара пәлтәңә сары чәч белән язылган. Анда гына сары чәч, чәкән мунчаласы төсле...

– Кызма әле, язу рәвеше дә минеке түгел ич!

– Язуны аны кирәксә кырыкка авыштырасың... Китәм, суга төшкәндәй юк булам, чумып-чумып эзләрсең, ну соң булыр!

Мәрзия теле арыганчы әрләде. Йолкынышып та алдылар. Бергә утырып чәй эчтеләр. Тагын дулаштылар...

Бәдретдин йокыга киткәч, ул, әкрен генә торып, өч аерлы өянке янына юл тотты. Салкын дип тормады, сәгать ун тулганны көтте. Күрде ул Сәлимәне, Хөснулла белән икесе иде... Әй йөгерә-йөгерә кайтты Мәрзия. Кайтты да, кар салкыны сеңгән тәне белән, йокыга талган Бәдретдиннең кайнар куенына чумды.

Язның чын-чынлап килүе иде. Ишегалдында кош-корт, мал-туар кояшта йокымсырый. Түбәдән тамчы тама.

Менә капкадан Хәйдәр күренде. Өч елдан бирле ватылып, инде әчке әгъзаларын бала-чага сүткәли башлаган матайны карап азапланган Гомәр Хәйдәрне күтәренке күңел белән каршы алды.

– Тәки таптым бит фәлшесен, пешкәге ярылган икән.

– Укыган кеше укыган кеше инде ул.

– Үртәмәсәнә...

– Әйдә киттек, ташла эшеңне.

– Кая киттек?

– Кара, оныткан да тагын. Бүген диплом алабыз бит.

Гомәр сыртына тавык кунган ат шикелле сискәнеп куйды һәм тиз-тиз ачкычларын җыя башлады.

# УНИКЕ ВАТЫК КОМПАС

1962 елның гыйнвар аенда безнең авылда бер-бер артлы кырык сигез бала туды. Бөтен район ду килде... Әле данnetwork республикага чыга иде дә, райком эшне зурга җибәрмәде. Өлкә һәм район газеталарына адресланган хатларны почта бүлекчәсендә үк ачып, тикшереп тордылар, кырык сигез бала турында хәбәр түгелме, янәсе.

Малай тусын дия-дия каенаналарга хәтлек киленнәре белән ярышып бала тапты ул гыйнварда. Анысы җайлы, участок больницасы үз авылыбызда гына – бер ишектән көмәнле апалар керә тора, икенче ишектән көпчәкле бишеккә төяп чыгара торалар... Әллә кайберләре икешәр әйләнде шунда! Акушерлар Әминә апа белән Мәүлидә әби, завод миченнән икмәк чыгаргандай тырышты, диделәр. Пролетар Габделхәйнең Мишә бәкесендә төн утырып кармагына шулхәтлек чабак та эләккәне юк, билләһи... Әминә апа белән Мәүлидә әбигә түлисе премияне күпсенеп, берәр приписка-мазар юк микән дип, авыл советы секретаре Разыяның метрикә журналын райплан вәкиле лично үзе килеп тикшереп киткән. Гаеп юк, балаларның тууы хак. Кырык сигезнең егермесе – малай, калганнары кызлар, ди, әлегә.

Сизгер колаклар спорткультторг базасында бала бишеге эзләп йөргән чагында ишеткәннәр – безнең ише тагын берничә авыл гыйнвар аенда шушылай «уңыш бәйрәме» үткәргән, ди.

Уңыш бәйрәменең хикмәтен еруктан эзлисе юк, язгы чәчүгә төшкән көн – 1961 елның 12 апреле, ягъни совет егете Ю.А.Гагаринның Җирнең тарту көчен җиңеп, батыр очучы-космонавт булып кайткан көне! Шул төндә дизелист Кәллә Гомәрнең эш урынын ташлап китүе аркасында, колхозның электр станциясе кичке сигездә үк сүнгән иде... Һәм менә нәтиҗә күз алдында: теге егерме малайны туганчы ук космонавт дип атадылар. Тагын ике елдан В.В.Терешкова егетлек күрсәткәч, калган егерме сигез кызны да авылның космонавтлар отрядына теркәп куйдылар.

Шаукым озак бармады. Н.С.Хрущев космонавтлар тудыру турында берниндиде дә карар чыгармагач, эти-әниләр тиз сүрелде. Ә инде «Звездный городок»та очучыларның зур отряды чират тора икән дигән хәбәр безнең авыл ирләрен бөтенләй картайтты. Һәм бала-чагалар янә төрле айларда берән-сәрән генә туа башлады.

Гагаринның сурәтен шырпы тартмаларында күреп, «Ракета» дип язылган уенчыклар белән уйнап, тәпи йөргәнче үк мактау сүзләре белән үстерә торгач, бу кырык сигез бала бераз сәеррәк, һавалырак, йолдызчарак һәм канатлырак иде. Аларны шартлы рәвештә ике класска бүлеп, урта мәктәпне укытып чыгардылар. Илаһи уптым Юлбарыс елының Кәҗәмөгез йолдызы астында тууга карамастан, кырык сигез төрле холык, теләсә кайсы йолдызнамәне фаш итәрлек кырык сигез төрле язмыш иде аларның. Авылның тарту көчен җиңеп, билгесез тарафларда югалган арада, тагын кырык сигезләп косманавт галәмгә чыгып керде. Ләкин алар арасында безнең авылныкылар берәү дә юк иде. Завод директорлары, администрация башлыклары, депутатлар, популяр артистлар арасында да юк иде безнекеләр. Ә Наил дигәне хәтта, шәһәр тормышына лач итеп төкереп, кайтып, өр-яңа тракторга хуҗа булды.

Йолдызлары коелган илебез, космонавтика көнен утыз бишенче тапкыр бәйрәм иткән чакларда, әлеге кырык сигез классташ очрашу үткәрергә теләде. Һавалы балаларны эзләп һәм чакырып хатлар китте... Тик ул хатларның уникесе генә гамәлгә ашып, уникe классташны гына тиешенчә үгетли алган иде.

Наил, авылда бердәнбер урта белемле тракторчы буларак, тагылма арбасын юып-сөртеп кенә йөри. Классташларын каршы алган көнне дә аның арбасы никахка чакыртылган такси кебек ялт итеп тора иде. Арбасына бәрән печәненә ярарлык итеп күләгәдә генә киптерелгән солы саламы җәелгән. Наилнең «луноход»ына төялеп авылның һәр кешесен үзенә дәшеп торган Түгәрәк урманга юнәлделәр. Исеме Түгәрәк булса да, урман шикелле урман иде ул – алты каены, җиде усагы, дүрт юкәсе бар... Калган агачларның исемен төгәл генә әйтә торган түгел, чөнки Түгәрәк урман үзе карурман эчендә.

Өч чакрым араны мондый тизлектә үтәргә күнекмәгән халык очрашу мәҗлесен арба өстендә үк башлап җибәрде. Балалар саны, машиналар маркасы, зарплата һәм коттеджлар турында сөйләшүгә егерме биш ел күрешмәгән классташларның күп вакыты китмәде. Кул саен берәр сумка ачылды, буш кулларда кырлы стаканнар уйнаклап торды. Наил классташлары өчен сөенеп, арткы тәрәзәдән күзен алмый, ә дуслары аны үртәп юл читенә буш шешә ыргыта... Урманга килеп җиттек дигәндә, Түгәрәк урман әйләнә башлаган иде инде.

Апрель аеның мичe суык чак. Учак тирәли гүя ботка пешермичә генә уникe бүре утыра. Өченче тапкыр батареяларын алыштырганнан соң, магнитофоннан ала карга тавышлары гына ишетелә башлаган иде.

Наил, кәефле дуслар алдында күз көеге булып утырмас өчен, уенчык тракторын сөйрәп карурманга кереп китте, бәлки, берәр болында узган елгы печән чүмәләләре адашып калгандыр йә торыктан корыган имәннәр очрамасмы – авылга берәр рейс илтеп килер.

Көнне уникe кешегә бүлә торгач, кич бик тиз җитте. Чыбык-чабык сындырырга иренгәч, учак та сүнде. Инде бер-береңә сораулар да бирәсе килми. Барысы да аңлашыла – авылга кайтырга кирәк.

Ә Наил юк. «Луноход»ының тавышы да ишетелми. Ул, мөгаен, Түгәрәк урманда таң атканчы утырырлар дип уйлагандыр.

Өйрәнә торгач, шунысы ачыкланды: учак тирәсендә дүрт яктан дүрт юл кисешә икән. Кайсысы авылга алып кайта торганы – монысын юл үзе генә белә. Кыскасы, уникe кеше берьюлы адашты... Авыл төньякта калган иде, ә көньяк кайда?! Ай бүген таң алдыннан гына чыгам, диде. Карурман өстендәге билгесез йолдызлар учак тирәсендәге коньяк шешәләрендәгечә генә җемелди, һич юл күрсәтерлек түгел... Горурлыкка көч килмәслек итеп кенә, Наилне чакырып, кычкырып караганнар иде, ләкин «Наил» сүзе ерактан алҗыган тавыш белән «ил... ил!..» дип әйләнеп кайтты. Карурманның дымсу ышыгы тәнгә сеңә башлагач, кайту чарасын эзләү бәхәскә әйләнде.

– Кычкырып елап карагыз, кульяулык алганда кесәгездән компас төшмәсме?

– Дүрт төркемгә бүленәбез дә дүрт ягың кыйбла! Кем алдан авылга чыга, башкаларны җыя!

– Әй, сез, баш врачлар, баш инженерлар, баш механиклар, башлыклар... адашканда юл күрсәтерлек башыгыз да булмагач!..

– Компас ясыйбыз...

– Имән бармагыңны магнит угы итепме? Сез юл күрсәтергә оста!

– Кеше – аяклы магнит!

– Магнитың тартып тора...

– Хатын-кыздан компас ясасаң табарсың юлны, бар!..

– Ирләрне компас угы итеп агачка эләбез, чалбар каешыннан... Баш ягын «плюс» диярбез, аягы «минус» булыр.

– Ике полюсы кушылган ирләрне элмибез. Каеш та жәлке.

– Туктагыз! Баш ул – акыл оясы, ә акыл дөньяда иң тискәре нәрсә. Шуңа күрә аяк ягын «плюс» дип алыйк. Мин аягыма күбрәк ышанам.

Компас угы итеп һәркемне – түгәрәк гәүдәлеләрне, хәтта хатын-кызларны да ботакка элеп карадылар. Ләкин һәркайсының үзенчә – башы бер, аягы икенче якка күрсәтте. Шулай итеп, карурман куенындагы әлегә Түгәрәк урман уникe көньяклы һәм уникe төньяклы булып чыкты.

Һәркем үзенә генә ышанды һәм үзе сайлаган юлдан гына атлады.

Наил арбадагы солы саламы өстендә гырлап йоклап ята иде, кинәт туңып уянып китте. Кул сәгатенең ике угы да уникe өстендә кавышкан. Классташларның хәлен белеп килим әле дип урманга керсә – учак сүнгән, дусларның эзе суынган...

Лаеш, Мамадыш, Сукырлы, Питрәч ягына юл алган уникe ватык компасны солы саламы өстенә төяп кайтып кергәндә, авыл халкы колхоз эшенә ашыга иде инде...

## ЧОРМАДАГЫ ФӘРИДӘ

Зарлану димәгез, сүз уңаеннан гына әйтәм, элек без, җыелган акчабызны учлап, көне-төне мал эзләп чаба торган идек. Ә хәзер... мал үзе эзләп килә. Почта әрҗәсен ачып җибәрүгә, учлап-учлап реклама хәбәрләре коела: сатам, төзәтәм, өйрәтәм, өшкерәм, сөйдерәм, бүләк итәм ише фирмалар көне-төне юмалап, үзләренә чакырып тора.

Бушлай гәҗит эченнән биш долларлык акча хәтлек кенә бер чакыру килеп төште – күрше йортның чормасын җиһазлап, чәч китәрүчеләр яңа остаханә ачканнар. Биш доллар хәтлек дип әйттем, чөнки Джордж Вашингтон рәсеме урынына чәч китәрүче кызның сурәтен куйганнар. Ә кыз һәйбәт... долларын күргән саен күрәсе килә...

Чәч китәрүче кызларның холкын беләсез инде, алар такырбаш клиентларга сәлам дә бирмиләр. Ә мине әллә кайдан ук күреп алып, ак халатларын җилпи-җилпи өч креслога берьюлы урын тәкъдим итәләр.

Чират та юк, ялындыручы да юк, буш креслоларның берсенә чумдым. Җилкәм түрдә, аяк идәндә, сурәтем көзгедә. Рәхәттән изрәп, күзнең берсен йомып куйдым, икенчесе белән көзгедән чәч китәрүче кызның сурәтен көтәм.

– Бу чибәр егеткә нинди прическа ясыйм? – дигән тавышка күземнең икенчесен дә йомам.

– Яшьләрчә булсын, – мин әйтәм, – матурайтыгыз әле бер, юкса бөтенләй кешегә күренерлегем калмады.

– Сиңа бишенче модель бик килешергә тиеш, тәвәккәлликме?

– Үзегез чамалагыз инде, осталык сездән, чәч миннән.

Шулчак минем яңакка бик йомшак, хәйран кайнар нәрсә орынып үтте. Күзнең берсен генә ачып карыйм... Сөбханалла... доллардагы президент кызның түше бит бу! Әллә чәч китәрүчем үзе дә минем креслога менеп утырганмы соң? Икенче күзем шар ачылды! Ну эшнең тәмен белеп эшләүчеләр бар бу дөньяда... Ак халатлы остам гәүдә бөгелешләрен минем иңемә туры китереп, чын күңелдән бишенче модель белән мавыккан иде. Көзгегә карасам – абау ул йөзнең сылулыгы – тасвирлап күрсәтер идем, куркам, аннан соң бу хикәяне укыган ирләр шул кызның адресын безгә дә әйт әле дип җаныма тиярләр иде бугай. Кызый кулындагы көмеш кайчысы белән керт-керт итеп биш тәңкәлек чәчемне турый, чәчемне түгел – бәгыремне! Күңелемдә берьюлы йөз сорау туды.

– Исемегез дә үзегез кебек матурмы?

– Фәридә.

– Карасана, Фәридә исемле матур кызлар да була икән! Фәридә, син бу тирәдә яңа кеше, ахрысы, элек бер дә күргәнем юк иде.

– Әйе, бүген генә күчерделәр.

– Син Фәридә, үзең кеше чәчен тураклыйсың, ә үзеңнең толымнарың – күз тимәсен! Егетләр күп бәйләнәләрдер сиңа.

– Исләре дә китми... Менә, бишенче модель шушы инде, йә, килешәме, матурым?..

– Бетте дәмени?! Бик тиз. Их, ике башлы түгел шул без бу фани дөньяда! Менә хәзер икенче прическага тотыныр идең... Туйганчы сөйләшеп тә калмадым.

– Башыңа бүрек киюгә онытырсың әле.

– Минме, синеме? Ниме, Фәридә, чәчне бер көн эчендә үстереп була микән? Иртәгә тагын килер идем.

– Онытырсың. Чибәр егетләр хәтерсез була...

Бишенче модельләренә йөз илле сум түләп чыгып киттем. Үзем урамда, җаным Фәридә янында калды.

Икенче көнне иртүк, ачылышына ук өлгерим дип, тагын чормадагы Фәридә янына килдем. Килсәм, гомердә булмаганны, чормада җир буе чират. Әллә ялгыш аптека ишегенә бастыммы дисәм, юк, дөрес инде – чәч алдырырга килүчеләр чираты.

Чиратым җиткәндә эшемә дә соңга калган идем инде. Креслога утыруыма ук таныды Фәридә.

– Прическаң матур бит әй, баһадирларча гәүдәңә килешеп кенә тора.

– Ни бит, Фәридә, спортчыларныкы кебек кыска чәч килешәрәктер миңа? Күптәннән кызыгам шуңа.

– Кичә үк әйткән булсаң соң, алтыным...

– Кичә үзем дә аптыраган ла ул.

Фәридә мине спортчы кыяфәтенә керткән арада җыелган халыкны күрсәң... Хәзер министрлар кырына керәм дисәң дә ул хәтле чират юк. Чират дигәнем мине утыргычтан төртеп төшерердәй булып чырай сыткан.

Ә утыргычта мин! Фәриднәнең кулы минем йөз илле тәңкәлек чәчне сыйпый. Күкрәге белән яңагыма тәки тиеп-тиеп, тиеп-тиеп, тиеп-тиеп ала.

– Рәхим ит, чәчең олимпия чемпионнарыннан ким түгел.

Минем, чиратка үч итеп, утыргычтан төшәргә исәбем юк.

– Фәридә, спортчы буласым килми, малай чакларым искә төшәрдәй иттереп, маңгай чәчен генә калдырыйк әле. Калганын кырып ташла. Түләү мәсьәләсендә борчылма, һәр заказ минем өстә.

Фәридәне әйтәм, җитез бит әй, чираттагы ирләр бер-ике кат тамак кырып өлгергәнче, газиз башкайларым утыз яшемә чаклы үстергән тубалдан котылып, маңгай өстендә кәҗә койрыгы хәтле генә чәч укмашып калган иде.

Хушбуй сибәргә ирек бирмәдем, урыныма башка кешене утыртасым килми. Фәридә янында рәхәт, менә шулай көннәр буе чәч алдырып кына утырыр идем. Ә чәч бетеп бара. Тагын нинди прическа ясатырга микән?

– Фәридә, беткән баш беткән, әйдә, бөтенләй алдырып ташлыйк әле, такырбаш булып йөрисем килә.

– Кыш көнеме? – диде остам, ике иңбашын берьюлы сикертеп, – ихтыярың, карлыгачым, миңа барыбер.

Күптән шулай әйтәсем калган икән... Вәт ичмасам мәшәкать! Фәридәм мине сабый баланы көйләгән кебек итте: җитәкләп юынгычка алып барды, күбекләндерде, үткен пычак белән ялтыратып кыра башлады, киселгән җиренә өф-өф итеп кершән сипте. Чираттагы ирләр, көнчелекләреннән нишләргә белмичә, урам ягына таба борылышып бастылар.

– Фәридә, иртәгә шушы вакытларда керсәм сине тагын туры китереп булыр микән? – дим.

– Иртәгә? – диде ул, иртәгесе көнгә бик зур мәгънә өстәп. – Синең чәчең калмады ласа, инде шәт ике айсыз үсмәс тә, әнә көзгегә кара, шаһзадәм...

Көзгедә мин үземне танымадым... Ярар, матураербыз әле.

– Ике ай күрми торсам, үләм, әлбәттә. Мин иртәгә парик мазар киеп килермен, парик китәргәнең бармы?

– Юк, тәк, былбылым, синнән төгәл йөз тәңкә. Кем чираты анда, килегез! – дип, Фәридә парик мәсьәләсендә артык җәелеп сөйләшүгә вакыт калдырмады.

Чираттагылар минем такыр башымнан көлеп калдылар. Шулай, бәхетле кеше гел көлке тоела инде ул.

Күкрәк киереп урамга чыктым. Баш түбәсенә «каз тәне» йөгерде, тышта хәйран салкын икән – бөрек эченә җил керде. Баш кечерәйгән, колакчынны төшереп бәйләргә туры килде.

Иртәгә, иртәгә, иртәгә нишләргә? Фәридә янына нинди хәйлә белән керергә?

Уйлый торгач, тәки чарасын таптым. Әгәр, минем урында берәр хатын-кыз, киресенчә, чәч китәрүче егеткә гашыйк булса, ул, әлбәттә, тап-такыр итеп чәчен алдырганнан соң ике-өч айсыз монда килә алмас иде. Ә мин киләм, иртәгә үк! Чөнки мин ир-ат, чөнки мин бәхетле, чөнки миңа сакал һәм мыек үсә!

Иртәгесен мыек төзәттерергә дип керсәм – Фәридәм юк! Мин генә түгел, егермеләп такырбаш эзли иде инде аны. Тиз генә мөдирне чакырттык, өстәл сугып Фәридәнең адресын таптырабыз.

– Борчылмагыз, – диде мөдир, аркабыздан сөеп, – Фәридә генераль директорның махсус приказы белән күрше остаханәгә җибәрелде, планнары үтәлмичәрәк тора, ди. Безгә дә өч кенә көнгә биреп тордылар аны, юкса планыбыз кычкырып янасы иде... Фәридә эшләгән җирдә план үтәү берни түгел ул...

Һәм без, егермеләп такырбаш, күрше чәчтарашханәне эзләп чаптык.

# КӨН ҺӘМ ТӨН

Кояш та җирне тигез җылытмый...

Дөньябызның бер ягында – төн, икенче ягында – көн.

Ауропада таң атса, Ерак Көнчыгышта кояш байый.

Урыс җирендә көн ачылса, Әмрикәдә көн бетә. Урыс малае йоклап ятканда, Әмрикәнең бәләкәче эшкә китә.

Мөселман кардәшләр, урыс дип атаганга кимсенмәгез, урыс сез пока – Мәскәү чиркәүләре чаң кагып уята, чаң сугып йоклата. Әгәр уятмаса, эшегезгә соңга калып, чукына-чукына, әстәгъфирулла, трамвай куар идегез, аңлатмалар яза-яза чукынышып бетәр идегез... Бездә шау-шулы көн туганда Әмрикәдә тып-тын төн уртасы, шуңа күрә алар чукына-чукына, әстәгъфирулла, тфү-тфү, трамвайлар да куып йөрми, кабинетларда да чукынышмый.

Кояшы да аумакай бу дөньяның – ике арада тик йөри шунда буталып... Пентагонда таң атканда, Кремльдә караңгы төн. Капма-каршы тормыш! Алар ашый – без йоклыйбыз, без эшлибез – алар ашый. Без социализмга капиталь ремонт ясыйбыз, ә алар социализмнан капитал ясый. Без аларның империализмын сүгәбез, ә алар безнең коммунизмда яши.

Аларда хәтта сыра сөючеләрнең дә партиясе бар, ә без исә миллионер партиябезне дә сатып эчтек.

Түгәрәк Җир шарында торышларыбыз үзгә булган кебек, тормышларыбыз да үзгә. Бездә – төн, аларда – көн. Әмрикәнең джентльмены сөйгән кызы белән коктейль эчәргә килгәндә, сәвит мужигы инде сөяркәсе белән айныткычта төн кунып чыга. Мистерның олы кызы туй күлмәге кигәндә, товарищның кече кызы төялеп кайтып та керә. Канзас-сити гимназисты сексопатологка сорау белән барганда, Казан пионеры гинекологка имтиханын алдырып кайта.

Бездә – төн, аларда – көн. Без йоклыйбыз, дошман йокламый. Колумбия мафиясе әле план гына кора, ә мәскәүнекеләр инде портфель бүлешә.

Аларда һәр кеше корал йөртә, ди, байлыклары күптер... Получка алган көнне безне дә уклау күтәреп каршы алалар. Сәвит мужигына башка коралның кирәге юк.

Менә шулай, товарищ! Бездә – төн, аларда – көн. Аларда – инфляция, бездә – спекуляция, аларда – порнография, бездә – мафия, аларда – эшсезлек, бездә – бушсүзлек, бездә – демократия, аларда – демонстрация... Ә бер карасаң, бар да киресенчә. Чөнки көн белән төн алышынып тора. Аларда – көн, бездә – төн. Бездә – Кремль, аларда – Ак йорт. Бездә Горбачев, Ельцин, Шәймиев, аларда – Буш кына. Исеме Буш кына булса да, Әмрикәсе буш түгел.

Ярый ла Кояш Җирне тигез җылытмый... Әгәр, мисал өчен, әйтик, Кояш һәммәбезне дә тигез күрсә һәм бездә төн булганда аларда да төн булса, без йоклаганда йоклап, без уянганда гына уянсалар... Безгә кызыгып алар да революция ясаса?! Алар да безнең көнгә калачаклар. Перестройка дигәннәре аларның да күрмәгәнен күрсәтер!..

# ТЕЛЕҢНЕ КҮРСӘТ...

Докладымны йомгаклап шуны әйтергә телим: татар теле һәм милләте турында сөйләрлек вакытым калмады... Сайлаулар турында күбрәк сөйләп аттык.

Пнимаете, мине бер сорау борчый, ни өчен безнең татар ике телле? Аның әле берсен дә тыяр хәл юк! Урысның пичәтендә ике башлы бөркет була торып та теле бер генә! Ә безнең канатлы барс бер башы белән ике телдә сөйләшә, ике гражданство иметь итә. Безгә нимидленно Рәсәй белән пичәтләрне алмашырга кирәк! Татарга ике башлы бөркет таман булачак! Аның бер башы татарча вәгазь сөйләп торыр, ә икенче башы урысчалатып гел «каравыл!» кычкырыр. Пчему? Птамушты бер Казанга ике бөркет башы сыя.

Пнимаете, ике тел берьюлы сөйли алмый. Берең сөйләгәндә, икенчең юл куярга тиеш. Ягъни мәсәлән, Фәүзия Бәйрәмова булган җирдә Владимир Жириновский ... кысып кына йөрергә тиеш. Бөтен вопрос та шунда, урыс сөйләгәндә татар дәшми түзәрме? Юк, кәнишне! Ну элек булса, кирегә сукаламыйча тыелып калыр идек. Ә хәзер – юк! Телебез озынайды соңгы елларда. Кабатлап әйтәм, телебез үсмәде, ә озынайды! Йә, апаем, телеңне күрсәтеп кара әле!.. Тәк, тәк, оялып торма, чыгарып күрсәт! Әнә, күрдегезме! Разве мондый телне тыеп була?! Бик әйбәт. Телнең хәзер бик кирәк чагы. Хәзер Рәсәйдә бөтен нәрсә тел белән генә эшләнә! Кем сөйли – шул ашый! Кем тыңлый – шул эшли! Татарга да тел бик кирәк! Пчему? Птамушты телең булмаса, ике башлы бөркет күтәрә дә китә!

Пнимаете, ике телдә берьюлы сөйләп булмагач, бер генә телдә сөйләшәсе кала. Гел татарчага гына күчсәк, безне урыс дәдәң аңламас инде, ник дисәң, безнең өйдә җитмеш ел яшәп, ул татарча җиде сүз дә өйрәнә алмады. Гел урысча сөйләшүне генә калдырсак, татарларга тагын сүгенергә туры килә, чөнки урысча сүгенүе рәхәтрәк.

А все же выход бар, иптәшләр! Безгә шундый җайлы телдә сөйләшергә кирәк – урыс та, татар да шундук аңлап алсын. Ике телне бергә кушып сөйләшик. Татар сүзлегеннән утыз мең сүз, урыстан йөз мең сүз алабыз да шуларны бер казанга салып болгатабыз. Һәр икеңә дә аңлаешлы тел килеп чыга. Без инде күптәннән бирле: пнимаете, кәнишне, гупчым, значит, мужыт, зәмичәтелни, әбизәтелни, как раз кебек алты-җиде һәм тагын өч хәрефле сүзләрне бик удачны кулланып сөйлибез. Урыска да бераз татар телен өйрәнергә туры килер. Пчему? Птамушты сүз сыер теле турында бармый!

Национальный вопроска килеп терәлгәч кенә телсез калды димәгез, сөйлим әле...

Кем белә, бүген урысларда күпме татар бар? Җиде миллионмы? Уникеме, бәлки, егерме биштер, ә? Мин дә белмим. Перепись үткәрергә вакыт юк – референдумнар күбәйде. Ну шунысын яхшы беләм: халык саны кими, иптәшләр... Кавышучылар көннән-көн арта, гүләйт итүчеләр дә җитәрлек, ә халык үрчеми. Пчему? Птамушты көн саен бала ясап була, ә көн саен бала табып булмый. Бала үстереп баракларда-общежитиеләрдә чиләнеп ятканчы, дүрт ваучерлы хатынга йортка керүең җайлырак.

Пока халык санын качаклар хисабына арттырабыз. Правды, кемнең кайсы милләттән икәнен ачыклавы көннән-көн кыенлаша. Тышкы кыяфәтенә карап кына кешене танып булмый хәзер. Элек кемнең кем икәнен психбольницаларда барыбер ачыклый торган идек. Бүген исә кешенең милләтен ухо-горло-нос врачы да ачыклый алмас. Чөнки бездә хәзер кечкенә борынлы яһүдләр, зәңгәр чәчле татарлар, кысык күзле урыслар һәм сап-сары башлы негрлар күбәйде. Нотык сөйли-сөйли тел очыңа төер чыкса, кемгә төкерергә белмәссең!

Кешенең милләте ни өчен кирәк диярсез инде сез. Кирәк! Бөтен халык бер тишеккә тулмасын өчен кирәк ул. Буталмасын дөнья! Юкса, айга карап чукынырга ярамаган кебек, дуңгыз итеннән бәлеш пешерергә ярамый! Чалманы муенга шарф итеп урарга ярамаган кебек, чапанны мини юбка итәргә ярамый! Урысны сөннәткә утыртырга ярамаган кебек, комганнан чәй эчәргә ярамый!

Күзгә күренеп үзгәрәбез...

Кешечә булсын дип, без дә буй-буй байрак астына тезелдек. Тарихта беренче тапкыр үзебезнең гимнны яздык. Правды, халыктан күптөрле тәкъдимнәр килде, ник ул депутатлар, «Их сез, матур кызлар!» дигән җырны гына гимн итеп алмадылар, дип җанга тиделәр. Во-первых, иптәшләр, яңа җыр

чыккан саен гимн алыштырып булмый, икенчедән, Асаф Вәлиев җырлап йөри торган ул җыр – удмуртларның күптән списать ителгән җыры!

Таким образым, телебез бар, милләтебез яши, гимныбыз яңгырый, байрагыбыз җилферди! Калганы – базарда!

Пнимаете, милли мәсьәлә буенча артык телеңә салынырга ярамый, күп сөйләсәң, телеңне кыскартырлар. Пчему? Птамушты!..

# АЙГА МЕНӘСЕМ КИЛӘ

Конверсия уңаеннан, Казандагы кайбер шау-шулы заводларны тынычрак эшкә көйләп җибәргәч, күңел тынычланды. Күңел тыныч хәзер, акча күп, баш аек... Аек башка әллә нинди дуамал уйлар килә.

Нишләп соң әле, мин әйтәм, татарлар арасында бер генә космонавт та юк?! Без космодромнан ерак яшибез, шуңа күрәме? Җиде миллион татарны үлчәүгә салсаң, нужәли инде арабыздан скафандр кидерерлек бер кеше табылмас икән?

Вәт әкәмәт, Мәскәүнең бөтен ракеталары да ике йә булмаса өч урынлы гына. Әйтик, аларны күп урындыклы итеп эшләсәң ярыймы? Ярый! Теге, сыгып чыгара торган ризыкларны әзрәк алсаң, аңа теләсәң күпме урындык сыя. Ул хәтле ризык төягәч, әлбәттә, киткән бер космонавтлары галәмдә еллар буе әзерне ашап ята. Рәхәт чөнки, чиратларда бил сындырасы юк, кием-салым кирәкми, фатир проблемасы хәл ителгән – кирәксә, тагын ике-өч бүлмәле станцияне китереп сылыйлар. Алар Җир шарына төкереп тә бирми – орбитада әйлән-бәйлән уйнап тик йөриләр. Хәтта акча алыштырырга да кайтмадылар...

Әгәр ракеталары унике урынлы булса, без дә качар идек бу мәхшәрдән. Юк, унике үк кирәкми, без үзебез ише суверен дәүләтләр арасында, тамак ягыннан санаганда, җиденче урында торабыз, димәк, ракетаның җиденче утыргычында берәр татарга да урын калуы ихтимал диган сүз. Унике утыргычлы булса, литвалылар да очар, боерган булса. Унҗиде урынга китсә, башкортларга да чират җитәр. Ә инде кырык сигез урынлы «Икарус»лар йөри башласа, Себер халыкларының барысын бергә җыеп алып китәрләр...

Нәрсә дип әле урыс халкы ракеталарга сыешмагандай кылана?! Утыртсыннар безне дә! Юкса күрше-күләннәрдән оят, урыс телен белә торып космоска чират көтеп ятабыз. Әнә Буа шикәр заводы хәтлек кенә Кубаның да үз космонавты бар. Кубалылар хәтле генә урысча беләбез инде анысы, җитмеш ел буе өйрәндек, бөтен татар мәктәпләрен ябып бетердек – һаман да шул, урыслар ракетага утыртмас микән дип. Утырттылар...

Космонавтлар отрядына эләгер өчен нинди генә имтиханнарны тапшыра алмый икән соң безнең татар егетләре?! Имтиханнарда түгелдер хикмәт. Әллә чырайларыбызны ошатмаган булалармы? Алай дисәң, нинди генә адәмнәр менмәде инде ул галәмгә! Сары чәчлеләре дә, пеләш башлылары да, табак битле кысык күзлеләре дә, мыеклы зур борынлылары да... Эзли китсәң, андый чырайлар татар арасында күбрәктер дә әле.

Ерак сәфәргә чыгар өчен җайлы халык без: беренчедән, хәзер татарга тылмач бөтенләй кирәкми, патшалар кушкан телне ана телебездән дә яхшырак беләбез. Икенчедән, ашау-эчүгә дә нәзберек түгел – бер телем ипи белән урталай ярып пешергән кабыклы бәрәңге тоттырсаң, галәмдә пенсиягә чаклы җан асрый алабыз. Безнең өчен ракетага күп нәрсә төйисе юк: киндер ыштан, тула оек, бер кием чабата, ике комган берсе бит юар өчен, икенчесе... Хәер, ипи белән бәрәңгенең гел сыгып чыгара торганын гына бирсәләр... бер комган да җитә.

Безне самимигә санамагыз, галәмгә чакырганнарын көтеп кул кушырып утырмадык. Арабыздан бер тәвәккәлне сайлап космонавтлар мәктәбенә үткәрдек. Кемлеген тиз генә абайлый алмасыннар өчен Марс исемлесен, Буа башкортын тапкан идек. Бөтен сынауларны үтеп, скафандрлар киеп кабинага кергәч, ракетаның төбенә ут төртәбез дигәндә генә, безнең Марс Рафиков сәяхәт алдыннан «Партиягә дан!» дип әйтәсе урында, ялгыш «Аллага тапшырдык» дип җиффәргән. Шундук скафандрын салдырып алганнар тегенең.

1961 елның 12 апрель көнне «Татарин космоста!» дип бөтен Рәсәйнең коты очкан иде. Имеш, юри генә Алексеевич икән, татарлыгы хак, ди... Безнең түрәләр сөенечтән Мәскәүгә ике миллиард тонна нефть бирергә, татар авыллары өстенә КамАЗ заводы төзетергә һәм өстәвенә Казан артына АЭС куйсагыз да риза дип вәгъдә биреп өлгергәннәр. Вәгъдәне биргәннәр бирүен, тик космонавт Татарин дигәннәре Гагарин булып чыккан. Сөенечле хәбәр ашыгычлык белән ялгыш ишетелгән, ди. Ә кем белә, бәлки, Гагарин чынлап та Татариндыр әле?! Татарларны Галәмгә җибәрмәсләрен белгәч, юри урыс булып язылгандыр... Тарихта андый хәлләр җитәрлек. Брест крепосте каһарманы майор Гавриловның керәшен татары икәнлеген сиздерделәрме – юк! Державин дигән атаклы урыс шагыйренең дә татар егете икәнлеген бөтен кеше белми. Әнә Ленинның да бер әбисе татар булып чыкты, хәер, монысы

белән бик мактанырга ярамый бугай хәзер. Мисал эзләп алай ерак китәсе юк, патшаларны гына күр – бөтенесе татардан азынган: Борис Годуновның да кем икәнен беләбез! Иван Грозныйның хатын ягыннан әбисе дә татар кешесе, аның Казанга яу белән килүе шул тещасына ачу итеп кенә лә... Михаил Перестройщикның да хатынын үзебезчә, иркәләп, «Рәйсә килен» дип кенә йөртәбез.

Мактанырга миңа куш, бераз читкәрәк кителде бугай... Сүзебез татар космонавтлары, ягъни юк нәрсә турында. Алло, космос, «САЛЮТ», «ПРОГРЕСС», «СОЮЗ», «МОСКОУ»! Ишетәсезме безне, майть якаңны?! Юк, ишетмиләр, ә без аларны гел ишетәбез. Бөтен галәм ишетсен өчен безнең «ТАТАРСТАН»га үз космодромы булу кирәк. Минемчә, космодромны үзебезнең АЭС өстенә салып куйсаң, бөтен татарларга да күккә очар өчен җайлы булачак. Ракеталарга ягулык мәсьәләсен хәл итәргә дә җиңел – ул тирәдә теләсә кайсы чишмәнең суы машина заправить итәргә ярый. Инде төзелеш өчен акча юк дисәләр, иң әүвәл җиде миллион түбәтәй тектерәбез, аннан шул түбәтәйләрне сузып бөтен ил буйлап китәбез. Хәер сорашу мактаулы эшкә әверелде ул хәзер.

Кайберәүләр минем белән бәхәскә кереп маташыр. Ниһаять, Җирдәгеләргә җир өләшә башлагач кына, зыяннан гайре хыял китермәгән Галәм турында сүз күтәрү нигә кирәк дияр. Кирәк, безгә космоска очу бик кирәк! Милли мәсьәләләрне Җирдә хәл итеп булмаячагына ышандык бит инде. Галәмгә чыккач, Җирдәгеләрнең тартып тору көче алты тапкырга кими, димәк, авыр гәүдәләребез алты тапкыр җиңеләя, проблемаларыбыз, архивларга теркәлгән гөнаһларыбыз юкка чыга дигән сүз! Димәк, урыныбыз җәннәттә булыр, Алла боерса! Ә җәннәттә бөтен кешенең дә милләте вә халәте тигез...

Беренче татар космонавтына алдан ук дан!

Яшәсен татар космонавтикасы!

# КЕМ ТҮБӘСЕНӘ НИТТЕҢ?!

Аулак өйләрдә уйный торган бер уен бар. Бөтенең бергә өелешәсең дә, баш бармакларны тотып, «Без, без, без идек, без уникe кыз идек...»не әйтеп бетерәсең. Аннан шым буласың да бер-береңне сүзсез генә үрти башлыйсың. Әгәренки берәр кеше авызын ачып көлеп җибәрсә – аңа шундук җәза. Андый-мондый җәза түгел, маңгайга чиртү! Башта «кем түбәсенә ниттең?» дип җаныңа тияләр. Кем түбәсен әйтсәң, шул түбә астында яшәгән кеше саен маңгаена берне сылап торалар...

Кызык уен ул, эш югында уйнарга рәхәт.

Безнең Казанның уналтынчы, егерме икенче, кырыгынчы, ике йөз дә утызынчы заводларында аны атнага өчәр көн уйныйлар...

Сез дә тик утырганчы шул уенны уйный торыгыз. Ну, ялгыш авызыгыз ачылып китеп «кем түбәсенә ниттең?» дип сорасалар, берүк безнең түбәне әйтә күрмәгез. Маңгаегызны чиртеп ярырлар. Баракта яшибез без.

Баракның да төрлесе була. Әйтик, уналтынчы заводның бараклары уналты метр озынлыгында, егерме икенче заводныкы егерме ике метр коридорлы, ә без ике йөз дә утызынчы заводныкында яшәп ятабыз... Ике йөз дә утыз метрның нәрсә икәнен күз алдына китерә аласызмы? Ну, әйтик, сез чатыр чабып бәхет эзләп йөргән чакта ялгыш канализация торбасына егылып төштегез, ди. Шуннан көн яктысына чыгар өчен ике йөз дә утыз адым юл үтәргә кирәк. Алла сакласын! Менә шундый инде ул безнең барак...

Аның көньягына бассаң, төньягы күренми. Көньяк өлешендә ислемай түгелсә, төньяк өлешенә барып җиткәнче ул черек бәрәңге исенә әверелә. Әгәр төньяк өлешендә берәр нарасый горшокка утырса, баракның көньяк өлешендә ашыгыч рәвештә эвакуация башлана.

Хат ташучы егетләр күтәреп килгән гәҗит-журналларын коридор буенча велосипед белән генә таратып йөриләр, бик ашыккан чакларында мотоцикл белән... Таратып бетермәгән көннәрдә кунып китәләр. Кунарга гына килгән кешегә кызык бездә.

Шау-гөр килеп яшәп ятабыз...

Безнең баракта ике дискотекага җитәрлек тол хатын яши, ике нарсуд залын тутырырлык сәрхуш бар, бер детдомга җитәрлек бала-чага! Кичкә керсәң, Опера һәм балет театрына әвереләбез: ишек саен дуэт, почмак саен ария, коридорда ут сүнгәч, балет башлана. Көн саен шул ук артистлар... Туйдыра, кәнишне.

Ике йөз дә утызлы баракның ике метры – брат белән икебезнеке. Братка илле яшь, миңа кырык. Ике ятим бер язмыш белән яшәп ятабыз.

Хатыннардан бәхет булмады безнең. Башта атайның хатыны китте. Аны эзләп атай үзе дә чыгып киткәние, ике ел инде што-ты кайтканы юк. Аннан соң атайның олы малаеның хатыны да чыгып качты, ну, шушы братның хатыны. Соңыннан минеке дә олакты... Әй, эчмәгән хатыннар белән яшәп буламыни! Аек хатын сүз күтәрми бит соң ул, шылт иттең исә, төяла дә чыгып китә. Ходайның рәхмәте, әнә башкаларның хатыннарын бaрактан куып та чыгарып булмый, шешә сдавать итәргә дә

ирләре генә йөри. Юк инде, беребез-бер уңмадык хатыннардан. Әйтәм ич, эчмәгән хатын кешемени ул?! Кием-салымның да зиннәтлесен давай аңа, ашау-эчүгә дә нәзберек алар, аларга фатирның да теге – депутатлар яши торганы кирәк, баракка гына риза түгел. Шуңа күрә мин хатынны кудым да чыгардым, бар, эчәргә өйрәнгәч кайтырсың, дидем. Ну, матурые үзе, иреннәре зурые аның, ачылмаган губной помада ике генә тапкыр сөртергә җитә торганые. Күпме иннек ашатты инде ул миңа! Үзе кайнарые, чукынчык. Авылга кунакка кайткач, бермәл кызып кителгән, ул, миннән качам дип, ялгыш бабайның кар базына егылып төшкән дә таң атканчы шунда утырган. Күрсәң, малай, таң атканчы баздагы бөтен кар эреп беткән... Ә менә братның хатыны киресенчә – салкыные... Каян беләмме? Брат аның куенына керүгә төчкерергә тотына иде. Нишлисең бит, бөтенебез шул ике метрлы бүлмәдә. Төне буе братның төчкергәнен тыңлап ятарга туры килә. Әле берара, мин төчкереп йөри башлагач, хатынымнан көнләшеп йөргән булды, мөртәт.

Брат белән хәзер үкенәбез менәтерәк, дуракланып нәрсәгә дип өйләнеп йөргәнбездер, ул туйга киткән аракыны икәү генә эчсәкме... өч көнгә җитәрие!

Әйдә, ярар, узган эш – төзәтелгән баш, ди. Сер бирмибез, әле менә «без, без...» уйнаганда ниттерерлек түбәбез бар. Олы Иван белән кече Иван дигәндәй, ике брат алты-биш, шөкер генә яшәп ятабыз. Безгә хәзер күп кирәкми... икебезгә бер ярты җитә...

Атайдан да бәхет булмады безнең.

Атай, дурак, биш ел буе зерәгә сугышып йөреп, нихәтле илне күреп, берәр юньлерәгендә пленга төшә белмәгән. Яшәп калсыные шунда, берәр Клара апа Цеткинага йортка кереп, без дә брат белән шунда сразы капиталист булып туган булырыек. Ул чагында без инде агалы-энеле братлар түгел, бароннар булырыек. Ну, һичьюгы инде, атай гына анда яшәп калса да, брат белән безгә ай саен берәр ящик гуманитар ярдәм җибәреп торырые.

Беркөн шулай, брат әйтә, атайның кем икәнен беләм мин, биш ел буе тәк кенә йөрмәгәндер, унбиш суткыга киткән җиреннән дә катын-кызлар эзләп килә иде аны, ди. Ә вдруг Ауропаның иң бай гуманитар ящиклы илендә, атакага барышлый, юл уңае берәр Карл Марксовларга су эчәргә кереп чыккандыр, ди. Аның кызлары күп булган, ди. Импортный мадамнар баланы бик тиз таба, ди. Расхутыннан тормыйк, эзләтик барон братыбызны, безнең ише туганнарын демократлардан талатып ятмасын монда, ди... Миңа шул җитә калды. Төннәр буе утырып белдерүләр яздым да станциягә төшеп һәрбер товарный поездга ябыштырып чыктым. Беләм, чөнки безнең йөк төялгән һәрбер вагон туп-туры чит илгә китә.

Ике ай вакыт үттеме-юкмы, тәки өченче борыныбызны күрү бәхетенә ирештек. Таң алдыннан кайтып төшкән бу: сакал-мыек баскан, өс киемнәре таланган, ялан аякка балтырлы калош кигән, ямаулы рюкзагыннан бер ярты чыгаргач кына таныдык. Шәмәрдәннән тиклем җәяү кайттым, юкса яртылык акчам калмый иде, ди бу... Өч борынга бер яртысын бушаткач, вокзалга төшереп кире товарный поездга утыртып җибәрдек, җәяү йөрмәсен инде, ни дисәң дә, жәлке, брат бит... Шуннан бирле атайның малайларын эзләүдән туктадык... Ялкау байдан хәерче туа, диделәр.

Алты кешедән бушаган ике метрлы бүлмәдә брат белән рәхәтләнеп яшәп ятабыз. Иркенгә өйрәндек шул, бүлмәне кысып тормасын дип, суыткычны да чыгарып саттык. Телевизорны да суыттык: безгә ярамый икән аны карарга, инструкциясендә экранга өч метрдан да якын утырмаска диелгән. Үзегез беләсез, безнең бүлмәбез ике метрлы гына. Кәмит күрәсем килсә, братның чыраена карыйм, диагональ буенча 61 сантиметрлы ул, төсле телевизор шикелле.

Вопшем, брат белән бик чыныккан кешеләр без... Илебездә тагын берәр этлек эшләсәләр дә кырыласыбыз юк.

Сезнең кебек «теге нәрсә юк, бу нәрсә юк» дип зарланып йөрмибез. Кашыкка ни эләксә – шул закуска, стаканга ни салсалар – шул исертә. Кайвакытта стаканыбызга шундый әкәмәтләр эләгә... бер кикерсәң, ике йөз дә утыз метрлы баракта бөтен чебеннәр кырылып бетә. Ә без исән! Чөнки бездә теләсә нинди чиргә каршы иманитет көчле. Просто бәхет кенә булмады безнең: ни атайдан, ни браттан, ни бaрактан, ни илдән...

Әгәр дә мәгәр «без, без, безиек» дип уйный калсагыз, кайсы илнең түбәсенә ниттең дип сорасалар, берүк безнең илне атый күрмәгез, безнең шикеллеләр миллионлаган бит әле, чиртеп маңгаеңны ярмагайлары...

# КҮКЕРТ МАЕ

Бу ярату дигәнең әллә нинди чирләр алып килә...

Гашыйк булганчы сиңа чуртым да юк, сау-сәламәт килеш тик йөрисең. Гашыйк булдың исә... аптекага йөгерәсең. Ә анда быел гына түгел, җитмеш ел буе чират, чөнки ярату мәңгелек, чөнки җирдәге барлык чиргә дә ярату гаепле. Сырхауның теләсә кайсысын туктат та сора – кайсы җирең

авырта, әйт менә?! Билеңме – бөгелергә ятраткансың, димәк, шулхәтлек яратам дигәч тә инде... Кулың эшләмиме – күтәреп йөртмәсләр аны. Аягың сызлыймы – хатының өстеннән ул хәтле йөргәнгә... Йә, әйт, тагын кайсы җирең авырта? Кан басымың уйнаклыймы – бер менә, бер төшә, бер менә-төшәме?! Аптырама, бик нормаль күренеш бу. Температураң утыз тугызга җиткәнме – җитсә ни!.. Әтәчләрнең тән температурасы тумыштан кырык ике градус әнә, аңа карап аптекага аспирин сорап килгәннәре юк! Белдеңме инде? Эчең авыртса да, йөрәгең авыртса да, башың түгел, сыртың авыртса да, шул ярату гаепле. Вакытында дәваланыйм дисәң, даруы да юк ичмасам, шуңа күрә бөтен дөньясы ярату белән тулган. Хәзергеләрнең эше дә, ялы да, ашы да ярату. Яраттырганчы эшлиләр, эшләгән җирләрендә ятышалар. Яратышкан җирләрендә тамак туйдыралар.

Гашыйкларны битәрләргә җыенмыйм. Үзебез дә яратыплар үлә яздык. Тәнендә җаны булган һәр совет товарищы ул елларда Хрущевка гашыйк иде – яңа туган малайларга Никита дип исем кушарга керештеләр, этиләре Сергей булганнарга медальләр өләштеләр. Ул влачка килгән елны ук, ни хикмәттер, сабын белән күкерт мае юкка чыкты, аның каравы яратуыбызны сынар өчен ул безгә кукуруз өләште. Ипи итеп тә ашыйбыз, ботка итеп тә пешерәбез, крахмалыннан кесәл болгатабыз... Бер ел ашыйбыз, ике ел... Кырларны, болыннарны кукуруз басты – силосы сыерларга, чәкәне безгә! Ярыша-ярыша чәкән кимереп тыныч кына яшәп ятканда, ирләр белән хатыннарны, егетләр белән кызларны талаштыра торган бер чир таралды. Теге... кашына торган нәмәрсә... Сыерларның койрык өстендә йоннары коелып тимгел-тимгел таплар чыга бит әле, әнә шул – корчаңгы – өйдән өйгә, авылдан авылга таралды. Баласы-чагасы, карты-корысы берсе-бер калмыйча кычына башлады. Кул җиткән төшне кул белән, җитмәгәнне сыерлардан бушаган баганаларга ышкып кашына, мин сиңайтим. Кашынмаган кешегә шикләнебрәк тә карыйлар иде ул чакта – корчаңгың юк икән, димәк, син Хрущевны яратмыйсың... Һәй, безнең халык патшаларны яратмыймы соң инде?! Ярата, шуңа күрә кашына... Иң әүвәл кычу дигәне мәктәпләрне басып алды. Укытучы кичә генә педны бетереп килгән малай-шалай була торган иде, ә без унынчы класс егетләре. Укытучы такта янында оеп тора, сүзен әйтә алмый – беләбез, аның да бераз кашынасы бар. Ул безгә сиздермәскә тырышып кына кулындагы указкасы белән җилкә чокырын тырмап ала. И, күрсәгез, малай, кычыткан җирне кашыганда шундый рәхәт ул... Укытучының күзе тона, гәүдәсе майшыклана. Аңа ярагач, без дә дөбер-шатыр кашынырга тотынабыз. Кая ул уку, кая ул дәрес! Хәер, ул елларда «кукуруз» сүзен дөрес итеп яза белсәң, класстан класска күчәр өчен шул җитә иде анысы... Вәйт, ярты дәрес кашынып үтә. Шулчак йөгереп кенә директор килеп керә. Ул хәйләкәр, ике кулын кесәсеннән чыгармыйча гына кашынырга өйрәнгән. Директор өстәл сугып кычкыра да йөгереп чыгып китә. Аны озак тоткарламыйбыз, әле тугызынчы, сигезенче, җиденче, алтынчы классларга кереп тә кычкырасы бар бит аның.

Бер арада клубны бикләп тордылар. Без кызларны биленнән кочаклап вальс әйләнә идек. Авылның фельдшерлары кочаклашуны тыйдылар, йогышлы авыру куеннан куенга тиз күчә, диделәр. Шуннан соң кемдер корчаңгылы күрше авыл клубыннан яңа төрле бию күреп кайткан... Ул биюнең җае шунда: ошатып йөргән корчаңгыңның бер җирендә дә кагылмыйча гына, ничек булдыра аласың, шулай селкенәсең, ягъни рәхәтләнеп кашынасың. Ул биюне хәзер дискотека дигән булалар... Пычагым, дискотека сиңа! Бездән калган «корчаңгы биюе» ул!

Соңыннан һәркем үзенең корчаңгысын озата кайта. Озатып әллә нишләмисең инде, ни турында гына сүз башласаң да, азагы парлашып кашыну белән бетә. Ә кайтыр юлда, үзең генә калгач, рәхәтләнеп аркаң белән чат саен багана шомартасың. Ул елны бик күп баганалар авышты...

Кыш буе шулай кашындык.

Язгы ташулар сабырлангач, инеш буена бөркәүле ике машина килеп туктады. Авыл халкына безне дә кушып, машина тирәсенә куып китерделәр. Берсенә кереп чишенәбез, икенчесендә киемнәребезне җыеп кыздыралар. Ветврачлар иде алар, чиренә күрә шулай тиештер инде. Киемнәребез суынган арада, тәннәребезгә күкерт мае сылап чыктылар. Ярату мәсьәләсендә саграк кыланырга дип үгет-нәсихәт тә биргәч, ветврачларыбыз күрше авылларга ашыкты.

Тәки котылдык без корчаңгыдан, истәлеккә теге биюләре генә калды. Хрущевтан да котылдык, әйтәм ич, артыграк яраттык без аны. Хрущевтан соң килгән Брежневны да яраттык. Нинди генә чирләр күрмәдек тә, нинди генә больницаларга кермәдек без Брежнев вакытында.

Хәзергесен дә яратабыз, ничек кенә яратабыз әле – аптекаларда имгә дисәң дә дару әсәре калмады.

Тагын кемнәрнең генә влачка киләсе бар икән дә, тагын нинди генә чирләр күрәсе бар икән гашыйк башкайларыбызның?!

Карале, яшьти, сезнең якларда сабын белән күкерт мае юкка чыккан, ди, дөрес хәлме ул?..

# БАКА КАРГЫШЫ

Безнең ПМК җитмеш ел буе сазлыкларны киптерде, әрәмәләрне сукалады. Аксакаллар әйтә, әнә шул сазлыкларның бакалары каргады инде безне, ди. Бака каргышы төшсә, яман икән ул, малай!..

Әйтәм ич, ПМКбызда рабочий класска көн бетте. Гафу, җәмәгать, яңача иттереп, «эшче сыйныф, фәлән-төгән» дип сөйли белмим. Үзегез төзәтеп укырсыз, бигайбә! Төннәр озынайды. Койма тирәсендәге лампочкаларны ватып бетерделәр, урларга мишәйт итә, диделәр. И тотындылар урларга... Башта каравылчыны урладылар – эте-ние белән! Аннан – механикны. Күп тә үтмәде, секретаршабыз юкка чыкты, начальнигыбыз белән... Баш инженерга чират җитте. Монысын да суыталар инде дип торабыз. Юк, алып китмиләр. Гаражда да кунып карады – юк, урламадылар. Заочно укыганын белгәннәр... Хурлыгыннан үзе китте.

Киткән начальство урынына кеше табылып тора. Менә алтын куллы механизаторларыбыз югала башлады. Гариза да язып тормыйлар. Араларында Озын Шәкүр атлысы барые. Ну, врач кебек инде, малай, сүнеп торган машинаның кырык төрле чирен таба... Китеп беттеләр шул... Ни эше, ни ашы юк хәзерге рабочий классның. Әле менә өч ай буе зарплата түләмәделәр. Түзәрбез, чыдам халык бит без. Түлке айның җидесе белән егерме беренче көннәрендә генә... Ими көткән сабый шикелле... чакырмаслармы дип өметләнәсең. Кассиршаны өч ай буе кеше күзеннән качырып тоттылар... Әнә Казанның ислемай фабрикасы зарплатаны «огуречный лосьон» белән түләгән. Тегү фабрикалары күлмәк-ыштан өләшкән аванс итеп: получкада өсләреннән чыккач, кире салып биргәннәр. «Оргсинтез» заводы полиэтилен табаклар биргән, вертолет заводы – мясорубкалар. Ә уенчыклар фабрикасы җәйге ялга китүчеләргә отпускной акчаны «Ванька-встанька» дигән курчаклар белән түләргә җыена, ди, тик уйнап утыр! Аларга рәхәт! Ә менә безнең бакалар каргаган ПМКбызда получка урынына... трактор бирделәр: дүрт кешегә берне! Алай да яңа начальство, тракторларны кызганып, штат кыскартырга җыена. Кыскартсыннар! Курыкты ди... Татар мужигын туганнан бирле кыскарталар! Аңа карап зыян күргәнебез юк. Штат кыскартудан Америка Кушма Штатлары курыксын.

Ә мин үзем ПМКбыздан кусалар, мех берләшмәсенә күчәм. Вәт алар ичмасам бай яши! Бай да, күңелле дә яши алар!

Дөньяның бөтен артисты иң әүвәл мех берләшмәсенә килә, аннан соң гына Мәскәүгә! Яланөс җибәрмәссең ич инде шундый да «простой Марияләр»не... Безнең Питрәч районында ике хатынның берсе Мария. Үзләре шундый да прастуйлар... Ну берсенең дә туны юк...

Безнең ПМК СПТУны бетергән салагалар кулына калды. Мыек та чыкмаган әле үзләренә. Кабинага керсәләр, трактор тәрәзәсенә буйлары җитми, асларына канистра салып утыралар. Үзләре безгә дә охшаганнар. Араларында кешечә сөйләшә торганнары да бар. Берсе әле һичбер хатасыз-нисез этисенең исемен дә язып күрсәтте... Кулларыннан килмәгән этлек юк, ну эш рәтен генә белмиләр.

Инде сер түгел, соңгы елларда хәрби заводлар мясорубка җитештерә башлады. Ракета тартып йөри торган вездеходларга да эш кимегән. Ул сигез көпчәкле әзмәверне йөк ташырдай арба итәләр дә безнең ише бака каргаган ПМКларга кайтаралар. Әнә шундый биш машинаны капкадан бер-бер артлы керттеләр дә, сүндереп, ачкычларын завгар кулына тоттырдылар. И вәссәлам! Провожающийлардан җилләр исте. Бу әзмәверләрне ничек кабызырга кирәклеген сорарга оныткanбыз. Әйтәм ич, без күргән техника түгел бу! Бала-чага кулына калгач юк инде ул! Әгәр дә мәгәр теге Озын Шәкүр монда булсамы. Бу әзмәвер үзе кабынып аяк астында койрык болгап торыр иде!

Завгар әйтә, гәҗиткә белдерү бирик, берәр кеше килеп кабызсын, күмер белән түләрбез, ди. Сптушниклар каршы төште, аның бөтен ояты безгә булыр, диләр. Үзләре вездеходларны, кармалап, кабызырга чамалыйлар. Кабина түбәсенә менеп тәмәке көйрәттеләр, радиаторга кул тыгып карадылар, көпчәкләренә дә типкәләделәр – юк, кабынмады!

Җыен дивана арасында да берсе акыллырак була, диләр. Бер шадра малай әйтә куйды:

– Бу машинаны, кабызса, угонщиклар гына кабыза ала. Ничек кабызганнарын качып күзәтеп торырбыз, өйрәнербез, – ди.

Завгар бик ошатты бу фикерне.

Шундук урамга чыгып бер-ике кибет янында пышан-пышан хәбәр тараттык. Куәтле машина кайтканны да, каравылчыбыз юклыкны да кирәкле кешеләргә җиткерсеннәр. Ныклап әзерләндек. Бер бензовозга алмаштырып, төнлә төшерә торган фотоаппарат алып кайттык, бөркәүле машина әрҗәсен түбәгә куеп, эченә кереп яшерендек.

Беренче төнне көткән угонщикларыбыз килмәделәр. Дөрес, таң алдыннан ике пацан кереп сөт шешәсе белән бензин эзләп йөрделәр. Әллә кайдан белеп торабыз – разведчиклар болар. Юкса безнең ПМКда сиксән бишенче елдан бирле бензин булганы юк, моны бөтен кеше белә! Солярка бар әле бераз. Аптырагач, завгар да әнә үзенең «Жигули»ена солярkага эшли торган «Беларусь» моторы куйды. Әгәр светофор төбендә «Жигули»еның капотын ачып пускач кабызып торган машина күрсәгез, шул безнең завгар булыр.

Без каракларны таң алдыннан гына йөриләр дип уйлаган идек. Икенче көнне, кояш та баеп бетмәгән иде әле, төялеп килеп төштеләр. Мин сиңайтим, базарга чалбар сайларга килгән малайлар шикелле, бөтен гаражны айкап чыктылар. Ә без аларның һәр адымын сиздермичә генә фотога төшереп барабыз.

Кунаклар эшне кыска тотты. Ышанасызмы, юкмы, ялганласам, утырган җиребездән – минә шушы түбәдән егылып төшим, без ике-өч тапкыр күз йомып алганчы вездеходның берсен кабызып апчыгып та киттеләр.

Завгар әйтә, их, шул угонщикларның берсен ПМКбызга эшкә алырга, ди. Ә теге акыллы малаебыз битендәге шадраларын тырный-тырный елап җибәрде, җизниләрнең яшел «Москвич»ын да капка төбенә китереп куясы калган, ике елдан бирле кабыза алганы юк, ди.

Төнге фотоларны өстәлгә тезеп салгач, бөтен ПМКны очкылык тота башлады – угонщикларның берсе үзебездән качкан Озын Шәкүр иде!

Ярыйсы гына үгетләгәч, азрак фотолар белән дә куркыткач, Озын Шәкүр яңадан үзебезгә эшкә кайтырга ризалашты. Тик бер шарт белән. ПМКбызның капка төбенә сагыз сата торган ларек ачам, ди. Ачсын, сатсын сагызын, чәйнәсеннәр – малай-шалайлар күп әле ул бездә!

Фотолардан карап, теге машиналарны тәки үзебез кабызырга өйрәндек. Бер уйласаң, Озын Шәкүрне елатып торасы да юк инде... Ләкин конверсия дигән галәмәтнең иртәгә нинди яңалык китереп чыгарасын кем белгән?! Шәкүр кебек осталарга ялынмыйча чараң юк.

Ни дисәң дә, бака каргышы төшкән илдә яшибез бит әле.

# ХУШ, ӘФӘНДЕ!

Ел саен дип әйтмим, шулай да дөрләп яна торган сәяхәт путевкаларын еш сүндергәлим мин. Гадәттә, Советлар Союзының күзенә генә карап «ләббәйкә» дип торган илләргә чакыручы путевкалар еш кабына иде. Ә минә бу юлысы мине сагынып көтеп торучы ил гомергә безнең илне санламады. Моңарчы дуслашыйк дидек – ишетмәде, товар алмашыйк дидек – көлде, коммунизмны бергәләп төзик дигәч, кәҗә тоягы күрсәтте. Шуңа күрә безнең матбугат бу мәмләкәтнең исемен бөтенләй югалтты, шуңа күрә сез белмисез аны. Ул ил – глобусның аскы өлешендәрәк, ераклыкка – чамасыз. Ә миңа барыбер, акча туздырырга сәбәп кенә булсын.

Гел әйтә килделәр миңа: йөрмә теләсә кайда, ярамаган нәрсәгә абынырсың, юлыңнан яздырырдай кешегә юлыгырсың, диделәр. Тыңламадым. Тәки юлыктым мин ул кешегә.

Шулай, әйткәнемчә, глобусның аскы өлешендә сәүдә урамнарын айкап йөрергә дип чыктым. Беренче ишекне ачып җибәрүемә үк маңгаемнан салкын тир бәрде. Андагы киштәләр терәү куймалы – товарны чак күтәреп тора. Бу күренешне гафу итә алмыйча бусагада басып торам. Кай якка атларга да белгән юк, әкрен генә баш әйләнергә тотынды. Алай-болай милли кемлегемнең кирәге чыга калса дип кенә киелгән бәрхет кәләпүшемне салып маңгаемны җилпим. Икеләнеп озак интекмәдем, каршыма самавыр гәүдәле бер агай килеп басты. Шикләнүдән күзләрем ныграк кысылдымы – агаем, имән бармагын чыраема төрәп, «Азия?!» дип сорап куйды. Мин, телемне яшерергә теләп, әйләнүдән туктаган башымны кагып кына үземчә «юк» дигәнне аңлаттым. Шуннан соң ул кесәсеннән симез янчык чыгарып, бездәге илленче еллардагы заем кәгазе хәтле акча сайлап алды һәм җилпенүдән туктаган кәләпүшемә салды. Эшләр харап. Әгәр бу хәлне безнең группа белән килгән берәр турист күрсәме – өйгә кайтуыма Черек күлдә коендырачаклар мине. Бирешмим әле, «Юк, юк!» дип һаман баш кагам. Ә самавыр сыман агай сорау ала, бу юлысы имән бармагын хәзер салган кәләпүшкә төртеп глобустагы кайбер башкалаларны санап чыкты. Түзмәдем, дәштем, «Казан!» дидем. Әйтүем булды, агай ике кулы белән иңемнән кочты:

– Татар!!! – ди бу һәм үзе ялт кына хәергә салган акчасын кире алды.

Самавыр сыман агай шушы кибетнең хуҗасы булып чыкты. Ул мине бөтенләй үз итеп, култыклап кибеткә алып керде. Күпне күреп кәефем кырылмасын өчен мин гел аяк астына гына карап йөрдем. Күтәрелеп карасам, унике почмаклы бүлмәдә икәнбез, агай аны контора дип аңлатты. Шул арада самавыр морҗасы кеби генә бер агайне, үзйөрешле җиңел өстәлгә төяп, «чакырылмаган кунак» сые китерде. Карыным ач булса да, кабаланмыйм, кибет хуҗасы ни ризыкка үрелсә һәм аны ни рәвешле итеп авызына капса, мин дә шулай кабатлыйм, чөнки ят сый-хөрмәт, таныш булмаган нигъмәт мине сагаерга мәҗбүр итә. Сөйләшеп киттек. Безнең телне миннән дә яхшырак белә бу – ярдәмгә һичбер трансинтернациональ сүзләр кулланмыйча гына сөйли.

– Сездә ни хәлләр бар? – дип, ул иң буш һәм иң авыр сорауны миңа аударды.

– Хәлләр искечә, – дидем мин, әзер җавап белән.

«Искечә» дигән сүземне самавыр сыман агаебыз бик өнәмәде, кайнап чыгарга җыенгандай чыжылдап куйды:

– Искечә?! Синең дә Казанда кибетең бармы?

– Бар. 224 нче гастроном, буржуйларча әйтсәк – супермаркет, ягъни мәсәлән.

Агайның бераз самавыры суынгандай булды.

– Сәүдәгездә эш авырмы?

– Юк ла, сатучылар тик утыралар… Ә элек авыр иде, анысы хак.

– Кибетләрегезгә кеше йөрмимени?
– Ник йөрмәсен, кая карама чират.
– Төшенмим, – ди агай, самавыр борыны тирәсен кашып, – чират күп, сатучыга эш юк дисең?
– Нәрсәсен төшенмисең инде аның, сатучылар алар кибет эчендә утыра, ә чират урамда.
– Аңламыйм.
– Һәй, дүрт-биш сәгать чират торсаң аңлыйсың аны. Без дә башта берни аңламый идек.
Дөресен генә әйткәндә, мин агайның сорауларыннан шүрләбрәк торам. Юлга чыкканда хатын кат-кат тукыды: кара аны, күп сөйләшә торган гадәтең бар, телеңә салынма анда, кайткач җавап тотасы булмасын, диде.
Гәп теләгәнчә куермагач, ул, сүнгән самавырны яңарткандай, төрепкәсен кабызды.
– Балаларың күпме? – ди бу миңа, бер күзе белән азиатларча, икенче күзе белән французларча текәлеп.
– Кешечә инде, берәү, – дим.
– Берәүме? – ди бу, көләсе килеп кенә. Ә хатының ничәү?
Ну, сораулары моның... Дөресен сорый бит тәки. Алдасам инде, дәүләтара мөнәсәбәткә эверелер...
– Хатыным... берәү генә. Ә сез, бай әфәнде, ничәгә җиттегез?
– Унсигез балам бар. Хатыным җидәү.
– Үпкән-кочканнарны саный китсәң, минем дә җидегә тула инде ул.
– Юк, – ди бай әфәндем, самавыр тоткасы хәтле генә кулларын колач итеп җәеп, – барыбыз да бергә яшибез.
– Берүзенә җиде хатын?! Анаңны собраниегә чакыргыры... Мин, сүгенүем ишетелмәсен дип, кәләпүшем белән авызымны томаладым. Башым баягыча түгел, икенче якка әйләнә башлады.
– Сигезенчесен алырга исәбең юкмы? – дип, юри үчекләп кенә сораган идем.
– Юк, бераз ял итәм әле, – ди.
– Җиде хатынга каршы берүзең, ә! Ну чыдам кеше икән син! Мин әле берсенә дә көчкә түзәм, юк, гыйшык-мыйшык мәсьәләсендә димим, анысы әлегә Аллага шөкер...
Шунысы һәйбәт, бай әфәнденең кибетендә һичбер хатын-кыз заты юк, теләсә нинди мәсьәләдә тавышны тыймыйча сөйләшергә була.
– Ул хатыннарың үзара чәнчелешеп бетмиләрме?
– Юк. Икесе бала карый, икесе өйне тазарта, икесе ишегалдында, иң яше тәртип саклый.
– Карале, бай әфәнде, син аның җидесен дә бергә кочаклап йоклыйсыңмы, әллә аерым-аерыммы?
– Төрлечә була, – диде әфәндем, күзләрен самавыр күмередәй җемелдәтеп.
– Ничек җан асрамак кирәк ул тиклем гаиләдә. Ярар, әйтик, чәршәмбе көнне балык ашлары белән туендың ди, атнакичне бәрәңге көне, җомганы камыр көне, ялга каршы көнне ит ашасаң, базар көнне суган суы суырсаң, елның бер аен ураза тотып үткәрсәләр, тартып-сузып яшәргә буладыр инде.
– Ашауны алар үзләре хәл итә. Ни теләсәләр, шул бар.
– Бай әфәнде, җиде хатынга ярап торыр өчен үзең ничегрәк туклансың соң?
– Ә үзең? – дип кайтарып сорап куйды бу.
– Мин кешечә инде: кило да дүрт йөз грамм ит, ярты кило май, кило ярым шикәр, ике шешә аракы, алты йөз грамм ярма, ике кадак сабын, бер кап кер порошогы, – дип санап киткән идем, бүлдерде ул мине.
– Шикәр белән майны хәйран ашыйсың. Ә менә итне ике килога җиткерергә кирәк. Көнгә ике кило ит ашамаган ир кеше кеше түгел ул... Акчаң күпме соң? – дигән иде, мин тиз генә чалбар кесәмдә тирләп пешкән валютамны капшап куйдым. – Юк, – ди агай, – мин өеңдәге байлыгыңны әйтәм.
– Әй, – дидем мин, – глобусның өске ягынарак кул селтәп, – акча җитәрлек лә ул миндә, бай әфәнде. Үзең ничек байый алдың соң, ни дисәң дә, гаиләң зур?!
– Әтидән калган мирасны арттырам.
– Әтиең миллионер булганмы әллә?
– Әтигә бабайдан калган.
– Ә бабаең?
– Бабай унҗиденче елны Казаннан куылган.
Мин тагын сагаеп калдым. Сөйләшүебез политик төсмер алды бугай. Тизрәк саубуллаша башладым. Самавыр сыман агай мине урамга чаклы озата чыкты һәм үртәүле чырай белән кабат сорап куйды:
– Йә, Казанда ни хәлләр бар дидең әле?
– Хәлләр искечә, – дидем мин, һаман кыйбламны саклап.
– Түгел шул! – диде агай, сусыз калган утлы самавыр кебек шәмәхәләнеп. Искечә түгел, яңача сездә хәлләр, искечә булса, сине дә Казаннан куарлар иде...
Безне бу илдән ашык-пошык алып кайтып киттеләр. Юл озын, самолет йөзә белмәгән малай-шалай кебек бата-чума бара. Баш әле бер якка, әле икенче якка әйләнә. Күңелемнән генә самавыр сыман

агайның кибетен туздырып йөрим, хатыныма иптәшкә дип аның алты хатынын урлыйм... Бу гына аз тоела, салоннан 77 хатын-кыз санап алам, һәммәсе дә миңа, ашатасы, эчертәсе, киендерәсе дә юк. Өйгә генә ияреп кайтмасыннар. Өйдә минем берәү бар инде, – шул җиткән. Ул берүзе җиде, юк, җитмеш җиде кешегә тора: керен юа, тузанын себерә, мине асрый, балаларны карый, эшенә ярый һәм иң мөһиме – чиратларын тора-тора табынны кора! Бу яктан әйткәндә, чит ил хатыннарының буыннары сыек...

Маңгай тиремне сөртергә дип эзләнеп куен кесәмә тыгылсам, кульяулыкка ияреп 224 нче гастрономнан алырга тиешле бер кило да дүрт йөз граммлык ит талоны килеп төште. Йа Хода, бүген айның утыз беренче көне, Казанга кибетләр ябылганчы кайтып өлгерсәк кенә ярар иде.

# КАЗА НАМАЗЫ

*Памфлет*

Таң атты. Җылымса май ае. Ашыгып киткән криминаль төннең онытылып калган симез ае. Ишек тупсалары чинавыннан өркеп чыга подъездларда төн кичергән сөрсү җилләр Кремльнең чиркәү чәүкәләре үзәк тарафка олакты – митингка, диләр.

Уянды инде йокысыз Казан. Шалтыр-шолтыр киләдер лә трамвае, таксие.

Сатлык завод капкалары авыз ачкан.

Тупыл мамыклары урап уза төсе качкан Сөембикә манарасын.

Казан елгасы төбеннән маймыч көтә балыкчылар, әллә эш юклыктан, әллә көч юклыктан, аңламассың...

Чү, нәрсә бу?! Ораторлар вәгазеннән зәгыйфьләндеме колак? Күз тидерделәрме әллә манарага кадакланган алтын айга? Көн туды исә маҗарадан гарык ласа болай да. Бактың исә, ни икенде, ни ахшам – Сөембикә мөнбәреннән ишетелә азан. Азан түгел, ишетелә игълан. Алланың бер колы – суфые үрмәләп менгән дә манарага шәрран яра: «Ачлык игълан итәм!», «Ачлык игълан итәм!» Тапкан урынын. Беткәнме кино-театр яны, берәр офиска кереп ят, түбә тап, тармы Ирек мәйданы?!

Ишеткән бер кеше, онытып барлы-юклы эшен, җыела монда әллә гайбәт өчен, әллә гыйбрәт өчен. Алдан килгән урын өчен дия-дия, сөенә-сөенә, омончылар килә. Агыла халык, хәйран калып. Киңәш барлап килә түбәтәйле, түбәтәйсез башлар. Җыела чаллар, аклы-каралы сакаллар, юристлар, туристлар, артистлар һәм байрак-байрак булып килә ...ист, ...нистлар да ...нитетлар. Ул халыктыр, ул халык... Кремль утары тирәли җәелгән әллә кайларга! Әйтерсең лә яу. Юк, яу түгел, шоудыр бу – аягүрә тамаша, байрак белән байрак бәрелешә, әләм белән каләм талаша.

Шундук озын өстәл кактылар, түтәлләргә постау яптылар. Альтернатив указ укый сәясәткә тәһарәтсез килгән фиркаләр җәмәгате, түбәтәйләр җәеп салды хәйрия җәмгыяте.

Маҗара юк һаман, көн әрәмгә уза.

Кемдә рупор, шул хуҗа:

– Тилермә, зинһар, төш аннан, синнән башка да бу манарага барлык илләрнең кызыл күзе төбәлгән. Очлы шырпы булып кадалган ул кяфернең күгенә. Һәм шуңамы бик теләгән кешегә авыш булып күренә.

– Төшмим. Җиңел мәллә монда менү? Уйладым алдын-артын. Төшәр идем җиргә, вә ләкин бар шартым. Шартыма ирешми төшмәм, нәсихәткә бирешмәм. Янгын сүндерүчеләргә әйтегез, баскычларын җыйсыннар, юкса төкерәм! Тыңламасалар, хәзер үк таш урамга сикерәм!

– Әйт шартыңны!

– Ашыктырма, минем вакыт иркен. Кат-кат сөйләп тормам, килсен халык, килсен.

Һәм җыела халык, урынына күрә, үлән саен берәү, түмгәк саен түрә. Тыгызлана сафлар, кысалана төркем, неосәүдәгәрләр неотовар төртеп, бронекиосклар яңа урынга баса, акчалы сән – кеше, акчасызы – мескен масса.

Калай бугазлы рупорны алды әписәрләр:

– Разойдись, исәрләр! Бу ниткән кәмит?! Төяп барчагызны апкитәсе дә бит, демократлар кушмый, майть якаңны!

Яңа патша халкы, һай, шул бигрәк үҗәт, яман, тарал дигән саен ишәяләр һаман.

– Кем әле син арендага алырга ошбу манараны, исполкомнан язма рөхсәт бармы? Ташла җиргә, митрикәң белән бергә!

– Кәгазьгә ышанмыйм шул мин, хәтәр товар ла ул кәгазь – бер карасаң, акча була, бер карасаң, вәгазь... Кәнфит тә төрәләр аңа, Указ да ул кәгазь. Минем шартым өчен кәгазьдән толк әз. Менә минем кулда тагын кәмит бер кәгазь, ни отыш, ни акча түгел, комарлы чир – ваучер! Урта хәлле иптәш идем, союзымны карта уйнап оттырдылар, коммунизмга алмашка учлап ваучер тоттырдылар. Илсез, өйсез,

җирсез, эшсез калдым, ә алмашка буй-буй чапан, буй-буй байрак, озын җиңле буй-буй күлмәк алдым. Кая гына китеп, кайларга бармадым бу арада, соңгы өмет икән шушы манарада!

– Ялыктырма, әйт шартыңны.

– Ваучерыма сатып алам Сөембикәне!

– Сөембикәне?! Манараны?!

– Аны!

– Озын җиңле күлмәк кидем дигәч тә син, бел чаманы!

– Беләм. Миңа бирмәсәгез, аны Кремль белән берәр кооператив барыбер алачак, урынын ошатмаса, дачасына илтеп алты ярусле офис итеп күчереп салачак. Миңа калса, вәгъдә бирәм сүтмәскә, низаг зурга китмәсә, хәзер үк төшәм җиргә, ач торуымны өзәм. Риза булмасагыз шартыма, хәлем китеп егылып төшкәнче манарада ач торам.

– Ярый, хуш, мисал өченгә бу байлыкны синеке дип фараз кылыйк. Тик нишләрсең икән аның белән? Ял урыны өчен артык биек, фатир итәм дисәң, лифты юк. Туристларга кирпечләп сувенирга сатам дисәң, анысын...

– Авызыңнан җил алсын! Мин аны мәчет итәм.

– Алданасың, суфый, фикерең ялгыш. Бу гыйбадәтханә сиңа һич китермәс табыш. Агач нигезе черегән – ул бит авыш.

– Һай сез, хөкемдарлар, бигрәк беркатлы ла, ышанасыз җыен юк-бар уйдырмага. Кайсыгызның күзе дөрес – күрегез, бу калада гел чиркәүләр авыш тора. Ава-ава дия-дия, дошман безнең манараны үз ягына авыштыра. Бу тирәдә көрәшчеләр эзләмәсеннәр дип дөреслекне, онытсыннар дип чын тарихның йөзен, яшел саплы көрәкләр актармасыннар дип нигезен... Ә сез шуңа ышандыгыз. Телисезме, манараның ныклыгын исбат итәм: түбәсеннән тотып бар гәүдәсен селкетәм.

– Юк, кирәкми, ышанабыз, кемлегеңне беләбез, кискен карар чыгарганда чиркәү белән бергә без! Ләкин бүген ашыктырма, камчылама шарт белән. Каршы торма. Аягөсте хәл итәрдәй мәсьәләме, киңәшләшик Баш белән! Йә сессия җыяргадыр, расласыннар. Референдум кирәк, бәлки, үткәрергә, төш җиргә. Таләбеңнән халыкара кәмит ясап булмый бит. Төш, теләсәң, ачлыгыңны җирдә генә дәвам ит.

– Анда төшсәм ни көтәсен беләм, тамырым саен глюкоза тутырырсыз шприц белән.

Җирдәгеләр уртак карарга килгәнче, көн үтте дә китте. Санкциясез җыен халкы манарадагы суфыйга теләктәшлек йөзеннән төшке аштан да ваз кичте. Әлсерәгән түрәләр озын җиңле бәндәнең шартына күнделәр, хәтта бер телем ак күмәч тоттырып парламентер менгерделәр. Башка чара юк, таралмый халык һаман-һаман да, Чулман аръягыннан ярдәмгә яшел әләмлеләр килә дигән фәрман бар. Җитмәсә, җөмһүрият күләмендә ул-бу булмагае дип, Әмерикә президентының Таҗ бәйрәменә барасы самолеттан безнекеләр төшеп калганнар. Димәк, хафаланырлык сәбәп бар!

– Җыен риза, бирәбез манараны, тик кара аны, соңгы тапкыр шаяруың булсын милләт белән. Инде төш иплә кенә.

– И, беркатлы-мәрхәмәтле халкым, әле дә ярый сез бар, кыен шартларда аягүрә басларга. Хилафлык кыласым юк сезгә бер мәртәбә дә, инде күтәрегез мине мөнбәремә хас мәртәбәгә. Калган гомерем тәүбәдә үтәр – мине ошбу мәчетнең мулласы итеп раслап кул күтәр. Риза димәктән, һәммәгезнең уч төбен күрим, вәгъдәм шарты итеп сезгә ваучерымны төшерим.

Шул кәгазьне тотарга дип күтәрелде куллар, димәк ки, шушы минуттан суфыебыз – мулла. Марля чалма урап алды, килешеп тора буй-буй күлмәк-ыштан. Азан әйтергә уе...

Телен тешләде җыен. Ахшам вакыты җиткәнгәме тынды уен, бронекиосклар өзде тимер-томыр көен. Сөембикә биеклегеннән ишетелде азан, Каза намазы хәстәрен китерде нәүмиз Казан.

– Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр.

Әшһәду әл лә иләһә иллэл-ләһү...

Намазлыкка әверелде таш җәелгән алан, кем ничек азан ишеткән – оеп калган. Манарага багып бөгелеп төште буйсынучан калам. Аллаһуын әйтеп үпте һәркем аяк асты ташын, хәтта шул ташка тезләнгән җөмһүрият Башы. Омончылар чын күңелдән мүкәләгән-поскан җирләрендә. Министрлар тәрәз ачты ап-ак өйләрендә.

Кайда баскан, шунда табып җаен, башын ташка ора-ора сәҗдә китте җыен.

# ЛӘЙСӘН ӘКИЯТ ТЫҢЛЫЙ

Мендәр бирмә, юрган бирмә, таш идәнгә урын җәй – барыбер зарланмас, тик әкият кенә сөйлә Ләйсәнгә. Шулай күнектерделәр инде.

– Бар, йоклатып кара, – дип, нәрәт бирделәр әти кешегә, – тик әкиятең җен-фәләннәр турында булмасын, йокы алдыннан теләсә ни сөйләп баланы саташтырырсың.

Өч сутый бакча хәтле софаның бер почмагына чумып, Ләйсән әкият тыңлый.

Әти кеше дә, кая, кызым, йокың тәмле микән, дигән булып кына софага килеп ятты.

– Тыңла, кызым, алтын балык турында... Бер түткәң Кара диңгез буена балык тотарга киткән. Бер сала бу ятьмәне, ике сала һәм, ниһаять, эләгә бит моңа, гади балык түгел, алтын балык! «Ни теләсәң, шуны сора, – дигән алтын балык – диңгеземнән аермасаң, барысын да эшли алам!» Түткәңнең түбәсе күккә тия, тота да өенә посылкалар җибәрә, хәтта язу да сала: «Картым-җанашым, алтын балык тоттым, җаның ни тели?» – дигән. Күп тә үтми, балыкчы түткәңә телеграмма килеп төшә: «Кирәк нәрсәләрнең исемлеген төзедем, хәзер үзем килеп җитәм, алтын балыгыңны күрсәтерсең.»

Телеграмманы укып күрсәткәч, алтын балык шундук юкка чыккан, ди.

– Әй, Ләйсән, тыңламасана шул көнче күбәләкнең юк-барларын, арттыра ул, арттыра. Мин сиңа менә үзем сөйлим, сертотмас үрдәк турындагысын. – Әни кеше дә кызы янына сыенды.

– Көннәрдән бер көнне әнкә үрдәк күл эзләп чыгып китә.

– Алтын балык тотаргамы?

– Һаман да шул бер балык башы... Юк ла инде, ял итәргә генә. Йоклаганда каршы дәшмиләр, кызым, тыңла гына... Хатыны киткән көнне үк әткә үрдәк урмандагы, таллыктагы, сазлыктагы җан ияләренә хәбәр тарата: «Хатын китте, аулак өйдә калдым», – ди бу. Шуннан урмандагы, таллыктагы, сазлыктагы җанварлар барысы да үрдәк янына җыела. Йортның асты өске килә. Белмим, бу әкиятнең ахыры ни белән беткән булыр иде, көтмәгәндә генә... әнкә үрдәк кайтып керә! Әткә үрдәкне төлке куеныннан көчкә сөйрәп ала ул, әйе...

Бу минутта әти кеше йоклаганга сабышты.

– Кызык түгел, кызык түгел, – дип өзгәләнде Ләйсән, – әби, әбием, син сөйләп кара инде, йоклый алмыйм.

Әби кеше көянтәле йомшак утыргычын софа янына китереп куйды да тирбәлә-тирбәлә Ләйсәнне юатты, аның да үз әкияте бар иде...

– Яшәгәннәр, ди, карт куян белән аның кызы. Күршеләрендә генә төлке яшәгән, ди. Куянның йорты таштан икән – газы, суы, миче дигәндәй. Ә төлкенең өе гел боз гына, яз җитте исә, су баса, ди. Шулай, килә бу куянга, бөтен зарын сөйләп бирә. Карт куян, аны-моны абайламыйча, төлкене кызгана, түрдән урын бирә, хәтта пропискага да кертә тегене. Ярар, кызыма иптәш булырсың, ди. Ел да үтми, төлке, куян кызы белән согласка килеп, карт куянны урманга куып чыгармакчы була... Һ-и-и! Карт куян гына булсак та, төлкеңнән хәйләкәррәк әле без... Һо-һо-о, – дип, авыз киереп бер иснәде дә әби кеше, үз әкиятенә үзе кинәнеп йокыга китте.

Ләйсән тынлыкта берүзе калды. Әтисе дә, әнисе дә, әбисе дә йоклыйлар инде. Ул, аларны уятмаска тырышып, софадан төште дә, саран лампаны сүндереп, үз караватына менеп ятты... Татлы төшләр, әкиятләре белән йокы килә, йокы килә... Тс-сс!

# НИХӘЛ ДИП СОРАМАГЫЗ...

Нихәл дип сорамагыз, безнең өйдә болай да врачлар җитәрлек. Мисал өчен әбине генә алыйк.

Үзе ишетмәгәндә дөресен әйтсәм дә була – карт инде ул. Аның яшьтәшләреннән беркем дә калмагандыр, шәт. Әбием исә әлегә ничава гына, безнең өйнең түрендә яшәп ята. Тик ятмый – ике тапкыр пенсиягә чыгар яше җитеп тә ул әле һаман йөри – эшкә йөри. Җитмәүдән түгел, эшсез яши алмыйм, ди. Сугыш вакытында хәрби врач булган, аннан үзебезнең шәһәргә кайтып, мин укый торган мәктәп янындагы бүлнискә урнашкан. Бүгенгесе көнгә хәтле дежур врач вазифасын үти. Ичмасам, мин укып бетергәнче генә – ун гына ел – ял итеп тормый. Никме? Әбиең врач булып эшләгән бүлнис каршындагы мәктәптә укысагыз, белер идегез сез минем хәлне...

Җәйге каникул бетеп укулар башлануга, мәктәбебезгә Гитлер сугышыннан калган күн сумкасын күтәреп, әбием килеп керә. Кергәнче үк, аны тәрәзәдән күреп алып, класссташларым пыран-заран, дөбер-шатыр, ыгы-зыгы куптара. «Теге килә» дә «теге килә» дигән булалар. Әгәр шушында минем юк чагым туры килсәме?! Җир шарында яшәүче барлык илләрнең әкиятендә нинди явыз карчык исемнәре бар – барысы да әбигә. Минем алда әйтергә кыймыйлар үзләре, анысы хак – шүрлиләр. Имеш, әгәр дә ки, мин алар турында әбиемә җиткерсәм, кеше саен нормадан тыш берәр укол эләгергә мөмкин. Әйттем ди, әйе, бик беләсегез килсә, әби белән күзгә-күз очрашмас өчен парта астына төшеп качардай чакларым еш була. Котылып булмый бит соң аннан, барыбер өйгә кайткач куып тота, тота да... каравыл кычкырта. Лутчы кадыйсы уколын мәктәптә генә кадасын, бөтен класс белән бергә җәзасы җиңел.

Ярый, әбиемнең кем икәнен белдегез.

Инде врач әнием турында бер-ике сүз.

Әнием завод бүлнисендә аллерголог булып эшли. Күпләрегез аллергологның кем икәнен дә белмисездер әле. Мин беләм!.. Кайбер кешеләр чәчәк иснәсә төчкерә, ят ризык ашаса йөткерә, җете төс күрсә кикерә икән. Андыйлар иссез, тәмсез, төссез тирәдәрәк яшәргә тиешләр, ди. Әнием аларны шуңа өйрәтә. Эш урыннары да катлаулы бугай. Җил көньяктан искәндә янган галош исе киләме – әниләрнең

заводыннан инде ул. Әни әйтә, эшчеләр шул истән башка яши алмыйлар, саф һавага чыксалар да башлары әйләнеп, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә, ди.

Тагынмы?!

Тагын апам бар әле минем.

Анысы да врач. Врач дип, студент кына әле ул, мединститутта укый. Дөрес, апамның юристлыкка укырга иде исәбе. Әби белән әнием гаилә династиясен дәвам итәргә дип сүзләрендә бик нык тордылар. Юрист эшенең киләчәге юк, диделәр. Бер-ике көннән җинаятьчеләрне тотып бетерерләр дә юристларга эш калмас, ә врачларга эш күбәя генә бара, диделәр. Апам өйдәгеләрнең сүзен аяк астына салып таптамады, әбием алдан шылтыратып куйгач, хирургия факультетына барды да керде... Икенче курстан апамны теш врачлары факультетына күчергәннәр.

Әбине әйттем, әнине беләсез, апамны әле генә сөйләдем. Әти юк, ул летчик булган... очып киткән... Мин үземме? Мин үзем өйдә йә клиент, йә пациент...

Мәктәптән кайтып керүемә башлана профилактика. Әби йөрәкне тыңлый, әни бит-кулларны микроскоп аркылы үткәрә, апам булып ул да авызымны ачтырып тешләремне саный, берәрсе төшеп калмаганмы, имеш. Көн саен югалта башласаң, бер айга да җитми бит соң алар. Ә мин җиденчедә укыйм.

Инде күршеләр дә керми безгә, чөнки кергән берсеннән кырыкмаса кырык чир табып торалар.

Урамнан уйнап кайткач та тынгы юк миңа – тамак кырганымны яисә ялгыш йөткергәнемне көтеп кенә торалар. Уеннан кергәч тамак кырмам дип үз-үземә күпме әйттем, ә ул юк, үч иткәндәй ныграк үҗәтләнә генә. Һәм өйдә фәнни бәхәс башлана.

Әби әйтә:

– Улымның кече теле кычыта, авызына җил кергән, кичекмәстән ингаляция ясарга кирәк, хәзер бәрәңге пары әзерлим.

Әни әйтә:

– Улыбыз тагын безнең завод тирәсендә уйнаган, тамак кыруы салкын тиюдән түгел, завод һавасыннан, сулыш органнарын кислород белән өрдерергә кирәк.

Апа әйтә:

– Ә минемчә, аның теше сызларга җыена.

Мин әйтмим. Өйдәгеләрне тыңлый торгач чын-чынлап йөткерергә керешәм, төчкерәсе дә килә.

Озакка сузылган бәхәстән уртак фикергә килә алмагач, ике ягыма ике градусник кыстыралар (берсенә генә ышанмыйлар). Шприц кайнатырга куялар. Әби үләннәр сайлый, әни ак халат кия, апа беренче курста язылган лекцияләрнең конспектларын актара. Ә миңа барыбер... Барыбер котылыр чарам юк. Әти кебек летчик булып очып китәр идем дә – яшем җитми.

Сизеп торам, анализлар юньле түгел. Миңа аякта басып торырга рөхсәт юк – кечкенә бүлмәдәге агач караватка кертеп салдылар. Бу бүлмәне алар изолятор дип атыйлар. Врачларым өчесе дә авызларына марля-респиратор каплап бер-берсе белән пышылдап кына бәхәсләшәләр.

Әби әйтә:

– Күптәннәнискәрә килдем, оныгымда йөрәк чире бар, ахрысы, температурасы дөрес, маңгаенда салкын тир, ә йөрәк ритмы кичәгедән ике тибешкә артыграк.

Әни әйтә:

– Бәйләнмә һаман йөрәгенә, авыру итеп күрәсең килсә, балага җиңелрәк чир беткәнме? Улым, әйт әле, күңелең болганмыйммы? Мәктәп ашханәсендә нәрсә ашаттылар?

Апа әйтә:

– Юкка интектермәгез энекәшемне, аңарга акыл теше чыгарга җыена бугай.

Фәнни бәхәс әкренләп әрләшүгә әверелә.

Әби әйтә:

– Акыл теше чыгарга ул синең яшеңә җиткәнме?

Апа әйтә:

– Ике сүзнең берендә яшемә бәреләсең, карт кыз дигән булып яшьлегемнән көнләшәсең.

Әби әйтә:

– Яшьлегем, яшьлегем, имеш. Миннән күпмегә генә яшь соң син?

– Динозавр бит инде син, ишу хәзерге заман акселератларын дәваларга йөрисең.

Әби әйтә:

– Мин динозавр булсам, син, син, син... шайтан таягы.

Апа әйтә... юк, әйтеп өлгерми, әни туктата.

Әни әйтә:

– Җитте сезгә, берегез яшь килеш баш ия белми, икенчегез картаеп.

Әби әйтә:

– Үзең дә картаеп киләсең, утыз җидене тутырдың. Беләсеңме нәрсә дигән сүз ул утыз җиде? Кешенең температурасы утыз җидегә чыкса, врач чакырталар, сиңа да «скорый» чакыртырга вакыт.

Әни әйтә:

– Әни! Ирсез яшим дип «скорый» чакыртыр хәлгә җитмәдем. Малай үземнеке, ялгыш дәваласам, үзем җавап бирермен!

Әби әйтә:

– Малай кеше синеке дә түгел, әтисенеке дә түгел, ул – хөкүмәтнеке. Син аны хөкүмәткә исән-сау үстереп тапшырырга тиеш идең, кулыңнан килмәде.

Тәки миңа катышырга туры килә, юкса фәнни бәхәс булып башланган әрләшү җәнҗал белән бетәргә мөмкин.

Мин әйтәм:

– Өчегез дә белмәдегез, миндә... өр-яңа чир!

Өч врачым телсез калып өч якка сикерә, шаккатып авызлары ачылудан респираторлары ертыла, күзләре сүнә, сулышлары тына. Изоляторым ачкыч белән бикләнә, минем белән бикле ишек аркылы гына сөйләшәләр.

Әби әйтә:

– Улым, кемнәр харап итте сине?

Әни әйтә:

– Позор!

Апа әйтә:

– Яле, энем, сөйләп бир...

Мин әйтәм:

– Миңа ундүрт яшь инде...

Әби әйтә:

– Кычкырыбрак сөйлә, ишетелми!

Әни әйтә:

– Кычкырасы гына калды, күршеләр ишетсен дисеңме?

Апа әйтә:

– Үземә генә сөйлә, энем, син чит ил кызлары белән дуслаштыңмы?

Мин әйтәм:

– Юк. Ул безнең мәктәптән. Алсу исемле.

Әни әйтә:

– Алсу да чирлеме?

Мин әйтәм:

– Кызлар бик сиздерми инде алар.

Апа әйтә:

– Кайсы төшең ныграк авырта?

Мин әйтәм:

– Алсуны үзен генә күрсәм, жарым күтәрелә, егетләр тирәсендә чуалса, йөрәгем авырта. Берәр көн күрмәсәм, хәлем бетә. Ике тапкыр кинога да бардык. Чибәрлеген күрсәгез! Менә, урамнан үткәндә кызлар да сокланып кала... Әй, сезгә сөйләп торган булам тагы... Яратуның ни икәнен белә торган кешеләрме соң сез?!

Әни әйтә:

– Улым, ә-ә Алсуның сиңа... тигәне юкмы? Яшермә, улым.

Мин әйтәм:

– Тиде.

Әни, әби, апам өчесе бергә әйтә:

– Ә-ә-ә?!

Мин әйтәм:

– Сумкасын күтәрешеп кайтканда ялгыш кына чәнти бармагым Алсуның чәнти бармагына тиеп китте.

Әби, әни, апа өчәүләшеп уфылдап идәнгә утырдылар. Изоляторның ишеге ачылды. Өчесенең дә халатлары салынган, газ плитәсенең дүрт конфоркасы да сүнгән.

Әни әйтә:

– Улым, Алсуны кунакка чакыр.

Икенче көнне мәктәптән кайтышлый ук Алсуны алып кайттым, аны үзебезнең өй эчендәге врачлар династиясе белән таныштырырга булдым. Таныштырасы калмаган икән...

Ишектән күренүебезгә, әби безнең аяк астына хлорлы чүпрәк җәеп салды – туфлиләрегезнең табанын сөртегез, янәсе. Әле ярый Алсу аны-моны абайламыйчарак калды, мин аны тизрәк изоляторга – теге инде, кечкенә бүлмәгә җитәкләдем. Кухня яныннан үтеп киткәндә күз төшереп калдым – дүрт конфорка да дөрләп яна: берсендә шулпа, берсендә ботка, берсендә чәй кайный, дүртенчесендә шприцлар. Шприц?! Әллә Алсу белән икебезне укол кадап акылга утыртмакчылармы? Безнең өйдә тал

чыбыгы, чалбар каешыише тәрбия кирәк-яраклары юк бит ул. Аз гына гаебең булса, шприц күтәрәләр... Тыңлап-тыңлап тордым, юк, плитәдә шприц түгел, чәнечке-кашыклар кайный икән. Димәк, стерильный табын әзерләнә...

Мул итеп табын җәелгәч, безне изолятордан чакырып чыгардылар. Кулларны су белән генә чылатып алырга исәп бар иде – әби килеп басты. Башта кулларыбызны ун процентлы хлорлы суда чайкатты, аннан ике кат сабынлап юдырды. Соңыннан, мамыкка өч процентлы аксеркә сеңдереп, юылган кулларыбызга сөртте.

Алсу әйтә:

– Сине көн саен шулай юалармы?

Ни дип тә җавап бирергә белгән юк. Әйе, дисәң, иртәгә үк бөтен мәктәпкә җиткерер шикелле, ә үзе безгә бүтән аяк та басмас.

Мин әйтәм:

– Әбием бүген деликатес пешергән, кул белән ашыйсы.

Алсу әйтә:

– Бишбармакмы?! Ур-ра!

Бишбармак дигәне бәрәңге булып чыкты.

Чәйгә кучкәнче әни, әби һәм апам сүз башлый алмыйча интектеләр. Әби батыр безнең, ниһаять, тамак кырды.

Әби әйтә:

– Алсу, быел флюорография үттеңме соң?

Алсу әйтә:

– Әйе, ник?

Һәм Алсу үзенең уңайсызланудан кызарып ут янган бит алмасын кашык сабы белән кашып алды.

Әни әйтә:

– Алсу, синең бәрәңгегә аллергия мәллә, битең кызарды. Димедрол бирер идем, кайтасың бар. Аптекадан ун процентлы хлорлы кальций алып чык. Хәзер рецепт язып бирәм. Ашаганнан соң эчәрсең, юкса диатезың көчәер.

Әби әйтә:

– Алсу кызым, эти-әниең нихәлләр, исән-саулармы, профессиональ чирләр белән интекмиләрме?

Мин әйтәм:

– Әбинең беләсе килә, эти-әниең кайда эшли?

Алсу әйтә:

– Ә-ә-ә... Мин юкса аңламыйча торам... Әбием атказанган укытучы, әнием мәктәп директоры, апам институтта укыта. Әтием... капитан, диңгездән кайтып кергәне юк.

Апам әйтә:

– Карасана, сездә дә династия икән. Барысы да укытучылар. Менә ичмасам профессия бу! Син дә үскәч укытучы булырсың.

Алсу әйтә:

– Юк. Белмим. Бәлки. Ләкин...

Һәм Алсу чәен дә эчеп бетермичә, рәхмәтен әйтеп, гафу үтенеп кайтырга җыенмакчы иде – апам туктатты, ашаганнан соң тешләрне чайкарга кирәк дип юынгычка таба күрсәтте.

Шул көннән бирле Алсуның безгә килгәне юк. Мәктәптә күрешәбез, урамда йөрибез, карын ачса, пирожки алып ашыйбыз, туңсак, трамвайларда җылынабыз. Ни хикмәттер, Алсуның мине үзләренә кунакка чакырганы юк.

Кызганыч, әлбәттә, чакырмавы бик кызганыч. Укытучылар династиясенең дә ничек яшәгәнен бик беләсем килә иде.

# ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫНДА

Халык гороскопларга ышана башлады, башка ышанырдай нәрсә калмагач. Гәҗит-журналларны алуга, иң әүвәл йолдызнамәдән үзеңнең хайваныңны эзлисең.

Инде белдерүләр аша танышырга теләгәндә дә без йолдызнамә телендә язышабыз:

«Фатирым бар. Кияүдә булмаган, 27 яшьлек Сукояр гаилә кору өчен бозылмаган Балык эзли. Адресым баганада».

«Мин – Кәҗәмөгез! Буе – 180 см, биле – 90 см, авырлыгы 110 килодан артмаган Кыслага өйләнергә телим. Беренче һәм соңгы этажларны тәкъдим итмәскә».

«60 яшьлек Сарык 35 тән узмаган Бозауны йортка кертә...»

Бөтен кеше үзенә тиң, әйбәт хайван эзли. Кемдер Ат елында туган, кемнәрдер Юлбарыс, Куян, Маймыл, Дуңгыз...

Мин үзем Арыслан, егерме ел элек бер Бозауга өйләнгән идем – карт сыер инде ул хәзер... Үзенең өч бозавы бар әнә... Кеше хайваннардан башка яши алмый. Авыл җирендә яшәсә, абзарда мал-туар асрый. Ә шәһәргә күчеп килсә, фатир тутырып, зоомаркетлардан хайваннар җыя башлый. Минем өч бүлмәле кетәклегемдә прпискага кермәгән биш хайван яши: песи, попугай, алтын балык, ташбака һәм хатынның әнисе, татарча әйткәндә, әби, ягъни мәсәлән... Фатир түгел – зоопарк! Әле базардан берәр шимпанзе алып кайтыйм дигән идем дә, хатын аркылы төште: нәрсәгә инде безгә ике маймыл, ди... Үзен белми... Ак песине ул алып кайтты. Кызганып инде... Вокзал ашханәсендә ачка үлә язган, мескенем... Ак песи безнең өйдә дегустатор ул хәзер, әби пешергән ризыкны иң әүвәл аңа биреп карыйбыз. Кайвакыт ашаганнан соң өчәр төн буе түбәгә менәлми иде, җанашым! Начар төркемгә иярмәсен дип, урамга чыгармыйбыз үзен. Туган көнен дә өйдә генә үткәрдек. Унҗиде песи җыелды, хуҗалары белән! И зурладылар Ак песине... Җиде килолы Муркаларын күтәреп, Ижауда яши торган баҗайлар да кайтканнарые... Яратабыз Ак песине, сөйләшә белмәгәне өчен яратабыз. Мырласа мырлар, әмма ләм-мим! Юкса ул бит гомер буе безнең аяк очында йоклый. Төнлә ни күргәннәрен түбәгә менеп сөйли башласа...

Тагын ташбакабыз бар, дидем, ташбака әбигә ияреп килде. Мин аңа ничә яшь икәнен белмим. Тыныч хайван икән үзе – кыш буе йоклый, ну, әби шикелле үк гырламый... Ташбакалар өч йөз елга хәтле яши, ди, имеш, әби менә шуны сынамакчы. Яшәр, яшәр... әбине әйтәм – кияүдән кияүгә генә йөри ул. Җиде кызы бар – шәһәр саен берәү. Миндәгесе – төпчек кызы...

Өч бүлмәле фатирыбызда бердәнбер импортный әйбер ул – попугай – тутый кош! Кош, имеш... Тутырган тавык, каклаган каз, бәлеш эчендәге үрдәк – менә болары кош, ичмасам... Ә тутый кош – настоящий хайван ул! Аны малаем алып кайтты, миңа үч итеп. Сүгенүеңнән биздерәм әле мин сине, ди. Әйе, мин артыгын ычкындырмыйм хәзер, аның каравы тутый кошыбыз сөйләшергә өйрәнде.

Телевизор кабызсак, каршына килеп утыра да... тотына сүгенергә. Сүгендерә торган илдә яшибез шул...

Илебез череп баесын дисәк, сүгенүчеләргә налог түләтергә кирәк: женнәрне сүксәң – йөз сум, авызга тисәң – ике йөз сум, анаңны сагынсаң – мең сум, ә хөкүмәтне сүксәң, льготалар булсын. Шулай итеп, эшләргә яратмаган федерацияне субъектлар алтынга күмәчәк. Штраф түләргә җиңелрәк булсын өчен Рәсәй 500 һәм 1000 сумлык яңа акчалар чыгарды. Тиздән үзебезнең Татарстанда да яңа акчалар әйләнешкә керәчәк, ди, имеш. Ул акчалар: «адин минималка», «адин пенсия», «адин штраф» һәм «адин взятка» дип аталачак, ди.

Тәртип турында сүз чыккач, безгә хайваннардан үрнәк аласы бар әле, алар үзләренең хуҗаларыннан әдәплерәк... аты-юлы белән сүгенә белмиләр. Ачуланган хайванга үз ишен куркытыр өчен өч хәреф җитә: йә «р-р-р...» диярләр алар, йә «ш-ш-ш...», йә «с-с-с...» итәрләр. Ә безнең хатыннар ирләре белән әрләшә башласамы?.. Татар алфавитының 39 хәрефе дә җитми... Ах син, з..! Син үзең х..! Ә син б..! Син ул п..! Үзеңне бел, с... дип, хайван исемнәрен санап китәсең... «С» хәрефеннән соң хатын кул астына эләккән беренче әйберне алып башыңа тондыра – ул ташбака булып чыга. Һәм син мозготрясение аласың, мозгаң булса... Ташбаканы кире очырасың... Хатынның селкенә торган мие юк, аның өч йөз яшьлек әнисе генә бар. Миңа үч итеп әби аквариумдагы алтын балыкны тутый кошка ыргыта, мин, аңа үч итеп, тутый кош өстенә Ак песине ташлыйм. Әби хитрый ж... – ташбакасына ияреп уртанчы кияүләренә китеп бара. Ак песи безнең белән бәхилләшеп түбәгә сыпыра. Хатын «ч. к. б.» – ягъни чоланга кереп бикләнә. Җәйге ялга киткәндә йорт хайваннарын кая куярбыз дип баш ватасы юк – проблема ел саен әнә шулай үзеннән-үзе хәл ителә. Гауга чыккан икән чыксын, борчылырлык нәрсәме?! Әрләшү бит ул ялкау телгә физзарядка гына.

Икенче көнне гәҗиттән яңа гороскоп табып аласың. Анда минем ишеләргә тагын зоомаркетка кереп хайваннар сатып алырга киңәш ителә... Тормыш дигәнең гел бертөрле ул... Хайваннары гына алышынып тора...

# КЫРЫКЛЫ МАШИНА

Берәрегезнең ГАИда дуслары юкмы?.. Бик кирәгие... Хәер, булса да әйтмисез инде сез аны. Тыны чыккан көпчәк шикелле шиңдегез. Зал тулы шофер – ире булмаса, хатыны...

Машинамны Казанга кертмиләр. Мин килгәнне әллә кайдан күреп алып, талон тишә торган теге нәмәрсәләрен чыгарып, көтеп торалар. Безнең районның ГАИ инспекторы Галимҗан абый бөтен постларга хәбәр итеп куйган. Иномаркаларны яраталар инде алар. «Запорожец» минеке! Маде ин Украина! Тәмам сәяси машинага әверелде ул, билләһи! Украина президенты безнекеләргә берәр авыр сүз ишеттерсә, «Запорожец» машиналарына көн бетә: адым саен туктатып, эчен-тышын актарып, көпчәкләрен иснәп, безнең ишене тентеп интектерәләр... Заправкага керсәң, ярты бак бензинны урлап калалар – Украинаның Рәсәйгә бурычы бар, диләр, нефть белән газ өчен...

Яшерен-батырын түгел, «Запорожец»ларга аек баштан утырып булмый. Җәй көне ул Чернобыльнең дүртенче блогы кебек – менә шартлыйм, күккә очам дип кайнап йөри. Ә кыш көне кабинада 40 градус суык. Кыш көннәре штраф түләтергә дип яныма утырган гаишникларның сыбызгысында төкерекләре ката. Пешеп йә өшеп үлмим дисәң, җәен дә, кышын да «салып» йөрергә туры килә. Аек баштан утырырга куркам мин аңа. Гомумән аек баштан курка торганга әйләндем әле мин – хатынга да аек баштан якын килергә куркам... Әллә мин генәме – эчмәгән кеше юк ул хәзер! Хәтта руль артында оча торган космонавтлар да туктаусыз эчәләр бугай... Җиргә төшкән чакларын телевизордан үзем карап тордым – ләх тегеләр, аякларында басып тора алмыйлар... Ике ягыннан ике врач тотып йөртә. Невесомость, имеш... Айлар буе сыгып чыгара торган закуска белән генә эчсәк, безнең дә невесомость башлана инде ул!..

Ә Галимҗан абый эчми – ярты ел инде, ташлады. Эчүен ташлаган кешене үзегез беләсез, ул вакчыл, ул саран була башлый... Әй, эчүен ташлаган кеше кеше түгел инде ул... Галимҗан абый, эчүен ташлагач, күзгә күренеп үзгәрде, юкка-барга бәйләнеп җанга тия хәзер. Исерек айнымасын, хәерче баемасын икән ул!

Шулай, Казанга җыенам. Урамда ничектер, минем «Запорожец» кабинасында гадәттәгечә минус кырык градус! Бәлки, утыз биш кенә булгандыр да, ну мин, үзегез беләсез, кырыклап кына санарга яратам: кырыктартмачы, кырыктан арттырмаска, кырыкмаса-кырык гаишник, Гали баба һәм кырык инспектор... Район үзәгеннән борылып, Казан юлына чыктым гына – Галимҗан абый таягын селки башлады. Көчкә туктап өлгердем.

– Мине күргәч, тизлегеңне киметергә кирәк. Менә монда зур хәрефләр белән нәрсә дип язылган? – ди бу.

– Шуны да белмәскә, – минәйтәм, – Г-А-И, ягъни мәсәлән, Галимҗан Абый Исерек диелгән!

Шушындый пүчтәк кенә шаяртудан да ачуы чыкты – Галимҗан абыйның чырае ике ай буе үз өендә кунмаган кешенеке төсле булды. Түгәрәк гәүдәсе белән минем өскә тәгәри башлады... Бар иде Галимҗан абыйның шәп чаклары... Мин «Запорожец» алган елларда биле дә беленеп тора иде әле аның. Шушы ГАИ баганасы янында постта торып кына түгәрәкләнеп бетте.

Минем күршем Фәридун, правасын алдырып Галимҗан абый белән сүзгә килгәч, ГАИ баганасына печелмәгән кәҗә тәкәсен бәйләп куйган иде. Дөрес, тәкәсенең тәкә диярлеге юк инде – җәй буе бөтен авыл кәҗәсенең күңелен күреп, тире каплаган шыр сөяккә генә калган. Ну мөгезе шәп әле, шиңмәгән. Фәридун әйтә: «Кәҗәм шушы багана төбендә бер-ике ай гына торып карасын, тазармас микән, әнә бит Галимҗан абый да тумышыннан шыр сөяк иде, ГАИ баганасы төбенә баскач, ике ай эчендә симерде...» – ди.

Болары сүз уңаеннан гына...

Галимҗан абый белән ник шаярттым дигән көнгә төштем...

– Син, малай актыгы, үзең исерек бит, – дип, пыяла көпшәле приборны авызыма терәмәсенме!

«Өф!» иттереп кичәге сулышымны өрәм тегеңә – капчыгы кабара, ә төсе күрсәтми. Егерме ел буе шоферларның авызын иснәүче булып эшләгән Галимҗан абзагыз беренче тапкыр үз борынына үзе ышанмады... Галимҗан абый каушавыннан шабыр тиргә батты – ике погонный метрлы гәүдәсен кая куярга белмичә, миңа карап тора. Ну, праваны бирми, син исерек, исе килмәсә дә күреп торам, исерек, ди... Инде правамны, машинасы-ние белән калдырып, Казанга баручы автобуска китмәкче генә идем, Галимҗан абый тагын куып җитте:

– Малай актыгы, ничек исерүеңнең серен әйт әле, бәлки, миңа да кирәге чыгар... Әйтсәң, праваңны да бирәм, – ди бу.

– Сере бик гади инде аның, – мин әйтәм, – үзеңә кирәк дозаны аласың да клизма ясый торган нәрсә белән...

Галимҗан абый, «клизма» сүзен ишетүгә, шундук авызымны томалады:

– Син, малай актыгы, бу сүзеңне безнең ГАИ начальнигына сөйли күрмә! Әле моңарчы шоферларның авызын гына иснәтәләр иде, – ди...

Кыскасы, Галимҗан абый: «Запорожец»ы тузган, ә техосмотр узмаган, дип, Казан юлындагы бөтен постларга да минем турыда хәбәр итеп куйган. Безнең әби-бабайлар, грамоталары булмагач, имза куясы урынга сәнәк, көрәк, чәүкә, тәре сурәте төшерә торганнар иде, ә гаишниклар тишек тишә... Чаллы ягыннан да килеп карыйм Казанга, Биектау ягыннан да, Кадышево, Юдино, Лаеш ягыннан да – туктаталар, каравыл кычкыртып штраф түләтәләр, талонны тишәләр. Машинаң тузган, янәсе. Безнең юлларда машина гына түгел, шоферлар үзләре дә туза! КамАЗ юлының авария булмаган бер генә җире дә калмады бит инде! Әнә без җиңеп ташлаган Германиядә... яңа салынган юлны сынаганда, капот өстенә стакан белән мөлдерәмә тутырып аракы куялар, ди, шул килеш машинаны сәгатенә 120 километр белән куалар, ди. Юл буе бер генә тамчы аракысы да түгелми, ди!!! Ә безнең юлларда син ул стаканлы аракыны кире шешәсенә тутырып, бөкесен сургучлап ябып, багажнигыңа бикләп куй – барыбер төшеп кала... Төшеп калмаганын гаишниклар ала.

Бирәрегезнең ГАИда дусты булса, зинһар, миңа телефонын бирегез, юкса бөлеп тә, тишелеп тә бетәм бит инде!

Юл читенә чәчеп үстерәләр мәллә бу ГАИны?! Алар хәзер машина саен берәү туры килә бугай. Болайга китсә, тиздән заводның үзеннән үк һәр машинага персональ инспектор биреп чыгарачаклар. ГАИны машинаң белән бергә сатып аласың. Гомер буе синең янында гына утырып йөри, үзең ашатасың, үзең эчертәсең, үзең киендерәсең, штрафны да гел аңа гына түлисе була.

Галимҗан абый гына кем бәхетенә эләгер?!

# КОТЛЫ-БОТЛЫ

Коммунизм үпкәләде безгә – төялде дә китеп барды, хәерче балалары гына өелеп калды. Сайлаулар җитте исә, менә кайтыр, менә кайтыр, дип өметләнәбез. Коммунизмны кире кайтарып була. Моның өчен күп кирәкми, кем нәрсә урлаган – китереп бирсен, үзе кайта ул! Көнчыгыш илләрендә шундый кырыс йола яшәп килә: әгәр кеше бер урласа, аның бармагын кисәннәр, ике урласа – кулын, өченчесендә – аягын... Әгәр бу җәзаны безнең илдә куллансаңмы?! Түрәләр арасында бер исән кеше дә калмас, аяксыз-кулсыз һәм дә ки башсыз йөрерләр иде. Баш дигәннән, иптәшләр, татар халкы бик акыллы ул, пчаму, птамушты аның ким дигәндә өч мие бар: арка мие, баш мие... һәм Минтимер Шәймиев...

Иптәшләр! Без урысны сүгеп күтәрелдек! Суверенитетны да урыстан әҗәткә алып тордык. Аны түлисе әле, нефть сатып түли алмасак, кире тартып алырлар. Урыс булган җирдә татарга тел юк... Хотя без, татарлар, үзебез дә урыс инде, просто татарча сөйләшкән генә булабыз. Хәзер исә, бер-беребездән тел яшермик: давай откровенно, если ты русский – докажи, если ты татарин – покажи... паспортыңны.

Бу сәхнә кешесе дөресен әйтә микән соң дип, аптырап утырмагыз. Артык дөресен сөйләү – ялганның бер төре. Үзең генә ялганласаң, шаярта диярләр, ә инде күмәкләшеп ялганласаң, сәясәт була ул, иптәшләр. Сәясәт дигәннән, депутатларга да эш авыр, сигез сәгать буе телевизор каршында ике кулыңны күтәреп утырып кара әле син! Бәбкәгә утырган каз да оядагысын көнгә дүрт-биш тапкыр әйләндерә. Безнең депутатлар ничек түзәләрдер?!

Иптәшләр! Сайлаулар бик кыйммәтле уен. Бәлки, киләчәктә безгә депутатларны чит илдән генә сатып алыргадыр, ни дисәң дә, чит ил әйберсе арзанрак та, затлырак һәм матуррак та.

Фәнни коммунизмның истәлеге булып бездә ике генә чират калды: берсе аның фатир чираты, икенчесе – телефонныкы. Бу чиратларның икесен дә хәл итеп була. Моның өчен, иптәшләр, бөтен сайлаучыларның да үзләрен депутат итеп сайлап куярга кирәк. Биш ел эчендә үзен генә түгел, бөтен туган-тумачаларын да фатирлы һәм телефонлы итеп өлгерәчәк ул. Өлгермәгәннәрен икенче срокка сайлап куярбыз. Аннан соң, ни өчен әле без аларны биш елга сайлыйбыз, өч елда да өлгерәләр алар...

Иптәшләр, безнең илдә колхоз җитәкчеләре бик бәхетле! Тырыша торгач, алар авыл халкын бушлай эшләргә өйрәтеп җиткерделәр. Мондый казаныш башка бер илдә дә юк. Хәтта череп баеган америкалылар да атнадан атнага зарплата сорап килә.

Агымдагы елда ит һәм сөт җитештерүне арттыру нияте белән Голландиядән көнгә сиксән литр сөт бирә торган сыерлар кайтарткан идек. Ашау җиткереп булмады... Чит илнең хайваны да комсыз түлке. Менә алар безнең корчаңгы холмогорлар кебек бернәрсә дә ашамаган килеш көн саен уникешәр-уналтышар литр сөт биреп карасыннар!..

Авыл халкы шәһәргә качып бетмәсен өчен, билет бәяләрен арттырырга исәплиләр. Юл йөргән өчен билет бәясен кешенең санына карап түгел, ә авырлыгына карап түләтәчәкләр. Әйтик, син илле килолы икән, бер билет аласың, йөз килолы булсаң – ике билет. Утыз биш килолы ирләр өчен льготалар булачак. Ә инде тәвәккәлләп Казанга килеп чыксагыз, туп-туры Кремльгә килегез. Казан Кремлен музей-комплекс итәләр. Анда утырган кешеләрне тарихи экспонат итеп калдырачаклар. Күрәсең килсә, билет алып керерсең.

Түгәрәкләп кенә әйткәндә, безгә шундый итеп яшәргә кирәк: сабан туйларыбызга Мәскәү президенты үзе килерлек булсын.

Бәйрәмнәр күп, килсеннәр генә.

Әле менә Республика көнен олылап бәйрәм иттек.

АО Россиянең ООО Татарстанына унбер яшь тулды! Унбер яшь – гүя без әле бишенче сыйныф укучысы гына... Мәскәү укыта әле безне, укыта!

Бәйрәмнәрегез котлы, мәҗлесләрегез тортлы, банкетларыгыз ботлы булсын...

# ДУС БАР, ДОШМАН БАР...

Ишек шакысалар, берүк ачарга ашыкмагыз – дусларыгыз булып кунакка килеп кермәгәйләре... Дошман керсә, телевизорыңны алыр да күздән югалыр. Кесәләре буш булса инде, алюминий кашыкларыңны тутырып китәр – төсле металл итеп... Дуслар килсәме?! Сыерың – бәлешкә, сарыгың – шашлыкка, тавыкларыңны күчтәнәчкә биреп җибәрәсең, йомыркалары белән... Китсәләр, әлбәттә... Кунак килсә, китә белми йөдәтә бит әле ул. Дошманнар исә кунаклар шикелле әрсез түгел, бәлеш пешкәнне көтеп утырмый, кунарга калмый, хуҗалар өйдә юк чакны сагалап тора да елт кына кереп, кирәк нәрсәсен эләктереп, тиз генә чыгып кача. Һәм бүтән әйләнеп тә карамый. Бер фатирны ике тапкыр баскан дошман юк әле ул. Ә менә дуслар бер генә түгел, ун килә, җиренә җиткереп сыйласаң... Дөрес анысы, кунакны бүтән килмәслек итеп тә сыйларга була... Юк шул инде, җанашым, аннары татар булмыйбыз без!

Дошманның, мескеннең, этлеген эшләгәч, ашау-эчү кебек вак-төяккә вакыты калмый... Әнә дүрт агай, Бәзәкә авылына килеп, су буендагы тупыл-өянкеләрдән бөтен карга ояларын җыеп алган. Карга-чәүкә тавышыннан котылган Бәзәкә халкы чәй эчәргә чакырып караган ул дошманнарны. Кая ул чәй эчү! Агайларың, карга ояларын кырга алып чыгып, сүтеп, алюминий-бакыр чыбыкларын машинага төягәннәр дә Чаллы ягына выжт. Инде Бәзәкә каргалары, яңа оя корырга дип, бөтен Рәсәйне бетереп, ялтыравык чыбык эзләп йөри. Табарлар микән, ай-һай! Урласалар гына инде. Бик беләсегез килсә, алай-болай хәвеф белән самолетлар югала калса, МЧС хезмәткәрләре ул алюминий очкычларны иң әүвәл төсле металл кабул итә торган җирләрдән эзли башлый.

Дошманнардан куркасы юк, әйтәм ич, алар эш кешесе, кунакка йөрми, вак-төяккә вакыт әрәм итми... Әнә Дәрвишләр бистәсендә егерме биш яшьлек бер тол хатын ялгызы гына мунча ләүкәсендә кызынып ятканда, утыз яшьләрдәге ике дошман егет килеп кергән. Нишләгәннәр дисең? Кергәннәр дә болар чишенгәннәр, чөнки мунча бик кызу булган... Дөрләп янып торган тимер мичне күтәреп алып чыгып киткәннәр. Күгәрми торган корычтан коелган затлы мич булган ул... Әле, җитмәсә, киемнәрен алырга дип кире кергәндә, ишек төбендәге алюминий мичкәләрне дә эләктергәннәр суы-ние белән. Теге егерме биш яшьлек чибәркәй ләүкәдә исән-имин килеш юынып калган.

Мисал өчен дип әйтик, әгәр шул дошманнар урынына мунчага ялгыш дуслар килеп кергән булсамы?! Гүзәлкәеңне кыстый-кыстый чәй эчерерләр, юынырга да ирек бирмичә хәл-әхвәл сораштырырлар, мактый-мактый, ләүкәдә кунып та калырлар.

Татар ашар да качармы?! Кунакка килсә качмый ул!

Татарның бөтен бәйрәмнәре ашаудан яралган. Бала туса – бәби туе... Исем кушканда – чәйгә алу... Табын артында шул ук туганнар, шул ук дуслар... Әле Фридрих Энгельс кебегрәк шәкертен ияртеп Карл Маркска охшаган мулла да килеп керә. Чәйгә алу дип гади генә аталса да, без бит инде «чәй»нең ни икәнен беләбез... Тирән эчле тәлинкәгә чүмәкәйләп өелгән токмачлы аш, бер табак бәрәңге янына тутырылган тавык, кыздырылган калҗа, гөбәдия, итле бәлеш, каймак белән коймак... Соңыннан баллы сагыз өләшеп чыгалар. Ашыйсың-күшисең, эчәсең дә күршеләрне чәйни-чәйни таралАсың... Күп тә үтми, кызыл туйлар башлана... Чәйгә алудан соң туйлар турында сөйләп торасы да юк. Туйлар күп инде ул... Хәләлең белән җитмеш ел бергә яшәп исән калсаң – Рәхмәт туе, илле ел буе аера алмасаң – Алтын туй, егерме биш ел түзсәң – Көмеш туй, парлашып тәки биш ел түздек, сөбханалла, дисәң – Агач туй... Ә менә Таҗ туе үткәрәсең килсә, унбиш яшеңдә өйләнеп, һаман шул бер хатын белән җитмеш биш ел буе тоташтан яшәргә кирәк. Кешенең бөтен гомере туйлардан гына тора. Бәби туе... Өй туе... Сабан туе... Сабантуйның һәр кызыгы ашау уенына корылган. Җамыяк төбеннән балдак эзләгән арада катык чөмерәсең. Багана башына үрмәләп симез әтәч алып төшәсең. Кемдер каймагын ялаган чүлмәкне күсәк белән бәреп ватасың. Бәрәңгедән бушаган капчыкны киеп сикерәсең. Тамагың кипсә, сулы чиләк ташыйсың. Авызга кашык белән йомырка капкач... ничек йөгереп була икән ул?! Инде көрәшләрдә җиңеп батыр калсаң, тәкә суеп ашыйсың. Ашыйсың килмәсә, уйнама!.. Йа Хода, туйлар гынамы? Гаилә мәҗлесләре, календарьдагы кызыл даталар, милли бәйрәмнәр... Без бит әле ике башлы бөркет чебиләре – күрше милләтнең бәйрәмнәрен дә калдырмыйбыз...

Татар өчен яшәү ашау икән ул!

Дөнья халкын татар ашарга өйрәткән. Мәгълүм ки, ашауның бер төре – банкет. Банкет сүзе татардан килә, банкет, ягъни банкалы ит дигән сүз. Бактың исә, «столица» дигән олы сүз дә ашау белән бәйле. «Столица»ның тамыр сүзе «стол» була. Кемгә – столица, кемгә – башкала! Аңлашылса кирәк, столицадагыларны ашата-ашата үзебезгә «атаң башы» кала...

Ә сез беләсезме, һәрбер ризык кешегә үзенчә тәэсир итә. Әгәр ат ите ашасаң – кешнәтә! Шуңа күрә җитәкчеләребез ат ярата безнең. Күпләп уылдык, үзебезчә әйткәндә, икра ашасаң, диңгез буена ял итәргә барасың килә башлый... Табындагы хайваннарның холкы кешегә күчә, ди, упшым... сыер, сарык, дуңгыз кебек кешеләр каян килеп чыга дип баш ватасы юк.

Яши белмәсәк тә, бәйрәм итә беләбез...

Татар егете өздереп җырлап кайтса, гармун сулышына мәҗлес исе сеңгән булыр. Күреген тарткан саен, бәлеш, өчпочмак, пилмән һәм арыш мае исе тарала.

Аш эчәсең киләме лә,
Чәй эчәсең киләме шул...
Яшел үләннәргә ятып,
Сөт эчәсең киләме шул...

Халык белеп әйтә: иртәнге ашны үзең аша, төшке ашны дустың белән уртаклаш, ә кичке ашны дошманыңа бир! Рас әйтелгән! Шуңа күрә, ашка дәшсәләр, ни вакытка чакырасыз – төшке яккамы, әллә кичкәме дип кайтарып сорарга онытмагыз...

# ХӘЙРИЯ САНДЫГЫ

Партиягә кердем әле – Бердәм Россия дигәненә, элеккеге коммунистларны чиратсыз алалар икән анда. Партбилетлары бигрәк матур – үзе кредит кәртечкәсе хәтлек кенә, бер ягында минем рәсем, икенче ягында аю, табанын суырып ята. Аркамнан сөйделәр: тыйнак кына котлыйбыз диләр, син бүгеннән «Единорос» диделәр.

Минем ише пенсионерлар өчен бик әйбәт оешма икән ул хәзерге партия – взнос түлисе юк, политукуларга йөрмисең, бюроларга чакыртып та сүкмиләр. Йомыш кушканнарын көтеп, өеңдә генә тик ятасың.

Яшәп ятам шулай, үзебезчә итеп әйткәндә, «Идинарус» булып...

Беркөн штабтан шылтыраталар: шулай да шулай, быелгы елны Хәйрия елы дип игълан иттек, һәркайсыбыз, ким дигәндә, берәр игелекле гамәл башкарырга тиеш, диләр.

Дуңгыз елын Хәйрия елы итеп үзгәртүләренә сөендем. Партиям кушканча, игелекле эш кылырга кул кычытып тора.

Киңәш йөзеннән таныш-белешләргә шылтыраткаладым. Ягъни, сезләр нишли анда, елыгыз файдасызга үтмиме?

Кемдер бала-чагаларыннан артып калган киемнәрне илтеп биргән... Миннән монысы юк инде, малайдан калганнарны үзем туздырып барам... Берәү әнә өеңдә җыелып яткан китапларны бүләккә тапшырган да тапшыруын... «Намус» романының бит араларына кияү тиешлеләре ун мең сум акча яшереп куйган булган. Тү-түт акча! Кем кулына кергәндер әле ул китап? Бүгенгеләр һушлары китеп детективлар, ужастиклар, триллерлар укып ятканда, «Намус»ыңны искә төшергәннәрен көтеп утыр хәзер... Артык китаплар минем үземдә дә күп күбен, әби-бабалар заманыннан калганнары да бар. Шикләндерә, билләһи! Илтеп тапшырырсың да тапшыруын, соңыннан бит араларындагы хәзинәләрен эзләп йөрисе булса?..

Үзем белән бергә пенсиягә чыккан «Москвич»ымны бүләк итәр идем инде дә, кабыза алмаслар шул.

Нинди генә файдалы эш эшләп карарга микән дип баш ватып утырганда, телефоныбыз шылтырады. Игелексез телефон ул – кич җитте исә, чер дә чер, кер дә кер, кил дә күр, бир дә бир дип кенә тора. Әйтәм ич, әнә тагын... Бакча күршебез Рәшит безне туган көненә чакыра. Рәшитләр белән без ял саен диярлек бакчада күрешеп торабыз анысы, өйләренә бармаенча түтәл өстендә генә котласаң да ярар иде. Әмма дә ләкин быел, әйтәм ич, игелек эшләргә кул кычытып тора. Өч тиенлек бүләген кызганып килмәгәндер әле, карун, жмут, саран бака дип сөйләп йөрмәсеннәр тагы. Барабыз. Бүләк күп ул бездә – бер сандык!

Хәйрия сандыгын ачтык. Туган көннәрдән, өй котлаулар, бәби туйларыннан җыелган бүләкләр арасыннан кыска җиңле, сары шакмаклы, ачык изүле ирләр күлмәге табып алдык. Алтмыш дүртенче размерлы күлмәкләр озын гомерле була бит ул. Ярар, затлырак итеп төрербез дә Рәшиткә тоттырырбыз, күз алдыбызда ук ачып карамаслар әле.

Бакча күршебезнең бәйрәме матур гына үтеп китте. Шунда ук мин мәҗлестәгеләрне беренче апрельгә, туган көнемә чакырып кайттым. Юкса игелек елының яртысы дигәндәй үтеп бара, үзебезнең әле кунак җыйганыбыз юк. Әнә Хәйрия сандыгыбыз да бушаган. Дөрес, мин үзем декабрь ахырында гына туганмын. Әй, мәҗлескә килгән кунак синең митрикәләреңне карап, кайчан туганыңны тикшереп торамыни ул?! Аңа гөрләшеп күңел ачарга булсын да, алып килгән бүләгенең бәясен чыгарырдай сыйланырга гына булсын.

Җыелдык. Сыйландык. Күңел ачтык.

Соңгы кунагыбызны өстәл астыннан эзләп таптык та төрткәләп озаттык, ишекне бикләп куйдык та, аяк бөкләп, чәчәкле-чуклы төргәкләрне, яулык чаклы кәгазьләрне сүтеп, җыелган бүләкләрне актара башладык...

Вьетнам базарыннан, «Кырмыска оясы»ннан, «Конфискат» кибетеннән алынган тауарлар белән Хәйрия сандыгыбыз мөлдерәмә тулды. Инде соңгы бүләкне генә сүтеп куябыз да... Телсез-өнсез калдык – теге, кыска җиңле, сары шакмаклы, ачык изүле ирләр күлмәгебез, кулдан кулга, мәҗлестән мәҗлескә, туган көннән туган көнгә йөри торгач, кире үзебезгә әйләнеп кайткан. Размеры да зурайган кебек: киеп-киеп караганнардыр инде. Нафталин, хлорофос, әфлисун кабыгы исе сеңгән. Болай ничава гына әле үзе. Кеше кимәгән ич, ник аны мин кияргә тиеш ди. Салып куям Хәйрия сандыгына. Игелек елы бетмәгән әле. Затлырак итеп төрербез дә бүләк итәрбез берәрсенә. Партиябез әйтмешли, кешегә игелек кылсаң, үзеңә игелек булып кайта ул!..

# ТАГЫН КҮПМЕ НИТӘРЛӘР?..

Ни, миңа үзебезнең Татарстан турында берәр нәрсә нитәргә кушалар. Нишләргә дә белгән юк! Мактап әкият язсам, мәскәүлеләр ни әйтер? Яманлап юмореска нитсәм? Ә вдруг Татарстанның эшләре яхшыга таба китсә, соңыннан мине нитсәләр... Сез тыңларсыз да таралышырсыз, ә мин ниемне нитеп калырмын! Шуңа күрә мин нитеп кенә сөйләрмен.

Ни бит әле, кичә генә без Мәскәү – папа, Казан – мама дип яшәдек. Мәскәү күп нитте инде ул безнең маманы. Әгәр референдумда бераз нитмәгән булсак, Мәскәүнекеләр безне бөтенләй нитәләр иде инде. Мактаулы кыз туйда нитә, ди, җитәр, инде Мәскәү белән талак! Хәзер без аның белән никахсыз гына нитешәбез. Мәскәү җиленнән туган балалар нишләрләр менә?!

Яшерен-батырын түгел, бераз нитсәк ниттек, әмма Татарстанны почти ирекле дәүләт иттек. Сам хоҗаин, сам хуҗа! Мәскәүдән ким яшәмибез. Үзебезнең Кремлебез бар. Үзебезнең Парламент, үзебезнең Президент – указларны нитеп кенә тора. Мәскәүгә ялынычыбыз юк, хәзер үзебезнекеләр шәп нитә. Бик теләсәк, вокзал янындагы «Пирамида»ны мавзолей да итә алабыз, буш әле ул пока. Кем алдан нитә – керә торыр. Шулай да татарда телнең ике ниле икәнен онытмыйк – Казан мавзолее ике караватлы булырга тиеш. Алдан килгән урын өчен, ә «Пирамида»да урын җитәрлек! Бер караваткa урыс демократларын сузып нитәрләр, икенчесенә татар центристларын. Мавзолейга чират җитмәгәннәре теге, Вишневский урамындагы тугыз катлы пирамидаларында нитеп торсыннар.

Ни бит, җәмәгать, Татарстан ул Рәсәйнең теге ние – альтернәтивы. Альтернәтива ул – һәр әйбернең ким дигәндә ике ние булырга тиеш дигән сүз. Әйтик, ике хыял – берсе ашау, икенчесе нитү, ике эш – берсеннән нитсәләр, икенчесенә китсәң, ике дөнья – берсеннән туйсаң, икенчесенә пожалысты, ике хатын... Без гел альтернәтива белән яшибез: ике милләтле, ике динле, ике телле, ике йөзле... Тәүлегебез дә икегә бүленгән, төне татарга – күк гөмбәзендә ае бар, ә көне... хәер, көн күрсәткәннәре юк әле безгә. Такташ сүзләре белән әйтсәк: яши миндә хәзер ике мин – берсе аның, малай, Мәскәү яклы, икенчесе каршы, сукин сын!.. Юлыбыз бер булса да, кыйблабыз ике – социализм, капитализм! Ленин сүзләре белән әйткәндә: большевик-меньшевик, левый-правый, правый-левый, уң ботым уңга каера, сул ботым сулга, ә ике бот арасында демократлар... Әнә шул демократлар нитә инде безне...

СНГда ни эшем бар, алма кебек илем бар! Арчадан дача алабыз, Осланга гараж салабыз, Чаллыдан фатир нитәбез. Атнага өч көн эшлибез, биш көн ашыйбыз. Өчәр ай акча көтәбез, капчыклап налог нитәбез. Эчкәнебез – Польский, махмыры – Чистопольский...

Ниме, тагын күпме нитәрләр икән әле безнең нине?!

# КАТЫ ШЕЛТӘ

Мөхтәрәм укытучылар, Август киңәшмәсендә катнашуыма аптырамагыз. Без сезнең белән коллегалар, мин дә маллар тәрбиялим.

Шөкер, бушлай эшләсәләр дә, укытучыларыбыз күп икән әле – зал тулы! Димәк, укырлык балаларыбыз бар дигән сүз. Хәер, соңгы ун ел эчендә минем Казан урамнарында йөкле хатыннар күргәнем юк. Реформага чаклы туган балаларны тәрбиялисездер инде... Хатыннарны бөтенләй йөк күтәрмиләр дип әйтеп булмый – кирәк чагында безнең укытучы апаларыбыз, алпавыт мунчасы чаклы биштәр күтәреп, Мәскәүнең Лужники стадионыннан Казанның колхоз базарына хәтле җәяү кайта алалар. Укулар башлангач, мәктәпләребез Кытай базарына әверелә.

Балалар саны кимегәнгә бер дә борчылмагыз сез. Кеше саны кимегән саен, проблемалар да кими. Кеше әзәйгән саен, димәк, эшсезләр саны, ачлы-туклы яшәүчеләр, фатир сораучылар һәм, әйтергә кирәк, җинаятьләр саны да кими. Алар барысы да безнең укучыларыбыз бит, мөхтәрәм коллегалар! Укучыны тудыру һәм тәрбияләү – хатын-кыз эше. Шулай булгач, бүгенге сәяси һәм икътисади мәхшәргә сез – хатын-кызлар гына гаепле!

Уку елының беренче сентябрьдән башлап тугыз ай буе дәвам иткәнен бик яхшы беләбез. Ләкин бөтен бала да тугыз айдан тумый. Менә минем үземне әнием җиде айдан тудырган: өченче чирек бетеп, каникулга чыкканнан соң... Минемчә, Рәсәйнең бүгенге реформаторлары, гомумән, биш айдан ук туган булырга тиешләр.

Юньле бала бишектән егылып төшеп, мәктәпкә килеп җиткәнче, искиткеч катлаулы вә мәшәкатьле юл үтә. Җиде ел эчендә бала 7565 тапкыр елап уяна, 7565 тапкыр ашарга сорый, 12220 тапкыр колготкиена «пес» итә, 2500 тапкыр үлемнән кала һәм елга 365 тапкыр «Минем әтием кем?» дип теңкәгә тия. Галимнәр әйтә, ана карынында бала тугыз гына ай түгел, ә җиде ел үсәргә тиеш, ди. Ул чагында баланы ясле-бакчага да йөртеп торасы булмас, роддомнан алып чыгасың да, әлифбасын тоттырып, туп-туры мәктәпкә илтеп куясың. Әлегә бу чынга ашмас хыял гына... Балалар болай да хәзер ана карынында ук институт бетереп туа. Һәм аның нинди институт бетереп тууы әти-әнисенең кайда эшләвенә бәйле: укытучыдан хәерче укытучылар династиясе туар, эшсездән – эшсез, начальниктан – начальник, депутаттан – депутат, бизнесменнан мафиозниклар династиясе туа... Әйе, укымышлы бандитка караганда надан депутат лутчырак...

Мәктәпләрдә реформа үткәрәсе бар. Әйтик, хезмәт дәресе урынына «эш эзләү серләре» дигән яңа фән кертергә кирәк. Эше булмагач, хезмәте нигә кирәк инде аның. Сез мине дөрес аңлагыз, мөхтәрәм коллегалар, кешенең акылы башында түгел, кешенең акылы кесәсендә!.. «Мани-мани»ең булса, тиз үсәрсең... Бала институтка кергәндә хәзер өч кенә өстәмә сорау бирәләр: «Әти-әниең кайда эшли?», «Дача төзи беләсеңме?», «Сыерыгыз бозауладымы?»

География укытучылары да зарлана: глобуслар һәм дөнья карталары кырык ямаулы. Җир йөзеннән авыллар, шәһәрләр, илләр югала. Яңа карталар сатып алырга мәктәпләрнең акчасы юк. Иске картадан Санкт-Петербургны эзләп аһ итәбез. Сталинград шәһәренең исеме карта өстендә кызыл кара белән дүрт тапкыр төзәтелгән. Элек бөтен исемнәр дә үз урынында иде, карталардан ут сүндереп эзләсәк тә таба идек. Таба алмасак, география укытучысы Габдулла абый башыбызга имән указкасы белән суга иде. Шуңа күрә без география дәресләрендә җәен дә, кышын да каеш бүрек киеп утыра идек.

Математика дәресләрендә дә программа яңарып дип өметләнәм. Әйтик, тапкырлау таблицасының валюта коридорын киңәйтергә кирәк. Бер килода чынлап та мең грамм буламы? «А» пунктыннан «Б» пунктына поездлар һаман йөриме? Бер метр юанлыктагы торбалардан бушлай нефтебез һаман агамы?

Химия дәресләре бүген урамда гына узарга тиеш. Шөкер, Менделеев таблицасы эчендә яшәп ятабыз... Агыйделгә фенол түгеп миңгерәтәләр, Иделдәге аммиакны иснәтеп һушыбызга китерәләр...

Балаларга бары укырга, укырга һәм укырга гына кирәк! Чөнки укыган чакта эш эзләү кайгысы юк...

Мөхтәрәм коллегалар!

Без хәзер Мәскәүнең иң өлкән укытучысы Сталин сыман мыеклы, Хрущев сыман пеләш, Брежнев сыман кашлы, Ленин кебек кечкенә булырга тиеш дибез... Ә бүгенге Ил башлыкларының тәртипсезлекләре өчен аны укыткан педагогларга каты шелтә белдерәсе генә кала.

# КОЗЕЛ БЕЛӘН БАРАН

*(Тукайга ияреп)*

Габдулла Тукайның «Кәҗә белән Сарык» әкияте моннан бер гасыр элек язылган. Ләкин андагы вакыйгалар безнең көннәргә бик тә туры килә. Тукай ул – әүлия – бүгенге базар реформасын алдан ук күреп бара, әкият белән үреп бара:

> Борын заман бер Ир белән Хатын торган,
> Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган...

Нәкъ безнең тормыш инде бу!..

Г.Тукай һәр гектардан 68 шартлы гектар уңыш җыеп ала белә торган Арча районын ташлап, хәерче Казанга күчеп килә. Шуңа күрә аның әсәрләре үзе кебек ярлы халыкны яклау хисе белән сугарылган...

Әкияттә ачлы-туклы яшәп яткан Ир белән Хатын тоталар да Кәҗә белән Сарыкны урманга куып чыгаралар... Ышанасы килми! Соң, егетләр, кайсы гына хәерче һәр килосы айлык пенсия хакына торган ике түшкә итне күрәләтә урманга чыгарып ташласын?! Юк, куып чыгармаган! Кәҗә белән Сарык үзләре чыгып качкан, хуҗаларының изүенә түзә алмыйча! Ник качмасын бичара хайван? Сарык, мескен, үзен шашлык итеп ашаганнарын көтеп ятсынмы? Кәҗә дә кача. Көнгә бер тапкыр ашатып, көне-төне имиеңне кармалый башласалар, чит илгә чыгып качарсың! Әле дә ярый Кәҗә халкы урлаша белә. Урлаша белгән хайваннар әйбәт яши безнең илдә! Сарык та, батыраеп, Кәҗәгә ияргән, тукта, чү, кешечә яшәп булмасмы дигәндер инде...

Халык әйтә: Кәҗә тәкәсенә Сарык иярмәс, ди. Ә бу әкияттә киресенчә, Тукайның Кәҗә белән Сарыгы ничек кавышканнар соң? Хәер, шагыйрь – чын әкият остасы. Әкиятләрдә бар да мөмкин... Аккошны яратсаң – сылу кызга әверелә, Бакага өйләнсәң – Хан кызы булып чыга, Камырдан әвәләп батыр малай ясыйсың... Ә чынбарлыкта исә, бөтенләй киресенчә... Хан кызы дип өйләнсәң, Аждаһа булып чыга, Асыл егет, ир булгач, Дуңгызга әверелә, ә малай ясаганчы әле тугыз ай буе камыр әвәләргә туры килә...

Г.Тукай әкиятләрне яратып яза. Ул демократлар кебек алдый, коммунистлар кебек куркыта, президентлар кебек юата. Аның әкиятләре күп түгел. Тукай чаманы белә. Юкса матур киләчәк турында күпме әкият сөйләргә була инде халыкка?!

Ярый, сүз башына әйләнеп кайтыйк... Кәҗә белән Сарык, ямаулы капчык асып, спонсор эзләп киткәннәр. Капчыктагы бүре башын да ачыкларга кирәк. Каян килгән ул?

Моңарчы татар әдәбияты тарихында бүреләрне суеп ашап, башларын капчыкка салып йөрү очраклары юк иде. Минемчә, бүгенге бизнесменнар, рэкетирлар, диллерлар һәм киллерларга охшарга тырышып кына Кәҗә белән Сарык теге капчыктагы бүрене терелэй тотып ашаганнардыр. Нишлисең бит, базар урманының үз законы бар... Тукайның чак кына әүлиялыгы җитеп бетмәгән: Татарстан байрагында бүреләр нәселе – Ак барсны күрә торып, теләсә кайсы Сарыктан Бүреләрне обижайть иттермәскә иде...

Әкият дәвам итә. Кәҗә белән Сарык бер аланга килеп чыга. Алан уртасында зур учак. Ә учак тирәсендә өч-дүрт бүре 8 Март көнен бәйрәм итеп утыра. Асылмалы казанда ботка пешә. Ләкин ботка итсез! Г.Тукай монда бүре мафиозникларның саранлыгыннан әче сарказм белән, ягъни итсез ботка белән көлә!

Боткага ит булды дип сөенәсе урында Бүреләр мафиясе Кәҗә белән Сарыкны ташлап кача. Ни өчен? Тукай үзе бу сорауга болай дип җавап бирә:

> Асраганнар бер Кәҗә берлә Сарык –
> Болар булган берсеннән-берсе арык, –

ягъни Казан тирәсендәге колхозларда мал-туар бүреләр куркырлык арык булган дияргә тели автор. Һәм ялгыша. Бүре сөяктән курыкмый, иптәшләр. Әкиятне алга таба укысак, без чын җавапны да табарбыз:

> Микикики, микикики, микикики,
> Капчыктагы бүре башы бит унике...

Аңлагансыздыр, Кәҗә белән Сарык рэкетирлар була! Алар шушындый янау белән бүреләрне куып, урман хуҗалыгын берүзләре хосусыйлаштырып куя.

Тукай Кәҗә белән Сарыкны олылап әкиятнең буеннан-буена исемнәрен баш хәрефләр белән яза. Шагыйрь ни әйтергә тели?

Бүреләр мафиясенең боткасын татыгач, Кәҗә белән Сарык өйләренә, ягъни элеккеге хуҗаларына кайтырга һич теләми. Алар хәзер үзләре хуҗа. Талау кәсебе белән көн итә башлагач, Кәҗә белән Сарык хәйран баеп, Кәҗәбез – «Козел», сарыгыбыз «Баран» булып, кысык күзле машиналарга гына утырып йөрерләр. Идел буенда бюджет акчасына өч катлы коттедж күтәрерләр. «Сарык» акционерлык җәмгыятендә Кәҗәбез генераль директор булыр, хайваннар җыенында сайлауларда катнашыр. Һәм без алар каршына буш капчык күтәреп киләсе кешеләр...

Кәҗә белән Сарык әкиятенең азагы юк. Ул кинәт өзелә. Бүгенге көн турында язылганга күрә цензура кискәндер инде. Шунысы билгеле: тора-бара Кәҗәнең кулы артык озынайгач, налог инспекциясе хезмәткәре – Былтыр – аны бүрәнә ярыгына кыскан...

Хәер, монысы инде башка әкият...

# УРТАДА КЕМ?

Уртада рәхәт.

Бәхетле кеше уртада яши белә...

Һәрнәрсәнең кыл уртасы бар. Картлыкны макта, яшьлектә яшә, күлгә соклан, диңгезгә кер, Туган ил дип сайра, чит илдә тор.

Безнең бәхет яшәү белән үлем арасында. Ачка үтермәсләр, артыгын бирмәсләр. Акчаң булса – талыйлар, әҗәткә сорап килсәң – каргыйлар. «Жигули»да йөрсәң, өен саткан, диләр, иномаркада йөрсәң, илен саткан, трамвайда күрсәләр, кире кайткан, диләр. Бассаң, утырган, диләр, утырсаң, баскан, диләр... Менә шуңа күрә бәхетле кеше уңга каермый, сулга карамый, уртада гына йөри. Левый түгел ул, правый түгел, большевик түгел ул, меньшевик түгел...

Бәхетле буласың килсә, утка керә, бозга сикермә! Июль чилләсендә пешмә, гыйнвар раштуасында өшемә. Урталыкта – утыз алты да алты градус. Бу – рәхәт яшәү дип атала. Дөрес, этәч белән тавыкның

тән җылысы кырык ике градус, чеби чыгарыр өчен табигать тере инкубатор ясаган. Шуңа күрә ир кешенең температурасы кырыкка җитә башласа, хатыннары утка төшә.

Бәхет турында хыялланган кеше һәрвакыт урталыкны эзли. Кар яуганда, яңгырны мактый, яңгыр яуса, кар сорый... Кыш уртасында утыбыз сүнә, җәйгә чыккач, су бетә.

Калын киенеп йөрсәң, кышкы салкыннарны җиңәргә була, ә июль чилләсеннән котылу юк, кояш сине теләсә кайдан эзләп таба.

Узган җәйне генә алыйк...

Июль чилләсе дөньяга утлы күмер сипте, һава кипте, болытлар төтенгә әверелде. Су тирәсенә йөри торган поездларга билетлар югалды, путевкалар дөрләп янды. Су урлау очраклары күбәйде. Синоптиклар, һава торышын әйтергә куркып, диңгез буйларына таралышты. Күләгәләр кырык ике градуска җитте. Базарда сатылмый яткан йомыркалардан чебиләр чыкты... Коты алынган ирләр суыткыч эченә кереп качты. Фатирында кондиционеры булган тол хатыннар барысы да кияүгә чыгып бетте.

Кеше гәүдәсенең сиксән проценты судан гына тора, ди. Калай сушилка кебек трамвайларга төялгән йөз литрлы агайларның бөтен җирләреннән су акты, туфли эченә тулды.

Олы юл чатында онытылып калган гаишниклар, «узышырга ярамый», «кырыктан ары кумаска» дигән түгәрәк калайларны су тирәсенәрәк күчереп куйдылар.

Авылларда чишмәләр коргаксыды. Фермаларда сөткә кушарлык та су калмады. Кайнар аракыдан җиңеләйгән ирләр үз сыерларын көтүгә чыгармыйча, савылмаган сөтләре оемасын өчен, кар базына төшереп бәйли башладылар.

Мич чыгаручы Сафуан җиде баласының күз алдында каравыллар кычкырып эшсез калды.

Тракторлары ватылып, чиллә тоткынында яткан агайлар Сафура бураннарында адашып үлгән авылдашларыннан көнләштеләр.

Яңгыр чакырабыз дип, районнар, үзара су сибешеп, айлар буе «Карга боткасы» уйнады. Тик яңгыр барыбер яумады. Соңыннан гына белдек, «Карга боткасы» дигән уен су сатучы бизнесменнар оештырган сәүдә булган икән.

Ниһаять, июль чилләсе үтте... Көннәр сүрелде.

Көзге яңгырлар әкренләп кар буранына әверелде.

Раштуа суыклары башланды...

Фатир җылыткыч торбаларны бәс сарды. Халык утын яга торган мич тирәсенә сыенды. Шома егетләр мич чыгаручы Сафуанны урлап алып киттеләр. Янына ике тән сакчысы куеп авылдан авылга, морҗадан морҗага, марҗадан марҗага йөрттеләр. «Рәсәйнең атказанган мич чыгаручысы» дигән мактаулы исем алып бирделәр.

Сырма хәтлек кенә апалар, сырган чалбар хәтлек кенә агайлар берләшеп синоптиклардан үч алырга җыендылар.

Базарда сатылмый яткан йомыркалар боз ядрәләренә әверелде. Коты алынган ирләр сыңар бияләй эзләде.

Танышу-кавышу турындагы белдерүләргә «кыш чыгарлык утыным бар», «керосин лампасы, газ колонкасы, кара мунчам исән» дигән җылы сүзләр өстәлде. Кондиционерлы түткәйләрнең йортка кергән ирләре качып бетте.

Калай трамвайларда кондукторлар өшеп үлде.

Икешәр кат итек кигән гаишниклар теге түгәрәк калайларны бистро, кафе, кыстыбыйный тирәләренә алып кайтты.

Хуҗалыклар үзенчә чиләнде.

Фермадагылар сөткә кар куша башлады. Базар тирәсендәге авылларда сыер җилененә мамык шәлләр урадылар. Яңа сауган сөт эчеп салкын тидерүчеләр күбәйде.

Кибет тирәсендәге кызлар күбеге бозланып каткан сыра шешәсен бушата алмыйча газап чикте.

КамАЗ юлында машиналары сүнеп калган ирләр җәй җиткәч кенә әйләнеп кайтты.

Су сатучы фирмалар җыйнаулашып кар көрәргә чыкты... Бер атнага кайнар су бетә дигән хәбәр таралгач, шәһәр халкы ун көнгә җитәрлек кайнар су җыя башлады.

«Йа Хода! Җылы көннәреңне кызганма!» дип ялвара торгач, ниһаять, Ходай ишетте... Раштуа суыкларыннан соң ярты ел үтүгә, тагын июль чилләсе килде...

Ә кемнәрдер уртада!

Язмыш безне кышкы кырыктан алып, җәйге кырыкка ыргыта, кырыкка төрләндерә: йә утка сала, йә бозга төрә. Йә Себергә олактыра, йә кызган табага бастыра. Йә яндыра, йә күмә... Һәм рәсемең астына туган елың белән киткән елыңны сызык аша язып куя. Без эзләгән урталык әнә шул сызык кына...

# ЭЧТӘЛЕК

Уен *(Роман)* ..............................

**Хикәяләр һәм юморескалар**

Сунар вакыты .............................
Яшьлек белән сөйләшү ........................
Авазлар ................................
Куен җылысы .............................
Карурманда кара песи ..........................
Югалган малай язмалары ........................
Яшел читлек ..............................
Дүртенче раунд ............................
Тимергали бабай хикәяте ........................
Таллар кичерер микән? *(Юлъязма)* .................
Бәхетле кеше ..............................
Капчык төбе ..............................
Көмешем ................................
Көзнең соңгы төнендә .........................
Сансыз фиргавен ............................
Мәхәббәт харап итте... .........................
Матайлы кызлар ............................
Әҗәт булыр... .............................
Шәлинский бәрәңге ..........................
Яңгырлы сабантуй ...........................
Тәнәфес .................................
Унике ватык компас ..........................
Чормадагы Фәридә ..........................
Көн һәм төн ..............................
Телеңне күрсәт... ...........................
Айга менәсем килә ...........................
Кем түбәсенә ниттең?! .........................
Күкерт мае ...............................
Бака каргышы .............................
Хуш, әфәнде! ..............................
Каза намазы ..............................
Ләйсән әкият тыңлый .........................
Нихәл дип сорамагыз... ........................
Хайваннар дөньясында ........................
Кырыклы машина ...........................
Котлы-ботлы ..............................
Дус бар, дошман бар... ........................
Хәйрия сандыгы ............................
Тагын күпме нитәрләр?.. .......................
Каты шелтә ..............................
Козел белән Баран ...........................
Уртада кем? ...............................

Литературно-художественное издание

**Каримов** Камиль Адгамович

# ИГРА

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Кәримов** Камил Әдһәм улы

# УЕН

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.З.Әүхәдиева, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.10.2010.
Форматы 84x108 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 19,32.
Тиражы 3000 д. Заказ О-1470.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.